ISSN 0206-4189

Казан утлары

3.2004

САЙЛАУЛАРДА—ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ



Казан утлары
Qazan utları

2004

3

(977)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы

БАШ МӨХӘРРИР

Равил Фәйзуллин

ИДАРӘ

Харрас Әюпов
Зилә Вәлиева
Мөдәррис Вәлиев
Фоат Галимуллин
Тәлгат Галиуллин
Миркасыйм Госманов
Алмаз Гыймадиев
(җаваплы сәркатип)
Флүс Латыйфи
(баш мөхәррир урынбасары)
Мирза Мәхмүтов
Туфан Миңнуллин
Хатыйп Миңнегулов
Гәрәй Рәхим
Факил Сафин
Ренат Харис
Зиннур Хөснияр
Розалина Шаһиева

Мөхәррирләр: **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

Гамәли хезмәткәрләр: **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Диләрә Максутова, Радик Вәлиев, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
Исәп-хисап бүлеге: **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
Факс — (8432) 43-56-12.
E-mail: kazanutlari@telebit.ru.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

ЗӨЛФӘТ. Актарылды дуамал бу гомер... Шигырьләр 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Карга короле. Роман 9
Нәҗибә САФИНА. Өзелгән яфрак ярасы. Шигырьләр (*Н. Гамбәр кереш сүзе белән*) 78
Розалина ШАҺИЕВА. Ефәкчеләр юлы. Кәрван чаңы. Шигырьләр (*Р. Гаташ кереш сүзе белән*) 128

ЯЗУЧЫ ВАХИТ ИМАМОВКА 50 ЯШЬ

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Имам 84
Вахит ИМАМОВ. Япон татары. Повесть 87

ПУБЛИЦИСТИКА

Мөнир АБДУЛЛИН. Җире барның җиме бар 134

ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"

Рәшит ФӘТХЕРАХМАНОВ. Татарга сатма матбугат 142

ФӘН

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге 150
Флера САФИУЛЛИНА. Татар шигъриятендә яңа сурәтләр 155
Флера ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ. Коръән Кәримнең татар мәкаме 177

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Татар-чуваш бәйләнешләре 165

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

70 — Мәгариҗ (*Баскыч буйлап*) сүрәсе 172
71 — Нух (*Нух*) сүрәсе 173
72 — Җен (*Җен*) сүрәсе 173
73 — Мүзәммин (*Ябынган*) сүрәсе 175
74 — Мүдәссир (*Бөркәнгән*) сүрәсе 175

"ЯЛКЫН" ЖУРНАЛЫНА — 80 ЯШЬ

Айсылу ГАЛИЕВА. Сиксәндә дә ул бала 180
"Казан утлары" архивыннан 184
Берлекнең яңа әгъзалары 183
Авыр югалтулар 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан 188

ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Казан патшабикәсе Сөембикә 192

В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Журнал выходит один раз в месяц

"Проза и поэзия": роман Р. МИРХАЙДАРОВА "Масть пики", повесть В. ИМАМОВА "Татарин-Японец" (*с предисловием М. Хабибуллина*), стихи ЗУЛЬФАТА, Н. САФИНОЙ (*с предисловием Н. Гамбара*), Р. ШАГИЕВОЙ (*с предисловием Р. Гаташа*).
"Публицистика": статья М. АБДУЛЛИНА посвящена проблемам землепользования в Татарстане.
"Дискуссия": "Герой нашего времени": статья Р. ФАТХРАХМАНОВА "Литература и судьба национальной печати".
"Наука": "Словарь нации", подготовленный А. ТИМЕРГАЛИНЫМ, статьи Ф. САФИУЛЛИНОЙ "Новые образы в татарской поэзии", Ф. АХМЕТОВОЙ-УРМАНЧЕ "Татарские мотивы в озвучении Корана".
"Дружба литератур — дружба народов": статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА посвящена связям татарской и чувашской литератур.
"Коран на татарском языке".
К 80-летию журнала "Ялкын" статья А. ГАЛИЕВОЙ.
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: портрет работы художника К. МУЛЛАШЕВА "Казанская царица Сююмбике"; поэтесса Ф. МУСЛИМОВА.

IN THIS ISSUE:

The magazin edits monthly

Prose and poetry: novel by MIRKHAIDAROV «Spade Suit», story by V. IMAMOV «Tatar-Japanese» (with M.Habibullin's foreword), verses of ZULFAT, N. SAFINA (with N.Gambar's foreword), R. SHAGIEVA (with R.Gatash's foreword).
Publicism: article by M. ABDULLIN devoted to problems of land tenure in Tatarstan.
Discussion: Hero of our time: article by R.FATHRAKHMANOV Literature and destiny of national press.
Science: prepared by A. TIMERGALIN, Dictionary of the nation, articles by F. SAFIULLINA, New images in the Tatar poetry, F. AKHMETOVA-URMANCHE, Tatar motives in Quran.
Friendship of literatures—friendship of peoples: article by F. GALIMULLIN devoted to connections of the Tatar and Chuvash literatures.
Al Quran in the Tatar language.
To the 80-anniversary of magazine «Yalkyn» article by A. GALIEVA.
New members of the Union of writers.
From a photo archive of the magazine.
Diary of public-cultural life.
On our covers: portrait of «Kazan Princess Syumbike» the work by artist K. MULLASHEV; poetess F. MUSLIMOVA.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 18.02.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8014. Заказ Э—90
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.

Зөлфәт

АКТАРЫЛДЫ ДУАМАЛ БУ ГОМЕР...

Алгысу

**Ургый-ургый чәбәләнә вакыт
Җилле күккә менгән төтендәй...
Бу сүзләрем сезгә ирешкәндә
Сез булмассыз инде... бөтенләй!**

**Ә шулай да сезгә сөйлиселәр
Һаман ташып тора күңелдән.
Күңел—тирәк... Ябалдашы—хыял,
Тамырлары
чынга күмелгән.**

**Шуңа күрә тере дөнья белән
Үле дөнья тоташ бу җанда—
Җан иясе һәрчак, һәрвакытта
Сират күперендә торганга...**

**Актарылды дуамал бу гомер,
Тузгып-тузгып еллар сүтелде,
Учак белән Галәм арасында
Актарылган төтен шикелле.**

**Алгысыды күңел, акыл исә
Аңламакчы булды, кызыкты:
Ул учакны кем тергезде икән
Һәм төтенен кемнәр тузгытты?**

**Тәндәге җан үзенекен итә:
—Тән күмелер... Ә мин—күмелмәм!
...Галәм төбендә шау учак яна,
Таша әйтер сүзләр күңелдән...**

**Ә шулай да... кем ут салды икән
Шул мәңгелек тере учакка?
...Бу соравым сезгә барып җитәр...
Ләкин... сез булмассыз ул чакта...**

Зөлфәт (1947)—шагыйрь; "Утлы бозлар", "Адашкан болыт", "Йөрәгемне былбыл чакты" һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.

Болгавыр бер шашкын ташкын булып
Айкый заман, чайкый гел генә...
Юылганда җаннар, убылганда
Актарыла хисләр, күмелә...

Язмыш дучар иткән афәтме бу,
Әллә бер сынаумы җаннарга?—
Әверелеп йә бер фәрештәгә
Йәки комсыз, кансыз җанварга

Ни кыйратыр икән яшь кешесе
Яңа чорның, яңа дәвернең?—
Романтик бер җилкәнме бу заман
Йәки... хыял өчен каберме?

Калды яшьлек ташкын уртасында...
Актарылып, дулап агар ул!
Кешедәшләр күреп аһ итәрлек
Ниләр җуяр, ниләр табар ул?

Берүк кенә, яшьлек, хыялларның
Саф-садәсен ташкын алмасын!
Китеп хыял, аның урынында
Сөмсез-юньсез хисләр калмасын!

Берүк кенә, яшьлек, берүк кенә,
Язмышларны чоңгыл упса да,
Булмастайны булдырмакчы булган
Яшьлек булуыңнан туктама!

Гел аръякка ашкынучан хыял
Болгавырда акса, буталса,
Ак җилкәнне җилләр йолкып алса,
Хәлсезләнеп кораб тукталса,

Диңгезләргә алгысыган күңел
Булып калса бары мал колы
Һәм яшьлекне чолгап дуламаса
Дуамал шул сөю ялкыны,

Ни генә соң калыр синнән, яшьлек?
Яшәрбез, йә, кемгә дәшеп без?
Яшьлек, синсез киләчәкләр сөмсез,
Тарих—тарих түгел яшьлексез!

Иман кайта, дибез... Иман гына
Яңартачак, дибез, дөньяны...
Яңартачак дөньялыкны — яшьлек
Һәм
мәхәббәт—
яшьлек иманы!

...Айкап ала, чайкап сала заман
Болгавыр бу шашкын ташкынга...
Хыял имин булсын! Җилкәннәргә
Җилләр тулсын давыл каршында!

Берүк, яшьлек, шулай булсын ла!..

Чиксезлеккә тын тәрәзәм ачык...
Уйларымны минем җилгәрде
Салкын йолдызлардан кубып искән
Җан өшеткеч Вакыт җилләре.

Соңгы мәле шундый булыр, ахры,
Минем аңлаешсыз гомернең—
Ташланырмын беркөн биек ярдан
Төпсез чоңгылына шигырьнең!

Борынгыда очкан кошларны мин
Эзләреннән таныйм күктәге!—
Димәк, дөнья миңа сабак бирде,
Димәк, гомер бушка үтмәде!..

Киләчәктә очар кошларны да
Эзләреннән таныйм... Һәм укыйм!..
Кош эзләре—шигырь юлы ласа!
Шигыре бу бөек Вакытның!..

...Чиксезлеккә тын тәрәзәм ачык...
Уйларымны минем җилгәрде
Кайнар йолдызлардан кубып очкан
Җан көйдергеч Вакыт җилләре!..

Өермә

Табигать үзе безгә гел
Ым кага да ым кага!—
Уй ташкыны кайчагында
Акмый дулап. Тын кала...

Гөлчәчәкләр ул болында
Дулкын да дулкын иде...
Күбәләкле иде болын...
Дөньялар тып-тын иде...

Низаглы, даулы дөньяга
Кул селтәмәк булдым да
Киттем
хәтер өермәсе
Өергән шул болынга!

Хәтер шул аулак болынга
Вакыт кулын тидергән...
Шомлы өермә елларны
Өергән шул, өергән!

Еллар узды... Таныр микән
Мине—уйнак колынны?—
Диеп эзләп килгән идем
Шул бик ерак болынны...

Ул болынның тан җилен дә
Хәтер саклаган иде!
Ләкин...
хәтерне дә таптап
Вакыт атлаган инде!—
Без печән чапкан болынны
Урман каплаган инде...

Ярый әле шул болын бар
Гомергә сагынырлык!
...Ялгыз бер күбәләк булып
Бу җаным кагынырлык...

Толпарны тоткан малай

Ерактан ук атлар таный иде—
Бар иде бит безнең шундый чак!
Төшләремдә җилә чабышкылар,
Юргалый ак юрга—аргамак!

Аргамакмы, юрга, толпармы ул—
Бабайларга "малкай" булды ул,
Атлар янында гел бөтерелгән,
Күңеленә бәйге җене кергән
Малайларга "бахбай" булды ул!

Күңле уйнаклаган ир-егеткәй
Юл югалтып чапкан чак булды.
Андый чакта сер сыйдырыр бер дус—
Көмеш тояк, толпар ат булды...

Һаман ат уйнаклый шигыремдә...
Уйнакласын... сулыш ачылсын?..
Толпар тоткан малай—мин үзем бит!
Хет шигырьдә күңел басылсын!

Гел тымызык кына көннәр килеп,
Сөмсез-өнсез чакта дөньясы—
Күндәм, ипле шигырь юлларымны
Пыр туздырып толпар уйнасын!

...Аргамакмы, юрга, толпармы син,
Чабышкымы... сабый колынмы—
Җилдер генә! Язгы болын ит син
Гомер юлым—шигырь юлымны!
Җилдер генә!

Хикмәт

Аңлыйсылар килә төсләр серен...
Мең төсмерле, мәгәр, төс сере!—
Ләкин шуны белергә бик тели,
Күңел тели, рәхмәт төшкере!

Җавап көтә күңел йолдыздан да,
Җем-җем җемелдәгән чыктан да
Сызылыплар кояш баеганда,
Моңсуланып кояш чыкканда!

Ни могҗиза кичнең иртәнгесе
Һәм дә һәр иртәннең кичкесе!
Дөньялыкның бөек көчедер төс...—
Серен ачмый безгә төс көче!

Нидер сизенгәндәй була күңел...
Һәр төсмердә—язмыш билгесе!

Серен ачмый көннең төнгесе
Һәм
Серен саклый төннең көнгесе...

Нидер сизенгәндәй була күңел...
Ачыласы серләр ни хәтле!
...Әмма ләкин...
ачышларда түгел,
Мәңге ачылмаслык ачышларны
Сизенүдә дөнья хикмәте!..

Ахыр

Еллар өйләдән авышкач
Уй бүтәнчә ачыла:
Карт бөркет булганчы, дисең,
Яшь чыпчык булсаңчы ла!

Тәкәббер, горур күңелләр
Шулай үзгәрә микән—
Бу дөньяда тагын бераз
Яшисе килгәнлектән?

Юкса, ашап туймаганны
Ялап туймассың, диләр,—
Яшим дип, чүптә казынып
Хур булырсыңмы, юләр?!

Күтәрсен биек талпыныш
Вакытлар агышында,—
Туктыйсы йөрәк туктасын
Иң биек очышымда!

Әйтсеннәр: "Ни булды моңа?
Нык иде бит югыйсә!—
Чама югалткан карт бөркет,
Үзен белештермичә!.."

...Ялварам, соң мәл хакында
Уйлар уйлаган саен:
Күктә үлгән карт бөркетнең
Язмышын бир, Ходаем!..

*

Мәхәббәтне һәм шигырьне
Кеше
Ихлас дога белән тиң күргән...
Иляһ шуны саф һәм бөтен килеш
Күңелләргә безнең җиткергән!

Һәммәсе дә табигатьтә кямил,
Бар иткән ул белеп, тигезләп...
Шуңадыр шул
җанны сискәндергән
Мәхәббәт һәм шигырь —
игезәк.

Шушы дога белән тәмамлармын
Соңгы мәлен яшәү дигәннең...
Яшәү булдымы бу? Әллә инде
Илһамланып бер төш сөйләдем?..

2000—2003.

Рауль Мирхәйдәров

КАРГА КОРОЛЕ

РОМАН

Дүртенче кисәк

ЧИМКЕНТ ЮЛЫНДАГЫ КАТРАН[1]

“Лидо” ресторалы мең тугыз йөз сиксән сигезенче елны каршы алырга әзерләнә. Иртән иртүк дизайнерлар, рәссамнар, яктыртучылар, витрина бизәүчеләр, автоматика һәм электроника, акустика һәм яктылык музыкасы белгечләре мәш килде. Нәргизнең фантазиясе чиксез, ниләр генә эшләп бетермәде, әмма барыбер Ташкентка гастрольгә килгән Лали исемле атаклы һинд биючесен Яңа ел кичендә “Лидо”да чыгыш ясарга күндерә алды. Өч көн инде җитди кыяфәтле япь-яшь егетләр зал уртасында әйләнеп торачак гаҗәеп зур чыршыны урнаштырып маташалар. Чыршы шулкадәр зифа, шулкадәр төз сынлы иде, хәтта бизәлмәгән көйгә дә аннан күзне алырлык түгел. Чындырмы, ялгандырмы, анысы билгесез, Фәйзиев аны хәрби ведомство аша тапкан, гигант “Антей” самолетында Себердән кайтарткан, дип тә сөйләделәр.

Нәргиз “Лидо”га өйлә алдыннан гына килде, аңа кадәр банкта булырга, ресторанның узып баручы елдагы финанс эшләрен тикшереп, талкып чыгарга өлгерде.

“Лидо” ачылырга егерме минутлап кына калып килә, шунлыктан, ресторанның гадәти эшенә комачауламас өчен, залны бизәүчеләр эшләрен тәмамларга җыена иде инде. Башкарылган хәтле эшләрне күздән кичергәч Нәргизнең сөенече эченә сыймады. Шөкер, беркемне дә өйрәтәсе, куалап, ашыктырып торасы юк, һәркем үз эше белән мәшгуль, дип уйлап куйды ул. Барысы да үзен яхшы яктан күрсәтергә тырыша. Киләсе елга да контракт төзисе барлыгын онытмыйлар, күрәсең. Әле алда Сигезенче март бәйрәме дә бар. Дөрес, залны бизәүгә акча җәлләмәделәр, чөнки “Лидо”га бәйрәм көннәрендә керү түләүле, билет хакы шактый ук кыйбат булып, аңа бизәү эшләренең бәясе дә кертелә иде. Яңа ел кичәләре унөченче гыйнварга кадәр бара, унөчендә исә тантана яңа елныкыннан ким булмый, чөнки күпләр

[1]*Катран*—карта уйнау йорты.

Ахыры. Башы 1–2 саннарда.

ул көнне яңа елга керүнең соңгы йомгаклау көне саный. Өстәлләргә заказны алдан ук биреп куялар, хәтта көздән үк. Дөрес, резерв урыннар калдырыла калдырылуын, ләкин алар гына житми, өстәмә рәвештә яңа өстәлләр куярга туры килә. Әнә, бүген дә алар бер-берсенә терәлеп үк тора диярлек. Яңа елны үткәргәндә сонга калучыларнын бер өстәл өчен мең сум түләргә әзер икәнлекләрен дә Нәргиз белә иде. Чөнки "Лидо"га, гадәттә, бай клиентлар гына йөри.

Залны тагын бер кат игътибар белән карап чыккач, канәгатьлек хисе тагын да арта төште һәм ул смена башлыгына быелгы премия фондының ниндилеген әйтми булдыра алмады. Кабинетына кереп барганда ул залда, кухняда, хәтта цехларда эшләүчеләрнең шатланып кул чабуларын, сөенешеп бер-берсен тәбрикләүләрен ишетеп калды. Нәргиз үзе дә шат иде, банк документларын өстәлгә таратып салды да изге эшне озакка сузмыйча премия фондын исәпләргә керешә.

Бер сәгатьләп исәпләп-чутлап утыргач кына акчаны бүлүнең ике-өч варианты кирәк булачагын аңлады. Житмәсә, моны Фәйзиев белән дә килештерергә кирәк булачак иде. Төшке аш вакыты житеп килә иде инде, Нәргиз, кәгазьләрен бер читкә этәреп, дизайнерлар тарафыннан стена белән бер төсле итеп, яшереп ясалган ишектән янәшәдәге бүлмәгә үтте. Бу бүлмәнең ни максатларга хезмәт итүен бер сүз белән генә әйтеп бетереп тә булмас иде. Почмакта Шубарин аңа туган көнгә бүләк иткән "Шарп" телевизоры тора, эссе көннәрдә ятып хәл алу өчен диванга хәтле бар. Бүлмәнең ванна, гардеробише башка уңайлыклары да житәрлек. Ләкин, шулай да, аны шәхси бүлмә дип әйтү дә дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. Чөнки ресторанда артык күзгә ташланырга теләмәгән кунакларга еш кына монда табын да әзерлиләр. Кыскасы, зәвекъ белән бизәлгән, затлы мебель урнаштырылган киң вә иркен апартамент иде бу. Нәргиз төшке ашны да шунда ашый.

Кулларын юып, эчке телефоннан төшке ашка заказ бирәм дип, кабинетына әйләнеп керүгә өч таныш булмаган кешене күреп алды. Аларның берсе—яшьрәге, озын буйлы, үгез муенлысы ишек төбендә тора, калганнары, бер-берсен бүлдереп, көлешә-көлешә стенадагы япон гейшалары, ымсындыргыч позадагы манекенчы кызлар төшерелгән япон календарен карый иде.

—Сезнең яшерен бүлмәгез дә бар икән әле,—дип усал елмайды гейшаларны караучылардан берсе. Модалы киенгән бу адәм арттан караганда яшь тоелса да, борылгач аның кырыклар тирәсендә икәнлеге ачык күзгә ташланды. Бу кыяфәтсезне Нәргизнең бернична тапкыр "Лидо"да күргәне бар иде кебек, ялгышмаса, ул акча туздыруны чүпкә дә санамаучыларның берсе. Нәргиз аларны Яңа ел кичәсенә билет алырга кергәннәрдер дип фаразлап, өстәле янына узмакчы булган иде, "үгезмуен"нарның өченчесе юлына аркылы төште (ул аларны эчтән генә шулай дип атап өлгергән иде инде), стена буендагы диванга таба ымлады.

—Сез нишлисез? Ни кыланганыгызны беләсезме?—дип, каты гына сорады Нәргиз, ләкин пыяла күзле адәмнең кулында ялтыраган пычакны күреп телен тешләргә мәжбүр булды.

Нәргиз костюмын төзәтеп куйгандай итте, күзгегә күз төшерде, чәчләренә кагылып алды, аңа ничек тә вакытны сузарга, ничек тә өстәл янына барып утырырга кирәк иде. Анда яшерен кнопка бар, сиздерми генә, тез башы белән генә кагылып китсә дә, аңа ярдәмгә килеп житәчәкләр. Ләкин өстәл янына утыру мөмкинлеге югалды. Дивандагы ир кеше, мөгаен башлыкларыдыр ахрысы, янына утырганда ул үзен кулга алып өлгергән иде инде, тыныч тавыш белән әйтте:

—Шундый юл белән Яңа ел кичәсенә билет алырга җыенасызмы?

Рәттән утыручы ир көлеп жибәрде, кесәсеннән "Мальборо" пачкасы тартып чыгарды беркемгә дә атап әйтмичә үзалдына мыгырданып куйды:

—Гажәп хатын, кытай, япон кызларыннан бер дә ким түгел, яхшырак булмаса әле, иң мөһиме, бернидән дә курыкмый икән.

Нәргиз үпкәләгән кыяфәт чыгарып торып басарга, өстәл янына узарга ниятләгән генә иде, ир кеше аны кулыннан эләктереп алды, урынына утыртты:

—Мине Лютый дип йөртәләр, Толик Лютый, бәлки ишеткәнең бардыр, синең "Лидо" ресторанны минем биләмәгә керә, ул миңа үтерелгән Җәләлдән мирас булып күчте. Безнең җыен шулай хәл итте, хәзер минем ник килгәнемне аңладыңмы инде?

—Юк, аңламадым. Бәлки син биләмә хуҗасыдыр да, ә минем монда ни катнашым бар, егетләр?

—Катнашың шунда,—дип сүз катты янәшә утырган Лютый.—Райкомга, райисполкомга сәмәнне график буенча ташыйсыңдыр әле, безгә дигән өлешне дә онытма!

—Ә сезгә ни өчен?—дип, усалланып сорады Нәргиз.

—Тегеләргә ни өчен түләсәң, безгә дә шуның өчен,—дип, тыныч кына җавап бирде Лютый.—Алар сиңа суларга ирек бирәләр, без дә шулай, юкса кислородны ябуыбыз да бар.

—Сез аны ничек ябасыз? Фондларны кисәсезме, спиртлы эчемлекләрсез калдырасызмы?

—Юк, бу көндез эшли торган райком эше, ә без эш башы итеп бер егерме менлек "погром" оештырырбыз, бер ай буе ремонтлап бетерә алмассыз. Шуннан соң да акылга килмәсәң, кызыл әтәч җибәрербез. Биләмәләрдә бер син генә ясак түләмисең, мин инде иң соңгы кооператорга хәтле салым түләтәм.

—Бәйрәм көнне, яңа ел алдыннан килеп кешенең кәефен бозу оят түгелме?—бу сүзләрне Нәргиз шулкадәр ачу белән һәм ихластан әйтте, хәтта Лютый да бер мизгелгә югалып калды. Шуннан файдаланып, Нәргиз аягына басты һәм куршесе аңга килгәнче, әйтә салды:—Житди мәсьәлә бу, түләргә туры килер, мөгаен. "Пекин"нан уйгурлар, Җину паркыннан яһүдиләр кемгәдер түлиләр, дип ишеткәнем бар иде. Ләкин мин бер үзем генә түләргә җыенмыйм. Эчемлекләр, азык-төлек, җиләк-җимеш, кабартма бирүчеләргә дә хәбәр итәргә тиешмен. Ләкин сезнең көегезне көйләп, башкаларның бәйрәм кәефен бозарга җыенмыйм, түзегез, Яңа ел кичәләрен тыныч уздырырга ирек бирегез, шуннан соң килерсез, шунда гарантияле житди сөйләшү булыр да. Киләсе көнегезне әйтегез дә тәпиләгез, эшләрем муеннан, әле төшке ашны ашарга да өлгермәдем.

Унбишенче гыйнварда кичен очрашырга булдылар, ләкин моннан соң да кунаклар китәргә ашыкмады. Нәргиз курыкмыйча сейфын ачты һәм шуның белән боларны тәмам үз ягына аударып бетерде, ике пачка бишлекне Лютыйга сузды:

—Бирәсе ясак өчен, расписка кирәкми, бәйрәмгә житәр дип ышанам.

Никадәр хафаланса да, Нәргиз бәйрәмдә беркемне дә борчып тормады, бары тик өченче гыйнварда, Артур Александрович төшке ашка кергәч кенә, "Лидо"га рэкитерлар килүен әйтте. Шубарин аңа түземлелеге өчен рәхмәт әйтте, алар белән үзен тыныч тотуын дөрес санады һәм унбишенә кадәр залга өстәмә өстәл куярга кушты. Ул өстәлдән директор кабинетына бару урыны яхшы күзәтелергә тиеш, иртәгәдән башлап монда үзенең дуслары белән Коста утырачак, ә швейцарны Ашотның туганы, Ташкентның җинаятьчел дөньясын яхшы белүче Карен алыштырачак. "Лидо"ның парадный ишегеннән Коста өстәленә сигнал җайланмасы үткәреләчәк. Артур Александровичның яман хәбәрне сабыр һәм үз-үзенә ышанып кабул итүе Нәргизне тәмам тынычландырды, күпме генә кыю кыланса да, Лютый белән очрашу аның башыннан чыкмый иде. Бар көчен, вакытын, энергиясен түккән ресторан Нәргизнең мәхәббәте һәм алдагы өмете иде бит.

Шубарин ресторанның башка хуҗаларын борчып тормады, кичен Коста белән Ашотны өенә чакырып алды, "Лидо"дагы хәлләр турында кыскача сөйләп бирде һәм тән сакчысына төрттереп әйтте:

—Ашот, миңа калса, хәзер шәһәр синең кулда түгел бугай,—диде.

Күп сөйләшми торган Ашот бу сүзләргә ярылып китә язды:

—Хәзер илдә берәр кеше берәр нәрсәне үз кулында тотамы? Узган ел "Ереван" рестораны янында Сашка Веселый белән Изя Либерман кооператорларга артык ясак салган өчен Нарик Кигряман белән Вәлине атып үтергәч, барысы да җимерелде бит. Ташкентка кем хуҗа икәнен шайтан үзе дә белми. Нарик барысын да авызлыклаган иде, һәр бөҗәк үз үләне төбенә кереп яшеренде. Җинаятьнең кайчан, ничек эшләнәчәгенә хәтле белеп тора идек бит. Хәзергечә азгынлык кая! Яшьләр тәмам бәйдән ычкынды, элекке хуҗаларны бар дип тә белмиләр, бүген җырла-бие, иртәгә өчен ишәк кайгырган. Барысын рәттән дер селкетәләр, абруйга, дәрәҗәгә карап тору бетте, караклыкның изге кануннарын, тәртип-кагыйдәләрен бар дип тә белмиләр. Ул гынамы, үз иптәшләрен тотып манчыйлар.

Нарик үләренә берничә көн кала миңа әйткән иде инде, Ташкентка, ди, бар җирдән ышпана җыела, Рәсәйдә мондагыча бай талау төшләренә дә кермәгән аларның. Хәзер бер йөрүдә йөз мең керерлек булмаса, кул пычратып та тормыйлар, ди. Талардай байлар исемлеген "наводчиклардан", хәтта милициядән дә сатып алырга була. Безнең яклар бүген—майлы калҗа ул. Дөрес, Мәскәүдә дә акча капчыклары аз түгел, Кавказда да җитәрлек, Әзәрбайҗанны әйтәсе дә юк.

Ләкин Кавказда караклар дөньясы текә, усал, алар биләмәләренә читләрне кертми, "йонлач сарыклар"ны үзләре кыркый. Артур Александрович, ипидер миңа, моңа кадәр беркемгә дә салым түләмәдек, хәзер дә түләмәбез. Дошманнарыгызны тез чүктерә белдек. Баштанаяк коралланган Ростов бандасын хәтерегезгә төшерегез әле, хәтта "шмайссер"лары да булышмады бит. Лютыйны да бөгәрбез. Аның ничә кешесе бар икәнен белмим белүен, тик җаен табарбыз. Сухроб мине Бармаксыз белән очраштырсын әле. Артем Парсегян Ташкентта төшеп калганнардан түгел. Миңа диган егетләре бар, үзе дә әзмәвердәй адәм, бергә-бер теләсә кемне буып ата... Бәлки безгә тегеләр белән маңгайга маңгай бәрелешергә туры килер. Шулаймы, Коста?

—Миңа нәрсә, мин һәрвакыт әзер,—дип куйды монарчы тып-тын гына утырган Коста.

—Болай итәрбез, Коста,—дип бүлдерде аны Шубарин.—Иртәгедән башлап "Лидо"да Нәргизне саклый башлыйсың, көн саен өенә озатып куя торган булырсың, ә төп планны Ашот белән Бармаксыз эшләр, аның Парсегян турында искә алуы шәп булды әле.

Коста белән Ашот китүгә, Артур Александрович Сенаторга шылтыратты һәм аның янына чәйләп алырга керәсе килүен әйтте.

Айның унбишендә, җомга көнне, алар рэкитерлар бандасы турында барысын да беләләр иде инде. Бандада ничә кеше икәнен дә, нинди машиналарда йөрүләрен дә, хәтта акча җыю көннәрен дә. Анысы айның унбишендә икән! Шубарин бандитларның мәнсезрәк бәндәләр икәнлеген дә уйлап куйды. Юкса, мәнле кеше җомга көнне—атна ахырында "эш"кә чыкмас иде. Киеренке вакыт, кызу-кайнар эшләрне атна ахырында эшләмиләр. "Лидо"да очрашуга ике сәгать кала Костага Лютый бандасының ике "Жигули"да акча җыеп йөрүен хәбәр иттеләр. Кооператорларны боргычлыйлар, фарцовщиклар белән алыпсатарларны да калдырмыйлар, һәр ларектан, лотоктан суыралар. Банданың кәефе шәптән, эшләре майлагандай бара, бер җирдә дә каршылык күрсәтмиләр, ызгыш-бәхәс юк, салымны тавыш-тынсыз түлиләр, дәүләткә түләгәндә дә андый тәртип һәм ашыгу булмый. Күрәсең, алар "Лидо" белән дә мәсьәлә хәл ителгән, кытыршылыклар юк, барабыз да алабыз дип кенә уйлыйлардыр. Банданың оятсызларча кыланышы хәтта күпне күргән Костаны да чыгырыннан чыгарды. Кара син аларны! Күзләре тонгандай кыланалар. "Лидо"ны күзәтеп маташу да юк. Барысын да алтын тәлинкәгә салып китереп тоттырырлар дип беләләрме?! Башлырак кеше уйлар иде, сакланыр иде бит! Бәлки аларны тозак-капкын көтәдер. Ләкин кичә дә, бүген дә Лютый бандасыннан ресторан тирәсендә иснәнеп йөрүчеләр булмады. Бу мәсьәләдә Ашот белән Коста бик нәзберек иде, сакланганны Алла саклармын, дигән ди бит. Әгәр Лютый бандасының унышлардан башы әйләнмәсә, алар Нәргиз исемле чибәр хатын белән очрашуга ныклап, бөтен

ваклыкларны искә алып әзерләнерләр иде, аны җилбәзәкләрдән санап, түбәнәйтеп карамаслар, күзәтүчәнрәкләре "Лидо" түбәсендә озын, төз гәүдәле егетне күрер иде. Телевизор антеннасын төзәткән булып маташучы егет кулындагы музыка уен коралы футлярына охшаш нәрсәне дә абайлар иде. Скрипка белән антенна ремонтламыйлар ич. Түбәдә засада көткәнен генә аңламаслык түгел. Банда ак "Жигули"ларда ресторан янына туктарга ярты сәгать кала "Лидо" янындагы тукталышка ике яшел "джип" килеп керде һәм кырыйдагы җайлы позицияләргә урнашты. Номерларына караганда болар шәхси машиналар иде. Әлбәттә, никадәр тырышып карасалар да, алар Калашников автоматларын, кыска көпшәле карабиннарны күрмәсләр иде. Төнгә таба салкынайтып җибәрүгә карамастан, һаман машинада утыручы егетләрнең кыяфәте бу бөркетләрнең "Лидо" янына юкка гына килмәгәнен аңлата иде бит юкса. Ләкин Лютыйның күзләрен май баскан, ул бернине дә алдан исәпләп тормый иде инде. "Лидо" янында урнашу план буенча барды, бернинди комачаулык, кыенлык тумады. Костага рациядән ярдәмчеләре гел хәбәр итеп тордылар һәм ул банданың кәеф-холкын, йөри торган маршрутын ноктасыннан ноктасына кадәр белеп торды. Соңгы хәбәр аларның "Салтанат" кафесыннан ару гына кәефләнеп чыгулары хакында булды.

Операция башланырга бер сәгать кала "Лидо"ның төп хуҗалары җыелды. Нәргиз аларны үзенең кабинеты аша арткы бүлмәгә алып керде, монда алты кешегә табын әзерләнгән иде. Нәргиз телевизорны кабул итү бүлмәсенә чыгарып куйды, чөнки төп вакыйгалар, арткы бүлмәдә, ягъни ябык банкет залында барырга тиеш иде. Гаҗәпкә каршы, Икрам Мәхмүдович барысыннан да бигрәк дулкынланды, гасабиланды. Моны Шубарин да күрми калмаган икән, ул профессиональ гангстер кебек, пистолетын пиджак эченә җайлап куйды да аңа эндәште:

—Берәр нәрсә кабып куй әле, дулкынлануың йөзеңә чыккан. Юкса, ролең бик гади, билгеләнгән вакытта Нәргиз белән залда утырасың, шулай тынычрак булыр, чөнки алар сине яхшы белә. Яхшылап каршылагыз, алып керегез, таныштырыгыз, өстәл янына утыртыгыз, аннан Нәргиз белән бергәләп чыгып китәрсез. Тагын бер нәрсә: оркестр ярты сәгать буе гел дәртле, утлы көйләр генә уйнасын, залдагылар шашынып бии башларлык булсын. Калганына борчылма, урамнан беркем дә ресторанга бәреп кермәячәк. Түбәдән безне Ариф саклый, ә кабинеттан шулай ук бер адым да ясалмас. Сөйләшүләр башлангач та Нәргизнең кабул итү бүлмәсенә иптәше белән Карен керер, һәм шулай итеп, кунаклар өч божра эчендә калыр.

Сенаторның ис китмәгән кыяфәттә пистолеты белән маташканын күреп (ул республика прокуратурасында Кощей белән сакчыны атып үтергәннән соң эшкә җигелмәгән иде әле), Фәйзиев калтыранган куллары белән зур гына рюмкага коньяк салды, бер йотуда аны эчеп бетерде, ә компаньоны шикелле үк коралланган борчылмас-пошмас Миршаб аңа лимон кисәге сузды һәм сорап куйды:

—Икрам, бәлки син Лютый шоколад оны сибелгән ананаслы десертны татып өлгермәячәк дип куркасыңдыр?—Бу шаяру нәкъ вакытында һәм урынлы янгырады, барысы да озаклап, рәхәтләнеп көлештеләр, метрдотельнең борчылуын кул белән алып ташладылармыни, ул күз ачып йомганчы тынычланып калды.

Шул арада Карен килеп керде һәм Артур Александровичка карап бер генә сүз әйтте:

—Киләләр!

Фәйзиев Нәргизны култыклап алды һәм ишеккә юнәлде, бераздан аның алгы бүлмәдә телевизорны кабызып җибәргәне ишетелде. Бүлмәдә калганнар исә мәйданга караган тәрәзә янына килде. Прожекторлар гадәттәгедән яктырак балкый, бөтенесе дә уч төбендәгедәй ачык күренә иде. Әнә моторлары сүндерелмәгән ике "джип" тора, беренче сигнал булуга ук алар банда төялеп килгән ак "Жигули"ларны камап алырга тиеш.

Тәрәзә янындагы өч ир бер-берсен дикъкат белән күздән кичерделәр һәм бер-берсеннән канәгать калганлыклары йөзләренә чыкты. Шактый

четерекле һәм куркыныч операциядә беренче тапкыр катнашырга туры килгәнлектәнме, коллегаларындагы киеренкелекне сизеп, Шубарин шаяртып әйтеп куйды:

—Яңа анекдот сөйлимме?

Һәм бераздан банкет залында яңгыраган шаркылдау авазлары хәтта телевизор тавышын да басып китте.

Нәргиз белән Икрам Мәхмүдович бу хәлгә аптырап, бер-берсенә карашып торган арада ике кулдашын ияртқән Лютыйның кереп җиткәнен дә сизми калдылар. Иярченнәре яңа егетләр иде, алары да Нәргиз әйтмешли, "үгезмуеннар" иде. Лютый исә ул арада Нәргиз белән кул биреп исәнләште, Икрамга баш селкеп кенә куйды. Күрәсең, ул метрдотельне җитди кеше дип белми иде. Банкет залы ягына ымлап сорады:

—Синдә кемнәр шулай тугарылып күңел ача, Нәргиз?

Яртылаш ачылган ишектән яңгыраган көлү тавышларын нәрсәгә юрарга да белмәгән ханым җавапны кыска гына итеп бирде:

—Кергәч, күрерсең.

—Шат күңелле кешеләр икән,—дип куйды бераз тынычлана төшкән Лютый.

—Әйе, шат күңелле,—диде елмаеп Нәргиз.—Әйдәгез, чишенегез дә килешүләр өстәле янына. Андагыларның күптән тамак чылатасы килә, шаркылдаулары да шуннан бугай.

—Андый "дипломат"лар күңелебезгә хуш килә,—диде Лютый һәм үзе дә көлеп куйды, иптәшләренә чишенергә кушты. Өс киемен салганда берсенең кесәсеннән тимер кастет төшеп китте, ул аны җайсыз гына кулына алды, ләкин үзе белән алмады, пальто кесәсенә кире шудырды. Чөнки Нәргизнең мыскыллы тавыш белән әйткәнен ишеткән иде инде:

—Сөйләшүгә мондый нәрсә белән килү безнең күңелгә хуш килми,—диде ул һәм кителгән "кунаклар"ны ияртеп банкет залына чакырды.

Алар кергәндә тәрәзә янындагы өч кеше һаман да көлүләреннән туктый алмаганнар иде әле, һәм монын мәҗбүри рәвештә түгел, ә чын-чынлап табигый көлү икәне йөзләренә чыккан иде, Лютый белән кулдашларының йөзеннән шикләнү, киеренкелек галәмәтләре юкка чыкты, алар да үзләреннән үзләре елмаеп куйдылар.

—Безнең җитәкчеләр,—дип томанлы гына таныштырды алар белән Нәргиз. Кул кысыштылар һәм Александрович аларның өчесен дә бай ризыктәгамле табын янына чакырды.

Кунаклар ишекне күз алдына тотарлык итеп утырдылар, Шубарин моны шунда ук искәртеп өлгерде, ләкин ул әзерләгән тозактан боларның чыгу мөмкинлеге юк иде инде—капкын ябылды.

—Йә, башлыйк, тынлыйбыз сезне,—диде Шубарин каршыларына нәкъ дипломатик сөйләшүләрдәгечә өчәрләп тезелеп утырган кунакларга карап.

—Безне тынлап торасы юк,—дип, көлемсерәде Лютый.—Без сезне тынларга килдек, үзебезнекен хуҗа ханымга әйткән идек инде.—Һәм ул күзләре белән ресторан директорын эзләргә кереште.

Икрам кунакларның бокалларына коньяк салып чыкты, ә Нәргиз һич кенә Миршаб яныннан китә алмый кайнашты да кайнашты, алдындагы чәнечке-кашыкларны тигезләп салган булды, сөйгәне каршында иң таза рэкитер утыруы аны шомландыра иде булса кирәк.

—Алар барысын да белә, мин әйттем,—диде Нәргиз.

—Димәк, безгә ясак саласыз инде, күпме тиеш булырбыз икән?—дип кызыксынды Япон.—Аннан соң, ничек түлисе: айлапмы, кварталга бер тапкырмы, әллә елга берме?

—Башкаларныкы кебек, ай саен, унбишендә, биш кисәк... Миңа калса, биш калҗа "Лидо" кебек ресторанга берни дә тормый. Кыйммәтле ресторан...

—Әйе, берни дә тормый,—дип сүзгә кушылды Сенатор.—Бәлки күбрәк тә түли алырбыз, ләкин безнең куркынычсызлыкны гарантияли алырсызмы? Сезнең түбә нидән гыйбарәт булыр?

—Без сезгә тын алырга ирек бирәбез, бөтен гарантия шул.—Лютый күнелле генә көлеп җибәрде, аңа, күрәсең, бу компания ошый башлаган иде.

—Ә сезнең башка кәсептәшләрегез "Лидо"га бәреп керсә, ул чакта нишләргә? Безнең югалтуларны сез күтәрерсезме соң?—Сенатор һаман үзенекен бөкте.

Сүзнең мондый юнәлеш аласын да башына китереп карамаган Лютый аптырый төшеп, иптәшләренә күз ташлады, алары исә җилкәләрен җыерып куюдан уза алмадылар.

—Башкалар түли бит әле, бернинди гарантия сорамый,—диде югалып калган һәм шунлыктан үпкәләгән кыяфәт чыгарган банда башлыгы.

Хуҗалар тагы бердәм көлеп куйдылар.

—Ә без, кадерлем, "башкалар" түгел, безгә гарантия кирәк, бәлки көндәшләрегез "погром" ясар, барысының астын-өскә китереп чыгар, шулай булгач, җаваплылык өлешчә сезгә дә төшәргә тиеш дип беләм,—дип сүзгә кушылды Миршаб.

Лютый җавап эзләп уйга калды, ә Япон тәкъдим кертте:

—Әйдәгез, башта тамак чылатыйк әле, бераз капкалыйк, соңрак ике якка да ярашлы карарга килербез, юкса, Нәргиз озакламый кайнар ризык китерәчәк.

Сүз көрәштерүчеләрнең уяулыгын югалтырга теләп, Сухроб янә үзен борчыган теманы дәвам иткән булды:

—Мин ялгыш ычкындырмадым, кадерле кунаклар. Без сезгә биш мең түгел, алтыны да түләргә риза, ләкин бездә бер теләк тә бар. "Лидо"да вахтер һәм гардеробчы булып сезнең ике саллы егетегез дежурда булсыннар, тагы ышанычлырак булсын дисәк, төнге каравылчы да сезнең кеше булырга тиеш.

—Алты мең өчен иртә таңнан кара төнгәчә кабакта тир түгәргәме?—дип, чын күнелдән аптырый калды Лютыйны озатып килүчеләрнең берсе.

Шактый гаугалы булачак бәхәскә дә ерак калмаган иде инде, ләкин нәкъ шул чакта банкет залына кулларына пар бөркеп торган поднос тотып өч "официант" килеп керде. Элегрәк тә кәефләнеп өлгергән Лютый кулларын угалап кычкырып әйтте:

—Әйдәгез, кайнар шулпага кадәр берәрне бөклик әле, күптәннән инде мондый шәп коньяк эчкән юк, дөресрәге, кабып караган да булмады бугай,—диде.

—Әйдәгез,—дип ризалашты Шубарин һәм сервировка өстәле ягына карамаска тырышып, янадан бокалларны тутырды, чөнки поднос тоткан "официант"ларның бу эшкә куллары ятмый, кыланмышлары көлеп җибәрерлек иде. Әнә Бармаксыз аш тәлинкәсен төшереп җибәрмәгәем дип куркудан уклау йоткандай гәүдәсен катырган, Коста бераз остарак маташтыра маташтыруын, поднос тотып байтак күнегүләр үткәргән Ашотның да маңгаена тир бәреп чыккан иде.

Барысы да эчеп куйдылар һәм кунаклар әле генә Нәргиз мулдан кертеп куйган затлы нигъмәтләргә капланууга "Лидо"ның хуҗалары, алдан килешенеп куймаган булсалар да, өстәл астында бер-берсенең аякларына кагылып алдылар, бу хәлиткеч мизгел житте дигәнне аңлатырга тиеш иде.

Артур Александрович "официантлар" ягына карап куюга аларның һәркайсы ак гөмбә кушып кыздырылган бытбылдык салынган, хуш ис бөркетеп утырган берәр тәлинкә алды һәм арттан килеп, өчесе берьюлы затлы нигъмәтне хуҗалар алдына, өстәлгә куйды. Кунакларга да шундый ук хөрмәт күрсәтелде. Алар бердәм рәвештә өстәлнең кунаклар утырган ягына чыктылар һәм тәлинкәләрне куюга, банкет залында күп тапкырлар кабатланган гамәл тормышка ашты: официантлар кулындагы ныклы белорус житененнән әзерләнгән сөлгеләр, нәкъ итальян мафиозилары һәм американ ганстерлары кулындагыча, күз ачып йомганчы элмәккә әйләнде. Капканнарын чәйнәп йота да алмаган кунаклар буылып гырылдый башлады, күзләре акаеп чыкты, шул ук мәлдә һәркайсының күкрәгенә пистолет терәлде, житез куллар Лютыйның бил каешыннан пистолет, калганнары-

нықыннан пычаклар тартып алды. Нәргиз кабинетыннан яшь, каракучкыл йөзле егет йөгереп чыкты һәм эһ дигәнче кунакларның кулларына тимер богау салынды, аларны өстәл яныннан суырып алып, стена янына аттылар.

Тук чырайлы бу таза, нык агайлар гадәти операларга бер тамчы охшамаган булса да, Лютый үзләрен милиция каптырды дип уйлап өлгерде. Ә залда пирәшләү иң югары ноктасына җиткән иде инде, оркестр яһүдиләрнең "Жиде дә кырык" дигән дәртле биюен сыздыра, төшереп алган халык ишелеп бии.

Кәсептәшләренең рухын күтәрү өчен булса кирәк, Лютый ямьсез итеп сүгенде дә котырынып, кычкырды:

—Ә син, пычрак сөйрәлчек, хаинлегең өчен җавап бирерсең әле!

Нәргизгә карата йөрәгендә яшерен мәхәббәт саклап йөргән Ашот бу сүзләрдән бөтенләй кабынып ук китте.

—Әле син тәртипле-тәрбияле хатын-кызны мыскыл итәсең, түбәнсетәсенме?!—дип кычкырды һәм шундый итеп китереп сукты, хәтта Лютыйның башы гәүдәсеннән аерылып очар кебек тоелып китте, бер үк вакытта нindидер ямьсез шытырдау һәм еламсыраулы тавыш ишетелде. Банда башлыгы Ашот сугып төшергән берничә тешен йотып та җибәрде. Өстәл янында Миршаб каршына туры килгән әзмәвердәй егет янәшәдә генә иде, ул Ашотның касыгына тибәргә аягын күтәрүгә үк өлгер Костаның теләсә нинди кирпечне урталай сындыра торган кул сырты "үгезмуен"нын бугазына килеп төште. Әзмәвер киселгән агач кебек гөрселдәп ауды, авыз кырыеннан мыегына нечкә генә кан юлы сузылды. Ачуына буылган Лютый башын селки-селки, Ашотка карап, сакауланып әйтте:

—Ә син, әрмәшкә хәсис, мине исеңә төшерерсең әле.

Ашот аны бер сугудан егып аударды һәм аяклары белән типкәли дә башлады, ләкин Артур Александрович үзенең тән сакчысын читкә алып китте:

—Җиткәндер дим, алар мәнсез кешеләр түгел, хаталарын аңлаганнардыр.

Шул мизгелдә өченче кунак тәрәзәгә ыргылды, күрәсең, иптәшләрен ярдәмгә чакырырга ниятләгәндер, ләкин Бармаксыз йокымсырамый иде, аяк чалып өлгерде, идәнгә тәгәрәгән егеткә дә ерткычлар "кучтәнәче"ннән өлеш чыкты.

"Лидо" хуҗалары яңадан өстәл янына җыелышты, үзләренә дә, официантларга да һәм Каренга коньяк салдылар. Бүленгән мәҗлесне дәвам иттеләр. Шубарин Костага карап әйтте:

—Коста, Лютыйны тәрәзә янына алып барып күрсәт, төшендереп бир, башыннан ахмаклыкларын чыгарып атсын. Без аны моннан бер шартыбызны үтәгәндә генә исән чыгарачакбыз.

Коста камырга әйләнгән банда башлыгын тәрәзә янына алып барды һәм бандадан тагын өч кеше утырган ак "Жигули"ларга ташланырга әзер ике "джип"ны күрсәтте. Аннан соң үзләрен тәртипкә кертсеннәр өчен ваннага алып керделәр, шунда богауларын салдырдылар. Хәзер алар куркыныч түгел иде инде.

Лютыйны кабат өстәл янына алып килгәч, Шубарин тагын сүз кушты:

—Ә минем шартларым мондыйрак, кадерлем. Хәзер метрдотельне чакырабыз, ул якын-тирәдәге бөтен кооператорларны да белә. Ул телефоннан сез бүген йолыкканнарның барысын да чакырыр һәм син аларның һәрберсенә, гафу үтенеп, исеңдә тот, гафу үтенеп, акчаларын кайтарырсың, башка һичкайчан борчымам дип, вәгъдә бирерсең. Ә хәзер берниндi фокус-мокус ясамыйча гына машинан янына чыгасың, кисәтеп әйтәм, чөнки сине Ашот озата чыгар. Бер генә ялгыш хәрәкәт ясасаң да, ул сине рәхәтләнеп теге дөньяга озатачак, машинадагы дусларың ут астында калачак. "Джип"тагы егетләрнең кулларында чын автоматлар, алар ике уйлап тормый, монысы тикшерелгән. Ә бу ике бөркетең бездә тоткын булып кала, син бүген бар гамәлләреңдә дә оттырдың. Ну, ничек, килештекме?

Лютый кире какты.

—Ярый алайса. Барысы да Алла кулында,—диде Япон тыныч кына.—

Мин сине Ашотка тапшырам. Ничек тели, шулай эшләсен, әле аны беркемнең дә кеше алдында шулай мыскыл иткәне юк иде.

Ашот Лютыйның якасыннан алды һәм ваннага таба өстерәп алып китте, соңгы мизгелдә банда башлыгы буылып гырылдады:

—Риза, сезнеке алдырды.

—Йә, монысы бөтенләй башка эш, ә хәзер бар, акчаларыңны алып кер, ә син, Ашот, игътибарлы бул, ул теләсә нинди кабахәтлек чыгарырга мөмкин.

Алар чыгар алдыннан бүлмәдә бер генә секундка утны сүндереп алдылар, бусы "джип"ларга ак "Жигули"лар янына барырга һәм теләсә нинди хәлгә әзер булырга кушып сигнал бирү иде.

Ун минуттан Лютый урамнан акча тутырылган спорт сумкасы тотып керде. Шубарин Фәйзиевне телефон янына утыртты һәм күпмедер вакыт узгач, "Лидо"га аптыраштa калган кооператорлар җыела башлады.

Акчаларны тараткан арада, Лютый бандасы белән алга таба нишләргә дигән мәсьәләдә, "Лидо"ның хуҗалары арасында җитди каршылык чыкты. Сенатор белән Миршаб милиция чакыртып, эш кузгатырга, шулай итеп, аларны үз кул астында тотарга тәкъдим иттеләр. Кораллы талау өчен һәр бандитка кимендә унбиш ел бирәчәкләре шиксез, диделәр. Шубарин катгый рәвештә милиция чакыртуга каршы төште, чөнки мине Коста да, Ашот та, Бармаксыз да аңламас, диде. Соңыннан официантларны тыңлап карарга булдылар, алары да, Японны яклады, аның сүзләрен кабатлады, милициядән үзебезне саклату килешми, бу безнең вөҗүдебезгә туры килми, диделәр.

Бәхәсле мәсьәлә хакында Лютыйга ачыктан-ачык сөйләп бирделәр, анысы шунда гына үзенең милиция белән түгел, ә үз тиңнәре, көчлерәк һәм уңышлырак эш итә белгән кәсептәшләре белән очрашканын аңлап алды. Караклар йоласы буенча, районны тынычлыкта калдырабыз дип ант иттергәч кенә рэкитерларны чыгарып җибәрделәр.

Рэкитерлар белән "түгәрәк өстәл" янында утырганнан соң бер айлап вакыт узды һәм бу вакыйга онытыла да башлаган иде инде. Ашот тәкъдиме белән ресторан штатына яңа кешеләр алдылар, куркынычсызлыкны ныгыту өчен катгый чаралар күрелде. Үз вакытында Шубаринга Лютый турында хәбәрләр ирешеп торды, банда "яраларын ялап ята, ауга йөрми икән", күрәсең, яңа елга хәтле талаганнары озак кына яшәргә җитәрлектер. Хәер, Коста белән Ашот әйткәнчә, хәзер Лютыйга бер генә юл—бандасы белән Ташкенттан чыгып китү, икенче бер шәһәр табу юлы гына калган иде инде. Башкалада барысы да бүленгән, үз калҗасын беркем дә үз ирегe белән бирмәячәк, яман даны чыккан банда башка күтәрелә алмаячак. Тагы бер айдан Японга Лютыйның алтын тешләр куйдырып йөргәнен, Ашхабадка күчеп китәргә җыенганын да ишеттерделәр. Анда лагерьда бергә утырган дусты бик югары күтәрелгән, кайчандыр Нарик Каграмян Ташкентны тоткан кебек, Төркмәнстан башкаласын үз кулында тота икән.

Дөрес, алар шәһәрнең вокзал яны районында күренәләр икән күренүен, кәсепләрен дә алыштырганнар, "уймакчы"га әйләнгәннәр. Лютый бу эштә шактый кул шомарткан бәндә икән. Нишләп шундый табышлы һөнәрне куркынычлы рэкитерлыкка алыштыргандыр, монысын бер Алла гына белә, күрәсең, беренче көннәрдә рэкитерлык җинелрәк һәм мул акчалы булып тоелгандыр, башын әйләндергәндер. Алар "эш"кә чыкмыйлар, көннәр буе акчага кәрт уйнап яталар. Чимкент трактында рэкитерлыктан кергән хисапсыз акчага сатып алган йортлары бар, ди. Кәрт уйнарга алар янына читтән дә килгәлиләр һәм Лютый һәйбәт кенә бер катран ачып җибәрмәскә микән дип тә уйлана икән. Лютыйның бу планын да "Лидо"да ишетеп беләләр иде инде.

Язга таба рэкитерлар булган вакыйга бөтенләй онытыла башлады, "Лидо" элеккечә һаман тауга үрмәли, ләкин борчулар да җитәрлек иде. Бер прокурор Камалов үзе генә дә ни тора. Аны игътибардан читтә калдырырга, эшләрне үз агымына җибәрергә ярамый иде. Казынган саен тирәнгәрәк төшә башлады түгелме?!

* * *

Ниһаять, Мәскәүдән Камалов турында алынган мәгълүматлар тынычланырга урын калдырмый иде. Прокурор зур тормыш мәктәбе узган кеше булып, җинаятьчелек белән көрәштә кемнәрдәндер киңәш, тәҗрибә сорап йөрердәйләрдән түгел. Миршаб белән Сенатор шуны яхшы аңладылар: республикага җитди план-максатлар тоткан, аерым вәкаләтләргә ия кеше килгән. Аны куркыту яисә сатып алу турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Прокурорны алар яшеренлек максатларында "Москвич" дип йөртә башладылар, аның өстеннән җыелган мәгълүматлар хәтерләренә уелып калды. Сухроб Әхмәдович тырыш абитуриент кебек һич төртелмичә, аның биографиясен сөйләп бирә алыр иде... Хөршид Азизович Камалов 1940 елда Ферганада туган. Сугыштан соң әтисен эшләргә Мәскәүгә күчергәннәр. 1963 елда Мәскәү университетының юридик факультетын кызыл диплом белән тәмамлаган, кафедрада эш тәкъдим иткәннәр, ләкин ул туган ягына омтылган. Аны республика прокуратурасына эшкә җибәрәләр, ике елдан Ташкентның бер районы прокуроры дәрәҗәсенә күтәрәләр. Район прокуроры булып эшләгәндә, аның бер дәрәҗәле һәм йогынтылы нәсел белән җитди низагы килеп чыга. Низаг шулкадәр җәнҗаллы була ки, аңа хәтта Рәшидовның үзенә катнашырга туры килә, яшьлеге генә Камаловны усал җәзадан коткарып кала да. Акылына килсен өчен үҗәт прокурорны Ташкенттан олактыралар, Мәскәүгә, өч еллык көндезге аспирантурага җибәрәләр. Көндезге аспирантурада ул бер генә ел укып кала һәм шул вакытта хокук саклау органнары мохитындагы җинаятьчелек турында фәнни хезмәт—"Хокук хөкеменә каршы җинаятьчелек" дигән бөтенләй яңа тема өстендә эшли башлый һәм көтмәгәндә генә угрозыскка күчә, 1971 елны подполковник дәрәҗәсендә бу эштән китә. Милициядән ул башкала ипподромында коралды бандены кулга алганда каты яралану аркасында китәргә мәҗбүр була, аңа үз хезмәттәше—милиция капитаны аткан була. Шунысы да мәълүм булды: подполковник Камалов милициягә кереп оялаган, төрле кыяфәткә керә белүче убырларны, ягъни сатлыкҗан бәндәләрне ачыклаучы яшерен аучы да булган икән. Җитмешенче еллар ахырында аның тырышлыгы белән Мәскәү милициясе, бигрәк тә аның югары эшелоны нык кына чистартыла. Милиция капитанының атуына да шул сәбәп була. 1972 елда унбер ай госпитальләрдә аунап, могҗиза белән генә исән калган һәм инде полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән Камалов ябык утырышта үзенең күптән язган диссертациясен яклый. Илдәге хокук саклау органнарының барлык тармакларындагы житешсезлекләрне ачып салган фәнни хезмәткә "Үтә яшерен" дигән мөһер сугыла. Югары инстанцияләргә эләккән берничә экземплярдан кала бу фәнни хезмәт бүгенгәчә яшерен булып санала.

Диссертация яклаганнан соң аны бер елга Франциягә командировкага җибәрәләр, шунда ул Париж янындагы бистәләрнең берсендә Интерполның эш ысулларын өйрәнә. Бу сәяхәттән сон, оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәшне оештыру тәкъдимнәре күрсәтелгән, гомумиләштерүче нәтиҗәләр чыгарылган тагын бер саллы фәнни хезмәт пәйда була, анысы да министр кабинетларыннан ары китә алмый, бикләнеп кала.

1973 елдан ул КГБнең ябык уку йортларында махсус фәннәрдән укыта. Монда инде аның угрозыскка очраклы эләкмәве, ә аерым вәкаләтләр белән җибәрелүен фараз итәргә генә кала.

1978 елда башкалада җинаятьчелекнең кискен үсеп китүе сәбәпле, аны Мәскәүнең бер районына прокурор итеп җибәрәләр.

1981 елда, Л. Н. Брежнев идарә иткән чорларда, Камалов нәкъ Ташкенттагы яшьлек елларындагыча, тагын бәхәскә, ил башындагылар белән бәрелешкә керә. Ләкин үз вакытында аның "Үтә яшерен" мөһере сугылган ике хезмәте белән танышып өлгергән Ю. В. Андропов ярдәм кулы суза, ул Вашингтонга, АКШтагы совет миссиясенең куркынычсызлык хезмәтен җитәкләргә җибәрелә.

Камалов оешкан җинаятьчелек белән көрәштә иң яхшы белгечләрдән санала һәм озак вакытка исәпләнгән стратегик программаларны эшләүдә катнаша.

Фәнни хезмәтләрен үтә яшерен сер итеп сакласалар да, аның илдә оешкан җинаятьчелек белән көрәш өчен махсус бүлекләр челтәрен булдырырга тырышканы мәгълүм. Үзбәкстан прокуроры итеп куелуга, ул нәкъ шуны тормышка ашырды да. Республика Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының рәис урынбасарлары, кадрлар өчен җаваплы Саматовны да кертеп, өчесе дә Камалов шәкертләре, яңа бүлек кешеләре дә КГБ хезмәткәрләреннән тупланды, алар, табигый ки, хәзер дә куәтле оешма белән араларын өзмиләр. Машинкада яхшы итеп басылган текст кулдан язылган өстәмә белән тәгәлләнә: “Прокурор Камалов җинаятьчел дөньяга һәм эшкуар даирәләргә реаль куркыныч ясый, беренче мөмкинлек туугa, аның исемен пычратырга, ә иң яхшысы, юкка чыгарырга кирәк!”

Шуңлыктан, бу көннәрдә “Лидо” хуҗаларын Лютый бандасы гына борчып калмыйча, сизенүләренә караганда, Сенаторның койрыгына утырган прокурор Камалов мәсьәләсе дә тәшвишләндерә иде.

Алар, гомумән, Лютый бандасы белән булган вакыйганың дәвамын күз алдында тотмыйлар, ул тәмамланды дип хәл иткәннәр иде инде.

Әмма барысы да башкача килеп чыкты, фаҗигале яңа борылыш алды. Шубарин әйтмешли, “Явызлык яңа явызлык тудырды”.

Март ахырында, Ташкент бакчаларында котырып алсу миндаль чәчәк аткан, һавада фарсы сиренենең баш әйләндергеч хуш исе уйнаган көннәрнең берсендә Артур Александрович Мәскәүдән килгән югары кунакны каршы алды. Хәер, бу кунак турыдан-туры Шубаринның үзенә түгел, ә бәлки республика Совминына килгән иде. Алар Шубарин белән күптәнге танышлар булып, аның да кулында алтын “Ролекс” ялтырап тора, түгәрәкләп әйткәндә, ул да пики валетларының берсе иде. Совминда күпләр аларның дуслыгын белә, чөнки Япон үз эшләрен генә түгел, вакыт-вакыт республика проблемаларын да шул дусты белән хәл итә иде. Зур түрәне Шубарин “Лидо”да кабул итте. Нигъмәтләрдән сыгылып торган табын, хуҗаның кунакчыллыгы шулкадәр тәсирле булды ки, кичәнең азагына ул чын-чынлап аягында басып тора алмый иде инде, әгәр аны ул тукталган ҮК резиденциясенә алып барсан, дустыңны сату булачак иде, шуңлыктан Нәргиз кабинетындагы диванга салдылар, янына кизү куйдылар. “Лидо”дан бик соңлап чыктылар. Мәрмәр басмалардан ресторан каршындагы мәйданга аяк атларга да өлгермәделәр, берничә пистолеттан, соңрак автоматтан аткан тавышлар ишетелде. Һәрвакыттa алдан чыгучы Ашот бу юлы да төркемнең алдыннан бара иде, беренче пулялар аны аяктан екты. Шубаринны исә үлемнән могҗиза белән Нәргиз саклап калды, хатын-кызга хас эчке тоем белән ул җиденче модельле кызыл “Жигули”ның бина артыннан, караңгыдан шуып чыгуында нииндидер хәтәр хәвеф барлыгын сизеп алган иде. Беренче ату тавышы яңгырамаган иде әле, ул кинәт тартып, Артур Александровичны шома мәрмәр баскычка екты һәм гәүдәсе белән каплады, ауның Шубаринга барганын ул аңлаган иде инде. Соңыннан Нәргиз “Лидо” ишегендәге фин пыялаларын челпәрәмә китергән автомат утын алдан сизенгәнен, моның ничек булганын үзе дә аңламаганын сөйләде. Дөньяда гаҗәп хәлләр җитәрлек ул. Һөҗүм итүчеләр янадан бер генә тапкыр да ата алмадылар, чөнки гардеробта тукталыбрак калган Коста чыгып җитте һәм инде кузгалып китә башлаган машинага пистолеттан ут ачты.

Шул арада автомат тоткан төнге каравылчы да килеп чыкты, Коста кызыл “Жигули”ны куып китмәкче иде дә, Шубарин аны кыска гына сүз белән туктатты:

—Кирәкми! Алар бездән беркая да китмәсләр,—диде һәм кем икәнлеген сизгәнен раслатыр өчен сорап куйды:—Лютыймы?

—Һичшиксез, шул, мин аның сөмсез чыраен күреп калдым.

—Алайса, ярар, монысы җитди нәрсә, чакыруын кабул итәм мин, ләкин хәзер вакланып тормыйк, Ашотны карыйсы бар. Зинһар, өеннән Каренны

чакырыгыз.—Һәм алар тән сакчысы белән икәүләп Ашотның гәүдәсен вестибюльгә алып керделәр.

Ашотны зурлап, хөрмәтләп күмделәр, тиешенчә җидесен уздырдылар. Һәм шуннан соң гына зур кинәшмәгә, "Лидо"ның банкет залына җыелдылар.

Сенатор белән Миршаб яңадан аноним рәвештә республика угрозыскысына, полковник Чураевка шылтыратырга тәкъдим иттеләр. Лютыйның аның кулыннан ычкынмаячагына шикләнмәскә мөмкин булыр иде. Бу вариантны шундук кире кактылар, чөнки сүз үч алу хакында бара иде инде. Миршаб элеккесенә охшаш тагын бер яңа тәкъдим кертте, боларның йортлары күрше республика җирләрендә, Чимкенттагы казакъ милициясенә белдерик, диде. Ләкин Коста тавыш чыгарды:

—Үтерүен безнең иптәшебезне үтерәләр, ә җәзаны милиция кулы белән бирикме,—диде ул ярсып. Һәм көтмәгәндә өстәлгә банда яшәгән йортның зурайтылган фоторәсемнәрен чыгарып салды, үзе әзерләгән планны сөйләп бирде. Моның белән Кареннан башка барысы да риза булдылар. Ул да каршы түгел иде, тик, үч алырга иң омтылучы кеше буларак, операциядә төп урынны үзенә бирүләрен сорады. Ләкин сөйләшүдә катнашучылар Каренның дәлилләре белән килешмәделәр, Костаны өстенрәк санадылар, чөнки ул тормыш һәм профессиональлек ягыннан тәҗрибәлерәк, шуның өстенә, Ашот белән аларны әле беренче тапкыр лагерьда утырганда ук туган тыгыз дуслык җепләре бәйли. "Бу минем намус эшем!"—диде Коста. Операциягә әллә нинди ныклы хәзерлек тә кирәкми иде, Лютый "уймак" уеныннан туеп, Ташкенттан кайтсын гына. Аларның төп шөгыле карта уйнау да аракы эчү. Сирәк-мирәк хатын-кызлар да булгалый булгалавын, ләкин "блатнойлар дөньясы" вәкилләре казна караклары, цеховиклар, кооператорлар, фарцовщиклар бәяләгән хәтле гүзәл затларны югары бәяли белми, болар бары Ананы гына хөрмәт итәләр.

Озак көтәргә туры килмәде, атна башында "Лидо"да телефон шылтырады, вокзалдан хәбәр иттеләр: бүген милиция Лютыйны дуслары белән бергә эш урынынннан куып җибәргән. Ниндидер делегация киләсе бар икән, тимер юл ресторанында ук аракы төяп, банда үз йортына ял итәргә кайтып киткән. Операция үткәрергә иң кулай вакыт. Лютый йортының поселоктан читтә, котырып агач, куак үскән аулак бакчада булуы да өстенлек бирә. Кәсептәшләре белән Лютый вокзалда "уймак" тәгәрәтеп йөргән арада Коста белән Бармаксыз, Ариф һәм Карен ул өйгә кереп, карап-тикшереп чыкканнар иде инде. Теләсә кайсы йозакны эһ иткәнче ача белүче Парсегянга авыр эш булмады ул. Операциядә катнашучы бу дүртәүнең һәркайсы ни эшләргә тиешлеген ачык белә иде инде. Планда төп урын төгәллек, тизлек, көтелмәгәнлек кебек сыйфатларга бирелде, куркынычның күзенә керә белү һәм кыюлык та исәптән төшеп калмады.

Коста тагын моннан өч ай элек инде бер тапкыр кигән официант киемен, аның астыннан исә Артур Александрович алып килгән кевлар жилетны да киеп куйды. Пуля тишә алмый торган Америка жилеты операциядә катнашучыларның хыялын уйнатып җибәрде, аны шунда ук сынап карарга да булдылар һәм Арифка данлыклы "Франчи"дан атып карарга туры килде. Нәтиҗә шаккатырды, операциянең уңышлы чыгасына канатландырып җибәрде. Коста киенгән арада аңа шәраптыр, эчемлек вә кабымлыктыр кебек, сәйран чигүче байларга хезмәт күрсәткәндә кирәк булган нәрсәләр тутырылган кәрзин алып килделәр. "Лидо"ның бай клиентлары җитәрлек, аның мондый тәҗрибәсе бар иде инде.

Юлда такси тотып, Коста озатучыларсыз, коралсыз-нисез Лютыйның элеккеге сарык абзары янында урнашкан йортына китеп барды. Элекке заманнарда зәвыктан һәм матурлык хисеннән мәхрүм ителмәгән хуҗа яшәгәне сизелеп торган йорт янына килеп җиткәч, ул нәкъ кәрт сугып утыручылар җыелган залның тәрәзәләре каршында тукталырга кушты һәм озаклап таксистка акча түләп маташты. Монысы көтелмәгән кунакны өйдәгеләр күреп алсын өчен махсус эшләнде. Машинадан чыккач, муенын-

дагы кубәләгән тозәткән булды, смокингын тартып куйды һәм азык-төлек тутырган икәнлеге ерактан ук сизелеп торган кәрзинен алып, ишек шакыды. Ишекне ыргылып ачып та җибәрделәр. Таныш булмаган яшь кенә егет ана керергә ишарә ясады.

—Йортыгызга иминлек бирсен!—диде Коста залга килеп керүгә һәм кыяфәтенә тәүфикъ иясе чалымнары чыгарды.

Өстәл янында алты кеше чыннан да кәрт сугалар иде, уртада җыелган һәм һәркайсысы янында өелгән акчаларга караганда, болар күптәннән һәм шактый зур суммага уйныйлар иде булса кирәк. Банданың җиденче кешесе анын артында тора, бары Коста бер сугуда аяктан еккан "үгез" генә күренми иде.

—Бөтен җирен айкап чык,—диде Лютый артта баскан егеткә. Алтын тешле авызыннан эт ырлаган авазлар ургылып чыккандай булды.

—Кунакларны начар каршы аласыз,—дип куйды Коста һәм ике кулын да күтәреп, тентергә тиешле егеткә таба борылды.

—Син, кабих, кунакчыллык турында теш агартып маташма,—диде мәгълүм сөйләшүдә катнашканнарның берсе.

Аны кармалап-тентеп яткан арада кемдер өстәл яныннан торды, кәрзингә ябылган крахмаллы җәймәне тартып төшерде һәм шатлыгыннан чыйнап җибәрде:

—Толян, син кабарга берни калмады, дигән идең, ә монда лыкынганчы ашасаң да бетмәслек ничаклы нигъмәт, авыздан сулар килә, билләһи.—Һәм барысы да кәрзин янына җыелдылар.

—Син моны безгә китердеңме?—дип сорады аптырашка калган Лютый.

—Әйе, бу сезгә, мин хуҗаларымның куйган таләпләрегезне берсүзсез, бер үзгәртүсез үтәргә риза икәнлекләрен әйтергә килдем.

—Ниһаять, кем белән эш иткәнлекләрен аңлаганнар,—дип куйды Лютый горурланып, мин-минлеге йөзенә бәреп чыкты һәм ул "чапкын"га утырырга урын күрсәтте. Күрәсең, көтелмәгән визит аны банда алдында бер башка күтәреп җибәрде. Ашотны шәһәрдә беләләр иде, шуңа күрә җавап үче көттеләр, ә монда барысы да майлагандай җиңел генә юлга салынып килә түгелме?

—Ә бу капкорсак сәүдәгәрләр күчтәнәчне агуламаганнар микән?—дип куйды кинәт Коста кергәннән бирле тәрәзәдән күзен алмыйча каранып маташкан берсе.

Коста кәрзиннән бер шешә ак аракы, тагы бер шешә коньяк тартып чыгарды, бер селтәнүдә аларның бөкеләрен ачты да стаканга аракы белән коньякны бутап салды, затлы югослав ветчинасыннан бутерброд ясады һәм стаканын күтәреп:

—Килешү өчен!—диде дә эчемлекне авызынна койды, рәхәтләнеп бутерброд чәйнәде.

—Кем шундый нигъмәтне агуласын, ди әрекмән колак?—диде аны ишектә каршылаган егет һәм көлә-көлә барысына да Коста авыз иткән болганма эчемлек ясады, берсе дә аңарга каршы килмәде, туктатмады.

—Без сезнең белән килешергә җыенмый идек,—диде банда башлыгы һәр сүзенә басым ясап.—Ә инде үзегез кул сузасыз икән, аны читкә этү гөнаһ булыр, кан җитәрлек коелды инде, Ташкентта да безне аңламаслар. Шуңа күрә, безнең гадәт-йола буенча, мин дә синең тостны кабатлыйм:—Килешү өчен!

Барысы бердәм эчеп куйдылар һәм кәрҗиндә кашык-чәнечке кебек нәрсәләр ятканлыгын күрсәләр дә, балык, ит, пешкән күркә, казылык кисәкләрен кул белән алып, авызларына тутыра да башладылар.

—Уңышлы көн бүген,—диде Лютый, шатланып әйтте, иптәшләренә ташлаган карашында җиңүче кыяфәте бар иде. Күптән түгел генә алар арасында авыр сөйләшү булганлыгы да сизелеп тора иде.—Әйдәгез, шушы көн хөрмәтенә дә эчик, әгәр без цеховик Япон белән килешсәк, Ташкент безнеке дигән сүз, санлаячаклар, үз районыбызны да кире кайтарырбыз.—Моның өчен дә эчеп куйдылар.

Эчемлек пары башына киткән Лютый кинәт кенә өстенә кайнар су сипкәндәй сикереп торды:

—Ләкин шартлар икенче төрле булачак. Безнең шартлар... Биш мең түгел, ун мең. Фрайерның һәлакәте комсызлыктан, диләрме әле?—Һәм, Костага карап, өстәп куйды.—Хуҗаларың күтәрә алырмы?

—Ник күтәрмәсеннәр, алар тынычлык тели, монысын төгәл беләм, ә биш мең өчен вакланып тормаслар.

—Бик шәп, акылга кергәнсез икән, ә кайчан түли башлыйсыз соң?

—Хет хәзер, минем машинам гына юк, берәрегез минем белән барсын, Нәргиз янына керербез, акча алырбыз да тагы монда кайтырбыз, мин аны үз кулым белән тапшырырмын.

—Бара!—диде Лютый ризалашып.—Барыгыз, тәгәрәгез, ләкин тагы бер шарт бар. Безнең исәпкә шушындыйрак тагы бер-ике кәрзин төя, килгәч, кешеләрчә өстәл әзерләрсең, савыт-саба табылыр, җыну һәм килешү көнен яхшылап юарбыз.

Йомышны арада иң яшь егеткә йөкләделәр, ә ак "Жигули" руленә Костага утырырга туры килде, егетнең машина йөртү таныклыгы юк икән.

"Лидо" янына килеп туктаганда ресторанда кичке тормыш үз көченә кергән иде инде, Костаны озатып килгән егетнең борчылуы йөзенә чыкты, Джиоевка аны хәтта тынычландырырга туры килде.

Алдан сөйләшенгәнчә, шик тудырмас өчен Нәргиз кабинетта ялгызы гына иде. Кергәч тә Коста арыган кыяфәттә кәнәфигә ауды, моның белән ул озатып килгән егеткә Лютый резиденциясендә үзенең бик курыккан-лыгын сиздерергә тиеш иде һәм директорга сөйләшүләр турында кыскача гына әйтте, аларның таләпләрен җиткерде:

—Хәзер, Нәргиз Гомәровна, аларның таләпләре икенче. Ун мең сорыйлар.

Нәргиз, аның раславын көткәндәй, озатып килгән егеткә гаҗәпләнеп карап алды.

Үз шәхесенә шундый зур игътибар күреп күңеле кытыкланган егет кистереп әйтте:

—Әйе, әйе! Толян: "Ун мең",—диде.

—Мин сезгә әзерләп куйган идем инде,—диде Нәргиз кәефсезләнеп һәм өстәл янында идәндә яткан "Адидас" спорт сумкасына күрсәтте.

Аннан соң егетнең игътибарын сумкадан читкә юнәлтү өченме, стенага кертеп ясалган сейф янына килде һәм ачып, төрле зурлыктагы акчалар чыгарды. Аларны өстәлгә таратып салды һәм Коста белән теге егетне акча санашырга чакырды.

Егеткә егерме бишлекләрдән ике мең җыярга куштылар, Коста шул ук сумманы унлыклардан, Нәргиз үзе бишлекләрдән җыярга тиеш иде. Акча тиз саналды, директор аларның барысын да җыйды һәм инде төрле зурлыктагы акчалардан биш мең сум яткан сумкага аптырамый-нитми эшереп тә төшерде.

Аннан кинәт исенә төшкәндәй, әйтте:

—Бу яман җан көйдергеч вакыйга бетүгә мин бик шат, Лютыйга бүләгем дә бар әле минем.—Һәм ул сумкадагы акчалар өстенә алдан әзерләнгән "Дипломат" маркалы уникe шешә чех сырасы, аларга өстәп ике блок "Мальборо" сигареты да ташлады.

Егетнең сыра һәм сигаретлардан күзе янганын күреп, өстәлдән бер пачка алды да аңа сузды:

—Рәхәтләнеп тарт,—диде һәм шунда ук чех сырасы саклаган суыткычтан банкалы фин сырасы алды, ачып бирде.

Яшь егет сыра эчеп маташкан арада ике кәрзингә тутырып кабымлык вә эчемлек керттеләр. Егет исә кесәсенә тыгылды:

—Мин ничә сум тиеш?—дип сорады. Лютыйның "безнең исәптән" дигәне исеннән чыкмаган иде әле, өстәвенә, чибәр хатын алдында вакланасы да килмәде бугай.

Ләкин Нәргиз каршы төште:

—Башка вакытта,—диде.—Бүген килешү көнендә "Лидо"дан бүләк дип

кабул итегез.

Коста сумканы алды, яшь егет ике кулына ике авыр кәрзинне эләктерде һәм алар килгән якларына китеп бардылар. Шәһәрне чыкканда ак "Жигули"ны юл читендә Парсегян "Волга"сы көтә иде инде, машина иясеннән тыш кабинада Ариф белән Каренның да йөзләре күренеп калды. "Жигули"ны узып китүгә "Волга", тавыш-тын чыгармый гына, аның артыннан кузгалды. Карен гына канәгать түгел иде, ул Коста банданы берүзе хәл итәчәк, дип өзгәләнеп барды.

Өстәл янында уенның иң кызган чагы иде, алар керүенә игътибар итүче дә булмады, бары кәрт өләшеп маташкан Лютый гына егеткә сорау ташлап алды:

—Йә, эшләр ничек анда?

—Барысы да о кей, яхшының да яхшысы. Хуҗа ханым сиңа бүләк тә җибәрде әле. Күрсәтсәм күзләрегез маңгаегызга менмәгәе.—Һәм ул ике блок "Мальборо"ны сумкадан алып өстәлгә ташлады. Барысы да пачкаларны ерта-ача, үзара бүлешә башладылар.

Ул арада Коста унике сыра шешәсен елгыр гына ачып та өлгерде һәм уйнаучыларга сузды. Сырадан барысы да сикереп-биеп куйдылар, башларын артка ташлап эчә дә башладылар. Джиоев шундук акчаны диванга чәчеп салды, моны барысы да күрде.

—Халдей, акчаларны интектермә, үзебез санарбыз, әнә Лютый кушканча өстәл әзерлә,—диде берсе, сыра шешәсеннән иренен бер генә мизгелгә аерып.

—Минем исемем Коста,—диде чапкын һәм сүзен дәвам иттерде:—Мин хәзер сезгә шундый өстәл әзерлим, мәңге онытмассыз...—Шул ук мизгелдә автомат тавышы яңгырады. Коста спорт сумкасыннан кулын алмаган көйгә ике төпле "Адидас" сумкасының астына яшерелгән автоматның курогына баскан иде инде. Израильдә эшләнгән җинел "Узи" автоматы як-якка пуля яңгыры сиптерә башлады. Ачык тәрәзәдән тышка сикергән берәүне сакта торган Ариф пулясы куып җитте. Барысы да күз ачып йомганчы тәмамланды. Соңгы ату тавышлары яңгыраганда бүлмәгә Карен белән Бармаксыз ыргылып керделәр.

—Әйттем бит, ул безгә берсен дә калдырмый дип.—Каренның кәефе төшкән иде.

Шул чакта бер генә тапкыр да атарга өлгермәгән, идәндә яткан Лютый селкенеп куйды һәм кулындагы пистолетын төшереп җибәрде.

—Ах, бу хәшәрәт исән икән бит әле!?—дип, сөенеп кычкырып җибәрде Карен һәм бандитны теге дөньяга озатуда үз өлешен кертте.

—Хәзер марафет ясыйбыз—аннан трассага. "Узи" Калашников кебек тавышлы булмаса да, ату тавышларын ишетүләре бар,—диде Коста һәм дивандагы, кәрт өстәлендәге акчаларны сумкага тутыра башлады.

Берничә минуттан Лютый белән дусларын бер өемгә өйделәр һәм өсләренә бензин сиптеләр. "Жигули" ишегалдыннан чыгуга, Бармаксыз йортны баскыч ягыннан яндырып җибәрде, тиздән ургылачак төтен баганасы алар Чимкент юлына чыккач кына күренә башларга тиеш иде.

* * *

Камалов өеннән коралсыз чыгып йөрмәс булды. Элекке угрозыск кешесенә хас сиземләү, тәҗрибә буенча ул үзен кемнендер бик нык күзәткәнен тоемлый, колпак астында икәнен аңлый, ләкин кем һәм ничек күзәткәнне тәгаен генә әйтеп бирә алмас, бу хәл шунда һәм шулай булды дип әйтә алмас иде. Аңа каршы чын профессионаллар эшләгәне сизелә һәм моны оештыручының аны җентекләп өйрәнгәне, аның нинди тормыш мәктәбе үткәнен белеп эш итүе аңлашыла иде.

Соңгы вакытта прокурорны бер күңелсезлек артыннан икенчесе сагалап килә. Берәр зур түрәне кулга алу турында ордерга кул куюы була, тегесе шундук каядыр югала, чыгып кача, ә кайвакыт ул бәндәнең үле гәүдәсен йә паркта, йә берәр чокырда табып алалар. Милкен конфискацияләргә

дип кул куйса, ул йортта коры дивар-стеналар гына утырып кала. Ә өстәлдә дәүләтне имеп яткан байгураның аванстан получкага хәтле очын очка ялгап баручы икәнлеген расларга тиешле унсумлыклар ауный. Вакытлар узгач, өстеннән шикаятьләр язарга нинди җайлы ысул...

Камаловка якын айларда кулга алынырга, ул имза салырга тиешле кешеләр исемлеген төзеп кертканнәр иде инде, ул аны ашыкмый гына һәм игътибар белән күздән кичерә башлады.

"Болардан кайсысын кисәтеп куячаклар, кайсыларын юлдан алып атачаклар икән?"—дип уйлап куйды ул һәм зур исемлектәге һәр эшне хәтереннән уздырды.

Күзләре ирексездән исемлектәге "Ачил Садыйкович Шәрипов" дип язылган юлда туктальш калды. Туганнарында кунакта утырганда ул Совминда зур урын биләүче бу түрәнең исемен телгә генә алган иде, аның хакында җан өшетерлек әллә никадәр хәбәр сөйләделәр дә ташладылар. Кайчагында бу кадәр бай мәгълүматны хәтта прокуратурадан да алып булмый.

Ачил Садыйковичка кияү тиешле майор да алардан ерак түгел, шушы ук мәхәлләдә яшәп ята икән, аның хакында да күп нәрсә ишеттерделәр: культура-агарту училищесы дипломы гына булган кешенең бабасы ярдәме белән ничек ОБХССка кереп урнашуын да, чин-дәрәҗәләрдә туктаусыз өскә үрләвен дә, кай арада гына хан сараедай йорт җиткерүен дә искә алдылар. Берсе дә калмады. Житмәсә кияү мәжлес корырга да бик ярата икән. Кирәк нәрсәне кочаклап та олаулап кына ташыйлар, үзе дә бервакытта да буш кул белән кайтмый.

Шәрипов майтарган саллы-саллы эшләрне яхшы белә иде Камалов, ул сиңа озын куллы кияү-балакай гына түгел. Аның башына кинәт кенә бөтенләй көтелмәгән фикер килде һәм ул тикшерү бүлегенә шылтыратты:

—Сез анда Шәрипов эшен кызулатыгыз әле, ике көннән мин аны кулга алырга ордерга кул куярга тиеш, югарыдан әмер бар,—диде ул серле иттереп һәм бүлмәсенә оешкан җинаятьчелек бүлеге башлыгын чакырып алды.

—Миндә бер план туды әле,—диде ул кискен генә.—Менә шушы адреста яшәүче адәмне күзәтү астына алырга кирәк булыр. Сизенәм, озакламый йә качып китәчәк, йә байлыгын яшерергә тотыначак. Ничек кенә булмасын, сез барысын да белеп торырга тиеш. Кача башласа, кулга алырсыз.

Икенче көнне эшкә килгәндә оешкан җинаятьчелек белән көрәш бүлеге башлыгы алгы бүлмәдә аны көтеп утыра иде инде. Аның борчулы йөзен күрүгә үк Камалов Шәрипов белән нидер булгандыр дип уйлап куйды. Хәер, бүлекнең эше муеннан, һәрберсе ашыгыч, һәрберсе яна торган эш иде, теләсә кайсы минутта ЧП—гадәттән тыш хәл чыгуын көт тә тор. Бу юлы да сизенүе дөрес булып чыкты. Кабинетка кереп тә җитмәделәр, полковник сөйли дә башлады:

—Бер өч сәгатьләп элек кенә, иртән, таң атып килгәндә, Ачил Садыйкович үз бакчасында атылып үлгән.

—Мондый вариантны—тормыш сөючән шундый кешене үз-үзен атып үтерүгә җиткерерләр дип башыма да китереп карамаган идем. Үтерүне яшерергә маташу түгелме?—дип кинәт кенә сорап куйды Камалов.

—Юк. Мөмкин түгел. Безнең кеше ату тавышы ишетелүгә үк коймага ташланган, ул раслый ала. Шәрипов үзе атылып үлгән. Өендә кичтән өч кеше була. Төнгә кадәр утыралар. Музыка уйнаталар, пылау пешерәләр... Табигый ки, минем кешеләр аларны кунаклар дип уйлаган.

Кабинет хуҗасы сәер яңгыраган җөмлә әйтеп куйды:

—Алайса барысы да туры килә икән шул,—диде.

—Шәриповның үләчәген сез ничек алдан ук белә алдыгыз?—дип сорый берни дә аңламаган полковник.

—Юк, мин аны үләр дип уйламаган идем. Качып китүен яисә байлыгын яшерә башлавын гына фараз иттем. Хәзер ул үлгәч милкен конфискацияләү мәсьәләсе дә юкка чыга. Ул барысын да дөрес исәпләгән. Минем күрәзәлеккә килгәндә, алданмагыз, шунсы ачыкланды, минем телефонны кемдер тыңлый.

Көтелмәгән яңалыктан югалып калган полковникка һушын җыярга мөмкинлек биреп Камалов дәвам итте:

—Хәзер үк генерал Саматов белән бәйләнешкә керегез, телефон тыңлау белгечләре һәм яздыру аппаратурасы белән ярдәм итсен иде. Белгечләр килгәч, яхшылап аңлатыгыз һәм үзәк телефон станциясенә барыгыз. Минем телефонны шуннан тыңлыйлар булыр. Шәриповның үлеме бу фаразны раслый, чөнки мин телефоннан аны ике көннән кулга алабыз дип, юри генә әйткән идем.

Төшке ашка китәр алдыннан гына полковник шылтыратты.

—Сез хаклы булып чыктыгыз, телефоныгыз тыңланган. Без япон аппаратурасын һәм байтак язма язылган зур бобинаны кулга төшердек, элемтә инженеры булып эшләүче Фәхретдинов дигән берәүне кулга алдык. Гаебен яшерми дә кебек, ләкин аның аркылы бөтен нечкәлекләрне ачып бетереп булмас, җеп очы бик нык чуалтылган анда...

—Элемтәчене миңа алып килегез, аның белән үзем сөйләшәм,—диде Камалов һәм трубканы аппаратка ташлагач җинел генә сулап куйды. Шикләнүләре дөрескә чыкты, аңа каршы акыллы, оста, тәҗрибәле дошман эшли, хәзер исә койрыкларына басарга җай туып килә иде.

Беренче каттагы ашханәдән бүлмәсенә күтәрелеп тә җитмәде, Фәхретдиновны алып керделәр. Утыз биш-утыз җиде яшьләр тирәсендәге фырт киенгән яшь ир кулга алынуына аптыравын да, югалып калуын да сиздерми, үзен дорфа тотмый иде. Сиздерсә, шул пианистныкына охшаган озын, көн саен карап, тәрбияләп торылган матур бармаклары гына сиздергәндер дә. Шул кулларга карап, аның ата картежник икәнен чамалап була иде. Прокурор яхшы белә: бу афәткә закон да, җәмгыять тә тиешле бәя биреп бетерми, юкса ул, фахишәлек һәм наркомания кебек үк, безнең "югары әхлаклы илебез"дә тамырларын байтактан һәм шактый тирән җибәргән иде инде. Бары күзәтүчән, акыл сизелеп торган күзләрендә генә каушау галәмәтен яшерә алмаган иде егет. Прокурор табигать тарафыннан акыл һәм талант бирелгән, ләкин аларны яман гадәтләреннән үтерткән, бар сәләтләрен, кешелек сыйфатларын һәлакәткә илтүче кәрт уенына багышлаган мондый кешеләрне аз очратмады.

Прокурор каршында шундый кара язмышка дучар кеше утыра иде булса кирәк. "Азартлы уеннардан котыласың юк, булмый да, төзәлергә тырышу—бушка азаплану",—дигән иде кайчандыр аңа Мәскәүдәге зур бер шулер.

—Тыңлыйм сезне,—диде кабинет хуҗасы.

Мондый сәер башлангыч элемтәчене чак кына да кыенсындырмады бугай.

—Минем сезгә әйтәсе сүзем юк, белгәнемне әйтеп бетердем инде. Тәүбә итүем генә башка берни дә өстәмәс,—диде Фәхретдинов тыныч кына.

—Телефон тыңлау белән күптән шөгыльләнәсезме? Андый заказлар еш буламы??

—Элемтә министрлыгында унбиш ел эшлим, белгеч буларак яхшы исәптә, ләкин моңа кадәр беркемнең дә мондый тәкъдим белән килгәне булмады. Килсәләр, шөгыльләнмәгән булыр идем дип тә ышандыра алмыйм, турысын әйткәндә, андый ихтыяж, тәкъдим юк иде. Ышансагыз—ышаныгыз, ышанмасагыз—юк.—Һәм ул җилкәләрен җыерып куйды.

—Минем телефонны контрольгә алырга заказ кем бирде, прокуратура эшләре белән кем шулай җентекләп кызыксына?

—Сезнең прокурорларча карашыгыздан ук минем кәрт уены маһиры, катала икәнлегемне сизгәнегезне аңладым инде. Бөтен гаеп кәрт уенында, җавапны да шуннан башлыйм, бәлки сезгә кайбер нәрсәләр ачыкланыр. Моннан бер өч ай элек булыр, мин рәттән ота башладым һәм бу шактый озак, биш-алты атналап дәвам итте. Зур акчалар да отмадым отуын, ун еллап әвәрә килеп йөрсәм дә, мин үзем уртакул уенчылардан исәпләнәм. Уенчылар арасында мине беләләр, оттырсам, вакытында түләп барам, безнең мохитта исемне пычратырга ярамый. Исемнең дәрәҗәсе никадәр югары бәяләнгәнен сез беләсездер. Ләкин соңыннан кул китте, бер-ике тапкыр

бик күпләп оттырдым, элек андый оттырышка бармый идем. Әмма соңгы уңышларым башны әйләндергән иде инде, һаман отасым, күбрәк отасым килә башлады, ставкаларны күтәргәннән күтәрә бардым. Хәзер аңлыйм мин, отарга тиеш булмаганмын, миңа каршы атаклы оста уйнаган, элеккеге отышларны да кемдер оештырган булган. Кыскасы, миңа "счетчик" куйдылар, әти-әнидән калган йортны сатарга куштылар. Ә гаиләне, балаларны кая куйыйм, кая барып сыеныйм? Алар сораган сумманы табу турында сүз дә булырга мөмкин түгел, мин аны кычкырып әйтергә дә куркам, ул теләсә-кайсы нормаль кешене дә акылыннан шаштырачак.

Шул арада минем әҗәтне көтмәгәндә икенче кешегә күчергәннәр, аны уенчылар арасында күргәнем юк иде. Хәер, оттырган кешемне дә элек белми идем, анысын Махачкаладан килгән катала диделәр. Алай дисәң, бездә откан яисә оттырган уенчының кайда торуы, кайдан килүе мөһим түгел, оттырдыңмы—түлә! Мин инде качып китү, үз-үземә кул салу турында да уйлый башлаган идем. Шундый көннәрнең берсендә миңа әҗәтемнең яңа хуҗасы шылтыратты, "Җину" паркындагы "София" кооператив кафесында очрашу билгеләде. Шунда ул әҗәтне басу хисабына бер телефонны тыңлауга куярга кушты. Мин сорыйм: "Кемнекен?" Ул көлеп кенә куйды, минем хәлдәге кешегә андый ахмак сораулар бирергә ярамый, диде, кемне тыңласаң да барыбер түгелмени. Тыңланачак кешене ул әйтмәде. Мин ризалык биргәч, эш урынында очрашырга килештек. Сөйләшенгән вакытта, смена башланырга бер сәгать кала, бинада үзем генә чагында, кара күзлек кигән ике егет килеп керде, алар эшләрен менә дигән итеп беләләр икән, сезнең телефонга ялганып та куйдылар. Минем бурыч, шылтыратып әйтүгә, бобинаны алып кеше мыжгып торган автобус тукталышына чыгудан гыйбарәт икән. Язмалы бобина тоткан кулымны аркага куеп, шунда йөренеп торырга тиешмен. Аны кирәкле кеше алып китәчәк, ләкин мин бернинди очракта да борылып карарга тиеш түгелмен. Мин гел шулай иттем дә, бобинаны кем ала дип кызыксыну башыма да кереп чыкмады, ул да минем кебек бихәбәр берәр бәндә булгандыр.

—Оста, оста эшләнгән,—дип бүлдерде каталаны прокурор, ул әле һаман аны каушатырмын дип ышана иде.

Ләкин элемтәче, ял итеп утыргандай, бер аягын икенчесе өстенә куйды, прокурорның чәнчеп әйтүенә дә карамастан, исе дә китмәстән, әйтеп салды:

—Беләсезме, иптәш прокурор, бу эш артында кем торганын белсәм дә, мин аның исемен атамас идем.

Хәзер инде кабинет хуҗасы гаҗәпләнде:

—Аңламыйм. Нигә җаваплылыкны үз өстеңә генә алырга? Башкалар белән дә бүлеш. Чын күңелдән гаебеңне тану, эшләгән җинаятеңә үкенү законда игътибарга алына.

Фәхретдинов кинәт кенә ихластан көлеп җибәрде һәм әйтеп салды:

—Беләсезме, Ташкентта сезнең хакта сүзләр күп йөри, принципиаль кеше икән, сатылмый, максатына ирешүчән, тагы әллә ниләр дип мактыйлар. Сезнең телефонга утырганнар икән, димәк, сез байтак власть ияләренең юлына аркылы төшкәнсез. Ләкин мин сездән "гаебеңне тану, җинаятең өчен үкенү" сүзләрен көтмәгән идем, бу бит баналь нәрсә, балалык. Сез моны уйлап әйтәсезме? Сез миңа чыннан да барысын да сөйләргә, тәүбә итәргә кушасызмы?

—Ә нигә сөйләмәскә ди?—Прокурор аның ачылуына ышанып бетми иде.

—Беләсезме, эшемдәге җинаятем өчен миңе күп булса өч елга утыртачаклар, әле бу кадәр срокка статья таба алуыгыз да шикле. Әгәр инде кем заказын үтәгәнемне белгән булсам, ә баш прокурор хәтле баш прокурор белән көрәшкә чыккан кешеләр төшеп калганнардан түгелдер, аларны сезгә әйтсәм, ягъни тәүбә итсәм, миңа бер генә генә хөкем—үлем җәзасы гына булыр иде. Лагерьда үтерәләрме, аннан кайткачмы—барыбер бер җирдә тәгәрәтәчәкләр. Сезнең белән кызыксынган кешеләрнең исемнәрен әйткән минуттан ук миңа үлем карары чыкты дигән сүз. Оттырыш өчен "счет-

чик"тан котылып булмаган кебек, ул карардан да котылу юлы юк. Моны юләр дә белә.

Җинаятьчелек сыртына сорыкорт булып ябышкан, алар тәлинкәсеннән ашаучы һәм үзләрен гуманист дип шапырынучы сөләгәй юристларның, халык арасында очсызлы дан казанырга, көнбатыш илләрендә демократ исеме күтәрергә атлыгып торган каләм пычратучы сатлыкҗан язучылар һәм журналистларның гына башында бер нәрсә—ничек тә булса үлем җәзасын юкка чыгару, җинаятьченең тормыш-көнкүрешен яхшырту, амнистия уйлап чыгару һәм теләсә нинди сылтау табып төрмә ишекләрен киңрәк ачу. Ә бит алар, сатлык юристлар, белми түгел белә: җинаятьчел дөньяда вәгъдәсеннән бер генә адым читкә тайпылганнарга да үлем, бары тик үлем җәзасы. Картларны да, яшьләрне дә җәлләп тормыйлар. Хәзер, белсәм дә әйтмәсемне аңладыгызмы инде? Тагы... Сатмыйм икән, мин төрмәдә дә аерым бер хәлдә, мактауда булам, сез бит төрмәдәге хәлгә хуҗа түгел, анда кем—баш, кем—аяк икәнен яхшы беләсез. Җинаятьчел дөнья сез түгел, ул туры, тугры булганны ярата; ә сез җәзалый да, кешечә бүләкли дә алмыйсыз, үзегез сөләгәй булгач, сөләгәйләргә таянасыз да!

Фәхретдинов ипле итеп, сүзләрне сайлап кына сөйләсә дә, прокурор аның мәнә-мәнә истерикага биреләчәген абайлап алды һәм өстәл астындагы кнопкага басты. Кабинетка шунда ук ишек артында гына торган оперативник килеп керде һәм инженер-каталаны алып чыгып китте.

Фәхретдинов чыгып киткәннән соң, прокурор телефон шылтырауларга игътибар итмичә, озак кына кабинеты буйлап йөренде, кәефе төшүнең сәбәбе күзгә күренмәс мәкерле дошманның бу юлы да йөзен ачмыйча шома балыктай кулдан ычкынуында гына түгел иде. Хафага салырлык нәрсәләр күп. Иң әчен пошырганы—кулга алынган элемтәче инженер хаклы иде. "Сездән бүләк тә юк, күсәк тә юк!" дигән сүзләрен исенә төшерде. Моңа ничек җавап бирергә? Камалов лагерьларда кеше үтергән, кычкыртып талаган өчен сигезәр, уникешәр мәртәбе хөкем ителгәннәрнең утыруын белә, аларны инде унөченче тапкыр хөкем итү лагерьда бөтенесен дер селкетсен, чираттагы бер мескенне үтерсен һәм гуманист-юристлар яраткан схема буенча тагын ундүртенче тапкыр җаваплылыкка тартыр өченме?! Бәлки, өч-дүрт тапкыр утырганнан соң берәр чик билгеләргә кирәктер, аннан соң инде электр урындыгы, бары шул гына, бәлки, җинаятьчелекне киметә алыр да.

Телефонын тыңларга кушучыларның кем икәнлеген Фәхретдиновның белмәвенә ул ышана иде, заказчыларны сатса, инженерны шиксез үлем көтүен дә белә, андый тәвәккәл адымга барган кешеләрдә, табигый ки, мәрхәмәт, шәфкать юк та юк инде ул.

Прокуратурага һәм шәхсән аңа бар нәрсәне алдан уйлап эшли белүче акыллы һәм усал дошман көрәшүенә ул кире каккысыз дәлилләр алды.

Инженерны кулга алуга йомгак ясап, бу хәлдә аның кайбер отышлы яклары да булуын билгеләп үтмичә кала алмады. Телефон станциясендә кулга алу белән ул каршы якка үзенең алар хакында белүен, маневрларын чамалавын сиздерде. Картежник элемтәче кулга алынуның каршы якта нинди гасабилык, паника тудыруын аңлау кыен түгел. Телефонын тыңлауларын прокурор каян белгән, берәрсе сатмаганмы, дип баш ваталардыр. Тагын нинди чаралар күздә тотыла? Кыскасы, аңа да, каршы якка да борчугамь җитәрлек иде.

Камалов кабинет буйлап йөрөнә торгач урам якка караган тәрәзә янына килеп басты. Каршыда, юлның икенче ягында, өч салмыш адәм, кулларын селки-селки нәрсәдер хакында кызып-кызып бәхәсләшә иде. Көзге җил аларның пиджакларын кабарта, һәм алар, җилкәнле көймәдәй, бер урында тора алмыйлар, боргаланып-сыргаланып ниндидер сәер йола биюен башкарган кешеләрне хәтерләтәләр иде.

—"Парус һәм градус астында",—дип куйды ул, урыс сүзләрен катыштырып сүз уйнату җитди һәм корырак кешегә каян килгәндер, ул моңа үзе дә төшенми калды.

Әлеге биюче төркем һәм күзгә урам анын карашын ирексездән үзенә тарта иде, ә могҗизалы үзгәрешләр дәвам итте. Көнбатыштан исүче һәм һаман көчәя баручы җил пиджаклары белән генә түгел, инде күптән модадан чыккан, киң, озын, галстуклар белән дә уйнарга кереште. Алары исә, төсле еланнар сыман боргаланып, пиджак изүеннән килеп чыгалар да каршыдагы шешәдәшнең йөзен, күкрәген, корсагын "чагып" алалар. Ирләрнең бер минутка да туктамыйча биюе, бу кызыл, буйлы һәм чуар галстукларның һәмишә җилфердәве вә чагуы прокурор күз алдында хыялый сурәт тудырды, ул инде кешеләрне күрми, алар артында ниндидер авыр һәм ябышкак, аңны томалаучы куркынычлар тулы рәсем генә торып калды. Анын башы әйләнеп китте, гүя тәрәзәдән сикерермен дип курыккандай, кинәт кенә артка чигенде.

Күлмәк якасын ычкындырды, галстугын бушата төште һәм янәшәдәге урындыкка ауды. Барып чыктың, инде күз алдында галлюцинацияләр башланды, ял итәргә, туйганчы бер йокларга иде, дип уйлап куйды ул. Отпускы алмаганга да ничә ел булгандыр. Чыннан да, Мәскәүдә дә коррупциягә каршы көрәш буенча махсус вәкаләтләр бирелгән көннән башлап анын ял иткәне юк икән бит.

Тагын берничә көн узып китте, әмма дошман үзен берничек тә сиздермәде. Теге яки бу чараны планлаштырганда төрле капкыннар, тозаклар да күздә тотыла иде тотылуын. Әмма дошман аларны оста гына читләтеп үтә белде.

Телефон белгечен кулга алганнан соң бер атна узгач, Камалов прокуратурада ике мөһим киңәшмә уздырырга карар кылды һәм икесенә дә Сухроб Әхмәдовичны чакырмаска дигән уйга килде. Моңа ничек карар икән? Дөрес, телефонын тыңлауда турыдан-туры аннан шикләнерлек нәрсә юк иде. Ләкин "колпак" астына алганнан бирле мондый да югары урында утырган кешене бер дә бизәми торган бәйләнешләре барлыгы ачыкланганнан-ачыклана бара иде.

Сухроб бөтен республикага киң җәелгән кооператив предприятиеләр хуҗасы, коточкыч зур суммалар белән эш майтаручы ниндидер Шубарин белән якын дус иде. Анысы исә үзгәртеп коруга кадәр яшерен цехлар тоткан һәм күләгәдәге икътисад хуҗаларының берсе булган, имеш. Камаловның бу хакта ишеткәне бар иде инде. Ул хәзер бизнесын легальләштергән, законлаштырган, казнага налогларын тәртипле түләп бара һәм кооператорлар арасында законлы миллионы булган беренче кеше икән.

Рәсми танылган миллионер сәясәткә һич тә битараф түгел иде, киресенчә, байтак партия бослары анын дусларыннан исәпләнә, Шәрәф Рәшидовичны да бик яхшы белгән, Акмал хан белән исә әшнәләнеп беткән. Анын затлы-кыйммәтле "Лидо" ресторанында шактый еш булуы хакында да мәгълүмат бар. Ресторанның хуҗасы булып Әкрәмхуҗаевнын иң якын дусты, Югары судтагы Сәлим Хашимовнын сөяркәсе, элеккеге фольклор ансамбле биючесе Нәргиз саналуы да билгеле иде. Расланмаган фактларга караганда, ҮКнын административ эшләр бүлеге мөдире "Лидо" эшчәнлегенә ниндидер финанс кызыксынуы да күрсәтә икән.

Үзәк Комитеттагы шефын чакырмыйча гына бер-бер артлы үткәрелгән ике мөһим киңәшмә, әгәр ул чыннан да прокурорга карата итәк астыннан ниндидер эш йөртсә, аны активрак хәрәкәт итәргә, үзен күрсәтергә мәҗбүр итәргә тиеш иде кебек тә, ләкин вакыйгалар агышы бөтенләй икенче якка кереп китте.

Беренче киңәшмәдә төп докладны ясаганда Камалов үзенең бите буйлап ике тапкыр көзгедән төшкәндәй кояш нуры йөгереп узганын сизде. Ул көнне артык әһәмият биреп тормаган, хәтта ни булыр икән бу дип, башына да кертеп карамаган иде. Ләкин бу хәл икенче көнне дә кабатланды. Оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш бүлегенә яшерен күрсәтмәләр биреп утырган чак иде ул. Бу юлы башыннан яшен тизлегендә гөман йөгереп узды һәм ул сүзен бетерүгә үк алдындагы кәгазьгә тиз генә "Теләсә нинди сылтау белән бер ун минуттан мине кабул итү бүлмәсенә чакыр" дигәнне сызгалап ярдәмчесенә сузды.

Берничә минуттан ул кабул итү бүлмәсендә иде инде. Ашыгып угрозыск башлыгы, берничә тапкыр операцияләрдә бергә катнашкан полковник Чураевның телефонын җыйды. МВД органнарында төс-кыяфәтен алыштыра белүче "убыр"ларның байтак икәнен белгән Камалов аңа үзенә ышангандай ышана иде.

Бәхеткә, полковник урынында иде, ул прокурорны тавышыннан ук танып алды:

—Ни йомыш бар иде? Вак-төяк аркасында борчымаганыңны беләм,—диде.

—Кеше ышанмаслык хәл. Миңа калса, безгә каршы яктагы бина түбәсендә бинокльле кеше утыра һәм яшерен киңәшмәдә ясалган докладны, сөйләнгән сүзләрне иреннәрдән укып магнитофонга яздырып бара. Мин моңа бер тамчы да шикләнмим. Прокуратурада әкият сөйләп яталар, йә булмаса, акылдан язганнар дип уйлый күрмәгез.

—Юк. Мин алай дип уйламыйм. Безнең якларда иренгә карап сөйләгәнне укый белүчеләр аз түгел. Алай гынамы, нинди эшләр күтәреп ятканыгызны белгәнгә әйтәм, мин үзем, мәсәлән, кайдадыр якында гына япон электроникасы белән шыплап тутырылган автофургон булса да гаҗәпләнмәс идем. Аннан бернинди тоткарлыксыз сезнең киңәшмәне тыңлап утыра алырлар иде. Җинаятьчеләрнең техник яктан камиллеге мине шаккаттыра. Әле менә алардан кулга төшерелгән җайланмалардан күргәзмә ясарга җыенабыз. Ул күп яктан күзегезне ачар, уйландырыр, дип ышанам. Сезнең хәбәргә килгәндә, киңәшмәне дәвам итегез, түбәдәге кешене куркыта күрмәгез, мине шушы минутта ук чыгып китте, дип исәпләгез.

Бер сәгатьтән прокурор киңәшмәне тәмамлаганда, полковник Чураев аны кабул итү бүлмәсендә көтә иде инде.

Камалов шунда ук аны кабинетына чакырды, гөман кылуына үзе дә ышанып бетмичәрәк, түземсезләнеп сорады:

—Хәлләр ничек анда?

—Сез хаклы булгансыз, ләкин без тиешенчә эшли алмадык,—диде полковник үкенү белдереп.

—Качтымыни?

—Үпкәләтмәгез, без андый ялгышларны җибәрмибез. Тере килеш алып булмады.

—Качарга маташкандамы?—дип өзелеп чыкты прокурорның тавышы.

—Бөтенесе дә уйламаганча, көтмәгәнчә килеп чыкты. Бу юлы чын эзгә төшә алуыбыз да икеле. Тыңлап кына кара. Сезнең шылтыратудан соң ун минуттан мин милиционерлар белән өйдәге һәр ике подъезддан түбәгә күтәрелгән идек инде. Сезнең тәрәзәләрдән чамалап, прокуратура эшләре белән кызыксынучының кайдалыгын ачыклау кыен булмады. Ялгышмаганбыз. Ул нәкъ шунда иде. Эшенә шулкадәр бирелгән иде, ике яктан килеп чыгуыбызны сизми дә калды. Хәтта качарга уйламады да, язманы сөртерергә җыенганда гына кулына богау төште. Янгын сүндерүчеләр өчен куелган баскычка таба алып барганда кинәт кенә сөрлегеп китте дә егылды. Мин әле "Куркуыңнан аякларың тотмыймы",—дип шаяртып та алдым. Ләкин ул җавап бирмәде, аягына тормады. Өстенә иелгәч кенә күкрәк турында, күлмәгендә кызыл кан табы күреп алдым. Пуля туп-туры йөрәккә барып кергән. Күрәсең, аның эшен саклап торганнар. Без ату тавышын ишетмәдек. Үз һөнәренең остасы тавыш йоткычлы мылтыктан аткан булырга тиеш. Тотылган адәмнең кесәсеннән машина йөртү таныклыгы чыкты. Берничә минуттан аның кем икәнлеге ачыкланачак.

—Кызганыч...—Камалов чын ихластан уфтанып әйтте.—Берьюлы күпме табышмак. Ә бит ул кешедә күп сорауларга җавап булгандыр.

—Борчылмагыз,—диде Чураев.—Андый куркынычка барган кешеләр, ярты юлда калмас, аларның максатлары бар, үзләрен тагын сиздерми калмаслар. Уяу булырга гына кирәк.

Шул ук минутта бүлмәгә ярдәмчесе белән полковникның бер кешесе килеп керде.

—Йә, белдегезме кем икәнен?—диде артык кызыксынудан түземсезләнгән Чураев.

Кергән кешедән алган кәгазьне Чураев кычкырып укыды:

—Айдын Бәйбулатов, месхет төреге, утыз яшьтә, хөкем ителеп төрмәдә утырган. Күптән түгел генә Аксайда яшәгән, Акмал ханның якыннары арасында булган.

—Аксай? Акмал хан?—диде прокурор аны бүлдереп.—Җеп менә кая сузыла икән...

Милиция кешесе пуляны да Чураевка бирде:

—Экспертлар иң яңа конструкциядәге автомат коралдан атылган, диделәр. Пуляның гадәти булмавына караганда, чит ил коралы булырга тиеш.

Чураев пуляны җентекләп, әйләндерә-әйләндерә карады да прокурорга сузды.

—Гади күз белән караганда да безнеке түгеллеге күренеп тора,—дип раслады прокурор.

Милиционерлар чыгып киткәч, күңеле күтәрелгәнлеге сизелеп торган Чураев әйтеп салды:

—Менә эзләренә дә төштек, ә сез кайгырган идегез. Акмал ханның яңадан калкып чыгасын көтмәгән идегезме? Тәҗрибәмә ышаныгыз, бу урында тагы ун ел эшләсәгез дә, әле күп нәрсә турыдан-туры яисә кыеклатып Акмал ханга бәйле булачак, аның мирасы—мәңгелек.

—Шулай да, Аксайдан килгән яшь егетне үтерүче җан кыюны чүпкә дә санамаучы куркыныч бәндә,—диде прокурор. Ул һаман Айдынның үлемен күз алдыннан үткәрә иде әле.

—Фикерегезне ачыграк итеп әйтеп булмыймы?—дип, кинәт кенә дәртсенеп китте Чураев.

—Яшь төрекнең үлемендә мәгънә күрмим мин,—диде прокурор.—Үтерүне оештыручы куркыныч адәм, аңа кеше гомере—сукыр бер тиен. Дошман аяусыз, ә без аның хакында әлегә берни дә белмибез. Ул үзен ике тапкыр күрсәтте инде, өченчесендә, бәлки, без дә аның йөзен карый алырбыз. Читтән генә булса да...

—Мин бер нәрсәне искә төшердем әле,—диде полковник уйчанланып.—Бу зобаныйның аяусызлыгы турындагы уегыз хәтеремдә элеккеге бер җинаятьне уятты. Анда да Айдын кебек үк барысын да төгәл, кушканны намуслы үтәгән берәү ирекккә чыгарга ике адым калганда үлемен тапты. Бер үк кул уйный кебек, бер үк кабахәт ысул.

—Җентекләбрәк сөйли алмассызмы?—диде прокурор һәм өстәлдә яткан диктофонны кабызып куйды.

Чураев сүзнең озак буласын белдереп, чәйнеккә ымлады һәм сүзен башлап җибәрде:

—Бу шактый элек булган хәл, Рәшидов үлгән көздә, төгәлрәге, аның вафатын әле күпләр белмәгән чакта, ягъни үлеменең икенче көнендә. Шул вакыйганың беренче өлешенә минем дә турыдан-туры катнашым булды.

Ләкин бөтенесе дә аңлашылырлык булсын өчен вакыйгаларны артка чигенеп, димме, башларга тиеш булам. Ул чакта иңнәремдә капитан погоннары иде әле һәм мин Ташкенттан шактый еракта эшли идем. Өлкә прокуратурасына Әмирхан Даутович Азлархановов, сезнең кебек үк Мәскәүдән җибәрелгән кеше, җитәкчелек итә иде. Себер татарларыннан иде бугай. Утыз алты яшендә ул республикада иң яшь җитәкчеләрнең берсе иде. Намуслы, гадел, тирән белем алган егеткә матур киләчәк телисе иде дә бит. Шул гаделлеге харап итте, димме, көнләшүчеләре, дошманнары күбәеп китте, үзе югында аны Реформатор, Теоретик дип кенә йөртә башладылар. Ташкентта, республика прокуратурасында сөйләгән докладларын бүгенгедәй хәтерлим, күпме бәхәс, шау-шу тудыралар иде алар. Бервакыт төн уртасында минем өйгә шылтыраттылар, милициядән хәбәр килде, өлкәнең иң ерак бер районында аның хатыны Ларисаны үтергәннәр. Лариса сәнгать белгече, Урта Азия халыкларының гамәли сәнгатен өйрәнә, дөресрәге, Шәрекъ керамикасы үрнәкләрен җыя иде. Коллекциясе шаккатыргыч бай. Фәнгә

чын көнелдән бирелгән кеше буларак, халыкара мәйданда да абруйлы санала, сәнгать буенча чыгарган альбомнары бар, чит илләрдә күргәзмәләр оештыра. Ә аны көч ачып йомганчы төсле фоторәсемнәр ясый ала торган "Полароид" фотоаппараты өчен генә үтереп ташлаганнар булып чыкты. Миңа ул чакта вертолет бирделәр һәм мин шунда ук җинаять булган урынга чыгып та киттем. Кичкә үтерүче тотылды, ул өлкәнең иң бай һәм инде ун еллап хакимият башында утыручылардан берсенең улы булып чыкты.

Егет юридик факультетның дүртенче курсында укый һәм үзен прокурор булачак кеше дип йөри икән. Менә шуны күтәрә алмады Әмирхан Даутович, йөрәге чыдамады. Сорау алган вакытта инфаркт булды аңа. Теге егеткә килгәндә, ул, чыннан да, үзе кеше үтергән районның прокуроры булды да. Монысы бераз соңрак. Ә Азлархановике ай больницада яткан арада, туган-тумачалары эшне шулай борып җибәрделәр ки, рәшәткә артына бөтенләй икенче кеше кереп утырды. Больницадан кайткач, боларны белгән Әмирхан Даутович күпме бәргәләнде, көчсезлектән, чарасызлыктан тагын икенче тапкыр инфаркт алды, тагын ярты елга көрәштән туктап торырга мәҗбүр булды. Ул чирләп яткан арада өлкә түрәләре минем астан ут йөртә башлады, китеп өлгермәгән булсам, һичшиксез, берәр ялган "эш" маташтырып, башыма җитәчәкләр иде. Аптыраганнан Әмирхан Даутовичка, ул Кырымда ял итә иде, икенче бер өлкәгә күчәргә ярдәм итүен сорап, хат язып ташладым. Шулай итеп, Ташкентка килеп эләктем. Ике инфаркттан соң азмы-күпме аякка баскач, Азлархановтагы Бекхуҗаевлар нәселе белән көрәш башлап җибәрде, ә боларның туган-тумачалары район белән өлкәдә генә түгел, бөтен Ташкентка җәелгән. Көчләр нисбәте шулкадәр тигезсез, прокурорны шундый итеп кысалар, ул бернисез кала: урыныннан куалар, өен тартып алалар, партиядән чыгаралар, исемен пычратып-буяп бетерәләр, ахырдан психбольницага илтеп тыгалар. Шуннан ул ун ел яшәгән шәһәрне ташлап китәргә мәҗбүр була, аны беркайда эшкә алмыйлар, хәтта юристконсульт урыны да табылмый. Теге нәсел аны шулай итеп буа.

Ул вакытта мин Ташкентта идем инде.Өч балам бар, хатыным дүртенчесе белән көмәнле, торырга квартирым юк, угрозыскның гади бер хезмәткәре идем, мыскыл ителгән, тапталган, бер гөнаһсыз килеш өстенә гаеп-гайбәт өелгән прокурорга ярдәм итә алмадым. Шул нәсел белән көрәшкә әллә ничә ел сарыф итте ул. Хатыны үлүгә биш ел узганда ул икенче бер өлкәдәге кечерәк шәһәргә күченеп китте. Бу шәһәр җинаятьчел "эш"ләрдә еш очрый, аны Лас-Вегас дип кенә йөриләр. Менә шунда ул кечерәк кенә бер консерв заводында юрисконсульт булып эшли башлый. Рухи сынган, сәламәтлеге дә елдан ел начарлана барган кеше тыныч кына үзенең соңгы көннәрен яшәп ята.

Нәкъ менә шул чакларда аның тормышында кискен үзгәрешләр башлана да. Лас-Вегасның мул ганимәтле эшкуарлары аны юрист итеп алалар. Һәм ул җәмгыятьтә тоткан урынына кире кайта башлый, дәрәҗәле туйларда күренгәли, кунакка чакырулар ешая. Законнарны тирәннән белгән һәм аларның төп көч икәненә инанган кешенең Лас-Вегаста миллионер—цеховиклар белән эшләвен ишеткәч, колакларыма ышанмадым. Соңыннан, бераз һушымны җыйгач, тормышта барысы да булырга мөмкин, и Ходаем, ул кичергәннәрне кичерергә язмасын, дидем.

Гомумән, мин аны хөкем итә дә, ачулана да алмадым, бу дөньяда күп яшисе калмаган иде инде, ә иң мөһиме, аны мин хөрмәт итә, ярата идем. Һәм хаклы булып чыктым, соңыннан вакыт аның Законга, Хокукка, Гадел хөкемгә тугры калганлыгын күрсәтте. Рәшидов үлгән көнне, эш бүлмәмдә телефон шылтырады, прокурор Азлархановның дулкынланган тавышы ишетелде. Ул нәкъ ярты сәгатьтән республика прокуратурасына килүемне сорады. Берни дә аңлатып тормады, ләкин мин ниндидер бик мөһим, иртәгә калдырып булмаслык эш килеп чыкканын төшендем. Очрашуга бер-ике минут кына соңга калдым, ерактан ук мин аны күрдем дә—аны бер егет куып килә иде. Әмирхан Даутович прокуратураның вестибюленә йөгереп керде, менә шунда аны эзәрлекләп килүче, кулындагы "дипломат"ы өчен

булса кирәк, атып үтерде дә. Үтерүчене тоттык без, ләкин дустымны коткарып кала алмадым.

Кыскача, менә шундый хәлләр. Ә хәзер кыйссаның икенче, баш житмәслек сәер өлеше башлана. Бәлки ул сезне Айдынны үтерү белән бәйле мәсьәләләрдә кайбер фикерләргә этәрер.

Шулвакыт кабинетка чәйнек күтәреп сәркәтип кыз килеп керде һәм прокурор полковникка чәй ясарга ашыкты. Бу вакыйгалар Камаловны кызыксындырып җибәрде, башында кайбер фикерләр дә оеша башлады инде. Ләкин сөйләгәннәренең анда нинди тәэсир калдыруын ачык тойган полковник шәрекъ кешеләренә хас салмаклык белән ашыкмый, кабаланмый гына бер чынаяк чәй эчте, икене эчте, бары шуннан соң гына дәвам итте:

—Әгәр "дипломат"ын эзәрлекләүчегә бирсә, ул исән калачак иде, ләкин мескенләнмәде, иң ахыргы мизгелдә дә нык калды. Хәтта үлеп барганда да җинаятьченең күкрәгеннән кулын ычкындырмады. Җинаятьчене тоткач, мин үз вазифам үтәлгән дип санадым. Прокурорның "дипломат"ын тикшерү бүлеге начальнигына бирдем, иртәгә республика прокурорының үзенә тапшырырсың, дидем.

Иртән эшкә килеп өстәлемдә яткан сводканы карагач тораташтай каттым да калдым. Төнлә прокуратурага бәреп кергәннәр, сейфны ачканнар, минем дустым Азлрханов гомере белән түләгән "дипломат"ны урлаганнар булып чыкты. Ишегалдында ике үле гәүдә ятып калган: берсе дежур милиционер, икенчесе Кощей кушаматлы сейфлар ачучы.

Камаловның тиз генә нидер язып куюын күреп, полковник тагын да саллырак итеп өстәде:

—Ләкин моның белән генә бетми әле, ул төннең бер вакыйгасы МВДның иртәнге сводкасына керми калган. Эзәрлекләүчене тотканда аның умырткасына зыян килде, рентгенка төшерү өчен аны Травматология институтына алып киттеләр. Төнлә җинаятьчене больницадан урлап чыгып киткәннәр, без аның хәтта шәхесен дә ачыклый алмый калдык. Шәраф Рәшидовичны олылап соңгы юлга озатыр алдыннан менә шундый вакыйгалар булып алган иде.

Шул ук көннәрдә прокуратурада Үзбәкстанда талап-азып йөргән Ростов бандасы турында да берничә эш карала иде. Усал, миһербансыз һәм мәрхәмәтсез кешеләрдән торган төркем аяусыз талау белән шөгыльләнгән, хәзер аны рэкет диләр. Сейфны ачкан, операцияне саклап торган кешегә "дипломат"ны алып чыгып биргән бәндәнең кесәсеннән Ростовка кадәр алынган билет чыкты, аның Ростовта туып-үскән Кощей бандит икәнлеге ачыкланды. Җинаятьләрне эзләү бүлеге, шулай итеп, Ростов версиясен күздә тотып эш итте, моның җирле мәнфәгатьләргә кагылганлыгын башына китереп караучы да булмады. Күрәсең, прокуратураның эш тәҗрибәсен бик яхшы белгән берәү кеше гомере бәясенә тикшерүне ялган юлдан җибәргән.

—Нинди кеше бәясенә?—дип сорады Камалов, үзе өчен нидер ачыкларга теләп.

—Сейфны ачкан, "дипломат"ны заказчыга биргән кеше.

—Әйе, сез хаклы, бу вакыйга кай ягы беләндер Айдынныкына охшаган,—диде прокурор аның белән ризалашып.

—Минә калса, операциянең ничек үтүен саклап торган кеше белән заказчының бер үк бәндә булуы ихтимал, прокуратурадагы каравылчыны үтерергә ул мәҗбүр булган, ә Кощейны исә тикшерүне тупикка кертер өчен, алдан ук уйлап куелганча, махсус рәвештә үтергән. Инде шул чакта ук миңа бу кеше хокук органнарын яхшы белүче, арабыздагы кыяфәт алыштырырга һәвәс хаиннарның берсе түгел микән дигән уй кергән иде.

—Тикшеренү эшләре ничек барды?

—Мин кызыксынып тормадым, чөнки прокуратура үз эшләренә борын тыкканны яратмый. Белгән кадәре шул, Ростов версиясенә ел ярым вакытны әрәм иткәч, тикшерүчеләр буталып бетте, эшне киштәгә куйдылар. Ләкин ул минем башымнан чыкмады, чөнки минем дустыма бәйләнгән иде ул. Менә бүген генә мин Кощей белән Айдынның үтерелүе арасында нииндидер

охшашлык, тәңгәллек тойдым. Элеккеге үтерү белән тагын бер охшашлык бар: Айдынның үлемендә дә прокуратура эшләрен яхшы белүче кеше кулы сизелмимени, сезнең кабинетта яшерен киңәшмә буласын теләсә кем белми иде, радиодан яисә телевидениедән игълан итмәгәнсездер ич...

—Дөрес, мин бу хакта ничектер уйламаган идем. Хәтта миндә киңәшмә буласын белгән кешеләрне тамгалап, билгеләп чыгарга да була.

—Ул исемлек белән дә эшләргә туры килер,—дип катгый итеп өстәп куйды полковник.—Аны миңа да күрсәтсәгез начар булмас иде. Мин мондагы күпләрне беләм, кайберләренең берьюлы ике урындыкта утыруын да чамалыйм, ләкин минем урындагы кешегә аларга якын килү авыррак, чөнки билгән кәнәфиләре артык югарыда.

—“Дипломат”ны нигә үзегез белән МВДга алып китмәдегез?

—Беренчедән, читенсендем, ни дисәң дә прокуратура надзор ясаучы инстанция. Икенчедән, “дипломат”ны алып китсәм, җитәкчелеккә бу турыда әйтергә туры киләчәк иде, ә алар арасында куылган прокурор Азлархановшәхесенә артык кызыксыну күрсәтүчеләр аз түгел. Кейста МВДның югары җитәкчелегенә кагылган кәгазьләр булу ихтималын да истән чыгарырга ярамый иде.

Берничә тапкыр ярдәмчесе кереп чыкты, Чураев прокурор Камаловның ашыгыч эшләре килеп чыкканлыгын чамалап алды һәм шәрекъ йолаларын саклап тормыйча, тизрәк саубуллашуны мәгъкуль күрде. Китеп барганда әйтте:

—Миңа бу эштәге шикле нәрсәләрне җиткерә барыгыз әле, вакыйгалар шул кадәр тиз әйләнеп китте, аларны инде туктатып булмаячак,—диде.

Камаловның кабул итү бүлмәсендә аеруча мөһим эшләрне тикшерүче Мәскәү юристлары җыелып өлгергән иде инде, һәркайсы прокурордан нинди дә булса җитди документка кул куйдырырга килгән. Ләкин алар арасында кемне дә булса кулга алырга рөхсәт сорап килүчеләр күбрәк иде.

Керүчеләр агымы бераз кимүгә прокурор диктофонны кабызып җибәрде һәм полковник Чураев сөйләгәннәрне тагы бер тыңлап чыкты. Әйе, тәҗрибәле шымчы ике үлем арасындагы охшашлыкны дөрес чамалаган, ике үтерү арасында байтак еллар ятса да, уйланыр нәрсәләр күп иде.

Эш көне тәмамланып килгәндә генә Камалов, кинәт исенә төшереп, архивка шылтыратты һәм күп еллар элек республика прокуратурасында булган хәлләр турындагы документларны иртәгәге утырышка әзерләргә кушты.

Гадәттә киңәшмәләр уздырыла торган киң вә иркен кабинетында озаклап йөргәндә, көтмәгәндә, башында яңа фараз туды. Шиксез, бүгенге акциягә прокуратура эшләрен белгән, хәтта яшерен утырышлар турында мәгълүматы булган кеше кулын салган. Эзләнү бүлегенә кергәндә дә җинаятьче сейфның кайдалыгын алдан белгән, прокурор Азлархановның “дипломат”ы сакланган урыннан хәбәрдар булган, юкса аларны эзләп йөрергә вакыты да, мөмкинлеге дә булмаган, әмма ялгышмаган. Димәк, шушы бинада эшләүчеләрдән кемдер юл күрсәткән. Моннан инде ике үтерү артында да бер үк кеше ятмый микән дигән фикергә дә ерак калмый иде. Прокуратурадан чыгып киткәндә Камаловның башында шундый уйлар оешып өлгергән һәм алар ныгыганнан ныгый гына бара иде.

Икенче көнне прокуратурага ясалган һөҗүм турындагы эш папкалары аның өстәлендә ята иде инде, ләкин ул аларны ул көнне дә, иртәгәсен дә карый алмады. Көндәлек эшләр бер минут та тынгылык бирми, ләкин, шуңа карамастан, Кощей кушаматлы Ростов уголовнигы белән Айдынның үлеме бер үк кеше, яисә бер үк төркем кулыннан түгел микән дигән уйны да чыгарып ташлый алмый иде.

Атна ахырында гына аңа бу кәгазьләрне карап чыгу мөмкинлеге туды, тикшерүчеләрнең нилектән комга утырып калулары да аңлашылды, башкача булуы да көлке, чөнки кемдер зур осталык белән юлларны Ростовка таба борып куйган. Ул Ростов бандалары эшен дә актарып чыкты, читтән килгән рэкетирларның юллары прокурор Азлархановныкы белән беркайчан да

кисешмәгән, аларны компромат тутырылган кейс кызыксындыруы да шикле иде. Ни пычагыма ул аларга? Ростов бандасына акча, алтын кирәк булган. Ул акча һәм алтын дигәннәрен алар газаплап-талап колхоз рәисләреннән, мамык заводы, ит комбинаты директорларыннан каерган һәм һәрвакыт аларга юл күрсәтүчеләрнен каты кулы сизелеп тора иде. Кощейне һәм милиционерны үтерүчеләрне Ташкентның үзеннән эзләргә кирәк. Прокуратураны талаучы үтерүченең чын җинаятьчеләр дөньясы вәкиле түгеллеге чамалана иде. Вазифа бүлешү, сәяси даирәләр мәнфәгатьләре уйнамыймы? Ләкин нинди максатлар? Менә монысын инде төгәл ачыкларга кирәк, чөнки җитмеш ел буе халык аңына үтерү яисә башка җинаятьләр сәяси максатларда булмый, ул бары уголовниклар гамәле дигәнне сеңдерә килделәр. Җинаятьчене табу гына да җитми, әнә шул фикерне халык аңыннан гына түгел, үзебезнең юрист туганнар аңыннан да алып ташларга кирәк иде.

Иске эш буенча яңа тикшеренүләр, эзләнүләр башлап җибәрүне кирәк тапмады, чөнки моның белән кемнәрнедер куркуга салырга мөмкин иде. Айдын эше белән ныграк, җитдирәк шөгыльләнергә кирәк булыр, ул уңышлы барып чыкса, мөгаен, бер үк җинаятьчеләргә юлыгырмын, дип фикер йөртте Камалов.

Полковник Чураев сөйләгәннәрне ул диктофоннан көн саен тыңлый башлады, иске җинаятьтә бүгенге вакыйгаларга да ачкыч ята дигән фикер эчке бер сиземләүдә туа һәм бер генә минутка да тынгы бирми иде. Көннәрдән бер көнне аның башына үтерелгән милиционерның хатыны белән очрашырга кирәк дигән ахмаграк уй да килде. Бәлки ул үткән хәлләргә берәр ачыклык кертер? Иренең үлемендә берәр нәрсәдән шикләнмәгәнме? Фикер әллә нинди баш китәрлек түгел, студент елларындагыча бәяләсән, "өчлелек" кенә иде, ләкин атна буе ул аның башыннан чыкмады, һәм, артык уйланып тормыйча, Камалов тол калган хатын янына китеп барды.

Тормыш тарафыннан ватылган, картаеп баручы, шапшаграк кыяфәтле хатын аны яратмыйча каршы алды. Аның шешә бөкесен еш ачарга ратканы да йөзенә чыккан иде. Хәер, дусларча һәм җылы каршылауга өмет юк, чөнки бу еллар эчендә прокуратурадан килеп аның хәлен белешүче булмаганлыгы мәгълүм иде, юкса, ире ун еллап прокуратурада вахтада торган, ничек кенә әйтсәң дә, сугышчан постында һәлак булган кеше. Нишлисең, үзен бөек санаучы илебездә исәннәрне дә, үлгәннәрне хөрмәт итә белмиләр шул.

Җыештырылмаган, пычрак бүлмә, өстәлдә бушаган портвейн шешәсе кукраеп утыра. Карчыкның баш төзәтәсе килгәнлеге йөзенә чыккан иде. Аны бу минутларда шуннан гайре берни дә кызыксындырмый иде булса кирәк. Прокурор Камаловның озаклап баш ватып, әзерләп килгән сорауларына карчык "белмим, хәтерләмим, күптән булган хәл бит инде" кебек бер каптырмалы җаваплар бирүдән уза алмады. Камалов башына килгән шушы мәнсез очрашу идеясен сүгә-сүгә чыгып китәргә җыенганда гына аркасына букча аскан мәктәп баласы килеп керде.

—Сухроб, балакаем!—дип пышылдады карчык һәм малай каршына ташланды.

Әбинең кыланмышына караганда, малайның күптән килгәне булмагандыр кебек тоела иде. Ул оныгын кочаклап, аркасыннан букчасын салдырды, үзе шул арада өстәл яныннан узганда, бик җитез хәрәкәт белән буш шешәне яшереп өлгерде, күз алдында үзгәреп китте, әллә ничек йомшакланды, мамыкланды, яхшыланды, күзләрендә тормышка өмет калыкты.

Саубуллашмыйча гына китәргә җыенган кунак ишеккә якынлашып килгәндә аны карчыкның сүзләре куып җитте һәм ул урынына кадаклап куйгандай басып калды.

—Бер нәрсәне искә төшердем әле, бәлки кирәге чыгар. Больницага алып килгәндә ирем бик хәлсез булса да, һушында иде әле, күз алдында җан биреп азаплана иде. Мине күргәч көч-хәл белән "Сухроб, Сухроб...", дип пышылдап өлгерде. Безнең оныгыбызның исеме шундый. Бабасы аны бик ярата иде, аның өчен үлепләр китәргә әзер иде. Мин аны соңгы тапкыр

онығын күрәсе килә, хушлашырга тели дип аңладым. Тиз генә машина бирделәр, оныкны алып килдек, ә ул күзләрен аннан читкә төбәп һаман үзенекен кабатлый бирде: "Сухроб, Сухроб..." Без аны саташа башлады дип уйладык, ярты сәгатьтән мәрхүмкәем газапларыннан котылды.

Карчыкны артык тыңлап торудан мәгънә күренми иде инде, прокурор аңа рәхмәт әйтте һәм бүлмәдә үзенең артык кеше икәнен сизеп, җиңел сулап, чыгып та китте. Юл буе "Күпме вакытны әрәм иттем..." дип үкенеп, үз-үзен тиргәп кайтты. Шуның өстенә, гомерендә беренче тапкыр күргән бу карчыкның язмышына, фәкыйрьлегенә, тормышта җайлаша алмавына үзен гаепле санап газапланды.

Лифтка утырмыйча, гадәттәгечә, җәяүләп кенә дүртенче катка күтәрелеп килгәндә, ул теге букча аскан сөйкемле, бик акыллы тоелган малайны исенә төшерде, исеме дә үзенә бик килешеп тора иде. "Сухроб" дип ул аны эчтән генә берничә мәртәбә кабатлады. Бүлмә ишеген ачып маташканда гына миен яшен ташыдай кистереп бер уй узды һәм ул алгы яктагы беркемне дә күрмичә, кабинетына ташланды һәм телефонга ябышты.

Полковник Чураевның номерын җыюга, галстук төенен бушатып җибәрде, аңа һава җитми кебек иде. Исәнләшергә дә онытып, ул турыдан-туры маңгайга бәргәндәй итеп сорады:

—Зинһар, әйтегез әле, ул көнне сез прокуратурада Сухроб Әхмәдович Әкрәмхуҗаевны күрмәдегезме?

Полковник Чураев, аның шундый юк-барга дулкынлануын аңлый алмыйча, берни дә булмагандай, тыныч җавап бирде:

—Әйе, ул көнне мин бик яхшы хәтерлим,—диде.—Ташкент районнарының берсендә, сүз уңаеннан, иң артта сөйрәлүче районда прокурор булып эшли иде ул. Икенче каттагы колонна янында басып торганын күреп калдым, йөзе ап-ак булган, бик кәефсез күренә иде. Әмирхан Даутович белән электән таныш булгандыр, шуңа күрә күз алдында булган бу канлы фаҗига, аның һәлакәте авыр тәэсир иткәндер дип уйлап куйганымны да хәтерлим әле.

—Әйтегез әле, ул "дипломат"ны кайда куйганнарын күрә алды микән?

—Күрде, әлбәттә. Мин кейсны тикшерү бүлеге башлыгына яшермичә, ачыктан-ачык бирдем бит. Аның кабинеты икенче катта, "дипломат"ны тотып ул Әкрәмхуҗаев яныннан үтеп китте. Ә тегесе колонна янында бик озак кына басып торды әле, аның югалып калган йөз-кыяфәте бүгенгедәй хәтеремдә.

—Менә монысы кызык!..—дип куйды прокурор һәм сүзне шуның белән туктатты да, чөнки дулкынланудан тыны кысылды. Беренче тапкыр ул Сенаторга карата читләтеп булса да шик ташларлык, гаепләрлек дәлилгә юлыкты һәм сизенүенең дөрес юлга алып чыгачагына ышана башлады. Моңа кадәр әчке сизенүендә аның беркайчан да ялгышканы юк иде әле.

Бишенче кисәк

Атып алырга рөхсәт

Соңгы вакытта Шубарин әллә нинди сәер халәт кичерә иде. Төгәл, пөхтә, нык ихтыярлы, теләсә кайчан көрәшкә ташланырга әзер кеше кинәт кенә күңел тынычлыгын югалтты. Хәер, аны башкалар сизә дә алмас иде, әмма моны хәләл җефете һәм Ашот үлгәннән соң тән сакчысына әйләнгән Костадан яшерә алмады. Соңгысы белән аралары тагын да якынаеп киткән иде.

Гадәти, нормаль җәмгыятькә сыеша алмаган Коста акча һәм эш мәсьәләсендә шаккатырлык дәрәҗәдә төгәл, хәтта вакчыллыка саналырдай тугрылык күрсәтә иде, ана теләсә нинди күләмдәге акчаны, теләсә кайсы финанс серенне югалтудан бер кәррә дә шикләнмичә тапшырырга була. Тугрылык

һәм принципиальлек аның төп байлыгы, төп таянычы. Ул шуның белән яши, тормышының төп кануны шунда иде. Ашот үлгәннән соң Шубарин аны шуңа күрә үзенең ышанычлысы итте дә инде.

Шәхси эшкуарлыкка юл ачылгач, Шубарин мәнфәгатьләренең төп өлеше Лас-Вегастан Ташкентка күчте. Ул киткәч, бары тик аның тырышлыгы, җанатар дәрәҗәдәге эшкә бирелгәнлеге аркасында гына аякта торган андагы җирле сәнәгать оешмалары күзгә күренеп сырхый башладылар.

Кайчандыр ул үзе уйлап чыгарган һәм акыллы икътисадчылар тарафыннан чарланган "айсберг" системасын, моңа кадәр шактый мул алынган керемне кооперативлар китергән акылга сыймаслык мөмкинлекләр, аннан алынган бай табыш белән чагыштырырлык та түгел иде.

Коста шефының күңел төшенкелеген сизми калмады, чөнки хуҗа кеше ана әле моннан ярты ел элек кенә күз алдына да китерә алмаган иң мөһим эшләрне дә тапшыра башлады. Хәзер Коста тәгәрмәчтәге тиен кебек бөтереләә, хәер, шеф үзе дә сауналарда кәеф-сафа чигеп ятмый, спорт мәйданчыкларында җилләнеп йөрми, ләкин эш белән кызыксыну күзгә күренеп кими бара иде. Дөрес, хәзергә аны компьютер коткарып килә, кооператив, шәхси һәм аренда предприятиеләренең бар челтәре акыллы машина хәтеренә кертелгән, бер кнопкага басуга кирәкле мәгълүмат күз алдында була. Табигый, мондый техника белән вакыт-вакыт үзенә ял биреп, тынычланып алырга да булыр иде.

Үзенең шәхси рестораны булса да, Лас-Вегастагыча бай сый-нигъмәтле мәҗлесләр дә бетеп бара. Коста хуҗасының хәзерге кулдашлары белән мөгамәләдә элеккечә якынлык тоймаганын да абайлый. Әллә Ашотның үлеме, әллә шәһәрдәге чик-чаманы белмәгән җинаятьчелекнең котырынуы куркытты микән дип тә уйлап куя иде.

Лютый бандасын тар-мар иткәч, алар куркынычсызлык чараларын яңабаштан карап чыктылар, аны оештыруга Карен күпме акча сораса, шуның кадәр бирделәр, хәзер аның кул астында башкаланың иң көчле сугыш осталары. Костага хәтта алар өчен "Лидо" подвалында ике спорт залы да ясатырга туры килде, анда көнен дә, төнен дә күнегүләр үткәрергә, осталыгынны чарларга була.

Артур Александрович үзе пистолет тыгып йөрергә яратмый, Карен тенкәсенә тиеп беткәч кенә машинасын корал белән тутырдылар, "Волга"ны үзгәрттеләр. Үзәк Комитет гаражыннан элек Рәшидов йөргән машинаның пуля үткәрми торган пыялаларын кулга төшерделәр, заводларның берсендә ишекне броня белән эшләп бирделәр. Хәер, Шубарин үзе бу турыда кәррә дә кызыксынмады. Ул куркуны белми иде, аның үз-үзен тотышында Коста аңлый алмаган нәрсәләр бар иде.

Соңгы вакытларда Шубарин еш кына сарык тиресеннән тун тегү белән мәш килүче Яков Наумович Гольдберг йортына кереп югала. Тиречe-күнчеләнең Ташкентта иң бай шәхси китапханә хуҗасы икәнлеге дә мәгълүм. Узган ел Шубарин шуларның туганнары чакыруы буенча Америкага барып кайтты, Яков Наумович үзе дә гариза язган һәм Кушма Штатларга китәргә җыенып ята. Бәлки шеф үзе дә океан артына ычкынырга уйлыйдыр һәм шунлыктан эшләргә суынгандыр? Бервакыт икәүдән икәү генә чәйханәдә төшке аш ашап утырганда, Коста турыдан-туры шул хакта сорады. Хуҗа сорауга үпкәләмәде һәм ана, сабыйга аңлаткандай итеп, җавап бирде:

—Әйе, бүген теләсә кая чыгып китәргә була, соңгы унбиш елда минем белән бергә эшләгән кемнәр генә читтә түгел хәзер. Бельгия, Дания, Голландия, Көнбатыш Германия, Италия, Франция, Израиль һәм, табигый ки, АКШ. Сиздер генә, һәркайдан миңа чакыру җибәрә алалар. Бу илләрнең күбесендә минем булганым бар, тормыш рәвешләрен беләм, андагы эшкуарлыкта билисе урынымны да күз алдына китерәм. Ләкин, кадерле Коста, аңлатып булмый торган нәрсәләр бар, шулардан берсе—рус җаны, рус кешесенә байлыктан, җәмгыятьтәге урыннан, комфорттан башка нииндидер гайре нәрсәләр кирәк. Шуңа күрә, бернинди Америкалар турында сүз булырга мөмкин түгел. Югыйсә, андагы дусларым,—ә алар миңа күп

яктан бурычлылар,—минем белән бергә эшләү проекты төзегәннәр, предприятие ачмакчылар. Алар ярдәме белән капиталымны бернинди югалтусыз Көнбатышка күчерә алам, ул җиргә аяк басуга ук кулымда дистәләрчә миллион акчам булачак, андый байлык белән анда да әллә ниләр майтарып була. Ләкин моның өчен туган илемнең күпме акча-байлыгын урларга кирәк булыр иде. Аны шулай итәләр дә. Балтыйк дингезендәге һәм Ерак Көнчыгыштагы портлар аша икенчел чимал, неликвид, металл ватыгы, дип, күпме байлык читкә озатыла. Минем дә ул портларда үз кешеләрем бар, чит илләргә әллә никадәр стратегик материаллар, чимал алып чыгып китә алыр идем. Әлбәттә, ришвәткә миллионнар туздырырга туры килер иде. Ләкин бу юл минеке түгел. Көнбатыш белән багланышларымны мин икенче төрле итеп күз алдына китерәм. Мин заманча хуҗалык итү мөнәсәбәтләрен, мәсәлән, банк эшенең куелышын өйрәнергә тиеш. Кайсы илнең системасы безгә якынрак икәнлеген карап-күзәтеп киләм инде мин, чөнки һәр илдә үз финанс системасы, үз нечкәлекләре. Ниһаять, мин күз аткан илнең халкы Россиягә ничек карый, безне ниләр бәйли, әйе, алардагы бик шәп куелган банк системасы гына кызыксындырып калмый мине. Баштан ук әйтим, бу исемлектән Америка төшеп кала, өйрәнер нәрсә юклыктан түгел, ә алар белән уртак тамырларыбыз булмаганлыктан. Европа бөтенләй башка, тарихыбыз уртак, хәтта кан кардәшлеге бар, ул безгә вә бәдәни, вә мәдәни яктан АКШларыннан күпкә якын. Бәлки, син без үзебез дә закон белән бик үк дус түгел бит, диярсең, ләкин без, Коста, дәүләтне какшатмыйбыз, чимал байлыкларын, башка кыйммәтләрне чит илгә олактырып ятмыйбыз. Безнең төп аермабыз менә шунда.

Шубарин, күрәсең, үзгәртеп коруга зур өметләр баглаган, аңа сүзсез ышанган кешеләрдән булгандыр, хәзер исә тирә-якта хөкем сөргән болгавырлык, анархия, икътисадның элеккегә караганда да ныграк җимерелүе аны төшенкелеккә этәрә иде булса кирәк.

Ә ил чын-чынлап җинаятьчелек патшалыгы! Бу хәтта Япон кебек булдыклы, гаярь кешене дә куркуга салды. Мәскәүнең үзендә җинаятьчелекнең иң хәтәр формалары чәчәк ата, анда аңа каршы торыр көчләр, мөмкинлекләр, ысуллар юкмы? Хөкүмәт, закон әһелләре башкалада яши, алар берни күрмиме, әллә күрергә теләмиләрме? Кремль стеналары янында ук диярлек җинаять кылына, ә җавап бирәсе кешеләр: "Әнә Нью-Йоркта, Чикагода Мәскәүгә караганда яшәү куркынычрак",—дип кенә котыла, ләкин бу сүзләрдән генә халыкка җиңелрәк булырмы соң?

Шубаринның икеләнүе, күңел төшенкелеге Костаны тәмам пошаманга төшергән иде инде һәм ул шефына бер-ике айга каядыр китеп ял итәргә, онытылырга тәкъдим ясады, тегесе монсу гына җавап бирде:

—Үзеңнән беркая да кача алмыйсың, качсаң да фикерләреңнән, фикерләүдән котыла аласыңмы? Аннан соң... Кая барырга? Бөтен ил бизгәк тоткандай калтырана, теләсә кайда кан коела. Кайда милләтара җирлектә, кайда җинаятьчел җирлектә.

Ул үз җанын кыярга махсус килгән Ростов бандасын хәтерли иде әле, кулларында өенең төгәл планы бар иде, алар хәтта аның үзен һәм гаиләсен нинди җәзалар көткәнен дә яшереп тормадылар. Исән калыйм һәм яшим дисәң, бер генә чара бар—дошманнан көчлерәк булырга кирәк. Кайчандыр үзенең "боз тавын" төзү өчен ул икътисадны, хокук белемен, банк эшен генә өйрәнеп калмады, көч куллану серләрен дә үзләштерергә туры килде, һәм монда ул барысын да узып китте, аны хәтта Ростов бандасы да "тешли" алмады. Хәлбуки, тормыш хыялы ул түгел, власть дип котырганы булмады, бар теләгәне, ашкынганы—хуҗалык итү талантына юл ачу иде.

Ростов бандасын үзлегеннән хөкем иткән, ягъни самосуд ясаган өчен аны гаепләүчеләр дә табылыр, ләкин егерме бер кешенең җанын кыйган биш кешелек, ерткычтан да зәһәррәк бу зәнкиләр төркемен башкача хөкем итеп тә булмас иде. Аның янына килер алдыннан гына да алар тагын өч кешенең башына җиткән иде. Соңыннан ул аларның аерым-аерым һәркайсыннан бандаының канлы юлы турында сөйләтте, җанының боз итәрдәй

сүзләрен видеомагнитофонга яздырып барды.

Көчләүне тәрбия белән, үгетләү юлы белән җиңеп була дип, аны беркем дә ышандыра алмас иде, бандит бары тик көчне генә таный, көчтән генә курка. Варлам Шаламовның "Җинаятьчелек турында очерклар"ын укыгач сөенеченнән башы күккә тия язган иде. Менә кайда ул илнең бар юридик вузларында өйрәнелергә тиешле документ! Артур Александровичның җинаятьчелеккә, аның идеологиясенә карашлары танылган әдипнең уй-фикерләренә тулысынча тәңгәл килә иде.

Егерме биш елын уголовниклар арасында уздырган Шаламов аларның җан хасиятен, рухи тайпылышларын кабинетта җинаятьчел дөнья файдасына закон чыгарып утыручыларга караганда уннарча мәртәбә яхшырак белгәндер шул.

Кайчандыр эшеннән куылган, Лас-Вегаста ул үзе сыендырган Әмирхан Даутович һәм аның якыннары Лариса Павловнаны үтергән прокурор Әнвәр Бекхуҗаевның үлемендә Шубарин кулы уйнады дип ышаналар иде. Әйе, ул да мәгълүм бер өлеш кертте кертүен, ләкин бу кара йөрәкле Бекхуҗаевны күптән инде башкалар, сүзләрен тота белүче житди кешеләр үлемгә хөкем итеп куйган иде. Бөтен нәрсә вакыт галиҗәнапләренә генә терәлеп калды, бер атна алданракмы, әллә соңракмы, хикмәт анда түгел, ул бары тик Әнвәр Бекхуҗаев кылган җинаять өчен төрмәдә утырып чыккан кешегә нәрсәдер эшләргә мөмкинлек кенә бирде. Ул бары үтерүче-прокурорның үлемен Лариса Павловнаның трагик вафаты көненә генә туры китерде, Бекхуҗаевлар мондый тәңгәллекнең мәгънәсен, ни аңлатканын төшенми калмадылар, әлбәттә.

Бер генә кабәхәтлек тә җәзасыз калырга тиеш түгел. Бусы да Шубаринның тормыш кагыйдәләреннән. Гаделлекне көч белән генә урнаштырып булганлыгын ул аңлый иде, чекрәеп күзгә кергән җиңүләр аңа эчке канәгатьлек хисе китерми, әмма ул прагматик буларак, көчнең реаль чагылышын бәяли белә иде. Прокурор Бекхуҗаевның үлеме ул бәндәләрнең кылган бар гаделсезлекләрен исләренә төшерергә тиеш иде. Кайчандыр алар аның җентекләп оештырылган бер эшен тартып алдылар һәм алтын күкәй салучы шул "тавык"тан озак еллар буе файдаланып килделәр. Юк, ул югалган акчаларын җәлләмәде, әмма үзен түбәнсетүне, гаделсезлекне күтәрә алмады, вакыты җиткәч аларга исәп-хисап ясар көн килгәнлеген күрсәтте. Кайчандыр Бекхуҗаевларның компаньоны булган Коста аларга иске вексельләрне илтеп бирде һәм яңа хуҗасы Шубарин исеменнән ультиматум белдерде: әгәр акчалар билгеләнгән вакытка кайтарылмаса, аңа мәетләр көтегез!

Узган еллар эчендә алынырга тиешле сумма 1 700 000 сум дип бәяләнгән иде һәм ул аны кайтарып алды да. Бекхуҗаевлар таләп ителгән сумманы Коста аша тапшырдылар. Чөнки теләсә кайсы җинаятьче кебек, алар көчкә генә буйсыналар иде. Юк, Шубарин акчага шатланмады, аңа лыкынып туя белмәгән нәселне үз урынына утырту гына кирәк иде.

Ул һәрвакытта үзен иректә кеше санады, ә яңа икътисади сәясәт моңа яшел урам ачты—тырыш, байлыгыңны арттыр, чит ил базарларына чык, ләкин салымнарны гына вакытында түлә.

Шуна карамастан, кооперациянең беренче елларда ук фантастик табышлар бирүе аны шатландырмады, киресенчә, шикләндерә төште, чөнки ул икътисад кануннарын әйбәт белә иде. Дәүләт кибетләрендә киштәләрнең бушап калуыннан файдаланып, кооперативлар бәяләрне шундый күтәрделәр ки, алар янына тишек кесә белән якын килерлек түгел иде. Һәм халык үз җавабын бирде, Ашхабадта, Яңа Үзәндә, Гурьевта, Рәсәйнең төрле шәһәрләрендә кибетләрне туздырып ташладылар. Ләкин бу фаҗигане беркем дә җитди кисәтү итеп кабул итмәде, Шубарин республикадагы кооператив хәрәкәтен юлга салырга тырышып карады каравын, ләкин аңа беркем дә колак салмады, барысы да бер көн белән яшиләр иде—бүген умыр, ә иртәгә өчен ишәк кайгырган.

Кооперативларга азмы-күпме мөнәсәбәте булганнар яхшы белә иде инде, алар беренче көннәреннән үк уголовникларның каты кулы астына эләктеләр.

Ике йөз илле сумлык итекләр, йөз тәңкәлек чүпрәк чалбарлар тегү үтә табышлы булса да, җинаятьчел дөнья моның белән генә канәгатьләнеп калмаячак, күбрәк акча табуның яңа юлларын эзләячәк иде. Җинаятьчел дөнья идеологлары, аның стратеглары, аларның акыл казаны дәүләт аппараты хезмәткәрләреннән берничә мәртәбә көчлерәк, остарак, хәйләкәррәк. Шубарин беренчеләрен дә, икенчеләрен дә яхшы белә, табигый ки, алар бернәрсә җитештермичә генә әвеш-тәвеш китереп, дәүләт предприятиеләреннән "безналичка" юлы белән кирәген "сатып алып", соныннан аларны тере акчага әйләндерү юлына басачаклар иде. Болай да инде илне бәясе төшкән акча ташкыны басып киткән. Ә сатлык икътисадчылар, журналистлар газетларга акча күплегенә эшчеләр, хезмәткәрләр гаепле, чөнки аларга хезмәт хакын артык нык күтәргәннәр дип яза бирделәр. Гомере буе финанслар белән эш иткән Шубарин һич күз алдына китерә алмады: ничек инде, бернәрсә җитештермичә илне шулай таларга мөмкин, бу бит, белә торып, аны финанс һәлакәтенә, тулы банкротлыкка илтү дигән сүз.

Мәҗлес саен "Безнең заман килде, егетләр, безнең заман..." дип тост күтәрергә яраткан Бармаксыз хаклы булып чыга түгелме соң.

Элек күп кенә гражданнар кебек, Шубарин да үзен власть һәм милектән аерылган итеп карый иде, үзендә дәүләткә карата якынлык хисе тоя алмады, әлбәттә, моның белән үзен оригиналь санамый, чөнки бу хис инде миллионнарга кереп оялаган. Ләкин Мәскәү коллегалары һәм казнадан умыра белүче түрәләр төзегән документ-килешүләрнең ике якка да чит ил банкларында йөзәр меңләп доллар китерүен күреп, ул ватанга икенче күз белән карый башлады. Менә шушы ил өчен бер дә куанычлы булмаган көннәрдә анда әллә нинди үзгәреш, көтмәгән борылыш булды да инде, яңа эшкуарларның илне, шул исәптән, аның үзен ерткычларча талаганын аңлап алды ул.

Дәүләтнең финанс системасын җимерү мисаллары шулкадәрле дә күп иде ки, берзаман ул аларны билгеле бер системага кертеп язып бара башлады.

Бөтен халык белән бергә ул да халык депутатларының Беренче съездын кызыксынып күзәтте, анда барган кайнар фикер көрәшенә, сүз алышуларга караганда уңай үзгәрешләр көттермәскә тиеш иде. Шул язмаларын депутатлардан берәрсенә бирергә түгел микән дип тә уйлап куйды, чөнки кая гына карама, барысы да икътисадка, инфляциягә, акча эзләүгә барып төртелә. Пенсионерларга, инвалидларга, яралы-гарип әфганчыларга, Чернобыль һәм җир тетрәү корбаннарына, җимерелгән шахталарда һәм газүткәргечләрдә зыян күрүчеләргә, качакларга, ятим балаларга—барысына да акча кирәк. Ә монда миллионнар чит ил банкларына оча, болай да авыр хәлдә бу коточкыч түгелме?!

Ул депутатларны берәм-берәм иләктән уздырырга тотынды, чыгышларына игътибар белән колак салды, үзенең тикшеренүләрен тапшырырдай, финанс дөньясындагы башбаштаклык хакындагы фикерләре белән уртаклашырдай кеше эзли башлады. Ләкин озакламый бу фикер дә үзеннән-үзе төшеп калды. Чөнки газетларда һәм депутатлар корпусында кооператорларның баш әйләндергеч уңышлары турында шапырыну өчен күпләп акча җыярга керештеләр.

Ләкин үзен борчыган уйларны кем беләндер уртаклашу теләгенә кинәт кенә юл ачылды да куйды. Ачил Садыйковичның бакчасында үз-үзен атып үтерүен ишеткәч, Шубарин тагы бер мәртәбә Камалов кулының катылыгын тойды, закон һәм гаделлек хакына берни алдында да туктап калмаячак бу. Менә ул минем депутатым, бу кеше мин әйткәннәргә битараф калмаячак, дип шатлыклы сискәнү кичерде ул.

Ачыктан-ачык талау белән шөгыльләнүче аферистларның туктаусыз үрчүен ил икътисады күтәрер хәлдә түгел иде инде. Монысын да Шубарин яхшы аңлый.

Аны, каты куллы дәүләт заманында күтәрелгән эшкуарны, наворишларның һавадан акча ясаулары чын мәгънәсендә ярсыта, рәнҗетә иде. Ул аларга "математиклар" дигән исем такты, акчаны алар катлаулы кәгазь

операцияләре аша ясыйлар, ләкин бер генә грамм да матди байлык эшләп чыгармыйлар. Элек акчаны ничек "сугалар" иде? Учетта булмаган, хисапка кермәгән продукция: мебель, келәмнәр, кием-салым, шәраб, коньяк—хәтта ювелир эшләнмәләр ясап. Шубарин карашынча, "математиклар" илгә дә, аның үзенә дә коточкыч куркыныч белән яныйлар һәм ул аларны һич тә кызганмыйча гадел хөкем кулына тапшырырга булды.

Башта ул, бернинди аңлатма-фәлән язып тормыйча гына, кәгазьләрдән бүрткән ике папка дәфтәр җибәрмәкче булган иде. Прокурор нәрсәнең нигә икәнен аңлар иде әле. Ләкин соңыннан аларга аз гына булса да кереш сүз язарга кирәк дигән фикергә килде һәм болай дип башлап җибәрде:

"Хөрмәтле Хөршид Азизович!

Прокуратурага җибәрелгән һәм шәхсән Сезгә адресланган бу язма башта сәер һәм гайре табигый булып тоелыр. Гаҗәпләнмәгез, җәмгыятьтә хәзер гадәти булмаган, аңлашылмаган нәрсәләр күп, аерым кешеләрнең, мәнфәгатьләрнең кояш астында үз урынын табарга маташуыннан килә ул. Кулыгызга килеп кергән мәгълүматлар белән танышкач, икътисади диверсантлар өерендә безнең кеше бар икән, дигән фикер туарга да мөмкин. Ялгышмагыз, мин сезнең кеше түгел. Мин хәбәр иткәннәрне анализлагач, аңларсыз, эшкуарларда да (аларны безнең законнар алдаларга, хәйләләргә өйрәтте) мәгълүм бер дәрәҗәдә әхлак кагыйдәләре дигән нәрсә бар, аларны санга сукмый башласаң, үзеңне юньле кеше булудан туктадым дип саный аласың. Тарихта шәхси һәм дәүләти омтылышларның тәңгәллегендә аеруча мөһим чорлар була, бүген шундый вакыт җиткәндер дип уйлыйм, ватанга куркыныч яный. Мин үз даирәмнең омтылыш-кызыксынуларын аңлы рәвештә Сезгә тапшырам, чөнки илне финанс һәлакәтенә илтүче юлны ябарга кирәк. Тагы... Хат прокуратурага түгел, ә Сезгә. Әгәр дә мин Сезнең шәхси сыйфатларыгызны белмәсәм, бу серләрем белән уртаклашмас та идем, чөнки монда язылган һәр юлның бәясе яшәү, тормыш бәясе ул. Зур уенда үзеңнекеләрне дә, читләрне дә аямыйлар. Ә инде хаинлек, мәнфәгатьләрне сату аеруча кырыс җәзалана. Республикада Сез башлап җибәргән көрәш юлларында, бәлки, кайчан да булса, безнең сукмаклар кисешер, менә шунда тулырак гәпләшергә мөмкинлек туар, ә хәзер вакыт ашыктыра".

Алга таба Шубарин конкрет фактларга күчте һәм беренче юлларыннан ук аяктан егарлык мәгълүматлар китерә башлады. Шулардан берсе, республика Төзелеш банкының кредитлар һәм ссудалар бүлеге башлыгының ялган документлар белән беркайчан да тормышка ашмаячак "өметле" проектларга коточкыч зур суммаларда кредитлар бирүе хакында булды. Акча кулга эләгү белән үк, Үзбәкстанны яңартабыз дип шапырынып йөргән эшкуарлар шул ук көнне качып китеп тә бардылар.

Япон башка банкларның эшен дә игътибардан читтә калдырмады, алары да, бирелгән суммадан үзләренә дә майлы калҗа эләктерү хисабына, дәүләт сәнәгать оешмаларының акчасын кооператорлар кесәсенә күчерүгә күз йомалар.

Шубарин бернәрсә дә житештермичә генә, предприятиеләрдәге "безналичка"ны, ике якка да төшемле итеп, җанлы акчага әйләндереп баеп ятучы ялган кооператорларның тулы исемлеген дә китерде.

Предприятиеләрдә оештырылган кооперативларны да искә алды, болары дәүләткә бигрәк тә зур зыян сала, чөнки төп житештерүгә кайтарып булгысыз зыян килә.

Ул банкларның акчасөяр инспекторларын да җәлләп тормады, бу комсызлар, ришвәт бирсәң, теләсә кайсы финанс тәртибен бозуларга күз йомарга риза, шуның өстенә банк контролен җайлырак әйләнеп узу өчен киңәш тә бирергә онытмаслар.

Төрле предприятиеләр белән килешү нигезендә алар өчен нәрсәдер башкарып чәчәк атучы кооперативлар да читтә калмады. Болары эш күләмен дистәләрчә арттырып язу исәбенә байый, заказ бирүчеләр исә артык түләнгән суммадан үз өлешен кесәсенә сала бара.

Финанс диверсиясе масштаблары шундый дәрәҗәгә житте ки, алар илнең куркынычсызлыгына турыдан-туры яныйлар, бу яктан аларга дәүләт һәм оборона серләрен саклау белән бертигез итеп карарга кирәк. Ул шулай ук кадрларны, бигрәк тә Союз дәрәҗәсендә, карап, тикшереп чыгарга тәкъдим итте. Илнең эчке базарын тәэмин итү, чит илләр белән сәүдә, банк эше, валюта алмаштыруда эшләүчеләр чиста куллы, саф күңелле ме? Мәскәүдәге оешмалар һәм банклардан мисаллар китерде, аларның башында утыручылар үзләрен артыгы белән иркен сизәләр түгелме?

Хатны ул чит илләргә юл сапкан уртак предприятиеләр һәм кооперативлар эшчәнлегеннән баш әйләндергеч дәлилләр белән тәгәлләде. Хатның авторын исәпләп чыгару мөмкинлеген бетерү өчен, табигый ки, үзенә дә Көнбатыш партнерлары белән шундый оешмалар төзү хакында Мәскәүдән уннарча тәкъдим булуын язып тормады. Прокурор Камаловка ул бары тик отыш бирерлек уен кәртләрен генә күрсәтте.

Ул Балтыйк дингезендәге һәм Ерак Көнчыгыштагы портларны да күрсәтте, шулар аша житештерү калдыклары һәм металл ватыгы дигән булып, торба, прокат, сыйфатлы корыч, төсле металл җибәреп ятканлыкларын ачты. Мәскәү эшкуарлары безгә бу портларда "яшел урам" ачылган дип мактанырга ярата.

Аноним автор прокурор Камалов игътибарын Алмалыктагы кургаш-цинк комбинатына, бакыр фабрикасына, Чирчиктагы кызуга чыдам һәм авыр эретелә торган металл житештерү заводына һәм аеруча таҗик алюминиенә юнәлтте, чөнки алар белән Мәскәү, Кавказ, Балтыйк буе һәм чит илләрнең эшкуарлары артык кызыксына башладылар. Соңгы вакытта әфган чигенең якынлыгы, төбәктәге тотрыксызлык аркасында уранга юл эзләүчеләр дә күренә башлады.

Предприятиеләрнең, бигрәк тә дәүләтнекеләрнең чит ил базарына чыгуы иң югары кимәлдә юридик саклау белән тәэмин ителергә тиешлеген дә кисәтеп куюны кирәк тапты Шубарин. Чөнки совет базарын үзләштерергә нигездә авантюристлар ташланды. Көнбатышта көн саен диярлек купшы исемле, буш кесәле фирмалар туып кына тора, аларның күбесендә исә элеккеге Рәсәй кешеләре өстенлек итә. Бер көнлек фирмалар алдан безнең пошмаслыкка, акрынлыкка, жавапсызлыкка һәм юридик наданлыкка исәп тоталар һәм "вакытында үтәлмәгән" дигән сылтау астында баш житмәслек суммалар каерырлык контрактлар төзиләр. Чит илләр белән сәүдәне үз агымына җибәрсәң, безнең дәүләт валюта эшли алмау гына түгел, соңгы алтын запасыннан да колак кагачак. Көнбатыш үзенекен ычкындырмый ул.

Ахырда ул эшкуарлар тапкан яна "алтын хәзинәсе"—Клондайкның кайда икәнлеген дә ачыктан-ачык күрсәтте, киләчәктә һәр өченче жинаять эше армия складларыннан һәм базаларыннан урлауга бәйле булачаклыгын фаразлавын белдерде. Малтабарлардан аккан мул акча генерал вә адмиралларның әхлакый ныклыгын күптән черетеп чыгарды инде. Бер генә юл бар—армия өстендәге сер пәрдәләрен күтәрергә вакыт.

Пакетны прокурор Камаловка жибәргәч, Шубаринның өстеннән тау төштемени, кәефе күтәрелде һәм ул элеккеге дәрт белән эшкә тотынды. Ике атнадан Артур Александрович үзенең усал хатының тәэсирен сизде, Ташкентта һәм республикада гына түгел, Мәскәүдә дә ялган эшкуарлар, аферистлар сафы күзгә күренеп сирәкләнде. Соңгы вакыттагы кулга алулар Камаловның Мәскәүгә хәбәр биргәнен, эшкә КГБ белгечләре тотынганын аңлата иде, чөнки хатта сүз илгә каршы икътисади диверсия турында иде. Хәтта милиция борылып карарга да курыккан кешеләрне кулга алдылар. Менә шунда гына Шубарин прокурорга тозак салуда Сенаторга да, Миршабка да булышу кирәк түгеллеген аңык төшенде. Ахыр чиктә ирекле һәм хокукый дәүләтне Камалов кебек кешеләр төзи. Әгәр аның тормышына куркыныч янаса, ҮК кешесен дә, Югары судтагысын да властьларга тапшырырга туры килмәгәе. Аноним хат биргән нәтиҗәләр Шубаринны канатландырып жибәрде, илдәге хәлгә үзгәреш кертә алуына ышаныч тудырды.

* * *

Бармаксыз кушаматы йөртүче, теләсә кайсы мәҗлестә "Безнең заман килде, егетләр" дип тост тәкъдим итеп бугаз ертучы Артем Парсегянга үзгәртеп коруларга шатланырга тулы нигез бар иде. Чөнки ул, ниһаять, хәзер хуҗа кеше, аның үз эше бар. Техниканы яхшы белә торган кеше буларак, ул уен автоматларының нинди төшемле эш икәнен бик тиз эләктереп алды.

Балалар уенында күз алдына да китерә алмаслык акча эшләү мөмкинлеге аның башына да килми иде әле. Көннәрдән беркөнне аны, алтын куллы кеше буларак, бик тә кыйммәтле, ләкин юньләп эшләмәгән бер автоматны карарга чакырдылар. Өч сәгатьләп казынды, тир түкте ул анда, әмма автоматны барыбер көйләп җибәрде. Хуҗа кеше эше өчен аңа ике йөз доллар сузгач кына аңлап алды: менә кайда икән ул чын эш, күзгә дә артык ташланмый, ә акчасы елга булып агып керә. Әлбәттә, уен бизнесы хуҗасы булырга теләү генә аз, иң тәүдә акчаң булырга тиеш, икенчедән уен автоматларын табарга кирәк. Италиянекен яисә Германиянекен. Американыкы булса, бигрәк тә шәп, алар ватылуны белми, өлкәннәрнең дә күзен кызыктыра.

Башта ул аларның бәясен сораштырды. Хәтта газлы су автоматларын сатып җибәрсә дә уен автоматлары алырга җитмәячәк иде. Шунда ул Сенатордан ике елдан кире кайтару шарты белән йөз мең акча сорады, хәтта процентлар түләргә дә риза иде, ләкин тегесе кире какты. Әмма ярты еллап вакыт узгач, үзе шылтыратты, сиңа акча һаман кирәкме әле, дип, өенә чакырды һәм, бернинди сүз куертып тормастан, аяк киеменнән бушаган катыргы тартмага салып йөз мең сум акча бирде. Акчаны күз дә йоммый бирүенә караганда, Сенаторның каяндыр миллионнар эләктергәненә шикләнәсе түгел иде.

Акча биргәндә Сенатор процентлар алырга теләмәде, бары бу кадәр сумманың нигә кирәк булы белән генә кызыксынып алды, Бармаксызга үзенең хыялы турында сөйләп бирергә туры килде. Картаеп баручы уголовникның өмет-хыялын аңлап җиткермәгән прокурор башта озаклап, рәхәтләнеп көлде, ләкин соныннан җитдиләнеп китте һәм бина табу, оештыру эшләрендә булышачагын әйтте. Һәм ул күп нәрсәләрдә булышты да, күрәсең, Бармаксыз алга таба кирәк булачак әле, дип уйлый иде булса кирәк.

Бармаксызның үз гомерендә бер генә эшкә дә шулкадәр дәртләнеп тотынганы, бу кадәр көч түккәне юк иде әле, уен бизнесына ул башы-аягы белән чумды. Үзәк Комитет кешесеннән сизелерлек финанс ярдәме алганнан соң ул беренче уен залын ачып җибәрде, ике ай узуга, автовокзалда тагы берне һәм эшләр унай гына агып китте. Дөрес, аңа ниндидер пешмәгән адәм актыклары ясак салмакчы булып карадылар каравын, ләкин Бармаксыз шунда Каренга әйтте. Тегесенең бер ротага җитәрлек ярдәмчеләре бар иде, алар шундый көч-куәт күрсәтте ки, рэкетирлар Парсегян биләмәләрен бер чакрымнан урап уза башладылар.

Бер елдан соң Артур Александрович Мәскәүдә Парсегянны халыкара техник күргәзмәләр оештыручылардан берәү белән таныштырды һәм Бармаксыз әле Ташкентта беркем дә күрмәгән өр-яңа егерме уен автоматы сатып алды, бу хәтле техникага түләү өчен искеләрен Сәмәркандка сатып җибәрергә туры килде. Бохара яһүдиләре белән сату-алу килешүе шул кадәр отышлы булды ки, Мәскәүдә бер тиен чыгарырга туры килмәде.

Яңа уен автоматларын ул таратмады, кеше күп йөри торган җирдә арендага өч заллы бина алды барысын да шунда, катлаулылыкларына карап, өч залга урнаштырды. Беренче елда ук аппаратлар аңа әҗәтләреннән котылырга мөмкинлек бирде, инде алдагы ун-унбиш елда япон һәм Америка техникасы җимешләреннән тыныч кына файдаланып ятып та булыр иде. Парсегянның уен автоматлары куелган залларда хатыны һәм улы хуҗа булды, вакыт-вакыт туганының улы булышкалады, ә кеше аеруча күп җыелган чакларда ярдәмгә башка туганнары килә торган булды. Бармаксыз үз

биләмәләрендә сирәк күренә, аппаратлар янында басып торуны, акча ваклаучы касса тирәсендә буталуны ул үзе өчен түбәнлек дип саный иде. Баеп киткән Артем Парсегян бик тә мәртәбәле тормыш алып бара башлады, көн саен эшлекле кешеләр чуала торган "Үзбәкстан" ресторанына кереп тамак ялгады, башкала хәлләреннән тел чайкап алу өчен кичләрен "Ереван"га сугыла торган булды. Бәйрәмнәрне, табигый ки, "Лидо"да уздыра иде. Ул күренүгә үк оркестр яраткан әрмән җыры "Торна"ны уйный башлый. Йөрүен көчәйтелгән моторлы ак "Волга"да йөрде, елның теләсә кайсы фасылында ак костюм кияргә яратты. Инде беркемнең дә бу кеше кайчандыр слесарь булган дияргә йөрәге бармас иде, яргаланып-теткәләнеп беткән кулларына да чисталык, аклык, шомалык керде.

Хәер, Артем Парсегян үзе дә үткәннәр белән мәңгелеккә өздем дип уйлый иде инде. Шулай да аның элеккеге "эшләре"н белгәннәр берничә тапкыр кызыклы тәкъдим ясадылар, ләкин Бармаксыз бриллиантлы йөзекле кулларын як-якка җәеп, килешле елмаеп әйтә белде: "Төйнәдем, егетләр, зинһар, гаепкә алмагыз!"—диде. Аңа караган һәркем төшемле кәсебе булган бу адәмгә куркынычның күзенә керү кирәк түгеллеген аңлый иде инде.

Ләкин бервакыт язмыш елмаюдан туктады, Парсегянга бөтенесе дә кире килә башлады. Яңа елга әзерләнгән лышпырдык декабрь төнендә, кешеләр бәйрәм иткәндә ниндидер явызлар түбәдән Бармаксыз бинасына кергәннәр, көндәшләре кызыгып туймаган егерме уен автоматының егермесен дә алып чыгып киткәннәр. Әлбәттә, талаучыларны эзләргә күпләр кушылды, Сенатор үтенече буенча, этле милиция дә килде, эзгә төшә алмадылар, маһир һәм оста караклар эш иткәнлеге сизелә иде.

Өч көннән соң Бармаксыз арыган кыяфәттә әйтте:

—Эзләү файдасыз, хәзер минем аппаратлар Кызылсу паромына якынлашып килә булыр, ә иртәгә инде Бакуда булачаклар, яисә бүген үк инде аларны Алма-Атада, бәлки Ахшабадта корып маташалардыр.

Соңгы елда анықы кебек аппаратлар башка шәһәрләрдә дә барлыкка килде, аның өметен шул өзә иде; эзлә хәзер, кайда синеке дә, кайда башкаларныкы?! Кайгыдан Бармаксыз эчүгә сабышты, кәрт уйный торган катраннарда буталып йөрде, караклар җыенына сугылды, талаучыларның эзенә төшәргә ярдәм итүчеләргә акчалата зур бүләкләр вәгъдә итте, ләкин... бәхет дигәнең аны мәңгелеккә ташлап киткән иде инде, күрәсең.

Иртә язда, иртән иртүк баш төзәтергә Чигатайга килгәч, аның өстәле янына ике егет килеп утырды һәм әйләнми-чолганмый гына болай диделәр:

—Юләрләнеп йөрмә, житәр, Бармаксыз, терсәк якын да, тешләп булмый. Безнең бик зәһәр ике эшебез бар, синең кебек компаньон, маһир кеше кирәк, уңсак, тагы шундый уенчыклар алырсың.

Бармаксыз ачыктан-ачык тәкъдим белән килгән егетләргә баштанаяк игътибар белән карап чыкты һәм сорады:

—Нишләп әле сез мине компаньон санyйсыз?

Уң кулына каттә генә рәсем төшерелгәне өлкәнрәк иде, аның янарак кына төрмәдән чыкканлыгы яисә Горбачевның 1987 елгы амнистиясенә эләккәне сизелеп тора иде, җавапны шунысы бирде:

—Бердән, сине авторитетлар искә төшерде, икенчедән, безгә машиналы кеше кирәк, өченчедән, синдә корал һәм дә ки алтын куллар... Операциядә сиңа төп урын билгеләнә...

Бармаксыз, аңлатып торуларсыз да, сейф ачарга кирәклеген төшенде. Икенчесе, яшьрәге, "булган егетләрдән" икәнлеге сизелеп торган корея-лы кәсептәше өстәп куюны кирәк тапты:

—Без сине, Артем, атна буе күзәтеп йөрибез инде, эшсез калдың, бетәсең бит... Җаныңны кыйнама, күтәреләчәксең әле, бер уңышсызлыктан сына торган кеше түгелсең, берьюлы өч йөз меңне югалтсаң да...

—Соңгы тиеннәремне тыгып залны яңарткан идем, картлыгыма кадәр үземне, балаларны ипигә кинәндердем дип уйлаган идем,—дулкынланудан аның куллары калтырый башлады, уен автоматлары югалу белән ул һич тә килешә алмый иде шул.

Корейяле кайсыдыр кесәсеннән житез генә коньяк шешәсе тартып чыгарды:

—Риза булсаң, уныш өчен бер шешә эчәбез дә таралышабыз. Ике көн эчмә, үзеңне тәртипкә керт, мунчамы, бассейнмы... Үзең карарсың. Ул арада без әзерләнә торабыз, операция алдыннан сиңа сугылырбыз. Йә, ничек?

Бармаксыз таныш булмаган кешеләрне тагы бер кат күздән кичерде һәм, ризалыгын белдереп, баш селкеде.

Парсегян ике көн буе әзерләнде, машинасын рәткә кертте, күптән кагылмаган коралларын алып куйды, өч тапкыр Лабзак саунасына барды, бер грамм аракы эчмәде, өйдәгеләре тыныч сулап җибәрделәр. Ул үзенең күтәреләчәгенә ышанды. Операция уңышлы узса, Артур Александровичтан яңа аппаратлар алырга ярдәм сорыйм диде, күнелендә яңа салон ачу уе бар иде, хәзер ул саграк булачак, әйберләрен "страховать" итәчәк. Элек тә шундый тәкъдимнәр бар иде инде. Уйларда-борчуларда ыгы-зыгы килеп ике көн узып та китте, кич белән сөйләшенгән вакытта койма капкасын шакыдылар. Тегеләрнең төгәллеге аңа ошады, чуалчык адәмнәрне яратмый иде. Гаражыннан машинасын чыгарды, өйдәге бүлмәсендә саклаучы коралларын алырга җыенганда гына үзен Варлам дип атаган олырагы аны туктатты:

—Кирәкми. Бүген корал кирәк булмас,—диде һәм эшне аңлатып бирде.

Баксаң, Олегның, ягъни корейялы егетнең Настя исемле дус кызы универсамда эшли икән дә контроль сатып алу вакытында ниндидер обэхэсэсникка капкан, тегесе аны мәхәббәт уены мәтәштерергә мәҗбүр иткән, шул роман ярты еллап бара икән инде. Настенька Олегка ОБХХС адәменен череп чыккан бай кеше икәнен, өендә чиксез зур акчалар тотуын, аңа кыйммәтле бүләкләр бирүен сөйләгән. Моны ул бернинди арткы фикерсез, болай гына сөйләп ташлаган, чөнки Олегны, үзе таныштырганча, инженер дип кенә белә, төп "һөнәре" ниндилегеннән хәбәре бөтенләй юк икән.

"Мәгъшук"ның байлыгы турында белешкәннәрен Варлам сөйләде, ул чыннан да бик бай икән, югарыдагы "йонлач куллар"га таянып, теләсә кайда теләгәнен тартып-суырып кына ала, ди. Машина, видеомагнитофоннарын ел саен алыштыра икән. Кыскасы, кызыктырырлык бәндә. Әле күптән түгел генә ул Настяга чия төсендәге яңа "Вольво" алачакмын дип мактанган, хәтта машина бәясенең 125 мең сум торганын да әйткән, экстра класслы швед машинасын Мәскәүдән кайтарачаклар икән. Машинаны менә-менә китереп җиткерергә тиешләр, димәк, акчасын өйдә тота.

Йортка бәреп керергә җайлы очрак та туып тора: әлеге бәндәнең хатыны Һиндстанда туристлык сәяхәтендә булып, бүген ирнең Настя белән очрашу көне икән. Настя аннан кичке уннарда китәргә тиеш, чөнки соңгы электричка әти-әнисе яшәгән Янгиюлга төнге унберлә кузгала, димәк, ул киткәннән соң, "мәгъшук" адәм өйдә ялгызы гына калачак.

Йөз егерме биш мең сумга машина алырга җыенучыда күпме байлык булырга тиешлеген генә Бармаксыз чамалый иде, шулай да сорап куйды:

—Ә йортка ничек керәбез? Сездә берәр план бармы?

Бармаксызны кызыксындырганына разый калып, Варлам горурлангандай әйтеп ташлады:

—Барысы да алдан каралган, Артем, без аны ике атна күзәтәбез инде, бар гадәтләрен өйрәндек. Ул сәүдәне бугазыннан алган, барысын да өенә китереп бирәләр, күзәткәнебезчә, директорлар, кибет мөдирләре үзләре генә түгел, кем эләгә шул, хәтта йөкчеләргә кадәр. Без дә саранланмадык, бер тартма деликатес җыйдык, шуны тотып үзем керәм, күргәнем бар ич, товар ташу шулай бара.

—Бәлки ул гыйшык уены яратучы Настяны озаткач тагы каядыр чыгып чабар?—дип сорады Парсегян.

—Тиеш түгел. Ул беркемне дә озатмый, әйтәм ич, аны күптән күзәтәбез ич инде, Настенька кебекләре күп аның, берсен дә капкадан ары озатмый. Мәхәлләдә мәгълүм кеше ул, нигә ди аңа күзгә ташланып йөрүләр?!

—Ышандырдың,—диде Бармаксыз һәм алар иске шәһәргә чыгып киттеләр. Вакыт кыса иде, ярты сәгатьтән Настенька ОБХХС Дон-Жуаны өеннән чыгып китәргә тиеш.

Кукчага барып житкәч, мәхәлләдә кеше юклыгын күреп, Бармаксыз сак кына сорап куйды:

—Варлам, каян мондый тынлык, халык кая олаккан?

Варлам, сәгатенә карап әйтте:

—Ун минуттан "Вакыт" программасы бетә, телевидениедән Урта Азия һәм Казакъстан мөселманнары башлыгы ниндидер мөһим вәгазь белән чыгыш ясаячак, барысы да телевизор янында утыра.

—Урамнарның болай бушап калганын мин безнең кварталда бер генә тапкыр, телевизорда коммиссар Каттани белән "Спрут" фильмы барганда гына күрдем бугай.

—Ул фильм турында ишеткән бар барын, карый гына алмадык. Без бит Горбачев амнистиясе белән ирекка чыккан кешеләр,—диде Варлам эчке бер кичереш белән.

Шул ук мизгелдә Олег аның сүзен бүлде:

—Әнә, Настенька белән безнең клиент чыкты.

Машина туктаган жирдән биек тимер-бетон коймага уелган капка әйбәт шәйләнә иде; аның янында ике шәүлә күренде. Нечкә билле, нәфис сынлы беренче шәүләне Олег шунда ук танып алды һәм сөенеп куйды, икенче шәүлә, ир кеше шәүләсе Варламны шатландырды:

—Операция планын кабатлыйм,—диде ул.—Хужа өйгә кергә, мин аңа телефоннан шылтыратам, ул кире капка төбенә чыгар, чөнки Настенька берәр нәрсәсен онытып калдыргандыр дип уйлар. Капканы ачар алдыннан ул, гадәттә, ут кабыза, "күзчек"тән урамга карый. Кулымдагы тартманы күргәч, өйгә кертергә кушар, ул үзе әйбер күтәреп маташмый, монысы да билгеле, ул моннан кечерәк тартманы да кулына алмый. Безнеке бик зур бит, аны махсус сайлап алдык. Без йортка кергән арада син, Артем, ишегалдына үтесен дә веранда артына яшеренәсең. Ул мине озата чыкканда өйгә керәсең һәм аны пистолет төбәп каршы аласың, ә бер минуттан мин ярдәмгә киләм. Олег безне урам яктан саклап торыр.

Алар капкадан күзләрен дә алмыйча һәм бүлдермичә Варламны тыңладылар, шулвакыт хатын-кыз гәүдәсе кинәт кенә ирнекеннән аерылды, асфальтта Настеньканың туфли үкчәләре шыкылдады, төнгә ябылган тимер капканың шыгырдавы ишетелде.

—Вакыт!—диде Варлам һәм алар өчәүләп машинадан чыктылар.

Биш минуттан йорт хужасы яшергән урыныннан теләми генә акчаларын, алтын-көмешләрен, асылташларын чыгара, Варлам аларны спорт сумкасына тутыра иде инде. Кыланмышына караганда төп трофейларга ерак иде әле. Аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торган Бармаксыз кинәт кенә эчке бер борчылу кичереп алды, йорт хужасының йөзе аңа таныш кебек иде. Ләкин күпме генә тырышса да исенә төшерә алмады. Ай буе айнымый эчү үзенекен иткән иде.

Бармаксызның йөзендәге борчылуны күреп, Варлам әкрен генә сорады:

—Ни булды?

—Бу адәмне кайдадыр күргәнем бар кебек, хәтеремә китерә алмыйм.

Варламның тавышына усаллык чыкты:

—Кызурак хәтерлә, юкса син аны атып үтерергә тиеш буласың, шәһәрдә сине белмәгән кеше юктыр.

Талауның беренче минутында ук майор Кодрәтовкә дә пистолетлы кешенең йөзе таныш кебек тоелып китте, аны кайдадыр Сухроб белән бергә күргән иде кебек, тик, бандит белән ҮК кешесе арасында нинди уртаклык булырга мөмкин? Кодрәтов пистолетлының хафаланып куюын да сизми калмады, аларның пышылдашуы сагайтып жибәрде. Шунда гына аңлады, йортына бәреп керүче дә аны белә бугай, югалып калу да шуннан. Йорт хужасының башы яшен тизлегендә эшләде. Әгәр ул дөрес аңлаган булса—аны исән калдырмаячаклар...

Әле бер минут элек кенә ул акчаларын җәлләүдән югалып калган иде, инде тормыш мәсьәләсе килеп баскач, Кодрәтов эһ иткәнче зиһенен туплады һәм ярты сәгатьтән байлыгының шактый өлеше белән хушлашып, аларга "Бетте" диде. Талаучыларның яше иягенә шундый иттереп типте, ул шунда ук аңын югалтты. Һушына килгәндә олырак яшьтәгесе пистолетын биленә тыккан һәм аның борын төбендә нашатыр спиртына манчылган мамык тотып тора иде. Яшьрәге өстенә иелеп усал пышылдады:

—Син, кабих җан, йөз егерме биш меңгә "Вольво" алырга йөрисең, ә безгә ярты-порты утызны биреп котылмакчы буласың, барып чыкмас! Сугымлык малдай иттереп, аяк-кулларыңны бәйләп, газиз корсагыңа кайнар үтүк куярбыз, акчаларың шундук исеңә төшәр.

Йорт хуҗасы кулында нашатыр спиртына манчылган мамык тотып торган кешенең үзенә тишәрдәй итеп каравын сизми калмады, таныды бугай ул аны каһәр, карасу шадра йөзенең агарып китүе дә шуннан. Кодрәтов үзенең нәкъ шушы мизгелдә үлемгә хөкем ителгәнлеген аңламаслык кына түгел иде.

Ә яшьрәк уголовник үзми дә куймый һаман акча турында, йөз егерме биш мең хакында лыгырдый бирде. Майор, чыннан да, артык куркудан "Вольво"га дип куйган акчасы хакында бөтенләй онытып җибәргән иде. Швед машинасына дигән акчаны исенә төшергәне өчен ул хәтта яшь бандитны кочаклап үбәр дәрәҗәгә җитте. Котылыр җай чыга түгелме соң? Хикмәт шунда, акча йокы бүлмәсендә, карават янындагы тумбочкада иде, шул ук тумбочкада пистолет та бар. Сирәк кулланылган пистолетка эш чыгарга тора. Ничек тә рэкетирларның уяулыгын киметергә, үзенең тулысынча аларга буйсынуын сиздерергә кирәк иде. Ул тәрәзәгә таба кузгалып куйды, ләкин картрак бандит аяк чалып өлгерде һәм Кодрәтов әйләнеп идәнгә килеп тә төште. Аяк-кулларын бәйләп ташладылар да каяндыр табып алган үтүкне, күлмәген күтәреп, корсагына куйдылар, яшь бандит штепсельне Кодрәтов алдында селкетеп торды да розеткага тыкты. Пешерә башлауга, ул үтүкне төшермәкче булып боргаланырга тотынды, ләкин картрак бандит, усал елмаеп, аны ике кулы белән эченә тагын да ныграк батырды, әрнеткеч авыртуга чыдый алмаган майор бар көченә авыр гырылдады:

—Бирәм! Барысын да бирәм!

Шунда гына Бармаксыз үтүкне читкә алды.

Тамагы кипкән йорт хуҗасы эчәргә су сорады, аңа суыткычтан алып шифалы су алып бирделәр. Эчеп куйгач, Кодрәтов талаучыларны йокы бүлмәсенә чакырды.

Йокы бүлмәсе зур түгел иде, Югославиядән кайтарылган ак төстәге "Людовик" гарнитуры стеналарга терәп үк куелган иде, чакырылмаган кунаклар ишексездән ишек төбендә тукталып калдылар, ә майор караватянында калган тар гына аралыктан яны белән атлап, зиннәтле тумбочкага якынайды. Ачкыч белән ишеген ачып җибәрде һәм акылыннан язгандай гырылдавык тавыш белән: "Алыгыз! Барысын да алыгыз, хәшәрәтләр!" дип кычкыра-кычкыра төргәк-төргәк акчаларны талаучыларга таба ыргыта да башлады.

Баскыннар йорт хуҗасының мондый хәлләрдә еш була торган истерикага бирелгәнен күрделәр һәм дүрт куллап акчаларны Варламның спорт сумкасына тутырырга керештеләр һәм чираттагы егерме биш сумлыклар төргәге урынына майор кулында пистолет пәйда булганлыгын сизми дә калдылар. Яшь егет күз ачып йомганчы ак караватка әйләнеп төште, майор исә пистолетын Бармаксызга төбәп, кычкырып җибәрде:

—Пистолетыңны келәмгә ташла!

Парсегянга кушканны үтәүдән башка чара калмады, чөнки куркудан акылын югалткан хуҗа, һичшиксез, ике дә уйлап тормый тәтегә басачак иде. Майор Бармаксызның кулларын күтәртеп коридорга алып чыкты һәм караңгы бүлмәгә, кладовкага бикләп тә куйды. Пистолетны кулыннан төшермичә, өйгә керә торган ишекне бикләде, калтыранган куллары белән суыткычтан аракы алып бер стаканга тутырып салды да авызына каплады.

Нидер эшләргә, мөмкин булган кадәр тизрәк ниндидер чара күрергә кирәк иде, чөнки талаучыларның урамда ярдәмчеләре булырга мөмкин. Башта милиция чакырырга уйлаган иде, ләкин соңгы мизгелдә тукталып калды, кладовкага япкан адәмне милиционерлар янында очратканым бар идеме соң, әллә ул үзе милиция формасында идеме дигән шик корты килеп кергән иде. Үз өстенә талаучыларны нәкъ менә милиция җибәргәнлегенә ул бер кәррә дә шикләнми иде. Бәлки, Сухроб Әхмәдовичка шылтыратыргадыр, аның Артур Александрович дигән әшнәсе бер взводлап тән сакчысы тота, алар коткара алыр иде. Ләкин болай итсән дә, озакка сузылыр, аннан соң бераз җайсызрак та кебек иде.

Һәм ул кинәт кенә угрозыскстан полковник Чураевны искә төшерде, аның җинаятьчел дөнья белән бәйләнеше юклыкка беркем дә шикләнә алмый, ярдәм итсә ул гына итә алыр да. Вакыт шактый соң булуга карамастан, ул полковникның эштәге телефон номерын җыйды, бәхетенә, трубканы күтәрделәр. ОБХСС майорының аңгы-минге сөйләвен тыңлаганнан соң, полковник Чураев әйтте:

—Нәкъ вакытында шылтыраттың, биш минуттан операциягә чыгарга тора идек, ләкин хәзер сезгә киләбез, безгә юл унае. Өегездә утны сүндерегез, тәрәзә янына килмәгез. Урамда аларның кәсептәшләре булырга мөмкин, бәреп кермәгәйләре, сак булыгыз.

Егерме минуттан мәхәллә урамнарында милиция машиналарының сиреналары чинап шәррән яра иде һәм Кодрәтов ишегалдына полковник Чураевның хезмәткәрләре кереп тулды...

* * *

Сенатор эш көнен һәрвакыт узган тәүлектәге милиция сводкалары белән танышудан башлап җибәрә иде. Соңгы вакытта вакыйгалар аерата күп була, сводканы вак шрифт белән дә биш-алты биткә көч-хәл белән сыйдыралар. Көндезге ЧПлар турында ул белә иде инде, шунлыктан, гадәттәгечә, Ташкентның төнге тормышы белән кызыксына башлады. Төнге җинаятьләр арасында күзенә Кодрәтов фамилиясе ташлануга игътибарын икеләтә арттырды.

Үзенә артык нык ышанган чибәр майорның йортын басуларын белгәч, аның рэкетирлар белән мангайга-мангай япа-ялгыз калуын күз алдына китереп елмаеп куйган иде, ләкин хәбәрне азагына кадәр укып чыккач, елмаюны йөзеннән кул белән сыпырып ташладылармыни. Хәбәрдә чагылып үткән таныш фамилия ирексездән валидолга үрелергә мәҗбүр итте. Камалов белән юллары аерылганнан бирле йөрәк даруы куллану гадәткә әйләнгән иде инде. Ләкин сводканы ахырына кадәр укып тормады, Парсегян фамилиясе барысын да пыран-заран китереп ташлаган иде инде.

—Ах, Артем! Ах, Бармаксыз, нәрсә эшләдең син,—дип кычкырып куярга мәҗбүр булды Сенатор һәм, җан авыртуга чыдый алмый, кабинетта ишеклетүрле йөри башлады. Җан кыйналыр нәрсәләр җитәрлек иде, сводкада язылганча, рэкетирларны полковник Чураев үзе кулга алган, ә ул соңгы вакытта прокурор Камалов белән бик шикле рәвештә әҗе-гөҗе килә, бәлки алар элек үк Бармаксызның койрыгына баскан булганнардыр, бәлки аның Парсегян белән иске элемтәләрен белә торганнардыр?

Кабинет хуҗасының башында берсеннән-берсе ямьсезрәк сораулар туа торды. Ләкин сорау нинди генә булмасын, бер нәрсә ачык тоемлана, Бармаксыз прокурор Камалов күзенә чалынганчы ук нидер кылырга кирәк, сонларга ярамый иде.

Ниндидер бер мизгелдә Сухроб Шубаринга шылтыратмакчы да иде, ләкин бу уеннан бик тиз кире кайтты, чөнки аңа уголовник Артем Парсегянның кулга алынуына ник шулкадәр борчылуын аңлатырга туры киләчәк. Монысы кирәкле гамәл түгел. Бары тик үзеңә таянырга гына кала. Шул ук вакытта сузарга да ярамый. Республика прокуратурасында сакчыны үтерүнең бердәнбер шаһиты булган Бармаксыз, бәлки, бик сәер шартларда Кощейның һәлакәте сәбәпләрен дә чамалыйдыр? Бу үтерүләрнең берсе хакында гына

беләме, әллә икесеннән дә хәбәрдармы, анысы мөһим түгел иде инде, ничек кенә булса да, Парсегянны йолып алырга, яисә ничек тә булса "телсез калдырырга", бәлки башка юл да бардыр...

Берничә сәгать буе ул Парсегянны коткару планнарын уйлап утырды, ләкин бер генә вариант та үзенә ошамады. Аны, бәхетсезлеккә каршы, полковник Чураев каптырмаган булса, ничек тә җаен табар иде, Бармаксызны барыбер коткарыр иде. Кодрәтовны үгетләпме, куркытыпмы гаризасын кире алдырып булыр иде. Беткәнмени сәбәпләр... Катырак салып ташланылган, талашып кителенгән, үз-үзебезне белештерми башлаганбыз, инде бик каты үкенәбез, дип тә язып була иде ич гаризаны. Әшне йомарга шулары да җитәр иде. Вакытның аның файдасына эшләмәгәнен аңлаган Сенатор, һич кичекмәстән, Бармаксыз белән очрашырга карар кылды.

Парсегян ябылган изоляторның башлыгын яхшы белгән Сенатор озакка сузып тормады, тикшерү бүлегенә китте, кем белә, бәлки ябылган кеше үзен коткаруның берәр юлын тапкандыр дигән уе да юк түгел иде.

Бармаксыз белән күрешү кыен булмады, чөнки соңгы атна дәвамында гына да инде өченче мәртәбә милиция хезмәткәрләрен талау очрагы теркәлгән иде. Ул шулай аңлатты да, Парсегяннан эз күрсәтүче шымчыларны ачыклыйсым килә, диде.

Сорау алулар бүлмәсендә Сенаторны күргәч, Артемның күзе дүрт булды. Конвой чыгып китүгә үк ул, сүзләренә аерым мәгънә салырга теләп, бер генә җөмлә әйтте:

—Сухроб, мин бик күп нәрсәдә сиңа өметләнәм,—диде.

Сенатор бу сүзләр артына яшерелгән янауны тоймаганга салышты:

—Мин дусларымны бәладә ялгыз калдырмыйм, шуңа күрә дә мин монда,—диде. Ләкин шунда ук каты гына чәнчеп тә куйды:—Нигә кирәк булды бу сиңа? Житмәсә, минем дусларны талыйсың... Сорасаң, тагы йөз мең бирмәс идеммени...

Менә шунда уен автоматлары хуҗасы милиция кешесен Сенатор янында берничә мәртәбә очратканын исенә төшерде, ләкин эш узган иде инде. Озак кына сүзсез утырдылар. Бармаксызга нинди киңәш бирергә белмәсә дә, кунак әйтмичә булдыра алмады:

—Бөтен бәла шунда, сине полковник Чураев үзе кулга алган, аның нинди кеше икәнен беләсең, юл табу ай-һай авыр, мөмкин хәл түгел, диярлек. Бу җәнҗаллы вакыйга минем дустыма, Кодрәтовка дә кирәк түгел, менә шушы кәртне уйнатырга тырышырбыз да. Ни генә булмасын, телеңне тешлә, минем белән танышлыгың, башка дусларың хакында ләм-мим! Хәзер булыша алмасак, төрмәдән тартып алырбыз, Сәлим югары судта ахыргы кеше түгел.

Артем Сенаторга сагышлы караш ташлап алды:

—Бәла ялгызы йөрми, диләр, дөрес икән. Үземне таламаган булсалар, бу эшкә барыр идеммени?—диде.—Минем яшьтә төрмәгә эләгү хәтәр нәрсә. Житмәсә, авыру аякларым белән... Син, Сухроб, тырыша күр инде, сине бер дә авыр хәлдә калдырганым булмады бит.

Сүзнең беткәнен аңлатырга теләп, Сенатор торып басты. Бернәрсә ачыклый алмаса да, килүенә үкенмәде. Бармаксызга артык ышанырга ярамый икән. Чыгарган төп нәтиҗәсе шундый булды. Очрашу шулай тиз төгәлләнер дип уйламаган Парсегян ашыгып әйтеп куйды:

—Тартырга бирер иден, ичмасам...

—Гафу, бөтенләй онытканмын, иртәгә үк берәр блок яхшы сигарет ташлап чыгармын.—Һәм кесәсеннән изелеп беткән "Кент" пачкасын алды да күпме калганлыгын да карамыйча, Артемга сузды.

—Икәү генә икән,—диде Бармаксыз кәефсезләнеп.

—Түз, иртәгә китерәм, дидем ич!—диде Сенатор һәм ашыгып ишеккә таба юнәлде.

Тоткыннар белән шыгрым тулы камерага кайткач, Бармаксыз аның көтелмәгән визиты турында уйлана башлады һәм Сенаторның барыннан да элек үз тиресе өчен калтыравын аңлап алды, артыгын сөйләп ташламагае,

дип курка. Менә шушы "артыгын"а ябышырга кирәк тә, юкса, мондагы яшьләр әйткәнчә, "еракка һәм озакка" олактырулары шиксез.

Очрашуны кат-кат башында әйләндереп карады һәм ҮК кешесенең бөтен кыяфәтенә бәреп чыккан ясалмалык, ихлассызлыкны тагын бер кат күргән кебек булды. Төптәнрәк уйласаң, аңа да гасабиланыр, үз-үзен тотышында гайре табигыйгә тартым хәлгә килерлек сәбәпләр бар-барын. Ләкин очрашу аны сөендермәде, киресенчә, күңеленә ниндидер аңлаешсыз шик-шөбһә генә кертте. Ә ул үзенең тоемлау, сиземләү сәләтенә ныклап ышана торган кеше иде. Борчулы уйлардан аның тартасы килеп китте һәм ул Сенатор калдырган сигаретларны исенә төшерде.

Пачканы кесәсеннән чыгарган иде инде, ләкин аны нәрсәдер тукталып калырга мәҗбүр итте, күз алдына үзен игелек кылам дип санаган кешенең йөгерек күзләре килде, колагында әйткәннәре яңгырады: "Иртәгә сиңа бер блок ташлап чыгармын..." Сенаторның ашыгып чыгып китү аңа качып китү булып тоела башлады, юкса андый зур урындагы кешене ашыктырырга кем генә батырчылык итәр иде икән...

"Агулагандыр, мөгаен, агулагандыр",—Артемның башында өзми дә куймый да шул шик бөтерелде, чыдап булгысыз дәрәҗәдә тартасы килсә дә, шырпысын алырга кыймады.

Өске сәкедә яткан нык-таза егет аны байтактан күзәтә иде инде. Аның кебек үк короллы талау өчен тотылган егетнең көмешсу каплы "Кент" сигаретын күрүгә үк авызына селәгәй җыелды, әгәр камерадагы башка берәүдә булса, ул аларны йолкып кына алыр иде. Ләкин Бармаксыз—үзен тыныч һәм тавышсыз тотса да, дәрәҗә буенча монда—иң зур авторитет иде. Шунда Артем үзе дә аңлап житкермәгән бер эш эшләп ташлады, капны өскә, егеткә таба чөеп җибәрде дә:

—Теләсәң, "Космос"ка алыштырып бир, мин Американыкын яратмыйм,—диде.

Тегесе очып килгән капны һавада ук эләктереп алды һәм, тиз генә күз ташлап, аска өч сигарет сузды:

—Житәме?

—Житәр!—диде Парсегян һәм татлы рәхәтлек кичереп сигарет кабызып җибәрде.

Төне буе йоклый алмады, төне буе аның миен бер сорау бораулады: агуланганмы сигаретлар, әллә юкмы? Хәтта төн уртасында торып, күршесен уятып тартырга сорады, көндез Америка сигаретлары белән кайтарырмын, диде. Шуннан соң гына бераз тынычлана төште, таң алдыннан тирән йокыга чумды.

Камерада ул иң соңгылардан булып уянды, саташулы тынычсыз йокы кичәге вакыйганы да оныттырган иде инде. Ләкин стенага таба борылып яткан күршесенә, Америка сигаретлары яратучы егеткә күз ташлауга бүген тагын килергә вәгъдә иткән Сенаторны исенә төшерде. Әгәр килсә... Башыннын кыелып узган шушы "әгәр" сүзе аны күршесен уятырга этәрде дә инде. Ләкин кагылуга ук мәет салкынлыгы кулын өтеп алгандай булды.

Бармаксыз кычкырып җибәрүдән чак кына тыелып калды, курку хисе бөтен барлыгын чолгап буа, кыса башлады, ул камерадашларын этеп-төртеп ишеккә ыргылды, аны куллары белән төя, аяклары белән типкәли башлады, шашкан кешедәй: "Прокурорга алып барыгыз! Мине прокурорга алып барыгыз!" дип, бөтен камераны яңгыратып кычкырырга кереште.

Ипле генә адәм акылыннан язды дип уйладылар булса кирәк, камерадашлары ул-бу әйтмәде, тавышка төрмә хадимнәре йөгереп килде, ишекне аяк-куллары белән дөбердәтеп ятучы Бармаксызны баштарак алар бер-ике сугуда аяктан егарга, авызын томаларга җыенганнар иде, үгез җегәренә ия Парсегян үзенә ташланган кешеләрне мәче урынына гына чөеп атты, бертуктаусыз прокурор белән очраштыруларын таләп итте.

Күрше бүлекләрдән ярдәмгә килеп життеләр һәм җыйнаулашып Артемны озын коридорның аргы очындагы бер кешелек камерага өстерәп алып киттеләр. Ул анда да тынычланмады, бөтен көче белән ишекне төя-төя

прокурорны чакырды. Шуннан соң гына дежур офицерлардан берсенең "Нигә ул сиңа прокурор, конкрет кем белән очрашырга исәбең?"—дип сорарга башына житте. Бармаксыз үзенең бары прокурор Камалов белән генә очрашырга теләвен, дәүләткүләм мөһим белдерү ясарга җыенуын әйтте. Чакырылган психиатр тоткын белән ун минутлап утыруга ук, аның үз акылында икәнлеген белдерде.

Кичә генә кораллы талау өчен кулга алынган, элегрәк уен автоматлары тоткан Артем Парсегян исемле берәүнең кичекмәстән үзе белән очраштыруларын таләп иткәнен белгәч тә Камаловның башына килгән беренче уе теге серле һәм борчулы аноним хат турында булды. Ул хат килгәнгә бер айлап вакыт узган иде инде. Шунлыктан ул артык уйланып тормыйча, кичекмәстән тикшерү изоляторына чыгып китте.

Килеп керүгә үк Парсегян Камаловтан үзен кичекмәстән икенче җиргә күчерүләрен, ул җирнең Сухроб Әхмәдович Әкрәмхуҗаевтан яшерен сер итеп саклануын таләп итте, юкса, беренче мөмкинлек тууга ук аны тагы теге дөньяга җибәрергә тырышачаклар. Тоткын шул хәтле курыккан, каушаган, ярсулы иде, шуның өстенә, акылга сыймаслык, адәм ышанмаслык нәрсәләр сөйләп атты ки, прокурор психиатр чакырырга булды. Ләкин аның уйларын сизенгәндәй, Парсегян һаман сөйли бирде:

—Сез мине ычкынган дип, шунлыктан абруйлы затларга нахак гаеп тага, дип уйлыйсыздыр, зинһарлап сорыйм, ышаныгыз миңа, кичә ул монда булды, телемне тешләргә киңәш итте, ике "Кент" сигареты бирде. Сенаторны яхшы белгәнлектән, сигаретлар агулангандыр дип куркудан мин аларны күршемә биргән идем, бүген иртән—ул инде мәет...

Менә шунда прокурор акылдан язган кеше белән сөйләшеп утыруына тәмам ышанды, чөнки Парсегян белән бер камерада утыручының үлеме хакында ана беркем дә әйтмәгән иде. Ләкин Парсегян туктый алмады, әйткәнемне һичьюгы тикшереп карагыз, дип ялынды, ялварды. Буш сүзне артык дәвам итмәс өчен прокурор коридорга чыгып, дежур офицерга Парсегян сүзләрен тикшерергә кушты.

Бер-ике минут та үтмәгәндер, офицер, шакып-нитеп тә тормыйча, бүлмәгә йөгереп керде һәм куркынган тавыш белән, чыннан да, 1960 елда туган, кораллы талау оештырган Снегирев дигән бәндәнең үлгәнлеген әйтте.

Шул минуттан алар арасындагы сөйләшү бөтенләй башка юнәлеш алды һәм ике сәгатьтән артык дәвам итте.

Ниһаять, бары тик шунда гына үлеп баручы сакчының "Сухроб... Сухроб..." дип тәкърарлавының мәгънәсе аңлашыла башлады. Район прокуроры карьерасының баш әйләндергеч тизлектә үсүе, Акмал ханны кулга алгач ник борчылуы мәсьәләсендә дә ачыклык пәйда булды.

Бармаксыз сөйләгәннәр дә аны кулга алырга тулысынча житә, ләкин Сенатор тормышында ачыкланмаган ак таплар артык күп иде әле. Парсегян аның белән сирәк-мирәк кенә очрашкан, барысын да белеп бетерә алмый. Мәсәлән, ул республика прокуратурасы телефоннарының тыңлануы турында берни дә белми, иренгә карап кеше сөйләгәнне укучы төрек егетенең үлеме хакында да бер сүз әйтә алмады.

Ләкин шиксез, Сенатор кебек үтә хәйләкәр, мәкерле кешегә каршы әлегә Парсегяннан да кыйммәтле шаһит юк. Үзе очраткан иң куркыныч һәм "явыз убыр"ның нәкъ менә Сенатор икәнлегенә Камалов шикләнми иде инде. Парсегянның куркуы да аңлашыла, табигый ки, ҮК кешесе үзенең яшерен тормышын белгән бердәнбер шаһиттан арыну өчен бөтен көчен куячак. Бармаксызны монда калдыру куркыныч иде һәм прокурор, генерал Саматов белән сөйләшеп, кыйммәтле тоткынны КГБ изоляторына күчертте.

Парсегян ничек кенә куркып калса да, Югары судтагы Сәлим Хәсәнович турында бер сүз дә әйтмәде, аның кирәге булуы бар иде әле. Әгәр Сенаторны кулга алсалар, дип фикер йөртте ул, Сәлим Парсегянның үзен сатмаганлыгын төшенәчәк. Бу киләчәккә төбәлгән, ләкин дөрес гамәл иде. Прокуратура ишегалдында кеше үтергән өчен Сенатор "вышка" алачак, ә талау өчен

Бармаксызга күп дигәндә ун ел бирергә мөмкиннәр. Менә шулчак Сәлим кирәк булачак та инде.

Прокуратурага кайткач Камалов Парсегян белән очрашуда аноним хатка бәйле бер генә нәрсә дә ачыкланмаганга үкенеп тә куйды, юкса ул шуңа өметләнә иде. Әңгәмә вакытында сүз җебен ничаклы гына шул якка таба сузарга теләсә дә, барысы файдасыз булып чыкты. Чөнки Парсегян "эшем кешеләре" арасында бер вак бөҗәк кенә булып, бүгенге абруе исә элек кылган җинаятьләренең "данлы" эзе генә икән. Ә хат баштан чыкмый да чыкмый.

Камалов хатны бик үк яшь булмаган рус кешесе язганын да тәгаенлый, чөнки "отечество", "держава" сүзләрен мондый язмада бары рус җанлы, өлкән буын вәкиле генә кулланырга мөмкин. Әллә никадәр гомерен Рәсәйдә, аның пайтәхетендә үткәргән Камаловны беркем дә бу фикереннән баш тарттыра алмас иде. Алынган мәгълүматларның дөреслеге шикләндерми, алар буенча ике тикшерү ясап карадылар, икесе дә тулысынча расланды. Ләкин бер нәрсә икеләндерә иде: хатның асыл мәгънәсе нидә, чынлап та Ватан өчен ихлас гамь, борчылумы анда, әллә кемдер дәүләт кулы белән көндәшләрен юк итәргә алынганмы?

Әгәр беренчесе икән, бу кешене ничек тә табарга кирәк, аның бәяләп бетергесез белеме, тормыш тәҗрибәсе, элемтәләре бар. Ул берүзе хокук сагындагы бик күпләрне алыштыра ала. Күпләр илгә каршы алып барылган экономик диверсияләр турында белми һәм белә дә алмый, хат авторы кебекләр берән-сәрән генә һәм нәкъ менә алар икътисад стратегиясен билгели дә. Мөгаен, хат язучы бизнес дөньясында стратегларның берседер, бүгенгедән һәм киләчәктән дә күп нәрсәне белүе шуны күрсәтә. Их, аның хат язуының ихлас вә төп сәбәпләрен беләсе иде.

Хәер, хат авторы үз алдына башка максатлар куйган булса да, Парсегянның көтелмәгән шаһитлеге кебек үк, бу язма да искиткеч кыйммәткә ия иде. Шушы мәгълүматларга таянып, Камалов икътисади диверсия ясарга маташуларны туктатып кына калмады, бәлки җинаятьчел дөньяга үзенең бу эшне белүен, хәбәрдарлыгын күрсәтте, прокуратураның вәзгыятьне үз кулында тотканлыгын, илне башбаштакларча һәм бернинди җәзасыз талау көннәре узганын да аңлатты. Болардан тыш, киләчәкне күздә тоткан икенче яклар да бар иде. Мәсәлән, шушы хат аркасында ул прокуратура эшенә бөтенләй башка күз белән карый башлады, хокук саклау органнары эшен күздән кичерде, баксаң, алар һаман вакыйгаларның койрыгында сөйрәләләр, беренче хәлиткеч адымны һаман да җинаятьчел дөнья ясый, законга сыймаган эш-гамәлләрне алдан ук кисеп-кисәтеп кую турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Шуңа күрә, ул ксерокста хатның копиясен алды, Мәскәүгә җибәрде. Хатта Мәскәү адреслары булган өчен генә түгел иде бу. Законга сыймас финанс операцияләренең никадәр осталык һәм киң колач белән үткәрелүен, бүгенге көрәш ысулларының бернигә ярамаганын күрсәтү, Генераль прокуратура һәм дәүләт куркынычсызлыгы комитетын шулар белән көрәшкә юнәлтү өчен дә кирәк иде ул хат.

Аноним автор раславынча, ил икътисады мәнфәгатьләрен дәүләт сере дәрәҗәсендә саклау чоры җитте. Шунсыз теләсә кайсы хөкүмәтнең дәүләтне кризистан чыгару тырышлыгы файдасыз булачак. Камалов бүген банк эшен, икътисадны, финансны яхшы белгән югары классы экспертларга һәм белгечләргә үтә нык ихтыяҗ туганлыгын аңлады, шул ук вакытта алар ачыктан-ачык та һәм яшеренеп тә эшли белергә тиеш, шулай булмаса, җиңү тиздән һәм мәңгегә мафия ягында булачак. Аларның экспертлары хаталы, ялган рецептлар бирми, алар җитез, йөремсәк, зур акча алып эшлиләр, тәкъдимнәре күз ачып йомганчы тормышка ашырыла. Квалификацияле белгечләрне, банкларны, финанс оешмаларын контрольдә тоту—хәзергечә читкә очкан халык акчаларын бөртекләп, берән-сәрәнләп җыеп йөрү түгел, ә вакыйгаларны алдан белеп тору дигән сүз ул.

Җинаятьчелек белән ныклап танышканнан соң Камалов алар белән элеккечә көрәшүнең файдасы аз икәнен дә төшенде, чөнки җинаятьчеләр

ул ысулны юристларга караганда да яхшырак белә. Янача эш итәргә, җинаятьчеләр арасына "штирлицлар" кертергә кирәк иде, проблемаларны эчтән белми торып, җинаятьчелекне җиңеп булмаячак. Караклар дөньясы инде күптән хакимият коридорларында күкрәк киереп йөри, моны Сенатор мисалы да раслап тора. Парсегян сүзләренә ышансаң, бу бәндә республика җитәкчелеге башына ук менеп утырырга хыяллана икән.

Камалов оешкан җинаятьчелек белән көрәш бүлеге башлыгының шылтыратуын көткән арада КГБ тикшерүчеләре "кыйммәтле" шаһитнең күрсәтмәләрен алалар иде инде. Сенаторны тизрәк, Бармаксызның исән калуын һәм яхшылап яшерелүен белгәнче үк кулга алырга кирәклеген Камалов аңлый иде. Ләкин бу Акмал ханны кулга алу кебек үк авыр нәрсә, чөнки традиция буенча республика җитәкчеләренә хәбәр итәргә кирәк, ә андый очракта моның сер булып калуы бик шикле иде. Шул ук вакытта Камаловның Сенаторны ычкындырасы да килми, качып киткән очракта да ул куркыныч тудырыга сәләтле иде.

Илдә үзгәртеп кору башланганга дүртенче ел, вәгъдә ителгән муллык юк, тормыш начарлана гына бара. Иң кирәкле товарлар юкка чыкты, азыктөлеккә бәя күтәрелде. Элеккечә бердәнбер культура булган мамыкка түләү хакы тиеннәр белән исәпләнә, бай табигатьле, иркен яклар бөлгенлеккә төшә бара. Ничек ризасызлык тумасын. Ә Сенатор кебекләр халык нәфрәтенең дары мичкәсенә шырпы төртергә дә күп алмаслар.

Акмал хан Мәскәүдәге тикшерүләрне шулкадәр оста, хәйләкәр рәвештә суза, тормышы өчен җан талаша һәм байлыгын әлегәчә беркемгә дә белдерми яшереп килә белде. Сенатор аның белән килешенеп эш итмиме, аның варисы түгелме? Баш әйләндергеч зур суммалары да анда сакланмыймы? Камалов башында әнә шундый көтелмәгән уй-фикерләр йомгагы әйләнде дә әйләнде. Ул әле һаман аларны бер җепкә тезеп бетерә алмый изалана иде. Шул чакта телефон шылтырады:

—Иртәгә Сенатор Сәмәркандта киңәшмә уздыра, беренче рейска билет алган,—диде трубкадагы тавыш.

—Бик шәп, безгә аны читтә кулга алырга кирәк, тавышы азрак булыр.

Әкрәмхуҗаевны кулга алу, инде көтелмәгән хәлләргә күнегеп барган халыкны да шаккатырды. Кешеләр аның хокук саклау, гадел хөкем турындагы атаклы чыгышларын хәтерлиләр иде әле, соңгы елларда аның исеме телдән төшмәде, атаклы юрист иде бит ул.

Сәмәркандта кулына богау салынуга ук Сенаторны туры рейс белән Мәскәүгә озаттылар. Шул ук сәгатьтә аның язмышы ерактагы Аксайда "гомер кичергән" Сабир-бабага мәгълүм дә булды. Акмал хан белән бергә үз язмышларын һәм биш миллион сум акча тоттырганда: "Сез һәрвакыт минем кешеләрнең күзәтүе астында булырсыз", дигәне шулай тормышка ашты. Кулга алу яшерен һәм тавыш-тынсыз гына үткәрелсә дә, хәбәр итүчеләр табылды. Сабир-баба Акмал ханны кулга алуда бары бер кешенең—прокурор Камаловның гаепле икәнен белә иде. Менә тагын ул карталарны бутап ташлады. Вәзгыятьне биш бармагыдай төшенгән Сабир-бабаның тамагына прокурор күптән сөяк булып утырган иде инде һәм ул аңа ныклап тотынырга карар бирде, җиңүе белән бик мактанмасын әле. Листовка текстын да ул үз куллары белән язды, Сухроб Әкрәмхуҗаевның кулга алынуын Мәскәү куйган кешеләрнең җирле зыялыларга карата башбаштаксызлыгы, кансызлыгы дип бәяләп, халыкны күренекле юристны якларга чакырды. Листовкалар яшерен рәвештә Наманган типографиясендә басылды, атчабарлар аларны барлык өлкәләргә таратып чыкты.

Сенаторны Мәскәүдәге "Матрос тынлыгы" дигән, яңгыравык купшы исемле төрмәгә яптылар. Иректән килгән яңа кешене камерада киң күңел белән каршы алдылар, аны монда күпләр белә, белмәгәннәрнең аның турында ишеткәннәре бар, мәкаләләре буенча таныш иделәр.

Сенатор иректәге вакыйгаларның төрмәгә бик тиз килеп җитүен белә иде, ләкин "Матрос тынлыгы" төрмәсендәгеләрнең республикадагы хәлләрне шулкадәр яхшы белүе аны чын мәгънәсендә шаккаттырды. Вакыт-вакыт

аңа алар Бадамзар чәйханәсендә утыралар һәм кичә узган пленум турында фикер алышалар кебек тоела иде.

Камерадашлары юридик фәннәр докторы сөйләгәннәрне йотып кына бардылар, аларга үз планнарын, хыялларын, уй-фикерләрен расларлык сүзләр кирәк иде. Ә ул аларның фикер агышын ачык чамалап, рухларын ныгытырга тырышты, чөнки һәркайсысының җинаять эше җимерелү ахыр чиктә аның файдасына эшли иде. Шул ук вакытта ул беркем белән дә дуслашмады, берләшмәде, теләктәшлек күрсәтмәде. Һәрвакыттагыча, ул үзе өчен генә уйлый иде.

Сәяси көчләр Үзбәкстанны Союздан аерып алыр куәткә иямени дип сораганнарга ул, уйлап та тормыйча җавап бирде: әйе, мәгълүм бер очракта булырдай нәрсә, диде. Аңа гына хас астыртынлык белән, барып чыга калса, Россия законнарының Төркстан гражданнарына таралмаячагын, үзләренең тыныч кына кайтып китәчәкләрен дә әйтеп куйды. Табигый ки, мондый раслау казна каракларына ошый иде һәм алар иректән килгән кешенең һәр сүзенә шатланып колак салдылар.

Халык хөкем барышын ничек кабул итә, без барыбыз да элек әйткәннәребездән баш тарттык, тикшерүчеләр басымы астында гына гаепне үз өстебезгә алган идек бит, дип кызыксынучыларга ул Акмал хан сүзләре белән җавап бирде. Халыкка сезнең алар өчен газап чиккәнегезне аңлата алдылар, диде. Бәлки, дөрес юл да булмагандыр, ләкин сез мамык өчен гадел бәя куйдырырга тырыштыгыз. Бүген һәркайда һәм һәрнәрсәдә Үзәкне гаеплиләр, сез бит газета укыйсыз, бу безнең дә тактика булырга тиеш. Үзенең әңгәмәләрен яна тоткын шулай тәмамлый иде.

Беренче көндә үк Сенатор Акмал хан турында белешергә тотынды, ләкин беркем дә аның белән очрашмаган булып чыкты, хәтта ин озак ятучылар да аның кайдалыгын белми иде. Табигый, камерадашлары аның ни өчен утыруы белән кызыксынмый калмадылар. Монда да Сенатор тел чарлап котылды, идея аерымлыклары өчен икәнлегенә ишарәләде. Ләкин ул Сәмәркандка очар алдыннан Бармаксызның исән калганын ишетеп өлгергән иде инде. Төп бәла дә шунда. Мәскәүдән килгән прокурор кулларына богау салган мизгелдә ул бер нәрсәне бик ачык аңлап алган иде инде: аның тормышы Бармаксыз һәм... Камалов тормышына бәйле. Әгәр бу үҗәт прокурор белән бер-бер хәл була калса, Парсегян элеккеге күрсәтмәләреннән баш тартыр иде. Газет укып баручы адәм хөкем барышының ничек оештырылганын яхшы беләдер. Хәлбуки, Парсегянның үзен юк итү күпкә отышлырак булыр иде. Менә шунда Камалов тагын ярык тагарак янында утырып калыр иде. Иң аянычы шунда, иректәге Сәлим Хәсәнович аның язмышы Парсегян кулында икәнлеген башына да китерми.

Хәзер аның өчен иң мөһиме—ничек тә Хашимовка хәбәр салу, дөресрәге, кыю бул, ва-банк бар дип, команда бирү иде. Прокурор Камалов бу юлы отты, ләкин Сенатор үзен җиңелгәнгә санамый, һәрхәлдә, ул әле үзенең соңгы сүзен әйтмәде. Биш миллион сум акча белән яшәү өчен көрәшергә була, акча көчен ул яхшы белә.

Бөтенләй көтмәгәндә җае да чыкты, Ташкенттан бер түрәне ирекка чыгаралар икән. Сенатор бу кешене яратмый, аңа ышанып та бетми иде, ләкин башка чара юк һәм ул тәвәккәлләргә карар бирде. Йөрергә алып чыккач, тегене читкә алып китеп, каты итеп әйтте:

—Ташкентка кайткач, беренче эшегез итеп, Лидо" ресторанына керегез, хуҗа ханымга миннән сәлам күндереп, Сәлим Хәсәнович белән очраштыруын сорагыз. Аңа мине кулга алуда мәскәүле белән уен автоматлары ярат учыдан шикләнергә урын юк, дип әйтегез. Хәтерегезгә сендерегез, минем аркада гаепсезләргә кыек карый күрмәсеннәр. Ә дошманнар белән мин үзем аңлашырмын, җаны чиста кешегә бернинди хөкем дә куркыныч түгел.

Бу юлы да ул үзен зыялы, тәрбияле кеше итеп күрсәтә алды, чынлыкта, шартлы телдә аның сүзләре "ничек кенә булса да прокурор Камалов белән сейфлар ватучы Артем Парсегянны юкка чыгарыгыз", дигәнне аңлаталар иде.

Сенаторны кулга алганнан соңгы вакыйгалар агышы, бәйдән ычкынгандай, шул кадәр кызулады, кайда нәрсә булганлыгын беркем дә белми кебек тоела башлады. Ләкин бу беренче карашка гына. Шушы вәзгыятьтә күп нәрсә Камаловка, Югары судтан Хашимовка бәйле булып, хәтта Сабир-баба да читтә калмаган иде. Барысы да чишелешенә таба бара һәм, гадәттәгечә, күп нәрсәне "галиҗәнап очраклылык" хәл итте дә.

Шулай булырга тиеш булганмы, әллә очраклы рәвештәме, нәкъ шул көннәрдә Камалов кулына кайчандыр СССР прокуратурасында тирән сер итеп телгә алынган документлар килеп керде. Үзбәкстанның Беренче секретаре язмышы кыл өстендә иде. Ләкин шунысы гаҗәп, Рәшидов дәвамчысын кулга алу Сенатор кулына богау салудан кимрәк яңгыраш тудырды.

"Матрос тынлыгы"ннан котылган адәм Сенаторның үтенечен аяк астына салып таптамады, Югары суд кешесе белән очрашты һәм сүзен-сүзгә Мәскәү хәбәрен ирештерде. Хашимов Бармаксызның кулга алынуын белә иде, ләкин аның дустына нинди куркыныч тудыруын анлый алмый баш ватты. Камаловы аңлашыла, аны күптән юк итәсе иде инде. Шефның үтенечеәмер, ультиматум. Димәк, Бармаксыз аның дусты һәм курсташының тормышына куркыныч белән янаучы нидер белә. Әйтелгән кадәресе Камалов белән Парсегян гомере өчен Сенатор теләсә нинди сумма түләргә дә әзер дигәнне аңлата иде. Сенатор үзенә бәяне бик зурдан куйган иде.

Бармаксыз белән әлләни катлаулы булмаска тиеш иде. Каракларның уртак казнасына йөз меңне ыргытсаң, аны шул ук көнне камерадашлары бугазлап ташлаячаклар. Сәлим Хәсәнович бу иске һм сыналган ысулны яхшы белә иде.

Ләкин шул киеренке, тыгыз көннәрдә тагы бер вакыйга булды һәм ул прокурор Камаловка да, Сенаторга да, аның дусты Миршабка да, хәтта Акмал ханның рухи остазы Сабир-бабага да кагылып үтте.

Кувасай бистәсендә месхет төрекләре белән җирле халык арасында ызгыш килеп чыккан һәм очраклы рәвештә базардан башланган җәнҗал бөтен Фергана үзәнендә милләтара бәрелешкә сәбәп булды. Йортлар өстендә ялкын телләре уйнады, борынгы Коканд белән Маргиланда кеше каны түгелде.

Төн уртасында Кремльдән күрсәтмә алган прокурор Камалов, таң атканны да көтеп тормыйча, махсус самолетта Фергана үзәненә очты, анда МВД гаскәрләре һәм милиция тартыла башлаган иде инде. Шул ук көнне прокурор һәм Югары Совет сессиясеннән, Мәскәүдән кайтып төшкән мөфти хәзрәтләре телевидениедән Урта Азия һәм Казакъстан мөселманнарына мөрәҗәгать белән чыктылар, халыкны тынычланырга, салкын акыл белән эш итәргә чакырдылар.

Республика прокуроры телевидениедән чыгыш ясап яткан минутларда Сәлим Хәсәнович ялланган үтерүчеләргә: Арифка һәм тагын ике егеткә инструктажны бетереп килә иде инде. Шулай итеп, Камаловка ятьмә куела башлады. Алар йөзәр мең сум аванс алдылар һәм шул ук төнне Чадаксай үткеле аша ике машинада Ферганага юл тоттылар. Ыгы-зыгы, канлы җәнҗал хөкем сөргән якларда Камаловның үлеме артык күзгә ташланмас, беркем дә аның махсус оештырылганлыгын әйтә алмас иде.

Фергана үзәнендәге чуалышлар хәтта Сабир-баба өчен дә көтелмәгән хәл булды, ул якташларының түземле сабырлыгына ышана иде. Күрәсең, халкының түземе төкәнгән, сабыр канатлары шартлап сынды. Бер генә нәрсә үкендерә иде—кан исеннән башын югалткан халыкны үз контроле астына алып булмый, ләкин аны теләгән якка борып җибәрергә мөмкин иде әле.

Прокурор Камаловның телевидениедән чыгышын Сабир-баба да тыңлады, мөфтинең дога-вәгазьләренә колак салды, ләкин акылга килергә чакыруны үзенчә кабул итте, телевизорны сүндерүгә үк Исмәт белән Ибраһимны, кайчандыр ҮК кешесен Наманган-Ташкент поездына илткән Җәлилне чакырып алды.

—Хуҗабызга, кадерле Акмал ханга булышыр сәгать җитте,—диде ул шәрекъ итагате кануннарын саклап тормыйча гына,—Ферганада, Кокандта, Маргиланда, үзәктәге барлык кышлакларда дөньяның асты-өскә килгәнен беләсез. Кызганыч, суешта үзебезнең мөселманнар зыян күрә, Аллаһу тәгалә бу гаепсез коелган кан өчен безне ярлыкар, дип беләм. Үз җирендә балаларының тамагын туйдыра алмаган кешенең күршесенә шикләнеп каравы табигый хәл. Мин диндәшләребез, безнең кебек үк сөнниләр булган төрекләрне талауны хупламыйм, еллар буе тулышып җыелган бар ачуны, нәфрәтне райкомнарны, судларны, милиция һәм прокуратура биналарын тар-мар итүгә борып җибәрергә кирәк. Хакимият халык ачуының көчен күрерлек булсын. Һәркайсыгызның Ферганада, Кокандта туган-тумачасы, дуслары бар, ә Җәлилнең хатыны Маргиланнан. Бүген үк өч машинага төялеп чыгып китегез, һәркайсыгыз үзенә ошаган аерым юлдан барыр. Халыкны бары тик Акмал хан гына тынычландыра ала дигән сүз җибәрегез, һәркайда аның исеме мөмкин кадәр ешрак телгә алынсын. Акчаны җәлләмәгез, кешеләр өереннән кушбугазлы, катырак тавышлыларны сайлагыз. Рәхәтләнеп кычкырсыннар. Хакимият биналарына бәреп керергә кирәк. Аракыга саранланып тормагыз, анаша да онытылмасын. Ләкин сак булыгыз, куркынычсызлык турында да хәтердән чыгармагыз. Яшьләрне туйганчы ашатыгыз-эчертегез, теләгән кадәр сарык суйдырыгыз, ит ашаган кешенең каны кайнар була, тизрәк йөгерә. Кыю булыгыз, бернидән дә курыкмагыз, кешеләрне хакимияткә каршы котыртучылар бер сез генә түгел, миңа хәбәр иттеләр инде, телмәрләр байтак җыелган анда. Егерме миллионлы Үзбәкстан—Әрмәнстан да, Балтыйк буе да түгел, без—бик зур көч. Тагы... Бер урында озак тормагыз, бер ике көннән сакал-мыекларыгызны кырып атарсыз, чәчегезне алдырырсыз. Кыяфәтне үзгәртә белергә дә кирәк. Юлда очраша калсагыз, машиналарыгызны алыштырырсыз. Үзегез белән күбрәк ялган номерлар алыгыз, беркемнең дә документ тикшереп торырга вакыты юк, иң мөһиме—эләкмәгез. Беләм, сезне өйрәтеп торасы юк, урынына һәм җаена карап эш итәрсез. Ә хәзер акча алыгыз да—юлга... Догаларым сезнең хакта булыр.

Ариф үзенең кулдашлары белән Ферганага таң алдыннан килеп керде, бүген булмаса, иртәгә комендант сәгате кертелү ихтималы билгеле, ә алай була калса, шәһәргә тикшерү үтмичә керү мөмкин булмаячак. Сигез зарядлы, оптик мүшкәле "Франчи"ыннан колак кагуынны көт тә тор. Ә аның бар ышанганы шул винтовка иде.

Аларны көтәләр иде инде, ләкин беркем дә аларның максатын белми, гомум шау-шу астында банк яисә саклык кассасын чистартырга килгән дип уйлыйлар иде. Җинаятьчел дөньяда артык сорау бирү гадәте юк, читләрнең серләре аркасында гомер кыскара төшә—бу хакыйкатьне алар бик иртә үзләштерәләр. Ариф прокурорның Ферганада, нигездә, ике җирдә—прокуратурада яисә милициядә буласын күз алдына китерә иде. Яшерен киңәшмәләр тагын кайда үтсен, ди. Болар өстенә биш минутлык дип йөртелүче очрашулар, тәртипсезлекләрне бетерү буенча штаб утырышлары... Бераз ял итеп алуга ук ул йорт хуҗасының мотоциклына атланып шул җирләрне карап кайтырга чыгып та китте.

Ике бина да бер-берсеннән ерак түгел, хәтта бер үк урамда икән. Ариф килеп җиткәндә генә өлкә прокуратурасы яныннан Ташкент номеры куелган "Волга" кузгалып китте, шофер белән янәшә прокурор Камалов утыра, өс киеменә караганда, янында коралы булырга тиеш түгел иде. Ариф ике сәгатьләп прокуратура тирәсендә булды, көчле бинокль ярдәмендә өлкә прокуроры кабинетының да, утырышлар залының да кайдалыгын бик тиз ачыклап өлгерде. Чакырылган кеше санына карап, киңәшмәләр шул ике бүлмәнең берсендә уздырылачак. Ләкин алар кайда гына уздырылмасын, Камалов йә президиумда, йә прокурор кәнәфиендә утырачак, трибунада булуы да ихтимал. Ничек кенә булмасын, һәр өч урын да күршедәге йорт түбәсеннән бик яхшы күренә иде.

Прокурор машинасын автоматлардан утка тоту варианты да каралган

һәм ике кәсептәш нәкъ менә шуның өчен килгән дә иде инде. Алар спорт автомобильләренең көчле моторлары куелган машиналарда күз ачып йомганчы юкка чыга алалар, бары прокурорның төгәл маршрутын билгеләргә генә кирәк. Ә Ариф күтә белә иде. Вакыт ашыктырмый, түләү вакыт исәбеннән түгел. Миршаб өчен иң мөһиме—ахыргы нәтиҗә.

Бөтен өлкәдә гадәттән тыш хәл игълан ителүе мәгълүм, күзгә артык ташланырга ярамый. Үзләре тукталган шәһәр читендәге йортка кайтуга, Ариф кәсептәшләренә машиналарындагы Ташкент номерларын Фергананекенә алыштырырга булышты да юл сумкасыннан Чейзның мажаралы детективын алып, ишегалдындагы айванга урнашты. Детектив романнар аңа вакыт уздырырга ярдәм итә иде, ялланган үтерүче буларак, уңайлы моментны көтеп ала белү аның өчен иң мөһим фактор, ә атканда тидерә алмау турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Шәһәрдә һәм өлкәдә хәлләр шәптән түгел. Камаловка эш муеннан. Прокуратурага ул кичен, йә булмаса, төнлә генә кайтып керергә мөмкин. Шунлыктан, Ариф машиналары белән маташучы кулдашларын борчып тормады, прокурор машинасын автоматтан атып китү вариантын да бөтенләй сызып ташларга ярамый иде.

Җәйге эңгер-меңгер төшүгә, Ариф кулдашларыннан берсен өлкә прокуратурасы бинасы янына җибәрде. Прокурор Камалов берәр төрле киңәшмәфәлән уздырып ятмыймы. Йөкләнгән бурыч бары шуннан гыйбарәт иде.

Ләкин ул кичтә Камалов өлкә прокуратурасына аяк та басмады, ул төне буе Маргилан белән Коканд арасында бөтерелеп йөргән икән.

Иртән, мотоциклга атланып, Ариф тагы өлкә прокуратурасына иснәнергә китте. Зур түрәләрнең һәм хәтта хәрбиләрнең машиналары дәррәү җыелуга караганда, бинада зур киңәшмә буласын аңлау читен түгел иде. Табигый ки, анда прокурор Камалов чыгыш ясамый калмас. Ул "Ява"сын борып маташканда гына, чыннан да, Ташкент номеры куелган ак "Волга" да килеп туктады.

Ниһаять, барысы да үз урынына утырды, "ау" корбаны буласы кеше "ау" буласы урынга килеп житте. Ариф ишегалдына кайтып керүгә үк аркадашлары эш сәгате сукканын аңлап алдылар. Барысы да кичтән үк сөйләшеп-киңәшләшеп куелган иде инде. Сүтелгән автомат винтовка салынган нәни чемодан-футлярны алып, егетләр ак "Жигули"ларда билгеләнгән позициягә китеп тә бардылар. Бераздан алар артыннан "Ява"ны иярләгән Ариф кузгалды. Прокуратура ишегалдында тып-тын, димәк, киңәшмә башланган дигән сүз. Ул үзе сайлап алган йортның түбәсенә ашыкты, анда аны кораллы ярдәмчесе көтә иде инде.

Көчле бинокль утырышлар залы буйлап күпме генә капшанмасын, ни гаҗәп, Камалов беркайда да күренмәде, ә трибунада сөйләүчеләр бер-бер артлы алышына тордылар.

"Тынычлан... тынычлан..."—дип тәкърарлады үз-үзенә Ариф һәм күз карашы белән генә иптәшенә дә тыелып торырга кушты. Коралны чыгарырга иртәрәк иде әле. Ул аркасы белән вентиляция торбасына сөялде дә күзләрен йомды, фикерне бер ноктага тупларга кирәк булганда ул гел шулай итә иде. Шул рәвешле ун минутлап утыргач көчле окулярларны кабат тәрәзәләргә төбәде, ләкин прокурор күренмәде. Эчке ишегалдындагы машиналар тукталышына күз салды һәм Ташкент номерлары куелган ак "Волга"ны бик тиз эзләп тапты. Шофер машинада, димәк Камалов та бина эчендә булырга тиеш. Ул, кинәт кенә дәртсенеп, биноклен өлкә прокуроры тәрәзәсенә төбәде—Камалов шунда иде.

Ариф иркен сулап куды, кабат күзләрен йомды һәм аркасы белән салкын моржага сөялде. Тынычланырга, ихтыярны тупларга кирәк иде. Шул рәвешчә тагы ике-өч минут утыргач кына ярдәмчесенә винтовканы алырга ишарә ясады. Камалов кабинет хуҗасының өстәле артында утыра, погонлы кешеләр белән ниндидер киңәшмә алып бара. Аркадашы "Франчи"ны җыеп маташкан арада Ариф кесәсеннән көзге чыгарып, "Жигули"да көтеп утыручы икенче кәсептәшкә дә сигнал бирде, бусы "объект" үз урынында,

өч-дүрт минуттан без чыгасы подъезд төбенә килеп туктарга кирәк дигәнне аңлата иде.

Ариф кулына автомат-винтовканы алды, ярдәмчесенә түбән төшәргә кушты, ә үзе оптик прицелны тәрәзәгә төбәде. Камалов ана яны белән утыра иде, Ариф аның чигәсенә төбәде. Болай тидерү мизгел эчендә үлем китерә, кайчандыр табиблыкка укып йөргән егет анатомияне бик яхшы белә иде.

Арифның тәтегә басуы булды, тәрәзәгә арты белән утырган кеше кинәт кенә күтәрелде дә ниндидер кәгазьне Камаловка сузды—һәм шунда ук бер якка авып та төште. Ариф үз гомерендә беренче мәртәбә тидерә алмады. Икенче тапкыр атып торырга вакыт калмады, кабинеттагылар барысы да урыныннан сикереп тордылар. Ариф күз ачып йомганчы "Франчи"не сүтеп, футлярына салды да иң кырыйдагы подъезд баскычына очты, түбәндә аны моторы кабызылган машина көтә иде инде.

Өлкә прокуроры кабинетында чын мәгънәсендә мәхшәр башланды, кемдер яралыга ташланды, кемдер өстәл астына ук кереп китте, бары угрозыск начальнигы гына югалып калмады, ул шундук телефонга ябышты һәм районны чолгап алырга боерды. Арадан кемдер кычкырып куйды: "Бөтенләй оятсызландылар, милицияне куркытмакчы булалар..."

Залда, чыннан да, милиция чиннары гына җыелган иде. Өлкәнең эчке эшләр идарәсе башлыгы телефоннан прокуратура тирәсендәге районнарда патруль оештырырга кушты һәм киңәшмә дәвам итте. Милиция житәкчеләре белән очрашу тәмамлангач, Камалов партия оешмасы утырышы бара торган залга керде. Жилкәсенә пуля тигән полковник Холматовның хәле турында, тәрәзәгә атучылар хакында берәр нәрсә ачыкланса, кичекмәстән үзенә хәбәр итүләрен кушып калдырды. Ләкин ана актив җыелышында чыгыш ясарга туры килмәде, чөнки ашыгыч хәбәр килеп төште. Берничә меңлек шашынган толпа Коканд шәһәр милициясе бинасы янына ыргыла икән. Бөтен эшне ташлап шул якка чыгып китәргә туры килде.

Утырыр алдыннан гына машина янына ниндидер лейтенант килеп чыкты һәм полковник Холматовның хәле турында әйтеп өлгерде. Ярасы куркыныч түгел, ә атучылар турында бернәрсә дә ачыклый алмаганнар иде әле. Аннан соң, лейтенант капылт кына кесәсенә тыгылды һәм кәгазьгә төрелгән нәрсәдер алып, аны "Волга" тәрәзәсеннән сузды:

—Ниндидер сәер пуля, иптәш прокурор...

Полковник Холматов турында яхшы хәбәре өчен лейтенантка рәхмәт әйтеп тә өлгермәде, машина алга ыргылды һәм алар үткән төндә инде ике мәртәбә булып өлгергән Коканд шәһәренә чыгып киттеләр. Бөтен уй-фикере Коканд тирәсендә бөтерелгән Камалов кулындагы ят пуля турында бөтенләй онытып җибәрде, аны шофер искә төшерде. Мәктәп дәфтәреннән ертып алынган кәгазь төргәкне ачып җибәрүгә инде бер тапкыр күргән таныш пуляны абайлап алды, иреннәрдән укый белүче төрек егете Айдын үлгән көнне аның өстәленә нәкъ шундый пуля китереп салганнар иде. Кызыксынучан шоферга ул берни дә әйтеп тормады, бары трофейны кире аңа кайтарды. Анысы, пуляны әйләндереп-тулгандырып карады да:

—Чыннан да сәер пуля, безнеке түгел бу, чит илнекедер,—дип куйды.

Угрозыскттан полковник Чураев тәкъдим иткән һәм җинаятьчел дөнья белән шактый таныш егет барысын да белеп һәм аңлап сөйли иде.

Хөршид Азизович бу пуляның кемгә төбәп атылганын әле прокурор кабинетында чагында ук аңлаган иде инде. Полковник Холматов очраклы рәвештә генә аның гомерен саклап калды. Ату өчен урынның һәм вакытның белеп сайлануы, ауны мәкерле һәм акыллы, үткен һәм сизгер дошман оештыруы турында сөйли. Житди чаралар күрергә кирәк булыр. Әгәр дә ул үлгән булса, атуның махсус рәвештә оештырылганлыгын беркем дә белми калыр иде. Сугыш заманы бит. Сугыш барысын да күтәрә ул...

Камалов кинәт кенә шоферыннан сорап куйды:

—Нортуха, синең үзең белән коралың бармы?

Тегесе, башын да бормый, җавап бирде:

—Әлбәттә. Полковник Чураев монда килер алдыннан гына тагын бер пистолет бирде, мондый ыгы-зыгыда сезгә ау оештырырга мөмкиннәр, дип кисәтеп тә куйды әле,—диде һәм прокурорга пистолет сузды.

Кичекмәстән килеп житкән эчке гаскәрләр ярдәме белән кичкә таба Коканд шәһәре милиция бинасына һөжүм итүчеләр алып ташланды. Милиция бинасын саклаучылар арасында югалтулар шактый күп булып чыкты. Солдатлар халык өереннән атучылар булганда да корал кулланмаганнар. Хәрбиләр килеп житкәнче үк котырынган толпаны туктатырга беренчеләрдән булып ташланган руханилар һәм жирле милиция вәкилләре аеруча зур зыян күргән иде.

Кичен Камалов тагын Ферганага, тәртипсезлекләрне бетерү штабы утырышына кайтып китте, аның белән бергә махсус гаскәрләр майоры да юлга чыкты. Майор "джип"та гына йөри, аны бронежилетлы дүрт автоматчы озата бара. Ике машина да—прокурор "Волга"сы һәм майор "джип"ы да—телефонлы булып, юл буе элемтә өзелмәде. Юлның күпмедер өлешен спецназ майоры "Волга"да барды, прокурорга "Джип"ка күчеп утырырга туры килде. Барысы да штабтан кайсы машинага шылтыратуларына бәйле иде. Прокуратура ялны белми эшли, хәрбиләр белән тыгыз элемтә урнаштырылган иде. Фергана юлында аларга еш кына кышлакларда, район үзәкләрендә тукталырга да туры килде, һәркайда аларның катнашуы, хәлне жайга салу кирәк иде.

Үзбәкстанда атаклы чүлмәкчеләр яшәгән Риштан бистәсе янынннан узып барганда прокурор күзенә ике мәртәбә жиденче номерлы ак "Жигули" чалынып узды. Машина башкаларыннан берни белән дә аерылмый, бары артык житезлеге, елгырлыгы гына күзгә ташлана һәм аның шоферы үтә тәжрибәле егеттер дигән фикер калдыра иде.

Ниндидер район үзәгенә кереп барганда "Волга"ны узып алга ыргылган машина чак кына авариягә эләкми калды, Әгәр ул яшен тизлегендә алга ташланмаган булса, ул барган полосага, каршыга килеп чыккан йөк машинасына бәрелеп көл булачак иде. Камалов хәтта гади генә машинада кеше ышанмаслык шундый көчле мотор утыруын үзенчә билгеләп тә куйды.

Шәһәргә керер алдыннан гына тагын әллә каян шул "жиделе" килеп чыкмаса, бу вакыйга, бәлки, онытылган да булыр инде иде, очсыз-кырыйсыз юл бит ул, "лихач"лар житәрлек. Әмма һаман бер үк машинаның күзгә ташлануы прокурорны уйга салды. "Жигули"дә утыручылар "Волга"ның автоматчылар утырган "джип"тан аерылып, ялгыз калуын көтәләр кебек иде. Ләкин уйлары чуалды. Көтмәгәндә телефон шылтыравы игътибарын читкә юнәтте һәм ул "Жигули" турында онытты, хәер, тегеләр дә күздән югалган иде инде.

Штаб утырышы барганда Камаловның исенә әллә нишләп куәтле мотор куелган машина төште һәм ул алдындагы кәгазьгә "ФЕР 36-12" номерлы ак жиденче модель "Жигули" кемнеке икән, ачыклагыз әле" дип сызгалап, язуны шәһәрнең ГАИ начальнигына ыргытты.

Штаб утырышының ахырында жавап килеп житте: "Андый номерлы ак "Жигули" Ферганада юк, күрәсең, бу номер ялган яисә урлангандыр".

Менә шунда барысы да урынына утыргандай булды, күп нәрсә ачыкланды: ак "Жигули"дәгеләр трассада, тәгаен, аны аулаганнар, әгәр янәшәдә спецназ автоматчылары бармаса, ниндидер берәр кискен борылышта һөжүм ясаячаклары шиксез, таулы-ташлы, борылмалы хәтәр юлларда теләсә-нинди аварияне, һөжүмне бик оста оештырып булыр иде.

Штаб утырышы тәмамлангач, Камалов иртән тәрәзәгә ату вакытында югалып калмыйча, районны чолгап алырга әмер биргән кешене—шәһәрнең угрозыск начальнигын бер читкә чакырып алды һәм спортзалда көрәшчеләр, самбистлар куллана торган манекеннар бармы икәнлеген белеште. Раслаучы жавап алгач, шуларның икесен алып килеп "Волга"ның арткы утыргычларына куярга кушты. Аннан соң, спецназ майорын табып, үзенә бер бронежилет, ике автомат һәм кыр бинокле бирүен сорады. Майор, артык сораулар бирмичә генә, прокурорның соравын канәгатьләндерергә китте.

Ярты сәгатьтән Камалов ишек алдына чыкканда, ул сораган нәрсәләр машинада иде инде.

—Кая барабыз?—диде шофер, автоматлар, бронежилет, манекеннар турында сорамый гына.

—Кунакханәгә кайтабыз, эт булып арыдым, иртәгә көн тагын да авыррак булмагае,—диде Камалов.

Бераздан прокурор үзләренең бөтенләй башка якка баруларын күреп алды. Бу хакта әйткәч, шоферның җавабы бик кыска һәм аңлаешлы яңгырады:

—Әйе, без кунакханәгә бармыйбыз. Монда минем туганнарым бар, төнгә кунакка киләм дип шылтыраткан идем. Безне көтәләр...—Бераз дәшми барды һәм өстәп куйды:—Иртәнге хәлдән соң кунакханә куркынычсыз урын, дип әйтә алмас идем. Икенче тапкырында алар тидермичә калмас.

Көндез ул Чураевка шылтыратып, тәрәзәгә ату турында да, ниндидер ят пуля турында да хәбәр иткән иде инде. Полковник атуның очраклы түгел икәнен бик тиз аңлап алды һәм куну урынын алыштырырга кушты.

Прокурор каршы килмәде, бары арыган кыяфәттә сорап куйды:

—Син кич белән трассада берәр шикле нәрсә күрмәдеңме?

—Безнең тирәдә бөтерелгән ак "Жигули"ны күздә тотасызмы? ФЕР 36-12 номе?

—Әйе, мин шуны күздә тотам, шунлыктан, машинага корал куйдырдым, ә бронежилет сиңа.

—Ә нигә спецназ озатуын сорамыйсыз?—дип сорады Нортухта һәм прокурор полковник Чураевның аңа ышанычлы егетне беркеткәнен аңлап алды.

—Бу аларны куркытачак,—диде прокурор. Шоферының йөзендә аптырау күреп, дәвам итте: "Озаклап аңлатып тормыйм, вакыт та юк, тарихы да озын. Хәрбиләрдә "утны миңа юнәлтегез" дигән төшенчә бар. Мин менә шулай эшләргә тиешмен, чөнки бу кешеләрне ычкындырырга хакым юк. Прокуратурага бик күп серләрне ачып бирерлек куркыныч җинаятьчеләр алар. Шуңа күрә, кемнендер озатып йөрүе турында сүз дә була алмый, хәтта безгә ау оештырылганын сизмәмешкә салынырга тиешбез. Барысына да җитезлек, өлгерлек кирәк, уяулыкны югалтырга ярамый. Көчле моторлы ак "җиделе" күзгә чалынса, бигрәк тә. Әле аның иртәгә бөтенләй башка номерлы булуы да ихтимал.

Тәҗрибәле оперативник полковник Чураев моннан бик еракта булса да, вәзгыятьне бик тиз чамалап алды, ят пуля турында хәбәр килеп ирешүгә үк ул Айдинның үлемен искә төшерде, аның башына да шундый кургаш кисәге җиткән иде ләбаса. Прокурорга ауны Аксай кешесен үтерткән кешеләр оештырганы ачык иде инде.

Ул төнне Ариф, кулына тулы әзерлектәге "Франчи" винтовкасы тотып, кунакханә каршындагы йорт түбәсендә бик озак утырды, бары сәгать дүрткә җиткәч кенә прокурорның кайтмаячагына төшенде. Ләкин бер нәрсә табыш-мак булып калды: кайтмауның сәбәбе нәрсәдә: ул үзенә ау оештырганнарын сизенгәнме, яисә көтелмәгән вакыйгалар аны Ферганадан чыгып китәргә мәҗбүр иткәнме.

Ариф икенче вариантны кулайрак санады, чөнки үзәндә киеренкелек кимеми, киресенчә, бәрелешләр тагы да көчәя төште. Ярсыган халыкка әрҗәләп аракы ташулары да билгеле иде инде. Шәһәр хакимияте бинаыларына һөҗүмгә ташланучы яшь җилкенчәккә илле сумлык "бүләк" таратып йөрүче кемсәләр дә бар икән. Акмал хан Мәскәү төрмәсеннән качкан икән дигән хәбәр йөри, баш күтәрүләргә ул җитәкчелек итә, дип тә сөйлиләр. Төнлә яшьләр өйләренә таралмасын өчен, кичкә алар җыелган урыннарга көтүе белән сарык куып китерәләр, шашлык мәҗлесләре оештырыла, аракы-хәмер су урынына ага. Прокурорга баш тәрәргә дә вакыт юк. Ариф боларны бик яхшы белә иде.

Яңа көн тууга прокурор Камаловка игълан ителгән ау да дәвам итте. Иртән иртүк мотоциклга утырып Ариф прокуратура һәм милиция янынннан узып китте, ләкин Ташкент номеры таккан таныш ак "Волга"

күренмәде, йә ул килеп җитмәгән әле, йә таңнан ук чыгып киткәндер. Аннан соң базар тирәләрен урады, кешеләр кайнаган чәйханәләрдә этелеп-төртелеп йөрде һәм төрле имеш-мимеш арасыннан алар ауларга тиеш кешенең бүген кай тирәләрдә булачагын ачыкларга тырышты. Балалар шакмагы белән уйнагандагыдай, вакыйгаларны алай да, болай да тезеп карады һәм прокурорның бүген, һичшиксез, Коканд юлында йөрергә мәҗбүр булачагын тәгаенләде дә. Канлы вакыйгалар, фетнә үзәге Фергана белән Маргиланнан шушы зонага күчкән иде инде. Ариф тиз генә ничек эш итәчәкләрен ачыклады, яңа тактика төзеде. Фергана–Коканд трассасы тулысынча максатка туры килә иде, өлкәдә хөкем сөргән тәртипсезлекләр аркасында бу юлны даими тикшереп торып булмый, мона милициянең көче, техникасы да җитми. Миршаб куйган бурычны үтәгәч тә Таҗикстанга, Ленинабад шәһәренә таба чыгып китүе җайлы. Аннан Ташкентка хәтле кул сузымы арасы. Коралны юл кырыенда, уңайлы берәр җирдә күмеп калдырырга да була, вакыты җиткәч, килеп алу озак түгел. Иң мөһиме, юкка-барга ыгы-зыгы килмичә, юл буендагы берәр чәйханәдә узып киткән машиналарны күзәтеп утырырга. Әгәр "Волга"ны озата килүче автоматчылар һәм спецназ булмаса, ул барыбер ерак китә алмас, көчле мотор белән аны эһ дигәнче куып җитеп була. Беренче текә борылышта ук аңа тераэп диярлек атарга мөмкин булачак. План һәм гади, һәм ачык иде, үзенчәлекле ауда катнашучыларның берсе дә каршы төшмәде, ике сәгатьтән үзләренә кулай күренгән чәйханә табып, шунда урнаштылар да.

Иртәнге якта Камалов йорт-нигезләрен югалткан качаклар өчен әзерләнгән лагерьда булды, аларны саклау өчен өч катлы бөҗра булдырырга кушты. Чөнки канга сусаган кешеләр өеренең бу якка да килеп чыгу ихтималы бар. Лагерьга ярдәмчесез карт-коры, хатын-кызлар һәм балалар җыелган иде.

Әгәр канга сусаган башкисәрләр өере әлеге "бөҗра"ларны өзеп качакларга ташланырга җөрьәт итсәләр, бөҗраның өченче катындагы хәрбиләргә корал кулланырга әмер бирергә туры киләчәк. Моны ул күңелендә кире каккысыз катгый карар итеп беркетеп куйды. Дөрес, үзәктән әлегә мондый боерык килгәне юк. Бәлки килмәячәк тә. Соңыннан баштан да сыйпамаслар бәлки. Ләкин ул шушы карт-коры, күзенә караган нарасыйлар хакына барысына да әзер иде инде. Кан исеннән исергән өер исә котырганнан-котыра барды, отыры явызлана төште. Өерне котыртып торучылар инде ачыктан-ачык кычкыра башладылар: армиядән дә, милициядән дә курыкмагыз, муллалар сүзен тыңламагыз, сезгә барыбер атмаячаклар!

Прокурор месхет төрекләренең аксакаллары белән сүз алып барган арада "Волга"да телефон бер генә минутка да тынып тормады. Нортухта төрле яклардан килгән хәбәрләрне көч-хәл белән язып өлгереп барды. Элеккечә иң кайнар нокта һаман Кокандта, аның тирәсендәге районнарда иде. Машинага утыргач, Камалов шофер егет язып барган хәбәрләре тиз генә укып һәм ашыгыч рәвештә Кокандка кузгалырга кушты. Анда аны күптән көтәләр иде инде.

Шәһәрне чыгуга ук, прокурор Нортухтага майор биреп калдырган бронежилетны кияргә кушты, автоматларны исә алар кичтән үк утыргычлар астына яшереп куйганнар иде.

Күнелләре бүген тагын ниндидер бер-бер хәл буласын сизенсә дә, юл буена берсе дә үзләрен эзәрлекләп килүчеләр турында ләм-мим сүз катмады. Юл борылмалы, таулы-ташлы, прокурорның бирелән үтәчәге күпләрдән сер түгел иде. Икесе дә күзләре белән көчле моторлы җиденче модельдәге ак "Жигули"ны эзләделәр, ләкин, үч иткәндәй, ул күренмәде. Кокандка тагы туктый-туктый барырга туры килде, чөнки һәркайда республика прокурорының сүзе, киңәше, ярдәме, закон көчен куллануы кирәк иде.

Тукталышларның артык ешлыгы Камаловны террористлар турында онытып торырга мәҗбүр итә, ләкин шофер егет бер генә минутка да уяулыгын югалтмады. Юл кырыендагы чәйханә янындагы кешесез ак

"Жигули"ны да беренче булып нәкъ менә ул күреп алды.

—Әнә ул ФЕР 36-12 номерлы машина, әрсезлекләре чиктән ашкан, хәтта номерын да алыштырып тормаганнар.

Камалов күз ачып йомганчы авыр уйларыннан арынды һәм хискә бирелмичә каты итеп әйтте:

—Монысы безнең файдага эшли, Нортуха туганкаем. Номерларын алыштырмаулары әйбәтрәк тә әле. Димәк, үзләренә артык нык ышаналар. Ышана бирсеннәр. Без аларны күрмәдек тә, сизмәдек тә дип исәпли бирсеннәр. Тизлекне киметмә. Монда алар юкка туктамаган, без бу җирдән узмыйча Булдыра алмый идек. Шулай бит...

Чәйханә яныннан бераз ераклашкач, прокурор бинокльдән арткы тәрәзә аша караш ташлады. Фаразы дөрес булган, өч ир үз дәрәҗәләрен белеп, ашыкмый гына ак "Жигули"га утырып маташа иде.

Шофер белән янәшә барган Камалов тиз генә утыргыч артыннан бер манекенны тартып чыгарды һәм үз артына утыртты, тагын бинокльдән карый башлады:

—Булдыра алганча, бар көченә ку, койрыкка тагылып киләләр инде. Шайтан алгыры, машиналары шәп каһәрләрнең. Әнә теге биек калкулык артындагы озын борылышны күрәсеңме, әгәр каршыдан машина килеп чыкмаса, һөҗүм итәр өчен моннан да уңайлы урын булмас. Калкулык артына кереп җиткәч, автоматларны алып, юл буендагы канауга чумабыз. Анынчы синең урынга икенче манекенны куярга кирәк булыр. Капотны ачып куярбыз. Шушы аларның игътибарын алмый калмас. Аларның коралы әзердер инде, куып җитәчәкләр һәм узып барышлый машинага тәрәп диярлек атачаклар, монысы гангстерлар алымы. Ә без җаена карап эш итәрбез.

Борылышка керүгә үк алар юл кырыендагы зур ташларны күреп алдылар, Нортуха нәкъ алар янында тормозга басты. Күз ачып йомганчы машинадан ыргылып чыктылар һәм әлеге ташлар янына чаптылар. Бөтен тәннәре чымырдап куйды, арттан куып килүче афәтнең салкыны аяк-кулларга йөгерде кебек. Ташлар артына качарга да өлгермәделәр ыжгырып килүче машинаның көчле мотор тавышы ишетелде. Күрәсең, аны соңгы көченә җиткереп куалар иде. Һәм бераздан шиннарын чыелдатып, борылышка таныш җиделе очып килеп керде.

Юл читеннән ерак түгел ак "Волга"ны күрүгә әзәрлекләп килүчеләр тизлекне, мондый шартларда мөмкин булганча, киметә төштеләр, ашкынып килүче машинаның ике тәрәзәсендә автомат көпшәләре күренде. Әле "Волга" белән тигезләшеп җиткәнче үк, алар котырып ут ачтылар, ә янәшәдән узганда, машинаны иләккә әйләндергәннәр иде инде. Йөз метрлар узып киткәч, "җиделе" туктап калды, үтә елгыр машина борылып ашыкмый гына кирегә килә башлады. Бәлки, алар һөҗүмнең нәтиҗәләрен күрергә теләгәндер, бәлки, машинадан нинди дә булса документ алмакчы булганнардыр, ә бәлки, киресенчә, милицияне ялгыш юлдан җибәрер өчен нәрсәдер ташлап китәргә җыенганнардыр.

Машина янына килеп җитәрәк "җиделе" туктады, чөнки күтәртеп куелган капот салонын күрергә комачаулый иде, ләкин машинадан чыгарга ашыкмадылар, көттеләр... Тишек шиннардан һава чыгуы ишетелде, каяндыр асфальтка сыеклык ага башлады.

Ак "Волга"ның чуккәннән-чүгә баруы зур ташлар артыннан да аерымачык күренә иде. Шунда "Жигули"ның ишекләре шартлап ачылып китте һәм аннан өч егет килеп чыкты. Икесенең кулында автомат иде. Алар сүзсез генә бер-берсенә карашып алдылар һәм, трассаның буш икәнен күреп, сак кына "Волга" янына киттеләр.

—Аякларына гына атарга,—дип пышылдады Камалов шоферына.

Ләкин шунда коралсыз чыкканы ниндидер сизенепме, бәлки, арткы утыргычта йон-мамыклары тырпаеп торган манекенны шәйләп алгандыр, кычкырып җибәрде:

—Атас, машинага!

Менә шунда рәхимсез автомат чираты бер мизгелдә өчесен дә кисеп ташлады.

—Нәрсә эшләдең син?!—дип кенә әйтергә өлгерде Камалов шоферына һәм террористлар тәгәрәп яткан юлга йөгерде. Әле берсен, әле икенчесен әйләндереп карады, шикләнер урын юк, өчесе дә җансыз иде инде.

Автоматын җиргә каратып тоткан Нортухта килеп җитте. Камалов сорауны кабатлады:

—Нишләп болай иттең? Мин бит сиңа әйттем, аякларына гына, дидем...

Шоферның күзләре кинәт кенә усал елтырап куйды:

—Болар—яллы үтерүчеләр һәм аларның ирекгә чыккач, минем гаиләмне суеп чыгуларын теләмим,—диде.—Мин безнең законнарга да, гадел хөкемгә дә ышанмыйм, ә болай тынычрак булачак һәм, шуның өстенә, бу—гадел хөкем.

Үтерелгәннәрне юлдан канауга чыгарып куйганнан соң, алар "Жигули"ны да күздән кичерделәр. Багажниктан ят кыяфәтле футляр килеп чыкты, ә аның эчендә исә төнлә күрү приборы куелган, сүтелгән автомат-винтовка иде. Италиядә эшләнгән һәм "Франчи" дип аталучы үтә сирәк очраучы коралның патроннигында әле ике патроны да бар иде. Камалов аларны сүтеп алды һәм уч төбендә сикертеп торды.

Аларны күрүгә Нортухта кычкырып җибәргәнен сизми дә калды:

—Кулымны кисәргә бирәм, сезнең кесәдә нәкъ менә шундый пуля ята. Кичә сезгә нәкъ шундый пуля белән аттылар. Аткан кешене дә чамалыйм, анысы "Жигули"дан автоматсыз чыкканы. Ул—"чистакул" ягъни, оста снайпер, мәргән. Андыйлар автоматка тотынмый.

—Ә мин аның исемен дә беләм,—диде прокурор тыныч кына.—Ариф атлы ул. Мин аның эзеннән күптәннән бара идем инде. Кызганыч, тагын җепләр өзелде.

* * *

Арифны ике егет белән Ферганага прокурорны "ауларга" озатканнан соң, Миршаб Сенатор фәрманының икенче пунктын үтәргә кереште. Монысы Бармаксызга, ягъни уен автоматлары тотучы Артем Парсегянга кагыла иде. Дөресен әйткәндә, ул аның үлеменең нигә кирәк булуын башына кертә алмый иде.

Ләкин Парсегянның эзе кинәт кенә югалды да куйды. Аның идән асты заводларыннан "Лидо" ресторанына аракы ташуны каплап торучы майор Кодрәтовны талаганда полковник Чураев тарафыннан кулга алынуын ул төгәл белә иде инде. Парсегянны җинаятьчел каналлар буенча таба алмагач, Миршаб аны милициягә эшләүче кешеләр аша эзли башлады, ләкин күзгә күренмәс стенага төртелгәндәй булды, беркем дә берни дә белмиме, әйтергә теләми идеме, анламассың. Ләкин Миршаб үҗәт затлардан, этәсен этте, төртәсен төртте һәм барыбер белде. Бармаксыз КГБ тикшерү изоляторында! Милициягә элек-электән хәбәр җиткерү белән шөгыльләнүчеләрнең югалып калу сәбәпләре шунда гына ачыкланды да. Һәм менә шунда гына Хашимов Бармаксызның үз шефы өчен бик куркынычлы нәрсәләр белүен чамалады да инде. Парсегян кинәт кенә кул җитмәслек кешегә әйләнде. Шунлыктан приказның беренче пунктын үтәүне ашыктырырга кирәк иде. Әгәр "Москвич"ны юк итә алсалар, Парсегянның судта мөхтәрәм кешегә, Сухроб Әхмәдовичка яла яктым, дип әйтергә генә башы җитәчәк иде. Монысы шиксез. Бу эшкә прокурор Камалов мәҗбүр итте, дип тә өстәргә була. Хөкем системасының барлык нечкәлекләре дә Бармаксызга билгеле, котылу юлын табар иде.

Парсегянның кайдалыгын белгән көнне, милициядәге хәбәрчеләре аңа Фергана—Коканд юлында прокурор Камаловка һөҗүм итүләре һәм атыш вакытында өч һөҗүмченең дә һәлак булуын җиткерделәр.

Димәк, "Москвич" бу юлы да аларны җинде.

Миршаб вакытында Шубаринның Ташкентта булмавына да сыкранып алды, ул бер ай элек генә банк эшләренә өйрәнү өчен Көнбатыш Германиягә

курсларга киткән иде. Алар Японның коммерция банкы ачасы килеп, хыялланып йөрүен беләләр. Әгәр Шубарин өйдә булса, нинди дә булса эшлекле тәкъдим әйтер иде әле. Дөрес, алар Шубаринны сәясәткә, бигрәк тә, җинаятькә бәйле эшләргә кертмәскә, бутамаска килешеп куйганнар иде. Ни генә булса да ул иректе һәм чиста куллы булып калырга тиеш иде. Чөнки беләләр, нинди бәла килсә дә, Японга аркалана алалар, ул гаиләләрен дә, үзләрен дә ярдәмсез калдырмаячак. Сәлим Хәсәнович әле алгарак та карап фикер йөртте: әгәр без базар икътисадына керәбез икән, ә эшләр шуңа бара кебек, капиталыңны Шубаринга биреп кенә киләчәк тормышың өчен курыкмаска мөмкин, иң мөһиме, үзең өчен генә түгел, балаларың, оныкларың киләчәктә тәэмин ителгән булыр, чөнки Артур Александрович акчаны кайда саласы, нинди предприятие сатып аласы турында һәркемнән дә яхшырак белә. Юк, Шубаринны үтерүләр белән бутамаска кирәк, Сенатор да мондый юлны хупламас, тирәнрәк һәм алгарак-ераграк карарга кирәк.

Фергана үзәнендәге җәнҗаллы башбаштаклыклар төгәлләнеп, вәзгыять тиешле күзәтү астына алынганнан соң, прокурорның кайтып җитүен дә көтмәстән Миршаб Камаловны Ташкентта каршыларга әзерләнә башлады.

Беренче эше итеп, Хашимов прокурорга һөҗүм оештырылуы турындагы хәбәрләрне газетларга һәм телевидениегә җиткерү турында күрсәтмә бирде, шулай булганда, ул инде үзе оештырырга алыначак икенче һөҗүм һәм аның нәтиҗәләре дә, һичшиксез, матбугатта күренәчәк. Шулай итеп, ул Парсегянга да, Сенаторга да барып җитәчәк.

Камаловны юкка чыгарудан башка юл калмаганлыгын Миршаб аңлый иде инде. Сенаторның приказын үтәмәсә, ул аны да үзе белән батырачак. "Москвич"ны исә бары үлем генә туктата ала. Шулай да, ул Ариф һәм аның иптәшләренең ничек һәлак булуларын төгәллекләре белән белми иде әле, ләкин аларны "Москвич"ның ниндидер тозакка алдап кертүен чамалый иде. Зур тәҗрибәле, милициядәге убырларга ау ачкан Камалов, табигый ки, прокуратура тәрәзәсеннән кергән пуляның нәкъ менә аңа төбәлгән булуын аңлаган, һәм үзен юри ачыктан-ачык ут астына куйган, шуның белән салкын канлы, зур стажлы террорист Арифның уяулыгын йоклаткан.

Прокурорга һөҗүм әзерләгәндә Миршаб иң элек тикшерүчеләрне ялган юлга кертергә исәп тотты. Фергана вакыйгалары аңа шундый юл сайларга үзләре үк күрсәтеп тора иде.

Фергана үзәнендәге башбаштаклыклар вакытында месхет төрекләре коралланган, чыгырдан чыккан үтерүчеләр һәм ут төртүчеләр өерен нишләп корал көче белән бастырмадылар икән дип баш ваттылар, ул гынамы, хәтта корал складларын штурмлаганда күз йомдылар. Өметләре киселгән төрек ир-егетләре аптырагач, кышлаклардагы мәктәпләрдә, клуб вә кинотеатрларда җыелып ач ятучы бала-чага, карт-коры һәм хатын-кызларны яклау өчен үзләренә корал бирүне үтенделәр, ләкин кире җавап алдылар. Үтерүчеләр һәм талаучыларга ут ачаргамы, атаргамы-юкмы дигәндә, мәсьәләне уңай хәл итүчеләрнең берсе, алар фикеренчә, республика прокуроры Камалов булды. Төн Патшасы Миршаб менә шушы картаны уйнатырга булды да инде.

Камаловка һөҗүм ясалачак төнне Ташкентта "месхет төрекләре милләттәшләренең фаҗигасе өчен прокурорга үлем карары чыгарды" дип язылган листовкалар тарату күздә тотылды. Ул үтереләсе урында шундый ук эчтәлектәге кәгазьләр, ә бәлки, хәтта плакат кую да каралды. Хашимов үзәк газетларның хәбәрчеләр пунктларына һәм республика газетларына телефоннан шылтыратулар оештырсаң да начар булмас, иде дип уйлап куйды. Мәсәлән, "Камаловның үлемендә җаваплылыкны яңа төзелгән "Үч" оешмасы үз өстенә ала" диебрәк. Кыска, усал, мәрхәмәтсез исем". Шулай итеп, республика прокурорының үлемен җәберләнгән, туганнарын һәм якыннарын югалткан, ялан кырда япа-ялгыз калган төрекләргә сылтарга мөмкинлек туачак. Ферганадагы канлы вакыйгаларның кызуы сүрелмәс борын прокурорның язмышын хәл итү белән соңарырга ярамый иде.

Камалов янып-пешеп Коканд белән Фергана арасында арлы-бирле чабып

йөргән арада Миршаб кешеләре кайчандыр Акмал хан Сенаторга биргән япон аппаратурасын файдаланып, прокурорның хатыны белән сөйләшүен тоттылар: ул шимбә көнне төшкә кадәр кайтып төшәргә җыена икән. Ләкин тагын бер мөһим яналык та мәгълүм булды, шимбә көнне Камаловка әтисе ягыннан туган тиешле кыз бала кияүгә чыга. Үзбәкләр туй мәсьәләсендә аеруча четерекле. Камалов хәтта өч көн-өч төн йокламаса да, теләсә нинди хәлдә дә туйда күренергә тиеш, бер генә сәгатькә булса да. Ә шәрекъта туйлар таңга кадәр дәвам итә. Менә шушы очрактан файдаланырга уйладылар да.

Туйның кайда үтәчәгеп ачыкладылар, Миршаб машинада Камаловлар йортыннан килен мәхәлләсенә кадәр булган араны үзе йөреп, тикшереп чыкты Камаловның абзасы җир тетрәүдән соң төзелгән яңа районда, "Шифалы су" дип аталган җирләрдән ерак түгел генә яши икән. Аннан ары юл Казакъстанга, атаклы Сары-Агач курортына таба китә. Монысы да искә алынды. Бакыр шәһәрчегеннән ерак түгел тирән чокыр төбеннән үтүче юл кебек һөҗүм итәр өчен унайлы җирне махсус эзләсән дә таба алмас идең. Инде һөҗүмне оештыру ысулын гына табасы калды. Бәлки узып баручы машинага автоматтан ут ачаргадыр? Ләкин ышанычлы юл түгел, пуля сукыр бит ул, кая барып эләгәсен кем белә. Эх, Ариф булса! Аннан инде ычкына алмас иде. Ялгышу мөмкинлеге булмаган ышанычлы вариант кирәк иде. Һәм шунда Хашимов полковник Халтаевны искә төшерде, ул югары түрәләр өчен кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре әвәләп ятучы Абрам Ильич дигән берәүне шау-шусыз гына, ипле генә итеп теге дөньяга озаткан иде. Халтаев сайлаган юл акылга сыймас дәрәҗәдә гади иде. Ул күрше өлкәдән чуерташ төялгән самосвал урлата да фәннәр докторы йөри торган маршрутны өйрәнеп, өстенә йөкле машина җибәртә, машинаны шунда ташлап та калдыралар. Шулай итеп, чираттагы юл һәлакәте хасил була. Кемне гаеплисең...

Югары судта эшләгән чакта Миршаб полковник Халтаев белән шундыйрак байтак нәрсәләр майтарган иде инде. Бер генә тапкыр эшләре уңмый калды. Анысында ялган документлар белән "идән асты миллионеры" Раимбаев дигән берәүне төрмәдән йолып алмакчы булганнар иде. Ахыр исәптә, Төн Патшасы ярдәмгә әнә шул "юеш эшләр остасы", район милиция бүлеге начальнигы Халтаевны да чакыра алган булыр иде. Ләкин аның Камаловны үзе юк итәсе килде, алда республика прокуроры кәнәфиенә утыру мөмкинлеге җемелдәп торганда, моны башкаларга тапшырып булмый. Ә "Москвич" бик күп мөхтәрәм кешеләрнең тамагына сөяк булып кадалган иде инде.

Әгәр төн уртасында берәр сәбәп табып, Камаловны туйдан чакырып алып булса, аның машинасы чокыр турына җитүгә, таудан каршына авыр йөк төялгән самосвал җибәрерләр иде, тар юлда ул "Жигули"ны изеп, сытып ташлаячак. Йөз-йөз егерме чакрым тизлектә килгән машинада кем дә исән калыр дип беркем дә гарантия бирә алмый. Соныннан чыгып карарга була, әгәр Камалов нинди дер могҗиза белән исән калган икән, анысы—пистолет эше.

Миршаб тирән чокыр янында шундый уйларга чумды. Операция күз алдыннан бөтен ваклыклары белән узды шикелле һәм ул нәкъ шушы вариантка тукталырга булды да.

Шимбәгә каршы, Сары-Агач тирәсеннән, казакъ номерлары куелган, бетон плитәләр төялгән самосвал урладылар. Ташкент янындагы курорттан ерак түгел месхет төрекләренең яшәве билгеле. Шулай булгач, Миршаб версиясе беркемдә дә шик уятмас. Шимбәгә хәтле Камаловның, һичшиксез, туйда булачагы, хәтта яшьләргә нинди бүләк бирәчәге дә мәгълүм иде инде. Акмал ханның телефон сөйләшүләрен тыңлый торган япон аппараты бу юлы да ярдәм итте. Туй көнендә дә телефонны берничә мәртәбә тыңладылар, шик тудырмас өчен, аппаратны даими рәвештә өзгәләп тордылар, монысы элемтә чыгымлый икән дигән фикер калдыру өчен махсус эшләнде. Бу мәсьәләгә карата да Миршабның үз планнары бар иде.

Төн уртасы җитәрәк туйдагы шау-шу, музыка, шатлык авазлары мәхәлләгә генә сыешмыйча, якындагы казакъ далаларына кадәр барып житкән бер мизгелдә, Миршаб һәм анын кулдашлары ике машинага төялеп операциягә чыктылар.

Урланган самосвал тулы әзерлектә юлдан аз гына читтәрәк караңгылыкка посты, менә шуннан ул "Жигули" өстенә ташланырга тиеш тә иде. Операциядә катнашучы машиналар чокырның ике ягына урнашты, алар безнекеннән кала дөньядагы бар полицияләрдә кулланыла торган "уоки-токи" сөйләшү аппаратлары белән җиһазланган, Хашимов машинасында хәтта телефон элемтәсе дә бар иде.

Килеп җитүгә бар нәрсәне тикшереп чыктылар, самосвалны сынап карадылар, тагын бер тапкыр трассадан үттеләр һәм разый калдылар, барысы да дөрес исәпләнгән кебек иде. Инде прокурорны туйдан чакырып чыгарырга гына калды. Шылтыратыр алдыннан туй барган йортка күзәтче җибәрделәр, үзбәк туйларында ишек теләсә кемгә ачык, кер, рәхим ит, сыйлан. Чакырылмаган кунак һичкемнең күзенә ташланырга тиеш түгел иде.

Берәр сәгатьтән соң Миршаб янында яткан сөйләшү аппаратында туйда пылаудан авыз итеп, бер касә хәмер кәгеп өлгергән "күзәтче"нең тавышы ишетелде:

—"Москвич" телефоннан еракта, ниндидер җитди кыяфәтле кешеләр белән гәп кора, аңа комачауларга базмаслар, миңа калса, шылтыратырга мөмкин...—Һәм Сәлим "уоки-токи"ны өзәргә җыенганда гына "күзәтче" җәһәт кенә өстәп куйды:

—Кунаклар арасында полковник Чураев, угрозыск ментлары гомумән дә күп монда.

—Нишләп?—дип каты итеп сорады ниндидер куркыныч сизеп алган Сәлим, хәтта бер мизгелдә тамагы кибеп китте.

—Кияүләре угрозыскта эшли икән, старлей.

—Ә...—дип куйды Хашимов берни дә аңлатмаган тавыш белән һәм шунда ук тынычланып, элемтәне өзде.

Ләкин хәзер үк шылтырату уеннан кире кайтты, тагы бер мәртәбә трассаны тикшереп чыкты, туй барган мәхәлләгә җитте, туйдан чыккан "күзәтче" белән очрашты, барысы хакында да бөртекләп сорашты, полковник Чураевның тозаклар куймаганына ышангач кына, билгеләнгән урынга кайтып туй барган йортның телефон номерын җыйды. Трубканы алучы булмады, күрәсең, кунаклар тавышыннан шылтырауны ишетмиләр иде бугай. Ул номерны яңадан җыйды, бераздан йомшак кына хатын-кыз тавышы ишетелде. Хашимов үзен прокуратура дежурные дип таныштты:

—Гафу итегез, берни эшли алмыйбыз, без хезмәт кешеләре... Хөршид Азизович, кирәге чыкса шылтыратырсыз, дип, туйга киткәндә сезнең номерны калдырган иде.

—Сезгә Камаловны чакырыргамы?—дип кабатлап сорады гаҗәп йомшак тавышлы ханым.

—Әгәр ул еракта булмаса һәм вакыты бар икән... Ерактарак булса, мин әйткәннәрне тапшырырсыз...

—Әйе, ул ерактарак шул, бакчада.Сүзегезне әйтегез, мин җиткерермен.

—Мәскәүдән Генераль прокурор шылтыраткан, иртәгә аны, якшәмбе булуга карамастан, Ферганадагы хәлләрне аңлатып бирер өчен Кремльгә чакырганнар, диегез. Анынчы ул Камалов белән сөйләшеп алырга тели икән. Бер сәгать-сәгать ярымнан аңа Мәскәүдән шылтыратачаклар. Өенә кайтырга куштылар, диегез.—Миршаб рәхмәт әйтеп трубканы куйды һәм бераздан йорттагы телефонны өзәргә кушты.

Мәскәүдән шылтырату ышандырырлык иде һәм ул Камаловны шикләндермәскә тиеш иде, төн уртасында йокы түшәгеннән беренче тапкыр гына күтәрүләре түгел.

Килен йортыннан прокурорны чакырып чыгару операциянең башлануы дигән сүз иде инде һәм Миршаб караңгылыкка поскан самосвал янына ашыкты.

Карен перчаткалы куллары белән машинаның баранкасын кыскан, ул "Жигули"ны изеп ташлагач машина эченә гомердә булмаган "Үч" оешмасының хөкем карарын ыргытасы һәм киреәксә, прокурорны кургашын белән сыйлап, теге дөньяга озатасы аркадашы исә тыныч кына тәмәке тартып утыра иде. Ачык ишек янына килеп Миршаб Каренга фәрман бирде:

—Трассага чыгуга, иптәшең автоматын кулдан төшермәсен. Туйда полковник Чураев утыра, ул иблистән барысын да көтәргә була, мин аны күптән беләм инде.

—"Уоки-токи"дан сезнең сөйләшүне ишеттек без, шеф, аннан башка да ментлар житәрлек икән анда, ләкин чигенергә соң, сез инде тәгәрмәчне әйләндереп җибәрдегез бугай,—диде ярыйсы гына тыныч хәлдә Карен һәм шул ук вакытта сорнай-көрнәйләр авазы янгыраган мәхәллә өстендә сыек кына булып яшел ракета уты кабынды, аңа күпләр күз дә салмады, туйда ниләр булмас, ә бу прокурор кайтырга чыкты дигән билгене аңлата иде.

Самосвал кабинасындагылар сискәнеп куйды кебек, ләкин үзләрен бик тиз кулга алдылар, Миршаб, читкәрәк китеп, ым какты—алга!

Самосвал акрын гына юлга чыга башлады. Ул чокырга ыргылачак жиргә килеп туктауга ук, икенче яктан өч тапкыр фонарь уты күз кысты—үлем машинасына старт бирелде.

Яхшы әзерләнгән спектакльдәге кебек, ике машина бер үк вакытта тирән чокырга чумдылар һәм аларны караңгылык чолгап кына алды, бары Камалов "Жигули"ның якынга яктыртучы фараларыннан төшкән пыскак ут кына прокурорның үлем юлын күрсәтә иде, Карен машинасы исә, сөйләшенгәнчә, утсыз бара бирде.

Бәрелешерргә бер минуттан да ким калып килгәндә, операциядә катнашучылар, хәтта Камалов үзе дә, жанны телгәли торган сирена тавышы ишеттеләр, иң соңгы тизлектә милиция машинасы килә иде.

Чураев туйга юктан гына килмәде, ул әле генә Ферганадән кайтып төшкән прокурорның тәгаен монда булачагын белә һәм Коканд трассасында һөжүм турында аның жентекләбрәк сораштырасы килә иде. Шуның өстенә, ул кабат һөжүм булу мөмкинлеген дә истән чыгармый, шуна күрә хужалардан прокурорны ераграк утыртуларын сорады, хәер, аның янына таныш булмаган кеше якын да килә алмас иде, кияүнең угрозыскттагы иптәшләре Камалов кебек хөрмәтле кунак утырган почмакны үтә игътибар белән сакладылар.

Камаловның көтмәгәндә кинәт кенә гаиләсе белән өенә кайтып китүен әлеге егетләр шул ук минутта полковник Чураевка хәбәр иттеләр дә. Хужа ханым артык нык дулкынланган полковникка прокурорның ни сәбәпле туйдан китүен аңлатып бирде. Прокуратурадагы бар телефоннарны яттан белгән угрозыск начальнигы ашыгып телефон номерын жыярга кереште, ләкин ул эшләми иде. Бусы тагы да аптырата төште. Ул машинасы янына ташланды һәм прокуратура номерын жыйды—Мәскәүдән бернинди дә шылтырату булмаган. Чураев шунда ук машинасын кабызды, карашы белән ике егетне арт утыргычка чакырды һәм сиренаны кабызып бар куәтенә Камалов артыннан ыргылды. Бер үк вакытта радиодан ГАИ постларына республика прокуроры машинасын туктатырга дигән әмер бирде, Чураев засаданы аның йорты янында оештырачаклар дип уйлый иде.

Сирена улавын ишетүгә, Карен кулдашына карап тыныч кына әйтте:

—Ментлар. "Москвич"ны алдап капкынга кертүләрен Чураев сизенгән бугай. Колагыңны торгызып тыңла, мин хәзер фара уты белән ул "Жигули"ны сукырайтам да өстенә ташланам, нәрсә булганын тикшереп ятарга вакыт юк, юкса чокырдан чыкканда ук оперативниклар каршы алачак. Ментлар машинасын күрүгә, мин тизлекне киметә төшәрмен, ә син фараларына ут ач, шуннан соң Келеска таба атылырбыз, анда безне көтәләр. Тик берүк кабинага ата күрмә, угрозыск Чураев өчен бөтен шәһәрнең астынөскә китерәчәк, ник туганыңа үкенерсең.

Машина артында сирена улавы ишеткән Камалов кайдадыр нindidер фажига булган ахрысы дип уйлап куйды.

Шул ук вакытта ул бу сигналның үзенә дә мөнәсәбәте барлыгын сизенеп тизлекне киметте, кире борылырга җыенганда гына аны үкереп якынлашучы машинаның утлары сукырайтты, алга таба ни булачагы ачык иде инде, ләкин юл җайсыз, монда югары класслы автоузышчы да борылыр урын тапмас иде, шулай да иң соңгы мизгелдә прокурор машинаны маңгайга маңгай бәрелүдән коткарып кала алды.

"Жигули" мамык урынына өскә атылды, анна арткы борты белән нәрсәгәдер эләкте һәм мәтәлчек ата-ата юл кырыендагы бетон баганаларны кырырга тотынды.

Самосвал тизлеген киметмичә үргә таба ыргылды, исән калган уң фара яктысында ерактан килүче милиция машинасы күренеп алды.

"ЗИЛ" тизлеген киметә төшүгә коелган маңгай тәрәзәсеннән автомат чираты яңгырады. Ике тәгәрмәче дә тишелгән патруль "Жигули" шулай ук караңгылыкка, юл астына тәгәрәп төшеп китте—Келеска юл ачык иде.

Чураевның туйда калган хезмәттәшләреннән берсе сирена тавышының көтмәгәндә туктап калуын һәм автомат тырылдавын ишетеп алды, угрозыск хезмәткәрләре икенче машинада шефлары артыннан ташландылар. Ун минуттан соң алар әйләнгән милиция машинасы янында басып торалар иде инде. Бәхеткә, полковник Чураев артык зыян күрмәгән, бәрелгән, сыдырылган урыннарыннан гайре зарарланган җире юк иде. Ике оперативникның икесе дә кул-аякларын сындырган булып чыкты. Ә трассаның алдагы өлешендә аларны металл өеменә әйләнгән прокурор "Жигули"е көтә иде.

Рация белән чакыртылган "ашыгыч ярдәм" Камаловның хатыны һәм улы үлгәнлеген раслады, ә ул үзе сынып-ватылып беткән, кара канга баткан булса да, исән иде әле. Аны ашыгыч рәвештә травматология институтының реанимация бүлегенә озаттылар.

Икенче көнне Хашимовка Камаловның һаман аңына килә алмавын, хәленең бик авыр, ышанычсыз диярлек икәнен ишеттерделәр. Хәер, бу хакта бөтен шәһәр сөйли иде инде. Эчке эшләр министры да прокурор Камалов үлем хәлендә дип телевидениедән чыгыш ясады. Югары милиция чины фаҗигале бу вакыйганы юл-транспорт һәлакәте дип бәяләп, бәрдергән һәм җинаять урыныннан качып киткән машинаны эзләү бара, дип, ышандырды.

Шул көнне үк Миршаб Мәскәүгә телефон буенча шифрлы текст җибәрде: "Москвич" бүтән куркыныч түгел.

"Матрос тынлыгы" төрмәсенең үтә катгый тәртипләренә карамастан, шифр Сенаторга барып иреште һәм инде ул тикшерүчеләр белән сөйләшүне икенче төрлерәк итеп алып бара башлады.

Ике атна вакыт узды, өченчесе тәгәлләнеп килә, прокурор исә һаман реанимация бүлегендә, бер генә тапкыр да аңына килә алмады, ул, чынлыкта, яшәү белән үлем арасында иде. Күпләр, хәтта врачлар да аңа бер генә диагноз куйдылар—яшәмәс... Атна буе травматологиядәге хәлләрне белешеп яшәгән Миршаб инде алар белән кызыксынудан туктады, аның өчен Камаловның исән калса да, республикада тәэсире беткән гап-гади инвалид булып калачагы ачык иде.

Ләкин язмыштан боерык икенчерәк булды. Егерме сигезенче тәүлек үтеп барганда Камалов күзләрен ачты һәм хәлсез тавыш белән сорады:

—Хатыным, улым ничек?

Җавап урынына дежур шәфкать туташы елап җибәрде. Гаиләсез калганлыгы сүзсез дә аңлашыла иде инде.

Шул көннән башлап ул гел торырга атлыга башлады, табибларны ашыгыч башкарасы эшләрем бар дип ышандырырга тырышты. Дөресен генә әйткәндә, ул үзен травматологларның кисәкләрдән җыеп ябыштырганын белми иде, исән калган бер генә җире дә юк иде бит. Азмы-күпме карарлык җире шул башы булгандыр. Хәер, анысы да чагыштырмача әйткәндә генә. Баш миенең коточкыч нык селкенүе

аркасында шулай озак аңсыз ятты да инде ул.

Тагы ике атнадан аны реанимация бүлегеннән өченче каттагы аерым палатага күчерделәр һәм ул үз янына полковник Чураевны чакыруларын үтенде. Ул каян белсен, үлем хәлендә яткан көннәрендә Чураев аның янында инде берничә мәртәбә булган иде.

Угрозыск начальнигы инде болай да үзен прокурор Камалов алдында гаепле саный, нәкъ мәрхүм Әмирхан Даутовичны коткарырга соңга калган кебек, монда да тагын бер тапкыр соңардым дип үз-үзен битәрли иде. Ләкин полковник бу юлы прокурорны исән калдыруда үз өлеше барлыгын белми иде, әгәр ул сирена улатып прокурор артыннан ыргылмаса, Кареннын "кулдашы", һич шик юк, бәрелеш нәтиҗәсен тикшерер һәм пистолеттан атып соңгы гомер жебен өзәр иде.

Полковник палатада күренүгә Камалов бер тында әйтте дә салды:

—Һичшиксез, бу—һөҗүм. Утсыз ажгырып килгән тау кадәрле машина фараларын яндырып сукырайткач та аңладым мин моны,—диде.

—Мин бер генә секундка да шикләнмәдем,—дип җавап бирде Чураев, әмма шул ук самосвалдан үзенә ут ачулары турында әлегә дәшми калуны мәгкульрәк күрде.—Әле ул гынамы,—дип өстәде полковник:—Бу Ферганада башланган ауның дәвамы, каяндыр сезне ничек тә булса һәм бик тиз арада юк итәргә катгый боерык бирелгән. Күрәсең, вакыт кыса, ашыгу-кабаланулары да шуннан...

—Мин каян икәнен чамалыйм,—диде прокурор—Жеп Сенаторга сузыла. Мин Акмал ханны кулга алганчы ук Аксай крезы аңа үз кешеләрен, вәкаләтләрен биреп өлгергәндер, менә каян килә шундый көчле, тынгы белмәс һөҗүм...

—Бәлки. Ләкин мин дустым прокурор Азлархановянмышында да, менә хәзер сезнекендә дә бер үк кешеләр кулы уйный дип уйлыйм. Үз вакытында Парсегяннан барысын да сыгып ала алмаганыма үкенәм хәзер. Сенаторның нииндидер, дәһшәтле, димме... серен белүче бердәнбер кеше ул. Аның белән төнге башкисәр арасында нинди дуслык, нинди бәйләнеш булырга мөмкин. Башыма сыйдыра алмыйм.

—Киңәшем шул, генерал Саматовка шылтыратыгыз, Парсегянны күз карасыдай сакларга кирәк. Моны минем исемнән әйтсәгез дә ярый. Сөйләгәннәрен видеокассетага яздырып барсыннар, алар кирәк булачак әле. Мафиянең кулы озын, аңа барып җитә күрмәсеннәр. Хәзер беркемгә дә ышанып булмый. Минем сезне ни өчен чакыруымны беләсезме?—Полковник озак кына сүзсез торды һәм сизелерлек дулкынланып дәвам итте:—Сез—мин тулысынча ышанган бердәнбер кеше, җинаятьчелек белән үлгәнче, җингәнче сугышырга карар биргәнегезне беләм. Кызганыч, ныклап булыша алмадым, үзем дә өлгермәдем...

—Алай димәгез әле,—дип бүлдерде Чураев.—Угрозыскта республикага кем килгәнен, аның бернигә карамый тәртип урнаштырачагын тиз күреп алдылар.

Ләкин прокурор, полковникның сүзләрен колак аша уздырып, дәвам итте:

—Монда күпме ятачагымны белмим, ярты ел булырмынмы, әллә бер елга сузылырмы, һәм моннан нинди булып чыгам бит әле. Алга таба нәрсә белән шөгыльләнермен. Элеккеге урыныма кайта алмамдыр инде. Иң аянычы, һәркайда артка чигенү бара. Бик күпләр тикшерү группаларының эшен "түгәрәкләргә" вакыт дип саный, җирле прокуратураны да авызлыкламакчылар. Мин моны Фергана вакыйгалары барышында бигрәк та ачык төшендем. Мәскәүнең үзендә дә шундый ук хәлләр. Ләкин сүзем бу хакта түгел. Мин сездән, намусыгыз кушканча, вәгъдә сүзе көтәм: моннан нинди булып чыксам да, сезнең угрозыскта миңа эш табарсыз бит, сайланып тормыйм, нинди эш тә ярый. Бары тик сезнең белән генә эшне ахырына кадәр җиткерә алачагымны сизәм.

Дустыгыз Азлархановөчен дә, үзем өчен дә, гаиләм өчен дә һәм, ниһаять, аяк астына салып тапталган Закон өчен дә сезнең белән бергә үч алачакбыз әле...

—Ни генә булмасын, мин сезгә мондый вәгъдәне бирәм,—диде полковник дулкынланып.—Минем үземнең дә алардан күп нәрсә өчен түләтәсем бар.

Август аенда газетларда оешкан җинаятьчелек белән көрәшү өчен "Гадәттән тыш комиссия" төзү турында хөкүмәт карары басылып чыкты һәм Камаловта яңадан өмет уты кабынып китте.

Ике елга тулы вәкаләтләр бирелгән андый комиссия республикада да төзелде, составына генерал Саматов та кертелгән иде. Дүрт айлап вакыт узды, инде яңа ел якынлашты, әмма бернинди җитди үзгәреш сизелмәде. Камалов кебек үк бу карарга зур өметләр баглаган Чураев ачынып әйтергә мәҗбүр булды: бу карар беркемне бернигә мәҗбүр итми, ул кирәкле законнар белән ныгытылмаган, ни матди, ни техник яктан тәэмин ителмәгән, тиешле кадрлар бирелмәгән. Карар хөкүмәтнең чираттагы бушкуык очыртуы гына булып чыкты. Җинаятьчел дөнья хакимиятнең чын мәгънәсендә кысыр икәнен аңлады, чөнки аның түземен барлык төбәкләрдә, җинаятьнең барлык төрләрендә сынап карады. Квартира басу, урлашу, кораллы һөҗүм, машина урлау, иң югары кимәлдәге мошенниклык дисеңме, берсе дә калмады. Һәм илдә җинаятьчелек тагын да котырыныбрак колач җәя башлады. Караклар дөньясы илдәге хәлне хакимияткә караганда дөресрәк бәяли белде, хөкүмәт исә яңа комиссияләр төзүдән һәм аларга дәһшәтле яңгыраучы исемнәр уйлап табудан уза алмады.

Октябрь аенда прокурорның сул кулыннан гипсны алдылар һәм ул, беренче эше иттереп, мафия белән көрәш бүлеге начальнигыннан Сенаторның тормышы һәм элемтәләре турында җыя алган хәтле барлык документларны алып килергә кушты.

Инде җентекләп әзерләнгән материаллар шактый гына иде, аларга фотографияләр дә өстәгәннәр. Камалов бу документларны белә иде инде, ләкин үзенә ясалган һөҗүмнән соң, бүген ул аларга башкачарак күз белән карый башлады. Һәр көнне уколлар, процедуралардан соң кәгазьләр актару гадәтенә әйләнде, иң беренче чиратта нәрсәдән тотынырга дип баш ватты. Озакламый хастаханәдән чыгарачакларын ул белә иде инде. Тора-бара Камалов гомуми исемлектән ике кешене аерып алырга булды. Бу затлар хакындагы папкалар аерым өстәлгә ятты. Беренчесенең тышына "Шубарин Артур Александрович. (Кушаматы—Япон) дип язылган иде.

Папкада фоторәсемнәр шактый күп иде. Аларның һәркайсы диярлек Шубаринны хәтта көнләшерлек югары дәрәҗәләргә, кәнәфиләргә ия кешеләр арасында сурәтли. Аның белән янәшә шәһәр һәм өлкә комитеты секретарьләре, министрлар, депутатлар, югары вазифа башкаручы кешеләр. Төсле рәсемнәрнең берсендә ул гаҗәеп матур затлы ау мылтыгының бизәкләренә сокланып торучы Акмал ханга карап елмаеп тора. Ике рәсемдә Шубаринны Шәрәф Рәшидович белән янәшә күрергә мөмкин. Шунысы кызык, һәр ике рәсемдә алар янында Әнвәр Абилович Тилләхуҗаев та бар иде. Ә аның белән Японны якын әшнәләр дип сөйлиләр.

Көннәр үткән саен аның башына үзен юк итү бурычын Сенатор белән Акмал хан эшлекле Японга йөкләгәннәрдер сыман тоела башлады, бу уе ныгыганнан-ныгый барды. Икенче яктан караганда, алар Шубаринга карата шантаж ысуллары да кулланырга мөмкиннәр иде, менә шул чагында прокурорның тормышы Японның чәчәк атуы бәясенә бәрабәр булачак та. Рәсми рәвештә миллионнары бар дип танылган, дәүләт аппаратында бихисап дуслары булган бу кешегә игътибарны көчәйтергә кирәк булачак әле. Прокурорның ясаган нәтиҗәсе шундый булды.

Икенче папкага, шул ук кызыл фломастер белән “Хашимов Сәлим Хәсән улы. Кушаматы—Миршаб-Төн патшасы” дип язылган иде.

Бусында инде күренекле, теләсә кайда сүзе үтә торган югары даирә кешеләре белән бергә төшкән фоторәсемнәр бөтенләй юк, гүя Миршаб кирәкмәгән рекламадан качып йөри. Анда бары тик бер рәсем бар иде. Анысында Югары суд кешесе бик дәрәҗәле саналучы “Лидо” рестораны хуҗасы, элеккеге атаклы фольклор ансамбле биючесе чибәр Нәргиз белән бергә төшерелгән. Хашимов турында мәгълүматлар аз, Сухроб Әхмәдович янында гел күләгәдә йөрсә дә, анын, юрист буларак, югары һөнәрмәндлеге, профессиональлеге, данга омтылышы, мин-минлеге әйтеп үтелгән иде. Аларны яхшы белгән кешеләр раславынча, район прокуратурасында бергә эшләгән чагында, еш кына иң мөһим карарны нәкъ менә Миршаб кабул иткән һәм тормышка ашырган булган икән. Анын ике мәгънәле кушаматка ия булуы да шуннандыр. Тагын анын усаллыгы, хәйләкәрлеге, мәкерле вә шома булуы хакында да мәгълүматлар өстәлгән. Үзенең сөяркәсенә дәрәҗәле мәхәлләдә йорт алып бирүе, ул гына да түгел, әкияттәгечә табыш китерүче “Лидо” ресторанын ачарга ярдәм итүе дә игътибардан читтә калмаган иде. Югары мәхкәмәгә Хашимов килгәннән бирле дәүләт байлыгын зур күләмнәрдә талаучылар еш кына “җәзанын иң югары чарасын” аласы урынга, төрмә белән котыла килгән. Мондый котылуларнын бәясе миллионнар белән исәпләнгәненә шикләнмәскә мөмкин. Димәк, Сенатор әнә шундый акыллы, мәкерле һәм шома кеше белән бер мичәүдә булып чыга, а андыйларны коры кул белән генә ала алмассын!

Полковник Чураевнын икенче килүендә прокурор аңа Шубарин белән Хашимовка кагылышлы папкаларны сузды һәм кыска гына аңлатма бирде:

—Ялгышмасам, менә шушы кешеләр мине ашыгыч рәвештә юк итәргә күрсәтмә биргән булырга тиеш.

Чураев папкаларга күз кырые белән генә карап алды һәм:

—Мин аларны күптән күзәтеп киләм инде,—диде. Бераз гына тын торгач, сүзен дәвам итте:—Бер үк вакытта сезне сөендерергә дә, көендерергә дә туры килә. Япон, әле Фергана вакыйгалары башланырга бер ай кала ук, банк эшләре буенча еллык курсларга, Көнбатыш Германиягә китеп барган. Ул Ташкентта коммерция банкы ачарга җыена. Сезнең кебек кешеләрне юк итү анын мәнфәгатьләре даирәсенә кермидер, дип уйлыйм, чөнки ул да, нәкъ сезнең кебек үк, хокукый дәүләт турында хыяллана.

Сенатор һәм Акмал ханнын кемнәргә йөз тотуын, җеп очынын кемнәргә сузылуын аңлау Камаловка яна көч бирде. Гаиләсенең һәлакәтен белгәннән соң, прокурор бик озак ниндидер битараф, ваемсыз-мәнсез халәттә яшәде, аңа хәзер барысы да бер сыман, сәламәтлеген ныгыту теләге дә әлләни борчымый иде, ләкин алда анык максат пәйда булгач, ул үтә бер үҗәтлек белән тормышка ябышты, көч тупларга, үзен ныгытырга тотынды. Ничек тә булса органнарда эштә калу котылгысыз теләгенә әйләнде.

Палатада телевизор бар иде. Ул СССР Югары Советынын өченче сессиясендә ясалган чыгышларны ешрак тыңлый башлады һәм депутатларнын сәяси сукырлыгына, күрә караулыгына хәйран калды. Теләсә кайсы социаль мәсьәләне, теләсә нинди башка проблеманы җинаятьчелекнең умыртка сөяген сындырмый торып хәл итеп булмаячак. Депутатлар менә шуны аңламый сөйлиләр, бәлки аңламамышка салышалар иде. Чөнки иртәме-соңмы финанснын алар кулында калачагы көн кебек ачык иде. Кооперация тудырган һәм зур акчалар тәмен татыган, хакимиятнең көчсезлеген аңлаган рэкет дигән афәтне инде туктатырмын димә, “шәфкатьле” законнар гамәлдә булганда бигрәк тә.

Декабрьдә Үзбәкстаннын яңа парламенты сессиясе эшли башлагач,

прокурор үзен тыеп кала алмады, хат язып президиумга җибәрде.

"Республика суверенитеты турындагы мәсьәләне һәр яктан хуплыйм, чөнки газиз туфрагыбызда коточкыч күләмдә үскән һәм инде бәйдән ычкынган җинаятьчелекнең тамырын корыту мөмкинлеген мөстәкыйльлек юлында гына күрәм. Башка илләрнең һәм хәтта күрше республикаларның закон чыгару гамәлиятенә әйләнеп карап тормастан, безгә ватандашларыбызга имин тормыш, мал-мөлкәтен, ә хәзер инде шәхси милкен дә саклауны тәэмин итәрлек үз законнарыбызны чыгарырга кирәк.

Бүгенге вәзгыятьтә Үзбәкстан бөтен ил җинаятьчеләре өчен кызыктыргыч җим булып тора, ул бомжлар, әрәмтамаклар, фахишәләр, аферистлар оясына әйләнде. Бездә үзебезнең җылы кочагыбызда үскән җинаятьчеләр, фахишәләр, сорыкортлар, наркоманнар да җитәрлек, ләкин авыр җинаятьләрнең дүрттән өч өлеше чит төбәкләрдән килгән "мөсафир"лар тарафыннан кылына. Җинаятьчел дөнья хокук саклау органнарын юлдан яздыру юлларын уйлап тапты һәм шуны уңышлы рәвештә гамәлдә кулланып килә: мондагылар җинаятьне әзерли, ә кесәләрендә кире кайтып китәргә әзер билетларына кадәр булган "мөсафир"лар, козгыннар шикелле, аны үтәп очып китеп тә баралар. Җинаятьчеләрнең шундый сыгылмалы һәм үтә хәрәкәтчән гамәлләренә каршы шундый ук хасиятләргә ия законнар кирәк. Теләсә кайсы җинаятьчел күренешкә күз ачып йомганчы җавап бирү генә бу вәзгыятьтән чыгара алачак.

Республиканы бугазыннан алган өч төрле куркыныч җинаять бар һәм алар өчесе дә шәхескә каршы юнәлтелгән: квартир басу, корал кулланып талау, машина урлау. Җинаятьчелекнең үсүендә хокук саклау органнарының йомшак эшләве генә түгел, беренче чиратта Закон чыгару эшенең начар куелуы гаепле. Үзегез уйлап карагыз: автомобиль теләсә кайсы гаилә өчен иң кыйммәтле әйбер, аны сатып алу өчен акчаны дистә еллар буе җыялар. Һәм менә шул машинаны урлаган өчен йөз сум штраф салалар яисә шартлы рәвештә бер елга хөкем итәләр. Закон кысаларында яшәүче ватандашларыбыздан көлү түгелмени бу? Машина урлауның гадәти хәлгә әйләнүенә төп сәбәп тә шунда, минемчә.

Җинаятьчелек дулкынын туктату, ватандашларыбызны саклау өчен сезнең карауга берничә тәкъдим кертәм:

1. Үзбәкстан ватандашы булмаган һәм аның биләмәләрендә җинаять кылган теләсә кайсы җинаятьче гамәлдәге законнарда каралганнан тыш өстәмә рәвештә тагын биш елга төрмәгә ябылуга хөкем ителсен. Бу закон "мөсафир"ларның юлын кисәчәк һәм республика халкын җинаятьчеләр басымыннан саклап калачак.

Шушындый ук, әмма тагын да катырак чаралар куллануны күздә тоткан тагын бер закон кирәк. Монысын артык сузу, гомумән, һәлакәткә тиң. Эш шунда, бөтен илдә мафиянең иң куркыныч төре—наркомафия үсеп килә һәм республика тагын бөтен ил һәм чит ил җинаятьчеләре өчен кызыктыргыч җимгә әйләнәчәк, СССРның наркотиклар базарына Шәрекъттән дә, Мәгъриптән дә ыргылучылар инде хәзер үк җитәрлек. Безгә, Ирандагы кебек, наркотик җитештерүчеләрне урынында юк итәргә кирәк. Болар бөтенесе дә халык файдасына, аның имин яшәве хакына булачак. Ә ике тапкыр авыр җинаять кылып та өченчесенә барган килмешәкләргә карата соңгы чара куллану зарур. Референдум үткәреп җинаятьченең ничә тапкыр хөкем ителү чиген билгеләргә кирәк. Бусы бигрәк тә авыр җинаятьләргә кагыла.

2. Квартира басучылар зарар күрүчеләргә китерелгән зыянны каплап бетермичә, ирекккә чыгарылмый, шуның белән бергә, дефицит әйберләр урланса, аларның чынлыктагы базар бәясе исәпләнергә тиеш. Мондый закон әлеге "һөнәр"не файдасызга әйләндерер иде.

3. Машина урлауга килгәндә, аны шәхси милекне урлау белән тәңгәлләштерергә, урлаучыларны ирекка машинаны хуҗасына кире кайтаргач кына чыгарырга кирәк. Шуның белән бергә, транспортны страховкалауны базар бәяләре буенча алып баруны рөхсәт итәргә, чөнки дәүләт мәнфәгатьләренә сукканда гына милиция чын-чынлап нәтиҗәле эшли башлаячак, шул чакта гына аның техникасы, машина урлауга каршы куллану чаралары һәм белгечләре булачак та. Җинаятьчел дөнья үзенең сафларын яшьләр хисабына тулыландырмасын өчен, закон нигезендә, аларның юлын кисәргә кирәк, чөнки байтак затлар өчен җинаятьчелек инде профессиональ һөнәргә әйләнде. Ике тапкыр куркыныч җинаять кылып хөкем ителгән җинаятьчене өченчесендә—атарга тәкъдим итәм, блатной тормыш романтикасы суына төшәр. Мәхкәмә ялгышларын булдырмас өчен андый җинаятьчеләр язмышын присяжныйлар суды ике төрле составта һәм ике тапкыр карарга тиеш дип беләм. Тагын, караласы законнар исемлегенә амнистияләр турындагы положениене дә кертергә кирәк. 1953 елгы афәтле мәгълүм Берия амнистиясеннән башлап, соңгы, 1987 елгы Горбачев амнистиясенә кадәр булган ярлыкауларны алып, анализлап карасаң, алар ил гражданнарына бәладән башка берни дә китермәделәр. Бүгенге җинаятьчеләрне ярлыкауда В. И. Ленинның туына йөз ел тулу яисә Совет властеның җитмеш еллыгының ни катнашы бар? Үзбәкстанда амнистияләр мәңгегә бетерелергә тиеш, чөнки алар "һәр җинаять тиешле җәзасын ала" дигән канунга туры килмиләр һәм, нигездә, хакимият югарылыгына ыргылып менгән дансөярләрнең мин-минлеге аркасында гына эшләнәләр.

Республиканың барлык законнары канун кысаларында яшәгән намуслы, вөҗданлы ватандашлар файдасына эшләргә тиеш".

Республика прокуроры хатын кичке утырышларның берсендә укыдылар һәм депутатлар аны көчле алкышларга күмделәр. Әлеге хаты белән Камалов җинаятьчелеккә каршы көрәшне дәвам итәргә әзер булуын һәм аны ахырына кадәр дәвам итәчәген күрсәтте. Аның яңа парламентка мөрәҗәгатеннән соң, озакламый яңа прокурор билгеләнәчәк икән дигән имеш-мимешләр тынып калды. Ә прокурор хастаханәдә ярты ел ята иде инде.

Камаловка Сенаторның докторлык диссертациясен дә алып килделәр. Гаҗәеп дәрәҗәдә дәлилләнгән, ифрат тирән фикерле, нәкъ вакытында язылган хезмәт иде ул. Анда казынган саен, Сухроб Әхмәдовичның бу фәнни хезмәткә бернинди катнашы юклыгын аңлый барды. Шундый мөһим фәнни хезмәтнең чын авторын ничек тә ачыкларга кирәк иде. Ул исән булса күпме файда китерә алыр иде. Республиканың мөстәкыйльлеге туып кына килгән көннәрдә андый кеше сулар һава кебек кирәк, ул алыштыргысыз белгеч булыр иде. Чөнки закон чыгару гамәлиятен янабаштан карап чыгасы бар, ә ул республикада яшәүче бар халыклар мәнфәгатен, гасырлар буена урнашкан гадәт-йолаларын, үзенчәлекләрен, яшәү рәвешен һәм әхлак кагыйдәләрен күздә тотарга, алар файдасына эшләргә тиеш.

Сенаторның авторлыгын билгеләү гаделлек хакына гына да түгел, ә бәлки аның демократик ирек һәм закон чыгару гамәлиятендә реформалар өчен армый-талмый көрәшүче даһи юрист дигән данын юкка чыгару, ачыктан-ачык җинаятьләргә баручы сәяси авантюристның чын йөзен ачу өчен дә кирәк иде. Ачык хөкем утырышларында ялган юридик фәннәр докторының асылын күрсәтү, башка авантюристлар өчен гыйбрәт булачак, хакимияткә ыргылучы җулик "юлбашчылар"ның чынлыкта кем икәнлекләрен ачып салачак иде.

Көтмәгәндә генә республика прокуроры әле исемнәрен дә ачыклап бетерә алмаган дошманнарына таба яңа сукмак тапты һәм, ни гаҗәп, мона аның шул һәлакәткә тиң фәлакәте сәбәп булды да.

Аның хәлен белешергә танышлары да, таныш булмаганнар да килеп йөри, кайчагында тулы бер хезмәт коллективы җибәргән вәкилләр дә килә иде, монысы исә прокурорның күнелен аеруча күтәреп җибәрә, чөнки ул еш кына үзен берни дә кыра алмадым, өлгермәдем, дип битәрли, рухи газап кичергән мизгелләре аз түгел иде. Шундый кешеләр килеп киткәннән соң, ничек булса да, янадан сафка кайтырга дигән теләге ныгыганнан-ныгый барды.

Яңа елга да күп калмаган иде инде. Шундый көннәрнең берсендә, Сенаторга кагылышлы кәгазьләрне инде ничәнче тапкыр актарып ятканда үзен өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк итеп күрсәтергә тырышканлыгы йөзенә чыккан япь-яшь кенә бер кыз килеп керде, хәер, бу аны ямьсезләми, киресенчә, ниндидер бер аңлаешсыз мөлаемлык кына өсти иде, керде дә үзен Татьяна Георгиевна дип таныштырды. Прокурор ирексездән елмаеп куярга мәҗбүр булды. Татьяна юридик факультетны тәмамлаган һәм моннан бер ел элек республика прокуратурасында диплом алды практикасы үткән икән.

Беренче караштан, беренче сүзләреннән үк үзенә ышаныч тудыра торган кешеләр була, андыйлар шактый сирәк очрый, әмма бу кыз нәкъ шундыйлардан иде булса кирәк. Кызны ниндидер яшерен сер борчый иде бугай, моны Камалов шунда ук сизенеп тә алды һәм ялгышмады.

Алып килгән чәчәкләрен вазага утырткач һәм җиләк-җимешләрен тәрәзә төбенә урнаштыргач, ул ишекне тыгызлабрак япты һәм читенсенгән сыманрак итеп башлап җибәрде:

—Берничә айлап мин сезнең яныгызга килергә кыймый йөрдем, вак җанлылыгым өчен, зинһар, гафу итә күрегез,—диде ул Камаловка туп-туры карап.—Миңа калса, мин белгән нәрсә, дөресрәге, минем чамалавым, сезгә һөҗүм итүгә бәйле булырга тиеш. Хәзер, булып узган вакыйгалардан соң, тагын да ныграк ышандым, республика прокуратурасында сатлыкҗан бар, ул сезнең бар серләрегезне, кая барырга җыенуыгызны, яшерен һәм ашыгыч киңәшмә чакыруыгызны, кемнәр белән хат алышуыгызны, кыскасы, барысын да бәйнә-бәйнә дошманнарыгызга җиткереп тора. Ялгышмасам, хәтта, эчке телефоннан сөйләшүләрегезне тыңлап бара булса кирәк.

—Нишләп алай дип уйлыйсыз әле?—дип, кызны куркытырга теләмичә, йомшак кына сорады прокурор.

—Практика узган чакта ул кеше минем арттан йөреп маташкан иде, хәтта бервакыт атаклы "Лидо" ресторанына да чакырды әле. Шунда безнең өстәл янына бер кеше килеп утырды, һәм аңлавымча, очраклы рәвештә түгел. Ул минем прокуратурада практика узып йөргәнемне белми, җилбәзәк кызлардан чираттагы берәү дип санады булса кирәк. Шуңлыктан, күзгә төтен җибәребрәк сөйләшергә тырышсалар да, колагыма берничә тапкыр сезнең исем чалынып үтте, дөрес, алар сезне "Москвич" дип кенә атадылар. Дөрес аңлаган булсам, минем "егетем" аңа прокуратурадан читкә чыгарырга ярамаган нәрсәдер бирде. Мин дә төшеп калганнардан түгел, булачак юрист бит, барыбер сизенеп калдым.

—Прокуратура эшләре белән кызыксынучы ул кешене сурәтләп бирә алмассызмы?—дип сорады Камалов. Эчке бер тоемлау аша ул әһәмияте белән Парсегяннан ким булмаган тагын бер шаһитка тап булуын абайлап алган иде инде.

Кыз алар янына килеп утырган кешене шактый ук төгәл сурәтләп тә бирде, күз алдында шунда ук Сенатор шәүләсе пәйда булды.

Камаловка тапшырылган кәгазьләр арасында аның рәсемнәре бар иде, шуларның берсен Татьянага күрсәтәсе итте.

—Әйе, бу—шул үзе!—диде кинәттән агарып киткән кыз.

Көтелмәгән уңыш прокурорны канатландырып җибәрде һәм ул Сәлим Хәсәновичның да фоторәсемен күрсәтте:

—Ул көнне ресторанда менә бу фырт егетне дә күрмәдегезме?

Миршаб белән Нәргиз елмаеп басып торган фоторәсемгә кыз күз сирпеп кенә алды.

—Әйе, күрдем. Ак костюмлы бу кеше, чыннан да, затлы-зәвекълы киенгән иде, ул бу ханым янында озак тормады, алар "Лидо"дан бергә чыгып киттеләр.

Камалов җинел сулап куйды. Практикантка очраклы рәвештә, әмма төп-төгәл итеп сатлыкҗанны исәпләп чыгарган иде. Яшерен кинәшмә барган көнне Айдынның ничек итеп каршыдагы йорт түбәсенә эләгүе дә анлашыла башлады.

Дулкынлануын яшерә алмаган кыз китәр алдыннан үтенечен дә белдерде:

—Минем бик тә сезнең белән эшлисем, сезгә файдалы буласым килә,—диде һәм эре хәрефләр белән телефон номерын язып, аңа сузды.—Инде ишек катына җиткәч, кискен генә итеп өстәп куйды:—Прокуратурада тирәгездә гел сатлыкҗаннар икән дип уйлый күрмәгез, уйлавымча, ул берәү генә, сезне бик хөрмәт итәләр, кайтуыгызны көтәләр...—Һәм бераздан соңгы утлы сүзләрен этеп чыгарды:—Мин дә сезне бик яратам...

Татьяна киткәннән соң, көтелмәгән яңалыкларга, күктән төшкәндәй килеп кергән бу кызга, аның ярдәменә хәйран калган Камалов әле бик озак караватында уйланып ятты, шуннан соң гына аксый-аксый коридорның икенче башындагы телефон янына китте. Мафия белән көрәш бүлеге начальнигына шылтыратып, үзе янына кереп чыгуын үтенде.

Полковник килеп керүгә үк Камалов ана Татьяна атаган фамилия язылган кәгазьне сузды:

—Прокуратурадагы бу шома егетнең тормышын микроскоп астына алырга кирәк булыр,—диде.—Яшерен мәгълүматлар дошманга аның аша китә дигән шик бар. Нигезле шикләр. Бүген үк полковник Чураев белән шәхсән очрашырга тырышыгыз һәм бу мәгълүматны кулдан кулга ана да тапшырыгыз. Объект икеләтә күзәтү астында булсын.

Яна елга бер атна кала Ташкентта калын кар яуды. Күбәләктәй эре кар бөртекләренең хастаханә бакчасындагы агачларны актан киендерүләре әйтеп бетергесез матур манзара тудырган иде. Аларга сокланып Камалов ярты көнләп тәрәзә янында басып торды. Актан киенгән мәңге яшел чинар агачлары кай яклары беләндер урманнарындагы чыршыларга охшый башлаганнар иде.

Көз озакка сузылганлыктан һәм җылы килгәнлектән, агачлар яфракларын коеп бетерә алмаган көйгә кышка керделәр. Ә суык ныгыганнан-ныгый барды. Калын кар катламын күтәрә алмаган яфраклар сабакларыннан өзелеп, йомшак кына җиргә коелдылар, һәр агач астында нәни генә таучыклар хасил булды. Гаҗәеп тамаша ул Ташкентта кышкы яфракларның коелуы.

Травматология бүлегендә ничәмә-ничә айлар яту дәверендә беренче тапкыр Камалов тәрәзә яныннан китә алмады, ул кешесез ишегалдына, койма аръягындагы урамнарга карап, озак уйланды, койманың теге ягында бөтенләй башка тормыш, урамнар хастаханә коймасының бу ягындагы бәлане бар дип тә белми, анда тормыш кайный, анда бәхетлеләр дөньясы. Кемнәрдер эшкә ашыга, кемнәрдер сөенеп өенә кайта. Кулларында Яна ел бүләкләре, чыршы таба алганнарның горурлык хисеннән авызлары ерылгандыр. Кичкә таба, шәһәр өстенә кинәт кенә караңгылык үрмәләгәч, утлар кабынып киттеләр, ап-ак карга төренгән бакча коймасы тышындагы тормыш шундый да ымсындыргыч, ямьле, матур, тылсымлы булып тоела башлады.

Түбәләренә җинелчә кар яткан жете кызыл трамвайлар, тәрәзәләрен балкытып, Энгельс урамы буйлап әле бер якка, әле икенче якка үтеп торалар. И Ходаның хикмәте! Кая киткән аларның рельслар кушылган

урыннарда тешләргә тия торган күңел кайтаргыч шыкылдаулары, шыгырдаулары?! Алар әйтерсең лә шома гына йөзеп баралар, йөрүләре җиңел, үзләрендә җылыдыр, җайлы-уңайлыдыр, нинди сөйкемле йөзләр балкыйдыр анда. Хастаханә тәрәзәсеннән карап торганда урамдагы һәр кеше бер-берсенә елмаядыр, трамвайларда өлкәннәргә вә балаларга урын тәкъдим итәләрдер, бер-берсенә сәламәтлек һәм бәхет кенә телиләрдер кебек тоела иде. Хәер, чынлыкта, моның нәкъ киресе икәнен белә ул: трамвайлар салкын, тәрәзәләре ватык, суык җил өрә, идәнннәр пычрак, чөнки ярты ел инде себерелмәгән, чистартылмаган булыр. Нәкъ менә кичләрен анда ышпана, анаша тартып күзләре тонган наркоманнар котырына, эштән арыган, йончыган кешеләр кайта, алар эчке бер куркыну белән киләчәк Яңа елны кötәләр—ул халыкка, ташкентлыларга ни алып килер? Ләкин болай уйлыйсы килми, күңел бәйрәм көтә. Яшьлектә калган еллардагы, Мәскәүдә чактагы кебек... Ә ул чакта тормыш күпме перспективалар, өметле мөмкинлекләр, бәхет вәгъдә итә кебек тоела иде... Тәрәзә янында төнге бакчага карап Камалов моңсу уйларга чумды: "Яңа ел минем өчен нинди булыр?—дип, сагышлы гына уйланды ул.—Бергә-бер күрәштә мәрхәмәтсез дошманны җиңә алырмынмы?"

Әлеге үлем уенында инде беркайчан да туктамаячагын яхшы белә иде инде ул. Йә җиңәсең, йә үләсең. Урталыкта юл юк.

Ул үзенең Ташкенттагы инде ияләнеп өлгергән йортын искә төшерде. Кинәт кенә аның шунда кайтасы килә башлады, андагы һәр чалым гаиләсен, улын хәтерләтә иде. Бергәләп Яңа елны каршылаулар никадәрле бәхетле мизгелләр булган икән.

Өйгә кайту турындагы уй җанын шулкадәрле тетрәткән иде, авыруларның күбесенең бәйрәмгә гаиләләре янына сорап китүләрен белгәч, ул да һичьюгы бер кичкә кайтып килергә карар бирде. Юкса, хастаханәдә әле мартка кадәр ятасы бар.

Бөтен җирдә Яңа ел алды ыгы-зыгысы сизелә иде инде. Авырулар кайтып килергә җыена башлады, табиблар йөгерешә, хәл белергә килүчеләр күзгә күренеп кимеде. Камалов яткан травматология бүлеге дә бәйрәмгә әзерләнде, йөри алган авырулар холлда телевизор янында чыршы бизәделәр, коридор буйлап чуклы-чачаклы бизәкләр элеп чыктылар.

Ниһаять, иртәнге обход вакытында, нәкъ Яңа ел алдыннан, ул да үзен дәвалаучы табибтан өйгә кайтып килергә рөхсәт сорады. Тегесе җитди генә карап куйды, күрәсең, аның Камаловны җибәрәсе килми иде, ләкин соңгы көннәрдә авыру күңелендә ниндидер үзгәреш, борылыш барганлыгын сизепме, уйчан гына сөйли башлады:

—Ләкин бер шарт белән... эчмәскә, тартмаска, дулкынланмаска. Болар барысы да сезнең өчен куркыныч тудырачак. Элекке тормыш турында онытып торырга туры килер, һәм дә бик озакка. Сезгә тынычлык, җайлы, ипле тормыш рәвеше кирәк, янәшәгездә акыллы китаплар, телевизор булсын... Якын елларга шулар белән канәгатьләнергә туры килмәгәе, бәлки гомерлеккәдер, кадерле Хөршид Азизович. Шушы усал шартларга риза булсагыз, кайтып килергә ярар. Сез ризамы?

—Тулысынча,—дип ачылып җавап бирде прокурор. Профессор авызыннан беренче тапкыр әйтелгән ачы хакыйкатьне, дөресен генә әйткәндә, ул колагы яныннан уздырып җибәрде. Тормышының калган өлешенә аның үз планнары бар иде.

Рөхсәт алгач, Камалов башта югалып калды, хастаханәдә озак яту кешене сүлпәнләндерә, йомшарта, ләкин ул үзен бик тиз кулга алды. Тешенне кысып булса да, хәлсезлекне онытырга кирәк иде һәм ул шулай итте дә. Телефоннан машинасын чакыртты һәм шофер өйгә кереп, киемнәрен алып килгән арада төрле планнар төзеп куйды. Иң элек, табигый ки, зиратка барырга, хатыны белән улының каберләрен карап

кайтырга кирәк булыр.

Коканд юлында засадага бергә эләккән Нортухта аны Чиготай зиратына бик тиз илтеп тә җиткерде һәм, әллә нинди тыюлар булуга карамастан, мазарстанга машина белән керде, чөнки прокурорга йөрүе авыр иде әле.

Зиратта ул бик озак юанды, суык җелегенә үтте, тәмам арыды һәм инде шәһәр үзәгенә кайтып барышлый күзенә "Лидо" ресторанының рекламасы чагылып үтте. Җылы, уңайлы залларда бай һәм матур бәйрәм киче тәкъдим итүче реклама. Нишләптер кылт итеп исенә Татьяна төште, нәкъ шушы ресторанда ул сатлыкҗанны абайлап алган түгелме соң?!

Камалов беренче тапкыр газиз улы һәм сөекле хатынының каберләрен зиярәт кылган, йөрәге урыныннан купкан мондый кайгылы көнне нидер эшләргә, әйтик, дусларын, туганнарын, хезмәттәшләрен җыярга тиешлеген дә чамалый, ләкин аның карамагында кайтып килү өчен бирелгән тәүлектән чама белән күп булса егерме сәгать тирәсе вакыт калган иде. Бәлки, җан газапларын җиңеләйтү өчен Коръәннән ниндидер юллар укырга кирәктер, ләкин, кызганычка каршы, динне санга сукмыйча үстерелгән буын вәкиле буларак, ул бер генә сүрәне, сүрәләрдән бер генә аятьне дә белми иде шул. Иң соңгы мизгелдә, күзенә "Лидо"ның ачык верандасындагы мәрмәр баганалар һәм ялган классик эслүбтәге ишекләре күренгәч, Мәскәүдә урыслар арасында яшәп ияләнгән бер гадәт исенә төште:

—Искә алырга! Искә алырга!!

Бу уйдан кинәт кенә барысы да үз урынына утыргандай булды һәм ул шоферга тукталырга кушты. Ресторанның ничектер Сенатор һәм Миршаб исеменә бәйләнгәнлеге, монда аның турында әллә ничә тапкыр сүзләр булганлыгы хакында гөман кылып торырга вакыты да теләге дә юк иде. Аның бар омтылыш-уйлары бер генә нәрсә тирәсендә чәбәләнә иде: соңга калып булса да, үзенчә, бер үзе, кешеләрчә, ияләнгәнчә, хатынын һәм улын искә алырга.

Кнопкага басуга ук ишек катында швейцар формасы кигән Карен пәйда булды һәм ул, прокурорны гомерендә бер тапкыр күргәне булмаса да, аны шунда ук таныды, бер генә секундка югалып калгандай булды. Ләкин күз ачып йомганчы үзен кулга алды һәм сүзсез генә ишекне киң итеп ачып җибәрде. Спорт курткасын гардеробщикка,—полковник Чураев комачауламаса, пистолеттан үзен теге дөньяга бөтенләйгә озатырга тиешле егеткә,—калдырып, прокурор киң вә якты холлга килеп керде һәм "Лидо"ның никадәр колач, зәвык белән төзелгәнлеген күреп таң калды.

Мондый кәттә тәгамханәдә, дөресен әйтергә кирәк, аның әле бервакытта да булганы юк иде. Ике залның кайсына керергә белмичә, ул бераз холлда басып торды һәм вестибюль кырында, икенче катка күтәрелүче киң мәрмәр баскыч янәшәсендә берничә өстәл куелган барны күреп алды. Зиннәтле баскыч күләгәсенә поскан әлеге бар беразга дип кенә кереп чыгучылар өчен бигрәк тә уңайлы иде. Прокурор шул якка таба атлады. Әйләнә торган биек урындыкка рәтләп утырырга да өлгермәде, бармен аннан итагатьле итеп сорады:

—Коньякмы, виски, джин яисә ликермы?

—Аракы,—диде Камалов, зәвык белән бизәлгән бай витринаны караштырып.

—Тотмыйбыз,—диде стойка артындагы кеше. Бу юлы әйткәне корырак янгырады янгыравын, әмма мәнсезлек күрсәтмәде.

Гадәттә, урыслар вафат булганнарны аракы белән искә алалар, прокурорның да шул традицияне бозасы килми иде. Уйга калды. Шул чак баскыч янындагы өстәл яныннан кемдер буфетчыга кычкырып әйтте:

—Залдан алып кил, безгә сирәк кунак кергән.

Күз ачып йомганчы бармен икенче каттагы залдан бер шешә "Столичная" алып та төште. Тирләгән шешәне ак тастымалга сөртеп, ул

авыру кыяфәтле клиент алдына бер рюмка куйды, ләкин анысы тагы берне куюны сорагач, тәҗрибәле һәм беркайчан да каушамаска өйрәтелгән официант сискәнеп китте:

—Анысы нигә?

Маңгаенда яра эзе сизелеп торган сәер кеше бернәрсә дә әйтмичә, аның кулыннан шешәне алды һәм күзеннән тутырып икенче рюмкага да аракы салды, янәшәдәгеләр ишетерлек итеп, кычкырып әйтте:

—Хатыным өчен, улым өчен.

Егет бернәрсә дә аңламады, ләкин баскыч янындагы өстәл тирәсенә баскан кешеләрнең аларның сөйләшүенә игътибар белән колак салуларын сизенде.

Эчеп куйгач, сәер клиент рюмкаларны читкә этәрде:

—Ә хәзер бер рюмка коньяк салсаң да була,—диде һәм капшанып кесәсеннән сигарет эзли башлады, бармен житез егет икән, ул, ярарга тырышкандай, "Винстон" кабын сузып өлгерде.

Маңгаенда яра эзе беленеп торган кеше сигаретны иреннәренә элүгә, кемдер тавышсыз гына кабызылган чакма сузды. Камалов яхшылып үтүкләнгән, күз явын алырдай ак күлмәк манжетыннан чыккан пөхтә, чиста кулдагы "Ронсон" чакмасына үрелде һәм аннан соң гына кул иясенә күтәрелеп карады. Аның алдында... Хашимов басып тора иде. Барменны аракыга нәкъ ул жибәргән иде дә инде.

Башлап нидер әйткәнче, Миршаб барменга күз сирпеп алды, тегесе стойка артыннан читкәрәк шуышты, күрәсең, ул сүзсез дә барысын аңлый иде. Бары тик шуннан соң гына, Хашимов чакмасын жилет кесәсенә тыкты һәм сүз кушты:

—Туып килүче Яңа ел белән! Сезне исән күрүемә шатмын, ишеттем, авыр авариягә эләккәнсез икән...

Прокурор җавапка ләм-мим сүз әйтмәде, бары тик бик күп гамәлләрен белеп өлгергән кешегә текәлеп карап торуын белде.

Югары суд кешесе озакка сузылган тынлыкны күтәрә алмады.

—Сезне могҗиза белән генә исән калган, дип сөйлиләр. Хәзер куркыныч эшегезне ташларга туры килердер, сезнең дәвамчыгыз булырдай кешеләрне дә әйткәли башладылар шикелле...

Камалов жинел сөякле бармен рюмкага салып өлгергән коньякны дәшми генә эчеп куйды, биек табуреттан сак кына төште, бары шуннан соң гына, әңгәмәдәшенең күзенә карап, әйтте:

—Өметләнмәгез, Сәлим Хәсәнович, ташламыйм. Без сезнең белән, Миршаб, барысын да яңадан башлыйбыз, дип исәплә. Мин инде счетчикны борып жибәрдем. Сенаторның да, сезнең дә миңа әҗәтегез артык зур. Түләргә туры килер!—Һәм ул сул аягына аксый-аксый ишеккә таба атлады. Сиздермәскә тырышса да, һәр адымның яңа газаплар китерүе аның йөзенә чыккан иде.

1990 ел.

РЕДАКЦИЯДӘН:

Хөрмәтле журнал укучылар!

Роман турындагы фикерләрегезне автор үзенә түбәндәге адрес буенча язып жибәрүегезне үтенә:

107207, Москва, ул. Алтайская, д. 4, кв. 423.

Аңа шулай ук **(095) 466-72-00** телефоны буенча шылтыратырга, яисә

E-mail: mraul61@hotmail.com адресы белән электрон почта аша да мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

ТАҢ КОШЫ—ТАҢДА ЙОКЛАМЫЙ...

НӘҖИБӘ САФИНА ИҖАТЫ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Иҗат—ул язмыш, диләр...
Дөрестән дә, тулаем алганда иҗатны "язмышым!" дип кабул иткән, барлык вөҗүден иҗатка багышлаган иҗаткярлар гына, Ходай биргән талантына карап, теге яки бу күләмдә уңышка ирешә ала. Һәм әйтергә кирәк, шуңа бәрабәр рәвештә Иҗатка шәхеснең язмышы, яшәеш рәвеше, тормыш-чынбарлыкка карашы, уй-фикерләр сөрешенең юнәлеш-кыйбласы, ахыр чиктә, холкы-фигыленең яшерен сулкылдаулары, фантазия-уйдырмалар белән бергә кушылып, тегеләйме-болаймы Иҗатка да күчә.

Була шундый иҗаткярлар, алар Табигатьтән килгән талант канатларына таянып, иҗатларының башлангыч чорында ук югары биеклекләргә күтәрелергә сәләтле икәнлекләрен күрсәтәләр, иҗади мохит та андыйларны (күп очракта!) бик тиз күреп алып үзенеке итә, һәрхәлдә, алардан янадан-яңа ачышлар, зур эшләр көтә. Күпчелек вакытта бу өметләр аклана да һәм "өметле" дип мөһер сугылган "яшь иптәшләр" дәверләр узу белән олуг бер әдип булып өлгерә... Чөнки ул, талантлы булуы өстенә, яшәүнең туктаусыз көрәш икәнлеген аңлап (ә Иҗат яшәү рәвешенең бер чагылышы, моделе ул!), тормыш каршылыкларын җиңә барып, әлбәттә, борчылу, шикләнү, газаплану, шатланулар аша Язмыш дигән катлаулы бер бөтенлек иҗат итә. Меңәр еллык тәҗрибә шуны күрсәтә ки, кызыклы, кабатланмас язмыш белән яшәгән шәхесләр генә беркемнекенә дә охшамаган иҗади дөнья тудыра алалар.

Була тагын икенче төр иҗаткярлар, иҗатларының беренчел кисемендә алар башкалардан әллә ни аерылып тормыйлар, ялтырап килеп чыкмыйлар, әмма югарыда санап кителгән сыйфатларга ия булу сәбәпле, кем әйтмешли, торган саен "ачыла" баралар, тормыш тәҗрибәләре арткан саен иҗатларында да янадан-яңа төсмерләр пәйда була, ачышлар барлыкка килә. Ни өчен шулай дигәндә, алар чишелеше таләп ителми торган бер хакыйкатьне яхшы үзләштергән булырга тиешләр: талантның юлдашы иҗат өчен көрәш, туктаусыз эзләнү, яңалыкка омтылуы ич! Ә инфантильлек—"балаларча суллык" авыруы күпме сәләтле шәхесләрне йотты, тормыш баткаклыгына кертеп батырды; шул рәвешле күпме зур ышанычлар вәгъдә иткән яшь кешеләр балалык чорында, олы, чын иҗатның "теге" ягында торып калдылар...

Бу нәүбәттән Нәҗибә ханым Сафинаның иҗади язмышы игътибарга лаек: ул әдәби стартны башка бик күпләргә караганда сүлпәнрәк алды кебек, һәрхәлдә, баштарак иҗатка сусаган яшь максималистларның алдынгы рәтендә саналмады, әмма бүген үҗәтлелеге, Иҗатка тугрылыклы хезмәт итүе нәтиҗәсендә Шигърияттә язмыш юраган үз урынын яулап ала алды, кулыннан каләм төшеп китәргә сәбәпләр булган чакларында да Иҗатка хезмәт итәргә үзендә көч тапты.

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлагач, ул шактый югалып торды. Баксаң, Нәҗибә ханым туган якларында, әдәбиятының тугрылыклы хадиме буларак, шигъри учаклар кабызып йөргән икән. Бу хакта аның яшьлек дусты Филүс Ханов бер язмасында болай дип искә ала:

"Мин Яңавыл районының Кисәк-Каен авылында туып үскән шагыйрә Нәҗибә Сафина турында сөйләргә булдым әле... Чөнки әле генә дигәндәй, без аның белән Нефтекама, Краснокамадагы каләм тибрәтүче яшь иҗатчыларны эзләп, "Акчарлак" әдәби берләшмәсе, аннан тагы да киңрәк күләмле "Инеш" иҗат берләшмәсен булдыру өчен янып йөргән идек. Аның белән бергә күпме авыл, мәктәп, завод-фабрика, тулай торак сәхнәләренә күтәрелдек, балалар бакчалары, ял йортларында—барысында да шигырь укыдык".

Менә шулай, учакларда янып чыныгу алган Нәҗибә ханым 80 еллар ахырында, урау юллар үтеп, кабат Казанга әйләнеп кайтты һәм иҗтимагый тормыш вә иҗади мохит казанында кайнап яши башлады; дөресрәге, күнегелгән гадәте буенча яшәвен дәвам итте. Кабаттан милли аң уянып килгән, татар халкы ирек вә бәйсезлек яулап йөргән еллар иде бит бу һәм Нәҗибә Сафина, ике дә уйлап тормастан, көрәшчеләр сафына басты: газиз халкының гайярь вәкилләре белән бергә мәйданнарга чыкты, шигырь сәхнәләренә күтәрелде, әдәбият-сәнгать әһелләре белән кайгысын-шатлыгын уртаклашып гомер кичерде. Шушы чорда заманыбызның күренекле шагыйре Мөдәррис Әгъләм белән уртак тормыш корып җибәрүләре дә аның иҗатына уңай йогынты ясады кебек. Һәрхәлдә, нәкъ менә шушы дәвердә шагыйрә иҗат белән аеруча актив шөгыльләнгән икән, бу бер дә гаҗәп түгел—янып яшәүнең бер нәтиҗәсе булырга тиештер ләбаса... Әйе, шагыйрә вакытлы матбугатта көлтә-көлтә шигырьләр бастырды, алар ахыр чиктә китап булып тәгаенләнделәр. "Таң кошы" җыентыгы 1997 елда дөнья күрде, әлегә соңгы китабы (ул "Әгәр дә уйланганда..." дип атала) 2001 елда басылып чыкты. Ул арада икеме-өчме балалар өчен шигъри күчтәнәчләр—китаплар әзерләргә өлгерде Нәҗибә ханым. Алай гына да түгел, иҗади активлыгын күреп алган каләмдәшләре аны моннан берничә еллар элек Татарстан Язучылар берлегенең идарәсенә әгъза итеп сайлап зур хөрмәт күрсәттеләр һәм, әйтергә кирәк, тынгысыз холыклы шагыйрә идарә эшендә үзенчәлекле "катализатор" хезмәтен үтәде кебек. Тормышта актив позициядә торган шагыйрә, иҗат кредосын билгеләп, болай дип язды:

Язгы ташкын, көзге балкыш—
Берсе дә түгел лә мин.
Мин барсы да, мин тик кеше—
Яшәүнең күге лә мин.

Чыннан да, иҗат—ул язмыш булса, хәзер без һич тә икеләнмичә әйтә алабыз: Нәҗибә Сафина бер кемнекенә дә охшамаган иҗат дигән язмыш иҗат итә алды, ул үзенең ин унышлы шигырьләрендә гасабилы җанын ачып бирүдән куркып калмады:

"Таң йокысын йоклыйлар бит аны",—
Иң татлысы иде таң йокысы...
Инде күптән таңда йоклый алмыйм,
Күптән инде, күптән мин—таң кошы.

Әйе, шагыйрь үзен "таң кошы" дип атый, ләкин шигырьнең хикмәте тирәндәрәк ята икән, ягъни шагыйрь шәхси кичерешләр аша милләти киңлекләргә чыга һәм зур гомумиләштерүләр ясый:

"Таң йокысын йоклыйлар бит аны",—
Имин булса әгәр туган җирем,
Исән булса әгәр җан ирегем,
Исән булса әгәр Дәүләт-Җирем,—
Таң йокысын мин дә йоклар идем...

Кыскасы, аңлашылса кирәк, Нәҗибә Сафина үзен уйлы, гамьле шагыйрь итеп танытты, Ил-ватан борчулары да аңа ят тойгы түгел. Ләкин шушы шигырь уңае белән тагын менә нәрсәгә тукталасы килә: кайчагында әдип бер шагыйранә юл белән дә әдәбиятта ниндидер бер ачыш ясый (әйтик, Әмирхан ага Еникинең "Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә" дигән галибанә юллары кебегрәк) һәм ул гыйбарә буыннардан-буыннарга күчә-күчә халык күңелендә саклана килә. Әнә бит Нәҗибә ханым да әбисеннән ишеткән бер нәсыйхәтне җыр иткән—шәп бит, чукынчык, тарихи бер эпостан киртләп алынган диярсең: "Таң йокысын йоклыйлар бит аны..." Ә Нәҗибә Сафина таң йокысын йоклый алмый, чөнки ул, үзе әйткәнчә, таң кошы...

Наис ГАМБӘР

Нәҗибә Сафина

ӨЗЕЛГӘН ЯФРАК ЯРАСЫ

Җанда шундый хәлләр

Дөнья гади генә могҗиза ул;
Белә дөнья үзенә кирәкне:
Бер утларга, бер суларга сала,
Нәни генә гыйсъян йөрәкне.

Дөнья... гали генә могҗиза ул,
Белә: кемдә нинди йөрәк бар.
Йә уйлата, йә жырлата аны,
Йә елата гомер буе зар.

Дөнья—"гади генә гали"—фани:
Яндыра да сала ләхеткә.
Өлгерәлсәң, тик жырларың кала...
Ярый жырлар кала бәхеткә.

Жырдай гали, гади бу дөньяга
Яшәр өчен диеп киләбез,
Жыр калдырып китәр өчен иленә—
Килә жиргә шагыйрь, беләбез.

Дөнья бары жыры белән гали,
Акча белән түгел... Нигә без
Жырчыларның кадерләрен әле
Жирләгәндә генә беләбез?!

Җәяүле җан

Нажар Нәжмигә

Чәчләрең кара чагында
Жаның яралы иде.
Яралы кош кебек, жаның
Талпынып барыр иде...

Күңелендә яра иде,
Ә дөнья бара иде.
Кулларында гармун гынаң
Сагыштан яна иде.

Яралы кош кебек жаның
Бер очты да бер төште.
Еллар синең өлешеңә
Жәлләмәгән көмешне!

Күңел яктыларың шулай
Чыкты микән ирекка?
Ә күңелләр һаман бәйдә:
Гомерләрне биреп тә
Алып булмады ирекне,—
Күңелләр—һаман яра.
Яралы кош кебек җаннар
Очалмый, җәяү бара...

Мин—яфрак, яндырыгыз...

Сары яфракларны көзен
Җыялар бит, җыялар.
Әйтерсең гөнаһ таулары—
Утлар ягып куялар...

Сутын тормыш сыккан яфрак
Дөрләп яна да бетә,
Көлен барыбер көзге җил
Очыртып алып китә.

Кешеләр дә шулайдыр ул,
Калса да каберләре—
Мизгел үтә, тарих өчен
Каламы кадерләре?

Таркала, көл була сөяк,
Ташны да төя тарих.
Кешегә дә тузан гына
Булу гыйлләсе бар ич.

Җилдә очар, җирне кочар
Тузанга калдырыгыз!—
Ә тузан кая да сыя...
Мин—яфрак, яндырыгыз!

*

Күк—шәмәхә. Кып-кызыл ай—
Тик урак кадәр генә.
Иссә җил, кузгалыр болыт,
Югалыр хәзер менә.

Кара болыт ертыклары
Кунганнар ак каенга.
Ап-ак шатлыкларны гүя
Батырганнар кайгыга.

Күк шәмәхә. Каеннар ак.
Ертык болытлар кара.
Ак каенның кәүсәсенә
Кемдер ясаган яра.

Таң. Күк—алсу. Каен—кызыл:
Кан ага ярасыннан.
...Гаепләне эзләп йөрим
Кешеләр арасыннан.

Кич. Барыбер кара җиргә
Түшәлә ап-ак томан—
Гөнаһлыларны акларга
Тырышкан шагыйрь сыман.

Беләсең

Җаның бушатыр яр кирәк кешегә,
Җанны ярып булмый гади күршегә.
Җан ярылыр яраларның барлыгын,
Бу дөньяның хәтта кылдан тарлыгын
Беләсең:
Кыл өстендә тота дөнья, егылмыйсың.
Иманың белән атласаң, кол булмыйсың.

Беребез—аккош, Беребез—ак кыш...

Син анда, сизәм, төн буе
Йокламый утырасың:
Өзелгән яфрак ярасын
Җыр белән тутырасың...

Язын синең җырың белән
Ачылыр бөреләре.
...Синең ялгызлыгың булып
Уларлар бүреләре...

Син булып чайкалыр хәтта
Язгы җилләрдә агач...
(Аккош күленә аккошлар
Кайтыр—мин кайталмагач!)

Син дә анда кайталмассың,
Көтәр дә...китәр аккош.
Җаның булып, өшеп, кайтыр
Аккош күленә—ак кыш.

Беребез—аккош,
Беребез—ак кыш...
Буламы чагыштырып?!
...Ак кыш белән аккошларны
Булмый шул кавыштырып...

Кызарып пешкән җиләкне
Учыңа җыясыңдыр.
Җиләк түгел, учларыңда
Кузлар дип тоясыңдыр.

Җиләкләрне җыясыңдыр,
Чирәмгә коясыңдыр.
Тагы ашый алмады, дип,
Җаныңны кыясыңдыр.

Җиләкләр ачы түгелдер,
Ачыдыр хатирәләр.
Үч иткәндәй, җилләр синең
Уйларны китерәләр:

"Инде шушы җиләкләрне
Ашыйсы иде бергә—
Сөюдән киту мизгеле
Җитә икән гомергә..."

Кызарып пешкән җиләкләр
Изелә учларыңда...
Җиләкләр дә пешә мәллә
Мәхәббәт утларында?!

Әгәр белсә...

Минем хәлне балык күрсә,
Күлен миңа бирер иде.
Ул аңласа, суга керми,
Утка үзе керер иде.

Минем хәлне кошлар күрсә,
Канатларын ташлар иде.
Миңа биреп канатларын,
Җәяү йөри башлар иде.

Минем хәлне тик син генә
Күреп тордың—җаның сукыр.
Тик син салган яраларны
Бер тотлыкмый сукыр укыр.

Балык, кошлар минем хәлне,
Минем хәлне белми әле.
Аһлар иде Мәҗнүн үзе,
Синнән алай булмый әле,
Синнән булмый...

Безнең көймә

Җәйнең хәле безнең хәлләр кебек—
Елап тора әнә түбәбездә.
Без дә шул халәткә киләчәкбез,
Бирешмәскә диеп түзәбез лә.

Җәй күз йомып ачкан ара гына,
Салкын җилләр тора көз сагында.
Яфракларның барын өзеп алып,
Көзләр он итәчәк кочагында.

Җилгә нәрсә, аның эше—өзү,
Инде болытлардан ак кар өзә.
Җиргә төшеп тапталган карларның
Язмышларын күреп болыт йөзә:

Тулышканчы күктә йөзәбез дә
Авыр булгач, җиргә төшәбез шул.
Без күкләрдә кайчан йөздек икән,
Хәзер шундый түбән—түшәмебез.

Безнең канат кайчан каерылган,—
Акчарлаклар оча, йөзә, йөри,—
Адымнарны саный-саный кемдер
Язмышларга йозак сала юри.

Ярга йозакланган көймәләрне
Тарткалый да дулкын бер чак өзә...
Безнең көймә безсез йөзеп китте,
Көзләр җитеп килә, күңел сизә.

Йөреп, йөзеп, очып тотам димә:
Вакыт-җептән үрелгән ул көймә!

Язучы Вахит Имамовка 50 яшь

ИМАМ

Имам турында укучыга аңлатып торуның хаҗәте юктыр дип уйлыйм. Бер фикер генә әйтәм: имам вазыйфасын 622-632 елларда Мәдинә каласында Мөхәммәт пәйгамбәр үзе үти. Ары таба дин буенча хәзерлекле һәм абруйлы кешеләрне генә имам итеп куйганнар...

Вахит Имам бүген Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге белән генә идарә итә. Әмма мин аны, тарихи әсәрләрен укыган кеше буларак, мәчет имамы булмаса да, тарихчы имамлыкка йөз тота дип әйтә алам.

Язучы Вахит Имам татар әдәбиятына "Сәет батыр" роман-хроникасы белән килеп керде. Бу—Русия империясенең, тәрәзә пыяласы чатнаган кебек, картасы сүтелә башлаган вакыт, союзлыкка йөз тоткан республикалар көтмәгәндә-искәрмәгәндә мөстәкыйль дәүләт булып киттеләр. Билгеле, кинәттән иннәренә ишелеп төшкән бәхеттән башлары әйләнгән республикалар да булды, алар азмы-күпме үз кул асларына кергән (автономия дип аталган) республикаларга ия булырга керештеләр. Моны алар Русия империясе үрнәгендә эшләделәр һәм шуның белән үз халыклары күнелләренә дә империя оеткысына хас шовинизм чире орлыклары салдылар.

Әнә шул чорда яшьләр дөньясында кайнап яткан Вахит кисәктән уянып киткәндәй татар халкының тарихын актара башлый һәм империя кул астында гасырлар буена михнәт чиккән бабаларыбызның тарихына озакка кереп китүен сизми дә кала. Гасырлар буена орыш-сугыштан башы чыкмаган Русия империясе аның күз алдына чын мәгънәсендә ике башлы каракош булып килеп баса. Кайчандыр аның да бабалары Идел буе Болгарында мөстәкыйль гомер иткәннәр ич, биш телдә сөйләшкән асылзатлары дөнья халыклары белән сәүдә иткәннәр, хәтта бөтен дөнья халкын тезләндерергә керешкән Алтын Урда империясе дә безнең бабаларыбызның телен-динен генә түгел, дәүләт белән идарә итү тәртипләрен дә алган. Кытайдан алып Рим империясенә кадәр йомшак тиреләр, балык җилемнәре, затлы ташлар һ. б. товарлар белән Иделдән—Кытайга, Болгардан көнбатыш Аурупа илләренә кәрван-кәрван затлы товар йөрткәннәр алар.

Вахит Имам тарихи әсәрләр язарга керешкәнче үк инде үз халкының тарихын белми үскән яшьләрне "Үз ишең беләнме?", "Йөрәккә якын кеше", "Яшәү яфраклары" кебек хикәяләре аша гаделлекне күрергә,

"тарихы булмаган халыкның киләчәге дә юк" дип бүгенге тормышның асылын аңларга өйрәтә. Ул гынамы: автор аларны үзенә юлдашлыкка дәшә, тарих сәхифәләрен бергәләп актарырга чакыра.

Ниһаять, Вахит Имамның хикәяләре милләтебезнең йөзек кашы булган "Казан утлары" журналында күренә башлый. Бу инде һәр яшь язучы өчен азмы-күпме сират күперен узу дигән сүз. Журнал Татарстанда көн күргән халыклар өчен генә түгел, бөтен дөньяга таралып яшәгән татарлар өчен дә бердәнбер үрнәк матбага ич! Бу журналда исем-атың күренү язучы булырга хыялланучыга беренче баскыч дигән сүз. Баскычын баскыч, ләкин бит бу журналда беренче әсәре күренүгә, борын чөеп, минме—мин дип йөрүчеләр дә булгалый. Вә ләкин Вахит Имам ул чирдән арынган булып чыкты: киресенчә, ул тагын да үҗәтләнебрәк, тырышыбрак язарга кереште.

Язучы Вахит Имамның үз кыйбласы бар иде—бабаларыбызның бераз монсу да, данлы да, шанлы да тарихы! Юк, Вахит Имам үз әсәрләрендә муллаларга хас коры вәгазь укымый, ул укучыларын үткәннән гыйбрәт яисә үрнәк алырга өнди. Менә "Идел" журналында басылган "Сәет батыр" роман-хроникасы. Анда автор "прогрессив" дигән патшага кул күтәрә. Бит Петр патша Ауропага тәрәзә ачкан кеше, ул Русия тарихында прогрессив карашлы шәхес буларак сурәтләнә! Ләкин "прогрессив карашлы" дигән шул патша татар халкына карата үтә мәрхәмәтсез була. Бу патша яу-сугыш уздырулары аша үз халкын тәмам хәерчелеккә төшерә, дөнья халыкларын яулау өчен хәтта христиан чиркәүләренең чаңнарын төшертеп, туплар койдырта. Бу патшаның комсызлыгын, кансызлыгын бер сәхифәдә генә сөйләп бетерерлек тә түгел. Укыгыз Вахит Имам әсәрләрен һәм, Син, хөрмәтле укучым, Петр патша турында рус тарихчылары язганның бөтенләй киресен күрерсең. Менә кем ача комсыз патшаның чын йөзен! Тарихи әсәрләре белән язучы Вахит Имам минем күз алдымда янә бер баскычка күтәрелде. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булгач ул тагын да катлаулырак тарихи темаларга әсәрләр язарга керешә.

Кайчак Вахит Имам тарихи фактлар белән артык мавыгып та китә. Шул чиккә житеп мавыга ки: әсәргә керергә тиешле вакыйга китапның композициясен боза, ягъни укучыны азмы-күпме әсәрдән аера башлый. Тарихта булган вакыйгаларны ничек булган шулай әсәренә кертү бар, билгеле. Ләкин әдәби әсәрләрдә, нигездә, вакыйгалар түгел, шәхесләр, әдип каләме белән каһарманга бирелгән характер өстенлек итәргә тиештер кебек. Бит, иң әүвәл, китапны кулына алгач та, укучының күңелен төп герой яулый. Каһарманнар арасындагы өчәр-дүртәр биткә сузылган бәхәсләр, монолог-диалоглар да әсәрне әлләни бизәми. Миңа калса, алгы планга һәрчак геройның характеры чыгарга, аның эчке кичерешe, үз мохитындагы тегe яки бу хәлгә карашы һәм кылган гамәлләре һәрдаим язучының күз уңында торырга тиеш. Мин күрәм-күзәтәм: әдип буларак, Вахит Имам бигрәк тә соңгы әсәрләрендә әнә шулай эшли башлады. Ә бу инде аның уңышы, язучы буларак тураеп басуы дигән сүз.

Мин тарихи әсәрләр язучы Вахит Имамга ничек итәргә киңәш бирергә җыенмыйм, мин хәзер аның белән тәмле шәраб чөмереп, бер өстәл янында киләчәк әсәрләребез турында киңәшә генә алам. Һәм мин аңардан ак вә изге көнләшү белән көнләшеп тә куйгалыйм. Бик күп тарихи очерклар язды ул. Безнең каһарман генералларыбыз вә гаскәрбашларыбыз турында. Татар батырлары "Генерал Бәхтияр Канкаев", "Генерал Карзафар Усаев", "Генерал Ярмөхәммәт Кадерматов", "Салават Юлаев" һәм башкалар — барысы да тарихи очерклар. Ә бу каһарманнар турында тәфсилле язу өчен күпме тарихи китаплар һәм архивларда тузанланып

яткан хезмәтләр, документ-мәгълүматларны актарырга кирәк! Язучыга һәр каһарманның тормыш юлын өйрәнергә, кайчак хәтта аның "күлмәген киярга" туры килә. Шулай итмәгәндә ничек кулыңа каләм алып, тарихи әсәр язарга утырмак кирәк! Менә шул ягы белән дә, ягъни максатчанлыгы, үҗәтлеге вә тырышлыгы белән дә әдип Вахит Имам үз калебендә кала бирә.

Вахит Имамның нәүбәттәге романы "Утлы Дала" дип атала. Роман, автор язуынча, трилогия йөзендә укучыга җиткереләчәк. Әсәрнең беренче китабы турында мин язып чыккан идем инде. Бүген, әдип илле яшенә аяк басканда, бары тик шуны гына әйтә алам: роман бар, укыла, ул үзенең укучысын тапты. Хәзер инде укучы китапка бәһа бирәчәк, хәтта әсәрнең яшәү гомерен дә укучы гына хәл итәчәк. Ләкин бер мәсьәләгә укучының һәм шул исәптән әдипләрнең дә игътибарын җәлеп итәргә телим: бездә шундый гадәт бар—авторның яна әсәре дөнья күрдеме, әшнәдуслары аңа газета-журнал битләрендә мәдхия укырга керешәләр. Хак, бу да кирәк, укучыларга китапның дөньяга чыгу хәбәрен җиткерү өчен. Ләкин бит әсәрнең асылын да, кирәклеген дә укучы хәл итәчәк. Хак бәһане дә бары тик укучы гына бирәчәк, дуслык һәм әшнәлек серенә төрелгән мактау сүзләре түгел. Сүз, әлбәттә, төпле тәнкыйтьче яки әдәбият галиме тарафыннан тикшерелеп, әсәрне сәнгати вә әдәби яктан һәрьяклап анализлап язылган хезмәт турында бармый.

Мең елга якын яшәү дәверендә Русия "инородецларга" гына түгел, рус халкына да игелек күрсәтмәде. "Моны бары тик дәүләт башына килгән җитәкчеләрдән генә күрергә кирәк", дигән фикер уздыра үз әсәрләрендә Вахит Имам. Әйе, армия һәм корал Русиядә һәр дәвердә дә беренче планда булды, ә халык турында кайгырту иртәгәгә калдырылды. Патша Русиясендә дә, Совет чорында да, сүздә демократиягә һәм цивилизацияле илләргә тинләшергә теләгән бүгенге Россия федерациясендә дә шул дәүләти сәясәт вә мәсләк ята. Вахит Имам, язучы буларак, илдә барган бүгенге сәясәт белән бик үк кызыксынмаса да, патша заманнарыннан ук килгән ул хәлләрне дә һәм сәясәтне әсәрләре аша халыкка һәрдаим искәртеп тора.

Инде демократиягә йөз тота башлаган Русия ни өчен, нинди сәбәпләр аркасында кайчандыр үзе җиңгән һәм ил-дәүләт төзелешен тәмам җимергән илләрне икътисади яктан куып җитә алмый? Ни өчен, ни сәбәпле ул үз халкының хәләтен кайгыртмый? Моңа җавап табу өчен мин, сезгә, Вахит Имамның тарихи темага язылган әсәрләрен укырга тәкъдим итәр идем. Аның әсәрләрен укыган кешенең милли хистән үлеп барган хәтере дә кузгалачак, яңарачак!

Бүген Чаллы каласында яшәп иҗат итеп яткан Вахит Имамга—50 яшь. Татар халкында борынгыдан килгән бер гыйбарә бар: "Юлга чыксаң, юлдашың үзеннән әйбәтрәк булсын". Яшермим, юлга чыксам, мин, һич икеләнмичә, юлдашым итеп Вахит Имамны алыр идем.

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН

Вахит Имамов

ЯПОН ТАТАРЫ

ПОВЕСТЬ

Башлам

Рәсәй дигән илдән көтелмәгән хат килеп төшкәч, Касыйм хаҗи аптырашта калды. Үз Ватаны—татар җирендә азмы-күпме туган тиешле якыннары булу ихтималын ул гомер буе чамалап яшәде-яшәвен. Хәтта, япон йоласына ияреп, алтмыш яше тулган көнне кызыл кимоно кигәч, туган авыллары Салавычка икеме-өчме хат та юллап караган иде. Яшел чирәмле урам-яланнарда бергә аунап үскән авылдаш-чордашларыннан җылы хатирәләр, сагынулы хисләр өмет итте, дүрт күз белән көтте—җавап бирмәделәр. Бу хәлдән соң инде егерме ел үтеп киткән иде һәм менә сиңа «мә»: көтелмәгән бер хат. Нindидер «Брежнев» исемле каладан, Касыйм хаҗи бөтенләй ишетмәгән-белмәгән Рафил Адияровтан.

Касыйм хаҗи гаиләсендә соңгы елларда берничә яңа йола-тәртип урнашты. Шуларның берсе—почта. Салисә ханым Касыйм хаҗидан унике яшькә кечерәк, күзләре-зиһене үткен; хатларны уку, аларга җавап юллау—күбесенчә аның җилкәсендә. Бу юлы да хатны энәсеннән җебенә чаклы Салисә укып чыкты. «Кадерле туганнарыбыз... кайнар сәлам» дигән сүзләренә әлләни зур игътибар бирмәделәр. Әмма шәҗәрәне, якынлыкны аңлатуга күчкәч, Салисә ханым сикереп торды.

—Рәхилә әбинең оныгы Рафил, дигән бит бу, Касыйм. Ә Рәхилә—минем әниемнең сеңелесе. Бу Рафил атлы бала безгә бик тә якын туган булып чыга. Яши икән, яши нәселебез!..

—Рәсәйдән шушы хатны алу белән үк без тагын кемпентай йә булмаса токкоко күзәтүенә эләккәнбездер инде, әнисе. Җанәбе Аллаһ ярдәме илә алардан котылырбыз. Ә ошбу яңа туганнарыңа җавап яз син, Салисә. Туганнан йөз чөерү мөселманга фарыз гамәл түгел...*

Салисә ханым кош тоткандай очынып һәм матур төшләр теләп чыгып китсә дә, Касыйм хаҗи әле таң атканчы керфек кага алмады. Ул бу төндә янә хыялындагы Салавычка кайтты.

Беренче кисәк

—Әй, малайлар! Поскын чокырына таба каерыгыз, Поскын чокырына! Пугач патша поскыны тиккә генә качып ятмаган ла инде монда. Җәеннәрнең менә шунда яшеренеп ятканлыгын белгән. Шуңа монда качкан, тамагы тук булган. Сез дә сагыз сыман сузылып йөрмәгез. Абдул, үз ягыңны каер! Касыйм, син яннан ку!

**Кемпентай*—контрразведка, *токкоко*—дәүләт куркынычсызлыгы хезмәте.

Бу әмер-күрсәтмәләрнең һәммәсен дә яр өстендә бөерләренә таянып баскан Гафур бирә иде. Аңа уникe яшь, ул аякларын чылатып азапланмый. Касыйм үпкәләми. Сигез генә яшьтә дип тормадылар, бүген аны да Салавычтан балык сөзәргә үз әртилләренә алдылар бит әле. Югыйсә, Колчак килгәннән соң авылда аңа сәлам бирүче дә калмаган иде. Чөнки әтисе һаман-һаман Колчакныкыларга йә олау, йә корал белән булышкалап йөрде. Касыймны да шуңа ияртеп «куштан, буржуй», дип үчекләп маташтылар. Түбән очтагы Шәрә Сафа малае Хәсән аны тыкрыкта туры китереп дөмбәсләп тә алды. Ә аннары Колчакныкылар кисәк юкка чыкты, аларны «Пермьгә таба чигенгән», диделәр. Шуннан бирле авылга бернинди кораллы гаскәр дә керми; ни кызыл, ни аклар юк. Әнә, ярлылар баш күтәрде, Хәлим Солдат малае Гафур бүген командада башлык булып йөри. Касыймны Нәҗметдин бай малае дип тормады, үз араларына алды бит әле. Башлык икән, башлык. Әйдә, йөри бирсен.

—Касыйм, Касыйм!—дип кычкырды берзаманны Гафур бөтенләй дә яңа тавыш белән.—Әнә, ихатагыз капкасыннан әтиең кул изи. Әллүр, өеңә сыптыр!..

Әтисе аны сүгенми-кычкырмыйча, әмма җимерек йөз белән каршы алды.

—Әгерҗегә кызыллар кергән, улым. Шиһабетдин мулла белән Зәки байны мәчет диварына терәп атканнар, ди. Әҗәлне хәерче кызыллар кулыннан көтеп ятып булмас. Юньлерәк киемнәреңне җыйна, бүген төнлә юлга чыгабыз.

—Кая?

—Юл йөрмәгән кеше түгел, анысын дөнья күрсәтер...

Гомер буе аларда ялчы булып бил бөккән Өрәк Миннәхмәт агай сизенгәндер инде, ул кич буе Нәҗметдиннәр ихатасыннан читкә аяк атламады. Касыймның әтисе катлы-катлы итеп сүгенеп тә карады, чыбыркы шартлаткан булды, ләкин юк, Өрәк Миннәхмәт, башаклы тагаракка борынын төрткән мүкләк сыер сыман, ихата тирәли иснәнеп урануын белде.

Юлга тәмам күз бәйләнгәч, төн уртасында диярлек кузгалдылар. Кызыллар афәтеннән качып котылырга чамалап йөрүчеләр бик аз түгел икән, Уфага илтә торган олы юл читенә ун-унбишләп олау тезелгән. Касыймга арбадан төшеп йөрергә рөхсәт юк иде, шулай да, әтисе сүз кушкан кешеләрнең җавапларыннан да ул күбесен танып, чамалап утырды. Салавычта берьюлы ике тегермән тоткан Гыймади агай монда. Әгерҗедәге такта яру заводы хуҗасы Мулләхмәт абзый алар белән. Касыймнар өенә гел-гел кунакка килеп йөри торган Тирсә авылы мулласы Мифтахетдин хәзрәт тә аларга ияргән икән. Аннары әтисе Нәҗметдиннең бертуган абыйсы Таҗетдин. Тагын Сәхиб бай, Хәлиулла хәзрәт, ике кызыләрмисне атып үтергән Госсам... Ай-һай, санасаң, күп икән...

Әүвәл алар Уфага төбәп юл тоттылар. Каланың Чапай кулына төшүен ишетүгә Пермьгә борылдылар. Олаулар төнлә генә барды. Көндезләрен йә урман эченә, йә куаклы күл буена туктап ял иттеләр. Ирләр сакта торды, хатыннар-кызлар учакны каплап, төтенне куып тарата-тарата ризык пешерделәр. Бөтен кеше бик сак кыйлана, шаярту-көлү түгел, үзара кычкырып сөйләшү дә онытылган иде. Ләкин бәла дигәннәреннән барыбер котылырга насыйп булмаган шул. Инде Пермьгә килеп җиткән чакта гына аларны кызылларның дозор җайдаклары куып җитте. Мөһаҗирләр юлга коралсыз-саксыз чыккан олау түгел, бердәм ут ачтылар. Шулай да атыш вакытында Аккүз авылыннан Сәләх дигән кеше вафат булды. Аны җиде-сигез чакрым чамасы читкә алып киткәч бер кушкаен төбенә җирләгәннәр иде дә, тол калган хатыны Әсма һәммәсен шаккаттырды.

—Күрәчәгебез шул икән, мин Пермьгә кереп калам, арытаба бармыйм...

Мөһаҗирләр олавы әнә шулай итеп таркала башлады. Барыбер дә, Колчак отрядларын алмаш-тилмәш китереп уза-уза, Иркутски дигән калага чаклы бердәм юырттылар. Калага килеп керсәләр, анда ата—улны, ана кызны белмәс-аермас дәрәҗәдә мәхшәр. Бер якта әллә нинди чех отрядлары корал селтәп йөри. Икенче якта нининдидер Учредилка депутатларыннан торган Комуч үзенә власть, буйсыну таләп итә. Семенов атлы атаман үзен Себер падишаһы дип игълан иткән. Аңа кемнәрдер генерал дәрәҗәсе биргән. Ул да хәзер барча көчләрне үз канаты астына тупламакчы, Урал аръягындагы җирләрдә Аллаһ булмакчы икән. Ә Колчакка ияреп килгән бандалар берсен-берсе санга сукмый, болар өй борынча йөреп байлык талыйлар, кабакларга кереп типтерәләр. Бөтен кала кылыч, мылтык таккан җайдак белән тулган, бар урамны кычкырыш-талаш, шартлау-атыш тавышлары ду китерә.

Әгерҗелеләрне әлеге Себер каласында да бәла көтеп торган. Касыймның Таҗетдин агасы бер кичтә үзенең улы Гаязетдин белән иркенрәк фатир белешмәкче булып чыгып киткән иде, атаман Семенов кешеләренә тап булганнар. Тегеләр Таҗетдин белән Гаязетдиннан әллә акча, әллә корал таләп иткәннәр. Таҗетдин каршы төшкән. Башкисәрләр Таҗетдин абзыйны җиргә егып изә башлаганнар. Унҗиде яшьтә генә булса да, Гаязетдин—ташбаш, кызу канлы бит. Әлбәттә, әтисен яклап тегеләр өстенә сикергән. Шунда бер башкисәр, арттан килеп, кылыч белән аның муенына чапкан.

Гаязетдинны толып эченә төреп алып кайттылар. Башы өзелгән, тәгәрәп китүдән тире белән сеңер җепләр генә саклап тора иде. Таҗетдин абзый аны фатирга алып кайткач та, җирләгәндә дә башын бәрә-бәрә елады. Өйгә кайткач, кара көеп, аның итеп әйтте.

—Аллаһ ярлыкамый минем качуымны. Менә, улымны алды. Мин гөнаһка баттым. Арытаба барырлык куәтем юк. Мин кире борылам. Ачуланмагыз мине, авылдашлар.

* * *

Гыйнвар ахырында большевикларның идән астына качкан комитеты Иркутскида фетнә оештырды. Санаулы сәгатьләр эчендә каланың дистәләгән почмагын янгын чолгап алган, әле вокзал тирәсендә, әле корыч кою заводы эчендә вагоны-вагоны белән снарядлар шартлый, халык кайсы якка чыгып качарга белмәүдән гаҗизләнгән иде.

Тәүге атыш тавышларыннан ук урыныннан сикереп купкан Мифтахетдин хәзрәт үзен әгерҗелеләрнең атаманы сыман уяу, коры тотты.

—Урамнарга сикереп чыгып тәшвиш кузгатмагыз. Анда сезне, барыбер дә, ядрә көтеп тора. Бала-чаганы, хатыннарны моржа артларына, идән асларына яшерергә кирәк... Хәлиулла, Госсам! Алтатарларыгызны яшереп тыгыгыз да, вокзал әтрафына таба йөгерегез. Колчак кайсы якка кузгала, безгә аннан калышмаска кирәк. Ә калган ирләр белән, сез кайтканчы, өй тирәли каравыл оештырабыз...

Хәлиулла белән Госсам ике-өч сәгатьтән соң ук манма тиргә батып кайтып керде. Аякләре юеш бияләй сыман салынып төшкән, күзләре исә бака бәбәкләре кебек акаеп чыккан иде.

—Большевиклар Колчак белән аның ярдәмчесе Пепеляевны таң белән үк Байкал өстенә чыгарып атканнар бит. Элеккеге Учредилка депутатларын төрмәгә ябып куйганнар. Полковник Гайде кул астындагы чех юлбасарлары бер якка да кысылмый. Большевиклар аларга поезд вәгъдә иткән. Чехлар хәзер сандыкларын тезеп вокзалда утыралар. Урыс әфисәрләре, икеме-өчме поездга төялеп, таң атканда чыгып качкан.

—Безгә йокларга ярамый. Монда калсак, большевиклар атып бетерәчәк. Качаклар бер без генә түгел, поезд булмый калмас. Вокзалга каравыл куймыйча башка чарабыз юк,—дип Мифтахетдин хәзрәт Нәҗметдин белән Гыймади абзыйны янә вокзалга озатты.

Барып житсәләр, ни галәмәт, дистәләгән татар-башкорт ирләре ике урысны перрон идәненә салып типкәлиләр. Тын алырга тукталган шикелле, бер арада усал итеп сүгенгән сүзләре дә ишетелгәләп куя.

—Без Колчакка сезнең Учредилка күселәре Өфегә килгәч биргән вәгъдәләргә ышанып кушылдык бит. Сезгә аерым дәүләт, Идел-Урал штаты төзергә ирек бирәбез, дидегез. Мәскәүдән гайре, элеккеге Казан ханлыгы кебек булып, аерым яшәргә форсат тудырабыз, дидегез. Сезнең шул вәгъдәгезгә ышанып безнең алты татар-башкорт дивизиясе Колчак ягына чыкты. Уралдан Иделгә чаклы сугышып уздык, күпме туганнарны-кардәшләрне кырдык. Инде сезгә Казан белән Самараны да алып биргән идек.

—Менә шулчагында сезнең Мосолов белән Шульдин атлы карагруһларыгыз «Рәсәй—бүленмәс һәм бербөтен», дип кычкырып биткә төкерделәр. Хыялларыбыз челпәрәмә килде. Аннары «сезгә аерым башкорт дәүләте төзергә ирек бирәбез», дип Вәлидине большевиклар төп башына утыртты. Дәүләт урынына уч төбе чаклы җир ыргыткан булып, Вәлидигә капчыгын тоттырдылар. Шулай, аклар ни, кызыллар ни—нинди генә битлек кимәгез,—барыбер илбасарлар, татар белән башкортны изеп тотучылар сез.

—Хәзер, Япон белән Кытай ягына качкан чагында да, үзегез белән алмадыгыз безне, вагоннардан тибеп төшердегез. Большевикларга каршы кан койган чакта кирәк идек, кача башлагач артык кашык булдык...

Нәҗметдин белән Гыймади агай бераздан барысына да төшенделәр. Төнлә урыс әфисәрләре Урал ягыннан өч поезд китергәннәр, тик аларга үз хатыннары белән үз байларын гына утыртканнар икән. Ә заманында Колчак гаскәрендә яу чыгып, соңрак Зәки Вәлиди белән бергә большевикларга сатылмыйча һаман аклар әләме астында калган татар-башкорт яугирләрен урыс әфисәрләре, чыннан да, вагон баскычларыннан тибеп кенә төшергәннәр икән.

Исерек булу сәбәпле башка качаклардан аерылып калган ике урысны типкәләүче татар ирләренең берсе бәхетсез яңа танышларына күз яшьләре аша сөйләп бирде.

—Гарьләнмәслекмени, туганкайлар?! «Пош-шел, чурбан! Нужен ты нам, как собаке пятая нога!»—дип кычкырды бит берсе. Аннары ияккә китереп типте...

Вакытлыча тукталган йортка кабат җыйналгач, Мифтахетдин хәзрәтнең карары катгый яңгырады.

—Шулай, бер генә түгел, йөз поезд тапсалар да, урыс байлары безне алмаячак. Җан биргәнгә җүн бирер, ди Ходай. Җәяүләп кузгалабыз.

* * *

Юлда корбаннар калдыра-калдыра, алар егерменче елның көзендә Харбин шәһәренә барып элгәштеләр. Җирле халык үзе Ватаннарын «Манчжу-Го» дип атап йөри, ләкин Харбинны бөтенләй дә Кытай каласы дип әйтерлек түгел икән. Аны егерме-утыз еллар чамасы элек үк Көнчыгыш Кытай тимер юлын салучы урыслар нигезләгән. Хак булса, әле улчакта ук калада унбиш-егерме меңләп урыс яшәгән, ди. Дөрес, торабара алар «тел белмибез, дин безнеңчә түгел», дип кабат Амур аръягындагы Благовещенск, Чита, Хабаровск калаларына кайтып төпләнгәннәр. Ә соңгы ике-өч елда Харбин янә үксез мөһаҗирләрне үз канаты астына сыендыручы мәркәзгә әверелгән, монда Рәсәйдән җыелган качаклар саны кырык меңләп исәпләнә икән.

Әгерҗеләләр әүвәл, муенсадан өзелгән сәйләннәр шикелле як-якка таралышып, каланы энә күзеннән кичергәндәй кат-кат айкап чыкты. Кызык, сәер: Харбин Сөнгәр белән Амур елгалары бергә кушылган иңкүлеккә таралып урнашкан. Амурның суы зәп-зәңгәр, Сөнгәрнеке өстенә бодай саламы таратып салган сыман куе-сары икән.

Каланың үзәге, билгеле ки, тимер юл вокзалы урнашкан мәхшәр оясында. Монда елан күче сыман чәбәләнеп яткан тимер юллар, дистәләгән депо, санап бетергесез вак-төяк алачыклар. Вокзалга Сахалян, Мукден, Дайрен калаларыннан минут саен поездлар килеп туктый. Күбесенчә кытай белән японнардан торган пассажирлар тимер юллар тирәли тезелеп киткән алачыкларга кереп китәләр дә, кырмыскалар сыман күтәренеп калага ашыгалар. Бу алачыкларның кайсында кибет тә, кайсында келәтләрдер—һични аңламассың.

Вокзалдан тыш калада өч район бар. Иң якындагысы, җисеменә күрә исеме дигәндәй, Нахаловка икән. Монысын әле беренче тимер юлчылар ук нигезләгән, соңыннан Рәсәйдән качып килгән урыслар, казаклар да шушы ук районда тамыр җибәргәннәр. Әле ун-унбиш еллар чамасы элегрәк биредәге урыс йортлары арасына кытайлар да нигез корып караганнар да, киртә белән баганаларына тикле күршеләре талап бетергәч, тау башына күчеп, Фундзядяй исемле үз бистәләрен булдырганнар икән. Нахаловкада дистәгә якын кытай яки корея сәүдәгәре үз кибетләрен саклап һаман биредә калса да, Рәсәйдән яңа качаклар килүен белүгә үк, җирле хакимнәр ул соңгы «башсыз»ларны да Фундзядяйга дәүләт хисабына күчереп утырта, ди.

Харбинда соңгы биш-алты ел эчендә Яңа шәһәр дигән район пәйда булган. Билгеле ки, тоташы белән качаклардан гына торган өр-яңа бистә инде. Монда кем генә юк? Нәкъ Кавказдагы кебек хәнҗәр-кылыч аскан грузиннар урамы. Буйлы-буйлы халат яки сырган бишмәт кигән үзбәк һәм таҗиклар. Кавказ таулары һәм Караком сәхрәләре аша качып килгән хохол милләтчеләре. Хәтта, Балкан һәм Төркия аша урау юллар үткән поляклар, эстоннар бар.

Ләкин Харбиндагы качаклар дөньясын Нахаловкага урнашкан урыслар биетеп тота. Кытай каласы, чит-ят җир, дип тарсынып тормаганнар, әллә ничә оешма һәм җәмгыятьләр төзеп җибәргәннәр. Бистә уртасында очына күтәрелеп карасаң бүрегең төшеп китәрлек чиркәү үсеп чыккан, аерым епархия бар. Меркулов белән Медведев атлы бай казаклар монда әллә нинди Себер хөкүмәте төзеп өлгергәннәр. Болар Урал тавы буйлап йә, һич югы, Байкал аръягыннан Себерне Рәсәйдән аерып чыгармакчы. Боларның җырын качак урыс әфисәрләре белән казакларның башлыгы—симез гәүдәле,

керпе энәләре сыман тырпаеп торган кап-кара мыеклы атаман Семенов әләктергән, ди. Урыс качаклары Кытайның Шанхай, Дайрен, Мукден калаларына да таралып өлгергәннәр. Хәрби көчләре җиде йөзәр кылычлы кавалерия полкларыннан хасил, җайдакларының гомуми саны унбиш-егерме меңгә хәтле җитә икән. Өстәвенә, Кытай белән Төркестан чигендәге Сәйдүн каласында элеккеге Ырымбур казакларының атаманы Дутов та зур бер армия туплап өлгергән. Боларның хыяллары, яшәү кыйблалары аермачык инде. Качак әфисәрләр янә Рәсәйгә басып кермәкчеләр, янә хакимиятне үз кулларына кайтарып алмакчылар. Шул уй белән һәркайсының күзе-башы тонган, кала читендә көн-төн буе хәрби өйрәнүләр үткәрәләр, атыш тынып тормый.

Нахаловка районында элек үк нигезләнгән татар урамы булса да, әгерҗелеләр кытайларның Фундзяд бистәсендәге Феньдо-Олу дигән иң кырыйдагы, бер киң тыкрыгына җыелып урнаштылар.

—Иваннардан каберең ерак булсын,—дип хәлиткеч сүзне Мифтахетдин хәзрәт әйтте.—Алар белән тапма да, бүлешмә дә.

Дөрестерме-юкмы, элек Феньдо-Олу «Артиллерия урамы» дип атап йөртелгән, анда күбесенчә Көнчыгыш Кытай тимер юлын төзүче урыс инженерлары яшәгән, ди. Тик берзаманны тимер юл, туп эшен белгән мондый белгечләрне урлау канат җәйгән. «Хунхуз» дип аталган ул җинаятьчеләр калганнарыннан баш әйләнер дәрәҗәдә түләү таләп иткәннәр. Урыслар әүвәл кумәкләшеп кубып кытайларның кибет-заводларын җимереп караганнар да, мондый дуамаллык файда китермәгәч, берәм-берәм Нахаловкага чыгып таешканнар.

Нәҗметдин хаҗи хатыны һәм балалары белән әнә шул, элеккеге рус мөһаҗирләреннән бушап калган йортларның берсендәге ике кечкенә бүлмәгә кереп урнаша алды. Салавычта калган утарларны күз алдында тотсаң, мондагы каралтыларны йорт дип атарлык та булмагандыр инде. Ике катлы такта дивар уртасына йә пычкы чүбе, йә ком-таш тутырганнар да, шуны тышкы яктан балчык белән сылап, түбәсенә камыш ташлаганнар. Ходайга мең шөкер, салкыннар зәһәр түгел икән, түзеп була.

Килмешәкләр әүвәл кытайларга, аларның килеш-кыяфәтенә яраклашып китә алмый тәмам иза чикте. Ирләренең дә, хатын-кызларының да киемнәрендә аерма юк. Һәркайсы әчтән кыска гына бишмәт киеп куялар, шуның өстеннән—чабулары җиргә җиткән халат. Ни хикмәттер: боларның бишмәтләрендә дә, халатларында да сәдәфләр гел янда. Җитмәсә, бик күп ир-атлары озын итеп чәч үстереп, толым үреп йөри. Хатын-кызлары арасында алты-җиде яшьлек сабыйларныкы шикелле бәпбәләкәй табанлы кешеләр очрап тора. Боларны байбичәләр, кияүгә чыккач ирләрен ташлап чит-ят сөяркәләр янына китмәс өчен сабый чакта аякларына агач калып кидереп үстергән, диләр. И-и, әрекмән шикелле беркатлылар, и-и, сантыйлар! Башына ис тигән фахишәне балачакта кигән агач калып кына бозыклык юлыннан саклап калса икән! Аучыга юлыктым яки капкынга эләктем дип, кайсы бүренең авызындагы калҗаны кире биргәне бар?

Кытайларда башка сәер гадәтләр дә җитәрлек. Болар бәла-каза килсә яки кара көнгә дип мая туплап кую йоласын бөтенләй дә белми. Ризык кирәкме боларга, утынмы йә күмерме—асларына су кергән шикелле сикереп торалар да кибеткә йөгерәләр. Һәм ни галәмәт: кибеттә берсе-бер кирәк-яракны атналык итеп алмый. Болар киләсе елга, бераз үссенгә, дип, хәтта балаларга да кием алмый икән.

Нәҗметдиннең авызы тәүге мәртәбә менә шушы хәлләрне белмәгәннән пеште. Вокзалда очраклы рәвештә генә туры килгән бер таҗик алып-сатары аңа кырыкмаса-кырык төстәге ефәк-сатиннардан тегелгән хатын-кыз күлмәкләре тәкъдим иткән иде.

—Берсе җиде даян* гына. Син боларны җәй көне унбиш-егерме даянга да алалмыйсың. Дайренда кибетем янды, бөлгенлеккә төштем. Сиңа мөселман туганым булганга гына сатам,—дип, чәче белән җир себерергә әзер булып кыстады бит тегә.

Нәҗметдин шыр-томана түгел, кибетләрдә мондый тауарларның хакын күргәне бар иде. Үзен бик кәттә эшмәкәр итеп танытмакчы булды.

—Синең көя төшкән чүп-чарыңа җиде даян әрәм. Алтыдан бирсәң, алам.

Таҗик әрепләшмәде, яңа хуҗа куйган хактан аткарды да китте. Ә Нәҗметдин башка кибетләргә кереп тәкъдим итсә, биш даян хактан да алучы юк. Хәзер кыш башланган,

---

**Даян*—Кытайдагы көмеш тәңкә.

мондый күлмәкләрнең беркемгә кирәге юк, иң аз дигәндә дә боларны әле ике-өч айдан соң, анда да тугыз-ун даянга гына аткарып була икән.

Әлбәттә, хәзинәдә әле Салавычтан ук төйнәп чыккан байлык-нигъмәтнең зур өлеше калган иде. Өстәвенә, Таҗетдин абыйсы да туган ягына кире борылган чакта, Иркутскида аңа бөтен булган малын тапшырып китте. Ләкин алар—ахыр чиккә дип төйнәп куйган мая; Нәҗметдин хаҗиның әлеге хәзинәне җилгә чыгарып җилгәрергә исәбе юк иде. Хатыны Разия белән утырып кат-кат уйлаштылар.

—Без аларның телен белмибез, кытайлар безне кочак җәеп каршыламас инде,—дип уфтанудан башлап китте хаҗи.—Аннары, без алар өчен, барыбер, килмешәк, барыбер, артык кашык. Шуңа күрә урыслар ягына авышыбрак йөрү файда бирмәс микән? Дөрес, кытайлар җирендә алар да безнең кебек үк эт типкесендә. Мәгәр чыбыркы яки бүре-мазар күрсә, көтүдәге барча маллар төсенә йә нәселенә карамыйча бергә кушыла, бер-берсенә сыена, бергә укмаша бит. Менә мин таң белән үк урыс бистәсен әйләнеп кайттым әле. Ни хикмәттер, кытайлар урысларга тәүлегенә бер мәртәбә бушлай ашау оештырганнар. Аларга тагын яңа чиркәү ачарга рөхсәт бирелгән, ди. Урамнарында, йорт араларында иснәнеп йөрүче юк. Аннары, иң гаҗәбе шул: кытайлар урыс качакларының яңа килгән һәр төркеме өчен яңадан-яңа йортларны бушатып торалар.

—Урысның эчеп тузынуыннан йә талавыннан курка торганнардыр инде,—диде Разия төртмә тавыш белән. Аның иреннәре дә билгесез качакларны мыскыллаган сыман бөрешеп тора иде. Хаҗи каршы төште.

—Юк, җаныем, бер көтү качак каршында милләт кадәр милләт бөгелеп төшмәс. Миңа калса, урыс әфисәрләрен, ул Семенов белән Дутов җыйган полкларны Рәсәйгә каршы йодрык итеп кулланмакчы болар. Большевиклар белән сугышып кан коясылары килми, урысны файдаланмакчылар. Шуңа күрә, эткә сөяк ыргыткан шикелле бер тәлинкә аш өләшеп, аларны чылбыр очына бәйләп тотмакчылар.

—Ярар, урыс чукынып китсен, без ни эшлибез? Ничек җан саклыйбыз?—дип Разия әңгәмәне төп эзгә төшерде.

—Шуңа урысларның хәлен аңлаткан идем дә бит. Без аларның телен беләбез. Аларның төпләнүен күзәтеп, күреп кайттым. Попов дигән купислары монда да саллы гына сәүдә йорты, олы кабак ачып җибәргән. Түргә һаман да шул Николай патшаның рәсемнәрен тезеп куйганнар. Заманында Рәсәйдә байбичәләр типтереп йөргән Александр Вертинский атлы бик данлыклы җырчы хәзер монда кич саен тамак ялына, исерек көенә шансонетлар суза. «Смирнов» аракысы саталар. Кәбестә шулпасы, пилмән, кәтлит пешерәләр. Астагы киштәгә самавырлар чыгарып тезгәннәр, мәгәр аларны кайната белүче юк, ди. Сараенда унбишләп ат тора, аларын да юньле-рәтле караучы юк икән. Әллә... әллә шул Поповка ат караучы йә көнлекче булып эшкә керим микән?

Разия шундук кистереп каршы төште.

—Иркутски поездыннан тибеп төшерелгән туганнарың сине беркайчан да гафу итмәячәк.

—Ай-һай, хатын. Безнең татарлардан берәүнең дә бүген туйганчы ризык ашардай рәте юк. Артларында оядагы кош балалары шикелле бер кавым икмәккә тилмереп утыручы хатыннары, туганнары. Безне кытайлар үзләренә якын җибәрми. Алар әле, бөтенләй, татар халкының кем икәнен, нинди икәнен дә белми. Шулай булгач, телибезме, теләмибезме, беренче мәлдә урыс качакларына елышырга кала. Аннары... төшем, керем дигән әйбер дә бар бит әле. Әгәр урыска елышу безнең мәхәлләгә файда китерә икән, башында акылы бар бер генә татар да моңа аркылы төшмәс. Аякка баскач, кем белән уртак казан асарга мәслихәтләрен үзебез ачыкларбыз...

Өч көннән соң Нәҗметдин хаҗи белән элеккеге тегермәннәр хуҗасы Гыймади агай сәүдәгәр Поповта ат караучы булып эшли башладылар. Хәер, ат караучы гына түгел, ихата һәм ишек төпләрен себерүчеләр, самавыр куючылар, исереп егылган әфисәрләрне озатып йөрүчеләр, канга батып сугыша башлаганнарны аеручылар, утын кисеп бүкән яручылар—һәммәсе дә бер үзләре иде. Тора-бара, әтисенә ияреп, кечкенә Касыйм да кул арасына керә башлады. Ул ут уйнатып самавыр куеп йөри, йөгертеп өстәл сөртә, «ә» дигәнче ялт иттереп итек чистартып ала. Килмешәк бала елгырлыгы исерек әфисәрләр күңеленә аеруча хуш килә, күрәсең. Болар аяк яллык хәерне кызганмый ыргыталар. Өйгә кайтып кесә бушатканда Касыймның табышы бик еш кына хаҗинықыннан да узып китә иде. Шуңадырмы, Разия телендә һәр кич саен яңадан-яңа «игәү-пычкы» пәйда була торды.

—Урыс аракысы иснәп бозылганчы Касыймны эштән туктат. Чит-ят артын сөртеп йөргән ялчыдан юньле кеше чыкмас. Баланың горурлыгын издермә. Үзенә дә чит кавемнәр алдында бил бөгүләр җитәр. Үз учагыңны як, үз шөгыленне булдыр. Мин дә тик кенә ятмам, акмаса да тамарлык итеп үз кәсебемне җайлап җибәрермен әле...

Разияның кинаяләре нигезсез булмаган бит. Бактың исә, ул да кай арададыр күрше урамнардагы кытай хатыннарын катык суы белән чәч юарга өйрәткән, серкә-селте ясап сата-сата үзенә бер кәсеп ачкан икән. Өстәвенә, кытай хатыннары кибеткә йөрү гадәтен бик үк белмиләр, ди. Разия энә, җеп, кереш, төймә тотып өй борынча йөри башлаган. Тора-бара ул әле икмәк пешереп сату турында да хыяллана икән.

Беркөнне Попов йортында әфисәрләр кара төн уртасы җиткәнче ду китереп эчте. Араларында Хара-Таган атлы бер калмык әфисәре дә булган икән, ике рус качагы шуны тиктомалдан кыйный башладылар. «Толкач» кушаматлы бер симезе ахырдан калмык әфисәренең баш түбәсенә чәйнек сыман түгәрәк шешә белән орды. Калмык һушсыз ауды, ә Нәҗметдингә лаякыл исерек «Толкач»ны олау белән өенә илтеп куярга әмер җиткерделәр.

Бугаз киереп җырларга маташкан «Толкач»ны көч-хәл белән тыя-тыя гына кайтыр юлга чыктылар. «Ротмистрлар чүлмәге» дип атап йөртелгән тыкрыкка җиткәнче тирән ерым аркылы үтәсе бар иде. Шул чокыр төбенә төшеп килгән чакта тарантас үрәчәсенә күтелмәгән шәүлә сикереп менде. Төн бик караңгы булса да, тәгаенләде хаҗи. Попов кабагында һушсыз ятып калган Хара-Таган бит бу.

—Т-с-с, сөйләшәсе булма!—дип гыжылдады калмык. Аның йөзе, муены, иңбашлары канга батып беткән иде, ахрысы, гәүдәсендә уч төбе кадәр чиста бер җир дә юк.

—Далага таба каер!

Чита бистәсен калдырып куе чытырман булып утырган таллыкка керүгә үк Хара-Таган итек кунычыннан ялтырап торган пычак чыгарды да күз ачып йомганчы аны корбанының муенына батырды. Усал кысылган тешләре аша берничә сүз саркып ишетелде.

—Чыңгызхан нәселе дип аталам мин. Урыс алабаена ханнар каны харам!..

Чокырланып торган бер иңкүлектә Хара-Таган арбадан әүвәл әфисәр мәетен тибеп очырды, аннары мәче сыман тавыш-тынсыз гына үзе сикереп төште. Дилбегәне кай арада эләктереп өлгергәндер, атны да ул туктатты.

—Мин сине белмим, син мине күрмәдең. Исән-имин яшисең килсә, сөйләнеп йөрисе булма!

Соңгы сәламе итеп Хара-Таган Нәҗметдиннең куенына бер төргәк акча китереп тыкты. Бер сәгать гомер эчендә күргән кыямәтләрдән тынсыз-өнсез калган хаҗи кабат һушка-зиһенгә килгәндә калмык әфисәре торган аланлыкта җилләр генә исә иде инде.

* * *

Нәҗметдин хаҗи яңа ел башында Нахаловкада, урыс качакларыннан бушап калган йортларның берсендә кечкенә генә кибет ачып җибәрде. Киштәләрдә күз кызарлык байлык әлләни юк иде. Күбесенчә тәбе, бизмән, көрәк, балта, сүс һәм каеш баулар, дегет һәм балавыз, тагын шуныңише хуҗалык вак-төяге. Беренче мәлләрдә кибеткә керүче бөтенләй булмады, аптырагач хәйләгә тотындылар. Нәҗметдин хаҗи каяндыр »уфалла« эшләтеп алып кайтты да шуның белән барча урамнарны, аеруча Фундзядяй бистәсен урап йөри башладылар. Яңа урам башына килеп кергән саен хаҗи чиләк төбе кага, Касыйм ала-тилә сүзләр кушып бар белгәнен кычкыра:

Балта сатам, пила юк,
Бер балтага биш юань*,
Балтасыз да яшәсәгез,
Ялкау кулыңнан куан.

Бәләкәч сәүдәгәрнең җырлабрак сузган тавышын ошаталар иде, ахрысы, калага чыккан һәрбер сәяхәтләре диярлек төшемле генә барды. Тик Нәҗметдин хаҗиның килеш-кыяфәтенә генә канәгатьлек билгесе бер дә өстәлмәде.

**Юань*—Кытайдагы вак акча.

Ул кич саен авылдашларын, якташларын барларга чыгып китә дә караңгы төн уртасы җиткәндә генә кире әйләнеп кайта. Бик сирәк кичләрдә генә ишектән кулларын уа-уа сөйләнгәләп керә.

—Бүген Гайнулланы химия фабрикасына каравылчы итеп урнаштырдык, Ходайга мең шөкер. Тагын Хәлиулла белән Агишка да эш табасы иде бит. Алар элмәккә менәр хәлгә төшеп яшиләр, балаларының кыяфәтләренә еламый карап булмый.

Феньдо-Олу урамына качаклар һаман өстәлеп тора. Владивосток, Находка, Сәйдүн, Мукден, Кытайның Мудадзян, Тәнсин калалары аша әйләнә-әйләнә элеккеге Апанай, Үтәш, Арыслан, Әҗем, Алтынбай, Адут атлы байлар килеп төште. Аллага шөкер, болар ике-өч тел белә, эшне тиз таптылар. Ләкин балаларны куярга-беркетергә бер урын юк. Болар йә озын көн буена ни кылырга белмичә, бер ишектән икенчесенә сугылып каңгырашып йөриләр, йә нинди дә булса бәхәс чыгарып үзара ызгышалар.

Бәлане Тирсә мулласы Мифтахетдин үзенчә хәл итте:

—Элек кибет булып торган Карташевлар йортыннан бары да чыгып качкан. Мин карап кайттым, мәчет ачарга ярый. Вилаятьләреннән рөхсәт алабыз да мәхәллә оештырабыз. Шуның артыннан ук, Аллаһ боерса, мәдрәсә эшли башлар.

Күмәк йөри торгач һәммәсе хәл ителде. Мәхәлләгә дә, мәдрәсәгә дә «Исламия» дип исем куштылар. Малайларны Мифтахетдин мулла белән Уфадан килгән Зариф казый, кызларны Касыймның әнисе Разия белән Апанай бай хатыны Рәшидә абыстай укыта башлады. Иртәнге азан тавышларын ишетеп, яше-карты тураеп һәм кукраеп йөри башлады. Инде барысы-барысы да әйбәтләнүгә таба китәр кебек иде.

* * *

Кытайга Төркестан чигендәге Сәйдүн каласы аша чыгып качкан татарлар, чит-ят кавем сыман, байтак көннәр буе Харбиндагы Казан кардәшләреннән ятсынып, качып йөрде. Казан татарлары аларның хәлләренә кергән төсле тәүге көннәрдә болайрак сөйләштеләр.

—Яуш хәзрәт, Тройскида көн беткәч, Балхаш буендагы Кызылъярга качып мәдрәсә тоткан кеше. Иж-Бубидан качкан Габдулла Чыңгыз да ничәмә-ничә еллар буена Төркестанның Гөлҗа каласында кыргыз-кайсак балаларын укытып йөргән. Икесе дә тәрәккыять юлындагы фидаилыклары өчен кадер-хөрмәт күрми интеккән кешеләр бит. Алай гына да түгел, Ишми ишан шикелле томана зобанилар үче белән куылган мөгаллимнәр. Вакытында аларны аралап-яклап кала белмәдек. Шаять, шуңа күрә һаман бездән сакланалар, һаман үчлеләрдер. Авызың бер пешсә, үпкә-рәнҗү бик тиз онытылмый шул.

Тик заманында татар арасыннан казакъ даласына качкан кардәшләрнең дәшми-аралашмый йөрүләренә элек эт типкесе хәленә калулары гына сәбәп булмаган икән. Кыш кергәч Харбинда Төркестаннан үзләренең нәселләре, яраннары белән качкан Аллаяр паша, Әкбәр Гали, Иргәш, Сәлимхан бәк атлы байлар пәйда була башлады. Шулар Феньдо-Олу урамындагы өч-дүрт татар ирен кыйнап ташладылар. Аңлатмалары да кайнар, саллы булды.

—Шул, сезнең Казан татарларыннан төзелгән атлы бригада гына башка җитте безнең. Шуларның Шамил Госман атлы, Нурулла Вахит, Якуб Чаныш атлы комиссарлары безнең телне, безнең юлларны белүдән файдаланып, командарм Фрунзе кул астындагы кызыл җәлладларны Фиргәнә белән Бохарага тикле китереп җиткерделәр.

—Өстәвенә, элек бездә мөгаллим булып йөргән күпме татар, шымчы сыман, алар ягына ауды. Җыен әтрәк-әләм, җыен батрак шулар кулы белән хат язганнар да, имеш, «бәкләр көн күрсәтми, кара халыкны талый» дип, Мәскәү тарафыннан ярдәм чакырганнар. Большевиклар шуны гына көтеп торган икән. Кылычларын айкап шундук басып керделәр. Әүвәл Хива ханлыгын сытып үткәннәр иде, аннары Бохара әмирлеген юкка чыгардылар. Кокандка, Җәләлетдин каласына чигендек, тауларга качып карадык. Анда да килеп җиттеләр. Чөнки алларында кызыл җәлладларга сезнең сатлык Казан татарлары юл күрсәтеп барды. Моннан ике йөз элек сезнең ерак бабагыз генерал Тәфкилев Чыңгызханнан калган Ак вә Күк Урдаларны Елизавета белән Әби патшаларга ничек саткан булса, бүген нәкъ менә сез безне урыс итеге астына илтеп салдыгыз, дәүләтебезне, азатлыкны тартып алдыгыз. Сез урыслар колы, мөселман туганнарыгызны вә иманыгызны саткан кавем икәнсез бит. Без сезне гомер буе каргап яшәячәкбез...

Татарлар йөзләренә дегет ягылган сыман кара көеп йөри башладылар. Шәхсән

үзләренең кыргыз, үзбәк, казакъ байлары алдында гаепсез икәнлекләрен дә аңлыйлар, әмма кичәге туган-тумачасы өчен гарьләнү хисе, барыбер дә, күз ачарга ирек бирми иде. Ярый әле, бер атна чамасы вакыт үтүгә, барча Рәсәй качаклары өчен сөенечле хәбәр килеп ишетелде.

—Бишкәк белән Фирганәдә җирле халык большевиклар хакимиятенә каршы баш күтәргән. Кытай чигендә торган бер полк солдат тулысы белән фетнәчеләр ягына чыккан. Хәзер Кытай белән Төркестан арасындагы чикләр ачык. Атаман Дутов үз армиясе белән Сәйдүннән Җәркән каласына һөҗүм итәргә әзерләнә икән.

Харбинда качак урыс әфисәрләре җыелып яткан Нахаловка бистәсе таяк тыгып болгаткан кырмыска оясы шикелле хәрәкәткә килде. Алардан күрмеш, Төркестаннан килгән уйгур, калмык, нугай, казакъ ирләре дә кылычларын кайрый башладылар. Барча качакларны яңа өмет чаткысы даладагы ялгыз учак сыман үзенә тарта иде.

* * *

Ишек-тәрәзәләренә бик эләргә әзерләнеп йөргән чакта Нәҗметдин хаҗиның кечкенә кибетенә Алыптай гәүдәле, таныш түгел ир-ат килеп керде. Бишмәт якасын бастырып куйган, киң кырыйлы фетр эшләпәсен кашларына хәтле төшереп кигән, болай да салынкырак күренгән ияк астына түгәрәк сакал җибәргән—сагаерга бик тә урын бар: теләсе кем күзенә чалынып йөрергә исәбе юк моның. Һәм ул, чыннан да, кибет эчен көйдергеч карашы белән айкап чыккач кына тыелып авыз ачты.

—Кордон аръягыннан мин. Таҗетдиннән сәлам алып килдем. Абзыеңмы әле ул синең?

Нәҗметдиннең тораташтай хәрәкәтсез калуын шәйләп алды бугай, күкрәк кесәсеннән чыгарып конверт сузды.

—Менә хаты.

Сәер кунак ишек эргәсендә урын алды, Нәҗметдин калтыранган куллары белән хатның читен ертты. Шакмаклы кәгазь битенә ермачланган кош теледәй бер хат. Кыска гына сүзләр. «Исән-имин авылга кайтып җиттем. Бары да элеккечә. Утарны сүтмәгәннәр. Маллар сатып алдым. Кабат элеккечә яшәп китәргә исәп тотып йөрим. Нияткә килсәң, сиңа да урын җитәр. Көтәбез, кайт. Таҗетдин борадәрең.» Соңгы ике сүзе артык, Нәҗметдин хәрефләр язылышына карап та абыйсының кулын ансат таный иде. Капкын өстенә китереп баскан төсле кымшанырга да белмичә аптырап торды. Үлемгә тиң элмәк көйләнеп кенә ята, аны сәер кунак кидерәчәк икән.

—Абыеңның сүзләрен хәзер мин дәвам итәм. Әнә, янында кисмәк тора, шуңа утыр да тыңла,—дип кырыс әмер аһәңе белән башлап китте ул.

—Мин, чыннан да, кордон аръягыннан. Мәгәр синең абзыеңнан хат китерер өчен генә дип Әгерҗедән Кытайга хәтле юл үтмәдем инде, анысын чамалыйсыңдыр. Миссиям бүтәнчәрәк. Мин—син уттан-судан курыккан шикелле ташлап качкан совет иленДәге кызыл комиссармын. Атым—Касыйм Чаныш. Совет хөкүмәте тарафыннан атаман Дутов даирәсенә үтеп керү өчен җибәрелдем. Аның штабында сезнең Салавычка терәлеп торган Уразай авылыннан чыккан Каюм хәлфә тылмач булып хезмәт итә икән. Ул синең кордашың, сез бер-берегезне яхшы беләсез, дип ишеттек. Син мине әнә шул Каюм хәлфә белән таныштырырга, юк, кавыштырырга тиеш. Калганын андагы хәл үзе өйрәтер.

Нәҗметдин авызын бик сак кына ачты.

—Мин Харбиннан Сәйдүнгә хәтле юл чыгарга тиеш буламмыни?

—Атаман Дутов үзе сине эзләп бирегә килмәс бит инде.

—Әгәр мин бармасам?

—Бармыйсың икән, Таҗетдин агаң белән хушлашасың инде.

Нәҗметдиннең итәк-чабуына тере елан ыргыттылар диярсең, хаҗи урыныннан капылт сикереп торды.

—Син, син! Кызыл җәллад! Абыемның монда нинди катнашы бар?—дип буылакалтырана кычкырып җибәрде ул.

Касыйм Чаныш учакта күмер болгатып утырган юлчы ваемсызлыгы белән Нәҗметдин итәгенә янә ут ыргытты.

—Социалистик революцияне кулга ак перчаткалар киеп кенә ясыйлар, дип уйлыйсыңмы әллә, сасы буржуй? Бернинди корбаннар да булмасын, кан да тукмә, шулай уйлыйсыңмы? Ай-яй, оста! Берегез дә талап җыйган байлыгыгыздан җиңел генә баш

тартырга, йә булмаса сабан артына җигелергә җыенмый бит әле. Алай гынамы соң? Шул таланган, урланган байлыгыгызны төйнәп, менә, Кытай җиренә хәтле элдертәсез! Ә без, имеш, Дутовның монда олы бер армия туплап ятуына да күз йомарга тиеш. Син безгә ярдәм итәргә теләмәсәң, синең абзаңа да кагылма, тимә икән. Акылың котмы, хаҗи? Түгелме? Алай икән, юк, абыеңны гына түгел, совет хөкүмәте өчен кирәк булса, әле Пермьга кияүгә чыккан сеңлеңне дә, Салавычта калган кардәшләреңне дә утлы табага бастырып биетәбез без. Икенең берсе. Сезнең каршыда кияүгә чыгарга ялындырып торучы кәләш алдына барып тезләнгән шикелле түбәнсенүләр бетте. Йә әнә шул Дутовлар канаты астына җыелып сез безнең башны ашыйсыз, йә революция җиңә. Күперләр яндырылган, артка юллар ябык. Инде аңладыңмы?

Нәҗметдиннең ирексез рәвештә аяк кагып куюдан башка чарасы юк иде.

* * *

Каюм хәлфә белән очрашуга Касыйм комиссар тагын пәһлевандай ике ирне ияртеп килде. Болар килештергән: таныш түгел ирләр иңнәренә үзбәк халатлары киеп алганнар, билләрендә алтын-көмеш йөгертелгән хәнҗәр-кылыч, иярләренә тикле шау бизәктән иде. Атаманга бүләккә дип саф көмештән коелган кылыч элэктергәннәр, яннарында бик шәп сыйфатлы бәрхет халат та бар. Өчесе тиң үзләрен эре бәрәңге ашаган шикелле бик кәттә тоталар, яннан басып күзәткән Нәҗметдин хәтта онытылып, гаҗәпләнеп торды.

—Минем меңбашлары Мәхмүт әмир илә Йосыф паша. Шулар белән бергә Алатау-Ачыкүл арасын елдан артык үз кулыбызда тоттык,—дип Каюм хәлфәнең күзенә төтенне Касыйм Чаныш өрде. Каян, ничек өйрәнеп өлгергәндер, үзбәкчәне дә борчак сыман сибә иде.

—Кызыл полклар безне, «басмач, басмач» дип мыскыл итә-итә, бүре көтүе кебек куып килә. Сәхрә иркен, большевик этләренә бирешергә исәп юк-югын. Мәгәр аеры йөрсәң, тәүге падишаһыбыз Аттила хан әйтмешли, ялгыз укны сындыруы ансат. Уклар бер садакка, бармаклар бер йодрык булып тупланса, шунда бөтен куәт. Менә шуңа күрә атаман Дутов белән кушылуда инде безнең исәп. Алайдагы меңәрләгән нәүкәрләр шуны көтеп калды. Мәсләк-кыйблаларны тәгаенләү өчен атаманның үзе белән бер дәстархан өстенә утырып сөйләшергә кирәк. Әйдә, атаман белән күрештер син безне, наиб Каюм...

Юлга чыккач Нәҗметдин шаклар катты: «җете кызыл» комиссарлар да шаяра белә икән.

—Кыргыз-кайсак далаларында сезнең атаманның чын фамилиясе Адутов, аның әтисеме, бабасымы Пермь тирәсендәге иштәкләрдән аерылып Җаек буена күчкән, шунда чукынган икән, дигән имеш-мимеш йөри, шул дөресме, наиб? Сине дә тиккә генә үзенә якынайтмаган, элеккеге якташлыгың-кардәшлегең юл яргандыр инде.

Бөтенесе тиң кычкырып, дәррәү көлештеләр. Каюм хәлфә күңеленә Касыйм комиссарның «наиб» дип күпертүе хуш килгәндер инде, ул бөтенләй туарылып китте.

—Кемнәр белсен инде? Аның да күз кабаклары минекедәй кысынкы, яңаклар? бүртеп тора. Чокынсаң-казынсаң, якташ-кардәш булып чыгуың да мөмкин. Бәлки, үзе юри генә әйтми йөридер ул...

Алла Сәйдүн манаралары күренүгә «меңбашлары»ның йөзе шундук җитдиләнде. Генерал дәрәҗәсен йөртүче атаман шәһәр читендә аерым кирмән корып яши, аны тулы бер эскадрон саклап тора икән. «Меңбашлар»ны да, Нәҗметдинне дә биек капка аша эчкә кертмәделәр. Чаптарларны яндагы бер йорт ихатасында солыга кушарга, җайдакларның үзләренә чолан күләгәсенә кереп ятарга туры килде. Ухылдый-ухылдый, янакөя көтеп әллә ничә сәгать үтеп китте. Инде төн уртасы җитеп килә иде. Ниһаять, кирмән капкасында Каюм пәйда булды.

—Генерал сезне дә өстәл янына дәшә. Андый дәрәҗә-хөрмәт һәрбер кунакка да тәтеми, моны белегез.

Каюм тылмачның ук теле хәтәр кәрмәкләнә иде, атаман исә үзе бөтенләй исерек булып чыкты. Янында тагын бер полковник кына янтаеп утыра, анысы да ләх исерек иде.

Касыйм комиссар белән аның «меңбашлары» һәрбер хәрәкәтне алдан ук килешеп куйганнар ахрысы. Атаман өстәле янына килеп җиткәнче үк «меңбаш» Мәхмүт Каюм тылмачның муен тамырына алтатарының сырты белән орды. Икенче секундта Йосыф «паша» да исерек полковникның баш түбәсенә буш шешә алып дөңгелдәтте. Аутовның

баш чүмеченә ниндидер чүлмәк белән кундырып, Касыйм комиссар үзе аны хәл итеп өлгерде. Атаманга әллә каян гына хасил булган олы капчык кидерә башладылар. «Басмачлар» арасында һичнинди ыгы-зыгы юк, һәммәсе дә майлап куйган шикелле бара иде. Ишек катында Каюм тылмачның баш калкытуын һичкем шәйләмәде. Төнге тынлыкны ярып мылтык аткан тавыш яңгырады. Ул тынуга, атаман йортын Касыйм комиссарның корыч әмер авазлары күмеп китте.

—Мәхмүт, Йосыф, тышка йөгерегез! Атларны капка төбенә китереп бастырыгыз! Мин Дутовны үзем алып чыгам.

Юк, атаман кадәр атаманның үзен урлап качарга насыйп булмаган икән шул. Кирмән диварлары артыннан да икеме-өчме атыш тавышы яңгырады. Нәҗметдин күреп торды, атаман бик симез, Касыйм комиссарның бер үзенә генә аны күтәреп йөгерү мөмкин түгел иде. Шуны аңлады, күрәсең, Касыйм Дутовны бер мизгелдә дөмбердәтеп баскычка ташлады да, алтатарын атаманның муенына терәп, котырына-котырына тәте угына басты. Атаманның гәүдәсе апра сыман җебеп төшкәч кенә, зәңгәрле-кызыллы тавышлар чыгарып, Нәҗметдингә әмер ташлады.

—Минем арттан йөгер, җебегән җан!..

Дутов сакчылары, туктаусыз ата-ата, аларны бер фәрсах чамасы куып карадылар. Ләкин Касыйм комиссар кешеләрен меңәр атлы көтүләрдән сайлап алынган иң шәп чаптарлар алып качкан иде шул, эзләренә баса алмадылар. Әмма кансыз хыянәт өчен үч алу дигән хис гарасат-давылдан кайтыш түгел, ул сине барыбер дә куып җитә икән.

Нәҗметдин Харбинга әйләнеп кайтуга тулы бер ай чамасы да вакыт үтмәгәндер, аның кибетенә караңгы төн уртасында килеп ут төрттеләр. Барча байлык хуҗаларның күз алдында бөртегенә тикле янып бетте. Үкси-үкси аеруча Разия өзгәләнде.

—Тернәкләнеп киткәч, аякка баскач кына бит. Кемнәр генә каһәрли дә, кемнең каргышлары гына төшәдер инде бездәй илсезләргә?

—Язмыштан узмыш юк, барысы да Аллаһ кулындадыр,—дип юаткан булды хаҗи үз хатынын.

Берничә көннән соң мәчеттәге Мифтахетдин хәзрәт ерактан ияк каккан сыман гына итеп чеметтереп узды.

—Атаман Семенов янына Уразайдан Каюм хәлфә килеп киткән иде. Ул һаман да мәрхүм Дутов армиясендә уралып йөри икән.

* * *

Харбинга сыенган татар качаклары шул ук елның май ае уртасында мәчет йортында манара күтәрергә һәм аның түбәсенә ай куярга булдылар. Кала хакимияте тарафыннан каршылык юк, мәхәлләдәге диндарларның кәефе күтәренке, күңелләре көр иде. Барыннан да бигрәк Мифтахетдин хәзрәт очынып-янып йөрде.

—Борынгы Болгар җирендә Алмыш хан ислам динен кабул иттергәнгә тәгәл бер мең ел тула. Мәчетебез манарасына ай куюны нәкъ шул көнгә, уникенче майга туры китерәбез. Читкә тибелгән мөһаҗирләр ди-ди каңгырып яшәп булмас. Үз кадеребезне үзебез белик, тарихи Ватаныбыз белән бер булып яшәргә өйрәник әле...

Билгеләнгән көнне, әче таңда ук, барча татар мәчет янына җыела башлаган иде инде. Әмма булачак тантана хакында татар гына түгел, Харбиндагы барча мөселманнар ишетеп өлгергән икән. Әле иртәнге намазга чакырган азан тавышлары ишетелгәнче үк Феньдо-Олу урамына үзбәк, казакъ, кыргыз, нугай, башкорт, таҗик качаклары килеп тулды. Һәммәсе дә бәйрәмчә киенгән, йөзләре якты, телләреннән бал тамып тора.

—Безнең беребезнең дә һаман мөстәкыйль мәхәлләсе юк бит әле. Без күбрәк дала-сәхрә сәяхчеләре шул инде, сезнең сымак гыйлемле, мәдәниятле, диндар халык түгел. Мәгәр без дә сезнең кардәш-туганнарыгыз, Аллаһ колларыдыр. Ходай тәгалә алдында олы савап булыр, без дә аның ошбу җиһандагы йортын ачуны манзара кылыйк, Коръәни Кәрим аятьләрен аның Җәнабына ирештерик әле.

Татарларның, әлбәттә, кочаклары ачык, күңелләре дала киңлекләре кебек иркен, чиксез иде. Күкрәкләренең иң түреннән кайнап чыккан җылы сүзләрне бер дә кызганмадылар.

—И-и, рәхим итегез, туганнар, мәйлең, мәйлең. Гамәл-гыйбадәтләребезне, әҗер савапларыбызны уртаклашырга килгәнегез өчен без чиксез шат...

Тәүге азан тавышларын ишеттерергә санаулы минутлар гына калган иде, көтелмәгән күңелсезлек-бәла килеп туды. Шушындый тантана, бәйрәм көнендә дә тавыш-гауга кубар дип кем уйлаган?

Ул мәчет ихатасы уртасына куелган сәдака тартмасы янында кабынып китте. Элек бер-берсен күралмаган ике дошман кеше туган-үскән җирдән фәлән мең чакрымда, җиде диңгез аръягында, һәрбересе эт типкесе хәлендә йөргән көе йөзгә-йөз килеп очрашканнар икән.

—Безнең мәдрәсәне яптырган мәхлукъ, соран йөзле, монафыйк бәндә бит бу! Җир йөзе синең ише надан зобанины ничек күтәреп йөри?—дип башланган беренче авазга ук, ихатага тупланган йөзләгән мөселманнар тавыш тарафына таба борылып басты.

Әгерҗелеләр шундук таныдылар. Сугышырга чыккан әтәч сыман мәйдан уртасында кукраеп торганы заманында Иж-Буби мәдрәсәсеннән куылган, аннары Төркестанның Гөлҗа каласына качып кына гомерен, денен, гыйлемен саклап калган фидаи җан Габдулла Чыңгыз иде. Икенчесе—кайчандыр Буби мәхәлләсендә имам-хатыйб булып торган Габдрахман Кәрим. Аны гел йә Ишми ишан, йә губернатор Камышинский янында койрык болгап йөргән өчен якташлары бер дә сөймәделәр. Нинди юллар белән Харбинга килеп эләккән ул, аны кем юллаган, бүгенгәчә кайда качып яткан?—белүче юк иде.

Казакъ, үзбәк, кыргыз ирләренең бик сәерсенеп текәлүен шәйләгәндер, ахры, Габдулла Чыңгыз аңлатуга күчте.

—Ишми ишан атлы томана зобани илә менә шушы куштан безнең Иж-Буби мәдрәсәсен куып тараттылар. Шушы шакшы бәндә Габдулла илә Гобәйдулла хәзрәтләр өстеннән нәҗес тулы шикаятьләр язып, аларны Сарапул исправнигы Зотовка ташып йөрде. Шул шикаятьләрне сәбәп итеп Гобәйдулла мөгаллимне зинданга ябып куйдылар. Мөхлиса абыстай—Тройскига, Габдулла хәзрәт Төркестанга качып кына бәладән котылып калды. Тәрәккыять вә иттифакъ яклы барча мөгаллимнәрне явыз Ишми ишан белән шушы соран төсле, кара йөзле кадимчеләр генә тотып ашадылар.

Мәйданга җыелган мөселманнар май сибелгән учак сыман капылт кабынып китте.

—Бәйрәм-гыйбадәтләребезгә кер йоктырып йөрмә! Синең ише хыянәтче вә кадимчене динебездән сөрәбез!

—Исән чакта ычкын моннан, хаин!

Габдрахман Кәрим колакларын учлары белән томалап шундук мәчет ихатасыннан чыгып сызды. Мәйдан гына түгел, диндар инсаннарның күңелләре-җаны агарып, чистарынып калган кебек булды.

* * *

Качак татарлар тәкъдиренә Кытай җирендә бөтенләй искә-зиһенгә китереп тә карамаган кайгы-хәсрәтләрне дә күрергә язган икән.

Беркөнне Разия кибеткә ишек төбеннән үк кычкырып килеп керде.

—Нәҗметдин, җыен! Итче Госсам кызы Сания үзенә кул салырга йөри. Бичараны урыс солдатлары су буенда тотып көчләгәннәр.

Кибет ишекләрен аннан-моннан бикләп, Нәҗметдин Разияга ияреп йөгерергә мәҗбүр булды. Әрхүн дип аталган кечкенә инешкә хәтле ара ерак иде, сулышы капсабуылса да Разия юл буена әлләниләр тезде.

—Сания кер чайкарга төшеп киткән булган. Исерек урыс солдатлары килеп ябышканнар... Егерме дә юк иде бит әле бичарага. Итче Госсам болай да кай тарафка яучы җибәрергә белми аптыраган иде. Хәзер ни эшләрләр? Саниясы чынлап торып кул салмаса гына ярар иде... Әллә Госсамның тегендә кылган кыек эшләре өчен Ходай каргышы микән соң бу? Госсам тегендә ике кызыләрмиснең башын кыйганые бит. Иллә мәгәр ул каргыш дигәннәре нишләп атаның үзенә түгел, балаларына килеп төшә икән? Нигә болай гадел түгел тәкъдир?..

Сания янында ике хатын утыра булып чыкты. Алар кызның ике кулыннан да нык тотканнар. Юатмакчы, искә-акылга килергә чакырмакчы булалар. Ләкин Сания миңгерәгән, зиһенен тәмам җуйган, күрәсең. Ул аз гына тукталып тора да, аннары башын колын сыман чайкый-чайкый, яңадан үкереп еларга тотына. Кызның күлмәк изүләре бил тиңенә тикле умырылып төшкән, алсу күкрәк очларында тирән теш эзләре, ботлары, беләкләре кара янып чыккан.

Госсам үзе күршедәге Сорнай авылына ит җыярга дип чыгып киткән булган, ул кичке эңгер-меңгер төшә башлаганда гына килеп җитте. Кызы янына иелеп, юатып та тормады, бер генә сорау бирде.

—Кайсы хәшәрәтләр сиңа кулын сузды? Исемнәрен сана.

Җавап өр-яңадан кабынган елау-сыктау аша килеп ишетелде.

—Берсе—Попов кабагында эшли торган Федор. Икенчесен белмим. Анысы Микулай әфисәр янында деньщик булып йөри.

—Табарбыз, ачыкларбыз,—диде Госсам боз шикелле салкын тавыш белән. Бераздан, искәрткән шикелле, өстәп куйды.

—Урыс белән якынайсаң, балтаң янында булсын, дигәннәр. Валлаһи, хак икән. Шушы урысларга күрше авыллардан күпме ит ташыдым, рәхмәт урынына биткә төкерделәр. Иленнән куылып чит җиргә китсә дә, урыс барыбер урыс булып кала. Янда балта юк-югын. Мәгәр ул ике вәхшине акылга утыртырга шушы пычак та ярап торыр әле.

Госсам итек кунычыннан беләк озынлыгы сугым пычагы тартып чыгарды. Ирләр-хатыннар искә-ушка килеп өлгергәндә ул абына-сөртенә Нахаловка бистәсенә таба йөгерә иде инде...

Аның җеназасын караңгы төн уртасында иске чыптага салып кайтардылар. Хәбәре дә шул ук төндә кайтып ишетелде. Госсам сәүдәгәр Попов йортына килеп кергәч Федор атлы ялчыга пычагын батырып өлгергән, әмма үч алуны котеп йөргән «кәсептәше»-деньщик аның сыртына да сәнәк белән китереп кадаган икән...

Шәһәрнең баш-башында күптән түгел генә нигезләнгән яңа зиратларда икенче көнне ике кабер артты.

* * *

Ярты ел чамасы вакыт үткән иде, Сания бичараның исеме янә халык теленә менде. Нәҗметдин хаҗига бичара кыз турындагы хәбәрләрне һаман да шул Разия ирештерде.

—Сания бозык юлга кереп киткән бит, әтисе. Госсамның вафатыннан соң хатынын зәхмәт суккан, ул урын өстендә ята. Кечерәк энекәш-сеңелләренә ризык таба алмагач, Сания теге бирән Попов янына барган, урыс әфисәрләре аракы эчертеп кызыкайны ятакларына сала башлаганнар. Сания хәзер төненә икешәр-өчәр урыс белән ятак бүлешә, ди. Сүзләр дөрескә чыкса, безнең бөтен татар милләтенә тап төшерә бит ул. Оят, хурлык!

—Шәп түгел, шәп түгел,—дип ухылдап сөйләнде дә, Нәҗметдин хаҗи байтак ара уйга калып торды.—Бу яман сүзләрнең мәчет, мәдрәсә тирәсендә дә ишетелүе бар бит. Кыргызлар, казакълар колагына керсә, күзне ачырмаслар. Берәр әмәлен эзләп табыйк без, җанашым.

Икенче көнне җайлап кына мәрхүм Госсам йортына сугылганнар иде, сигез-тугыз яшьлек сабыйлар кулларын җәеп, авызларын ачып тик торалар.

—Кичә кичтән бер әфисәр кер юарга дип килеп алган иде, һаман кайтканы юк.

Нәҗметдин сәүдәгәр Попов утарына үзе урынына ат караучы булып кергән Степанны яхшы белә иде, башын иеп, шуның янына китте. Степан кәбестә сыман катлаулы егет түгел, шытырдап торган кәгазь акча тоттыруга, шундук ачып салды.

—Полковник Ткаченко күршесендә, Зеленцов дигән капитан йортында ул сезнең чибәрегез. Зеленцов үзе иртә белән үк Шанхай ягына чыгып китте инде. Мөгаен дә, сезнең чибәркәйнең җимешләрен хәзер Зеленцовның деньщигы Максим суырадыр...

Зеленцов яшәгән йортның капка төбенә житкәч, Нәҗметдин Разияны беләгеннән кысып, шып туктатты.

—Әүвәл мин үзем шымчылыкка кереп чыгыйм әле. Сиңа барысын да күрү мәҗбүри түгел. Аннары чакырырмын.

Нәҗметдин ишекне кат-кат шакып карады, эчтә шылт иткән тавыш та юк. Аптырагач, ачып, тупса аша гына узган иде, тораташтай калды.

Сәке шикелле тәбәнәк, киң итеп ясалган караватта ат сыман туарылган Сания җәйрәп ята. Өстендә сыңар чүпрәк кисәге дә юк, чәче-башы тузган, җәннәт бакчасы ачык, үзе гырлап йоклый. Ир уртасы хаҗи күз йөгертеп чыкты. Чит-ят күзе кызыгырдай байлык бар икән шул монда. Тыгыз, мул күкрәкләр, чыбыктай нечкә бил, озын, таза ботлар, ап-алсу тән. Урыс качаклары бу сылуга юкка гына сикермиләр икән.

Сания бик озак чәбәкләгәч, йолыккалагач кына сыңар күзен ачты. Каршында кем басып торуын абайлады, әлбәттә, әмма хурлану-үкенү чаткыларын тамчы да күрсәтмәде. Аның аякка баскач сөйләнә башлаган сүзләрендә дә иман-тоз юк иде.

—Мине оялтырга, хурларга дип килгәнсеңдер инде син, кем, Нәҗметдин абзый. Ә мин ник оялыйм? Өйдә ач көе утырган энекәшләр өченме, монда килеп әрәм булган

үзем өченме? Әгерҗедә яшәп калган булсак, мөгаен дә, әрәм булмас идем. Инде күптән кияүгә чыгар идем, бала табар идем. Мине монда сез өстерәп алып килдегез бит. Җимешен дә, әйдә, бергә-бергә татыйк...

Берәр атна чамасы вакыт үткәч Сания мәдрәсәдә идән юарга кереште. Аның өлкән энекәшен Нәҗметдин үзенең яна кибетенә өйрәнчек итеп алды, кечеләре мәдрәсәдә укый башладылар. Тик тәкъдир, явыз, Сания гөнаһларын алай җиңел генә ярлыкамаган шул. Кызый-балакай тол калган хатын шикелле бер ай буе гына үз эченә йомылып йөрде дә, кайсыдыр бер кичтә Попов йортына качты. Ике көн буена татар мәхәлләсенә «Сания эчә башлаган, кызыгыз урыс солдатлары белән себерелә», дигән чәнечкеле сүзләр ташып тордылар. Мәдрәсә мөгаллимнәре, мөтәвәллият вәкилләре җыелып барган чакта соң иде инде. Санияны абзар түбәсендәге элмәктән бергәләп төшерергә генә насыйп булды.

* * *

Кыш керүгә, Алатау аръягындагы Рәсәй тарафыннан Харбинга берсеннән-берсе аяусызрак хәвеф-хафа турында хәбәрләр килеп ишетелде.

—Идел буендагы барча өязләрдә коточкыч корылык булган, авыл-калалар яртылаш бушап калган, адәм балалары ачлыктан бер-берсен ашауга тикле барып җиткәннәр. Казан белән Уфа губерналарыннан гына да бер миллионга якын мөселман баласын ач үлемнән коткармакчы булып Урал, Себер, Төркестан ягына алып киткәннәр, ди. Совет хөкүмәтен танымаган Америка булып Америка да ач Рәсәйгә ярдәм кулын сузган, кәрван-кәрван пароходлар көнсаен урыс портларына икмәген, итен, маен бушка ташый икән.

Көннәрдән-беркөнне «кытайлар да Рәсәйгә җибәрер өчен дөге, май, ит кебек ризыклар туплый башлаганнар», дигән сүзләр килеп ирешә. Татар-башкорт качаклары мәчет тирәсенә җыелып шомлы уйга калды. Фикерләр дә, тәкъдимнәр дә төрле-төрле иде.

—Бу Рәсәйне гомер бакый аңлап булмас инде,—дип башлады тире, йон, бал җыя-җыя бертуктамый юлда йөргән Җирән Харис хәзрәт.—Моннан җиде-сигез ай элек кенә Мәскәү комиссарлары, бөтен гәҗитләрен тутырып, «чит илләргә бер кыш эчендә унике миллион пот ашлык саттык», дип шапырганнар иде бит әле. Көтелмәгән корылык килүгә ярты халык ачтан кырылырлык булгач, большевиклар хөкүмәтенә соңгы күлмәген сатып бәйрәм корган исерек урыс сыман дуамаллану нигә кирәк икән?

Төркестан далалары аша качып килгән Әҗем салкын тавыш белән генә әләктереп алды.

—Нигә булсын, шул, Микулайдан тартып алган тәхетне саклап калу өчен инде, туганкаем. Шуның бәрабәренә алар унсигезенче елдан бирле бөтен Рәсәй халкын акыртып талыйлар. Рәсәйдә корбаннарны санау мәңге булмаган бит. Теге сугыш йә бу ачлык вакытында бер миллион кеше кырыламы, ике миллионмы—патшалар түкереп бирә. Алар өчен, иң беренче чиратта, тәхет, власть мөһим.

—Иң яманы шул әле аның, к-һем, карендәшләр,—дип тамак кыра-кыра сүзгә Мифтахетдин хәзрәт кушылды.—Ул, син унике миллион пот дип әйткән икмәкне талаганда да урысның камчысы, иң әүвәл, безнең татар крәстияненең сыртына төшә бит ул. Чөнки урыс крәстияненең берчакта да артык икмәге юк. Ялгыш уңа икән, ул аны барыбер чыгарып сата да ду китереп эчә. Ул унике миллион пот икмәкне дә, шиксез, татар крәстияннәреннән талап җыйганнардыр. Көтелмәгән ачлык башлану барыннан да бигрәк Казан белән Өфе тирәсендә котырына, андагы халыкны чалгы белән ургандай кыра икән, бүтән нәтиҗә юк, урыс хөкүмәте Идел буендагы ачлыкны алдан чамалап-белеп оештырган инде.

Бераздан Җирән Харис янә дилбегәне үз кулына алды.

—Татар милләтенә килгән бәла-каза аны талау белән генә бетсә икән?! Юк шул, туганкайлар. Казан белән Өфе тирәсеннән җыеп читкә озатылган бер миллион татар баласы турында да уйлап карагыз әле. Урыс хөкүмәте аларны «ач үлемнән коткарабыз», дип читкә чыгарган, имеш. Тот капчыгың! Ул ятимнәрне, иң элгәре, урыс мәптәкләренә, урыс приютларына илтеп тыгачаклар. Әниләренең имчәкләрен таба алмыйча аптыраган сукыр эт йә песи балалары сыман интеккән ул ятимнәр исемлекләр белән митрикәләргә иртәгә үк, чукындырып тормыйча да, урыс Иваны, урыс Мәтрүнәсе итеп язылачак. Монысы инде дүрт гасыр буена патшалар тарафыннан иң сыналган

ысул. Явыз Иван падишаһны гына искә төшерегез. Ул, Казанны алгач, тол вә ятим калган унбиш мең татарны Рәсәйгә алып китеп, урыс алпавытларына өләшмәгәнмени? Безне хәзер дә урыс элеккечә йота...

Ахырда, бик озак тарткалашулардан соң, барыбер дә, кумәк карарга килделәр:

—Америка хәтле Америка ярдәм кулын сузган икән, без, татарлар, читтә кала алмыйбыз. Һәммә мөһаҗир гаилә кулыннан килгәнчә ризык бүлеп бирә. Иллә мәгәр, качак татарлардан җыелган байлык-нигъмәт фәкать Идел буендагы кардәш-карендәшләр кулына барып ирешергә тиеш!..

Харбиндагы татарлар гына да ике көн эчендә дүрт вагонны тутырып ризык тупладылар. Мәскәүгә адресланган ярдәм-нигъмәтне кытайлылар үзләре озатып барачак ди. Татар качаклары фидаиларча инану-бирелгәнлек белән һәр вагонның ишегенә «сәлам такталары» беркетеп, кагып чыкты.

«Гайнә татарларына Харбинда яшәгән көе дә иманын-денен саклап калган туганнарыннан бүләк. Безне дә онытмагыз.»

* * *

—Мәскәүдән «Правда» газетасы килгән, «Правда» газетасы!—дигән хәбәр таралгач, әүвәл Харбиндагы һичкем шаккатмаган иде. Ләкин моның сере «имәндә икән чикләвек», дигән сыман сәер булып чыкты. Шәһәр буйлап кулдан-кулга күчеп йөргән газеталардагы яңалык шаккатмалы иде.

—Югославиягә качкан барон Врангель дә, Парижга шылган Вакытлы хөкүмәт министры Милюков белән генерал Деникин да безнең Харбиндагы Себер хөкүмәтен тәнкыйть итеп чыккан. Аларның һәммәсе дә Меркулов төзегән ялган хөкүмәтне һәм Себерне Рәсәйдән бүлеп алырга җыенган атаман Семеновны утлы табага салып пешерәләр. Урыс монархиясе яклы Париждагы барча союзларның да, патша генералларының да таләбе бер—Рәсәй бердәм һәм бүленмәс булырга тиеш! Рәсәйне таркатырга җыенган Меркулов-Семеновлар—урыс дошманнары!..

Харбиндагы мөселманнар гына түгел, грузиннар, украиннар, хәтта кытайларга тикле баш түбәләренә күсәк белән орган шикелле телсез-өнсез калды. Бу урыс кешесе эт типкесенә калган сукбай булса да кол һәм аның тәненнән-җаныннан иң сасы пумала белән кусаң да, карагруһлык чире мәңге китми икән!

Мифтахетдин хәзрәт моңа ике-өч җөмлә белән генә мөһер сугып куйды:

—Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карар, ди. Врангель белән Деникин да шулай. Кул-аяклары бәйләп бәдрәфкә ташланган мескен хәлендә үзләре. Мәгәр «коткарыгыз» димиләр, әле һаман мин урыс, дип өреп яталар бит...

Аның каравы, шушы «Правда» газетасын алганнан соң Харбиндагы карагруһчылар йокыдан типкәләп уятылган сыман булды. Тиз арада калада «Рәсәй эмигрантлары үзәге» барлыкка килде. Япон сәүдәгәрләре «үзәк» өчен өч катлы зур таш йорт сатып алып бирде. Түбәгә һәм ишек өстенә ак, зәңгәр, кызыл төсләрдән хасил буйлы-буйлы әләм мендереп элделәр. «Үзәк» хезмәткәрләре каладагы барча качакларны исәпкә алып чыкты. Күп тә үтмәде, иллешәр-йөзәр кешелек взводлар һәм роталар төзеп, качакларны кала читендә ялан-кырларда сугыш эшенә өйрәтә башладылар. Боларның нәфесләре арыш капчыгында хасил булган нәни тишек сыман торган саен зурая гына барды. Берзаманны урыс әфисәрләре аерым урам яки кечкенә утар нигезләп урнашкан татар, поляк, украин, үзбәк, грузин, эстон качакларын да үзләренең «ирекле ополчение»ләрендәге хәрби күнегүләргә куарга тотындылар. Иң беренче булып, мөселман качаклары сикереп каршы чыкты.

—Патша хөкүмәте вакытында изеп-талап тотуыгыз гына җитмәгән, Кытай җирендә дә безне тезләнгән хәлдә яшәтергә җыенасызмы әллә? Юк инде, монда сез дә, без дә бердәй дәрәҗәдә, һәммәбез килмешәкләр. Чит-ят җирләрдә дә сезнең кубызыгызга биеп йөреп булмас.

Икенче атнада ук татар, башкорт, үзбәк, таҗик качаклары үзләренең мөселман йөзлекләрен төзеп куйды. Һәрбер йөзлек өчен ямь-яшел ефәккә алтын төсендәге ай төшерелгән әләм булдырдылар. Санаулы көннәр эчендә атлы эскадроннар үсеп чыкты, корал урынына агач кылыч, хәнҗәр кулландылар. Урыс карагруһчыларына каршы кузгалган мондый бердәм үҗәтлекне күреп кытайлылар мөселман яугирләрен мылтыклар һәм туплар белән дә тәэмин итмәкче иде, качаклар баш тартты.

—Кунак рәвешендә килеп баш тәрткәнбез икән, тыйнак яшәү хәер. Бер басмага

сыеша алмаган ике кәҗә тәкәсе сыман сөзешеп яту—дошманнарга бәйрәм...

Урыс карагруһчылары тарафыннан күрсәтелгән басым мөселман качакларын чынлап торып берләшергә мәҗбүр итте. Чәньчүн, Дайрен, Мукден, Шанхай калаларында урнашкан җәмгыятьләр, вәкилләр җибәреп һәм сәрмая туплап, өр-яңа адымнар кыла башладылар. Уйламаганда-көтмәгәндә Кытай җирендә «Яшь Төркестан» һәм «Яшен» газеталары пәйда булды. Харбинның үзендәге мәдрәсәне гимназия дип атадылар да аңа Исмәгыйл Гаспралы дигән исем беркеттеләр. Бу эшләрнең башында үзбәкләр белән Кырым татарлары торса да, аларга каршы чыгучы беркем табылмады. Ходайга мең шөкер, иске төрки-татар телен һәр мөселман белә һәм барча яңа гамәл качак җәмгыятьләре өчен сөенеч кенә иде.

Алты-җиде төбәккә таралып утырган татарлар Мукден каласына җыйналып «Мәркәз» дигән үзәк төзеп куйды. Шул айда ук бөтен Кытай буйлап «Милли бәйрәм» атлы газета тараттылар. Үзләрен һаман ятим итеп тоеп йөргән татарлар өчен яңа җылы учак кабынган сыман булды.

Мөселманнар дөньясындагы яңарыш һәм бердәмлек башка милли җәмгыятьләргә дә бик тиз йокты, ахры. Беркөнне Нәҗметдин хаҗиның кибетенә Одинец белән Квитченко атлы украин адәмнәре килеп керде. Кулларына яртышар капчык тулырлык кәгазь төпләмәсе күтәргәннәр, күзләре төнге ябалакныкы шикелле ялт-йолт килеп тора.

—Син «Милли бәйрәм» газетасының мондагы хәбәрчесе бит. Татар газетасы булса да, барыбер язып җибәр! Урыслар үзләренә терәк эзләгән чакта «без украиннар белән бер ананың ике улы кебек бертуганнар, телебез бер», дип бугаз ярып кычкырырга бик осталар. Ә без, менә, ике ай эчендә урысча-украинча-кытайча сүзлек төзедек тә, телләребездә күк белән җир арасы аерма ятканын исбат итеп чыктык. Җен башка, пәри башка, дигәндәй, урыс белән хохол арасында бер урманда үскән ике капка баганасы чаклы да туганлык җепләре юк!..

* * *

Егерме бишенче елны Харбинга Кызыл армия полклары кереп тулды. Юк, болар илбасарлар түгел, аларны, имеш, Кытай хөкүмәте Манъчжурияне японнардан саклау өчен чакырып керткән икән. Кызыллар берәүне дә какмады-сукмады, төнлә килеп тә һичберкемне чыгарып атмадылар. Болар, унтугызынчы елгы комиссарлардан аермалы буларак, хәйлә белән һәм юмалап эш итәргә өйрәнгәннәр иде. Качакларны көпәкөндез берәм-берәм үз штабларына чакыртып алалар, анда һәммәсенә бер үк төрле үгет-нәсихәт:

—Совет власте китмәслек, җимерелмәслек булып мәңгелеккә урнашты. Ул сезнең берегезне дә җинаятьче дип санамый һәм җәзага тартмый. Калдырып киткән йортларыгыз, ихаталарыгыз шул көенчә көтә. Теләсәгез, сез бүген үк бер дә шикләнмичә кабат туган җирегезгә кайтып яши аласыз. Сезнең монда качып яшәвегез чит илләрдә совет хөкүмәтенең качакларга карата гадел мөнәсәбәттә булуына шик тудыра. Хәтта, әле шуны гына истә тотып та совет хөкүмәтенең сезгә тиясе, сезне рәнҗетәсе юк. Әйдә, кабат кайтып, үзегезчә хәят нигезләгез...

Туган җир бик сагындыра иде шул, күпләр тупларга өлгергән сарайларын, җиһазларын, терлекләрен сатып юлга җыендылар. Аерылышу алдыннан елашу-ухылдашу да, әлбәттә, аз булмады. Шулай да, вәгъдә-иман беркетеп өлгерделәр.

—Туган якларга кайтып урнашуга ук сезгә фоторәсем белән хат салырбыз. Хәлләребез әйбәт булса—рәсемгә баскан килеш, начар булса—утырган килеш төшелгән булыр. Сезгә дә кайтыргамы, юкмы—шуннан чамаларсыз...

Калганнар дүрт күз белән тилмереп хат көттеләр. «Җавап-сәламнәре» ярты елдан килде. Кайтып киткән якташларының һәммәсе дә рәсемнәрен ... яткан көе төшеп салган иде.

* * *

Нәҗметдин хаҗи йокларга ятарга җыенып йөри иде инде, ишекне шакымыйнитмичә Рәшидә абыстай атылып килеп керде. Чәче-башы тузган, йөзе тоташтан яшь. Үзе һаман үкерә-үкерә елый, ярты сүзен аермалы түгел.

—Таһирны бүген иртән апкиткәннәр иде... Төн җитте, һаман юк... Машина килеп алды. Консуллыктан... Үткән атнада Үтәш байны да... шулай апкиткәннәр иде бит. Суга төшкән балта ... балта сыман булды, һичбер хәбәре юк. Таһир белән дә шулай

булыр микәнни соң? Аерым йорт алгач, аякка баскач кына. Кемнәргә генә барып ярдәм сорыйм соң, и, Ходаем?

Нәҗметдин уйга калды. Әйе, мәхәлләгә ниндидер кара зәхмәт йокты. Бер ай элек Закир Бичуринны Рәсәй консуллыгына чакырып алганнар иде. Шунда аны җир йоткандай булды, һичбер хәбәре юк. Узган атнада Үтәш байны алып киттеләр— әйтерсең, базга чумды. Инде, менә, Таһир Апанаев. Барысы да качаклар арасында үзенең йортын-кибетен булдыруга ирешкән иң хәллеләр. Һәммәсе диярлек ике-өч тел белә. Менә шуларны ниндидер аңлатма бирергә дип алып китәләр дә, Рәшидә абыстай әйтмешли, суга чумган балта сыман эзсез югала тегеләр. «Консуллыкның идән асты бүлмәләре күп», дип сөйлиләр. Әллә шунда бикләп газаплыйлар бичараларны, әллә богау кидертеп Рәсәйгә үк озаталар микән? Ничек кенә ачыклыйсы моны?

Таң атуга ук Нәҗметдин хаҗи хатыны Разия белән өлкән улы Касыймга өзеп әйтеп куйды.

—Тәкъдир, чират, дигәннәре миннән дә әлләни ерак йөрмидер. Советныкыларың мине дә килеп җыйнаулары мөмкин. Алар алып китсә дә, мин үзем теләп барсам да, сезгә корыч фәрман. Шул сәгатьтә үк иң кыйммәтле кәгазьләрне җыйнап төйнисез дә, Хайлар урамындагы чулак уйгур карты янына ычкынасыз. Төп-төгәл бер атна вакыт тын да чыгармыйсыз. Әгәр кайтмыйм икән, шул картның малае сезне Япония корабына утыртып җибәрәчәк. Аннары инде үз хәлегезне үзегез кайгыртырсыз...

Харбин урамнарына кияүдәге азгын хатын янына ияләнгән ир сыман мыштым гына килеп кергән совет солдатларын берзаманны танымый башладылар. Кайсы гына кибет яки кабак ишегенә барып төртелмә, шунда исерек солдатлар, шунда сугыш. Бер урыс әфисәре элеккеге япон кибетендә иске җилләткеч табып алган да, ике кытай сәүдәгәренә мылтык терәп, көчләп саткан, диләр. Мондый хәбәрләр тау башыннан ычкынган кар йомгагы сыман зурая гына бара. Имеш, кызыллар ундүрт яшьлек үзбәк кызын тотып көчләгәннәр. Имеш, исерек солдатлар Яңа шәһәрдә поляк костелларын талап чыккан.

Калага, әйтерсең лә, үләт чире йокты. Кирәк-яракка кибетләргә ирләр генә йөри башлады. Хатын-кызларны, бала-чаганы урамга чыгару, капкага йә тәрәзәгә килеп шакысалар, ишек ачучы юк. Ике күрше арасында хәл белешүләр генә түгел, урыс солдатлары каршында татар, таҗик, үзбәк телендә сөйләшүләр бетте.

Чыдамады, Нәҗметдин хаҗи Совет консуллыгына үзе җыенып китте. Туганнарын күргән шикелле авызларын ерып каршылаган булдылар. Якасына өч алтын шакмак таккан ниндидер башлыклары көтелмәгән кунакка, хәтта, бал белән чәй дә тәкъдим итеп маташты. Ләкин хаҗиның йөзе үзгәрешсез, максаты нык иде, курыкмыйча тезде.

—Сез әүвәл Закир Бичуринны, аннары Гайнан Үтәшев белән Таһир Апанаевны алып киттегез. Берсе-бер кире әйләнеп кайтмады. Алар кайда?

Нәҗметдин хаҗиның үз уеннан кире чикмәс үҗәт кеше икәнен чамалаганнардыр, ахры. Өч шакмаклы башлык кыңгырау шалтыратуга, бүлмәгә әзмәвердәй гәүдәле ике хәрби кеше килеп керде. Нәҗметдин шуларның берсенә текәлде һәм дию күргән сыман акайды да катты. Каһәрен өшкерим, купис Попов йортында ничә еллар буе ишек сакчысы булып торган чуваш Гаранин бит бу! Ул ике кичнең берендә «мин чека кулыннан чак-чак кына качып котылган кеше», дип борчак сибә иде, менә ни сәбәпле исән калган икән!

Гаранин хәзер әфисәр киемендә, йөзе әче балан капкан сыман кырыс, сорауларын да көттереп азапламый бирде.

—Әле сине кулга алырга чират җитмәгән иде бит, нишләп үзең килдең?

Нәҗметдин өч шакмаклы башлык алдында тезгән җөмләләрне кире кабатлады. Гаранин аларны колак тирәсеннән генә үткәреп җибәрде, аннары җан алырга килгән Газраилдәй усал итеп дәште.

—Син кайчаннан бирле япон разведкасы файдасына эшлисең? Ул «Милли бәйрәм» газетасын чыгару өчен япон хөкүмәте күпме акча бирде?

Нәҗметдиннән җавап ишетелмәгәч, өй кыегыннан ычкынган кар өеменә охшаш яңа сораулар яуды.

—Синең абзыең нишләп Рәсәйдә торып калды да, үзең нигә бирегә чыгып качтың? Гаяз Исхакый чит илләрдәге Вакытлы хөкүмәтне кемнәр катнашында оештырды? Рәсәйдәге татар контрлары белән бәйләнеш тоту каналларыгыз кайда?

Болары инде шайтанының да шәрә калдырырлык ят мәгълүмат иде, Нәҗметдин

энмәшмәде. Сугып аудардылар. Аннары аны әзмәвердәй ике әфисәр озын коридорлар һәм бормалы-сырмалы баскычлар аша ниндидер тынчу, караңгы базга алып төште. Хәрбиләрнең берсе ишек өстендәге нечкә бауны тартып ут кабызды. Нәҗметдин хаҗи базның нәкъ урта бер җиренә куелган чанга текәлде дә торараштай калды. Чан яртылаш рәвештә ниндидер сыеклык белән тулган, аңа башы ярылган Апанай бай гәүдәсен ташлаганнар. Мәрхүмнең сыеклыкка чумган куллары-аяклары яртылаш ашалып беткән. Мәрхүм мизгел узган саен диярлек акрын гына сыеклыкка чума һәм шуның эчендә юкка чыга бара. Нәҗметдиннең Казандагы тире эшкәртү фабрикасына байтак кергәне бар. Чандагы сыеклык кислота булырга тиеш...

Ишек катындагы хәрбинең ажгырып үз өстенә сикерүен Нәҗметдин хаҗи аның күләгәсеннән үк чамалап, сизеп алды. Ул баш түбәсенә балта белән суккандай шап итеп таш идәнгә утырды, кансыз хәрби аның гәүдәсенә абынып тимер чанга чумды. Аның дию тавышлары чыгарып үкерә башлавыннан икенчесе өнсез калган иде. Нәҗметдин идәндә яткан канлы балтаны эләктереп аның ботына чапты.

Өскә күтәрелгәч, Нәҗметдин беренче очраган ишеккә китереп типкән иде, теге күгәненнән кубып тышка чыгып очты. Артта буш дала җәйрәп ята, качу өчен тоткарлык юк иде.

* * *

Токиодагы «Исламия» җәмгыяте яңа качакларны җылы каршылады. Японияде дә мөһаҗир татарлар саны ун-уникe мең үренә җитеп килә, мәркәздәге Санай урамына урнашкан мәхәлләнең эшли башлавына да биш-алты ел икән. Мәчеткә манара куярга хакимнәр тарафыннан рөхсәт бирелмәгән, шулай да, гыйбадәт кылу, күрешеп яшәү өчен бик тә ярап тора.

—Габделхәй хәзрәт, Корбангали угълы,—дип үзе башлап таныштырды имам.—Заманында Саба олысының Наласа авылында мәсҗед тоттым.

Шушы хәзрәт өйрәтүе буенча, Нәҗметдин белән Разия Токионың Акабу-ху дигән районында искерәк йорт табып урнаштылар. Бу район бик тә тыныч, үзәккә таба Нагасаки дигән урам алып чыга, совет илчелеге дә ерак түгел икән. Соңгысына Габделхәй хәзрәт үзенчә аныклык кертте.

—Алдыңны-артыңны карап йөрергә бик нык өйрән, хаҗи. Сине япон инулары гына түгел, моннан ары урыс этләре дә күзәтәчәк икән.

Хаҗига «ину» сүзенең мәгънәсе соңрак барып җитте. Анысы японнарда «эт» дигән сүз, бередә кемпентай белән токкоко шымчыларын шул рәвешчә мыскыл итәләр икән. Нәҗметдин үзенә тагылып йөргән андый «ину»ларны аерырга тиз күнекте, чөнки тәүге атналары һаман-һаман эш урыны эзләп үтә иде. Әлеге юлдагы беренче киңәшләрне дә һаман да шул Габделхәй хәзрәт бирде.

—Японнар үзләрен ямато расасы, ягъни мәсәлән, Ходай тәгаләгә иң якын, иң югары катлам, дип йөри. Шулай булгач, безнең кеби мескен качакларга алар арасында урын юк. Алар килмешәкләрне дәүләт эшләренә, хакимияткә якын җибәрмиләр. Безгә сәүдә, дин, мөгаллимлек тармаклары гына кала. Син дә кәсебеңне шул сукмактан эзлә.

Нәҗметдин хаҗи әүвәл чат саен тулып яткан болан тиреләрен җыеп эшкәртеп карады, Разия унар-егермешәр икмәк пешереп урамнарга чыкты, юк, япон кадимнәре берсенә дә тәгәрәп төшмәделәр. Бактың исә, болан японнар өчен изге хайван санала, алар аның тиресенә түгел, итенә дә тими, шулай ук табынган ризыклары да фәлән дистә төрле пешерелгән дөге ашы икән.

Разия көтмәгәндә-уйламаганда балчыктан төрле-төрле вак-вак сыннар ясап, шуларны буяп сату эшенә кереште. Сыннар арасында кемнәр генә юк? Сап-сары чәч толымнарын мул күкрәкләре өстенә таратып салган марҗа кызлары. Гармун күреген өзелерлек итеп сузган урыс егетләре. Яулыклары мендә-менә очып китәрдәй итеп йә кәләпүшләренә бармак очларын гына тидереп биегән татар кызлары, татар егетләре. Чыдамасаң, һәммәсен җыйна да ал. Ләкин юк, япон бичәләре боларга да күз читләрен генә салып уза икән. Разия урамнан кайтып керә дә һәр кич саен елый.

—Моннан шундый сак кына төянеп чыгып китәм, юлда көмәнле хатын сыман иләп кенә йөрим. Ә Нагасаки чатына җиткәч ачып карасам, сыннарымның яртысы ватылып беткән була. Калганнары да кояш астында басып тора-тора барыбер таралып төшә. Очсыз яулык бәясе торырлык та табыш алалган юк.

Бер көнне ул әлеге шөгыленә дә өзеп нокта куйды.

—Юк, әтисе, һәр милләтнең үзенә генә хас кәсебе бар икән ул. Балчыктан сын ясау татар шөгыле түгел, урыс чире. Аның белән урыс шөгыльләнсен, ә син, татар, ата-бабаңнардан калган үз кәсебең белән дөньяңны ку икән.

Икенче көнне үк Разия японнарның «Кабуки» дигән милли театрыннан бер кочак аллы-гөлле җепләр алып кайтып чигү чигәргә утырды. Ни галәмәт, аның төгәлләп бетергән һәр чигүен шул ук театр кешеләре кырып-себереп алып бара иде. Разия, кызып китеп, ак чәчәкле юка шәл-яулыклар бәйли башлады, аларын да кулыннан йолкып диярлек алып китә тордылар. Берзаманны качак татарлар йортына яп-яшь кызлар килеп ябырылды. Боларда озакламый Сакура матсурие* башлана, йола буенча һәрбер яшь кыз кимоноларына ак чәчәк чиктерергә, «фуросики» дигән нәфис яулыклары да аллы-гөлле чәчәкләрдән генә торырга тиеш икән. Разия төннәрен юньле-башлы йоклый алмас булды. Ә японнарның Сакурасын «лалә, ирис, хризантема» дигән бәйрәмнәр алыштырды, аларына да өр-яңа төстәге кимонолар, яулыклар кирәк булып чыкты...

Нәҗметдин хаҗи көзге айларда, өйрәнгән гадәт буенча тәвәккәлләп, Токиода да зур булмаган кибет ачып куйды. Аллага шөкер, монда, Харбиндагы кебек, Касыйм белән икәүләп »уфалла» сөйрәп йөрисе юк, японнар яңа кибеткә бик еш керә иде. Әмма хаҗи тоташ тиргә, пошаманга төште. Болар керәләр, карыйлар, ахырда күбесенчә елмая-елмая, гафу үтенә-үтенә, буш кул белән чыгып та китәләр.

Яңа качакның намазга гел үртәлеп килүен сизеп алды бугай, Габделхәй хәзрәт Нәҗметдингә сәер киңәш бирде.

—Син төкеренергә ашыкма, японнарның үз кибетләренә кереп күз салгалап йөр, аннары болар белән ничегрәк эш итәргә кирәклеген җиңелрәк төшенерсең.

Хаҗи биш-алты кибетне әйләнеп чыккан иде, тәмам аптырады. Син боларның кибетенә кереп бер әйбер алмыйсың-нитмисең, ә хуҗаларының һәркайсы сине ишек төбенә чаклы килеп, рәхмәт әйтә-әйтә озата. Арурак кибетләрдә бушка чәй тәкъдим итү гадәте дә бар икән. Гаҗәп: бигрәк итәгатьле, кунакчыл, олы җанлы икән бу японнар.

Нәҗметдин берочтан «Рейнгольд», «Флєдермаус» дип аталган немец кибетләренә дә сугылып чыкты. Соңгысының исеме катлаулы түгел, «Ярканат» дигәнне генә аңлата икән. Вәт әкәмәт, һәр милләттә өйрәнерлек, гыйбрәт алырлык хикмәтләр бар. Менә, әлеге кибетләргә дә гел аксыл чәчле, озын буйлы, нечкә билле, таза ботлы, мул күкрәкле яшь кызларны гына җыйганнар. Байтагының Корея йә Сингапур, Малайзия кызлары булганлыгы әллә каян кычкырып тора инде, мәгәр юк бит, һәммәсе дә фәкать немец телендә генә чәчрәтеп сөйләшәләр. Кисмәк, бүкән ише әйберләргә охшатып ясалган өстәл-урындыкларны да, сыра мичкәләрен дә Германиянең үзеннән үк китертелгән, диләр. Хактыр, валлаһи. Официант кызларның алъяпкычларына чаклы немецча бизәлгән бит.

Өйгә кайткач Разияга әмер кыска булды.

—Татар байбичәләре шикелле ыспай итеп киен. Күкрәгеңә хәситә, чәчеңә таңкәләр ас. Өчпочмаклар, вак бәлешләр, кыстыбыйлар пешер. Самавырың һәрчак кайнап торсын. Бушка сыйлап японнарның ушларын алабыз. «Вәт булдыра татар абыстае», дип үзеңә карап сокланcыннар әле.

Ни галәмәт, шушы эшләрне җайга салганнан соң японнар Нәҗметдин кибетенә язгы ерганаклар кебек агыла башладылар. Татар ризыгын бушлай гына авыз итәргә яхшысынмыйлар, күрәсең. Кирәкме ул, түгелме—кергән бере йә Нәҗметдин белән Касыйм кулдан ясаган кашыкларны, җамаякларны ала, йә Разия абыстай бәйләгән-чиккән яулыкларны, пәрдәләрне рәхмәт укый-укый җыеп чыгып китә.

Тора-бара Нәҗметдин белән Разия кибетенә татарлар үзләре дә йөри башладылар. Кайбер кичтә унбиш-егермешәр качак җыела. Туган илкәй онытылмый икән, күз төпләрен яулык читләре белән сөртә-сөртә үзләре чыгарган өр-яңа җырларны сузалар.

Монда ят ил, монда илне
Каплаган тау-таш җире,
Бу түгел минем илем.
Монда илнең уллары юк,
Чиртмиләр саз кылларын,
Көйләми монда берәү дә
Без татарның җырларын.

**Матсури*—бәйрәм (японча).

Аеруча хатын-кызларда кайгы-хәсрәт чиксез. Алар бигрәк тә балаларының япон булып үсүенә кайгырышалар. «Нинди дә булса чарасын күрергә кирәк», диләр, ә үзләре бармакка бармак та сукмыйча яшәүләрен дәвам итәләр.

—Әйдә, татар мәктәбе оештырабыз,—дип бер кичтә Разия чәчрәп чыкты.

—Ничек? Җитәрлек сандагы балаларны каян табабыз?—дип һәммәсе аптыраштылар.

—Урам буйлап төрлебез төрле якка чыгып китәбез дә, кайда төрки-татар сөйләме ишетәбез, шуларны бер өйгә җыябыз.

Ике-өч көн буе эзләнеп йөргәннән соң да чама белән бер үк сыйныф тирәсендә укыган биш бала табылды. Шул атнада ук Санай урамындагы мәчеткә терәлеп торган кирпеч йортның беренче катында Разия абыстай аларга сабак бирә башлады. Өч-дүрт айдан соң балалар саны утыз шәкерткә җитте. Мөһаҗирләр күңеленә тәүге тапкыр шатлык-бәхет хисе сеңгән сыман булды. Сөенергә ашыкканнар икән.

* * *

Язгы бер көннең таңында башланган коточкыч дөбердәү Токио халкын урыннарыннан сикереп торырга мәҗбүр итте. Нәҗметдин, Разия, Касыйм, алардан кечерәкләр өчен күз алдына бөтенләй дә китерә алмас олы кыямәт купкан: болар яшәгән йорт дингездәге гарасат-давыл уртасында калган кебек үрле-кырлы килә, диварлар ярыла, өй эчендәге барча җиһаз-байлык җен кузгаткан сыман почмактан-почмакка шуып йөри иде.

—Урамга, урамга йөгерегез!—дип кычкырды Нәҗметдин, иң беренче булып. Үзе, идән астына төшеп, элек яшереп куйган бер-ике төргәк хәзинәсен алмакчы иде дә, түшәм аерылып, аннан ком, таш, такта кисәкләре коела башлавын күргәч, ул да елан чаккан кебек кабаланып тышка томырылды.

Урамга чыксалар, анда ахырзаман көнендәгедәй мәхшәр. Кай тарафка карап йөгерергә белмисең, һәрьякта көтү-көтү малларны йотардай булып җир ярыла, дөбер-шатыр килеп йортлар убылып төшә, бөтен тирә-юньдә тузан болытлары, төтен, ялкын, үкереп елаган тавыш. Иңкүлектә урнашкан Акабу-ху бистәсе генә түгел, Япония горурлыгы булган мәгърур Фудзияма тавы да чал сакаллы карт шикелле башын селки-селки ухылдап-уфтанып утыра сыман. Аның тарафыннан да дию улаган шикелле яман котсыз тавыш ишетелә. Кул сузымы арага аерылсаң да, бер-береңне танырлык, ишетерлек түгел.

Шулай да, төтен-тузан арасыннан барыбер шәйләделәр: японнарның барчасы да диярлек калкулыкларга, үрләргә таба йөгерәләр икән. Нәҗметдин белән Разия кечерәк балаларны, мәче сыман, иннәреннән, муеннарыннан усал каптырып алды. Берни ишетмәсәләр дә, тамак яра-яра барыбер кычкырдылар.

—Тау өстенә, тау өстенә таба йөгерегез! Аймыл булуыгыз, югалуыгыз мөмкин, берүк аерылышмагыз!..

Табигатьнең ярсып тузынуы бер тәүлек буена туктаусыз дәвам итте. Соңыннан аңлаттылар. Мәркәз астында коточкыч җир тетрәү булып узган. Шул аяусыз туфан-бәхетсезлек шәһәрнең танырлыгын бөтенләй калдырмаган. Хибия бакчасы, Васеда университеты, «Санно-отель» кунакханәсе урнашкан районнарда урамы-урамы белән йортлар юкка чыккан, корбан булган һәм югалган кешеләрнең саны унар-унар меңләп исәпләнә икән.

Калкулык-сопкаларны кетәклектәге тавык өере сыман сырып алган халык әле тагын ике-өч көн буена шәһәр эченә төшәргә җөрьәт итми торды. Ниһаять, тәвәккәлләделәр. Әлбәттә, аяусыз гарасат һәркемнең дә йортын-хуҗалыгын сытып-изеп узган, югалтулар чиксез, шуңа күрә һәр тарафтан елау-сыктау авазлары ишетелә иде. Мондый кайгы-матәм халәте башкалада әле яңадан да ике-өч атна буе кара сөрем кебек гел таралмый торды.

Татарлар үзләренең мәхәлләләре янына да курка-курка гына җыелышкан иде. Урап алгач, үзләренең күзләренә үзләре ышанмыйча, балбалдай тик тордылар. Санай урамындагы йортлар яртылаш убылып төшкән, ә боларның мәчете урнашкан өй диварларында сыңар ярык та юк. Түбәсенә саф көмештән ясап куйган кечкенә аена тикле зыян-зәүрәт килмәгән, ул бер көтү тавык арасына җибәрелгән ялгыз әтәч төсле кукраеп утыра иде.

—Аллаһы тәгалә кодрәте бу. Чит җирдә дә үзебезнең дин-иманнан аерылмаган

өчен Аллаһ рәхмәте бу,—дип кайберәүләр чышан-пышан гына сөенеч белдерергә дә ашыкты.

Әмма дуамал җир тетрәү татар мәхәлләсен дә тулысынча урап үтмәгән шул, әле дүрт-биш ай гына эшләп өлгергән мәдрәсә урнашкан йорт нигезенә тикле җимерелгән иде.

—Ярар, анысы олы каза түгел, мәчетнең мөтәвәллият бүлмәсендә булса да өр-яңадан эшләтеп җибәрербез,—ди-ди бер-берсен юатышсалар да, Нәҗметдин хаҗи ярымҗимерек йортына бик күңелсез кыяфәт белән кайтып керде. Балигъ булып килгән Касыймны урамга чакырып сөйләшкәндә дә йөзе хушлашырга җыенган кешенеке төсле җитди, уйчан иде. Сүзләрен дә ашыкмыйча, иплән кенә тезде.

—Мәчеткә бер зыян да килмәгән, ә мәдрәсә җимерелгән. Монда ниндидер фал бар шикелле рәк миңа. Син дә кушылып уйла әле, улым. Аллаһы тәгалә изге мәчетебезне саклап калган, димәк, дини гамәлләребез өчен ул бездән бик разый. Тик мәнә мәдрәсәбезне яклап калалмаган бит. Аңа тел тидерүем түгел, гөнаһ сүзләрем өчен берүк ярлыкасын... Үлчәүнең ике ташы шикелле итеп күз алдына китерсәк, димәк... димәк, безнең гыйлем өлкәсендәге гамәлләребезне хуплап бетерми ул.

—Нигә, ни сәбәпле?

—Менә шул мәсләктән чыгып уйлый торгач, мин бер фикергә килдем. Без чит җирдә, чит халык арасында да үз телебезне, үз гореф-гадәтләребезне сакларга тырышабыз, монысы бик мәслихәт. Иллә мәгәр бездәй мескен качакларны үзләренең илләренә, газиз җирләренә сыендырган хуҗалар, төп халык бар бит әле. Японнар безне үз араларына алдылар, чит-ят тарафыннан, шул ук урыс шымчылары тарафыннан безгә җил-давыл тидермиләр. Без алар төзегән йортларда яшибез, шулар үстергән ризыкнигъмәт белән тукланабыз. Безнең алардан ким бер җиребез дә юк шикелле, әмма... тиң дә түгел.

—Без кай яклап тиң түгел соң, әткәй?

—Без үзебезне сыендырган, безгә ризык биргән японнарның телен өйрәнмибез. Без мәнсезләр, без тинтәкләр, улым. Менә шуңа күрә японнар безне дәүләт оешмаларына эшкә кертми, шуңа күрә тавыш бирү, сайлау хокукыннан мәхрүм ителгәнбез. Тиң булырга һәм абруй-танылу казанырга җыенасың икән, син, иң элек, хуҗалар телен өйрән. Шул чагында гына хуҗа халык сине үз итәчәк, хөрмәт күрсәтәчәк.

Касыйм, тыенкы елмаеп, бүлергә мәҗбүр булды.

—Син мине шушы яшемдә япон мәдрәсәсенә бирергә җыенмыйсыңдыр бит инде, әткәй?

Нәҗметдиннең күзләре усал кысылды, йөзе кырысланды.

—Ниятемне дөрес чамаладың, нәкъ менә шулай итәчәкмен, улым. Әнә, Ломоносовны беренче мәртәбә сабак алырга егерме яшендә кереп утырган, диләр. Соңыннан һәрбер урыс кешесе күкрәк сугып горурлана торган галим булып ирешкән бит әле. Гыйлем алу—кияүгә чыгу түгел. Соңарасы яки үкенәсе юк. Син дә үкенмәссең. Япон белән әшнә булып, тигез булып яшим дисәң, аны мыскыл итмә, аның телен өйрән...

Күңелендә әтисенең тәкъдиме белән хәтәр ризалашса да, яшүсмер Касыйм әле ай буена ныклы карарга килә алмый йөрде. Ул арада Япониянең барча каласыннан мәркәзгә тракторчылар, шоферлар, төзүчеләр килеп тулды. Кырмыска оясын болгаткан шикелле, Токионың астын-өскә китерә башладылар. Мәхәллә үзәге булган Санай урамында да җимерелгән йортлар урынына яңалары калыкты. Төзүчеләр, берочтан, мәчетнең черегән-таушалган түшәм-түбәсе урынына ялтырап торган манара күтәрделәр. Мәчеткә терәлеп, мәдрәсә, мөтәвәллият өчен махсус нигезләнгән ике катлы йорт та калкып чыкты. Шулчагында Касыйм үз карарын әтисенә илтеп ирештерде.

—Аш биргәнгә таш ату—татар эше түгел. Синең сүзеңнән чыкмыйм, япон мәдрәсәсенә укырга барам, әткәй.

* * *

Егерме сигезенче елның яз башында Нәҗметдин белән Разия янына Харбиннан һич тә көтелмәгән кунак килеп төште. Бу—заманында Салавычта ике тегермән тоткан, аннары, кызыллардан качып, Пермьнан Харбинга кадәр юлны бергә үткән авылдашлары Гыймади агай иде. Әллә соңгы елларда Харбинда бер-бер хәл булган, әллә Япониягә тикле юл газапларын бик авыр кичергән инде—йөзе-кыяфәте бер көтү ат тоягы астында калып изелгән табакныкы сыман төссез-нурсыз, таушалып-кипшенеп

беткән. Кочаклашып күрешкәч тә, ул авылдашларын ничек итеп табу серләрен бәйнә-бәйнә сөйләп маташмады, бер җөмлә белән аныклап үтүне генә кирәк тапты.

—Япон җирендә дә бирешмәгәнсез, зур мәхәллә булып оешып яшисез икән, ярхәмкалла.

Аннары Гыймади агай итек кунычыннан алып Нәҗметдингә таушалган хат сузды.

—Сиңа туган илдән кош теледәй сәлам. Озын юллар үтеп Харбинга килеп төште. Ялгыз гына укуың кулайрактыр. Хәбәрләре сөенечле түгел.

Бакчадагы ялгыз бүкән өстенә утырып, таушалган хат юлларына күз йөгертеп чыккач, Нәҗметдин ярсуыннан бүре кебек улап җибәрүдән чак тыелып калды. Каһәреңне генә өшкерим! Туган-үскән җирең шушы тикле нәҗес белән тулса да тула икән!

Хатны Перьмдә яшәүче, Нәҗметдиннәргә бик якын кардәш тиешле Зөбәйдә абыстай юллаган. Моннан бер ел чамасы элек Төркиядә бөтендөнья мөселманнарының ниндидер зур корылтае булган, Зөбәйдә абыстай, «ятып калганчы атып калыйм» дип кенә, әлеге хатны шунда чыгучы мөфти Риза хәзрәт аша озаттырган икән. Әмма хатында бер генә сөенечле хәбәр дә юк, әйтерсең лә, аның һәрбер юлы тоташ кан белән тулган.

«Иркутскидан кайткач, Таҗетдин абыеңны Салавычка кире кертмәделәр. Йортларыгызны сәвит тартып алгач, Таҗетдин безнең Пермьгә сөрелде. Авылныкылар «ул безне таламады, ялчылар тотмады, булган ризыгын ярлылар белән бүлеште», дип Казан белән Уфага язып та карадылар, файдасы тимәде. Таҗетдин Пермьдә әүвәл ат караучы булды, аннан итек фабригында каравылда торды. Комиссарлар, өтермәдә кыйнап, үпкәсен тишкән булган. Һаман саен кан төкереп йөрде, мантымады. Үткән кышта, азагы, мәрхүм булды. Пермьдә мөселман зираты өстенә завут салдылар бит. Татар авыллары ерак. Күпме түрәләргә ялынып бардым, олау бирмәделәр. Азагы, кул чанасы белән тартып, каладан ике чакрымдагы мукшы зиратына, төнлә генә яшереп җирләргә мәҗбүр булдым. Мин япа-ялгыз хатын бит, миңа рәнҗемәгез...»

Зөбәйдә абыстай йөрәк канын куша-куша тагын бер хәбәрне бәян иткән иде.

«Егерме икенче елның кышында Кытайдан сез юллаган дүрт вагун икмәк Пермьгә исән-сау килеп җитте. Бер вагундагы тактаны син язган булгансыңдыр инде, кулыңа карап шулай гоманладык. Якын-тирә татар авылларында халык ачлыктан урамы-урамы белән кырылды, иллә мәгәр сез җибәргән ризыкны безгә бирмәделәр. Вокзалдагы урыс түрәсе ике вагун ашлыкны аракы завутына озаттырган. Икесен чучка фирмесенә илтеп аударганнар...»

Нәҗметдин өй эченә кабат кергәндә дә яңакларындагы күз яшьләре кибеп бетмәгән иде әле. Кунак хуҗаның хәлен сизенгәндер инде, байтак ара дәшми утырдылар. Гыймади агай телгә килгәч тә, аның сүзләрендә юанырлык хәбәрләр юк иде шул.

—Большевиклар Кытайга да тараканнар сыман үтеп керде инде. Сунь Ят-сен дигән бер сатлыкны табып, шулар Пекинда фетнә оештырдылар. Боларга бушлай ит кисәге күреп котырынган эт өере сыман бер көтү ач-әрвах кушылды. Хәзер Кытай икегә бүленеп бетте. Бер якта—Сунь Ят-сен белән Рәсәй җырын җырлаган кызыл комиссарлар. Икенче якта—бездәге байларны аңлаткан Гоминьдан хөкүмәте. Гоминьданлыларга япон белән немец ярдәм итә, диләр. Сунь Ят-сен ягына безнең комиссарлар кереп тулды. Кытайда хәзер моннан ун ел элек нәкъ Рәсәйдә булган шикелле хәл. Ата—улын, ана—кызын танымый, үзара суешалар.

—Кытайда да безнең татарларга яшәргә җай калмаган, димәк,—дип Нәҗметдин хаҗи кунакның бирегә килү максатын бәян итәргә чакырды.

Гыймади агай авыр сулап сузды.

—Калмады шу-ул. Халык икегә бүленеп бер-берсен кыра икән, анда безнең эше килмешәкләргә урын юк. Теге, бабайлар әйтмешли: «Ике фил сугыша башласа, вак җанвар таптала, чебен-черки кырыла». Урыс шундый бит ул, тешен бер батырса, кире ала белми. Кытайда да сугыш-яуның бик озакка сузылуы мөмкин. Безгә аннан чыгып таю ягын карау хәерлерәк. Дөрес, елгырраклар Төркиягә качарга да өлгерделәр инде.

—Сине мондагы хәлне ачыкларга җибәрделәрмени?

—Диңгездә акулалар көтүенә буйлы-буйлы төстәге лоцман атлы балыклар юл күрсәтеп йөзә, диләр. Шундый сәер хәл турында ишеткәнең бармы? Менә мин дә лоцман балыгы кебек сезнең хәятне күрергә дип килдем.

—Нинди нәтиҗә чыгарырсың икән?

—Аллага шөкер, сезне япон изеп тотмый икән. Монда килеп тә тамыр җибәреп

була. Алайга китсә, Харбиндагы татарларның чегән таборы сыман сезнең янга килеп төшүе дә әлләни ерак йөрмәс.

* * *

Гыймади агай бик җилләнеп кайтып китсә дә, Харбиндагы татарларның Япониягә күченүе һаман сузыла торды. Ай арты ай узды, ул арада Япониянең үзендә дә хәлләр көтелмәгәнчә катлаулана башлады. Ил буенча йорттан-йортка әллә нинди хәбәрләр күчеп йөри:

—Хәрби офицерлар, самурайлар: «Без—ямато, без иң өстен раса. Европа—ул Азиянең ярыматавы гына. Азияга без тулысынча хуҗа булырга тиеш»,—дип кычкыралар. Шулар хөкүмәттән хәрби чыгымнарны арттыруны таләп итә икән.

Самурайлар, чыннан да, ниндидер уңышка ирештеләр бугай, яшь ирләрне, егетләрне армиягә торган саен күбрәк чакыра башладылар. Юк-бар гына әҗәт өчен дә өй борынча йөреп, булган хәзинәнең астын-өскә китереп тенти-тенти үзәкләргә үткән салымчылар артты. Нәҗметдин хаҗиның да түшәккә менгән хаста кебек тәнендәге җанын чак саклаган кибет аламасын атнасына өч-дүрт мәртәбә дөбер-шатыр китереп актардылар. Тауарлар искерә башлады, керем бетте.

Хаҗи киңәшкә дип мәхәллә имамы Габделхәй хәзрәт янына барган иде, тегесе көтелмәгән тәкъдим белән шаккаттырды.

—Көймә комга терәлде, без дә ипи белән суга утырган дәрвиш хәлендә, хаҗи. Аптырагач, кияүне Кореяга күчерергә булдым. Монда сәүдә өчен бөтенләй юл ябык, ә тегендә, хак булса, салым талап җелегеңне суырмыйлар икән. Дөя зур дип, ризык үзе аның авызына барып керми. Без тәвәккәлләргә булдык. Теләсәң, кушыл, хаҗи...

Көзге салкын җилләр башлангач юлга чыктылар. Разия белән Касыйм Токиода кибет аламасын саклап калды, Нәҗметдин хаҗи үзе белән бергә ике кечкенә баланы да алды. Чыннан да, Кореяда оядан бәбкә урларга килгән козгын шикелле туктаусыз иснәнеп йөрүче салымчылар юк, сәүдә сукмаклары иркен икән. Хаҗи Мэйдэн каласына килүгә үк бал-балавыз белән сату итәргә керește. Кыш урталарында кием-салым кибете ачып җибәрде. Бер уйласаң, җиңеңне сызган да эшлә генә инде. Әмма, юк, тәкъдир хәерче юрганы сыман кыска икән бит ул. Бер якка тартасың, икенче якта ярык килеп чыга.

Берсе сигез, икенчесе алты яшьтә булган Нәҗия белән Расих ишек алдыннан көнаралаш тәпәләнеп йә елашып кайта башладылар. Урыс белән чиктәш булып гасырлар буе сугышып яшәгәнгә күрә, кореялыларның өлкәннәре генә түгел, сабыйларына тикле үчле, усал. Боларның берсе дә синең татарлыгыңны, качаклыгыңны искә алып тормый. Син Рәсәйдән килгәнсең икән, мөһер һәркемгә бер: димәк, дошман. Кореяда мөселман гаиләләре байтак дистәләгән, әмма аларга монда мәдрәсә-фәлән ачарга һич рөхсәт юк.

Телиме-теләмиме, Нәҗметдин дә Токио урамнарын сагына башлады. Бер ишегалдында алар өч япон гаиләсе белән бергә тордылар, читкә китеп күз салсаң, үзара тыныч-ипле яшәгәннәр икән. Японнарның балалары да байтак кына иде, тик тавыштыннары бөтенләй чыкмады бит. Сабыйларның ихатада ниндидер утыргыч йә үсемлек сындырган чаклары да булды. Урыс яки татар булса, әллә кайчан канга батышып, сугышып бетәр иде. Ә японнар сабый чактан башлап тәрбияле, сабыр, алар үзара кычкырып талашуны белми. Иң яман итеп сүгенгән сүзләре дә: «ахмак, тиле»...

Икенче елның җәй ахырына хәтле тарта-суза түзеп йөрде дә, Нәҗметдин хаҗи янә Токиога әйләнеп кайтырга мәҗбүр булды. Ләкин бәла дигәннәре күләгә сыман ияреп кайтып җитте.

* * *

Утыз беренче елның көз башында Нәҗметдин хаҗи белән улы Касыймның икесен дә кулга алдылар. Югыйсә, аларның гаиләсе «белмәгәннең башы авыртмый» дигән сыман һичбер төрле сәясәткә тыгылмый-катнашмый, күбесенчә хуҗасы намаз укыганда почмакта шым гына утыручы мулла песие шикелле тавыш-тынсыз яшәүне мәгкуль күрә иде.

Аталы-уллы качак татарларны Сугамо дип аталган соры төрмәгә илтеп бикләделәр. Элегрәк ишеткәннәре бар: бирегә үлемгә хөкем ителгән иң яман җинаятьчеләрне генә китерәләр, моннан исән чыгу юлы бөтенләй юк икән. Ике качак татар япон

императорының шәхси дошманнары яки дуамал башкисәрләр белән тиңләрлек ни эшләгән?

Сорау алырга әүвәл Нәҗметдин хаҗине йөртеп аптыраттылар. Сораулары бер үк:

—Синең якташларың ник Харбинда торып калды да, ни максаттан син берүзең Японияга килдең? Кореяга нигә дип барган идең, анда сиңа нинди өстәмә бурыч житкерелде?

—Мәскәү сине ни өчен Японияга юллады? Мәскәү белән бәйләнешкә керү каналларың нинди?

Нәҗметдин хаҗи үзенең үткән гомер юлын кимендә ун мәртәбә бәйнә-бәйнә сөйләп биргәннән соң да ышанучы кеше табылмады. Хаҗины төннәрен алып китеп тә кыйный-кыйный газаплый башладылар. Өстәвенә, Япониядә көздән алып язга кадәр сузыла торган яңгырлар һәм дымлылык тәэсир итте бугай. Җиденче дистәсен ваклаган хаҗи көннәрдән-беркөнне бөтенләй аяксыз калды. Болай да ияк-яңакларын ап-ак сакал-мыек каплаган хаҗигә туксан яшьлек картлар төсе керде. Ике ай чамасы шулай тинтерәттеләр. Аннары иң көчле ядрәләр дә алалмаслык диварларны сытып, зинданнарга бер-бер артлы гайре сәер хәбәрләр килеп керде.

—Башында егермеләп самурай офицеры торган солдатлар хөкүмәттә инкыйлаб ясаганнар. Самурайлар өч министрны кылыч белән тураклап ташлаганнар. Премьер Танака бөтенләй юкка чыккан. Император аның урынына Окада дигән кешене билгеләгән. Самурайлар чигенми, илдә хәрби диктатура урнашуын таләп итә икән.

Атна-ун көн чамасы да ара үтмәде, тагын бер яңалык:

—Японнар Кытайдагы Мукден каласына бәреп кергән. Кытайлар җан-фәрманга кача. Япон дивизияләре бөтен Маньчжурияне яулап алганчы сугышачак икән...

Нәҗметдин хаҗине газаплауның кирәге калмады бугай, чыгарып җибәрделәр. Егерме яшен тутырган Касыйм да чыгарылды, тик иреккә түгел. Хөкүмәт кулына корал тотардай һәммә ирне армиягә ала, япон телен, гореф-гадәтләрен камил өйрәнеп өлгергән Касыйм моннан ары Маньчжурия фронтында тылмач булып хезмәт итәчәк икән.

* * *

Касыйм югалды, әмма, аның урынына дигән төсле, япон жирендә Харбин, Мукден каласыннан күченгән татарлар пәйда була башлады. Ни өчендер күпләп килмәделәр. Санай урамындагы мәхәлләгә ун-унбишләп гаилә кушылгандыр. Араларында Әгерже ягыннан беркем дә юк иде. Бик озак көттергәч кенә Гыймади абзый ялгыз күчеп килде. Харбин ягы хәлләрен шул аңлатты.

—И-и, туганым, «карт агачны күчереп утыртмыйлар», дип бер дә юкка гына әйтмәгән икән шул ата-баба. Күпме гомер уздың, ә чит җирдә әле һаман бер төрле дә тамыр җибәрә алмыйбыз бит. Ике-өч ел элек Гоминьдан хөкүмәте Кытайдан урыс гаскәрләрен куа башлагач, и-и, сөенгән идек. Иллә мәгәр сөенечебез очкылык тоткан шикелле кыска гына булды. Урыс урынына әүвәл Харбинга, аннары бөтен Маньчжуриягә япун солдатлары кереп тулды. Бер уйласаң, кытай ни дә, япун ни—бездәй качакларга аермасы бөтенләй юк шикелле. Мәгәр япуннар да сарык көтүенә ябырылган бүреләр сыман азына башладылар. Хәзер аларны Монголиягә, аннары Рәсәйгә басып керергә җыена, диләр. Ә мин сине элек килгәндә дә кисәткән идем инде. Урыс тешен батырган калҗаны мәңге ычкындырмый. Кайсы якта, нинди генә җирне басып алмасын, ул икенче көнне үк «бу безнең ата-баба җире», дип бугаз ера башлый. Димәк, озакламый урыс белән япун арасында бик зур дау кубачак. Ә безгә ике ут арасында торып калу хәтәр. Йә теге, йә бу як барыбер өтәчәк безне. Шуңа күрә Харбиндагы бик күп татар Төркиягә качты. Минем улым белән киявем дә шунда. Ә мин монда мантып булмасмы дип, сезнең янга килдем. Безгә кояш кайда якты чырай багар, тәкъдир үзе тәгаенләр әле...

Укмашып киттеләр, ул-бу сизелмәде. Көнбатышта сугыш хәрәкәтләре баруга карамастан, качак мөселманнар Япониянең Нагоя белән Кобэ калаларында да яңа мәчет манарасы күтәрделәр, аңа терәп, шәкертләр өчен мәктәп салдырдылар. Әлеге изге гамәлләр хакындагы хәбәр ерак Төркиягә дә барып җиткән, ахры. Санай урамындагы мәхәлләнең мөтәвәллиятендә күркә сыман кабарынып йөргән Кырым татары Вәли беркөнне намаз алдыннан зур яңалык әйтте.

—Мәүлид аенда Төркиядән Гаяз Исхакый җәнабләре килә. Рәсәйдән куылган бар юксыллар өчен бердәм татар-башкорт җәмгыятен нигезләү, «Казан» журналын нәшер итү хакында сөйләшүләр булачак.

Гаяз хәзрәт—татар дөньясында исеме яңгыраган мәшһүр, олуг кеше. Аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» атамалы язмасы заманында бар инсанны шаккаттырган иде. Большевиклар инкыйлабыннан соң бердәм татар-башкорт җөмһүрияте төзү уе белән янып йөрде. Хәлбуки, большевиклар аның койрыгына басты, күрәсең, ачлык елны Гаяз хәзрәт тәүге мөһаҗирләр эзеннән Рәсәйдән чыгып качты. Менә, Япониягә килә. Качак татарларга ул хәзер ниләр тәкъдим итәр?

Көтеп житкерделәр. Нәҗметдин хаҗиның Исхакыйны инкыйлабтан соң берничә мәртәбә Казан, Уфадагы шау-шулы җыелышларда күргәне бар иде. Хәзер, кыяфәтенә карап, аны элеккеге, егет чагы белән чагыштырып торды. Гәүдәгә калынайган, буйга утырган сыман. Чигә чәчләренә чал йөгергән. Мыегы гына, сагыз сөрткән шикелле, элеккедәй кара. Күз кабаклары шешенгән, елмаерга ашыкмый. Юк, бу элеккеге, сикереп менеп йодрыгы белән мөнбәр төя торган Исхакый түгел инде. Авызын кайнар ашка пешергән кеше кебек, ул хәзер һәр сүзен үлчәп сөйләшә, үз-үзен тотышына, кыяфәтенә олпатлык һәм бәя белү иңгән.

«Исламия» мәчете идәненә тезелешеп утырган качакларга ул әүвәл Рәсәйдә Идел-Урал штаты төзүнең зарурлыгы турында сөйләде, большевиклар хакимиятенең тиздән җимереләчәген кат-кат гоманлады. Аннары сүз акрын-акрын гына качак татарлар җәмгыятен төзү турындагы кысаларга күчте.

—Бөек Туран дәүләте, олуг Туран Урдасы,—дип әллә ничә тапкыр кабатлады ул.—Бүген төрки дөньяда коллыкка төшмәгән бер генә ил, бер генә дәүләт иректе, азат рәвештә торып калды. Ул да булса Төркия. Ул—бөтен төрки дөньясы өчен әләм һәм дә ки барча төрки халыклар шул әләм тирәсенә тупланырга тиеш.

Габделхәй хәзрәт Корбангали сикереп каршы чыкты.

—Синең тәгамеңне бүген төрекләр туендыра, шуңа нисбәтән төрекләр җырын җырлыйсың булыр, Гаяз хәзрәт. Ә Япониядә безнең хәл катлаулырак. Монда ислам динен тотучылар бик санаулы гына. Без монысы төрки, тегесе гарәп яки фарсы дип берсен тартып, икенчесен этеп яши алмыйбыз. Безнең өчен төреге дә, гарәбе дә Аллаһ колларыдыр. Японнар тарафыннан йотылмыйк, балаларыбызны японлашудан саклап калыйк дисәк, безнең өчен иң дөрес юл төреккә-гарәбкә, татарга-якутка аермыйча Аллаһка табынудыр. Шуңа күрә безнең җәмгыятебезнең нигезе дә фәкать ислам дине генә була ала, әләмебез—Коръән.

Нәҗметдин хаҗи инкыйлабтан соңгы елларда Уфа, Казан җыелышларында күргән төсле Гаяз хәзрәт капылт кызып китте. Габделхәй хәзрәт белән үзара усал сүзләр алмаша-алмаша байтак ызгыштылар. Ахырда Гаяз хәзрәт кулын өметсез селтәп, амин да тотып тормыйча мәчет мөнбәрен ташлап чыгып китте. Икенче көнне исә аны бөтенләй Төркиягә кайтып киткән, диделәр. Күнелләрдә юшкын утырып калды.

* * *

Гыймади агай юраган юш килде. Утыз алтынчы елның февраленда самурайлар Токиода тагын фетнә күтәрделәр, иске хөкүмәтне куып тараттылар. Император Хирохито хөкүмәт башлыгы Окаданы төшереп, аның урынына Коноэ атлы бер туганын куярга мәҗбүр булды. Аңа карап, самурайларның таләбе үзгәрмәде.

—Европа—ул Азиянең ярыматавы гына. Ә Азия безнеке булырга тиеш!

«Яңа премьер көнбатышта тупланган ике армиягә Монголиягә бәреп керү өчен әзер торырга әмер биргән», дигән хәбәр тараттылар. Үз калҗасын уяу саклаучы Совет дәүләтенең җавап сүзе озак көттермәде.

—Рәсәй белән Монголия үзара яңа солых төзегән. Япония монгол җиренә нәфес суза икән, урыс армиясе дә үз туганын яклап сугышка керәчәк, ди.

Мондый солых япон хөкүмәте өчен көтелмәгән күсәк булды, ахры, ярты ел чамасы «ыһ» иткән дә тавыш бирмәделәр. Кышка аяк басканнар иде, яңа хәбәр:

—Принц Коноэ Германиягә баргач, андагы Риббентроп белән корыч сыман ныклы солых корган. Ул «Коминтернга каршы пакт» дип аталса да, төп максаты японнарны урыс дәүләте белән сугышка керергә котырту, кыстау икән.

Бу чаклы уңыштан, ис тигән шикелле, хөкүмәтнең башы әйләнде, күрәсең. Алдын-артын уйлап тормыйча, Коноэ көнбатыштагы кайсыдыр бер дивизиягә совет чиген бозарга әмер биргән. Самурайлар Владивостоктан әлләни ерак булмаган Ханко күле буенда совет гаскәрләренә каршы сугыш башлаганнар. Әмма бәрелеш бер атна чамасы да сузылмаган, советныкылар японнарны бүре көтүенә килеп кергән тилергән эт

урынына талап чыгарганнар. Ул көннәрдә бөтен Япония нахакка типкәләнгән сабый шикелле кайгыга чумып йөрде. Кемпентайныкылар тагын, бер сәбәпсез көе, Нәҗметдин белән Касыймны полиция бүлегендә кыйнап кайтардылар.

Тик япон хөкүмәте һичбер төрле сабак алырга җыенмады бугай. Берзаманны Токио ярлары Германиядән килгән кораблар белән тулды. Бик тә яшерен сер тараткан шикелле, колактан-колакка гына хәбәр җибәрделәр:

—Немецлар Япониядә танк, туп, автомобиль заводлары төзергә хыяллана. Байлыкларын хәрби максатка түккән байчуралар биш ел буена бернинди дә салым түләмиләр.

Әлеге «сер»гә ия булуга ук Касыйм әтисен йокыдан уяткан шикелле төрткәләргә кереште.

—Немецлар моннан тиз генә китәчәк түгел. Мин әйтте диярсең, алар японнарны әллә нинди капкыннарга илтеп кертәчәк әле. Әмма безгә йоклап яту гөнаһ. «Алма пеш, авызга төш», дип көтеп ятып булмый. Немецларга кушылып, нинди дә булса яңа шөгыль кузгатырга кирәк.

—Алар монда хәрби заводлар кормакчы булалар бит. Качып китеп ятим хәлендә йөрсәң дә, син үз Рәсәеңә каршы мылтык төзәргә җыенасыңмыни?—дип Нәҗметдин ду купты, ә Касыймның үз кырыгы кырык.

—Һе, нәкъ менә мылтык, туп, ядрә ясау заводларын гына кор, димәгән. Шул немец агентларына сырпаланап, ачуым килмәгәе, шырпы фабрикасы ачып җибәрсәң дә була. Хәзер Япония белән немец кулы идарә итәчәк, әйдә, шуннан файдаланыйк, димен бит мин сиңа.

Нәҗметдин тойды, сиземләде. Касыйм яңа буын кешесе, ул үзенчә чәчә һәм үзенчә ура. Аны иске кәвеш кияргә үгетләү—өметсез эш. Ул үз ниятен һаман-һаман тамчы сыман бертуктаусыз коеп торачак бит. Кул селтәми булмый.

—Әй, үзең чамала инде,—диде ул ахырдан.—Мәгәр үз гомереңдә Рәсәйгә каршы селтәнәсе булма. Аның өчен уйнаштан туган сыман булсак та, ул барыбер безгә газиз Ватан...

Касыйм бер ай эчендә үзенә түбә тапты. Германиянең «Отукен» фирмасы филиал ача икән. Иң беренче чиратта «Штукен»га сүс белән каучук кирәккән, ди. Касыйм баш-аягы белән шуңа кереп чумды, өйгә кайтып керми. Бер күренгән чакта Нәҗметдин аңа «үтилче», дип төрттереп алган иде, Касыйм ике-өч җөмлә белән аның авызына су каптырды.

—Иң биек тауның очына да итәктән башлап менәләр бит, әткәй. Әнә, «Мерседес» фирмасыннан килгән берәү мине монда үз вәкиле булырга чакырып йөри...

Шапырынмаган икән, Касыйм бераздан, чыннан да, зур автомобиль фирмасының Япониядәге вәкиле иде инде. Сәяси хәлләрне дә чиста су төбенә караган шикелле алдан күреп торган. Нәкъ җәй уртасында японнар Вампин каласы янында Кытай җирләренә бәреп керде. Боларның һәрбер полк яки рота командирлары янына хәрби киңәшчеләр булып немец офицерлары кереп тулган, өстәвенә, эт типкесе хәлендә йөргән генерал Чан Кай-ши да япон гаскәрләрен колач җәеп каршылаган икән. Коммунистик Кытай төзергә җыенган кызыл комиссарлар чигенә башлаганнар. Әлбәттә инде, хәзер совет Рәсәе дә йоклап ятмый, төп хәрби киңәшче булып Кытайга маршал Блюхер үзе килеп төшкән, күкне совет очкычлары биләп алган. Ләкин Кытайдагы кызыл комиссарларга җитди уңыш елмаймаган бугай, Блюхерны Мәскәүгә чакырып кулга алганнар, ди.

Японнарны әллә Кытайдагы җиңүләр сукырайтты инде, әллә немец киңәшчеләренең коткысына ансат бирелделәр—нәкъ бер елдан соң алар Хәсән күле буенда Рәсәй җирләренә бәреп керде. Ун көн үтүгә үк совет гаскәрләре аларны куып чыгарса да, сабак алмадылар. Маньчжуриягә тупланган ике зур армия бик тиз арада Халхин-Гол тирәли ике яклап Монголия җиренә басып керде. Максатлары, сукырларча, шул ук:

—Байкал арты—безнең туган җир!..

Корабларга тутырып, Япониягә читтә һәлак булганнарны кайтара башладылар. Ә биредә болай да һәр йорт саен диярлек тоташ күз яшьләре. Әле явыз салымчылар соңгы байлыгыңны тәяп чыгып китә, әле буыны да юньләп ныгымаган яп-яшь егетләрне армиягә көчләп алалар. Сугыш җир хуҗасы японны, табыш өмет итеп утрау дәүләткә килеп чыккан кытай белән уйгурны, качак татар, калмыкны—һәммәсен берьюлы тигезләде сыман. Утлар-сулар киселде, кибетләрдә ирекле рәвештә ризык

сату бетте, һичбер ихатада уен-көлешү юк. Нәҗметдин хаҗи белән Разия абыстай өчен бердәнбер юаныч шул—аларның Касыймына тиюче юк, ихаталарын да япон шымчылары урап үтә иде.

* * *

Рәсәй җиренә Гитлер армиясе күптән бәреп кергән, авыр яулар Мәскәү тирәсендә бара иде инде. Япон гәзитләрен актармалы түгел, башыннан азагына тикле барча битләрне фашистларның җиңүләренә яки фюрерның бөеклегенә мәдхия уку белән шыплап тутырганнар. Германия вәкилләре яки япон хәрбиләре янына якын килсәң, телләрендә фәкать бер генә җыр:

—Немецлар Мәскәүне басып алуга ук, бу яклап Рәсәйгә япон гаскәрләре бәреп керә. Утыздан артык дивизия әмер генә көтә. Самурайлар бердәм ант итәләр: «Байкалга хәтле булган җирләр алты атнада яулап алыначак». Сугышчылар өчен сигезәр дәрәҗәдәге «Чыгып килгән кояш нурлары» һәм «Изге хәзинә» орденнары әзерләнгән инде. Гитлерның девизы «Дран? нах Остен» булса, безнең чакыру «Дран? нах Зюйд!»

Сугыш кайсы гына илгә каршы алып барылмасын, ул милләтне берләштерә икән. Японнарны һич танырлык түгел. Котырган үгез каны эчеп ярсыганнар диярсең, һәр япон ире фронтка ыргыла, хөкүмәттән йә Советлар Союзына, йә Сингапурга каршы сугыш ачуларын таләп итә. Хөкүмәттә тагын инкыйлаб үткәрелде, хакимият башына Тодзио атлы сугыш чукмары менде. Итагаки, Доихара дигән аның урынбасарлары да, шулай ук, генераллар. Самурайлар хәзер һәр кич саен немец кабакларына кереп типтерәләр. Һәрбер кабак гейшалар һәм исерекләр белән тулы.

Шушы мәхшәрне тыныч кына күзәтердәй көче калмагач, Касыйм японнарның борынгы башкаласы Нарага барып кайтырга булды. Японнар әле былтыр гына үз империяләренең ике мең алты йөз еллыгын шаулап-зурлап үткәргәннәр иде, Нарага да яңарыш канаты кагылып узган икән. Үзәктәге Зур Будда храмы урнашкан мәйданга тоташ алтыннан коелган яңа Будда сынын куйганнар. Аның янәшәсендә коелган бакыр лалә чәчәге дә саф алтын шикелле ялтырап тора. Мәйдан тулып эреле-ваклы болан көтүләре йөри. Аларга кычкыручы, бармак янаучы юк. Бирегә килгән һәркем нинди дә булса ризык табып аларның күңелен күрергә, кулы белән кагылып иркәләргә омтыла...

Кайту юлына Касыйм шактый гына соңга калып чыкты. Юл караңгы, ара ерак түгел, ул машинасын куаламыйча гына кайтырга исәп тоткан иде. Инде мәркәзгә якынайган чакта әүвәл аның игътибарын Киото бистәсе ягыннан килүче ялгыз фара яктысы, аннары көчле мотоцикл гөрелтесе җәлеп итте. Төн уртасы барыбер узган инде, дуамал рәвештә кая ашыга бу?

Юкка түгел икән. Киото бистәсе урнашкан тау өстендә бер-берсен узышып чапкан янә ике ут күренде. Шик калмады: тегеләр куа, ялгыз мотоциклчы җан-фәрманга качып бара. Нигә кача, нинди гөнаһ кылган, куучылары кем?

Ялгыз мотоцикл Касыйм килгән якка оча иде. Хуҗасы алда кискен борылыш көткәнен белмәгәндер, ахры. Бер мизгелдә тәгәрмәчләр юлдагы ташлар өстендә усал сызгырды да, бичара хуҗа мотоциклы белән бергә әйләнә-тулгана читкә чыгып очты. Куа килүчеләр белән ике ара әле шактый ерак иде. Касыйм машинасын юлга аркылы китереп кискен туктатты һәм бәхетсез мотоциклчы янына сикерде.

Бәхетсез юлчы канга баткан, әмма аңында, акылында иде әле. Ул үз өстенә иелгән Касыйымны шәйләүгә үк, телгәләнгән иреннәрен ачып сәер сорау бирде.

—Син кем? Кайсы як кешесе?

—Татар,—диде Касыйм аптырагач.—Качак татар. Исемем Касыйм. Немецларның «Мерседес» дигән фирмасында эшлим.

Бичара юлчы бер йотым саф һава сулагандай булды. Көтмәгәндә рус сүзләре белән тезеп китте.

—Качак булсаң да, Россияне каргап яшәмисеңдер бит? Әйт, Касыйм-сан!

—Юк, каргамыйм.

—Каргамасаң, сиңа шул үтенеч.—Яралы юлчы түш кесәсенә тыгылды, кечкенә төргәк алды.—Менә моны яшер. Син немец фирмасында эшлисең, Германия илчесе сыман, сине тентемәсләр. Ә соңыннан Исия урамына илтеп тапшырырсың. Онытма, Исия урамы, тугызынчы йорт. Мияги дигән рәссам каршы алыр. Озак сузма, бүген үк илтеп тапшыр. Моны Рәсәй көтә...

Юл читенә Киото ягыннан килеп җиткән мотоцикл фараларының яктысы төшә

башлады. Касыйм яралы, сәер юлчыны өскә таба өстерәгән булды. Ашыга-кабалана, барыбер, сорау бирде.

—Сине кем дип белеп калыйм соң? Исемең ничек?

—Рамзай*. Бәлки, берәр кайчан ишетерсең әле...

«Рамзай» бик кадерле кеше иде, күрәсең, куа килүчеләр аны шундук иң кыйммәтле шифаханәләрнең берсенә алып китте. «Рамзай» хакында шуннан ары бер төрле дә хәбәр килеп ирешмәде.

* * *

Шулай да, әкәмәт бу «дөнья, хәят, яшәеш» дигәннәре! Бөтен җирдә җәһәннәмнәренә биргесез аяусыз сугыш бара, сәгать саен меңәрләгән җаннар кыела, ә Япониядә гап-гади кеше хокукларына да ия булалмаган Касыйм өйләнергә йөри!

Бу турыда кайтып авыз ачкач, Нәҗметдин хаҗи белән Разия абыстай Касыймны тәненнән явыз җен кугандай тотып өшкерделәр.

—Бөтен кеше ничек итеп җан сакларга белми, ә бу тәмугъ уртасында торган килеш хатын ала, имеш! Утыз биш яшеңә җиткәнче башлы-күзле булу—ике ятып төшеңә бер тапкыр да кергәне юк иде. Ә хәзер кәләш таптың да капландың. Мондый мәхшәр заманада синең сымак камыт киеп, арба тагып кая бармак кирәк? Әллә җен алыштырдымы соң үзеңне, тфү-тфү!

Юк, хаҗи белән абыстай беркадәр харамлыйлар, моны үзләре дә яхшы белә иде. Касыйм әле Харбинда чагында ук качак кызларына күз аткалап йөрде. Ул вакытта башы бик яшь иде, ярәшү-кавышу хакында сүз дә кузгатмады. Япониягә килгәч тә, «хәерчегә җил каршы» дигән шикелле, Касыймга яшьтәш-чордаш булырдай кыз очрамады. Разия абыстай янына кача-поса килеп, Касыймны уйгыр, төрек, бурят кызлары белән таныштырырга кыстап карадылар. Ана кеше үзе үк кылыч белән селтәнгәндәй шундук каршы төште.

—Өйләнсә, татар кызын гына ала, башкача фатихам юк!..

Инде менә, «бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына» дигәндәй, кырык бишенче елның язында, әллә кайлардан урап, Токиога Аппакайлар гаиләсе килеп төште. Сорашкач шаккаттылар: Аппакайлар Харбиннан әүвәл Австралия ягына чыгып качкан, аннары гына Сингапурга барып урнашканнар икән. Ләкин ничә әйтсәң дә, бер сүз: хәерченең чалкан егылса да борыны каный шул ул. Сингапурга былтыр япон солдатлары басып кергән, шулар ук Аппакайларны Токио пароходына төяп аткарганнар.

Касыйм Аппакайларның җиткән кызлары Салисә белән танышуга, тәүге чәчәк күргән язгы бал корты шикелле, аңа чат ябышты. Немец фирмасында эшләп йөргән «капиталист» Касыйм да Аппакайлар күңеленә хуш килгәндер инде, болар бер очрашу вакытында «ашыгып-хаталанып» ризалык та биреп ташлаганнар. Шуннан бирле әтисе белән әнисенә Касыйм күз ачырмый:

—Ярәшергә, калымнарын түләп куярга кирәк, яучы җибәрегез!..

—И-и, рамазан аенда, ураза өстендә кеше мәшәкатьләп йөрмик. Корбан гаетен үткәрик, шуннан ары җибәрербез инде,—дип, «яшь кияү»не көч-хәл белән үгетләп җиткерделәр.

Әмма җәй аена аяк басканнар гына иде, Америка очкычлары Токио өстенә бертөзлексез бомба ташкыны түгәргә тотындылар. Урамнар гына түгел, унар чакрымга сузылган заводлар, причаллар һәм бистәләр юкка чыкты. Хәрабәләрне үтеп йөрмәле түгел, исән калган йортлар сирәк иде. Касыйм олыгайган әти-әнисен дә, Аппакайларны да шактый читтә, Кюсю утравында нигезләнгән Нагасаки каласына күчерергә булды.

—Япония тулысынча капитуляция ясамыйча торып, Америка Токионы җимерүдән туктаячак түгел. Хәрабәләр астында калып изелгәнче, әйдә, ичмаса, тынычрак калага күчеп җан саклагыз. Сугыш барыбер бетәр, шул чагында кабат кушылырбыз.

Сугымга чыгарылган мал диярсең, һәммәсе дә сүзсез буйсындылар. Якыннарын Касыйм үзе Нагасакига илтеп урнаштырды. Кала уртасында элек күн заводы булып исәпләнгән корылмалар арасында бер барак буш икән, шуның бүлмәләренә кереп төпләнделәр. Тын океан ягындагы Кофу бугазына терәп мөселманнар өчен лазарет оештырганнар, Салисә шунда йөреп эшләргә риза булды. Аерылган чакта, Касыймның күзләренә төбәлеп, сәер итеп әйтте:

**Рамзай*—совет разведчигы Рихард Зоргеның яшерен кушаматы.

—Болай да соң табыштык. Сак белән Сок кебек булмасак кына ярар иде инде...

Касыйм Токиога әйләнеп кайтса, тагын шул ук мәхшәр. Америка очкычлары, козгыннар өере шикелле дистәләп-йөзәрләп килеп, япон мәркәзенең исән калган йортларын үтүклиләр. Кала дистә чакрымнарга сузылган хәрабәләр өеменә әверелде, түбәләре, ишек-тәрәзләре умырып ташланган мескен алачыкка охшап калды. Җитмәсә, болай да кул-аягын бәйләп иң эссе мунча ләүкәсенә ташланган бичара өстенә бер ләгән кайнар су сипкән шикелле, тәнеңне-җаныңны өтеп алырлык хәбәр тараттылар:

—Советлар Союзы Япониягә каршы сугыш ачарга җыена, Германиядән бушаган бар гаскәрен хәзер көнчыгыш чикләргә таба күчерә икән.

Аягында йөри алырдай барча кеше, төбе тишелгән иске корабтагы күселәр көтүе шикелле, якын-тирәдәге утрауларга, тау һәм мәгарәләр арасына качып китте. Менәменә Совет гаскәрләренең бәреп керүен көттеләр, хәвеф-хафа басты. Һәм көтмәгәндә, баш түбәсенә тимер гөрзи белән китереп орган шикелле, явыз, кара хәбәр:

—Американлылар Хиросима каласына атом бомбасы ташлаганнар! Кала юкка чыккан!..

Ике көннән соң, Касыймны тәмам акылдан шаштырырлык яңа кара кайгы:

—Америка самолетлары Нагасаки өстенә дә бомба ташлап киткән. Нагасаки да вулкан өтеп үткәндәй бөтенләй җимерелгән...

Әүвәл Кюсю утравына һичкемне кертмәделәр. Көнбатышта Совет гаскәрләре Квантун армиясен пыр туздыра башлаган икән, корыч тәртип урнашты. Кайгы-хәсрәткә бирелү, матәм-шом күрсәтү—зур җинаять. «Япония—җир йөзендәге иң югары ямато расасының бишеге ул. Аны Ходай үзе шулай итеп яраткан. Аны җиңүче юк!..»

Мең төрле хәйлә һәм мең бәлаләр аша барып эләккәч, Касыйм Нагасаки каласын бөтенләй танымады. Шәһәр юкка чыккан, элеккеге бистәләр, храмнар, урамнар урынына ком-таш өемнәре. Бөтен якта корым, тузан, көл, күмерләр. Кайчандыр күн заводы булган, ә ике ай элек Касыйм әти-әнисен, якыннарын калдырып киткән бараклар урынында хәзер вулкан кратерыдай чокыр...

Корбаннар турында бик көттереп кенә хәбәр иттеләр.

—Хиросимада йөз кырык мең, Нагасакида җитмеш биш мең чамасы кеше янып юкка чыккан...

Касыймны җиһанга бәйләп торучы соңгы җеп өзелде...

Бар атна үтүгә Япониягә тәкәббер, таза, тук чырайлы Америка солдатлары кереп тулды. Император Хирохито, күрше бакчасына алма урларга кергәч тотылган юешборынлы малай сыман курка-йолка барып, Америка крейсерында берсүзсез капитуляция турындагы кәгазьгә кул куйды. Хәрби хөкүмәтне җитәкләгән Тодзио, Итагаки, Доихара кебек генералларны атып үтерделәр. Ничәмә-ничә еллар буена императорның иң тугры адъютанты булып торган генерал Сигеру, хурлыкка түзә алмыйча, харакири ясап үз гомерен кыйды. Аның үрнәгенә йөзләгән-меңәрләгән офицерлар, самурайлар, солдатлар иярделәр. Япония өстендә, әйтерсең, кояш сүнде.

Касыйм да, ирексездән, үз-үзенә кул салу турында уйлый башлаган иде инде. Кадерләргә-сөяргә туган җиреқ, ата-анаң, кәләшең, якыннарың калмагач, бу җиһанда яшәүнең нигә кирәге бар? Сине үзенә тартып, ымсындырып торучы барча учак сүнде. Ил дигәннәре көлгә әверелгән, аяк астыңда җир яна. Утыз биш яшеңә җитсәң дә, син һаман эт типкесе хәлендә. Ни солтан, ни олтан булачак түгел. Тәмугъ эчендәге кебек газаплануларга күпме түзмәк кирәк?

Беркөнне кич шундый караңгы уйлар томанында кайтып килә иде, ярымҗимерек йорт ихатасында «Исламия» мәхәлләсенең имамы Вәли хәзрәт каршы алды.

—Син нишләп инде өченче көн буе ни өйлә, ни ахшам намазында күренмисең, олан?

Касыйм эндәшмәгәч, сынаган шикелле, бик озак текәлеп торды. Аннан иплəп әйтте.

—Аппакайларның Салисәсе исән калган бит, олан. Ул бомба дигән нәмәстә төшкән чакта лазаретта булган. Берникадәр янган, мәгәр зыянлы түгел, ди. Ул хәзер Хонсю атавында, карантинда икән...

Бер-берсен эзләп табышып кочакларына чумгач, Касыйм белән Салисә икесе дә җиргә тезләнделәр. Кәләшендәге үзгәрешләрне кияү егет үзе бераздан гына күрде, сиземләде. Салисәнең бер як күкрәге янган, шул якта ук күз кабагы, муены, иңбашы, колак тирәләре чалгы белән тунап алган шикелле пеләшләнеп һәм тартылып тора. Бичара кыз үзенең мескен кыяфәтеннән бик хурлана, күрәсең, елый да елый.

—Мин бала да таба алмаячакмын икән бит. Ярәшкән чакта биргән вәгъдәңнән азат итәм. Мине жәлләп, бәхетсез булма, Касыйм...

«Исламия» мәчетендә никах укытып чыкканнан соң гына Салисә йөрәгендә йөрткән иң олы серен ачты.

—Моннан әлләни ерак булмаган атауда Михара дигән вулкан тавы бар икән. Яраткан егетләренә кияүгә чыга алмаган бәхетсез япон кызлары шул вулкан кратерына ташланып үләләр, ди. Ул тау юлын мин әле син эзләп килгәнче үк белешеп куйган идем...

* * *

Илле дүртенче елда Касыйм Токионың Шибуйя-Ку бистәсендә ике катлы өр-яңа йорт салдыра башлады. Моны ишеткәч, мәчеттәге бер намаздан соң да аңа тыныч кына кайтып китәргә ирек бирмәделәр.

—Бөтен татар Америка белән Австралия ягына чыгып китә. Соңгы елда, менә, Төркиягә дә капка зур ачылды. Япа-ялгыз утырып каласың бит, синең башыңа тай типкәнме әллә?

Касыйм әүвәл сантый дәрвиш сыман тик көлемсерәп йөрде, бәхәс-дәгъва куптарып маташмады. Әйе, дөм-саңгырау түгел, гел ишетеп тора. Пензаның Әлбәдән, Зөянең Шыгырдан, Дим буендагы Каргалы, Чулманны тирәләп утырган Биккол, Тирсә, Сарайлы, Камай авылларыннан качкан Еники, Алтынбай, Әҗем, Бөркет, Апанай, Сүлти, Зәйдулла нәселләре, баскак солдатларга ияреп, Америка белән Канадага күчеп киткәннәр. Аларның кайсылары Сан-Франциско яки Берлингейм, кайберсе хәтта Нью-Йоркның үзенә үк барып урнашкан, ди. Бәхет эзләп Төркиягә китүчеләр дә шактый ешайды. Дәлилләре хәтәр:

—Анда, ичмаса, туганнарыбыз арасында яшәячәкбез. Дин бер, тел бер. Монда йотылабыз...

Касыйм үзенә җомга намазында хөтбә укырга чират җиткәч кенә күңелендәге уйларын-хисләрен берьюлы ачып салды.

—Без егерме елдан артык гомер буе японнар куенында яшибез. Безне Рәсәйдәге кебек эт типкесендә йөрттеләр, дип әйтергә телем күтәрелми. Японнарга нинди кайгы-хәсрәт күрергә язган булса, барысын бергә кичтек. Сугыштан соң, бөтенләй йорт-түбәсез калгач та, читкә типмәделәр. Хөкүмәт безне японнар белән бер дәрәҗәдә күреп, өч ел буе байчураларының җәйге утарларында яшәтте, ризыктан аермады. Ашаган табагыңа төкермиләр, менә шуңа китмим. Монысы бер.

Касыйм мәчетнең намаз идененә тезләнгән илдәшләренә күз йөгертеп чыкты. Туганнарының һәммәсе гаепле кешеләр шикелле аска төбәлгәннәр, арадан берсе дә каршы әйтергә кыймый. Касыйм үзенең хак сөйләвен тоемлап, ары дәвам итте.

—Икенчесе. Ни үкенеч, монда килгәч, безнең бик күп туганнарыбыз вафат булды инде. Мәркәз уртасында җир алып, шунда мөселманнар зираты нигезләдек. Анда безнең әти-әни, абый-апа ята. Барыбыз да рәхәт эзләп, җайлы тормыш эзләп Төркиягә, Әмрикәгә китсәк, безнең ата-аналарыбызның каберләрен монда кем кадерләр? Хәзер шулай, бөтен дөнья буйлап, сансыз татар зиратлары сибеп йөрикмени?

Намаз иденендә тезләнгәннәр һаман дәшмәделәр. Җан тавышы белән, әрни-әрни, Касыйм янә тезде.

—Динең белән телеңне саклап калу өчен чәнечкеле атау эзләп табу да аз. Алар икесе дә менә монда, безнең йөрәктә ул. Иманыңны син үзең кяферләргә сатып җибәрмисең икән, синең йөрәгеңне тере тәнеңнән тартып алалмыйлар. Аңа фәкать без үзебез хуҗа. Ә японнар, Ходайга мең шөкер, безнең Аллаһны кимсетми, урыс кебек көчләп чукындырмый. Балаларыбыз өчен мөселман мәктәбе бар, Аллаһка табынырлык мәчетебез исән. Болар өчен һаман-һаман японнарга рәхмәт. Үз җирләренә безне сыендырган хуҗаларны «боларны урыс килеп кыйнады, Америка какты», дип кимсетергә, мескенгә чыгарырга бик ашыкмыйк әле. Япон кыйналды, әмма тезләнмәде. Мин ышанам, япон үзе дә, аның белән бергә без дә берзаманны тураеп басарбыз әле. Японның күк күкрәтер көннәре алда көтә. Мин ышанам...

Икенче кисәк

—Галимҗанның малае Рафил кайткан,—дигән хәбәргә Салавычта әүвәл ыжлап бирүче дә табылмады. Һе, кайткан икән, кайткан. Авылдагы һәр ун өйнең тугызыннан чыккан балалар хәзер читтә, калада яши. Атна саен уны-унбишләбе машинасында кайтып тора. Машинада җилдерүен-җилдерәләр, ә киткәндә, барыбер, ата-аналарының ит-каймагын төяп сыптыралар. Чираттагы бер «ач-әрвахның визиты» бу атнада Галимҗаннар өенә туры килгән икән, моның нәрсәсе бар?

Әмма бер-ике сәгатьтән соң ук Галимҗаннар ихатасы каршында тыз-быз йөгерешкән салавычлылар күренә башлады. Сәер сүзләр китте.

—Рафил Япониядә яшәүче ниндидер туганын тапкан, ди. Авылга Галимҗан белән Саниядән теге япунга хат яздырырга, аны кунакка чакыртырга, дип кайткан, ди.

Салавычлыларның астына шундук су йөгерде. Галимҗаннар гаиләсен уттан алып, суга салып чайкый башладылар.

—Ул Тәкәрлек Рафил бәләкәй чагыннан ук ырвач булды. Мәктәпкә өстенә май ягылган ипи алып бара да, классташлары каршында ашый башлап, шуның яртысын ручкага йә пеналга алыштыра иде. Институтка сынау биргәндә дә укытучылар каршына ниндидер солдат киемнәрен киеп кергән. Хәзер дә япунга качкан татарны берәр хәйлә белән савар өчен генә эзләп тапкан инде ул. Баксаң, бернинди дә туган-мазар түгелдер әле.

Шулчагында гына һәммәсе йокыдан типкәләп уятылган кешеләр шикелле капылт зиһенгә килделәр.

—Бәрәч, бәрәч! Ул Рафилга туган тиешле япун кем икән соң? Эрвәлүтсиядән соң безнең авылдан Нәҗметдин бай белән Госман хәзрәт чыгып качкан, дип сөйлиләр иде. Алар кайсы яклап Галимҗаннарга туган тиешле ди? Рафил тапкан япун безнең берәребезгә чынлап торып туган-кардәш булып чыкмагае...

Кичкә таба, көтүгә тупланган мал шикелле, Галимҗаннар ихатасы каршына бар авыл җыелды. Кунакка кайтып төшкән Рафил тарафына таләп катгый:

—Нинди ясалма туган эзләп таптың анда? Кайсы япуннан хат килде? Ниләр язган? Ул безнең кайсыбызга туган-кардәш тиеш? Әйдә, чык, авыл каршында сөйлә!..

Рафил институтларда гына түгел, хәтта аспирантураларда да укып йөргән кеше. Томаналарны күз чалымына китереп тормады, елгырлары-шомалары белән дә бәхәсгауга куптарып маташмады, әллә нинди ялтыравык сургычлар белән бизәлгән олы конвертны салавычлылар кулына чыгарды да бирде.

—Касыйм бәй сезгә дә, безгә дә бердәй авылдаштыр. Аның хатында бернинди дә сер юк. Һәммәгезгә сәлам юллаган, бергәләп укыгыз.

«Мин укыйм да, мин укыйм. Миңа бирегез»,—дип шәрран ярып кычкырсалар да, хатны тегеләй-болай итеп боргалап карауга ук ары аткардылар.

—Моның алды—гарәп, арты латин хәрефләре белән язылган бит! Моны кем аңласын?

Хат һәммә салавычлы кулыннан йөгереп узды, гарәп яки латин имласын сукалаучы бәндә табылмады. Ахырдан хатны, барыбер дә, Рафил кулына кире тоттырдылар.

—Син институт каридурларында, галимнәр арасында буталып йөргән кеше. Әйдә, үзең укы.

—«Сөүгеле Рафил туганыбыз, Гөлчәчәк килен, Сания сеңлебез, кияү әфәнде!»—дип кичәге аспирант егет хатны кычкырып укый башлагач, салавычлылар әле әрем капкан төсле йөзләрен сытып, иреннәрен бөрештереп, бөтенләй битарафсыз гына торган иде. Аннан соңгы җөмләләрне ишетүгә үк, ачлык елны бушка өләшенә башлаган бер телем икмәкне эләктереп калырга омтылган әрвахлар шикелле, берсен-берсе төртеп алга ыргылдылар.

—«Балалар вә бөтен туганнарыбыз, кардәшләрем, илдәшләр! Берегезне дә күреп белмәсәк тә, һәрбарчагызны сагынып, йөзегезгә багып сөйләшергә зар-интизар булып, авылдашларыгыз Касыйм белән Салисә Япониянең җылы җилләре аша һәммәгезгә юксыл тулы сәламнәр җибәреп, хәер-догаларыгызны өмет итеп кала. Шулай ук, Япония мәркәзендә яшәгән бәгъзе татарлар да, һәммәгезгә сагынулы сәламнәрен җибәреп, догагызны өмет итәләр. Сезнең барчагызга да иминлек эчендә сәламәт вә бәхетле яшәвегезне Җәнабе Аллаһтан теләп калабыз...»

—Чукынып кына китсен, борынгы заман калдыгы бит бу! Мулла бит бу!—дип

кычкырып җибәрде, түзмичә, мәңге йә кибет, йә берәр өмә тирәсендә болганып, бушлай стаканга табынып гомер иткән Руслан.

Әллә ничә авылдаш берьюлы, каз сыман ысылдап, «урыс тамак»ны шундук туктаттылар.

—Тс-с, алланы-мулланы силсәвиткә чакыртасы нәстә! Нинди кешеләр яза моны, нинди байлык туплап өлгергәннәр—шуны белеп бетерик, аннары синең белән бергә типтерербез.

Рафил каушамыйча ары дәвам итте.

—«Сездән хат килүгә, картлык көнебездә туганлык артты, дип бик шатландык. Ерак булсак та безне онытмаганнар, үзебезне күреп белмәсәләр дә, исемнәребездән таныйлар икән, дип бинайһә сөенештек. Без картайдык, кул-аяклар сызлый, фани дөньяда күрешер өмет калмады, ахирәттә генә кавышырбыз инде. Ә сез яшьләр, үзегез бер килеп китәрсез, иншалла. Ходайның рәхмәте киң ул. Безне искә алуыгыз өчен Ходай сезгә әҗер савапларын бирсен, амин!..»

Хат иясе алга таба үзләренең Япониягә ничек килеп эләгүләрен, ни рәвешле гомер сөрүләрен бәян иткән иде. Һәммәсе дә колакларын торгызып тыңладылар. Әһә, берсе Мөхетдин, икенчесе Аппакай нәселеннән икән боларның. Ата-бабалары элек Агыйдел, Иж, Салавыч буенда гына түгел, Оренбур ягында да зур утарлар тоткан. Касыйм хаҗи хәзер бөтен Япониядәге «Исламия» дигән җәмгыять рәисе (анысы пүчтәк!), ә иң мөһиме, ул төп заводы Германиядә булган «Мерседес» фирмасы филиалының президенты икән. Әнекәйгенәм! Буржуй, миллионер бит бу!..

Ә үзләре канәгать түгел һаман, зарланган булалар. Салисәсе, әнә, үзе турында ничек итеп яза:

—«Сездә инде салкыннар башланадыр, әле монда җылы. Мәгәр мин йөрәгем начарга күрә эссене бик яратмыйм, өйдән чыкмыйм. Дөрес, өйдә һава суыта торган машина бар, шул җиләслләтәдер... Аннары монда җир кечкенә булганга, өйләр бик тыгыз утырган. Өйләр биек, җил-һава йөрергә гел урын юк. Аның өстенә, автомобильләр хәйран калырлык күп, урамда һавадагы май исенә буылып интегәсең...»

Тыңлаучылар арасында күпләр эчтән генә «их, монда кайтарырга иде сезне, сәвит җәннәтендә мунча керсәгез иде сез», дип сүгенәләр, әмма бүлдермиләр. Ни әйтсәң дә, читтәге кешенең карашы кызык иде.

—«Карга баласы булып карга баласы да, кайсы якта гына тумасын, үзенчә кар-кар, дип кычкыра. Төркиягә яки Америкага баргач, Татарстаннан килгән, үз әти-әнисе янында яшәп тә татар телен белмәгән туганнарыбызны күреп шаккатабыз.»

—«Туган ил сагындыра. Кайтсак, беренче эш итеп, зиратка барып дога кылыр идек. Икенче—Салавыч суына аягыбызны тыгып утырыр идек.»

—«Адресыгызга Брежнев каласы дип язгансыз. Андый шәһәр кайсы якта була?.. Без сезгә хатыбызны әүвәл тасмага яздырып салган идек тә, урысча булмаган язма кабул ителми, дип илегездән кире кайтардылар... Безгә хат язган өчен әгәр сезгә авырлык-фәлән килсә, берүк борчылмагыз. Ходайның рәхмәте киң, бер табышкач югалмабыз әле...»

Менә шундый, моңсу гына, сагыну тулы бер хат. Рафил укып чыккач әле күпләр зиратта ясин догасын тыңлаган төсле җитдиләнеп, хисләренә чумып тик тордылар. Әмма ярты авылда кара төн уртасы үткәнче ут сүнмәде. Әле ир белән хатын капма-каршы утырып, әле күршеләр бер-берсенә йөреп баш ваттылар.

—Касыймның да, Салисәнең дә бабалары безнең районнан бит. Аларның нинди чыбык очлары монда торып калган да, алар кемгә кардәш? Нигә әле миллионер япунны Салавычка, хуҗа булып, Рафил белән Галимҗаннар чакырырга тиеш? Җитмәсә, Касыйм үзе тегеләрне Япониягә чакырып кунакка алмакчы була. Саллы гына хәер тамуы бар. Нигә әле нәкъ менә Галимҗаннныкылар корсак киереп барырга тиеш анда? Бәлки, без ул япунга аларга караганда да якынрак туганнардыр?..

Бераздан тәрәзәләрдә утлар сүнде, ләкин дистәләгән йорт хуҗалары таңга кадәр йоклый алмадылар.

* * *

Икенче көнне Комгансызлар урамында яшәгән ирле-хатынлы Артур белән Рәйсә ихата алдына сугышып чыкты.

—Мотоциклны гына түгел, кирәк булса сыерны да сатабыз, каһәренне өшкерим!

Синең балаларыңа сөт кирәк дип, Японияга бармый калырга мин тинтәкме әллә?— дип Артур Рәйсәне көрәк айкап куа чыккан иде, тегесе итәгең биленә тикле күтәреп җавап бирде.

—Менә моны күргәнең бармы, пакыч? Менә сиңа Япония, менә сиңа сыер!

Күрше-күлән халкы авыз ачып катты. Артуры тракторчы булып, Рәйсәсе мәктәптә укытып моңа чаклы күгәрченнәр кебек чөкердәшеп кенә яшиләр иде бит әле. Араларыннан нинди мәче узган?

Һәр икесен салавычлылар аерым-аерым урап алгач бары да ачыкланды. Рәйсәнең апасы Аппакайларның Казанда яшәгән бер энекәшендә кияүдә, Артур шуны белеп өлгерүгә, бер көн көтмичә, Японияга чыгып кыякларга нният иткән икән.

—Ашыкма, кияү, тумаган тайның билен сындырырсың,—дип Салавычтагылар Артурны әллә ничә тапкыр чалбар балагыннан тартып күктән җиргә төшермәкче булды, әмма күчәреннән ычкынган хуҗаның үз кырыгы кырык:

—Ырвач Рафил иртәгә үк ул япун Касыйм янына чыгып китә дә, аннан бер миллиюн акча эләктереп кайта. Рафил Касыймга пычагым да туган тиеш түгел. Минем права зуррак! Или йорт-җирне сатам да япунга чыгып китәм, или...

Артур шуннан артыгына аңлатма-мазар биреп маташмады. Ә зәхмәт дигәннәре тап-таза ирне дә сугып ега икән.

* * *

Бәйдәге ач этне майлы сөяк күрсәтеп котырткан шикелле, Рафил берәр айдан авылга өр-яңа хәбәрләр төяп кайтып керде.

—Касыйм хаҗи японча да, урысча, татарча да тутырып, өч нөсхәдә чакыру язып салган. Шуның берсен япон консуллыгына илтеп бирәсе бар. Японнар, гадәттә, виза алганда бернинди тоткарлык йә киртә ясамый, ди. Аннары чит илгә чыгып йөри торган махсус паспорт артыннан да юыртасы бар икән бит әле. Менә шунысын алу өчен безнең оешмалар синең нәселеңне җиде бабаңа чаклы чокып тикшерә, кырыкмаса-кырык иләк аша җилкеп чыгара, ди. Безнең берәр чыбык очы бабай мең ике йөз кырыгынчы елгы Нева сугышына чаклы немец яки швед баронында кучерлыкта йөрмәгән булса ярый әле тагын...

Яңалык, сәгате-минуты белән чүпрәдәй күпертелеп, Салавычтагы барча ихата-каралтыны урап чыкты. Хәбәр бер капкадан икенчесенә күчеп йөргән чакта чабата олтырагыдай нинди генә койрык такмадылар?

—Рафилнең хатыны Гөлчәчәк чирле икән бит ул. Чакыру әрәм булмасын өчен, Рафил Галимҗан белән Санияны алырга дип кайткан.

—Япуннарда анда кунакларның санына карап бүләк бирәләр, ди. Рафил шуңа әтиәнисен дә үзе белән алып бара инде.

—Рафилның аның институтта чакта ук арты пычранган, шуңа күрә кандидатлыгын да яклатып тормый тибеп чыгарганнар. Менә тагын аңа Япуниягә чыгарга рөхсәт бирмиләр дә, Касыйм байны савып кайту өчен Рафил хәзер Галимҗан белән Санияны эшкә җигә инде...

Салавычлылар бүген дә тәрәзәләрдәге утларын бик соң сүндерделәр. Ләкин берсе дә гырлый башларга җитешмәде бугай. Йөрәккә шом салып, урам буйлап әллә ничә ир-ат кычкырып узды.

—Галимҗаннарның мунчасы белән лапаслары яна. По-жар, пож-жар!

* * *

Зимагурлар урамында яшәгән Рафаэльне соңгы айда, әйтерсең лә, шайтан алыштырды. Элек көн дә бауга таккан юаш бозау сыман карышусыз-нисез кыяфәттә колхоздагы культиватор, чәчкеч, сабаннарны ремонтларга чыгып йөри иде, хәзер машиналар паркына таба аяк та атлаганы юк. Аның каравы, хәзер аны көн дә йә Әгерҗе, йә Сарапул юлында күрәләр, һич югы, ул иртә-кичен авылдагы хуҗалык тауарлары кибетен урап кайта. Ихатага ташыган әйбере дә сәер. Йә кәйлә белән ниндидер шнур-шпагатлар, йә шахтерлар лампасы белән эреле-ваклы кесә фонарьлары. Берзаманны Рафаэль сораган «антиквариатлар»ны сатучы кызлар бөтенләй дә аңламый башладылар.

—Миңа төнлә күрә торган бинокль белән компас, лупа кирәк.

—Казан кибетләренә заказ биреп, узган гасыр карталарын кайтартып булмый микән?..

Көннәрдән-беркөнне ул авыл Советы бинасына кереп, анда хуҗа булып йөргән Робсонны шаккаттырды.

—Мин элеккеге Нәҗми бакчасы урынына йорт салмакчы булам. Аны оформить итәр өчен нинди кәгазь кирәк?

—Бәрәч, бәрәч! Ул урынны илле-алтмыш ел буена берәү дә өнәми иде бит әле. Заманында куян фирмесе оештырып карадык, нинди дер зәхмәт йогып, барча маллар кырылып-үлеп бетте. Ходай каргаган шул ташландык җиргә нәрсәсенә кызыгып күченмәкче булдың?—дип рәиснең төпчөнүенә каршы Рафаэль авыз эчендә ике-өч сүзле генә ботка пешерә алды.

—Тыныч урын. Чишмәгә дә якын. Аннары минем малай, Марат, шәһәргә сыймый башласа, рәттән генә нигез кора ала...

Сату-алу шома үтте бугай. Рафаэль атна-ун көн дигәндә ташландык иңкүлекне биек койма белән әйләндереп чыкты. Маратлары Ижау каласында олы кооператива хуҗа кеше иде, көн саен диярлек йөге-йөге белән такта, багана, җепсә кайтарттырып торды. Шул Марат акчасына күршедәге Аккүз авылыннан балта остасы Хәйрулланы да яллаганнар иде. Рафаэльләрдәге сәер ниятләрне, беренче булып, авылга шул чыгарып тиште.

—Боларның бабасы Өрәк Миннәхмәт Нәҗметдин бай утарында гомер буе ялчы булып йөргән. Нәҗми белән Таҗи байлар Себергә качкан чакта байтак акчаларын, алтыннарын күмеп киткәннәр, ди. Өрәк Миннәхмәт моны күреп торган, иллә мәгәр, төн караңгы булгач, кайсы алмагач төбенә күмгәннәрен генә шәйләмәгән икән. Хәзер Рафаэльләр шул хәзинәне эзләргә җыеналар...

Авыл акылдан ычкынды. Беренче төндә үк дүрт гаилә дүрт почмактан кереп, Нәҗметдин-Рафаэльләр утарын казый башлады. Әтисенә Марат кесә телефоны калдырып киткән иде, тегесе шуның аша хәбәр итте бугай. Көтү каршылауга, өч җиңел машинага үгез сытардай егетләрне төяп, Марат кайтып төште. «Кырхабурлар»ны бәрәңге бакчасы артына алып чыгып, иске идән чүпрәге урынына җилгәрделәр. Авыл койма ярыгыннан гына күзәтеп ятты, капка ачып чыгучы табылмады. Марат ул көнне яңа ихаталарына каравыл калдырып китеп барган иде, икенче атнада болай да сукыр тычкан кыяфәтле булуы өстенә борынына бармак калынлыгындагы күзлек элгән ират аламасын сөйрәп кайтты. Авыл иренне-иренгә терәп кенә чыш-пыш килде.

—Бу—иске Болгардагы Ага-Базарны аркылысыннан-буена казып чыккан галим, бик данлыклы археолог икән. Әҗеренә «Жигули» әзерләсәң, мин синә җиде бабаңның иске кәвешенә тикле табып бирәм, дигән.

Авыл надан, анда атаклы Ага-Базар урнашкан яланның инде моннан илле ел элек үк яңа сусаклагыч астында калуы хакында белүче юк иде. Барча урам халкы дошман тылына җибәрелгән разведчиклар сыман тын да алмый күзәтеп кенә ятты. «Данлыклы археолог» үзе белән металл эзләгечләр, әкәм-төкәм төсле локаторлар алып кайткан икән. Иртә таңнан кара төнгә чаклы бер атна казыдылар. Коймасы кирмән диварларына биргесез яңа ихата уртасында тәгәрмәч кыршауларыннан, сынган көрәк-сәнәк, балта аламасы, тишек ләгән, ярымчерек комган, тагын әллә нинди чүп-чарлардан хасил олы тау пәйда булды. «Данлыклы археолог»ның да түземлеге коргаксыган, ахры. Бер металл эзләгечен тез башына сугып сындырган да, ул бичара кычкырып елый-елый җәяү кайтып киткән. Марат аның артыннан үзләренең яңа «утары»ннан чыккан бердәнбер зиннәтне—борыны сынык көмеш чәйнекне ыргытып калган икән.

* * *

Рафил хәзер эшкә барырга чыккач көн дә милиция бүлеге аша урап китә. Документларын җыеп тапшырганга ике айдан артык вакыт узып бара, ә милициянең визалар бүлегендә аңа бернинди дә анык кына җавап бирүче юк. Килгән саен бер өстәлдән икенчесенә куып йөдәтәләр. Әле эш урыныннан бирелгән бәяләмәдәге кайсыдыр имзаның яшел кара белән куелуы ошамый тегеләргә, әле хезмәт кенәгәсендәге даталарның һәммәсе дә аермачык чекрәеп тормый икән. Чаллыдагы уналтынчы мәктәптә син егерме икенче өченче июльдән эшли башладың ни, егерме тугызында ни—чит илгә чыга торган паспорт битләренә синең исем-фамилияңне язып кую өчен моның кайсы шайтанга кирәге бар микән?

Ләкин боларның монастырена үз уставың белән керә алмыйсың шул. Болар синен ише авыл гыйбадларын «тимер пәрдә» артына чыгарып җибәрмәс өчен махсус

утыртылган. Ипиләре шуннан. Менә шуңа күрә болар син китергән һәр яңа кәгазьне рентген аша тикшергән шикелле кырык кат актаралар. Килгән саен «кыек» табылып тора.

—Сез үз биографиягездә әтиегез турында «беренче Украина һәм Икенче Белоруссия фронтларында сугышкан, өч кат яраланган», дип язгансыз, ә Татвоенкомат аның ике тапкыр яралануын гына раслап белешмә бирде.

Егыл да үл икән. Әткәйнең тәненә моннан кырык биш ел элек ике ядрә кыйпылчыгы кергәнме, әллә өчме—моның минем Японияга чыгарга җыенуымда яки миңа бирелергә тиеш чит ил паспортына нинди катнашы бар? Шушы Рәсәйне яклап сугышкан, чиләкләп кан койган бит инде минем әткәй, шул җитмимени соң сезгә, алла колкайлары?! Тагын әткәй канының группасын да ачыклап китереп бирмимме соң сезгә, кадалып киткерләре?!.

Рафил көн саен шул рәвешчә сүгенә, әмма эчтән генә. Ә тыштан ул нәзәкатьле итеп елмаерга һәм һәркөнне башын иеп кенә яңа кәгазьләр китерергә мәҗбүр. Болар печән чүмәләсе өстенә менгән эт кебек бит. Болар белән санлашмыйча булмый.

Беркөнне Рафилны күн белән тышланган ишек артындагы аерым бүлмәгә чакырып талкыдылар. Ишектә бер язу юк, аны кутеп алган ир уртасы хуҗа да гап-гади күлмәккостюмнан иде. Рафил үзен ничек тотарга белми тирләп бетте. Ә тегенең сорау бирми генә тезгән сүзләре тырнак астына кадаган энә шикелле кайнар, сәер.

—Син комсомолга кергән чакта Зоя Космодемьянская турында «аны немецлар басмый калмагандыр инде» кебегрәк сүз әйткәнсең.

—Син беренче «Жигули»еңны алгач та, биш ай үтүгә үк, аны күрше авылыгыздагы бригадир Зиннур Шәеховка яңа машина хакыннан аткаргансың икән.

—Авылга кайткач син хатыныңны чишмә буенда озак торган өчен тотып кыйнагансың...

Рафил баш түбәсенә чүкеч белән орган шикелле кисәк миңгерәде, беренче кар кебек җебеп төште. Ярый әле гражданский костюм кигән тикшерүче явыз түгел икән, папкасында тоткан кәгазьләрне өстәл түренә атты. Рафил аларга күз йөгертеп чыгуга шундук ачыклады. Боларның берсе үзе белән дүрт ел буе бер парта артында утырган авылдашы Рәсим, икенчесе үзләренә туган-тумача тиешле Зәйнәп куллары бит. Мине Японияга җибәрми калудан бу ахмаклар нәрсә ота инде?..

Ахырда тикшерүчегә бер мең тәңкә акча чыгарып бирергә туры килде. Бер сыер бәһасе чыгым китте дә бит, «майламаган кашык авыз ерта» диләр, нихәл итмәк кирәк?..

Инде, ниһаять, паспорт бланкларын тутыра гына башлаганнар иде, тагын яңа яктан көтелмәгән бәла. Мәскәүдә Брежнев атлы «даһи» китеп барган, аның атын «горур йөрткән» Чаллы хәзер иске исеменә кире кайта икән. Авыртмаган башка тимер тарак, янә түзәсе бар.

* * *

Биш-алты сәгатькә сузылган талку-җилгәрүләрдән соң, ниһаять, Японияга алар Ширәмәт һава аланы аша кузгалдылар. Делегация башлыгы булып барган Инна Абрамовна үтә җитди оешма вәкиледер инде, күрсәтмәләр тезде.

—Делегация башлыгы (ягъни аның) рөхсәтеннән башка беркая бару юк. Кибетләргә, ресторанга, хәтта туалетка кергәндә дә парлап (?) кына йөрисе. Японнардагы токкоконың этлек-мазар әзерләве мөмкин, ялгыз гына йөрүчеләр беренче самолетка утыртып кире очыртыла!

—Төнге бар, казино, секс-шоп ише черегән капитализм сазлыклары ягына әйләнеп карамаска! Совет гражданинына андый чирләр ят булырга тиеш!..

Инна Абрамовна тәкъдим иткән кешеләрне бәхәссез-нисез рәвештә делегациянең старостасы, комсоргы һәм звеньевойлары итеп сайладылар. Самурайларның кансызлыгы, сакэ-гейшаларның тыелган булуы хакында тагын бер кат соңгы «догалар» укылды.

Ханэда дигән һава аланына төшеп утырдылар. Таможнядагы тикшерү гамәлләре биш минутта бетте. Автобус белән алып китеп «Гранд-отель» атлы кунакханәгә илтеп урнаштырдылар да, юынырлык-кырынырлык ара үтүгә, ресторанга ашка чакырдылар (соңыннан ачыкланды, «Гранд-отель»ләре—ул узгынчы балыкчылар гына туктала торган, иң түбән класслы кунакханә икән).

Совет кунаклары утырган рәтләр арасыннан официант кызлар җилдәй шуып узды. Һәр кунак алдына буы чыгып торган тәлинкә тезделәр. Тәлинкәдә ап-ак төстәге, буйлы-буйлы «нигъмәт». Күпләрнең тәгам түземнәре корыган иде инде. Янда яткан

чәнечке-пычакларны тотып торырга керештеләр. Ни галәмәт, «нигъмәт» дигәннәре генә һаман бирешмәде. Чит өстәлләрдә утырган узгынчылар пырых-пырых килеп көлешә башладылар. Хикмәт ачыкланды: совет кунаклары «нигъмәт» дип торырга маташкан нәрсә кул сөртергә китерелгән юеш тастымал кисәге—осибори икән...

Рафил кич белән, «тимер башлык» Инна Абрамовнадан «мәрхәмәтле» рөхсәт алганнан соң гына, Касыйм хаҗи белән Салисә ханымнарның өенә шалтыратты. Алдан ятланган сәламләү сүзләрен ни төрекчә, ни инглизчә ерып чыга алмый азаплана иде, трубкада Казан радиосыннан да сафрак татар сөйләмен ишетеп, авып китә язды.

—Хуш киләсең, Рафил туганыбыз! Рәсәйдән дә гап-гади инсаннарны чит-ят илгә мосафирлар итеп чыгаралар икән!..

Икенче көнне Рафилне кунакханәдән Касыйм хаҗи үзе килеп алды. Хат буенча җитмешнең шактый гына аръягында дип белгәч, Рафил инде тешләре коелып беткән, бөкресе чыккан, ап-ак сакаллы картны көткән иде. Бактың исә, Касыйм хаҗи шәмдәй төз гәүдәле, яңаклары алсуланып торган «егет» булып чыкты. Чигәләрендә беркадәр чал чәчләре бар да, маңгаена, күз тирәләренә җыерчыклар яткан. Салавычтагы илле яшьләрдәге «ил агаларын» да сыңар кулы белән бау итеп ишәрдәй гаярь ир-ат бит бу...

Рафилгә «тимер башлык» рөхсәт иткән вакыт арасында Токиодагы Җәмигъ мәчетне дә, «Исламия» җәмгыяте офисын, ике катлы мәдрәсә бүлмәләрен, татар ширкәтенең милли-мәдәни үзәген дә күрсәтеп өлгерделәр. Рафил үз илендә соңгы ун елда бер мәртәбә күрергә насыйп булмаган ат казылыгыннан, кымыздан, эремчек кортыннан авыз итте. Иң соңыннан аны Токиодагы мөселман зиратына алып киттеләр. Рафил шунда үзенең туксан җиде яшьлек бер ватандашын очратты да авыз ачып калды.

Түтәл булып тезелгән каберләр арасыннан барганда кечкенә итеп ясалган Сөембикә манарасы каршына тезләнгән ап-ак сакаллы, ак күлмәкле ялгыз картны күргәч, Касыйм хаҗи Рафилнең җиң очыннан тартты.

—Менә шушы аксакалыбыз Япониядәге иң карт татар була, хәлен белү лазим.

Касыйм хаҗи инде кычкырып дәште.

—Исәнлек-саулыкмы, Гайнан хәзрәт? Сине сау-сәламәт көе күрүебезгә шатбыз.

Аксакал карт—байтак еллар буена Җәмигъ мәчеттә имам булып торган Гайнан Сафа хәзрәт, хәзер инде күзләре-колакларының сәламәтлеге дә әлле-мәлле икән. Шулай да, Касыйм хаҗиның тавышын ишетүгә, ул шактый җитез-каудар кузгалып тезләреннән купты. Йөзе-кыяфәте дә ут алган мич авызы сыман яктырып киткән иде.

—Татарстаннан кунак килде, хәзрәт, олы кунагым бар,—дип, аның колагына иелә төшеп дәште Касыйм хаҗи.

Хәзрәт сискәнеп китте, Рафилгә күз төбәде. Иреннәре арасыннан кысыр сыер сөте сыман сүзләр сытылып чыкты.

—Казан торамы соң әле, улыкаем?

—Тора, бабай, тора!—дип Рафил дәртләнеп кычкырган иде, аксакал карт янә җиргә бөгелеп төште. Туксан җиде яшьлек картның ярымсукыр күзләреннән яшь атылып чыккан, куллары-иңбашлары исә кыңгыраулы сәгать кебек дер-дер килә иде.

—Тора икән. Аллага мең шөкер, һаман тора икән. Яшибез болай булса. Рәхмәт, улым, рәхмәт...

* * *

Рафил авылга кабат әйләнеп кайткач, салавычлылар кыл урталайга бүленеп болайрак фикер йөртте.

—Япон миллионеры янына күрешү һәм буш кул селтәп кайту өчен баралармыни, сантый! Валлаһи да, укый-укый моның түбәсенә кирпеч төшкән икән!—дип бер өлеше мосафир ирне тилемсәгә чыгарып аткан иде, ушлырак булып саналган бригадир, хисапчы, укытучы халкы икенче мөһер тапты.

—Миллионер кешене бер баруда гына савып кайттың ди, тот! Бай кешедән кыш көне бер көрәк карны да бушка гына урлый алмыйсың бит.

Авыл озак бәхәсләште, әмма бәя-хөкемнәре уртак булып чыкты. Мосафир ир моннан ары һәммә салавычлы өчен Сантый Рафил иде.

* * *

Салавычны өр-яңадан туксан беренче елда гына, әйтерсең лә, чеметеп уяттылар. Янә Рафил инде. Мөгез чыгармый гына тора беләме соң?

—Сәгать биштә Касыйм хаҗи белән телефон аша туры элемтә була. Моннан җитмеш

ел элек чыгып качкан авылдашына сорау бирердәй кешеләрнең һәммәсе дә клуб залына килсен.

—Япония хәтле Япония белән ничек итеп авыл телефоны аша сөйләшеп булсын ди ул? Аннары, япун миллионеры сыңар трубкага әйткән сүзне бөтен авылың белән ничек ишетәсең?—дип шиккә алсалар да, кечке бишкә авыл клубына кереп тыгылдылар.

Сәхнә уртасына гап-гади телефон аппараты китереп куйганнар, ике янда ике кара тартма, һәркайсыннан зал түренә икешәр-өчәр чыбык сузылып киткән. Рафил үзе читтә утыра, зал ягына күз дә атмый. Шушында ук авыл Советы башлыгы Робсон, колхоз рәисе Ислам йөзләренә кәттә кыяфәт чыгарып утыралар. Болар да килгән булгач, туры элемтә диганнәре ялганга чыкмый, димәк.

Аппаратка тәп-төгәл сәгать биштә җан кергәндәй итте. Япония артык еракта шул, Салавыч телефонын җир йөзеннән минуты-секунды белән эзләп таба алмады, күрәсең. Рафил ашыгып трубканы күтәрде, ике кара тартма шундук телгә килде.

—Әссәламе галәйкем вә рәхмәтулла вә бәрәкәтүһ!

—Чукынды!—дип кычкырды бугаз ярып һаман шул ук айну белмәс Руслан.—Безне алдап намаз тыңлатырга җыйган бит бу сантый.

Тагын тирә-юньдәгеләр ояда утырган ана казлар булып ысылдады.

—Тс-с, алланы-муллаңны! Тс-с, диләр бит сиңа!

—Мөхтәрәм авылдашлар вә кадерле туганнарыбыз!..

Салавычлыларның һәммәсе дә телевидение камерасына төшәргә әзерләнгән кебек итәк-чабуларын җыештырды, кыяфәт-карашлары бердәм җитдиләнде. Залда утырганнарның күбесе: Касыйм хаҗи аларның һәркайсын берәм-берәм санап чыгар, дип өметләнде бугай. Ә ул мондый өметне күз чалымына да китермәде, ахры, үзенекен тезде.

—Соңгы көннәрдә әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык шатлык, томан эчендәге гүзәл бер манзара эчендә яшибез. Татарстан җөмһүриятенең үзен мөстәкыйль вә азат дәүләт дип игълан итүе хакындагы хәбәр килеп иреште. Татар халкының дүрт йөз кырык елдан соң кабат бәйсезлек яулавына ышанып бетә алганыбыз юк. Үз гомеремдә беренче мәртәбә чын күңелдән мин татар булуым белән чиксез горурланам. Дәүләтчелегебезне кабат тергезгән өчен рәхмәт сезгә, авылдашларым, рәхмәт сезгә. Янгызда булсам, мин һәммәгезнең кул очларын үбеп чыгар идем...

Дуңгыз тыкырыгына терәлеп утырган Әхкыямның Ревосы белән Самсоны Чаллыдан үзләренең марҗа хатыннарын ияртеп кайткан икән. Касыйм хаҗи телефон аша коры сәлам түгел, ә бер миллион акча тапшыра диярсең, теге ике сантый шул марҗаларын клубка да ияртеп килгәннәр бит. Хәзер менә шулар кигәвен талаган кысыр сыер сыман пыран-заран килде.

—А чо вы нас сюда притащили, два дятла? Наххер нам нужны эти стариковские каля-маля? Лучше бы мы на вашей крыше жопы грели.

—Ылатны инде, Наташ, ылатны инде. Зинаһар, не шуми, стыдны бит,—дип чышанлый-пышанлый әүвәл Ревосы үзенең марҗасын сөйрәп чыгып китте. Самсоның хатыны алай иелә-бөгелә качуларга риза түгел икән, җиз самавыр хәтле күкрәкләрен сыер җилемедәй уйнаклатып, төкереген чәчте.

—И нахрен вам сдался какой-то беглый старикашка? То же мне, «родственничек нашелся». Тьфу, пошлость!..

Касыйм хаҗи телефон аша һәммәсен дә ишетеп торган сыман җавап сүзен китереп ирештерде.

—Без Рәсәй идарәсе астында озак газап чиктек. Алар безнең мәдәниятебезне, йортҗиребезне, телебезне, җаныбызны да талап бетерделәр. Шуңа күрә чит-ят җиргә куылган, нахакка рәнҗетелгән һәрбер татар кебек, мин дә авыз тутырып «азатлык вә тулы азатлык», димен.

—Минем карашымча, күрше олысларда гомер сөрүче башкортлардан алып Себердәге якутларга кадәр бәйсезлеккә ирешүдә иң туры юл—ул өр-яңа татар дәүләте булып берләшү. Якут, чуаш, чирмеш, мукшы, башкорт вә нугайлар—һәммәсе берьюлы татар байрагы астына килеп берләшмәсә, тулы азатлыкка ирешүдә башка юл юк. Берләшкән милләтләр оешмасы шул очракта гына безне тулы хокуклы вәкил ясап үзенә кабул итәр. Шул вакытта бүген чит җирләрдә интеккән бәгъзе татарлар да үзләренең туган илләренә очып кайтып җитәр...

Мәңге айну белмәс әлкәш Русланның гына түгел, аның күршесенә чүгәләгән Кеткет Шәмсиянең дә түзем самавыры кайнап чыкты. Парлап кычкырдылар:

—Әрәмтамаклар җитмәгән, син генә кирәк иде ди монда. Потың бер тиен!

—Ул японнарда интегеп яткан миллиюннарыңны безнең илгә җибәр!

Ходай Тәгаләнең «амин» дигән чагына туры килгән диярсең, кара тартмаларда Касыйм хаҗиның төн йокысын качырачак яңалык сүзләре яңгырап ишетелде:

—Бәйсезлек игълан иткәч, Татарстанда да яңа мәчетләр торгызырга ирек ачылган икән. Ислам дине кабул ителүнең мең дә бер йөз еллыгы уңаеннан Чаллы илә Түбән Кама калаларында Аллаһ йортлары калкып чыгуын ишетеп нык сөендек. Инде үзебезнең туган авылыбыз йөзенә дә зур яңарыш кертәсебез килә. Әгәр Салавыч үзегендә, иске ихатабыз урынында яңа мәчет күтәрелеп чыкса, туган туфракка үз бурычыбызны аз булса да кайтарган булыр идек. Шул максаттан без авыл Советындагы хисап кассасына йөз мең доллар күчерергә булдык. Киләсе атнада, шуны алганны раслап, без фәкыйрьләрегез тарафына да хәбәр-хәтер җибәрсәгез иде...

* * *

Салавычны танымалы түгел. Элек колхоз рәисе Исламнан кала һичбер кеше каршында да бил бөгүче юк иде, хәзер Робсон—король! Ул урамнан үткәндә җәяүлеләр генә түгел, атта, трактор-машинада баручылар да, урәчәләреннән сикереп төшеп, авыл башлыгы каршына йөгереп чыга. Бөтен авыл битлек киеп алды диярсең, Робсонга каршы кайтарып сыңар сүз әйтүче юк, артыннан сүгенеп калучы юк. Робсон нинди генә йомыш кушмасын, җавап игезәктәй бер үк:

—Ярар, Робсон әфәнде. Рәхмәт, рәхмәт.

Авылда булган чираттагы җеназаны озатканда кабер казырга чакырамы ул сине, урамга юынтык су яисә иске кәвеш чыгарып аткан өчен силсәвиттәге келәмгә чакырамы—якты чырай күрсәтеп, кулны күкрәк турына кушырып, һаман шул сүз:

—Рәхмәт, рәхмәт.

Ижаудагы Марат Салавычка яңа кушамат та тагып өлгергән икән инде:

—Даблью, даблью, даблью. Рәхмәт, рәхмәт, точка, ру.

Ә үзе, каһәр, атнасына ике-өч мәртәбә укалы тартмалар, затлы шешәләр төяп Салавычка кайта да төшә, кайта да төшә. Кайткан саен Рафаэльләр өенә, әйтерсең лә, йә шәхси заводларын бүлешергә әзер торган кәттә кодаларны, йә вагон-вагон бирнә төяп килгән яшь киленнең үзен төшерәләр. Иләннәрне балавыз яккандай сап-сары итеп юып чыгаралар. Шәп итеп мунча ягыла, Ристан урманыннан өр-яңа миллекләр җыеп кайтарыла. Мунча тирәсендә—Ижаудан ияреп кайткан яп-яшь кызлар, капка төбендә, казан эргәсендә «яңа ялчылар» төркеме биеп кенә йөри.

Кунак һаман да бер—Робсон, Робсон. Авыл Советы белән Рафаэльләр, Рафаэльләр белән үз йорты арасында Робсонның аяклары җир йөзенә дә тими, чак күтәреп кенә йөртмиләр.

Җилбәзәк хатын итәге сыман уйнаклап, авыл эчендә төрле сүзләр купты:

—Робсон мәчет төзетергә подрядчиклар эзли, Марат майлы калҗа эләктереп калмакчы, ди.

—Марат Ижаудагы бар банкны үз кулында тота, долларны «агач тәңкә»ләргә бик тә ансат әйләндерә икән...

Утсыз төтен булмаган шикелле, соңгы гоманлаулар чынга ашты, ахры. Авылга терәлеп торган Убыр тавы итәгендә болын чаклы җирне бүлеп алдылар да, әүвәл губернатор диварлары сыман койма тотып, шуның эчендә кырмыска оясыдай кайный башладылар. Хәзер колхозның бөтен техникасы шунда, төзелеш идарәләреннән яллаган краннар, экскаваторлар, бульдозерлар шунда. Робсонның—авыл Советына, Исламның—ындыр табагына, йә булмаса фермаларга кереп караганы юк. Тирес өемендәге кортлы тавык шикелле, көн-таң атса шунда казыналар.

Авыл әүвәл түшәктәге хаста сыман хәрәкәтсез генә күзәтеп яткан иде.

—Касыйм хаҗиның бездәге миллион «агач тәңкәләр»гә биргесез байлыгын җилгә җилгәреп бетерә бит болар. Ул нәзер иткән мәчетнең нигезен булса да салмыйлар микәнни соң?

—Туймас тамак Робсон «әй, качак Касыймның гүргә карап утыра торган чагы җиткән ләса, Япониядән кубып, ул безнең илгә килеп йөри аламыни», дип кенә җибәрә, ди. Болай булса, бу ике убыр мәчеткә тиеш бөтен малны йотып бетерә бит.

Берзаманны авыл аякларын әлле-мәлле бәйләп сугымга салган мал шикелле дәррәү сикереп купты.

—Касыйм хаҗи мәчетне бар авылга нәзер иткән иде. Димәк, уртак. Безгә өлеш кайда?

«Губернатор диварлары» эченнән беренче төндә үк ике меңгә якын кирпеч урладылар. Кем алты-җидене, кем иллене. Өйләрнең кыекларына дип кайтартылган җиз калайлар өелеп тора иде, аннан җилләр исте. Капчык-капчык цемент аякланды. Бәбкәлеккә әзерләнгән иллегә якын борыс юкка чыкты. «Яңа хуҗалар» иртә белән сүс төргәкләрен, толь өемен, «вагонка» дип йөртелгән агач рейкаларны эзләп таба алмады.

Икенче төнгә, күрше авылдан яллап, һәр койма буена өчәр-дүртәр ирне бастырдылар. Бу адымнары учакка дары сипкән шикеллерәк булды.

—Аһ, шулаймы?—дип кычкырды, иң беренче булып, Комгансызлар урамындагы Япон Артур.—Миңа тиеш малны йоткан өчен дуәрисегезгә ясин чыкмасаммы?!.

«Халык зур ул, көчле ул...», дип олуг шагыйрь белми әйткәнмени? Шушы төн уртасы үтеп киткәнче үк Убыр тавы түбәсенә олы катапульта төзеп бетерделәр. Кое сиртмәседәй озын бастырыкның бер башына бензин-керасин тулы чүлмәкләрне Япон Артур көйләпчөйләп тезде. Брезент бияләйгә төргән утлы күмерләрне дә чүлмәкләр авызына ул бәйләде. Ә аннан соң суйган урысны да сикереп торгызырдай, иләмсез бер әмер:

—Пл-ли, алланның-мулланның кабер такталарын!

«Губернатор диварлары» эченә бармагы ярыкка кысылган Шүрәле сыман үкереп биш-алты чүлмәк очты. Алар такта өемнәре, кирпеч катламнары өстенә бәрелеп, берәмберәм шартлый башладылар. Бөтен ихатаны тутырып чүлмәк ватыклары очты, янгын купты.

—Каравыл! Ахырзаман килде, ахырзаман!—дип кычкырып, яллы сакчылар берсенберсе изә-сыта тимер капка бигенә ябырылды...

Таң атканда ихата эчендәге янгын сүнеп беткән, такта өемнәре юк, әмма кирпечбетон катламнары элеккечә чекрәеп тора иде.

* * *

Ике ел чамасы вакыттан соң әйләнеп кайтты да, Сантый Рафил бөтен Салавычның йокысын-өнен алды.

—Касыйм хаҗи килә. Мөфти хәзрәтләре чакырган. Безнең авыл мәчетенә Касыйм хаҗиның әтисе Нәҗметдиннең исемен бирмәкчеләр.

—Нинди мәчеткә? Каян килгән? Кайда андый мәчет?

—Ну, анысын инде, туганнарым, үзегез беләсездер...

Утка элгән казан кайнап чыгарлык та ара үтмәгәндер, Галимҗаннар өенә Робсон белән Ислам килеп җитте. Икесе тиң тоташ тиргә баткан, эт өстерә-өстерә чаптырганнармыни!

—Каян гына уйлап таптың инде? Нигә килә хаҗи, кайчан килә?

Рафил өшкереп тә бирмичә, иңбашында булмаган мамыкларны-тузаннарны чиертәчиертә сузды.

—Мужыт... Мәүлид кичәсенә килеп җитәр, мужыт... Корбан гаетенә тикле... түзеп торыр әле.

—Мәүләтенең гаете кайчан була да, Корбанының туган көне кайчан?

—И-и, абзыйлар!—диде Рафил, чигәләрен тотып.—Хәрәм малны таларга ябышканчы, кыямәт көне турында уйларга өйрәнсәгез иде сез. Хәер, бөкрене кабер генә төзәтә, телне әрәм итмик.

Робсон белән Ислам һаман, шөпшә сыман, очып-очып кунды:

—Шулай да, шулай да, кайчан килә соң инде ул хаҗи, ничә айдан килә?

—Корбан гаетенә чаклы түздерә алсам, дүрт ай чамасы вакытыгыз бар икән шул әле. Кыймылдагыз, әйдә.

* * *

Касыйм хаҗи белән Салисә абыстай җылы, мул августның унысында килеп төшәчәк икән. Япа-ялгыз түгел. Олы кунаклар арасында Казандагы мөфти Ислах хәзрәт бар, шулай булгач, ияреп-саклап йөрүчеләр генә дә ике-өч машина чамасы булачак, ди.

Салавычка бер атна алдан ук шул рәвешчә хәбәр җибәргәннәр иде, халык күп җыелды. Авылдан чыгып киткәннәргә үзләре кайту гына җитмәгән, койрык итеп, хатыннары-балаларына тикле ияртеннәр. Һәммәсе дә клуб белән мәчет арасында кайнаша, сөйләмнәрен-телләрен юньле-башлы аермалы түгел.

—Пап, пап, а чо это столько народу собралось? Чо раздавать будут?

—Кич белән Иж аръягындагы мукшыларда Каргатуй буласы икән, бушка лыкынганчы эчеп калыр өчен шулар янына сыптырасы булыр.

—Хоть бы какой-нибудь захудалый магазинчик пригнали, а то и водки нет...

Ай-һай, туган, ашыкмый тор әле. Әнә, Әлкәш Руслан ду китереп дуңгыз куып йөри. Теге дүрт аяклы явызы бригадир Фәррахлар ихатасыннан ничек итеп чыгып ычкынгандыр? Дуңгыз үз ишен тапмый каламы соң? Руслан белән әрле-бирле килеп куышалар, әнә. Хәер, болар ялгыз түгел. Русланга Комгансызлар урамындагы Кап-йот Шәкүр ияргән, исерекләр байтак икән, димәк.

Робсон белән Ислам утлы табага баскан шикелле тыз-быз йөренәләр. Бер күзләре Әгерҗе юлында, икенчесе Убыр тау ягында. «Губернатор диварлары» каршына эскерт хәтле итеп утын кайтарып өйгән булдылар, ике «дуәрис»не алар да каплап бетерә алмый. Әнә, икешәр катлы йортлар бөтен Салавыч өстендә шәрә ботактагы ябалаклар төсле чекрәеп утыралар. Хәзер Робсон белән Исламның икесен дә бер генә уй бораулый:

—«Ни кишеремә кайтасы итте соң бу хәерсез картлач? Японияләрендә көн-таң атса вулкан атып, җир селкенеп тора. Сиксән яшен сикереп узган картны нигә җир йотмады?..»

Аның каравы, Япон Артур белән Рәйсәләргә бәйрәм. Ире Салавычта гомер күрелмәгән фрак-костюм кигән, муенында затлы күбәләк. Соңгы ике көндә эшенә дә барып күренмәгән, дип сөйлиләр иде. Мунчадан чыкмыйча да утыргандыр инде, элек сабын йөзен күрмәгән куллары хәзер аккош канатыдай ап-ак. Рәйсәсе Артурны култыгыннан бер дә ычкындырмый, авызлары суга җебетергә салган күн кәвештәй ерык. Телләрендә ризык-ниґъмәт кенә.

—Ике мәртәбә Уфага машина яллап барып, беконнар, шпротлар, сыер теле, паштет, кысла төяп кайттык. Нәкъ авылдагыча булсын дип, каклаган казына чаклы әзерләп куйдык, менә. Әти-әнидән дә газиз туганнарыбызга «агач тәңкәләр»не җәлләп булмас инде. Галимҗаннарның Рафиле, валлаһи, сантый бит ул. Шулай булмаса, Япония тикле Япониядән ике кулын селтәп кайтыр идемени? Коры кашык авыз ерта, диләр. Майлый белү кирәк. Кайтсын гына, кайтсын зур кунаклар...

Ходай боларның сүзен илтеп ирештерде, ахры. Авыл очында җиңелчә тузан куптарып килгән зур кортеж күренде. Алда—буяулары, көзгеләре белән ялт та йолт килеп уйнаклаган «Джип».

—Мөфти машинасы. Йә кайсыдыр авыл мәчете, йә каладагы берәр мәчетнең юкка чыккан манарасы инде бу,—диде Әгерҗедәге банк тирәсендә буталып йөргән Рәшит.

Бәхәскә кермәделәр. Чөнки «Джип», чынлап торып, мөфтинеке иде. Халыкта башка хәсрәт. Кортеж мәйдан уртасына килеп туктауга ук, һәммә машинаның ишек-тәрәзенә барып ябырылды.

—Касыйм хаҗи кайда? Япун картлачы кайда?

Япония кунаклары икенче, Галимҗаннарның Рафиле иярләгән машинадан чыкты. Касыйм хаҗи җиргә аяк басуга ук туфрак үбәргә дип тезләнмәкче иде, ирек бирмәделәр. Ике-өч тәүлек буе ачка кыргылганнан соң башак тулы тагаракка ташланган мал көтүе диярсең, берсен-берсе этә-төртә, изә-сыта, хаҗины төрле яклап ирләр белән хатыннар сырып алды. Әле итәк чабуыннан, әле кулыннан каптырып, һәрбересе үз ихаталары ягына каералар.

—Элек Гыймади тегермәне торган урамдагы Хәлим Солдатны хәтерлисеңме, хәзрәт? Мин шул Хәлимнең оныгы Рабиндранат булам. Без синең әбиең ягыннан туган тиешләр бит.

—Әй, чукынып кына йөрмә монда, сасы көзән! Ихатагызның тутыкмаган кадак күргәне юк. Морза Мөхетдин бай нәселенә сез галахлар каян килеп туган? Син, ичмаса, хәзрәт, Түбән урамдагы Хәерниса түтәйне исеңә ал. Атаң Нәҗметдинне аның янына атна саен килеп йөргән, диләр. Мин шул Хәернисаның оныгы булам инде...

Болар Касыйм хаҗины әле тагын күпме вакыт талар иде микән—мөфти Ислах хәзрәтнең тавышы шып туктатты:

—Сез бөтенләй әрсез алабайлар төсле кыйланмагыз инде. Касыйм хаҗиның әле Салавыч өстенә керфек атканы юк, ә сез каз йолыккан сыман ябыштыгыз.

Кунак хәзрәт авыл өстенә күз йөгертеп чыкты. Әлбәттә, танымады. Каралты-куралар бары да әйбәтләнгән, кабарган күркә шикелле кукраеп утыралар. Кайсы якка карасаң да—шифер түбә дә, калай түбә. Элек берьюлы ике тегермән тотучы Гыймади бай гына шулай кыйлана иде, хәзер исә, әнә, биш-алты йорт өстенә мансардалар корып җибәргәннәр. Ихата алды саен йә ике-өч йөклек такта, йә кызыл вә ап-ак кирпеч өемнәре. Утынга кытлык беткән, мичләрнең һәркайсын газга ялгаганнар. Күз тимәсен, күрәйгән бит, ныгыган бит авыл. Әйе, мондый авылга кайтып җирләнсәң дә була.

Әле Кытайда чагында ук ишеткән иде ул. Саргосс дигән диңгездә ниндидер бик үзенчәлекле балыклар бар икән. Тын океан буйлап кайсы якка гына йөзеп китмәсеннәр, әмма соңгы сәгатьләре якынлашуны сизенүгә, шул балыклар үзләренең газиз Саргоссларына кайтып үлә икән. Шушы яңалыкны Япониядә, Төркиядә, Австралиядә, Сингапурда күпме ватандашы белән уртаклашты ул! Һәркайсында тик бер теләк, тик бер хыял иде—туган якка, газиз туфрагыңа кайтып яту! Һәм менә бит, андый бәхет бик ерак та түгел. Газиз зират янәшәдә генә, кул сузымында гына!..

Ислах хәзрәт төрткәләде, ахры, капчыктай зур бүксәсенә икмәк тәрәп баскан ир-ат телгә килде:

—Тәкле аягыгыз белән, газиз туганнарыбыз Касыйм әфәнде һәм Салисә ханым! Сезне янә туган авылыгыз туфрагында сәламли алуыбызга чиксез шатбыз. Авылыбыз даны өчен кылган гамәлләрегез алдында баш иябез.

—Ну, фиптерә Робфон!—дип фифылдады якындагы төркем эченнән бер сакау ир.—Кафыйм хаҗи атчут форамафын өчен хәдер факалы белән җирне дә феберә бу.

Икмәк тоткан ир-ат нотыгын дәвам итте.

—Сезнең авылыбызны яңарту өчен кылган тәкъдимегезне яше-карты хуплап каршы алды. Сез җибәргән байлык-зиннәтләрнең бер тиенен дә җилгә очырмадык. Менә шушы күркәм, гүзәл мәчет сез юллаган акча бәрабәренә калкып чыкты. Аңа хөрмәтле мөфтиебез Ислах хәзрәтләренең ризалыгы белән данлы әтиегезнең аты—Нәҗметдин исемен куштык. Аның ишекләрен ачып керү йоласын да тәүге булып сезгә тапшырабыз.

Ап-ак күлмәк кигән яшь кызларның берсе Касыйм хаҗи кулына кайчы китереп бирде. Хаҗи йөзенә көләч җил кагылды, иреннәре елмайгандай итте. Ул авыл клубы каршында торган мәчет тарафына борылды, үзен-үзе белештермичә ике-өч адым атлады. Карашы белән йотардай, колачлардай булып хаҗи мәчеткә текәлде, утлы күмер йоткан яки үткен кылыч очына килеп төртелгән шикелле шып туктады, йөзе, елмаерга җәелгән иреннәрен дә кире җыя алмыйча, агач битлек кигән кешегә охшап калды.

Алда чеп-чи наратлардан, аннан-моннан сипләп күтәрелгән бер йорт тора иде. Бүрәнәләр—төнлә белән, урлап кына агартылган шикелле ала-кола. Урыны-урыны белән кабыкларын да юнып бетермәгәннәр, шаян бала-чага кызыл ләпек чәпәп чыккан шикелле буйдан-буйга шадраланып тора. Йортның озынлыгы, күп булса, тугыз-ун адым бардыр. Өйалдысы—юньләп ышкы йөзе күрмәгән чи тактадан, кояш төшкән ягы, язгы чабата сыман, авызын ачкан инде. Түбәгә тутыкмый торган калай япкан булганнар да, ул бүре тешенә эләккән сарык тиресе шикелле теткәләнеп беткән. Манарасы кыек, бакыр ае сазлык эченнән сөйрәп алган сыман яшькелт-кызыл.

«Бу ни бу, туганнар?»—дигән караш белән Касыйм хаҗи салавычлылар йөзенә текәлде. Күз алдыннан дистәләгән бәндә йөгереп узды. Мөселман сакалының ни икәнен дә белмәүче тешсез картлар: Шикәрдәй ак чәчләрен җилгә туздырып баскан җиңги вә апалар… Ирен читләренә капкан тәмәкеләрен сагыз урынына чәйнәүче егет-җилән... Базарга сату өчен чыгарылган мал шикелле тыгыз ботларын, мул күкрәкләрен ярым-ачкан маржа киленнәре… Баштанаяк ләпеккә коенган дуңгызны тезләре арасына кыскан исерек ир...

—Йә, Ходаем, коткар?—дип пышылдады да Касыйм хаҗи, күкрәгенә тотынып артка авып төште.

—Аның йөрәге начар, йөрәге!—дип кычкырып, хаҗи каршына Салисә ханым килеп тезләнде.

Мәйданга кәмит карарга җыелган кешеләрнең һәммәсе дә аһ-ваһ килеп йөгерә башладылар. Япон Артурның хатыны Рәйсә чәрелдәгән сүзләр һаваны ярып узды:

—Күпме акча җилгә чыгып очты, авызына керим!..

Касыйм хаҗи, хатынының кулын кайнар кысып, соңгы гозерен әйтте:

—Берүк, илгә апкайтып җирлә, Салисә бәгырькәем? Ялгыш, мине монда калдырып китә күрмә?!.

Октябрь-ноябрь, 2003.
Чаллы.

Әсәрне язганда Рафаил Адутовның «Япониядәге кардәшләребез», Әмрулла Агиның «Бер кеше язмышы», шулай ук «Әхмәтвәли Мәңгәр турында истәлекләр» китабында сурәтләнгән качак татарлар тормышы да өлешчә нигез итеп алынды (Автор).

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ГАДИ, МИЛЛИ "НИСА"

Укучыларыбызга яхшы таныш дип беләм мин Розалина Шаһиева исемен. Җитмешенче еллардан—үзе язганча, "иң шигъри чор"дан ук ул—шигырьләре, татарчадан һәм татарчага тәрҗемәләре, шигърият, сынлы сәнгать турында мәкаләләре белән күпләрнең хәтерендә калгандыр. Үзе дә нәкъ шул еллардан бирле белемле, эрудицияле, күп нәрсә белән кызыксынган, эзләнүчән, зыялы шәхес буларак, күңелдә яши. Милләтебезнең үз кызы, халкыбызның рухи байлыкларын тирән аңлап, аның әрнүләрен дә үзенә алган, әмма чын татарча горур, серле, нәфис зат булып та гәүдәләнәдер ул чордашлары күңелендә. Ул чакта ук җаны белән бөтен дөньяны, шул исәптән төрки халыкларның бердәнбер мөстәкыйль дәүләте Төркияне яратуын яшермәгән өчен, Розалинаның әдәбиятка юлы да бераз урау булды... Иҗат биографиясендәге бу чорны ул соңрак болай дип бәяләячәк:

Ирек, дисә, шагыйрь зынҗыр кия,
Илем, дисә—мәңге мөһаҗир...

Юк, тоткын булмады, йәки Бродскийлар кебек чит илгә дә чыгып китмәде ул—аның моңны, азат сүзне эчкә яшереп, күңеленә бикләнеп, "эчке эмиграция"се еллары булгандыр бу, бәлки. Розалинабыз уку-укытуга йотылды, телләр, сәнгать дөньясына чумды—нәтиҗәдә, рухи баеп, үсеп, яңарып шигырьгә кайтты. Миллилеге дә үсә генә барды аның.

Шагыйрә турында инде моңа кадәр дә матур-матур, үзләре дә шигъри эссе саналырлык мәкаләләр басылып чыкты. Әйтик, "Кара мәрҗән" китабына шундый эссены, кереш сүз итеп, Равил Фәйзуллин язса, "Казан утлары"нда дөнья күргән шигырьләр шәлкеменә матур юлламабәяне Наис Гамбәр бирде. Ә инде күптән түгел дөнья күргән яңа китабы "Ниса"га берьюлы ике күренекле каләм иясе—шагыйрь Зөлфәт һәм өлкән әдип Миргазиян Юныс мәкаләләре урнаштырылган... Шагыйрә турында язучылар барсы да аны киң карашлы, дөнья шигърияте традицияләрен үзләштереп, күп мәдәни учаклардан ут алган, әмма милли, үзебезнең шагыйрә итеп таныйлар. Яңа сүз остасы итеп!

Розалинаның "Бөек Ефәк юлын"н, аннан узган төрле ил кәрваннарын күзаллап, рухта бер сәяхәт ясап, төрле мәдәниятләрне сагынып, барлап язган шигырьләре бар. Әмма тарихи ядкярлар белән очрашу—аның милли горурлыгын гына арттыра дигән тәэсир кала: ул бөтен шигъри дөньясы белән чын татарча аң, фикер һәм сурәтләр шагыйрәсе булып кала. Ә бит үзе—шәһәр, Казан кызы; ул урысча да яза алыр иде. Әйе, үз милләтеннән, туган телдән ваз кичү хакына ул төрле бүләкләргә—"триумф"ларга да ирешер—Мәскәүләргә йөз тотканнар юлыннан да китәргә мөмкин иде. Андыйларга нәфрәтен дә яшерми яза ул, чын милли шагыйрәбез, аның кредосы да борынгы төрки бабайлардан килә, катгый яңгырый: "Шаһиева—сүзем!" дигәнен бик яратып, рәхәтләнеп кабул итәм мин. Форма җәһәтеннән ул—ирекләрәк ритмны ярата, кысаларга сыймыйча, иркенлеккә омтыла. Әмма "чын безнеңчә" уйлый, сүзләре дә—әдәби телебезнең Тукайлар, Дәрдемәндләр кулланганы. "Җанеки!" дигәндәй, матур гыйбарә-эндәшләр... Әнә шуңа да әлеге "Ефәк юлында" да, хәтта Сфинкслар илендә дә милли рух сакчысы итеп тоя ул үзен; әйе, Мисыр, Иордания, Багдад, Төркияләрдә дә татар рухына тугры кала. "Кеше йөзле арыслан"—сфинкс кебек, ул да "тешләп саклый милләт мирасын"... Халкыбызның газиз шәҗәрәсен дә барлый ул, аның тамырларын, яшерен, шигъри код-геннарын

эзли, таба белә. "Шәҗәрәмнең һәр ботагы Былбыл кунганга авыр" дигәне шул юлдагы матур табыш бит! Мондый юллар бүгенге татар шигърияте антологиясен дә бизи ала, безнеңчә. Сүз җаеннан: яңа гына мин аның әлегәчә Язучылар берлегендә тормавын белеп тә гаҗәпләндем...

"Кара мәрҗән"нәр коючы "Карауҗадан пир Шәйхетдин" кебек, Розалинаның остазы— халык, аның тарихы, бүгенгесе... Шуңа да ул бүген яңа тәхәллүс—"Ниса" исемен алган: үзе аңлатканча, Юнандагы җиңү алиһәсе Никага охшатып, гади татар кызы исемнәре Гыйльмениса, Хөббенисалардан кыскартылган ул. Ә Миргазиян ага Юныс аны Кәрьяндәге мәгълүм "Ниса" сурәсенә бәйләп аңлата.

Ә шагыйрәбезнең—Нисаның җаны татар тарихына, иске агач Казанга, Сөембикәләр мирасына, авылларыбызга, моңлы табигатькә, тау, елга, талларга топташкан. Әнә ни дип яза ул:

Әллә элмәк,
әллә мәрҗән
татар дигән бу муенса?
Баба күзе. Ана сүзе. Киләчәгем.
Насыйп булса...

Мондый юлларны укыгач, афәрин!—диясе килә сиңа, Ниса!

Рәдиф ГАТАШ

Розалина Шаһиева

ЕФӘКЧЕЛӘР ЮЛЫ, КӘРВАН ЧАҢЫ...

Татар җаным

Егермене сугып, канат кагып,
казна корып, туктаганда
заман шавы,
тимер шәһәр зинданыннан,
исән калып,
карап тора бу дөньяга—бер могҗиза—
"гаҗәп маймыл",
чишелмәс сер—илаһи бер татар рухым,
татар җаным!

Күзәнәктән үсеп чыккан якутлардан,
төпсезлеккә очкан камил очкычлардан,
заман күрке-машинадан хикмәтлерәк

фән-уй тулы бу заманда—
кaһәр сөю,
чиксез гайрәт, акыл тулы—
үлемсез бу моң чишмәсе,—
минем газиз татар рухым,
татар җаным!

Акылларда уйный хисап, санау арта...
Банк-Кәгъбә—"мамыклының"
морҗалары...
Моны, көлеп, мәҗүси, дип инкарь итә
нечкә җисем, гүзәл фетнә—
шигырь колы—татар рухым,
татар җаным!

Туган җирем! Сиңа шуңа күңел пәрвәр:
рәхмәт
газап—баскан кайнар күмер өчен!
Үсәр уллар, тугаеңда туйлар гөрләр,
күбәләкләр, атлар уйнар,
үлеп терел, үлеп терел—безнең өчен!

Күрде күңел—кире аккан елгаларны,
үлем белән золым тулы
ямьсез хата, йолаларны;
ләкин сизә ил-баланың
бакча кебек үсәчәген—
аллы-гөлле чәчәкләргә батып атачагын,
тик яшәсен, сырышкандай җил агачка,
мәңге барсын киләчәккә
минем моңлы татар рухым,
татар җаным!

Әбелһәүл

Ничә мең йолдызлар, изге Кояш,
сиксән болыт, бер ай, мең дәвер—
әйләнәбез: патша, шагыйрь, дәрвиш...
Купмый сакта тора
Әбелһәүл...[1]

Тырнак асларында—түгәрәк Җир...
Мыгырдана шәһәр, дәүләтләр,
Комлыкларда кайный күбәләкләр,
Кых! Кых! Көлә аста мәләкләр!

Меңъеллыклар, сары кәгазь булып,
алдан-арттан уза куышып...
Орынып китә—яугир, башкисәрләр,
пәйгамбәрләр үтә шуышып...

Җиргә упкан тырнакларым белән,
таш күзләрем белән, яланбаш—
сөзеп карыйм алга, еракларга—
Адәм йөзле тоткын тораташ.

Бу тормышның җилбәзәк матурлыгын,
Татлы көен, серле пошымын—
алыштырдым мәңге сак торуга,
салып умырткага басымын...

Барлыйм—эзлим, узган, киләчәкне—
әллә бөек акыл, әллә кол—
тешем кысып, карыйм тирә-якка,
рух ирекле, бәйдә—аяк-кул!..

Җан кузгалып киткән чаклар була...
Йә чәйнисе килә бәрәвен,
үчеклисе килә сабырсызны,
йә уяна эчтә фиргавен!..

Күп яшәдем! Күп тылсымнар күрдем:
җанлы кабырчыклар, бакалар...
Илаһлары—йә бугазны буды,
йә йомшарып, сөйде аркадан.

Бар күргәнем күкрәк кабыгымда:
сабырлыгым хакы—матдәмдә.
Кемдер менә тояк астымдагы
Гөлне таптап, кертте матәмгә!..

Җилләр үбә! Гөрли гомер, вакыт...
Мәңге сакчы хәлдә торасы
Әбелһәүл мин...
                    Адәм йөзле арыслан...
Тешләп саклыйм милләт мирасын!

Плащ кигән гөлле урамнарың, Париж,
Хушбуй исе... Көяз карчыклар...
Монматрда мең кат тиражланган
                    Дега-Ренуарлар,
Балконнарда—мәшһүр "чыпчыклар"...
"Сәнгатьләрдә яңа алым беткән":
Мәңгелеккә импрессионизм иле
Итте сине
Сәрхуш рәссамнәрең... Әйтерсең лә,
Иһрам эчендәге—илаһлар...
Чиркәү эчләреннән эре-эре
Атлый сыман безнең тарафка...
Карт һәм жыраучы шәһәр,
Пәрдәләрең кинәт ачылып китеп,
Коелыр сыман аска бар серләр...
Парик кигән җилбәзәк Людовиклар,
Ачык түшле узган гасырлар.
Кибәк кебек вак машина—"зыр-зыр":
Килдең менә, Казан, Парижга—
Инде күңел рәссам чугы белән
Бар илһамын сиңа багышлар.

...Булон урманына
Ап-ак оек кигән атлар чума...
Онытылып, көнчыгышка
                    Һаман каерылам...
Анда—Бальзак... Экипажда—дама!
Эшләпәсе—кара каурыйдан...

[1] Кеше йөзле арыслан, сфинкс.

Җанеки

Сагынуым саплам-саплам сары,
аннан хәтер келәм тукый барыр—
һәр вакыйга анда тынны кысар,
тетрәндереп хәтта келәмчене...
Хуш пар былбыл—сөю манзарасы,
гөл бостаны—әле сугарасы...
Елга-йолдыз—аяк гизгән җирләр,
таулар, чүлләр—күтәрәсе вөҗдан...
Анда тагын серле бер чишмәлек—
белдекләләр аңлый алмас
бер "көй"—
әйтелмәгән бер бөртек сүз,
караш,
күз кысуы асыл ярның:
—Җанеки!...

⁂

Тубыгымнан—дөньям: һәлакәтем,
вак уйларым, соры мәшәкатем,
ыгы-зыгы шәһәр,
сәүдә бәрәкәте,
калҗа-калҗа кибет,
кара ирләр
арасында һаман синең сының,
кулым сузсам, югала тылсымың.
—Тәңреләрдән җиргә
тәгәрәгән "ташым",
тирән кулларыңа куяр идем башым,
нинди тансык миңа нур учагым—
җәннәт кирәк чагым,
корыган чагым.
Хәтәр хыял тота, буып җаным:
Ефәкчеләр юлы... Кәрван чаңы!..

Китеп баручы нарат Казанга

"Бай булган—тыелсын!"
Коръәннән

Мәҗүси мин, агач моңы
Чорналганга бәгырьгә—
Таш маймыллар доңгырдаган
Бу шәһәр миңа нигә?!
Татар тамыры—агач тамыр,
Сумалалы җан-бәгырь,
Шәҗәрәмнең һәр ботагы
Былбыл кунганга авыр.
Тәңре кабызган яшәвем
Бүрәнәдән—алтыннан.
—Сеңдергәнгә тарихымны
Елыйсыңмы ахырдан?
Синнән, гөлдәй, калкып чыккан

Йорт-нигезем, миллэтем,
Гөбеләрем, бишекләрем,
Каләм-китап—дәүләтем!
Таш куышлы балаларга
Бураларым—җәннәтем—
Нарат, каенкайлар тәмен
Ничек итеп аңлатыйм?!
Агач илем! Китмә мәңге!
Җан — агачка мәдхия,—
Кочам кәүсәң, сыйпыйм: яфрак...—
Иңнәреңә баш куям...

Шөкер, каләм!
Синнән башка җирдә
узганнарын белми бер кавем...
Мин билгесез үтмәм
калдырганга
сары кәгазьләрдә
сукмагым.
Сәлам, байрак!
Җилфердисең ялгыз.
Минем кебек, нәүмиз
бала җан...
Ертылмыйча тотыл.
Килер көннәр,
мәйданнарда оер
җан вә җан.

Кибә тамак!...
Туфрагына егыл
Ватаныңның,
газиз илеңнең!
Ирекле рух—үзе гавәм,
дәвам.
Мин табынмыйм потка!
Чи-ген-мим!

1997—2002.

Мөнир
Абдуллин

ҖИРЕ БАРНЫҢ ҖИМЕ БАР

Җир—бетмәс-төкәнмәс байлык чыганагы. XVII гасырда яшәгән инглиз галиме Вильям Петти юкка гына "Хезмәт—байлыкның атасы, җир аның анасы", димәгәндер. Чыннан да, җир безне ашата, киендерә, җылыта, сыенып урын бирә. Адәм баласы аны эшкәртеп, үзенә кирәкле азыклар җитештерә, мал-туары өчен кирәк кадәресен әзерли. Җир астыннан нефть, күмер, тимер һәм башка файдалы казылмалар табып ала.

Җир кешегә меңнәрчә еллар буена хезмәт итеп килә. Техника туза, машиналар, кешеләр алмашына, ә җир һаман игелек күрсәтә. Адәм баласы беренче тапкыр җирне чокып шунда орлык салган. Тора-бара сука, сабан, трактор һ. б. техниканы уйлап тапкан. Техник казанышлар крестиянны азмы-күпме авыр хезмәттән коткарган. Шулар иген үстерергә, мал-туар асрарга булышкан.

Крестиян халкы гомер гомергә җирнең кадерен белеп яшәгән. Уңышсыз ачлык елларында да аннан өметен өзмәгән. Күк йөзенә карап Ходайдан яңгыр теләгән, җирнең көч-куәтенә ышанган. Билгеле, җир-ана гел мәрхәмәтле генә булып тормаган. Аның крестиянны бер телем иписез калдырган еллары да булган. Әмма нинди генә еллар булмасын, җирдән күбрәк алу ягын караганнар. Аның мәйданын киңәйтү өчен урманнарны кискәннәр, агачларны яндырганнар. Ләкин җирне ничек телисең, шулай арттырып булмый. Алай гына түгел, аның белән сак эш итмәсәң, ул еллар узу белән уңдырышлылыгын киметеп, икмәксез калдырырга да мөмкин.

Безнең чорларга кадәр үк меңнәрчә еллар элек кешеләр чәчүлек орлыкның, ашламаларның, басуларны сугаруның нәрсә икәнлеген белгәннәр. Әйе, җир белән эш итә башлаганнан бирле кешеләр ул тотрыклы уңыш бирсен өчен аны эшкәртү, уңдырышлылыгын күтәрү ысулларын эзләгәннәр. Борынгы грек фикер ияләренең, Рим язучыларының хезмәтләрендә үк көл, тирес куллану турында киңәшләр бирелә. Пар җирләре калдырылган, өч басулы чәчү әйләнеше булып, аның берсенә ял биргәннәр. Ул ял иткәндә чүп үләннәрдән арындырганнар, тирес керткәннәр. Бу хакта күренекле тарихчы Газиз Гобәйдуллин да "Тарихи сәхифәләр ачылганда" дигән китабында искә алып уза. Ул 1770 елда Россиядә сәяхәт кылган немец Георгиның сүзләрен китерә: "...Хәзерге татарларны игенче дип әйтергә ярый. Чөнки алар җирләрен рус крестиянына караганда күбрәк тиреслиләр...".

Игенчелек системасы даими камилләшә барган. Җирнең уңдырышлылыгын күтәрү өчен нәтиҗәле алымнар кулланырга тырышканнар: чәчү әйләнешләре үзгәрә, минераль ашламалар кертелә, чүп үләннәргә, үсемлек авыруларына, корткыч бөҗәкләргә каршы химик матдәләр файдаланыла, җир эшкәртү

алымнары камилләшә. Ләкин игенченең иң явыз дошманы—су һәм җил эрозиясе аны сагалап кына йөри һәм нык кына зыян да сала. Крестиян моңа нәтиҗәле каршы тора алмаган. Бүген дә су һәм җил эрозиясе китергән зыян җир шарында миллиардларча сумнар белән исәпләнә. Безнең республикада гына да су һәм җил эрозиясенең зыяны аркасында ел саен байтак җир мәйданы авыл хуҗалыгы әйләнешеннән төшеп кала. Эрозиягә каршы чаралар үткәрү кирәк булган сөрү мәйданы соңгы кырык ел эчендә ике тапкыр чамасы артты. Ел саен кар һәм көчле яңгыр сулары белән туфракның уңдырышлы катламы юыла, елга һәм сулыкларга ләм утыра. Шуның аркасында Татарстанда, белгечләр теле белән әйтсәк, һәр елны 700 мең тоннага якын гумус, ягъни уңдырышлы катлау югала. Ә галимнәрнең исәпләвенчә, бу 10 миллион тонна органик ашлама кертүгә тиң. Шунысы да бар: эрозиядән зыян күргән басуларга никадәр күп ашлама кертсәң дә, анда уңыш күпкә ким була. Кертелә торган минераль ашламаларның яртысы чамасы юылудан килгән югалтуларны каплауга тотыла. Эрозиягә дучар ителгән җирләр бигрәк тә Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе, Теләче, Югары Ослан, Яшел Үзән, Питрәч районнарында күп.

Әлбәттә, бу афәт бер бүген генә килеп чыккан нәрсә түгел. Ул Россиядә XIX гасырның икенче яртысында, ягъни 1861 елгы реформадан соң киң тарала. Крестияннарның иң яхшы җирләре алпавытлар кулына күчә. Крестияннар исә авыш урыннардагы, чокыр-чакыр тирәсендәге җирләрне, комсу туфракларны сөреп, иген үстерергә мәҗбүр булалар. XX гасыр башына инде чокыр-чакырлар киңәя, туфрак юыла башлый, ком бураннары көчәя. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, патша Россиясендә туфракның юылуы аркасында ел саен 300 мең гектарга якын җир бөтенләй ташландык хәлгә килгән. Колхозлар оештырылу елларында, билгеле, эрозиягә каршы көрәш кайгысы булмаган. Узган гасырның алтмышынчы еллары башында инде Татарстанда бөтен җирнең 20 проценты эрозия белән зарарланган була.

Эрозиянең килеп чыгуына еш кына адәм баласы үзе дә гаепле. Урманнарны туктаусыз һәм тәртипсез кисү, ерганакларны ныгытмау, аларны күммәү, яңгыр сулары белән юылган басуларны тигезләмәү, юл буйларын ныгытмау һәм яшелләндермәү, тау битләрендәге кырларда тиешле агротехник чаралар үткәрмәү, агачлар утыртмау, урман полосалары булдырмау—болар барысы да эрозиянең көчәюенә китерә.

Билгеле, бу юнәлештә республикада бернәрсә дә эшләнмәде һәм эшләнми, дип әйтеп булмый. Шул ук алтмышынчы еллар башында чокыр-чакыр, ерганакларның ишелүенә каршы кайбер чаралар күрелде. Мәсәлән, читәннәр куеп, вакытлыча буалар төзеп, җимерелә барган елгаларга чүп-чар тутырып, игенченең бу явыз дошманын авызлыкларга тырышып карадылар. Тик мондый чараларның әллəни йогынтысы сизелмәде. Язгы сулар һәм яңгыр сулары барысын да юкка чыгара торды. Ярлары ишелә килгән елгаларның кырыйларына урман полосалары утыртуның да файдасы тимәде. Чөнки кар һәм кар суларын кырда саклап калу өчен чаралар күрелмәде. Шуңа күрә чокыр-чакырлар, ерганаклар зурайган саен урман полосалары үзләре дә юкка чыкты.

Ни өчен соң әле без бу хәлгә битараф карыйбыз? Бөтен республика басуларында ерганаклар хасил булып, ярларның ишелә баруын читтән генә күзәтеп торып, уңдырышлы җирләребездән колак какканны көтәбезме?

Туфракны эрозиядән саклау өчен федераль һәм республика бюджетыннан шактый акча бирелә. Ә җирле хакимият органнары үз акчаларын кызганалар. Алар кечкенә генә ерганакларның зур чокырларга әйләнүен күз алдына китермиләр, ахрысы. Әлбәттә, дәүләт ярдәменнән башка гына мондый зур эшләрне башкарып чыгу күмәк хуҗалыкларның хәленнән килми. Әгәр дә вакытында җитди чаралар күрелмәсә, тора-бара моның бик кыйммәткә төшүе ихтимал. Эрозия үзенең җимерү көчен туктатырга уйламый. Татарстанда инде аның белән зарарланган җирләр 1 миллион 300 мең гектардан артып китте.

Чокыр-чакырларның күбәюе аеруча борчылу тудыра. Алар 1960 елда республика буенча 12433 булса, 2000 елга 19883 кә җитте. Җимерелә барган чокыр-чакырларның гомуми озынлыгы 27 мең километрдан артып китә. Бигрәк тә Мамадыш, Югары Ослан, Яшел Үзән, Питрәч, Әгерҗе, Кукмара районнарында күп алар. Мәсәлән, Мамадыш районында 1960 елда җимерелгән чокыр-чакырлар 1080 булса, 2000 елда алар 1685 кә җитте. Хәзер дә аларның саны кимеми.

Дөрес, республиканың кайбер районнарында җирне саклау программасы

эшләнеп, ул уңышлы тормышка ашырыла. Бу яктан Азнакай районы үрнәк була ала. Монда берничә ел элек шушы мәсьәләгә багышлап республика семинар-киңәшмәсе үткәрелде. Җирне саклау, эрозиягә каршы көрәш проблемаларын район хакимияте, авыл хуҗалыгы предприятиеләре даими күз уңында тоталар. Менә ни өчен район хуҗалыкларында текә яр буйларына, ерганакларга үлән чәчелә, вак таш салына. Ә инде чокырларның тирәнлеге 3 метрдан да артып китсә, су җыела торган корылмалар төзелә, башкача әйткәндә, ул чокырлар зур таш кисәкләре белән тутырыла. Бу эш артык кыйммәткә дә төшми, әмма эрозиягә каршы нәтиҗәле көрәшергә мөмкинлек бирә. Районда вак таш тутырылган шундый 60 тан артык чокыр бар.

Район хуҗалыкларында эрозиягә дучар ителгән җирләрнең исемлеге һәм аларны тәртипкә китерү буенча чаралар картасы булдырылган. Җил эрозиясенә каршы көрәштә нәтиҗәле алымнарның берсе буларак, юл кырыйларына агачлар утыртылган. Ел саен 20-30 гектарда кыр ышыклау агачлары, 30-35 гектардагы чокыр-чакыр кырыйларына агач үсентеләре утыртып чыгалар. Соңгы ун елда 430 гектардан артык мәйданда агач үсентеләре утыртылган. Азнакай урман хуҗалыгы чокыр-чакыр кырыйларына утырту өчен үсентеләрнең һәм декоратив үсемлекләрнең унлап төрен үстерә. Азнакай районы территориясенең байтак өлешен калку һәм сөзәк җирләр алып тора. Җил эрозиясе мондый урыннарга аеруча зур зыян салучан. Шуңа күрә сөзәк басуларны киртләчләп эшкәртү алымы кулланыла. Урман хуҗалыгы агачлар утырта. Берничә ел эчендә сөзәк урыннарда урман үсеп чыга. Болар өстенә район территориясендә скважиналар бик күп. Меңләгән километрга электр линияләре сузылган, җир асты коммуникацияләре дә җитәрлек. Алар үзара юллар белән тоташтырылган. Мондый кишәрлекләрдә туфрак эшкәртү, чәчү, урып-җыю агрегатларына эшләү кыенга туры килә. Шуның өчен дә район хакимияте һәм районның җир төзелеше хезмәте шушы корылмалар тирәсендәге җирләрдән нәтиҗәле файдалану чараларын күрә. Мәсәлән, соңгы 15 ел эчендә электр линияләре сүтеп алынган яки реконструкцияләнгән.

1996 елдан башлап районда җир көне үткәрелә. Анда агрономнар, урман белгечләре, җир төзүчеләр, мәктәп укучылары, төзүчеләр катнаша.

Болар барысы да азнакайлыларга җирдән нәтиҗәле файдаланып, аның уңдырышын күтәреп һәм эрозиядән саклап, игенчелектә югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек биргән. Бу район 2002 елда республикада иң күп ашлык җыеп алды һәм иген уңышы елдан-ел күтәрелә бара. Азнакайлылар 2003 елда 202 мең тонна ашлык җыеп, тагын алдынгылар сафында атлыйлар.

1997 елның мартында Татарстан Министрлар Кабинеты "1997-2005 елларга Татарстан Республикасында туфракның уңдырышлылыгын күтәрү һәм аны эрозиядән саклау буенча комплекслы программа" раслады. Шуннан соң республикада хәтсез генә эш башкарылды. Мелиораторлар аеруча активлык күрсәтәләр. Алар республикада барысы 526 буа төзеделәр, 1200 дән артык корылма ясадылар. 2,5 мең гектардан артык мәйданда урман-мелиорация чаралары үткәрделәр.

Башка хуҗалыклар да кул кушырып утырмыйлар. Мәсәлән, Биектау районының "Чулпан", Мамадыш районының "Дружба", Саба районының Тукай исемендәге, Чүпрәле районының "Ялкын", Чистай районының "Кама" күмәк хуҗалыкларында үткәрелгән мондый чаралар җирнең торышын яхшыртты. Биектау районының "Чулпан" күмәк хуҗалыгында 25 ел буена эрозиягә каршы чаралар комплексы тормышка ашырылды. Шуның нәтиҗәсендә хуҗалыкның чокыр-чакырлы җирләрендә авыл хуҗалыгы культуралары игү өчен уңай шартлар тудырылды.

Эрозиягә каршы көрәш чаралары комплексында ышыклау агачлары утырту аерым урын алып тора. 2002 елда 800 гектарда, моннан тыш юл кырыйларында 980 гектарда ышыклау агачлары утыртылды. Ләкин бу бер урманчыларның гына эше түгел. Шуны истә тотып, Арча, Балтач, Кукмара, Саба һәм кайбер башка районнарның авыл хезмәтчәннәре дә зур эш башкаралар. Тик һәр районда да бу мөһим эшкә тиешенчә әһәмият бирелми әле. Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматларына караганда, кайбер районнарда урман полосалары утырту өчен җир бүлеп бирү турында уйлап та карамыйлар.

Сүз дә юк, урман хуҗалыклары эше бу яктан мактауга лаек. Ләкин аларның үзләренә генә моны башкарып чыгу кыен. Шуңа күрә бу эшкә авыл хезмәт-

чәннәре дә активрак тотынса, авыл хуҗалыгында файдалану өчен яраксыз җирләргә агачлар утыртуга игътибарны арттырса, моннан файда күбрәк булачак. Әнә Арча, Балтач районнарында агачларны чокыр-чакыр кырыйларына, коры, үзәнлекләрнең текә авышлыкларына утыртып, бик игелекле эш башкаралар.

Әмма кайбер урыннарда урман полосаларын утырталар да оныталар. Еш кына агач үсентеләренең рәт аралары эшкәртелми, аларны чүп үлән басып китә.

Бөтен бәла шунда, XX гасырның кырыгынчы-илленче елларына кадәр туфракны җил эрозиясеннән саклауның бу мөһим чарасына игътибар ителмәде. Урманнар утыртылды, ләкин кыр ышыклау урман полосаларына ис китмәде. Тик гасыр уртасында гына "Табигатьне үзгәртүнең сталинчыл планы" нигезендә зур чаралар тормышка ашырыла башлады. Ул чакта бөтен ил шушы эшкә күтәрелде. Татарстанда кыска гына вакыт эчендә 50 мең гектардан артык мәйданда ышыклау урман полосалары утыртылды. Әмма бу ялкын тора-бара сүнде. Хәтта булганнарын саклап, карап үстерү турында кайгырту җитмәде. Кайбер урыннарда аларны кисеп бетерүгә кадәр барып җиттеләр. 1960 елда басылып чыккан "Татарская АССР за 40 лет. Статистический сборник" дигән китапта мондый саннар китерелә: 1953 елда чокыр-чакыр кырыйларындагы кыр ышыклау урман полосалары, утыртылган агачлар 57,1 мең гектар булса, 1959 елда алар 31,1 мең гектарга кала. Хәзер кыр ышыклау урман полосаларын бик сирәк урыннарда гына күрәсең.

Әлбәттә, гидротехник чаралар үткәрү, урман полосалары утырту—туфракны эрозиядән саклауның бердәнбер юлы түгел. Белгечләр кар һәм кар сулары тотуның, басуларны авышлыкка аркылы сөрү, сөрү катламын тирәнәйтүнең дә әһәмиятен югары бәялиләр. Хәзер исә кар тоту турында оныттык. Элек кар тоту буенча күмәк хуҗалыкларга план җиткерелеп, аның үтәлеше даими тикшереп торылды. Югыйсә, моның артык мәшәкате дә юк. Тик төрлечә сәбәп табып, моңа кул селтәдек.

Агрономия фәне туфракны эшкәртүнең күптөрле алымнарын белә. Заманында җирне эшкәртүгә кагылышлы бәхәсләр шактый куерып, белгечләр бердәм фикергә килделәр: туфракны җирле шартлардан чыгып, һәр төбәкнең үзенчәлеген исәпкә алып эшкәртү хәерле, шаблонга һич тә юл куярга ярамый.

Бериш галимнәр җиргә ял бирергә, ягъни чиста пар калдырырга, дигән фикерне якладылар. Элек чиста пар калдыру мәҗбүри итеп куелды. Аннары җир тик ята, чиста пар чүп үлән тарату чыганагына әйләнде, дигән карарга килделәр. Шулай итеп, чиста пар мәйданы кимегәннән кими барды, шул исәпкә бөртекле ашлык җире арттырылды. 1925-1929 елларда чиста пар җирнең 33 процентын алып торса, 1963 елда инде ул 1,2 процентына калды. Шуннан соң бөтенләй оныттылды. Соңгы вакытта чиста парның кирәклеген исбатлап чыгыш ясаучыларның булуы гаҗәп түгел. Әгәр дә чиста парны бөтенләй бетерсәк, бөтен басу-кырларыбыз тоташтан сөрү җиренә әйләнәчәк. Бу яктан Татарстан болай да Россиядә чәчүлек җиренең артык күп сөрелүе ягыннан алдынгылар сафында. Профессор Н. Максимов, туфрактагы дымны саклау максатында һәм чүп үләннәр белән көрәштә чиста парның әһәмияте аеруча зур, дип саный.

Инде җирне эшкәртүгә килгәндә, элегрәк калаксыз сабаннар белән эшкәртүгә өстенлек бирелде. Чиста пар басулары кимегәч, чәчү әйләнешләре бозылгач, җирне чүп үлән басты. Аннан котылабыз, дип күп кенә хуҗалыклар җирне калаклы сабаннар белән сукалауга керештеләр. Ә алтөрәнсез сабаннар белән эшкәртү чүп үләннәрнең тагын да артуына китерде. Басуларны кара солы басып алды. Шуңа күрә республика авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белгечләре туфрак эшкәртүне калаклы сабаннар һәм калаксызлары белән бергә алып барырга киңәш итәләр.

Курган өлкәсенең танылган игенчесе Терентий Мальцев гомере буена туфракны калаксыз сабаннар белән сөрүне яклап килде. Ул үз хуҗалыгы "Заветы Ленина" колхозында корылыклы елларда да югары уңыш үстерүнең төп сәбәпләреннән берсе итеп әлеге алымны куллануны санады. Терентий Семенович фикеренчә, туфракны калаксыз сабаннар белән эшкәртүнең файдасы шунда, үсемлек үзенә азыкны туфракның өске катлавыннан ала. Анда органик матдәләр күбрәк. Шуңа күрә басуны эшкәрткәндә туфракның шушы катлавын әйләндермичә өстә калдырырга тырышалар. Шуның өстенә үсемлек калдыклары туфракны органик матдәләр белән баета, аның уңдырышлылыгын күтәрә. Т. Мальцев, сөрү катлавын өскә әйләндереп сукалау туфракның

структурасын җимерә, дип санады.

Ләкин җирне калаксыз сабаннар белән эшкәрттең дә шуннан соң аның уңдырышлылыгы яхшыра, югары уңыш җыеп алырга мөмкин, дип уйларга ярамый. Җир калаксыз сабаннар белән сукаланганнан соң да аны өстән эшкәртәләр, ягъни культивациялиләр, тырмалыйлар, орлык күмдерү хәленә китерәләр. Шунысы бар, калаксыз сабаннар белән эшкәрткәндә игене җыеп алынганнан соң басудагы камыл өстә кала. Ул кар тотып кына калмый, ә бәлки туфракның өске катлавын җил-давылдан да саклый. Димәк, эрозия куркынычы кими. Белгечләр исәпләп чыгарганча, туфракта берничә сантиметр гумус катлавы булдыру өчен әлләничә еллар кирәк. Ә аны юк итү өчен берничә сәгатьлек ком бураны да җитә.

Авыл хуҗалыгы алга киткән илләрдә хәзер җирне мөмкин кадәр азрак эшкәртү фикерен куәтлиләр. Алар моны, бер яктан, ягулык-майлау материаллары азрак тотылуы, икенчедән, эрозиядән килгән зыянның кимүе һәм явымтөшемнең нәтиҗәлелеге белән аңлаталар. Җирне азрак эшкәртү, дигәндә, туфрак өстендә үсемлек калдыкларының 70 проценты калырлык итеп эшкәртү күздә тотыла. Хәзерге заманның куәтле тракторлары, туфрак эшкәртү машиналары, минераль ашламаларны һәм агулы химикатларны чиксез күп куллану туфракның физик үзлекләрен нык үзгәртә.

Безнең республикада туфракны эшкәртүгә зур игътибар бирелә. Бу елның үзенчәлекләренә, көз килешенә бәйле рәвештә эшләнә. Монда җирнең чүплелегенә, нинди культура чәчеләсенә, элгәргә, техникага һәм башка мөмкинлекләргә карап һәр кыр өчен аерым билгеләнә.

Минераль ашламалар дигәннән, агрохимиядә шундый бер закончалык бар: үсемлекләрне туендыру өчен киткән төп элементлар туфракка кайтарылырга тиеш. Җир ничек кенә эшкәртелмәсен, шушы таләп үтәлмәсә, яхшы уңышка исәп тоту кыен. Ел саен уңыш белән бергә азот, фосфор, калий һәм башка туклыклы матдәләр китә. Минераль ашламалар кулланыла башлагач кына җир шарында уңыш арта башлаган. Академик С. Волькович хезмәтләреннән күренгәнчә, 1870 елга кадәр бөртекле культураларның уңышы уртача бер гектардан Голландиядә—15,5 центнер, Германиядә—13 центнер чыккан. Инде минераль ашламалар барлыкка килгәч, 1900 елда Голландиядә бер гектарда 19,4 центнер, Германиядә 18 центнер уңыш үстерелгән. Утыз елдан соң, бигрәк тә азотлы ашламалар җитештерү җайга салынгач, Голландиядә гектардан 31,8 центнер, Германиядә 24,8 әр центнер уңыш алалар. Ул заманда Россиядә минераль ашлама заводлары булмаган диярлек. Берничә суперфосфат заводы эшләгән, алары да чималны читтән кайтарткан.

Татарстанның исә, соңгы елларда игенчелектә ирешкән уңышлары нәкъ менә минераль ашламаларны Россиянең башка төбәкләренә караганда күп кертүе белән дә аңлатыла. Нурлат, Арча, Балтач, Саба һәм башка кайбер районнар минераль ашламаларны нәтиҗәле кулланып, уңыш үстерүдә югары нәтиҗәләргә ирештеләр. Моңа кадәр Кубанда гына үстерелә торган уңышны хәзер Татарстан хуҗалыклары да җыеп ала.

Ләкин минераль ашламаларны кирәгеннән артык кертү, үсемлекләрне саклау буенча химик матдәләрне чамадан тыш күп куллану туфракта үзгәрешләр барлыкка китергән, аның эчелеген арттырган. Гомумән, галим-белгечләрнең фикеренчә, җир шарында туфракның уңдырышы кими бара. "Экология и экономика современного сельского хозяйства" дигән китапта (авторлары И. Гәрәев, С. Шәрипов) шундый мәгълүматлар бирелә: җир ресурслары ярлылана, начарая бара. Чөнки күбрәк керем һәм мөмкин кадәр югары уңыш җыеп алуга юнәлдерелгән технологик һәм экономик сәясәт алып барыла. Планетаның барлык илләрендә якынча 1,2 миллиард гектар авыл хуҗалыгы җире, көтүлек һәм болынның уңдырышлылыгы нык кимегән. Мондый хәл Россия Федерациясендә, шул исәптән Татарстанда да күзәтелә. Россиядә 209,9 миллион гектар авыл хуҗалыгы җиренең 53,5 миллион гектары эрозиягә дучар ителгән, 9,5 миллион гектары сазлыкка әйләнгән. Еш кына предприятиеләр корганда, файдалы казылмалар чыгарганда туфракның уңдырышлы катлавын саклауга куелган таләпләр искә алынмый. Шул сәбәпле зур мәйданнарда туфракның уңдырышлы катлавы юкка чыга.

Димәк, җирнең табигый уңдырышын саклау гына җитми, аны даими яхшырта барганда гына ул үзенең уңыш бирергә сәләтен саклап кала ала. Шуңа күрә

җирне ел саен органик ашламалар белән ашлап торуның әһәмиятен әйтеп торасы да юк. Тик республикада кыйммәт бәягә минераль ашламалар алырга күнеккән кайбер хуҗалык җитәкчеләренең органик ашлама әзерләп, кырга чыгарып артык мәшәкатьләнеп йөриселәре килми. Фермалары тирескә күмелсә күмелә, әмма аны солярка, бензин юклыкка, техника җитмәүгә сылтап, кырга чыгаруны оештырмыйлар. Белгечләр гумусны тулыландыруның төп чыганагы итеп нәкъ менә тиресне саныйлар. Тик аның кадерен белеп бетермибез әле. Авыл кешесе гомер-гомергә бәрәңге бакчасын тирес белән ашлаган. Яңгырсыз елларда да бәрәңгесез калмаган, үзенеке үзенә җитеп барган.

Академик Дмитрий Прянишников авыл хуҗалыгында тиресне төп ашламаларның берсе итеп санаган. Ул аны туплау, саклау, аннан компост ясау һәм куллану алымнарын өйрәнгән һәм шуны пропагандалаган.

Безгә бу мәсьәләдә чит илләр тәҗрибәсенә күз төшерү зыян итмәс. Мәсәлән, Германиянең экологик яктан чиста продукция житештерүче авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә тирес бердәнбер азот чыганагы булып санала. Мондый хуҗалыкларда үсемлекләрне авырулардан һәм чүп үләннәрдән саклау өчен химик препаратлар кулланмый. 2002 елның декабрендә Биектау районындагы "Сөт плюс" фирмасы белән таныштыру җыелышында Германиянең "Замсваген" авыл хуҗалыгы предприятиесе директоры Кеслинг чыгыш ясады. Монда гектардан 70 центнер уңыш алалар икән. Кеслинг әфәнде шундый югары уңышның төп сәбәбе итеп туфракка һәр елны күп итеп тирес сыекчасы кертүне саный.

Канаданың Квебек провинциясендә булып кайткан галим, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе профессоры Әхәт Салихов болай дип сөйли: "Квебек провинциясенең авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә минераль ашламага караганда күбрәк органик ашламага өстенлек бирәләр. Игеннәрне җыеп алганда вакланган салам кырда кала, аннары аны яз көне җир эшкәрткәндә камыл белән бергә туфракка күмдерәләр." Канада фермерлары тәҗрибәсеннән күренгәнчә, алар кукурузны орлыкка җыеп алганнан соң кырда калган үсемлек калдыкларын да җиргә күмдерәләр. Вакланган соя саламы да басуда кала. Үсемлек калдыкларын ашлама итеп файдалану, органик ашлама кертү күп кенә фермерларга минераль ашламалардан башка гына яки аларны бик аз гына кертеп, иген үстерү мөмкинлеге бирә. Ә органик ашлама җитештерү аерым игътибар үзәгендә тора. Мәсәлән, 100 сыеры булган фермер аслык итеп прессланган саламны файдалана, бозауларга аслык итеп салу өчен пычкы чүбе сатып ала. Тирес һәм тирес сыекчасы бетон белән эчләнгән саклагычларга тутырыла. Аны кыш айларында болгатып торалар. Ашламаны җирне туңга сөргәндә яки күпьеллык үләннәрне бер кат чабып алгач кертәләр.

Безнең үзебездә дә моңа охшаш тәҗрибә бар. Ләкин бездә һәр яңалык бик авырлык белән генә тормышка ашырыла. Семинар-киңәшмәләрдә күрсәтеп бирү, сөйләп аңлату да ярдәм итми. Кайвакытта икътисадый-финанс кыенлыкларына, акча юклыкка сылтап, кайбер авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә мөмкин булганын да эшләмиләр. Аннары уңыш түбән булды, яңгыр яумады, дип зарланышырга тотынабыз. Алексеевск районының Илшат Гомәров җитәкчелегендәге фермер хуҗалыгы бөртекле культуралар үстерә һәм ел саен югары уңыш ала. Ләкин ул минераль ашламаларны кулланмый диярлек. И. Гомәров бер басуга борчак чәчеп, аны яшел килеш сөреп куя. Билгеле булганча, бер гектарга яшел масса—сидерат 50-60 тонна тирескә тиңләшә. Саламны фермер ваклый һәм җиргә күмдерә.

Азнакай районының "Авангард" күмәк хуҗалыгында да минераль ашламалар белән бик артык мавыкмыйлар. Шуңа карамастан, югары уңыш җыеп алалар.

Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенең игенчелек кафедрасы берничә ел буена шушы проблема буенча тикшеренүләр алып бара. Академия профессоры, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Х. Хәбибрахмановны тыңлап карыйк әле: "Күпьеллык үлән чәчүлекләре һәм берьюллык кузаклы культуралар мәйданын арттыру, яшел ашламалар—сидератларны мөмкин кадәр күбрәк куллану, саламны органик ашлама сыйфатында ваклап җиргә күмдерү тотрыклы югары уңыш үстерергә, арзанлы ашлык җитештерергә, берүк вакытта туфракның уңдырышын күтәрергә мөмкинлек бирә".

Салам димәктән, хәзер бериш галимнәр саламны органик ашлама итеп

файдалану, ягъни аны җиргә кертү фикерен яклыйлар. Тик менә кайбер урыннарда аның кадере юк. Саламны яндыралар, аннан тизрәк котылу ягын карыйлар. Күпләр Белоруссиядән, Казахстаннан зур чыгымнар тотып, кыш көне малларның җанын асрап чыгу өчен салам ташыганнарын онытканнар. Саламны яндырганда туфракның химик-биологик составы начараюы, агулы газлар аерылып чыгуы билгеле. 2002 елның сентябрендә Кама Тамагы районында шундый хәлгә юлыктым. Кинәт Кама Тамагы поселогыннан ерак түгел бер басуда соргылт төтен күтәрелде. Барып карасам, бер абзый ат җигелгән арбага утырып, салам яндырып йөри. "Кайдан сез, абзый?"— дим. "Кама" хуҗалыгыннан", ди бу. Аңа шулай кушылган. Басудагы салам гына янмый, тау битләре, үләннәр, агач куаклыклары, җиләкле үзәнлекләр яна.

Якынча исәпләүләргә караганда, республикада һәр елны 3800 мең тонна саламның 1500 мең тоннасы терлек аслыгы итеп файдаланыла. 2300 мең тоннасы эскерткә куела. Кайбер хуҗалыкларда ул эскертләр еллар буена кырда тора, тычкан оясына әйләнә. Шушы кадәр салам 8,5 миллион тонна органик ашламага тиң дип санала. Моны файдалы матдәгә күчереп исәпләсәң, бу—96 мең тонна минераль ашлама дигән сүз. Менә ни өчен саламны яндырырга кирәкми, ә черемә, компост ясау өчен файдалансаң, күпкә отышлырак.

Җирне саклауда, аның уңдырышлылыгын күтәрүдә ачы туфраклы басуларны известьлау аерым урын алып тора. Татарстанда бүгенге көндә миллион 372 мең гектар ачы туфраклы җир бар. Бу—сөрү җиренең 38 проценты, дигән сүз. "Татагрохим"ның генераль директоры Салихҗан Кәлимуллин сөйли: "1987-1992 елларда 350-380 мең гектарда известьлауның фәнни нигезләнгән циклына күчү нәтиҗәсендә республикада ачы туфраклы җирләрнең артуы туктатылды һәм 1990-2001 елларда ул 388 мең гектарга кимеде."

Россиянең ачы туфраклы җирләрне зурдан кубып известьлау өчен мөмкинлеге юк. Ә безнең, киресенчә, республикада известь оны чыгара торган карьерларыбыз бар. Арча районындагы Күпербаш известь карьеры үзе генә дә ни тора. Ул проект куәте буенча елга 50 мең тонна известь чыгара ала. Россиядә инде ачы туфраклы җирләр 35 миллион гектардан артып киткән. Белгечләрнең исәпләвенчә, шул сәбәпле генә дә Россия 20 миллион тонна ашлыкны алып җиткерми.

Агрономнар яхшы белә: ачы туфраклы басуларга ашлама кертүнең әлләни файдасы юк. Менә шуларны истә тотып, "Татагрохим" акционерлык җәмгыяте Татарстан кырларына известь кертү, туфракның ачылыгын бетерү өчен ел саен зур эш башкара. Тик агрохимикларга хөкүмәтнең булышлыгы җитәрлек түгел әле.

Башка кайбер сәбәпләр аркасында да Россиянең күп кенә төбәкләрендә инде җирнең уңдырышы нык кимегән. Әнә галимнәр тагын бер ун елдан Кубан хәзерге кебек уңыш үстереп ала алмас, дип кисәтәләр. Алар моны җиргә әлеге дә баягы минераль ашламаның кирәгеннән артык күп кертелүе белән аңлаталар. Шуңа күрә дә белгечләр җирнең уңдырышын күтәрүнең, аны саклауның, эрозиягә каршы көрәшнең төрле юлларын эзләүне дәвам иттерәләр. Әйтик, күп кенә алга киткән илләрнең авыл хуҗалыгында әйләнә-тирә мөхитне саклау буенча фәнни программалары бар. Моның төп максаты экологик яктан чиста продукция җитештерүдән һәм җирне саклаудан гыйбарәт. Канадада 1935 елда ук кабул ителгән закон буенча җирбиләүче үзенең парга калдырган җирендә җил эрозиясенә каршы чараларны үтәсә генә җирне саклау турындагы законны үтәгән булып санала. Законны бозучы штрафка тартыла. Канадада туфракны саклауга юнәлдерелгән игенчелек системасы югары уңыш алырга ярдәм итә. Бу ил халкының 4 проценты гына авыл хуҗалыгында эшләсә дә, ул үзендә җитештерелгән бодайның шактый өлешен башка илләргә дә сата.

АКШта да туфракны саклау программасы эшләнгән һәм ул уңышлы тормышка ашырыла. Нәтиҗәдә су эрозиясеннән туфракка килә торган зыян 22 процентка кимегән. Җил эрозиясеннән килгән югалтуларны да киметүгә ирешелгән. Сәбәп нәрсәдә? Фермерлар иген үстерәсе җирләргә үлән чәчкәннәр һәм урман полосалары утыртканнар. Җыеп алынмаган уңыш өчен аларга хөкүмәт компенсация түләгән.

Ирландиядә дә шундый ук программа эшләнгән. Монда күп кенә фермер

хуҗалыкларында азотлы һәм фосфорлы ашламалар кирәгеннән артык күп кулланыла, дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Шуннан соң туфракка минераль ашламалар кертү нормасы билгеләнгән.

Бу тәҗрибә Татарстан хуҗалыклары өчен ни дәрәҗәдә кулайдыр. Шулай да белеп тору зыянга булмас. Югыйсә, кайбер районнарда күмәк хуҗалыклар берсеннән-берсе уздырырга теләгәндәй, бурычка бата-бата минераль ашлама сатып алып, мөмкин кадәр җиргә күбрәк кертергә тырышалар.

2003 елның гыйнварында Владимир шәһәрендә "Яңгыр суалчаннары һәм туфракның уңдырышлылыгы" дигән беренче халыкара конференция үткәрелде. Анда 70 ләп доклад тыңланды. Россия, Белоруссия, Украина, Литва, Үзбәкстан, Грузия һәм Һиндстандагы танылган фәнни үзәкләрнең галимнәре бергә җыелып, бүген иң мөһим проблемаларның берсе турында фикер алыштылар. АКШта органик калдыкларны эшкәртү өчен суалчаннардан файдаланалар икән. Бу туфракның уңдырышын күтәрүгә ярдәм итә. Инде уңай нәтиҗәләре дә бар. Галимнәр шуны исәпләп чыгарганнар: 50 суалчан көн саен бер квадрат метрда туфракны 25 грамм гумус белән баета.

Без инде төрле сәбәпләр аркасында шактый җиребезне су һәм җил эрозиясеннән саклап кала алмадык. Туфракның уңдырышлы катлавын исәпкә алмыйча файдалы казылмалар чыгарыла, промышленность предприятиеләре төзелә. Татарстанда, мәсәлән, нефть районнарында элегрәк никадәр уңдырышлы җирләргә, табигатькә зыян килде. Ул чакта җир-анабыз, аның киләчәк язмышы кызыксындырмады, күбрәк нефть чыгарылсын да, Татарстанга дан-шөһрәт килсен, дигән фикер өстенлек итте. Мәскәүләр якаңнан тоткач, эшләми хәлең юк. Түбән Кама ГЭС ын корырга дигәч, анысын да кордык, ләкин иң уңдырышлы җирләребез, болын, көтүлекләребез су астында калды. Болардан килгән зыянны әлегә беркемнең дә исәпләп чыгарганы юк, исәпләп чыгарырга уйлаучы да юк. Хәер, моннан инде ни файда!

Җирнең уңдырышын күтәрү, аны саклау һәркемгә кагыла. Элегрәк хөрмәтле язучыларыбыз да авыл хуҗалыгында барган үзгәрешләргә шатланып, кимчелекләргә көенеп, вакытлы матбугатта үз сүзләрен әйтә тордылар. Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев һәм башка кайбер әдипләр авыл халкының, крестиянның яшәү рәвешен тоеп, күреп яшәделәр, авылда барган үзгәртеп коруларга битараф калмадылар, яхшысын яхшы, начарын начар дип яздылар. Соңгы вакытта галиҗәнап язучыларыбыз әллә авылдан биздeләр, әллә барысы да ал да гөл, дип уйлыйлар, республиканың агропромышленность комплексында агрореформаларның барышы, моның уңай һәм җитешсез яклары, авылларыбызның иртәгәсе көне турында дәшмиләр. Бүген җир-ананың киләчәк язмышы турында язучының үткен фикере, акыллы киңәше, төпле сүзе җитми. Әлбәттә, авылларга чыкмыйча гына, Казан каласыннан торып кына крестиянны яклап җылы сүз әйтүе җиңел түгел. Язучы әйткән сүз һәркемнең күңеленә үтеп керер, авыл кешесеннән бигрәк, үз мәнфәгатен күбрәк кайгыртучы түрәләрне уйланырга мәҗбүр итәр.

Билгеле, җирне саклау турында сүз бер бүген генә бармый. Элек-электән галимнәр дә, агрономнар да, әдипләр дә чаң сугып килделәр. Тик моңа колак салырга теләмәделәр. Хәзер эш шуңа барып җитте, Россиядә җиргә кертү өчен тирес тә юк. Чөнки маллар саны бик нык кимеде. Соңгы елларда һәр гектар җиргә 8-10 тонна урынына 0,5 тонна органик ашлама кертелде. Татарстанда эш болай ук начар тормый. Шулай да белгечләр якындагы 10-15 ел эчендә, җитди чаралар күрелмәсә, туфракның уңдырышлылыгы 12-15 процентка кимү ихтималын кисәтәләр. Җире барның җиме бар, дигәннәр борынгылар. Югыйсә, тора-бара бик күп нигъмәтләрдән колак кагуыбыз ихтимал. Бу меңнәрчә тонна ашлык, бәрәңге, чөгендер, яшелчә һәм башкалар җыелмый калачак, дигән сүз.

*

Дискуссия: “Безнең заман герое”

Рәшит Фәтхерахманов

ТАТАРГА САТМА МАТБУГАТ...

1907 елның декабрендә “Әлислах”та Тукай татар мабугатының аянычлы хәле өчен ачынып, “Бер гәзитә идарәсе хәленнән” исемле шигырен бастыра. Шуннан нәкъ ике ел элек кенә “Кайда китте цензурлык”, “Иркенләнде каләмнәр” дип беренче тапкыр Тукаев имзасы белән шатлыклы аваз биргән шагыйрьнең бу юлы татарларда нәширлек бизнесының өметсез булуын искәртеп чаң кагуы очраклы хәл түгел иде, әлбәттә.Болар турында язмаска да булыр иде. Әгәр дә... Әгәр дә татар матбугатының хәле үткән гасыр башындагыдан аз гына уңайрак булса, газета-журнал һәм китап тиражлары тавыклар көләр дәрәҗәгә төшмәсә, барлык милли нәшриятлар дәүләтнең фәкыйрь дотациясенә өметләрен сузып, мескен хәлдә көн күреп ятмаса...

XX гасыр башында Тукай татар матбугатына хас булган үзәккә үтәрдәй проблемаларны төрле яклап һәм күп тапкырлар күтәрә. Кызганычка каршы, ул проблемалар бүген тагын да кискенрәк рәвештә каләм әһелләренең бугазына басып, тын алырга ирек бирмичә яшәп яталар. Бүген асылда матбугатның, әдәбият һәм сәнгатьнең (боларны милләтнең дип аңларга кирәк) язмышы хәл ителә. Фәкыйрьлек, укучы һәм тамашачыдан колак кагу классик мәдәният вәкилләренең “теш сызлавына” әйләнеп бара. Яңа, традицион булмаган агым тарафдарлары исә популярлык мәсьәләсенең чишелешен азгынлык һәм оятсызлык пропагандалау аша хәл итәргә омтылалар, шуның белән үзләренең барлык матди ихтыяҗларын канәгатьләндерү юлын эзлиләр... Һәм әхлаксызлык сазлыгына батып баручы җәмгыять чүплегенә әйләнгән аудиторияләрдә житәрлек азык табалар да. Болар барысы да хөрлек дип, демократия дип тамгалана. Шоу-бизнес лидерлары “халык мәхәббәте”н яулап алулары белән горурланып, үлеп баручы традицион сәнгать вәкилләренә тәкәббер караш ташлый. Соңгылары исә беренчеләрен талантсызлыкта гаепли. Дөнья җәмәгатьчелеге Русиядәге әхлакый кыйммәтләр мутациясен исе китеп күзәтә. Кайсыдыр Америка политологы: “Сез, русиялеләр, безгә охшарга телисез. Әмма сез торбаларны бутагансыз һәм чиста су кранын ачасы урынга канализация шакшысын тоташтыргансыз”,—дип әйткән ди, имеш.

Пычрак су белән уйнау хирыслыгы, аянычтыр, безнең милли әдәбиятка да яхшы ук үтеп керде. Моның асыл сәбәбе дә билгеле, әлбәттә. Нинди юллар белән булса да татар телле укучыны саклап калу, аны мавыктыру, үзенә тарту, киләчәктәге үсеш өчен ныклы җирлек булдыру, болгавыр чорны исән-имин үтү. Азгынлыкны чуар бизәкләп булса да, кешенең хайвани асылын уятып, әдәби табынга жим

урынына фәхешлек һәм зина куеп булса да, милләт өчен ят булган идеяләрне, тискәре фәлсәфәне байрак итеп күтәрү хакына булса да...

Җәмгыятьтә һәм әдәбиятта хөрлек чоры башлангач та, элеккеге ориентирлар дәррәү җимерелеп, яңа кыйбла эзләү һәм табу ихтыяҗы килеп тугач, әдәби номенклатура әдәбиятның фәлсәфи һәм рухи үсеш концепциясен эзләү белән мәш килде. Демократия әле үзенең сабыйлык чорын кичерә иде һәм һәртөрле "балалар авырулары" аңа тиз йогучан булып чыкты. Тиешле иммунитет күпчелек очракларда җитенкерәми иде. Милли аңга рухи СПИД куркынычы җитди үк яный иде. Менә шундый шартларда яңа сәнгать доктринасы эшләнде. Бу эзләнүләрнең нигезендә, һәр болгавыр чорга хас булганча, үткәндәге казанышларны кискен кире кагу да, яңага тынгысыз омтылыш та, вәзгыятькә аналитик бәя бирергә тырышу да ята иде. Бу процессны инде хәзер тулысы белән кузаллау да кыен. Күп санлы публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре, әдәби ел йомгаклары һәм кулуарлардагы бәхәсләр, теле һәм радио тапшыруларындагы әңгәмәләр...

Доктринаның формуласын соңгы елларда тәнкыйтьтә, публицистикада һәм әдәби иҗатта актив шөгыльләнүче Рафаэль Сибат менә бу рәвешлерәк тәкъдим итте: "Татар өчен Азия медиумы белән Европа прагматлыгыннан торган симбиоз әдәби концепция һәм фәлсәфә кирәк!" Никадәр катгыйлык һәм телнең "симбиозлыгы!" Бу әдәби юнәлешне әлеге әдип үзенең иҗатында тормышка ашыра да башлады. Соңгы елларда аның тарафыннан иҗат ителгән романнар нәкъ менә шундый "симбиоз" фәлсәфәгә корылган. Яшәеш турында фикер йөртергә тырышып, әлеге әдип, мода шаукымына ияреп, христианлык, мөселманлык, мәҗүсилекнең яңәшә куеп булмый торган карашларыннан шундый коктейль оештыра: күз аллары карангылана, наданлыкка, мәгърифәтсезлеккә таң каласың! Мисал итеп күптән түгел генә Исхакый премиясен алган (аһ, кемнәр генә бәя бирә бу романнарга!) "Ялгызак" романын китермичә кала алмыйм. Романның фәлсәфи үзәге Казан мәдрәсәләрендә белем алган Заһидулла тирәсендә бөтерелә. Заманы өчен тирән белемле, физик һәм рухи яктан көчле итеп сурәтләргә омтыла автор үз персонажын һәм, әдипнең үзенә генә хас булган каршылыклы фәлсәфә белән коралландырып, аннан нинди генә фикерләр әйттерми дә, нинди генә сүзләр сөйләтми! Геройның автор сүзләре белән сөйләве аның туксанынчы еллар татар зыялысына гына хас булган гыйбарәләрне еш куллануында ачык чагыла. Шул ук вакытта әсәрнең барлык персонажлары диярлек ике сүзнең берендә "мать твою" сүзтезмәсен кулланалар. Юлбасар бандитлар да, керәшен Мәкчимнең марҗа хатыны да, Заһидулла үзе дә бик ярата бу сүзләрне (бу гыйбарә, бәлки, автор теленнән персонажларга шулай актив күчә торгандыр?) Әсәрдә әүлия буларак сурәтләнеш алган Малмыж мулласы исә Гайсә пәйгамбәрнең дөньяга килүен мәдрәсә белемле(!) Заһидуллага христиан побы төслерәк аңлата. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр автор укучыга зинаны изгелек сыман тәкъдим итү белән мәшгуль. "Әйе, Тамара белән очрашкан ***изге*** нокта..."—дип уйлап куя Заһидулла кайчандыр үзләре зина кылган урынга килгәч. Романның башыннан ахырына кадәр зинаның изгелеге рефрен булып кабатлана. Бу романга да Исхакый бүләген бирмәсәң... Мутант карашларның мондый коктейлен тагын кайда очрата аласың?!

Сюжетны тормышта булган, үзе ишеткән вакыйгалар белән шыплап тутырганнан соң да (шулай эшләгәч, янәсе, роман тормышчан була) авторда роман вакыйгаларының реальлеге турында шик кала, әсәр ахырындагы соңгы "Автор сүзендә": Монда язылганнарга укучы ышанырмы? Тормышта мондый хәлләр буламы?" дигән сорау язучы тарафыннан бик тә урынлы куела. Әлеге әдипнең иң соңгы романы "Инабәт" тә, фәлсәфи роман буларак тәкъдим ителүгә карамастан, үзенең синтетик характеры, "агач теле" белән күңелдә авыр тәэсир калдыра, авторның персонажлар телен индивидуальләштерергә тырышып артык көчәнүе дә ярдәм итми, колоритлы натуралар урынына сабын куыгы кебек буш образлар калкып чыга. Дөрес, роман кадәр романны тоташ бушлыктан тора дип әйтү хата булыр иде. Әдипнең кайбер табышлары да күзгә чалынып киткәли, урыны-урыны белән мавыктыргыч эпизодлар да очраштыргалый, әмма романны әлеге дә баягы "симбиоз" фәлсәфә "үтерә", татарча романда без күрергә өметләнгән милли төсмерләр юыла. Җанны иркәли, рухны канатландыра торган әдәби сурәт урынын купшы бизәкләр ала. Романның

мондый ясалма көязлеге бәлки кемнәргәдер ошыйдадыр, әмма мин үзем, мәсәлән, аны кабул итә алмыйм.

Безнең татар халкы үзгәртеп корудан соңгы чорны идеологик яктан чамасыз таркау хәлдә каршы алды. Традицион ислам янәшәсендә нинди генә дини агымнар пропагандаланмый бүгенге татар матбугатында: ул буддачылыкка тартым булган тәнречелек тә (янәсе матди яктан японнар яхшы яшиләр), христианлык һәм аның һәртөрле зыянлы секталары да, чиста рәвешле будда дине дә, хәтта исламның башка беркайда да очратырга мөмкин булмаган, яһүдилек белән укмаштырылган мәзһәбләре дә. Халыкка яңа идеология тәкъдим итүчеләр, нигездә, бер принципка таяналар: кайсы халык матди яктан яхшырак яши, шул халыкның дине дә яхшырак. Евроислам идеясе дә нәкъ менә шул принциптан үсеп чыга: диннән без үзебезгә дөньяви тормышыбыз өчен файдалы нәрсәләрне генә алабыз. Моның яһүдилектән башка нәрсә түгел икәнлеге әйтелгән иде инде. Шунысы кызык: милләткә мондый синтетик идеяләр тәкъдим итүчеләр үзләре күпчелек очракларда бер динне дә тотмыйлар һәм асылда бер генә динне дә ныклап өйрәнмәделәр. Нигә ашказанына төшерү өчен теш арасында чәйнәлә торган нәрсәләр белән гыйбадәтне бутарга? Гыйбадәткә ихтыяҗ ул җанның, рухның таләбе, ә милләтнең матди хәле исә аның сәяси бәйсезлегенең ни дәрәҗәдә булуы һәм промышленностьтагы технологияләрнең яңалыгы белән генә бәйләнгән. Ахыр чиктә һәр төрле байлыкның да хуҗасы Аллаһы Тәгалә икәнен дә онытмасак иде. Боларның әдәбиятка катнашы ни дәрәҗәдә соң? Соңгы еллар татар әдәбиятында әлеге идеяләр ачыктан-ачык яктыртылмасалар, бәлки, болар турында бу урында сөйләп торырга да ихтыяҗ булмас иде.

Яңа дингә омтылыш кайчан туа? Гадәттә милләтнең тиешле дини тәрбия алмаган, шул сәбәпле рухи иммунитет җитәрлек югарылыкта булмаган, һәртөрле азгынлыкларга баткан вәкилләре яңа пәйгамбәр һәм яңа табыну объекты эзләү белән мавыгалар. Мондыйларга шәригать үзенең катгыйлыгы һәм бәндә кальбенә зур җаваплылык йөкләве белән артык кырыс тоела. Безнең әдәбиятта әлеге тип кешеләрнең психологиясен унышлы яктырткан, үзенең төзелеше һәм чынбарлыкны сәнгатьчә сурәтләү чараларының оригинальлеге белән игътибарны җәлеп итә торган бик тә үзенчәлекле әсәр иҗат ителде һәм дөньяга чыгу белән үзенә тиң күләмдә резонанс та биреп өлгерде. Ул—Марат Кәбировның “Сары йортлар сере” повесте. Марат әфәнде әле чагыштырмача яшь язучылардан, әмма аңарда әдип өчен бик тә әһәмиятле булган табигый психоаналитик талант яхшы ук сиземләнә. Гыйлемен тагын да баетып, яшәешнең асыл фәлсәфәсенә тиешле дәрәҗәдә төшенгән очракта аның үткен каләме, иншалла, куәте һәм егәре белән зур мәйданнар яуларлык әсәрләр дә бирер әле.

Повестьның фабуласы бик гади. Яшәү өчен яраксыз, завод тирәсендәге агулы зонада шәһәрчә унайлыклары булган фатирларда үзләренең дөньяга ни өчен килгәнлекләре хакында уйланып тормыйча гына кешеләр яшәп ята. “Сары йорт” кешеләренең типик гомуми образы автор тарафыннан бөтен нечкәлекләрен белеп, уйлап тудырылган. Бу—homo sovetikusлар тибы. Болар белән очрашу өчен телевизор төймәсенә басып “Яңалыклар” программасын берничә тапкыр карау да җитә. Менә шул кешеләр тормыштагы бәхетсезлекләренең хакыйкый сәбәбе турында уйланмыйча гына физик һәм рухи яктан гарипләнеп, үзләренең мескен тормышларыннан бик тә канәгать булып тыныч кына һәлакәтләренә табан баралар. Боларны сурәтләгәндә Марат Кәбировның сатирасы гротеск дәрәҗәсенә җитә, чынлыкта бу Гоголь һәм Чеховларны көнләштерерлек сатира. Һәлакәтне ваемсыз кабул итү — рухи имгәтелгән, үчле һәм мәкерле, кара эчле бүгенге җәмгыять әгъзаларының төп сыйфаты. Әдипнең аяусыз реализмы боларны төрлечә фаш итә, sovetikusлар тибының эчке дөньясындагы караңгылыкны, наданлыкны сурәтләү дәрәҗәсе үзенең үткен төгәллеге белән таң калдыра. Әдипнең сатирасы кайвакыт үтергеч фантастик масштабларга җитә, әмма әдәби сурәт чынлыгын югалтмый. “Сары йорт” кешеләре гарип туган балаларын үтереп үзләре шикелле үк гарип агачлар төбенә күмгәннәр дә, һәрбер җан иясенә хас булган нәсел дәвам итүгә булган инстинктив омтылышларын да югалтып, “күбесе шыр ялган һәм дөньяда булмастай шап-шарә хыяллардан гына торган” вакыйгаларны бер-берсенә сөйләп, шулар белән көнелләрен күтәреп акрын гына үлеп баралар.

Боларның тормышы, рухи халәтләре җаһилият заманындагы гарәпләрнекенә

карaганда да түбәнрәк. Аларны һәртөрле мистика белән алдау, ырымнарга һәм тузга язмаган нәрсәләргә ышандыру өчен артык көч түгәргә дә кирәкми. Коммунистик пропаганданың "гармоник үсешкә ирешкән социалистик җәмгыять кешеләре" менә шулар инде. Шушындый җәмгыять әгъзалары янына көннәрдән бер көнне гыйлемлеге һәм табигый яшәү рәвеше өчен система тарафыннан төрлечә эзәрлекләнгән сукбайга әйләнгән Мәдинә карчык килеп чыга һәм "яннарына килеп бераз тыңлап тору белән бу кешеләрнең төзәлмәслек авырулар икәнен сизә". Карчыкның боларга ярдәм итәргә, дәваларга тырышуы кискен каршылыкка очрый, "сары йорт" әһелләре карчыкны үзләренә ни өчендер җәза бирүче сихерче буларак кабул итәләр, чөнки үзләренең үткәннәрендә җәзага лаек бик күп вәхшилекләр табалар алар. Марат Кәбиров таланты мондый тип кешеләрнең психологик сурәтен искитмәле оста тотып алган. "Кешеләр Мәдинә карчыктан куркалар иде, ул аларга изгелек иткән саен сары йорттагыларның куркуы көчәйде, куркулары арткан саен алар әйбәтрәк була барды. Тик бу әйбәтлек тыштан гына иде, икейөзлелек кенә иде, ә күңелләре белән алар тамчы да үзгәрмәде, күңеленнән алар үзләре кылган яхшылыкка каршы, үзләренең әйбәт якка үзгәрүеннән үзләре үк курка иде".

Бу сурәт, әчке дөньяның мондый тасвиры укучыны әлеге җәмгыять әгъзаларында чынбарлыкны кире ягы белән кабул итү феноменының асыл сәбәпләренә төшендерә. Җаһиллек, мәгърифәтсезлек, бары тик коммунистик томаналык кына шундый бәндәләр әвәли ала. Болар үзләренең диннәрен һәм милләтләрен онытканнар, наданлыклары кеше төсле итеп кабергә мәет индерү йоласын да белмәслек дәрәҗәдә. Менә шушындый кешеләрдә хорафатларга ышану, табыну өчен яна объектлар эзләү, яна пәйгамбәр көтү ихтыяҗы туа да инде. Повестьта язучы моны бик уңышлы табылган, бик тә үзенчәлекле деталь белән дәлилли. Мәрткә киткән Мәдинә карчыкны сары йорт кешеләре, үлгән дип белеп, кабер янына алып киләләр, соңгы мизгелдә генә карчык уяна һәм аякларына торып баса. Кәфенләнгән мәетнең торып басуы җан тетрәрлек күренеш, билгеле. Менә шушы мизгелдә чынбарлыкны ике төрле кабул итү феномены күзәтелә. Бу күренештән таң калган сары йорттагылар карчыкны фәрештәләр килеп кулларыннан тартып торгызганын күзәтәләр, карчык үзе дә аларның хакыйкатьтән авышкан фантазияләренә бер мизгелгә генә булса да гүзәл кыз сурәтендә күренеп ала. Повестьта вакыйгаларның сурәтләнеше күпчелек очракта менә шундый гариләнгән фантастик пафос аша, сары йорт әһелләренең теле белән башкарыла. Кызыклы алым бу! Тилеләр пафосына һәм аларның гарип мантыйгына гына күз салыгыз:

"О ул мизгелләр... Ап-ак кәфенгә төрелгән карчык әкрен генә торып басты да һәммәбезне дә берәм-берәм күздән кичереп чыкты, аның карашында оҗмах нуры да, тәмуг уты да бергә уйный иде. Җаннарыбызны дулатып барыбызның да күңеленә курку салгач, ул болай диде: "О, кешеләр! Сез тиздән яна чорга аяк басачаксыз. Шушы мизгелдә сезне афәтләрдән коткарачак пәйгамбәр туды. Коткаручыгызның кадерен белегез, күңел тәрәзәләрегезне сөртеп багыгыз аңа, эт хөкемендә яшәтмәгез..." Без аның сүзләренә ышанмадык. Без, гомумән, Аллага да, дингә дә ышанмый идек..."

Әмма автор сурәтне шушы юнәлештә генә алып барса, әсәр мистик повесть булудан ерак уза алмас иде һәм аның кыйммәте дә бүтән берәмлекләр белән үлчәнер иде. Мистик пафос янәшәсендә язучы чынбарлыкны реаль сурәтләү алымын да куллана. Вакыйгаларны Мәдинә карчык күзлегеннән карап сурәтләгәндә стиль шул рәвешле үзгәрә. Әлеге эпизодны әдип сары йорт әһелләре пафосы янәшәсенә дөньяга реаль караучы, җеназа укыган мөселман картының монологын кертү аша да бирә.

"Әлхәмделиилаһи шөкер, Аллаһы Тәгаләмез үз мөэминебезне җиргә терелэй бирүдән саклады. Азан намазын укып бетерүемә (биредә язучының исламны белеп җиткермәве күзгә ташлана, җеназа намазына азан әйтелми һәм азан намазы дигән намаз гомумән юк) мәрткә киткән кешенең йокысын ачты...

Юк, мин фәрештәләрне дә, сихри нурларны да күрмәдем... Карчык әкрен генә торып утырды, аягына басты, тирә-ягына, кешеләргә гаҗәпләнеп озак карап торды. Авызларын ачып-ябып, ачып-ябып алды... Сүзен ишетмәдем, берни дә әйтмәде бугай. Бәй, башкаларга ишетелсә... Күңелләре белән нәрсәдер көткәнгә, өмет иткәнгә шулай тоелгандыр, һәркем үзе теләгәнне ишеткәндер..."

Марат Кәбировның стильләр контрасты аша ясаган аналитик нәтиҗәсе кызыклы һәм гыйбрәтле. Бүгенге җәмгыятьнең милләткә яна диннәр, яна пәйгамбәрләр,

аның өчен ят булган кыйммәтләр эзләү һәм тәкъдим итү белән мәш килгән катламының реальлектән никадәр ерак торуын, "сары йортлык синдромы" белән чирләвен дәлилли ул. Көнбатышка һәм японнарга күз текәүчеләр, чит цивилизация кыйммәтләрен безнең җәмгыятькә индерергә тырышучылар—рухи иммунитеты югалган милләтне аздыручылар, адаштыручылар алар. Соңгы вакытларда гына татар матбугаты шундый берничә "пәйгамбәр" турында мәкаләләр бастырды. Күрәзәчелек, сихер белән мавыгуның соңгы егерме елга якын вакыт эчендә патологик чир дәрәҗәсенә җитүе хакында әйтеп тору да артык шикелле. Әйе, болар барысы да Көнбатышта бар, сектантлык, һәртөрле азгынлыкка тулы ирек бирү хөрлек дип шунда тамгалана һәм, кызганычка каршы, бу инде—безнең дә бүгенге чынбарлык. "Сары йортлар сере"ндәге мөселман картының нәтиҗәсен тагын бер тапкыр укыйк: "Күнелләре белән нәрсәдер көткәнгә, өмет иткәнгә шулай тоелгандыр, һәркем үзе теләгәнне ишеткәндер".

Көнбатыш, әлбәттә, үзенең нечкә психоагрессиясен янадан-яна кинлекләргә тарату өлкәсендә стратегик максатлар куеп актив һәм, әйтергә кирәк, нәтиҗәле эшли. Әле советларның ярыйсы ук нык чагында, 1978 елда, Америка Кушма Штатларындагы Лозан шәһәрендә христианлаштыру буенча конференция үткәрелә һәм анда христиан булмаган халыкларны христианлаштыруның 2025 елга кадәр исәпләнгән дөньякүләм программасы кабул ителә. Шушы вакыт аралыгы эчендә 10000 телевизион тапшыруны, 250 төрдәге максатчан басманы финанслау өчен 870 миллиард доллар күләмендә акча тоту планлаштырыла һәм бу бурычларны тормышка ашыру махсус фәнни-тикшеренү институтына йөкләтелә, ел саен башкарылган эшләрнең статистик хисабы алып барыла. Озакка сузылган бәхәсләрдән соң христиан аналитиклары мөселманнарның иманын һәм карашларын үзгәртүдә экспансионистик тактика сайларга дигән нәтиҗәгә киләләр. Бу эшчәнлекнең аяныч нәтиҗәләрен без бүгенге татар дөньясында күзәтәбез. Рус хөкүмәтләренең болай да гасырлар буе татарга каршы алып барган сәясәтенә Көнбатыш аналитикларының тырыш хезмәте килеп кушылганнан соң милләтнең үз асылын үзгәртүе торган саен ныграк сизелә.

2002 елда "Казан утлары" журналы (№7) оештырган "Хәлең ничек, татар китабы?" дигән түгәрәк өстәл янындагы әңгәмәдән Илсөяр Хәйруллина китергән фактларны гына карап үтик. "...күренекле затларыбызның кайсын гына алып карасак та, аларның нәсел дәвамчылары, ни кызганыч, йә урыслашып, йә яһүдләшеп беткән, күбесе башка милләткә хезмәт итә. Газиз Гобәйдуллиннар, Бубыйлар, Фатих Кәримиләрнең дә нәселләре милли чисталыгын югалткан инде",—ди "Рухият" фонды җитәкчесе. Бабалары зыялы мөселман рухание булган бик күп татар балалары бүген дә Казан урамнарында муеннарына тәре тагып йөри, телләре—рус, кайберләре татарныкы да, русныкы да булмаган синтетик әдәбият тудыру өлкәсендә ярыйсы ук актив эшли. Аяныч тыр, боларның да укучылары юк һәм, әлбәттә инде, була да алмый. Милләтнең бу дәрәҗәдә үзгәрүе үзен татар язучысы дип йөрткән бәндәне тетрәндереп уйландырырга, тән йокыларын, качырырга тиештер. Нинди ул "симбиоз фәлсәфә" турында сафсата сатулар! Милли консерватизм, идеология һәм яшәү рәвешендә башкаларны кабатламауны күптән инде байрак итеп күтәрергә вакыт!

"Нидән гыйбарәт соң ул Көнбатышның без кызыккан яшәү рәвеше?" дигән сорауны татар зыялысы үз алдына күптән куярга һәм аңа җавап та табарга тиеш иде. Атаклы мөселман дәгъвачысы Әхмәт Дидат үзенең Пакистанда сиксәненче еллар уртасында укыган лекциясендә, Америка статистикасына таянып, АКШ җәмгыяте хакында менә мондыйрак мәгълүматлар китерә: илле миллионнан артык алкоголик, ирләрнең 13 проценты үз кызлары белән җенси якынлык кыла, боларга өстәп гомосексуалистлар һәм лесбиянкаларның мыжлап торуы, наркоманиянең чәчәк атуы! Көнбатышча яшәү рәвешенә хөрлек бирү һәм аны әдәбият-сәнгатьнең барлык чаралары белән дә пропагандалау нәтиҗәсендә безнең җәмгыять аларны бу өлкәләрдә куып җитеп узып китеп бара түгелме соң? XIX гасыр ахырларыннан башланган милләтнең үзгәрүе, милли рухның акрынлап җуела баруы өченче меңъеллыкның беренче елларында логик тәгәлләнү стадиясен кичермиме? Моның сәбәбе Көнбатышка чамасыз ияруда түгелме?

Гөлчәчәк Галиева, Тәлгат Галиуллин, Әсгать Салахларның соңгы вакытларда "Казан утларыры"нда басылган повесть-романнарын гына алып карыйк: зина үзенең бөтен формаларында гадәти яшәү рәвешенә әйләнгән, башка төрле бозыклыклар да

табигыйләшкән, авторлар боларны талантлы каләм белән тәфсилләп һәм нечкәләп тасвирлыйлар. Бер яктан караганда, әдәбият, әлбәттә, тормышның көзгесе буларак, яшәешне чагылдырмыйча кала алмый кебек. Бәс, шулай булгач каләм әһелен теге яки бу темага алынуда гаепләү урынсыз булып чыга төсле. Тормыш үзенең бөтен катламнарында да әдәби әсәр объекты була ала ич. Бу җәһәттән караганда, тема сайлауда әдипкә нинди дә күрсәтмә бирү ярамый торган һәм перспективасыз эш. Чынбарлыкны сәнгатьчә чагылдыру алымнарын һәм ысулларын сайлауда да худож-никны ирекле дип саныйк. Модернистик алымнарга мөкиббәнме ул, үзен постмодер-нистик агымнар вәкиле итеп хис итәме, әллә инде традицияләргә, классик алымнарга ябышып ятамы—белем һәм талант потенциалы мөмкинлек биргәнне сайласын. Мөһиме—әдипнең сурәтләү объектына карата тоткан позициясе. Язучының сәнгатьчә бәясе нинди югарылыктан торып, кайсы каланчага басып бирелә—менә шунысы әһәмиятле. Әгәр дә әдипләр тормыш тасвирын тудырганда нәфеснең иң түбән, иң актык теләкләрен кузгатуны һәм үстерүне максат итеп куйганнар икән, мондый әдәбиятның поты бер тиен! Миңа калса, соңгы чор татар әдәбияты вәкилләре итәк астында казынуда һәм азгынлык тантанасы аша укучы күңелен яуларга омтылуда күп кенә очракларда Көнбатышның детектив әдәбиятын да уздыра башладылар төсле. Европа әдәбиятына ярарган кием милли татар әдәбияты өчен элмәккә әйләнү ихтималы зур икәнлеге күп очракта онытылды. Безнең әдәбият үзенең мең елга сузылган тарихында тәкъвалык киемен үзенә өлге итеп алган иде, милләтне һәм аның мәдәниятен бөтен яшәү тарихында, бигрәк тә куәтле колониаль изү шартларында шул саклады. Колониаль шартларда татар зыялысы кульязма әдәбиятны урманнарга качып күчереп булса да укучыга җиткерде, укучы да бурычлы булмады: әдәбиятка ихтыяҗ халыкның барлык катламнарында да житәрлек зур булып кала бирде.

Тәкъвалыктан баш тартып, демократияне бөтен җирне ачып күрсәтү иреге дип сабыйларча аңлатучылар үзләре утырган ботакны кисүче мокытларга охшадылар. Әдәби пространствоны нәфис теләкләренең бәйрәм итү мәйданы дип аңлатучылар Бальзакның "шигрин күне" эффекты белән очрашуга дучар ителделәр: азгынлык тантанасы көчәйгән саен, мәйдан кысыла барды, тиражлар саекты, әдәбият дотация энәсенә утыртылырга мәҗбүр ителде, мохтаҗлыктан, игътибар житмәүдән интеккән каләм әһелләре ярдәм сораган кулларын хакимияткә таба суздылар. Мәдәниятне күтәрү, аның алгарышы турында сүз барганда инвестицияләр түгел, ә дотация, дәүләт ярдәме хакында гына сөйләнелә, сәнгать әһелләре үзләренә теплица шартлары тудырылуны тели башладылар. Бу инде үлемнең котылгысыз якынаюы диган сүз иде. Спонсорлар һәм татар меценатларына өмет өзгәннән соң, дәүләт агайның киң җилкәсенә ышаныч баглап ялгышмыйсыңмы син, татар зыялысы?! Дотация ул—фәкыйрьләр азыгы, һич кенә дә алгарышка, үсешкә нигез була алмый. Хисне сүлпә-нәйтүче, уйны саектыручы, фикерне томалаучы чара ул.

Үз карашымны мин болай дип дәлиллим. Иң беренчесе, дотацияләнгән сәнгатькә "коллык, тарлык, ким-хурлык" белән килешергә туры киләчәк. Хакимияттә берникадәр дәрәҗәдә демократик рух хөкем сөргәндә дә бу шулай булачак. "Кем түли, шул музыкага заказ бирә" принцибы хакимиятнең дә, иҗатчының да канына сеңәчәк (коммунистик чор мирасы булган бу күренеш белән без бүген дә әйбәт үк таныш). Икенчесе: әдәбият-сәнгать әһелләренә "тагарак психологиясе" сеңәчәк. Бу—көнчелек, үзара тарткалашлар, ызгыш-талаш өчен сарыф ителәчәк гаҗәп зур энергия диган сүз. Иҗат энергиясе менә кая тотылачак! Монысы да бүген күзәтелә дип әйтергә тулы нигез бар. Көнлекче язучының олуг әсәрләр тудыра алачагына шикләнәм мин. "Тагарак психологиясе" бер иш талантлы иҗатчыларда "тамак туклыгы" феноменын тудырачак. Бу феномен вәкилләре—тагаракның эчендә коенучылар. Мондый шәхесләр өчен һәртөрле проблемалар үзенең үткенлеген югалта, "тагарак"ка урнашканчы күтәргән олы мәсьәләләрне алар ихтыярсыздан оныталар, үз теләкләре белән күп нәрсәләргә тыю-табу салалар.

Хакимиятнең сәнгать өчен әзерләнгән "тагаракка" җимне бик аз салуын исәпкә алсак, аннан читкә күп чәчелмәячәген чамаларга була. Шуннан соң да әдәбият-сәнгать үсеше өчен дотациянең нинди дә булса әһәмияте бар дип уйлау тирән хата түгелме? Азык һәркемгә гадел, тигез бүленгән очракта да нәтиҗәсе аз булачак. Дөрес, өч-дүрт меңлек тираж белән әдәби журналлар, мең ярымлык тираж белән китаплар басылуын дәвам итәчәк. Ләкин бу яшәүдән бигрәк акрын гына үлеп баруны

хәтерләтә. Милләтнең 0,001 проценттан да азрагы файдаланган әдәбиятны, әйтик, кайсы халыкка хезмәт күрсәтә дип санарга соң? Бу санны хәтта элитар укучы дип тә атап булмый, чөнки әдәби әсәрләре күпчелек очракта элитар түгел. Көпшәк, сюжетсыз, телсез, әхлаксыз әсәрләрнең зәгыйфь конвейерын эшләтүнең кемгә хаҗәте бар?! Заманында русның танылган язучысы булган Андрей Белый җан асрау өчен хәтта талантлы автор тарафыннан язылган әсәрләрне дә "рөхсәт ителгән дәрәҗәдәге халтура" дип атый. Күп кенә очракларда бүгенге әдәбиятның иң уңышлы дип табылган үрнәкләре дә менә шундый халтура таләпләренә генә җавап бирә шикелле. Ул гына да түгел: "стакандагы давыл" күләмендә резонанс алган кайбер романнардагы фәлсәфи наданлык, ясалма купшылык, тел-стиль хаталары искитәрлек дәрәҗәдә. Еш кына аларга язылган бәяләмәләр дә шуннан югары түгел. Болар барысы да дотацияле әдәбиятка йөз тотудан килеп чыккан нәтиҗәләр.

Тик шулай да төп сәбәпне әдиптән түгел, нәшриятлардан эзлисе килә. Дотациягә йөз тоткан нәшриятлар ахыргы максатлары нидә икәнлеген оныттылар шикелле. Авторларны алар иҗат җимешләре өчен түгел, акчалары булганда гына яратырга өйрәнделәр. "Тагарак"тагы әдип белән спонсорлы әдип кенә китап чыгаруга өмет итә алу хәленә китерелде. "Бизнес сүзе белән китап сүзенең янәшәлеге мөмкин түгел" дигән фикер актив рәвештә үстерелде. Чөнки ул фикердән башка дәүләт ярдәменә исәп тоту мөмкин түгел иде. Эчтәлек, сюжет, сәнгатьчә эшләнеш дигән төшенчәләр онытылды, яңа заман нәшриятларында боларга ихтыяҗ аз. Миңа калса, бүген татарда яңача эшли торган, чын маркетинг һәм менеджментның нәрсә икәнлеген аңлаган, яхшы рецензент һәм әдәби агентлар институтына мохтаҗ булган, китап сәүдәсенең яңа технологияләренә нигезләнгән хосусый нәшриятка ихтыяҗ зур. Алдан ук сизеп торам: бу бинаһая зур хезмәт һәм осталык сорый торган эштән "укучы юк" дигән сылтау белән баш тартырга омтылалар. Яр кырыена килеп: "Йөзеп булмаячак, йөзеп булмаячак",—дип кычкырып торудан мәгънә аз, суга кереп карау кирәктер. Татар әдәби китабының поценциал тиражы бүгенге көндә кимендә 25-30 мең, шул биеклеккә ирешү һәм аны тагын да үстерү нәшриятлар һәм сәүдәгәрләр эше. Хәләл акчага омтылган нәшрият алдында торган киртәләрне дә яхшы чамалыйм. Гасыр аша яңгыраган Тукай авазы да шуны искәртә кебек: "Сиңа, дустым, сүзем шулдыр: татарга сатма матбугат. Трактир ач татарга, сат та тор һәртөрле мәшрубат[1]".

Татар язучыларының кайберләре Тукайның ирония белән әрнеп әйткән сүзен чынга алып, әдәби табынга "мәшрубат" кую белән мәшгульләр. Ә татар әдибе "бәхетенең" шигрин күне "кысылганнан-кысыла бара, ягъни укучы кими. Биредә сәбәп"не соңгы еллардагы матди бөлгенлектән генә эзләү аз булыр шикелле. Рухи тамырларның коруы үзен күбрәк сиздерми микән? Ә ул тамырларга балта чабуда соңгы йөз еллыкта ярымансыз рәвештә, кайвакыт ихтыяри-мәҗбүри хәлдә, татар әдипләре үзләре дә аз тырышмадылар. Коммунистик чорда бу дингә каршы аяусыз көрәш рәвешендә алып барылды, советтан соңгы чорда Көнбатыш культын сендерү стилендә башкарылды. Көнбатышның төптән уйланылган пропагандасы йогынтысында һәм үзебезнең әдәбият-сәнгать ярдәме белән милли рухын югалткан укучы океан артындагыга охшатылган суррогат татар әдәбиятын укып мәшәкатьләнмәде, көнбатышча яшәү рәвешен ул шул даирә әдәбияты һәм сәнгате ярдәмендә дә бик җинел үзләштерде: телен онытты, традицияләренә төкерде.

Дөрес, соңгы елларда татарның мең еллар буена дәвам итеп килгән традицияләрендә тәрбияләнгән яшьләр катламы да барлыкка килә һәм ишәя башлады: яшь туташлар һәм егетләрнең байтагы йөзләрен исламга таба бордылар. Ләкин болар да "симбиоз" фәлсәфәгә корылган әдәби әсәрләргә мохтаҗлык кичермиләр, кабелләрендә иман тарафыннан тудырылган иммунитет аларны мондый әдәбияттан тыя. Ә менә мөселман рухани әдәбияты белән кызыксыну соңгы дистә елда һаман да кимеми: дини һәм мөселман календарьларының берничә төре дистә һәм йөз меңләгән тиражлар белән халыкара тарала, аларның гомуми тиражы берничә йөз меңгә җитә. Милләтнең чын рухи ихтыяҗларының кай тирәдәрәк икәнен чамалау өчен кызыклы саннар бу. Татар язучысына, ихтимал, утырып уйланырга, йөзен ялган кыйбладан чын кыйблага борырга вакыт җиткәндер. Чын татар романының

[1]Мәшрубат—эчемлек

герое булырдай типларны, мөгаен, милләтнең менә шушы татарлыгын югалтмаган һәм сакларга омтылган катламы арасыннан эзләргә кирәктер. Моның өчен, әлбәттә, шушы катламның тормышына үтеп керү, гыйбрәтле язмышларны шулар арасыннан эзләү кирәктер. Шәхеснең адашудан туры юлга чыгу процессы катлаулы һәм авыр, әдәбият менә шушы өлкәдә, шушы процесста актив катнашучы инструмент булырга тиештер. Нәфеснең нечкә теләкләрен канәгатьләндерү юлына гына басмыйча, түбәнлеккә карата иммунитет, азгынлыкка карата нәфрәт тәрбияләү вазифасын тиешенчә үтәгәндә генә укучының киң катламының игътибарын җәлеп итү мөмкиндер. Милләтнең һәртөрле үсешенә ирешүне стратегик максат итеп куйганда гына әдәбият укучылы була һәм үзенең киләчәген тәэмин итә ала.

Яңа чор (1985—2003 еллар) әдәбияты заманның Бальзак каләменә тиң каләм белән сурәтләнергә лаек булган вакыйгалары алдында калды. Кеше холкы бу чорда үзенең бөтен яклары белән ачылды: түбәнлек, үзең өчен генә яшәү, үз мәнфәгатьләреңне генә кайгырту җәмгыятьтә өстенлек ала башлады, профессиональ үтерүчеләр, дәүләткүләм җинаятьләр чоры бу. "Каләмнәр иркенләнгән" чорда иҗатчы өчен яңа чор кешесенең чирләрен фаш итү мөмкинлекләре дә артты. Әдиптән бары тик осталык һәм фидакарьлек кенә таләп ителә башлады. Шөкер, язучылар арасында үзенең кайсы халык чишмәсеннән су эчкәнлекләрен онытмыйча игелекле каләм белән милләткә хезмәт итүчеләр дә бар. Мин иң беренче чиратта Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим, Фәнис Яруллиннарның исемен атар идем. Исемлекнең тулы булмавы өчен язучылар үпкәләмәсеннәр, максатым исемнәр санауда түгел. Нәбирә Гыйматдинованың соңгы вакытларда уңышлы эволюция кичерүче иҗатын да атап китмичә мөмкин түгел. Айдар Хәлимнең "Өч аяклы ат", Нәбирә ханымның "Икебезгә дә авыр", Фәнис Яруллинның "Яралы язмышлар" повестьларын мин соңгы унъеллыкның иң уңышлы әсәрләре исемлегенә кертер идем. Милләт фаҗигасен ачуда иҗатчы алдында темалар диапазонының никадәр киң икәнлеген уңышлы дәлилли бу әсәрләр. "Яралы язмышлар" повестенда ятимнәр проблемасы гына түгел, безнең бүгенге җәмгыятьнең матди һәм рухи хаерчелегенең кешелексезлек, ерткычлык кебек сыйфатларны ничек үстерүе, фикер мутантлашуының нинди фаҗигаларга китерүе ачык чагыла. Фәнис Яруллин бу әсәрдә метафоралар артына качмыйча, шулай әйтергә яраса, "турыдан-туры эфирда" чаң суга. Әлеге язучының яңа чор кешеләрен сурәтләүгә багышланган хикәяләре һәм башка әсәрләре дә позитив юнәлешле, унай тәэсирле булулары белән аерылып тора. Әдәбият галиме Рифат Сверигин бу әдипне "Лев Толстойларга тиң олы зат" дип бәяләве белән хаклы.

Нәбирә Гыйматдинова әсәрләрендә дә хәзерге чынбарлык үзенең аяусыз яклары белән төрле юнәлешләрдә ачыла. Бүген ул—татар прозасында иң актив иҗат итүчеләрдән. Бигрәк тә соңгы елларда исламны гыйлем буларак өйрәнү һәм яшәү рәвеше буларак кабул итү процессында бу әдибәнең иҗаты тулы канлырак, чор героен тудырганда объективрак була бара.

"Хәзерге геройларны сурәтләүдә, ачуда безнең иҗатчыларганиләр җитми дип уйлыйсыз?"—дигән сорауга, иң беренче чиратта, тормыш турындагы асыл белемне Коръәннән үзләштерү җитми дип җавап бирер идем. Чын ислам позицияләрендә торып иҗат итүче әдипләребез, кызганычка каршы, күп түгел. Безнең милләт, Россиядәге кайбер башка милләтләрдән аермалы буларак, яңа меңъеллыкны зәгыйфьләнсә дә үз потенциалын югалтып бетермичә каршы алды. Рухына ят булган идеяләр белән таркатудан саклыйсы иде, куәтен һәм егәрен арттырасы иде аның. Моңа исә ислам кушканча яшәүче һәм мөселманча фикерләүчеләр санын ишәйтеп кенә ирешеп була. Үткән гасыр хаталарын кабатлаудан сакланасы иде, чөнки милләтнең иң нык талкынган, әдәбиятның укучысыннан колак кага язган чоры—егерменче гасыр. Егерменче гасыр сабакларын онытмаска иде!

Ғәп Фән

Адлер Тимергалин

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

АТНА — Борынгырак чыганакларда: "адинә". Борынгы Һиндстан һәм Иран халыкларында, шулай ук Борынгы Болгар дәүләтендә дә, атна биш көнлек булган *(атна сүзе үзе дә "бишенче көн" дигән сүз — Р.Әхмәтьянов)*. Көнчыгыш Азиядә тугыз көнлек атнаның гамәлдә йөргәнлеге билгеле. Атна — фарсыча *һәфтә*, җидекөнлек. Мондый атна якынча айның (бигрәк тә күктә яңа Ай туу периодының) чирек өлешенә туры килә.

Халык җомганы *атна көн* дип йөртә. Шуңа күрә җомга алдыннан булган көн (пәнҗешәмбе) халыкта *атна кич* яки *кич атна (кече атна)* дип тә атала (бу термин мөселман календаре урнашканнан соң туган, чөнки һиҗрәдә көннең кичәсе аның үзеннән алда килә). Дөрес, телдә "кече атна кич" дигән сүз тезмәсен очраткач, моңа икеләнеп тә каласың (мәсәлән, Фатих Әмирханның "Бер хәрабәдә" исемле хикәясендә "ике күзе ике төрле" булган бер карчык: "Һәр кече атна кич Әсманың өрәге ишек алдыбызга килә, бик хафалый: тәрәзәләрне шакылдата, кайсы вакытта шаркылдап көлеп йөри; кайсы вакытта ачулы була", — ди). В.М.Беркутов: "Казан татарлары пәнҗешәмбене "кече атна", "кече җомга" дип тә йөрткәннәр" дип яза. Башкорстанның Тепекәй сөйләшендә атна кичне *кысима* диләр икән. Ә "җомга" көн татарда "олы җомга" дип аталган. Халык телендә дүшәмбе — *башкөн*, сишәмбе — *бушкөн* (мишәрләрдә). Сишәмбе көне татарларда тукучылык, эрләү-бәйләү көне булып исәпләнгән. Чәршәмбене *канкөн* дип атау исә ерак гасырлардан ук килә (XIII — XIV гасыр болгар эпитафияләрендә очрый). Бу атама ул көннең корбан китерү көне булуына ишарәли. Бу көн, төрекләрдәге кебек, татарда да табиблык, багучылык, имчелек көне булган (хәер, татарда: "Им көне — шимбә көн" дигән борынгы сүз дә бар). Шимбә — *атна арты, атнарасы көн* яки *корыкөн*, якшәмбе — *башкич*. Кайбер сөйләшләрдә шимбә көнне *аракөн* яки *атнарас (көн)* дип атыйлар. Якшәмбене *базар көн* дип тә йөрткәннәр, ә кайбер сөйләшләрдә ул *урыс атнасы* һәм *урысйома (урыс җомгасы)* дип атала. Шунысы кызык, Чистай керәшеннәре җомга көнне *татар атнасы* дип атыйлар. Чыганакларда җомга мәгънәсендә *адинә* язылышы да очрый (атна). Керәшеннәрдә сишәмбене *утлари көн* дип тә йөртәләр (чуашларда *ытлари көн*). Пермь татарларында сишәмбе — *атланган көн*. Карачай — балкарларда бу көннең (изге) *Георгий көне* дип аталуын искә алсак, әлеге исем атка атлану мәгънәсендә булырга тиеш сыман. Электә кыпчакларның сишәмбене авыр көн дип санаганлыклары билгеле. Алар сишәмбе көнне Изге Гөрҗи (Георгий) үлгән дип ышанганнар һәм "Гөрҗи көне"ндә юлга чыкмаганнар, мөһим эшкә тотынмаганнар, хәтта елмаймаска киңәш иткәннәр *(Морад Аджи буенча)*.

Атна көннәрен нинди базар үткәрелүенә карап атау да күзәтелә. Мәсәлән, Татарстандагы Биектау районы Мәмдәл авылында дүшәмбене *Кала базары көне* дигәннәр, ә сишәмбе көн *Мәмдәл базары көне* булган.

Болгар эпитафияләрендә дүшәмбе — *әрнә баши*, ягъни атна башы. Моннан без атна көннәренең тәртибе гарәпчәдәге кебек булмаганлыгын да күрәбез, чөнки гарәптә: шимбә (шәнбә) — җомгадан соң беренче көн, ә якшәмбе — шимбәдән соң беренче көн, дүшәмбе — шимбәдән соң икенче көн, сишәмбе — шимбәдән соң өченче көн, чәршәмбе (чәһаршәнбә) — шимбәдән соң дүртенче көн мәгънәсендә, ахырда исә — җомга яки атна көн.

Дәвамы. Башы 1-2 саннарда.

VI–VIII гасырларда болгарлар атнаның өченче көнен атна уртасы дип санаганга охшый (русларда да ул – "среда", ягъни урталык, немецларда да шул ук хәл). Димәк, җиде көнлек атна көнкүрешкә соңрак кергән булырга тиеш: әйткәнебезчә, ай-кояш календарендагы атна башта биш көнлек кенә булган.

Хәзерге календарьда ел әйләнәсендә 52 атна була, ләкин кайбер табышмакларга караганда, халык ай эчендәге тулы атналарны гына исәпләгән һәм бер елда барысы 48 атна гына килеп чыккан.

1929 елда СССР да бишкөнлек атна кертелә (һәр биш көн саен бер ял көне була, җитештерү өзлексез булырга тиешле урыннарда төрле кешеләрнең ял көне төрле көннәргә туры китерелә). Ләкин ике елдан соң, 1931 елда, мондый "күчмә" графиктан баш тартырга туры килә һәм барлык хезмәт ияләре өчен бердәм ял көне карарлаштырыла, әмма ул җиде көнгә бер тапкыр түгел, бәлки алты көнгә бер тапкыр итеп билгеләнә. Чыганакларга караганда, мондый күчмә графиклы эш атнасы гаилә тормышының нигезләрен какшаткан, ил күләмендә әхлаксызлыкка, җенси тотнаксызлыкка китергән. Алты көнлек атна безнең илдә 1940 елның уртасына кадәр кулланылды, аннары сугышка хәзерлекне ныгыту зарурлыгы белән бәйле рәвештә җидекөнлек атна кабат торгызылды. 1967 елда ул ике ял көне булган җидекөнлек атна белән алмаштырылды.

Атна көннәрен җиде планетага тиңләп атау Көнбатыш Европа телләренә хас, ләкин планеталар исәбен якшәмбедән башлап санау, мәсәлән, атаклы дингез сәяхәтчесе *Әхмәд ибн Мәҗидтә* дә очрый: 1) Кояш – *якшәмбе* символы (Кояш алласы – Гиперион белән Теяның улы, Ай һәм Авроранның туганы, соңгырак чорда – Аполлон); 2) Ай – *дүшәмбе* символы (Ай алиһәсе, Латонаның кызы, соңыннан – Диана); 3) Марс – *сишәмбе* символы (басу-кырлар һәм мал-туар көтүләре алласы, соңыннан – сугыш алласы, римлыларның нәсел башы, Юпитер белән Юнонаның улы); 4) Меркурий – *чәршәмбе* символы (гимнастика, сәүдә һәм тәмле теллелек химаячесе, Юпитер белән Майяның улы); 5) Юпитер – *пәнҗешәмбе* символы (күк һәм аллалар белән кешеләр патшасы, Сатурн белән Геяның улы, римлыларның баш алласы); 6) Венера – *җомга* символы (матурлык, мәхәббәт һәм никях алиһәсе, Юпитер белән Диананың кызы); 7) Сатурн – *шимбә* символы (борынгы итальяннарда игенчелек алласы, вакыт-заман алласы, Юпитерның атасы).

АХУН(Д) – Чыганакларда фарсы сүзе дип күрсәтелә. "Остаз", "укытучы" мәгънәсендә. *Мулла* һәм *мөхтәсибләрдән* югарырак дәрәҗәле рухани. Аерым төбәкләрдә өлкән рухани. Мәс., татар әдибе Фатих Кәриминең әтисе *Гыйльман ахун* Бөгелмә өязендә утыз алты авылның ахуны булган. // *Ахунлык вазифасы.*

Ахун термины Рәсәй хөкүмәт фәрманнарында 1788 елда Екатерина II тарафыннан Оренбург Мөхәммәд дине Мәҗлесе оештырылганга кадәр шактый вакыт элек тә телгә алына.

Бу терминның бөтен Ислам дөньясында таралган булуына карамастан, аның чыганагын бер генә телдә дә табып булмый. Алим Гафуров *ахун(д)* сүзенең килеп чыгышын түбәндәгечә реконструкцияләп карый. Ул бу сүз төрки *ага* (әфәнде) һәм фарсыча *ходавәнд* (хөкемдар, падишаһ, әфәнде, хуҗа) титулларының кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән булырга мөмкин дип фараз итә. Бу вакытта "ходавәнд" сүзе кыскарган (гадәттә ул кыска "хонд" шәкелендә кулланыла да) һәм *ага хванд* сүзе туган, аның беренче өлеше дә кыскаргач, *ахванд* яки *ахонд* сүзе ясалган. Әгәр галимнең фаразы дөрес булса, "ахун(д)" сүзенең мәгънәсе "әфәнде әфәнде" булып чыга.

АХШАМ ф. – Эңгер-меңгер вакыт. Р.Әхмәтьянов бу сүз төрки "ак" һәм фарси "шам" (кич, эңгер) сүзләреннән оешкан (ягъни беренчел мәгънәсе "якты эңгер") дип яза һәм аны госманлы (төрек) сүзе дип искәртә. Ләкин бу сүз "Диване лөгатет төрк"тә үк очрый һәм "кич, кояш баю вакыты" дип аңлатыла. "Гарәпчә – татарча – русча алынмалар сүзлеге"ндә "акшам" сүзенә түбәндәге аңлатма бирелгән: 1.Эңгер-меңгер вакыт. 2.Кич белән.

Темников (Түмән) сөйләшендә "*өченче акшамы* – үлгәннән соң өче, өчесе" дигән сүз теркәлгән.

Халыкта ахшамнан соң өй җыештырырга, идән себерергә ярамый дигән ышану бар.

ӘБ г. — Бу сүз *ата, әти* мәгънәсен белдерә һәм, *әба, әби, әбү* рәвешен алып, кеше исемнәрендә компонент булып килә (*Әбабәкер/Әбүбәкер, Әбүханифә, Әбидәламә*). Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында Йосыф үзе күргән төшен этисенә сөйләгәч: "Йа әбәти, моңа тәэвил айгыл *(төшемне юра)* имди," — дип үтенә. Күрәбез, бу очракта автор *"әбәти"* сүзендә төшенчәне ике тапкыр кабатлый. Бүгенге татар теленә аны: *"эткәем"* дип тәрҗемә иткәннәр. Гарәп телендә тагы *Әбиһи* кушаматы да очрый. Мәс., Могавия хәлифәнең бер ярдәмчесе *Зияд ибн Әбиһи* (вафаты 673 елда) исемле булган. Ә "ибн Әбиһи"нең мәгънәсе — (үз) атасының улы, ягъни атасы кем булуы анык түгел дигән сүз. Зиядның абруен күтәрергә теләп, Могавия аның исемен *Зияд ибн Әбү Суфйан* дип үзгәртә һәм аны үз атасы Суфйанның никахтан тыш туган улы дип игълан итә. Ә моның Зияд өчен бер хурлыгы да булмаган, чөнки теге яки бу кемсәнең Исламны кабул иткәнгә кадәрге гөнаһлары автомат рәвешендә ярлыкана.

Күплек шәкеле — *абаә.*

БАЛА ЕЛГА — Сөйләшләрдә очрый торган термин. Чишмәдән агып чыккан кечкенә елга, инеш. Аның суы эчәргә дә яраган, бала елганы пычратмаска тырышканнар.

БАЛБАЛ тар. — Сынташ. Төркиләрдә батыр сугышчы үлгәч, аның кабере янына озынча ташлар бастырып куйганнар (борынгы төрки телдә *"таш бал"* дигән сүз дә булган). Батыр үзе исән чакта күпме дошманны үтергән булса, кабере янына, еш кына кабер өстендәге курганга куелган ташлар да шул санда булган. Нурихан Фәттах бу ташларны "балбал" (дошман) дип атаганнар дип яза, ләкин күренекле тел белгечебез Р.Әхмәтьянов фикеренчә, "балбал" сүзе "пәһлеван" сүзе нигезендә барлыкка килгән.

Таш балбаллар Көньяк Себердә, Үзәк һәм Урта Азиядә, Көнчыгыш Европа далаларында таралган. Татарстанда хәзерге Әлмәт районы Мактама авылы басуында да җир астыннан балбалга охшаш таш табылды.

Скиф чорына караган дүрт кырлы һәм дүрт чырайлы бер балбал 1848 елда Төньяк Кавказда Збруч елгасы буенда табылган. Аның гәүдәсенә төшерелгән ат, мөгез быргы һәм кылычка карап, кайбер рус галимнәре бу балбалны борынгы славяннар куйган дигән фикер әйткәннәр *(мәсәлән, П.Н.Третьяков)*, ләкин аларның фикере тиешенчә нигезләнми.

Алтын Урда чорында, Ислам дине кабул ителгәч, балбаллар кую гадәте юкка чыга, ләкин далада элек куелган сыннарга кагылмыйлар, алар фәкать рус империясе урнашкач кына җимертелә һәм юк ителә. Балбалларны руслар "болван" дип мәсхәрә итәләр, "истукан" һәм "баба" дип тә атыйлар. Борынгы курганнарны казып, андагы байлыкны талап йөрүче "кабер козгыннары"н руслар "курганщик" дип атаганнар.

Балбалларны үз күзләре белән күргән язучы Миргазиян Юныс бу хакта түбәндәгеләрне яза: "Мин Запорожьеда, Мелитопольдә хезмәт иттем. Аннары Одессада, Мариупольдә эшләдем. Төбәкне өйрәнү музейларының ишек алдында яртылаш җиргә батып, кыерсытылып, нәүмиз яткан балбалларны — кыпчаклардан калган бөек мирасны күргәләгәнем бар минем. Мелитопольдә атарга өйрәнү тирының бруствериын яңартканда чыраен эре калибрлы пулемет пулялары чәрдәкләп бетергән шундый бер сынны казып чыгарган идек. Мариуполь–Донецк юлындагы, ялгышмасам, Новоселовка исемле авылда безнең ерак бабаларыбыз ясаган бер сынны койма ташлары арасында күреп, елар дәрәҗәгә җиткәнемне хәтерлим."

Борынгы төркидә *"балбал текмәк"* — балбал кую, утырту. Кирмән һәм шәһәрләр тирәсендә җиргә казып утыртылган бүрәнәләрдән гыйбарәт койманы электә *текмә* дип атаганнар. Текмәләр шәһәрләрне камап алганда да кулланылган. Чыганакларда *"текмәләр тегү"* гыйбарәсе дә очрый.

Балбаллар һәм зиратлардагы ташбилгеләр арасында уртаклык булуы шөбһәсез, тик соңгыларында, Ислам кушканча, кеше сыны белән охшашлык калмаган инде.

Тагын кара: *Алтын балбал.*

БАЛГА бор. — 1.Төркиләрдә сугыш балтасы, айбалта. 2.Тимерчелектә зур, авыр чүкеч; молот, кувалда.

Балда г. — әл-Балда. Бу сүз "идиот", "дивана", "аңгыра", "тинтәк", "ахмак" һ.б. шундый мәгънәләргә ия. Рус телендәге "балда" сүзенең бер мәгънәсенә тәңгәл килә дияргә мөмкин. Бу тәңгәллекнең очраклы хәл булуы шикле. Ихтимал, рус теленә бу сүз суфилар белән очрашканнан соң килеп кергәндер, чөнки суфилар кайчак үзләрен чыннан да "балда" (идиот) дип атыйлар (Идрис Шаһ буенча), кыланыш-гамәлләре һәм сүзләре дә шуларга тартым. Икенче яктан исә, Александр Пушкинның Балдасы — нәкъ менә суфиның үзе инде.

Шунысы кызык, *Ай зодиагында 21 нче йорт* (алар барысы 28) гарәп астрологиясендә әл-Балда дип атала. Ул Укчы йолдызлыгының Кәҗәмөгез белән янәшә өлкәсендә урнашкан.

БАЛИГБАШЫ тар. — Балиг башлыгы. Рус телендәге *квартальный* сүзенә дә туры килә шикелле.

БАРНАГЫЛ тар. — Борынгы өч тиенлек бакыр акча. // *Бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле үгез кебек эшлисең, эш хакы атлыга көненә өч барнагыл, җәяүлегә ике барнагыл. (Афзал Таһиров).*

БАРЫМТА тар. — Мөселманнарда кяфирләргә ясалган һөҗүм; күчмә төрки кабиләләрдә бер-берсенең көтүләрен әйдәп кайту өчен ясалган һөҗүм. "Башкортостан" энциклопедиясендә "Төрки халыкларда куып алып кителгән мал-туарны, урлап алып кителгән хатын-кызны һ.б. ны кире кайтарырга рөхсәт итә торган хокук нормасы" дип аңлатыла. Башкортларда барымта гадәте әле XVII гасырларда да нык сакланган була. Мишәрләрдә бу сүз *"бартан итү"* формасын алган. "Үзбәкчә — русча сүзлек" (Москва, 1959) *барымта* сүзенең "залог" һәм "заклад" мәгънәләрен күрсәтә.

Тагын кара: *Карымта.*

БАСМАЧЫЛАР, БАСМАЧЫЛЫК — 1917 — 1926 елларда Урта Азиядә башында төрле милли-азатлык көчләре торган хәрәкәт. Басмачылар Төркестанны совет хакимлегеннән азат итүне һәм үз дәүләтчелекләрен торгызуны максат итеп куйганнар. Совет матбугатында басмачылык хәрәкәте күп еллар буена фәкать тискәре бәя генә алып килде.

Басмачылар ягында сугышучылар бер Урта Азия халкы гына булмаганлыгын да әйтергә кирәк. Мәсәлән, башкорт галиме Зәки Вәлиди Тоган 1920 елда, Русиядән эмиграциягә китеп барышлый, басмачылар хәрәкәтенә кушыла. Яшь төрекләр революциясе эшлеклесе, берара Төркиянең сугыш министры да булып торган Әнвәр бий Төркестанда советка каршы көрәшкән басмачыларга җитәкчелек итә һәм шунда һәлак була.

Бу яктан караганда, татарларның роле тискәре булганлыгын танырга туры килә. Татар язучысы һәм әдәбият белгече Гази Кашшаф басмачыларга каршы сугышларда актив катнашкан һәм аның бу турыда "Чүл буенда" исемле озын хикәясе дә бар (XX гасырның 30 елларында китап булып басылган). 60 елларда әлеге китапны кабат басып чыгару мәсьәләсе кузгатылып, ул Татарстан китап нәшриятының еллык тематик планына да кертелгән иде. Ләкин план "югары инстанцияләр"дә карала торгач, аны планнан төшерү мәгъкуль күрелде, чөнки Урта Азия халыклары, аеруча үзбәкләр, татарның мәскәүләр ягыннан торып сугышуын хаинлек дип кабул итәләр иде һәм алар моны беркайчан да онытмадылар.

Татарның күренекле генералы Якуб Чанышев та (1892 — 1987), Идел буе беренче аерым укчы татар бригадасының комиссары буларак, Төркестанда азатлык сөюче басмачыларны тар-мар итүдә катнаша. Бервакыт татар бригадасын Бохараны саклаучы мөҗәһидләргә каршы җибәрәләр. Якуб Чанышев солдатларның тормышын саклап калырга ниятли — бернинди коралсыз килеш дошман станына бара һәм басмачыларны бирелергә өнди. Башта аны атып үтерергә дә ниятлиләр, ләкин татар егетенең дәлилләре ышандыра, күрәсең, ахырда басмачылар атаманнары Абдулла-бәкне һәм аның яраннарын кулга алалар да, коралларын ташлап, өйләренә таралышалар.

БАТМАН тар. — 1.Электә татарларда топаш агач кәүсәсен чокып ясаган озынча савыт, ул бал саклау өчен һәм аны күләмен үлчәү берәмлеге итеп кулланылган. *Батман* сүзе белән *бадьян* сүзе арасында генетик бәйләнеш юкмы икән? И.Гигановның русча — татарча сүзлегендә бадья *"бал циляк"*, ягъни "бал

чиләге" дип тәрҗемә ителә. 2.Болгар-татарларда авырлык һәм күләм үлчәү берәмлеге; 4 пот чамасы, ә кайбер җирләрдә 10 кадакка тигез булган. Ләкин төрле илләрдә һәм төрле төбәкләрдә аның авырлыгы төрлечә йөргән (мәсәлән, ике төрле фарсы батманнары, Бохара батманы, Һива батманы һ.б.). В.М.Беркутов "батман" сүзе ике кисәктән тора дип яза: *бат*—авырлык мәгънәсендәге сүз+*ман*. Галим "ман" сүзенең М.Кашгарый лөгатендә "дүрт" мәгъәсендә кулланылганлыгын әйтә. Ләкин хакыйкать өстәрәк ята шикелле: "мән" дигән авырлык үлчәү берәмлеге дә кулланылышта йөргән бит. А.К.Курышжанов үзенең "Исследование по лексике "Тюркско-арабского словаря" дигән хезмәтендә *батман* белән *ратльне* янәшә куя һәм аның 144 дирһәмгә, яки 449,28 г. га тигез булуын күрсәтә.

И.И.Назаров "батман" лексемасыннан рус телендәге "безмен" сүзе килеп чыккан дип исәпли. *(И.И.Назаров. Тюрко-татарские элементы в языке древних памятников русской письменности. "Ученые записки Казанского гос. пед. ин-та", вып.15. Казань, 1958.)*

Батман җир мәйданын үлчәү берәмлеге булып та хезмәт иткән. *Почык* (ярты) *батман* чирек дисәтинәгә тигез дип исәпләнгән. Басу мәйданы буларак та батман төрле төбәктә төрле зурлыкка ия булган. Батманның авырлык һәм җир мәйданын үлчәү өчен берәмлек булып кулланылуы бик аңлаешлы: Мәсәлән, уйгурларда *"патман"* чәчү өчен 573,44 кг орлык кирәк була торган җир бүлемтеге.

БАШ КҮНӘК тар.—Баш сөягеннән ясалган җамаяк, баш чүмече. Чаг.: русча *череп—черпак*. Тарихи чыганакларда бәҗәнәк ханы *Куряның* рус кенәзе *Святославның* баш чүмеченнән җамаяк ясатуы турында мәгълүмат бар. Мондый гадәт монголларда да булган. Мәс., *Чыңгыз хан* үзенең элекке химаячесе, аннары дошманы булган Онг ханны җиңгәч, аның баш сөягеннән алтын белән коршауланган җамаяк ясарга кушкан һәм мәҗлесләрдә шуннан эчә торган булган. Гарәп авторлары бәҗәнәкләрне башкортлар белән бәйлиләр һәм, көнбатышка күчеп киткән бәҗәнәкләрдән аерып, башкортларны *эчке бәҗәнәкләр* дип атау да очрый. Юлда очраган ят кешенең башын кисеп, баш чүмечен кубарып алып китү гадәте борынгы башкортларга да хас булганлыгын без *Ибне Фазлан* язмаларыннан беләбез. Күрәсең, электә баш сөяген савыт итеп файдалану бик күп вәхши халыкларда булгандыр. Мәсәлән, гарәпләрдә баш чүмеченә охшатып ясалган 1 л. чамасы сыешлы агач савытны *кихф* дип атаганнар.

БАШ ӨСТЕ тар.—Электә хан-солтаннар фәрманын үтәүче кеше хан алдына тезләнеп, башын сузып, ханның фәрман язуын баш өстенә куйдырып үзенә алган һәм шул чагында "Баш өстә" дип әйтергә тиеш булган. Ягъни боерыгыгыз баш өстемдә, ул минем башымнан югары, аны үтәү өчен башым белән җавап бирәчәкмен мәгънәсендәге әйтем булган. Соңыннан ул үзгәрә төшеп, "баш өсте"нә әйләнеп калган *(Н.Исәнбәт аңлатмасы)*.

БАШМАКДАР тар.—Башмак кидерүче.//*Йәнә ун мең сакый колым бар иди,. Йәнә ун мең хазер башмакдар иди. (Х.Кятиб).*

БАШМАКЧЫ—Электә мәчеттә кешеләрнең аяк киемнәрен алып-биреп торучы. "Башыңа төшсә башмакчы булырсың" дигән мәкаль шуңарга карата әйтелгән.

БАШНЯ—Манара. Башня сүзе рус теленә татар теленнән кергән дигән фикер бар (*маш* яки *баш* сүзеннән). *Кремль* сүзенең төрки чыгышлы булуы турындагы гөман да шактый нигезле. Чыннан да кремль сүзе русча чыганакларда монгол-татарлар хакимлеге чорында гына кулланылышка керә, ә аңа кадәр шәһәр эчендәге кальганы руслар *детинец* дип йөрткәннәр. Ихтимал, рус телендәге кремль сүзенең килеп чыгышы монголча *хэрэм*—стена, дивар сүзенә бәйледер. Тарихчы М.Худяков "кремль" сүзенең татар теле аша кергәнлегенә шикләнми. Шуңа күрә *башня* сүзенең төрки чыгышлы булу ихтималы арта.

БАШТАК иск.—Бозык, азгын. Хәзерге телдә *башбаштак* сүзе бар. *Хан олы солтан булмаса, халкы алай баштак булмасмы?* "Картлар җыруы"ннан.

БАШЫБОЗЫК төрк.—Электә төрек сугышчысы, регуляр армиядә хезмәт итмәгән солдат. Сөйләм телендә "тиле батыр", "шәрә батыр" мәгънәсенә дә ия. Рус телендә—*башибузук*.

Флера
Сафиуллина

ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЯҢА СУРӘТЛӘР

Хәзерге татар шигъриятендә гаять кызыклы, катлаулы, яңа сыйфатлы үзгәрешләр бара. Бүгенге шагыйрь өчен киртәләр-тыюлар юк. Булса да, ин зур киртә—шагыйрь үзе, анын үз-үзенә таләпчәнлеге, яңача әйтергә тырышуы, яңа сурәтләү чаралары куллануы, үзенең шәхси стилен расларга омтылышы... Шигърият телендәге үзгәрешләр дә яңа сүзләр, яңа мәгънәләр, яңа төсмерләр генә түгел. Бу—яңа үлчәмнәр, җөмләдә ирекле сүз тәртибе һәм шуңа бәйле акцентлар үзгәрү, шигърияткә җанлы сөйләм теле килеп керү һәм сөйләм стиленә хас яңгыраш барлыкка килү... Боларның сәбәбе, ахыр чиктә, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә барып тоташа: матбугат иреге, сүз иреге шигърияттә дә яңа сурәтләр барлыкка килүгә этәргеч булды.

Татар поэзиясендә буыннар алмашу да көчле. Нигездә, яшь һәм урта буын тота хәзерге шигырьне... Шигырьдәге нәфислек реаль тормышка хас булган дорфалыкның поэзиягә бәреп керүе белән янәшә яши. Табигый нәфис яңгырашлы рифма урынына күбрәк куәтле сүзләрнең ярашуы өстенлек итә кебек. Шәхси эслүб булдыруга да омтылыш зур. Ул—ритм, рифмада гына түгел, шуларны тәэмин итүче чараларда да чагылыш таба...

Хәзерге шигырь, еш кына капма-каршы сүзләрнең янәшәлеген үзенә сыйдыра. Объектив дөньяның предметлар һәм күренешләрендәге зур аермалар телдә янәшә яшиләр... Сөйләмдә кайчак антоним сүзләр үзара бәйләнешкә керә һәм бер сүзтезмә булып йөри башлый. Мондый күренеш оксюморон (грек сүзе—тапкыр, ахмак дигән мәгънә) дип атала: мәсәлән, **чын ялган, бай хәерче, коры диңгез, күзле сукыр, атышсыз дуэль...**

Антонимнар мәкальләрдә, халык җырларында, шигърияттә сурәт ясауда һәрвакыт файдаланылганнар. Гасырлар буе кулланыла килеп, XX йөзьеллык башында халык тормышында зур роль уйнаган иҗтимагый-сәяси вакыйгалар нәтиҗәсендә, "иске" белән "яңа"ның көрәше елларында антонимнар белән сурәт ясау тагын да арта төшә: **аклар—кызыллар, иске тормыш—яңа тормыш, байлар—ярлылар, туу—үлү** һ.б. Антонимнар көндәлек тормышка гына түгел, шигърияткә дә килеп керә. Антонимнарга корылган түбәндәге шигырь юлларын искә төшерик:

Иске тормыш:
Үлә,
Үлә,
Үлеп бетә.
Яңа тормыш:
Көлә,
Көлә,
Килеп җитә.

(Б. Сирин)

Әлеге шигырь капма-каршы мәгънәле сүзләре, аларның урнашу рәвеше белән игътибарны җәлеп итә. Ә бу шигырь исә махсус рәвештә антонимнар ярдәмендә сурәт ясау нигезендә барлыкка килгән:

Кайдадыр **көн**.
Кайдадыр **төн**.
Кайдадыр **җылы**.
Кайдадыр **суык**.
Гөлләр...

Гөлләр...
Бакча...
Чүлләр...
Үлем...
Туу...

(Ә. Давыдов)

Антонимнарның мондый "гадәти" кулланылышы яңа буын шагыйрьләрне канәгатьләндерми, күрәсең. Хәзерге поэзиядә башкачарак юл белән сурәт ясау арта бара. Капма-каршы мәгънәле сүзләр бер-берсе белән сәер синтаксик-мәгънәви бәйләнешкә керәләр һәм шул рәвешле үзенчәлекле сурәт барлыкка килә: нәни гигант (Зөлфәт), **парлы ялгыз** (Ф. Сафин), **елый-елый көлү** (Р. Харис), **пешә-пешә туңу** (Н. Әхмәдиев), **күзле сукыр** (Р. Гатауллин), байый-байый бөлү (Л. Лерон) һ. б.

Алтмышынчы елларда ук антоним сүзләр белән мондый сурәтләр ясау поэзиябездә очраштыргалый, билгеле. Ш. Мөдәррриснең бер шигырендә шуңа охшаш юллар бар:

Болар бергә һәр кайсы—
Таныш түгел таныш.
Үпкәләмәс көзгегә
Авызы булса чалыш.

Мондый гыйбарәләр халыкның җанлы сөйләмендә күптән яшәп киләләр. Көндәлек аралашуда **сакаллы сабый**, **сукыр бәхет**, **камыр батыр**, **күзле сукыр**, **тере мәет кебек** тезмәләр һәркемгә аңлашыла. Алар поэзиядә дә сурәтләү чарасы буларак урын ала:

Шуннан хатын сузып яткырды
Бу котырган **камыр батырны**.
Көмеш сабына кадәр кылычны
Йөрәгенә аның батырды.

(М. Җәлил)

Ә күпме **күзле сукырлар**!

(Р. Гатауллин)

Яз гына Рухыннан,
син—беттен!
Ашыйм-эчәм,
гомер кичәм
дип куанма.
Тере мәетеңнең
төртелергә кабер эзләп
аунавы ул...

(Р. Фәйзуллин)

Мин яшимен,
Ә үзләре
нәкъ **тере мәет** кебек...

(Н. Гамбәр)

Бүген күпме **тере мәет**
тулган җиргә.
Тик исәннәр белән алар
никтер бергә.

(Н. Сафина)

...Терелеккә милләт тере
сыман...
Ләкин...
тере мәет түгелме?

(Зөлфәт)

Кичерә күр, соңга калма.
Акла безнең гаепләрне,
Мәрхәмәттән мәхрүм калган
Үксез **тере** *мәетләрне*.

(Л. Шагыйрьҗан)

Соңгы еллар поэзиясендә ***тат-*** тамырына ***-лы*** кушымчасы ялганып ясалган *татлы* сүзе, бик күп сүзләр белән бергә кулланып, антонимик мөнәсәбәтләргә кереп, парлы сүзләр белән сурәт ясауда актив катнаша башлады. Бу сүз шигырьләрдә түбәндәге сүзтезмәләрне барлыкка китерә: **татлы авырту, татлы газап, татлы гөнаһ, татлы сагыш, татлы җәза, татлы тетрәү, татлы хыял, татлы ялган** һ.б. Ә **"татлы—ачы"** каршы куелышы борынгы халык авыз иҗаты—мәкальләрдән үк килә.

Гайбәттән **татлы** юк, хак сүздән ачы юк. *(Татар халык мәкальләре, III)*

Хакыйкать **ачы**, ялган татлы. *(ТХМ, III)*

Мондый антоним сүзләрнең XX гасыр поэзиясендә сурәт буларак кулланылышын Г. Тукайның әнисенә багышланган шигырендә күрәбез:

Бар күнелләрдән дә җылы, йомшак синең кабрең ташы,—
Шунда тамсын күз яшемнең **ачысы** һәм **татлысы**.

Мондый сурәт Ә. Давыдовта да бар. Ләкин Ә. Давыдов аны мәкальдәге кебек кулланмый; ул **татлы** сүзен **авырту** сүзе белән очраштыра:

Кайчак “Авыртмыймы,—дисең миңа,—
Йөрәк каты куллар тиюдән?”
Елмаям, ә йөрәк кысыла
Татлы авыртуны тоюдан.

Ачы һәм **әче** сүзләре, **татлы** сүзе белән антонимик мөнәсәбәтләргә кереп, күп гасырлар кичеп, хәзерге поэзиядә дә гаять активлык күрсәтәләр:

Бергә-бергә татыйсың да
Татлысын да әчесен дә.
(Л. Шагыйрьҗан)

Әй, син, телем, айлы төнем,
Якты көнем.
Әремнәрдән *әче*, балдан
Татлы телем.
(Л. Шагыйрьҗан)

Татлыдыр бу, диеп ымсынасың,
Әче булып чыга капканың...
“Сөенечкәдер!” дип очынасың,—
Кайгы шакып керә капканны.
(Ф. Зыятдинова)

Бәхетле, бәхетсез сүзләре дә **алдану, газап, даһи** дигән сүзләр белән бәйләнешкә кереп, көтелмәгән эффект барлыкка китерә: **бәхетле алдану, бәхетле газап, бәхетсез даһи**:

Кыз борылып карауга, ул туктап калды.
Яфраклар... Кинәт шыбырдап яфраклар
давылы кузгалды.
Егет исенә килеп, пышылдады:
Дәшмә... Беләм... Ул бит инде күптән...
бу дөньядан киткән иде...
Нинди охшашлык!
Бәхетле алдану!
(М. Галиев)

Газаплар өләшә йөрәкләр,
Бәхетле газаплар.
Шатлыклы газаплар.
Әрнүле газаплар.
(Э. Шәрифуллина)

Яхшылык чәчкән дә явызлык урган
Бәхетсез даһилар дөнья тулы.
(Г. Афзал)

Сүзтезмәдә антонимик төшенчәләр нигезендә сурәт ясау табигать күренешләренә дә нигезләнергә дә мөмкин: **төнге кояш, караңгы якты, көзге җәй** һ.б. Л. Шагыйрьҗанның бер шигыре “Көзге җәй” дип атала. Анда шундый юллар бар:

Их, көзләрнең **кышка** түгел,
Җәйгә ялганган чагы...

Кузгалды күнел атлары:
Тизләтте, юыртты.
Биеште уйнап каршымда
Караңгы якты.
(Р. Хисмәтуллин)

Сулышыма кояш нуры кирәк әле,
Тик бүлмәмә тулган куе караңгылык.
Шул чагында ишегемнән якты бөркеп
Син керәсен өйгә **төнге кояш** булып.
(Г. Рәхим)

Кышкы, җәйге сүзләре дә, аерым сүзләр белән яңа мөнәсәбәтләргә кереп, гади укучының башына да килмәгән, көтелмәгән ассоциацияләр барлыкка китерә: **кышкы җәй, кышкы яшен, кышын яуган яңгыр, җәйге кар** һ.б.:

Тик бер кабат яз күрергә телим.
Ник куркасыз **кышкы яшеннән**.
(И. Иксанова)

Су буенда ап-ак комлык.
Бер тавышсыз ап-ак янгыр,
Ап-ак серләр, ап-ак шатлык...
Ап-ак җәй уйлап таптым.
Кышкы җәй.
(Р. Хисмәтуллин)

Н. Әхмәдиев хатын-кызга биргән күпьяклы сыйфатламасында аны “**кышын** яуган **яңгыр**” дип атый. Ул гына да түгел, хатын-кыз ул әле—“**төнлә** чыккан **кояш**”та, “**көндезге ай**” да икән, “**аяз көндә яшен**”дә икән ул!

Җәйге кар ул,
Кышын яуган яңгыр.
Ир-атка соң ничек чыдарга?
Төнлә чыккан кояш,

Көндезге ай,
Аяз көндә яшен—хатын-кыз,
Хатын-кызны аңлыйм дия-дия,
Күпме ир-ат калган акылсыз.

Изге сүзе, **алдау**, **ялган** сүзләре белән бәйләнешкә кереп, көтелмәгән мәгънәләр барлыкка китерә: **изге алдау**, **изге ялган**. Гаять тә әйбәт мәгънәле булган изге сүзе мондый сүзләр белән бәйләнешкә кермәскә тиеш иде дә бит... Нишлисең? Заман изге сүзен дә тискәре мәгънәле сүзләр белән янәшә кулланылышка кертеп җибәргән шул.

Алдау... ләкин бу—**изге алдау**, дип,
Карасын салган, ап-агын кигән,
Яшьләрен яшереп, мәйданга килгән:
"Кояш күк балкып менсен дарга" дип
Алдау... шулай да **изге алдау** бит.

(Х. Туфан)

Өзгәләнде былбыл, таңга кадәр
Җырларына җырны ялгады;
Берьялгызы белде моңлы былбыл
Горур кызның **изге ялганын**.

(Зөлфәт)

Салкын сүзе **җылы**, **утлы** сүзләре белән бер үк сүзтезмә эчендә килеп, үзенчәлекле сурәт барлыкка китерә:

Тик **салкын җылы** бу
Әбиләр чуагы.
Язмышым соңарып,
Кызганып елмайды.

(Н. Измайлова)

...Араларына чәчрәде
Салкын утлы күз яше.

(Р. Харис)

Ирекле сүзе **азат**, **бәйсез** булу мәгънәсен белдерә. Ләкин шигырьдә бу сүз **әсир**, **кол** сүзләре белән көтелмәгән, хәтта антонимик бәйләнешкә керә: **ирекле кол, ирекле Кавказ әсире**. Дөрес, **Кавказ әсире** дигәне Л. Н. Толстойдан килә. Аның онытылмыйча, поэзиягә көчле шагыйрьләребезнең социализм чорында Кавказ төбәкләрендә ял итүләре белән бәйледер кебек:

Мин Иделгә кайттым... Җиремдә дә
Сагынам таулар илен, яшермим...
Үзәннәрдә таулар җырын җырлыйм,
Мин **ирекле Кавказ әсире**.

(Р. Гатауллин)

Һәркем шикле, һәркем бетле,
Ирекле коллар,
үзен-үзе алдый торган
хаиннар булдык.

(Г. Афзал)

Базар тулы коллар...
Мин дә шунда—
Шул **ирекле коллар** базарында.
Сата безне мәрхәмәтсез заман
Чит җирләрдә түгел—
Казанымда!

(Рәшит Әхмәтҗанов)

Г. Моратның «Бәйле бәйсезлек» шигыре дә басылып чыкты...

Газап сүзе дә, үзенә карата антонимик мәгънәдә йөргән сүзләр белән бергә килеп, көтелмәгән сурәт барлыкка китерә: **газаплы ләззәт**, **ләззәтле газап** һ. б.:

Газаплы ләззәт, ләззәтле газап
Җылы туфрактан гарешкә аша.
Ходаем, берүк ярдәм ит җиргә—
Җир ужымлаган мәлләр, ләбаса...

(Зөлфәт)

Кайчандыр еш җырланган бер җырда "**еракта**гы **якын** дустым" дигән гыйбарә хәтердә калган. Ә. Давыдовның "Еракта**гы якын туганнар**" дигән шигыре дә бар. Түбәндәге шигырь юллары да хәтердә:

Җыр җибәрәм матур көйгә салып,
Ерактагы якын,
Ерактагы якын кешемә.

(З. Нури)

Соңардым мин, хатлар язмыйм,
Сина—**ерак якыным**...

(Ф. Сафин)

Һәм менә иң яшь шагыйрьләрдән берсе—Л. Янсуар болай дип язып чыга:

Килә бүген Сиңа сыенасым,
Килә назларыңны тоясым,
Нурлы карашыңнан җылынасым,
Ерактагы якын Кояшым.

Шагыйрьләр **якындагы ераклык** кебек тезмәләр белән дә сурәт ясыйлар. Беренче карашка сәер тоелса да, ул ниндидер серле ассоциацияләр барлыкка китерә:

Якындагы ераклыкны
Кичергән кемнәр генә?
Күзләрең миндә, башкаең
Бүтәннең иңнәрендә.

(Н. Әхмәдиев)

Бер төркем сүзләрдә антонимик мөнәсәбәтләр аеруча ачык сиземләнә. Аларның бер төшенчә оештыруы шагыйрьнең үзенчәлекле табышы һәм яңалыгы дип бәяләнә ала: **матур ялган, нәни гигант, парлы ялгыз, кадерле кайгы, телле телсез, утсыз ялкын** һ.б. Мәсәлән:

Иң матур кыз! Иң сөйкемле!
Нинди **матур ялган**!
Ул ялганга рәхмәт! Мине
бәхетле итә алган.

(Р. Фәйзуллин)

Их, син, сәях дустым, **нәни гигант**!
Без—ракета күк, тик бер аерма:
Ракетаның тыш катлавы яна,
Безнең исә—йөрәк, тойгыларның
Атмосфера катлауларында.

(Зөлфәт)

Күңелеңдә исемемне
Саклыйсыңдыр таң кызым.
Исә җилләр, кичә илләр,
Сау бул, **парлы ялгызым**!..

(Ф. Сафин)

Р. Фәйзуллинның да "Парлы ялгыз" исемле бер шигыре бар. Бу сүзләр, шигырьнең исемендә генә булып, текстта яңадан кабатланмый.

Читләрдән караучыга без—
Туйдагы пар ат кебек!
Ә эчләрдә яра саркый
Чәерле нарат кебек...

Укучылар хәтерлидер: 2002 елның азагында—2003 башында "Ватаным Татарстан" газетасында Н. Гыйматдинованың шул ук "Парлы ялгыз" исемле проза әсәре басылган иде. Күрәсең, безнең җәмгыятьтә шушы мәгънәдә тормыш итә торган кешеләр арта бара... Әсәрләрдә шул чагыла:

Шигърияттә һаман капма-каршы мәгънәле сүзләрне янәшә куеп сурәт ясау арта бара.

Рәхәт газап бирүчем,
Сау бул бүгенгә!

(Эльс Гадел)

Кагылма каенга—
Кагылма.
Кадерле кайгыма.

(Р. Гатауллин)

Гөрли базар. Берәү генә тыныч.
Ымлый гына бары, сөйләми.
Дөньядагы **телле телсезләргә**
Тылмач була ала бу әби.

(Рәшит Әхмәтҗанов)

Соңгы гыйбарә Айдар Хәлимнең татар китабына багышланган бер шигырендә дә урын алган:

Телле телсез булган телемдәй,
Йөзем, телем һәм күземне ачтың...

Утлы, утсыз сүзләре дә яна сурәтләр барлыкка китерер өчен кулай булып чыккан: **утлы оҗмах, утлы яңгыр, утсыз ялкын** һ. б.:

Гөлле тәмуг, утлы оҗмах түбәндә.
(Р. Сүлти)

Өсләремә, **утлы яңгыр** булып,
ява,
ява,
ява ла күзләр.
(Р. Аймәт)

Күңелләрдә **утсыз ялкын** дөрли,
Шатлык оча җиргә сыймыйча.
(Н. Әхмәдиев)

Шигырьләрдә **Камыр батыр** үрнәгендә **елак батыр** да барлыкка килә:

Дөнья матур—исең китәрлек,
Ал кояшлы,
Зәңгәр чәчкәле.
Синең кебек **елак батырлар**
Безнекеннән зур киләчәкле.
(Ә. Рәшит)

Мондый берәмлекләр арасында фигыль сүзтезмәсендәге антонимик төшенчәләргә нигезләнгәннәре дә шактый күзәтелә: **китмәскә дип килү, көлә-көлә елау, елый-елый көлү, елмаеп елау, елап көлү, төшкән саен күтәрелү, өши-өши яну, пешә-пешә туңу, үлә-үлә яшәү, байый-байый бөлү, үлеп терелү, (хәмер) эчми исерү, үзгәреп тә үзгәрмичә калу, яшь чыгармый елау, ерагайган саен якынаю, хурлый-хурлый соклану** һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, беренче урында килгән компонентларның күпчелеге **-ый/-и, -а/-ә** формалы хәл фигыльне тәшкил итәләр. Сирәгрәк **-ып/-еп/-п** хәл фигыль, **-ган/-гән, -кан/-кән** формалы үткән заман сыйфат фигыльләре кулланыла. Мисалларның зур күпчелеге хәзерге поэзиягә карый. Берничә мисал китереп үтик:

Хурлый-хурлый сокланабыз,
Елый-елый көләбез...
Шайтан алгыры, шулай
Матур яши беләбез.
(Р. Харис.)

Сузылып кул житәр жирдә
Якын һәм ерак кешен,
Ә син түз, **ела елмаеп**,
Житәлсә әгәр көчең.
(Н. Әхмәдиев.)

Картлык яшьлеге, **төшем өне—өнем төше**, **мәхәббәтнең нәфрәте—нәфрәтнең мәхәббәте, ялганның дөресе—дөреснең ялганы, беренченең киләчәге, юләр башның акыллыгы—акыллы баш юләрлеге** кебек стиль әйләнмәләре дә поэзиядә арта кебек. Ә. Баяновның бер шигыре бөтенләе белән шундый антитезалы сурәттән гыйбарәт:

Кичәгемнең бүгенгесе,
Бүгенгемнең кичәгесе,
Дөресенең ялганыдыр,
Ялганымның чын дөресе,
Мәхәббәтнең нәфрәт төсле,
Нәфрәтемнең мәхәббәттәй
күренеше—
Аның эше.
(Ә. Баянов)

Алданрак язылган бер шигырендә дә Ә. Баянов мондый төзелешле сурәткә мөрәҗәгать итә:

Соң түгелдер әле, дигән булыйк,
Серне бик чәчми генә
Алдым менә жавап—кергәч гомер
Картлыкның яшьлегенә...

Соңгысы безгә З. Нури шигыре буенча да таныш. Житмешенче еллардан аның бер шигыре хәтердә сакланган:

Картлык яшьлегемә кердем...
Кирәк түгел артыгы!..

Зөлфәт бер шигырендә **фаҗига** белән **бәхет** сүзен очраштыра; алар арасындагы аерма гаҗәеп зур, ләкин **фаҗигале бәхет** сүзтезмәсе моңа кадәр беркемдә дә очрамаган үзенчәлекле сурәт барлыкка китергән:

Фаҗигале бәхет көз төсендә,
Кабер түгел бәгырь өстендә.

М. Галиевнең бер шигырендә исә **яшь чыгармый елау** сурәте оста кулланылган:

Кайберәүләр
Авыз ачмый җырлыйлар,
Икенчеләр
Яшь чыгармый елыйлар.

Бу тезмә, алдагы **авыз ачмый елау** сүзтезмәсе белән антонимик мөнәсәбәтләргә кереп, **елау** сүзенең мәгънәсен тагын да төгәлрәк аңлауга китерә.

Бөек һәм **матурлык** сүзләре һич тә негатив мәгънәгә ия түгел. Әмма **ялган бөек** һәм **ялган матурлык** сүзтезмәләрен дә без табигый итеп кабул итәбез. **Яхшы** һәм **яман** сүзләре, сәер мөнәсәбәткә кереп, **яхшы ялган, яман дөреслек, ягымлы ялган** кебек сурәт ясаганнар.

Булыр—моң аңлаудан мәхрүм,
Күнел колагына дөя баскан сак бай,
ялган "бөек"ләр.

(Р. Гатауллин)

Үз Ләйләңне эзләп йөргән чакта
Кисәтсә дә чатта кызыл ут,
Кул бирәсең кайчак җиде ятка,
Ялган матурлыкка кызыгып...

(Р. Закиров)

Ягымлы ялган булса да,
Килешә хатын-кызга.

(М. Галиев)

Шунысы кызык: татар халык мәкальләрендә үк инде мондый сурәт булган. **Яхшы ялганнан яман дөреслек яхшы** *(Н. Исәнбәт, Татар халык мәкальләре, III том)* мәкалендәге көчле сурәт нәкъ менә шушы сүзтезмәләрнең каршы куелышы аша барлыкка килгән.

Сыйфатлы исемнән торган тезмәләр әйтелгәннәр белән генә чикләнми, әлбәттә. Берәр-берәр генә булса да, **бөек билгесез, бөек ялган, ихлас ялган** кебек әйләнмәләр дә очраштыра:

Тәрәзәмнән керә кабат—
Шук малайлар тавышлары.
Алар мине кабатламас,
Вакытында үзен табар, эзләр.
—Эврика!—дип кычкырасы
Бөек билгесезләр!

(М. Галиев)

Нинди **бөек ялган** белән
Күзләренә нур салыйм?!

(Н. Измайлова)

...Мин тезләнеп сәҗдә кылам бүген
Мәхәббәтнең **ихлас ялганына**.

(Ф. Мөслимова)

Поэзиядәге мондый гыйбарәләр кайчак мәгънә ягыннан шактый сәер булалар, ләкин, ияртүче сүзнең мәгънәсенә каршы фикер белдереп, үзенчәлекле тезмәләр барлыкка килә. Мәсәлән, Ә. Баяновның бер шигырендә каршы куелыш ике сүзтезмә арасында гына түгел, һәр сүзтезмәдә дә сиземләнә:

Ул минем **кире фәрештәм**,
Ул минем **уңай җенемдер**.
Төссез һәм тәнсез күләгә,
Минем икенче "мин" емдер...

(Ә. Баянов)

Әлеге күренешләрнең квинтэссенциясен чагылдыра торган бер шигырендә, М.Җәлил турында язып, Зөлфәт **былбыл** белән **бөркетне** каршы куя. Ләкин шагыйрьгә бу каршы кую кына җитми. Ул тагын антонимнар өсти: **җырлый белми—сугыша белми**. Шагыйрь, тагын да буяуларны куертып, соңгы сурәтне иң югары дәрәҗәгә күтәрә...

Җырлый белмиләр **бөркетләр**.
Сугыша белми **былбыл**.
Җырдан сызланмый **бөркетләр**,
Сугышта үлми **былбыл**.

Муса кайсы шул кошларның?
Жанына сыйган жир, күк...
Сугыша белгән былбыл ул,
Һәм **жырлый белгән** бөркет.

Бу шигырьгә бәйле рәвештә икенче бер урында Зөлфәт зур аяныч белән болай дип тә искәртә: "Былбылын сугыш бөркете урынына яуга чыгарга мәжбүр иткән илнең, халыкның гөнаһларын кем күтәрер? *(Зөлфәт. Ике урман арасы. Эссе, шигырьләр, жырлар, поэмалар.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1995.—15 б.)*

М. Галиев иҗатында гына урын алган бер очрак бар: капма-каршы мәгънәләр очрашып-чәкешеп, сурәт барлыкка килә... "Ничек дөрес ялгышканбыз".

Гажәп тә соң инде!.. Шагыйрьләр шигырьнең формасы белән бергә мәгънәсенә дә басым ясыйлар. Һәр шагыйрь үзен башкалардан аерып торган, ул гына әйтә торган, ул гына әйтә ала торган тәгъбирләр эзли. Һәм "ачылмаган ачышлар" ясый. М. Галиев бу сүзләрне юкка гына очраштырмый:

Чәчелеп лә ята—уйлар, жырлар,
ачылмаган ачыш, дөньялар...

Поэзиябездә мондый сурәтләр барлыкка килүгә рус теле дә ярдәм итеп, этәргеч биреп торадыр кебек тоела. Әгәр **соңгы могикан** (последний могикан) булмаса, **тәүге соңгы могикан** була алмас иде; **светлая грусть** булмаса, **якты сагыш** булмас иде; **сладкая ложь** булмаса, **татлы ялган** булмас иде; **Кавказ әсире** булмаса, **ирекле Кавказ әсире** булмас иде... Мәсәлән:

Туксан яшьлек ветераннар
Илдән ничәү бар икән?
Авылында Сафуан карт
Тәүге соңгы могикан...

(М. Галиев)

Рус теленең "смотреть через розовые очки" фразеологизмы һәм "красивая ложь" сүзтезмәсе тәэсирендә булса кирәк, бездә алсу ялган һәм кара чынбарлык каршы куелышы барлыкка килгән:

Чынбарлыкка алсу күзлек аша
Юанганбыз карап—чыдарлык!
Ал пыяла күпме алдый ала?
Алсу ялган—кара чынбарлык!

(Л. Шагыйрьжан)

Татар поэзиясендә сирәк күзәтелгән бер антонимик каршы куелышны да күрсәтеп үтик:

Елыйм,
шәфкать сорыйм—
антиминем миннән көлгән була.

(Ә. Рәшит)

Шигырь бөтенләе белән антонимнарга нигезләнгән булырга мөмкин. Г. Моратның "Син" шигыре тулысынча капма-каршы төшенчәләрне белдергән сүзләрдән гыйбарәт. Шигырьдә фигыльләр юк. Бары антоним исемнәр, нокталар аша урнашып, кешенең йөрәгендә—күнелендә—жанында яшәгән капма-каршылыклар бердәмлеген күрсәтеп торалар...

Горурлыгым. Мескенлегем.
Таянычым. Абынуым.
Тугрылыгым. Хыянәтем.
Ихтыярым. Табынуым.
Бергәлегем. Ялгызлыгым.
Нәфрәтем. Мәхәббәтем.
Әсирлегем. Хөрриятем.
Яшәешем. Һәлакәтем.

Шигырьнең яналыгы ап-ачык тоела. Андагы антонимнар, беренче зат тартым кушымчасы алып, бер составлы жөмләләр буларак яшиләр. Аларда үзенчәлекле симметрия бар: һәр юлда парлап-парлап урнашканнар. Киеренкелек арта бара һәм

ул—сүзләрнең мәгънәләренә бәйле: **горурлык—мескенлек, таяныч—абыну, тугърылык—хыянәт, ихтыяр—табыну, бергәлек—ялгызлык, нәфрәт—мәхәббәт, әсирлек—хөррият, яшәеш—һәлакәт.** Бер парның гына антоним булуы сәеррәк: **ихтыяр—табыну**, ләкин кучерелмә мәгънәсендә алар да антонимик мөнәсәбәттә торалар. Шигырь кеше тормышының аерым-аерым этапларын үз эченә ала. Бер гомер шикелле тоела бу юллар. Ә тормыш каршылыклардан гыйбарәт бит. Шуна күрә киеренкелек шигырьнең буеннан-буена үсә бара...

Р. Фәйзуллинның бер шигырендә дә антонимнар әсәрнең үзәген тәшкил итәләр:

Жырлады читләргә **китүче**
Яшь, таза, сөлектәй бер **егет**:
Безнең жир—**сыктар-елар жир**...
Безнең жир—**шүрәле каргар жир**...
Жырлады читләрдән **кайтучы**
ак йөзле, чал чәчле бер **бабай**:
Безнең жир—**уйнар-көләр жир**!
Безнең жир—**сандугач сайрар жир**!..

(Р. Фәйзуллин)

Туган жирен ташлап китүче сөлектәй егеткә бу дөнья авыр, ямьсез булып тоелган. Ләкин ул читтә яши алмыйча, инде картаеп, чал чәчле бабайга әйләнеп кайтып килгәндә, туган жирдән дә гүзәлрәк жир югын аңлап кайта... Шушы үзгәрешләрне шагыйрь синтаксик параллелизмга ярдәмгә килгән антонимнар белән сурәтли: **китүче—кайтучы, таза—ак йөзле, яшь—чал чәчле, егет—бабай, сыктар-елар—уйнар-көләр, шүрәле каргар жир—сандугач сайрар жир**. Шигырьне шушы антонимнар тотып тора. Шулар, текстта әйтелеп тә бетмәгән фикерләрне күз алдына китереп, олуг бер хакыйкать турында сөйлиләр: туган жирдән кадерле нәрсә юк икән дөньяда!

Р. Фәйзуллинның антонимнарга корылган гажәеп яңгырашлы шигырьләре шактый. Шулардан берсе:

Мине **май** дип белдең, ахры,
Мин бит **ноябрь** сыман.
Кояшым аз, күгем—**тулы**—
Салкын яңгыр да томан.
Мин үзем дә белми торган
Бер сәерлектә яшим.
Чилләләрдә кайчак **өшим**,
Кышларын ярсып **яшьним**.
Үзем дә кайчак төшенмим
Күңелемнең хәлләрен.
Көтәм жылы **ләйсән яңгыр**,
Чыга **зилзиләләре**.

Монда да шул ук хәл: **май—ноябрь, аз—тулы, кояш—салкын яңгыр (томан), чиллә—кыш, өшү—яшьнәү, ләйсән яңгыр—зилзилә**. Шагыйрьнең икенче бер шигыре дә ("Парадокс") нәкъ менә антонимия аркасында бер бөтен булып оеша:

Көтәсең **газиз** кешеңне,
Бер **имгәк** шалтырата...
Ялманып **алтын** эзлисең—
Алдында **нәжес** ята.

Жилләр белән **жыр** юллыйсың—
Ул **гайбәт** булып кайта.
Хәер бирсәң, кыйбаткарак
Үзеңә китереп сата.

Бирәүгә **икмәк сузасың**—
Ә ул сиңа **таш** ата...
Гавәм жанын **пакьлим** дисең—
Ә ул **күзең** акайта.

Изге хөрлеккә өндисең
Вәхи сүз ката-ката.
Ыржаеп тарихи хата
Ботын күтәреп ята.

Антоним сүзләр арасында сурәт ясаучылары күбесенчә исемнәргә, сыйфатларга, фигыльләргә карый:

Бәләкәйләр аркасында
Пәһлеваннар орыша.
Акылсызлар аркасында
Хәкимнәр кычкырыша.
Гөнаһлылар аркасында
Изгеләр кырылыша.

(Р.Харис)

Бәләкәй—пәһлеван, акылсыз—хәким, гөнаһлы—изге антонимнары шигырьне тотып торалар, шулар икенче юллардагы **орыша**, **кычкырыша, кырылыша** кебек якын яңгырашлы формалар белән интонацион бөтенлек барлыкка китерәләр; иядәге күплек кушымчалары охшаш яңгырашны тәэмин итәләр; **аркасында** бәйлек сүзенең кабатланып килүе шигырь юлларын бер бөтен итүдә катнаша.

Л. Шагыйрьҗанның "Сезнең язлар" шигырендә антонимнар, нигездә, фигыль сүз төркеменә карыйлар. Ләкин төп каршы куелган төшенчәләр—без һәм сез.

Сезнең язлар гөрли әле, **көлә**,
Безнең язлар инде **елый** белә...
Сезнең хисләр ташый язлар саен,
Безнең инде елы ничек килә.
Сезнең язда бозлар **китә агып**,
Безнең бозлар инде **эреми дә**...
Сөю сәгатьләре **суга саздә**,
Безнең инде кайчак **йөреми** дә..

Язлар әле **сезнең иртә килә**.
Ә безнеке кайта соңлабрак...
Бәхет **сезгә сорамыйча керә**,
Без көтәбез инрәп, елап, сорап...
Кабатлана **һәр ел сезнең** язлар,
Безнең инде **елы-елы белән**.
Сезнең язлар **көлә** генә әле,
Безнең язлар инде **елый** белә...

Бу шигырьдәге сагыну-сагышны, яшьлек үтеп киткәннең ачысын **без** һәм **сез** каршы куелышы тагын да арттыра, интонацион каршылыкны да көчәйтеп җибәрә.

Антонимнар, шигърият дөньясына туктамыйча кереп, хәзерге татар поэзиясенең иң төп бизәкләү чараларыннан берсенә әйләнеп баралар:

Эндәшмәүчеләр турында
Бернәрсә дә уйламагыз:
Яхшы дип тә, **яман** дип тә...
Олы дип тә, эре дип тә,
Үле дип тә, **тере** дип тә—
Бернәрсә дә уйламагыз,
Үз сүзен әйтмәгән кеше
Ул беркем дә түгел әле.

(Н. Измайлова)

...Татар шигыре заманга бәйле рәвештә үсә, үзгәрә, яңара. Традицион сурәтләрне дәвам иткән хәлдә, ул үлчәм һәм формаларны яңарта-яңарта, шигырьнең төп берәмлеге булган Сүзне, аның төрле мәгънәләрен хәрәкәткә китерә, сүзнең башка сүзләргә булган бәйләнешләрен төрләндерә, укучыны гаҗәпләндерергә, сискәндерергә омтыла, заманның катлаулы күренешләренә туры килердәй яңа сурәтләр эзли...

Шигърият хәзер—азат! Язучы—ирекле! Әйтер сүзе булган шагыйрьнең мөмкинлекләре чикләнмәгән... Хәзерге шигърияттәге сүз-сурәтнең башка үзенчәлекләре дә күзгә күренә: телебезнең сүзлек катламнары хәрәкәткә килә; дини, иҗтимагый лексика активлаша; борынгы искергән сүзләр калкып чыгалар, шагыйрьләр яна сүзләр иҗат итәләр, телебезгә алынма сүзләр үтеп керәләр... Шигъриятебез халыкны яшәешкә өнди, мескен булмаска өнди, тарихи хәтеребезне яңарта, Шәрык әдәбиятының гүзәл традицияләрен кире кайтара... Хәзерге шигърияттәге табышлар гаять кызыклы, күп яклы... Ышанып калабыз: шигъриятебездәге бу яңа һәм кызыклы күренешләр алга таба да өйрәнелер әле...

Әдәбиятлар дуслыгы—халыклар дуслыгы

Фоат Галимуллин

ТАТАР–ЧУВАШ БАГЛАНЫШЛАРЫ

Бу ике күрше халыкны берләштергән яклар аз түгел. Аларның телләре төрки булган кебек, моң, музыка өлкәсендәге якынлыклары да бәхәссез. Шунысы да бар: бу ике кавемнең телләре төрки гаиләгә керсә дә, бу ике милләт, махсус өйрәнмәгән вакытта, бер-берләренең телләрен аңламый диярлек. Дин аерымлыгы да (чувашлар христиан динен кабул иткәннәр) аларның яшәү рәвешенә җитди аерымлыклар керткән. Әмма бергә аралашып яшәгән урыннарда татарлар һәм чувашлар бер-беренең телләрен яхшы ук беләләр, бу исә аларга рухи өлкәдә дә аралашып, бер-берен баетып яшәү мөмкинлеген бирә. Һәр ике халыкның сүз сәнгате үз юлы белән үскән, аларның чын милли йөзе бар.

1897 елда халык санын исәпкә алу нәтиҗәсендә Казан, Сембер, Уфа, Самара, Оренбург губерналарында 900 меңләп чуваш яшәгәнлеге беленә, шуларның 550 меңе Казан губернасында. "Менә шуны искә алсак,—ди чуваш галиме И. Иванов,—чуваш халкының культурасын саклап калуда һәм үстерүдә Казанның нинди әһәмияткә ия булуын күз алдына китерү кыен түгел"[1]. Билгеле булганча, культураның иң мөһим компонентларыннан берсе—аның миллилеге.

Бер инану яшәп килә: язучы һәм шагыйрьнең иҗаты никадәр миллирәк булса, ул гомумкешелек тарафыннан да шулкадәр кызыксынып кабул ителә. Чөнки миллилек меңнәрчә еллар буена гомумкешелек белән бик күп бәйләнешләр нәтиҗәсендә, башкалардан кыйммәтле якларны алып, ләкин аларны үзенең карашларына, принципларына, яшәү рәвешенә җайлаштырып үсеп килә. Чуваш галиме И. Иванов та, татар-чуваш әдәбиятлары элемтәсе турында фикер йөрткәндә, шундый нәтиҗәгә килә: "Һәрбер милли шагыйрь, барыннан да элек, үз халкының, үз милләтенең рухын аның көчле чагылышында күрсәтергә омтыла. Башка халыклар өчен ул шуның белән кызыклы да. Г. Тукай поэзиясе татар халкының табигатендә, рухында булган барлык матур якларны үзенә җыйган. Менә шуңа күрә дә гомумкешелек культурасының бер өлеше булып, әле бүген дә бик күп халыкларга армый-талмый хезмәт итә"[2].

Татарның Г. Тукае гына түгел, аның борынгыдан килгән шигърияте, грамоталылыгы, китаплы милләт булуы да башка халыкларга, шул исәптән чувашларга да, уңай тәэсир ясап килгән. Казан шәһәре үзе генә дә чувашларның гомуми мәдәни дәрәҗәсен күтәрүдә, әдәбиятын үстерүдә, язма сүз сәнгатен барлыкка китерүдә зур урын тоткан. Күренекле чуваш мәгърифәтчеләре, шагыйрьләре, галимнәре Татарстан, аның башкаласы Казан белән бик якын элемтәдә булганнар. Гомумкультура ягыннан әнә шундый алдынгырак мохиттә туган чувашлар да фән, мәгърифәт өлкәләрендә тизрәк җитлеккәннәр. Әйтик, Тәтеш төбәгендәге Күшке-Яңа Тимбай авылында чувашның ике күренекле әдәбият әһеле туып-үскән. Аларның беренчесе Иван Яковлев. Чувашлар өчен әлифба авторы, күренекле мәгърифәтче И. Яковлев (1848—1930) 1875 елда Казан университетын тәмамлый. "Әлифба"сының кереш сүзендә ул беренче карашка сәер яңгырый торган фикер әйтә: "руслар, татарлар, чувашлар—барысы да кешеләр". Шулай да бу тикмәгә әйтелмәгән. Россиядә бары бер милләт—руслар гына өстенлекле булып килде. Татарлар, чувашлар һәм башкалар иң гадәти хокуктан—белем алудан, бигрәк тә дөньяви фәннәрне өйрәнүдән мәхрүм ителделәр. И. Яковлев тырышлыгы белән Сембердә 1868 елда чуваш укытучылар мәктәбе һәм губернада берничә чуваш мәктәбе ачылу—ул шартлар өчен бик тә мөһим эш иде. Шундый мәктәпләрнең берсе туган авылы Күкше-Яңа Тимбай авылында эшли башлый. Бу авылда туып үскән икенче бер чуваш әдәбиятының күренекле вәкиле—Тихон Педэрки (Петр Петров) (1903—1976). Ул авылдашы И. Яковлев турында "Күкше малае" дигән тарихи-биографик трилогия яза. 1950 елдан Казанның Совет районы халык мәгариф бүлеге мөдире, 126 нчы мәктәпнең директоры була. Казанда вафат та була.

---

[1]Казан утлары.—1972.—N 2.—164 б.
[2]Шунда ук.

Заманында И. Яковлев ачкан Кошки-Яңа Тимбай авылы мәктәбендә булачак драматург И. Максимов, Чуваш Республикасының халык шагыйре Александр Алга, язучылар Владимир Ухли, Сантор Тимбай, Чувашстанның халык артисты Анна Казакова кебек мәшһүр кешеләр укыган. 1992 елда Татарстан Хөкүмәте Кошки-Яңа Тимбай авылында И. Я. Яковлев хөрмәтенә тарихи-мәдәни үзәк булдыру турында карар кабул итте[1].

Күренекле шагыйрь Михаил Сеспель да иҗатын Казанда башлады[2]. Педер Хузангай да Татарстанда туып үскән. Казан—аның иҗаты башланган шәһәр. П. Хузангай сүзенә шушы мәгънә салынган, ул "Казанлы" дигән сүз. Чуваш әдәбиятында беренче булып баллада язган М. Ф. Федоров та 1878 елда Казан укытучылар институтында берьеллык курс тәмамлый. Шул ук елда ул "Арзюри" ("Шүрәле") балладасын иҗат итә. Димәк, ул халык телендә йөргән Шүрәле мифологик образын язма әдәбиятта Г. Тукайга кадәр шактый элек гәүдәләндергән икән. Татар халкының бөек шагыйре үзенең шул исемдәге әкият-поэмасын чирек гасырдан соң язды.

1905—1907 елларда чуваш вакытлы матбугаты һәм демократик әдәбияты барлыкка килүдә Казан шәһәре белән бәйле. 1905 елның ахырында бирелә "Хыпар" ("Хәбәр") исемле газета чыгарырга рөхсәт алалар. Дөрес, ул ике елдан соң ябыла. Ун елдан соң, ягъни 1917 елда, ул яңадан чыга башлый. Әмма аның сәяси юнәлеше үзгәрә, инде ул инкыйлапны хупламаган язмалар бастыра башлый. Шуның өчен большевикларга уңай мөнәсәбәттә торучылар "Канаш" ("Киңәш") газетасын чыгара башлыйлар. Аңа да Казанда нигез салына. Билгеле булганча, 1920 елда Чуваш автономияле өлкәсе төзелә. Шуннан соң "Канаш" газетасы, Чуваш нәшрияты, чуваш милли театры Казаннан Чабаксарга күчерелә. Бу елларны соңыннанрак П. Хузангай болай тасвирлады:

Кайнап торды Казан эш белән,
Һәм әдәби Казан кайнады.

Чуваш каләм әһелләре, татар язучыларыннан гына түгел, аның сәяси эшлеклеләреннән дә үзләре өчен төрле яклап ярдәм алалар. "Бәйнәлмиләл"не беренче булып чуваш теленә тәрҗемә иткән Тайр Тимкинең татар инкыйлабчысы, "Урал" газетасын оештыручы Хөсәен Ямашев белән берничә тапкыр очрашып, үзен борчыган сорауларны ачыклаганы мәгълүм[3].

Чувашстанда татар әдәбияты көннәре. Бер төркем татар һәм чуваш әдипләре. 1984 ел.

Чуваш әдәбияты эшлеклеләре татар каләм осталары иҗатын яхшы беләләр, аларга тиешле бәя белән дә чыгыш ясыйлар. Әдәбият белгече, Ипполит Иванов, мәсәлән, Г. Тукайны, шагыйрь буларак, югары бәяли, аның—татар әдәбиятында күтәрелеп чыгуын халыкның олы үткәне һәм бай әдәби традицияләре белән бәйли. "Күп гасырлык тәҗрибәгә, рус һәм көнчыгыш әдәбиятларының бай традицияләренә таянып үскән татар әдәбияты Тукай иҗатында иң югары ноктасына күтәрелде[4]",—ди. Һәм үз чиратында татар әдәбиятының, бигрәк тә Г. Тукай иҗатының чуваш сүз сәнгать үсешенә көчле йогынты ясавын билгеләп үтә[5]. "Иң югары нокта" дигәндә, әлбәттә, И. Иванов татар каләм осталары даирәсен тарайтып ала. Билгеле булганча, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Камал һәм башкалар иҗаты бу югары ноктаның тотрыклылыгын тәэмин иткән казанышлар булды. Г. Исхакый исемен, әлбәттә, ул елларда теләгән очракта да И. Иванов әйтә алмый иде. Билгеле булганча, Г. Исхакый "Ике йөз елдан

[1]Ватаным Татарстан.—1992.—23 май.
[2]Казан утлары.—1972.—N 2.—164 б.
[3]Шунда ук.
[4]Шунда ук.
[5]Шунда ук.

соң инкыйраз" әсәрендә үткәргән фикерләре белән Г. Тукайга һәм аның замандашларына таяну ноктасы булды.

Егерменче елларда һәм аннан соң да чуваш шагыйрьләренә Һ. Такташ йогынтысы зур булды. Һ. Такташ үзе дә алар белән очрашуларга теләп бара, аралашулардан үзенә дә күп нәрсә ала. Шундый аралашуларның берсе 1930 елның 20 июлендә була. Ул анда болай ди: "Безне аерган нәрсә—телләр аерымлыгы, ләкин бу аерымлык безгә комачауламый, аерым милләтләрнең культура эшчеләре тудырган уңышлар белән файдаланырга да киртә була алмый. Чуваш язучылары тудырган, пролетариат өчен кыйммәтле булган әсәрләр татар пролетариатына рухи азык булган кебек, татар пролетар язучылары тудырган әсәрләр дә чуваш пролетариатының социализм өчен булган көрәшендә көчле корал булып хезмәт итә ала"[1].

Чуваш халкының бөек мәгърифәтчесе Яковлев Иван Яковлевичка куелган һәйкәл.

Бу фикерләрне әйткәндә, сүз дә юк, Һ. Такташ ул вакыттагы идеология кысаларында уй йөртергә мәҗбүр. Аннан аңлашылганча, әйтерсең лә, әдәби әсәр бары тик эшчеләр, пролетариат вәкилләре укысын өчен генә языла? Акыл хезмәте кешеләре, крестьяннар, димәк, әдәби әсәрләрне укымаска тиеш була. Болар, сүз дә юк, Һ" Такташның—үз күңеленә каршы килеп әйткән сүзләре. Чөнки бөек шагыйребез Һ. Такташ, әсәрләрен язганда, аларны авыл кешеләре дә, зыялылар да укысын дип язды. Ә татар һәм чуваш язучылары әсәрләре һәр ике халыкка да "рухи азык булыр"га тиешлеген ул, һичшиксез, дөрес һәм бәхәскә урын калдырмаслык итеп әйтә. Бу ике халыкның бер-берсе белән рухи якынлыгы, бердәй уй-ниятләр белән яшәве аның "Иптәшләр" (1927) шигырендә дә чагыла. Кызыл армиянең җәйге өйрәнүләрендә булгач язылган әлеге әсәр ихлас хисләрне чагылдыра, җитмәсә, алар гаҗәеп талантлы итеп гәүдәләндерелгәннәр. Димәк, әлеге шигырь юлларының укучыларга тәэсир итү көче дә зур. Бу, дөресен әйткәндә, большевиклар фиркасе өчен теләнгән күренеш түгел иде. Чөнки, алар гоманынча, аерым талант иясенең массаларга йогынтысы зур булу фирканең тәэсирен кочәйтүгә зыян китерәчәк, андый шәхесләрне юк итсәң, аларның тәэсир итү көче дә юкка чыгачак. Утызынчы ел урталарына кадәр яшәгән булса, Һ. Такташ, һичшиксез, эзәрлекләүләргә иң беренчеләрдән булып дучар ителәчәк иде. Ник дигәндә, аның зур талантының тәэсире татар укучыларына гына түгел, бәлки чуваш, мари, удмурт, башкорт һәм башкаларга да зур булды. Татарстанда яшәүче йөз утыз меңнән артык чуваш милләтеннән булган укучылар аны беләләр, ихтирам итәләр, күбесе шагыйрьне оригиналь телдә аңлый.

Н. Степанов язганча, "Һ. Такташ гаиләсе белән П. Хузангай гаиләсе дус булган, кунакка йөрешкән. Хәтта Һ. Такташ шушы дуслык хөрмәтенә малаена Аван (чувашча "яхшы", "киң күңелле" дигәнне аңлата) исеме кушкан икән[2].

Һ. Такташның замандашы Хәсән Туфан да чуваш язучыларын үз итә. Мәгълүм булганча, ул, каләмдәш дусты Һадиның үлеменә хәсрәтләнеп, "Ә үткәнгә хатлар бармыйлар" дигән шигырьләр циклын язган иде.

Салыр идем, ләкин почтальоннар
Хатны аңа илтә алмыйлар:
Киләчәккә хатлар барып җитә,
Ә үткәнгә хатлар бармыйлар.

Никадәр сагыш хисе, чарасызлык газабы һәм чын шигърият! Утыз елдан артык вакыт узгач, Х. Туфан тагын шуңа охшашрак бер шигырь язды. Чуваш шагыйре Васлей Митта да, безнең

[1]Такташ Һ. Әсәрләр.—Казан: 1942.—317 б.
[2]Ватаным Татарстан.—1992.—23 май
[3]Казан утлары.—1970.—N 12.—105—107 бб.

Х. Туфан кебек, хаксыз рәнҗетелүләргә дучар булган шәхес. Шуңа күрә аның мондый шигъри юллары булуы гаҗәп түгел:

Үзеңне күреп белмәсәм дә,
Чын туганым син, Туфан.

Әйе, аларга исән килеш танышу насыйп булмый. Тугандаш халыкның бу шагыйре иртәрәк үлеп китә. Моны ишеткәч, Х. Туфан аңа багышлап шигырь язмый кала алмый. Анда без тагын бер кат инде ничә еллар элек таныш булган хис-кичерешләр гәүдәләнеше белән очрашабыз:

Ә йөрәктә
Сәламнәр дә сиңа,
Әйтер сер дә шактый күп иде,
Почтальон да бармый инде сиңа,
Телефон да, Митта, юк инде...[3]

Беренче карашка, Х. Туфан биредә күпмедер дәрәҗәдә үз-үзен кабатлый шикелле. Әмма дөресендә бу язмышлар уртаклыгы, аларның үкенечле булуы белән бәйле охшашлык кына. Һ. Такташка багышланган шигъри шәлкем белән В. Митта үлеменнән соң язылган шигырьләрнең эчке рухы бөтенләй башкача. Беренчесендә үзара эчкерсез, кешеләрчә дуслык хисләре үзәктә торса, икенчесендә бердәй рәхимсез язмышка дучар булган кешеләрнең газап уртаклыгы өстенлек итә. Уйлар, хисләр Х. Туфанны кабат утызынчы еллар урталарына кайтара.

Чуваш галиме И. Иванов күзәтүләрендә бик яхшы күренгәнчә, утызынчы елларда татар һәм чуваш әдәбиятларының дуслыгы тагын да ныгый. Н. Шелеби, Я. Ухсай һәм И. Тхтиның Татарстан турындагы яратып язган шигырьләре, хикәя һәм очерклары барлыкка килә, татарчадан чувашчага һәм, киресенчә, чувашчадан татарчага әсәрләр тәрҗемә ителә. Укучылар белән очрашулар да уздырыла[1]. Аерым каләм әһелләренең дустанә мөнәсәбәттә булулары гомуми бәйләнешләрнең даими төс алуына китерә. Мәсәлән, Чувашиянең халык шагыйре Я. Ухсай болай дигән: "Утызынчы елларда, Мәскәүдә яшәгән чагында, мин һәркөнне диярлек дустым Муса Җәлил белән очраша идем. Мәскәү урамнары буйлап йөргәндә, ул Тукай шигырьләрен укырга ярата, безнең Ивановны татар теленә, ә Тукайны чувашчага тәрҗемә итәргә кирәклеге турында сөйли торган иде. Һәм Муса, чыннан да, үзенең сүзен онытмады. Аның булышлыгы белән, шагыйрь Шәрәф Мөдәррис тарафыннан тәрҗемә ителеп, "Нарспи" поэмасы сугышка кадәр үк татар телендә басылып чыкты"[2].

Чуваш шагыйрьләре үз чиратында татар каләмдәшләрен, алар аркылы Татарстанны үз иттеләр. П. Хузангай "Туган Татарстаным", "Хәсән Туфанга", "Татар шагыйрьләренә" дигән шигырьләрен иҗат итте. Я. Ухсай исә "Муса Җәлил", "Мине татар, диләр" кебек шигырьләрендә шулай ук татар дусларын үз итүен күрсәтә. Соңгысында М. Гафури, М. Җәлил, Х. Туфаннарны җылы итеп искә ала. Шул ук Я. Ухсай "Келбук карт" поэмасында гүзәл татар кызы Зәйнәп образын сурәтли. Аның чуваш егетенә булган мәхәббәте фаҗигага нигез булып чыга. Яшьлек, чибәрлек явызлык белән очраша. "Кельбук картның Әхмәт агай белән сөйләшүе" дигән бүлек шушы хәсрәтле вакыйганы хикәяләүгә корылган. Поэма, татар әсәрләренә дә хас булганча, мелодраматизм белән сугарылган. Шуңа күрә ул татар укучысы тарафыннан да үз күреп кабул ителде.

П. Хузангай үзе өчен дә Ватан булган Татарстанга карата күңелендә йөрткән хисләрен аеруча олы итеп белдерде:

Сагынам сине һаман, Казан,
Хәтердә син, хәтердә син.
Яшьлегемә күзем салсам,
Сине күрәм хәзер дә мин.
Кайларда сез, кордашларым,
Хәтерлимсез яшьлек таҗын?

Синдә туды, Нурлы Казан,
Минем иң беренче җырлар,
Кайда безнең өчәр телдә
Шигырь укып йөргән еллар? —
Һади Такташ, Гадел Кутуй
Миңа киңәш биргән чорлар!

Казан—минем кардәш калам,
Татарстан—матур, бай җир! —
Елдан-ел үс, балкы һаман,
Синең даның белсен бар җир!
Мин—бер улың, гүзәл калам!
Сиңа рәхмәт, сиңа сәлам!

Болай итеп бары Татарстанга аеруча үз итеп караган кеше генә әйтә ала. Педер Хузангай шундый кеше иде.

Дуслык, әлбәттә, бер-береңә мәдхия җырлаудан гына тормый. Дуслар тәнкыйть фикерләрен дә үзара туры һәм гадел әйтергә тиеш. Әдәби хәрәкәт тарихында без моның шактый гыйбрәтле

---

[1]Казан утлары.—1972.—N 2.—167 б.
[2]Шунда ук.

мисалларын да күрәбез. Әйтик, 1930 елда чыккан "Ун ел эчендә татар матур әдәбияты" альманахында Г. Кутуйның "Тәрҗемә әдәбият турында" дигән мәкаләсе урын алган иде. Бу мәкаләгә карата татар әдәбияты вәкилләре төрле-төрле фикерләр әйтеп чыктылар. Чуваш язучысы А.Федоров та шактый кызыклы уйлануларын укучыларга тәкъдим итте. Андагы фикерләрнең кайберләре бүген дә актуаль. Биредә күбрәк игътибар итүебез шуның белән аңлатыла. Иң әүвәл А. Федоров үзенең татар каләмдәшен хуплый. "Ул (Г. Кутуй—Ф. Г.) анда татар әдәбиятында җыен чүп-чарны тәрҗемә итү, сүз, фикер, образларны дөрес бирмәү яки бозу, сыйнфый яктан тотнаксыз булган нәрсәләр сайлау (мәсәлән, П. Романовны) һәм аларга ныклы марксизм тәнкыйтьләре ясамау белән көрәш мәсьәләсен вакытлы куя. Болар һәммәсе дә дөрес. Ләкин Кутуй моның сәбәбе нәрсәдән булганлыкны ачып салмый. Ул тик фактларны гына саный һәм күп кешеләрне үпкәләтергә теләми. Яхшы тәрҗемә ничек булырга тиешлеген дә әйтми. Ул телләрнең теория яклары турында бөтенләй таныш түгел булса кирәк. Һәрбер милли телнең үзенә аерым хосуссияте, башка телләрдә булмаган образлары, оборотлары бар. Шунлыктан бик яхшы тәрҗемә ителгән вакытта да әсәр үзенең төп оригиналында булган агышын, ачыклыгын югалта. Татардан чувашчага яки чувашчадан тәрҗемә иткән вакытта телнең бөтен нечкәлекләре белән җиңел тәрҗемә итәргә мөмкин. Ләкин урысчадан татарчага яки чувашчага тәрҗемә иткәндә алай ансат түгел. Бу телләрдә урысчада булган образларны аңлатырлык бай сүзләр табып булмый (бу фикер бәхәсле: чуваш теле ничектер, белмим, әмма татар телендә урыстагы теләсә кайсы образлылыкны бирү мөмкинлеге бар—Ф. Г.). Мәсәлән, Г. Ибраһимовның "Тирән тамырлар" дигән әсәренең беренче җөмләсендәге "Фәхрине үтереп ташладылар" дигән сүзләрне урысчага тәрҗемә итсәк, ул "Фахри убит брошен" рәвешендә чыга. Ләкин урысча болай дип сөйләмиләр. Ирекле-ирексез "Фахри был убит и брошен" яки "Фахри был убит" дияргә туры килә (Бу очракта урыс теленең мөмкинлекләре чиклелеге турында сүз бара түгелме?—Ф. Г.). Ә чувашчада ул "Фәхрия велләри прахрыч" рәвешендә чыга, анда тәгъбир бозылмый (Күргәнебезчә, биредә А. Федоров төрки телле милләтләр булган татар һәм чувашларның тел, әдәби образлылык, тәгъбирләр ягыннан бик якын булуы, аларга аралашып яшәү өчен мөмкинлекләренең зуррак икәнлеген күрсәтергә тели—Ф. Г.).

А. Федоров шул ук вакытта тәрҗемә өлкәсендә хәл итәсе мөһим мәсьәләләрне дә күтәрә. Алар хәзер дә хәл ителгән дип раслап булмый. Ул мәсьәләләрнең иң мөһимнәреннән берсе—тәрҗемә эшенә югары квалификацияле һәм фәнни яктан әзерлекле кешеләрне тарту. "Бу эш гади техник эш кенә түгел, тел һәм художество әдәбияты турында теоретик белем булмаганда, ул чын әдәби тәрҗемә булмаячак. Татар тәрҗемәчеләре арасында әле Көнбатыш Европа телләрен түгел, урыс телен дә фәнни яктан белүчеләр аз. Татар телендәге Көнбатыш Европа әдәбиятыннан булган тәрҗемәләр һәммәсе дә икенче кулдан, ягъни урыс теле аркылы үтеп чыкканнар. Шунлыктан аларны бик яхшы тәрҗемә дип санарга мөмкин түгел"[1].

Тагын шуңа игътибар итәргә кирәк: Г. Кутуй әлеге мәкаләсендә инде Шәрык әдәбиятларын татар укучыларына тәкъдим итү мәсьәләсен бөтенләй үк күтәреп тә тормый. Чөнки сүз бара торган елларда (1920—1930) татар әдәбиятының башлыча урыс әдәбиятына гына йөз тотарга тиешлеге кире каккысыз рәвештә хәл ителгән була. Әлеге мәкалә уңае белән сүз алып барганда, чуваш язучысы А. Федоров моңа борчылуын белдерә. "Безнең союз халыкларының телләреннән төрек, иран, әфган кебек көнчыгыш халыкларының телләренә тәрҗемә мәсьәләсен дә куярга вакыт булса кирәк. Чөнки матур әдәбиятның кешелек җәмгыятен яңадан төзүдә зур көрәш коралы икәнлеге мәгълүм"[2]. Биредә А. Федоровның берьяклы гына уйлавы игътибарны тарта. Ягъни ул төрек, иран, әфган халыклары телләреннән безгә тәрҗемә итү турында да түгел, бәлки безнең әдәбиятны аларга тәкъдим итү турында гына сүз алып бара. Әйтерсең лә, аларда безнең өчен рухи кыйммәтле берни дә юк кебек килеп чыга. Аның ни өчен шулай эшләргә чакыруы соңгы җөмләсеннән ачык аңлашылып кала. Безнең әдәбият, "кешелек җәмгыятен яңадан төзүдә зур көрәш коралы буларак", теге Көнчыгыш халыкларына кирәк булачак икән. Ә алар әдәбияты, имеш, безнең өчен файдалы була алмый. Утызынчы еллардагы мохиттә мондый карашта тору табигый иде.

Илнең үз эчендә рус әдәбиятының гегемонлыгы да нәкъ шундый максатлардан чыгып урнаштырылды. Югыйсә, 1917 елгы инкыйлабка кадәр татар әдәбияты да байтак халыкларның сүз сәнгатьләре өчен үрнәк булып хезмәт итте. Инде егерменче елларда татар әдәбиятының үз әһелләре дә мондый дәрәҗәне югалту белән килешергә мәҗбүр булдылар. Шул ук вакытта кайбер әдәби эшлеклеләрнең, ялган горурлык саклап, татар әдәбиятын үз кабыгы эченә бикләргә теләүләре дә бәйләнешләрнең чикләнә баруына китерде.

Сүз дә юк, тарихының зурлыгы, үсешенең катлаулылыгы белән татар әдәбиятына тиңләшерлек әдәбиятлар элеккеге СССРда әлләни күп түгел иде. Бу бигрәк тә Идел-Урал җирлегендәге

---

[1]Кызыл Татарстан.—1930.—6 август.

[2]Шунда ук.

милләтләр белән чагыштырганда шулай булды. Шуңа күрә татар әдәбияты вәкилләренең күпмедер дәрәҗәдә, яшьрәк әдәбиятлар белән аралашканда, үзләренә мөгаллимлекне алырга омтылулары аңлашыла да. Чуваш язучысы А. Федоровның язуына караганда, мондый хәл Гомәр Гали, Ф. С.-Казанлының үз-үзләрен тотышларында чагылган. "Г. Галиев һәм аның фикеренә кушылучы башка иптәшләр татар әдәбиятына карата "читтән" булган тәнкыйтьчеләргә татар әдәбият эшчеләре тарафыннан популярлаштырылган фикерләрдән узмаска тиеш, татар әдәбияты һәм татар тәнкыйтендәге дөрес булмаган якларны ачу аларның эше түгел, аларга аның белән маташмаска кирәк, диделәр. Ф. С.-Казанлы башка милләтләрдән дә татар әдәбияты белән кызыксынучылар һәм аны белүчеләр бар дигән сүзне ишетергә дә теләмәде. Вак милләт язучыларыннан берсе Тукай үлгән көнгә багышлап бер мәкалә язып китергәч, Фатих Сәйфи аны бөтенләй эшкә яраксыз дип тапкан. Чит милләтләрдән татар әдәбияты белән кызыксынуга каршы булган мондый караш бөтенләй бетерелергә тиеш"[1].

Төптән уйлап караганда, А. Федоров мәсьәләне бик дөрес куйган. Вак милләтләргә татар әдәбияты рухи азык бирә һәм алар аны үзләре өчен үрнәк булу ягыннан өйрәнәләр икән, алардан без отабыз гына бит. Бу хупланырга гына тиеш иде. Чөнки әдәби әсәрме ул, әллә фәнни хезмәтме, басылып чыккач, аны теләсә кайсы милләт вәкиле укырга хаклы булган кебек, аның турында фикер әйтеп чыгарга да хокукы бар. Бу җәһәттән чуваш язучысы, мәкаләдән күренгәнчә, гамәли адым ясый. Фикерен турыдан-туры әйтеп сала, хәтта Г. Ибраһимовның "Ерактан сәлам" дигән мәкаләсен гомуми фраза һәм теләкләрдән генә тора дип саный һәм бу "Г. Ибраһимов өчен һичбер гафу ителерлек түгел. Татарның карт язучысы булу сыйфаты белән аннан күбрәкне көтәргә мөмкин булыр иде",[2] ди.

Биредә чуваш авторының күпмедер хаклы булуын танырга туры килә. Татарстанның X еллыгы уңае белән язылган бу мәкалә авторының инде берничә ел читтә яшәгәнлеге сизелә, ул гомумән фикерләр әйтергә мәҗбүр. Г. Ибраһимов әдәбиятның шул еллардагы хәле турында Кырымга барып житкән кайбер гомуми мәгълүматлар буенча гына фикер йөртә ала. Ул әдәбиятның пролетар юнәлештә үсешен хуплый, бу уңайдан заман таләп иткән бурычлар куя. Шул ук вакытта мәкаләнең "каты авыру хәлемдә" язылды, дип, автор тарафыннан искәртеп куелуын да онытырга ярамый. Дөресен әйткәндә, "Ерактан сәлам" мәкаләсе "Ун ел эчендә татар матур әдәбияты" җыентыгында нинди дә булса бер рәвештә ктанашмый калмау өчен генә язылган. Ник дигәндә, ун ел эчендә әдәби хәрәкәткә йомгак ясаучы бу хезмәттә шул вакытның күренекле әдибе катнашмау дөрес аңлашылмас иде. Ныклы анализга нигезләнмәгән бу язмадан А. Федоровның (аның гына да түгел) канәгать булмавы аңлашыла, әлбәттә.

Шулай да Г. Ибраһимов мәкаләсенең кыйммәтле якларын да күрмәү мөмкин түгел. Аның әһәмияте шунда, ул "стиль-тип-характер-сурәт-композиция кебек форма ягы белән дә"[3] кызыксына, аларны камилләштерү мәсьәләсен дә күтәрә. Әйе, сирәк булса да бу елларда да сәнгатьлелек мәсьәләләренә игътибар ителә иде.

Шагыйрь һәм аның шигыре нинди булырга тиеш? Бу турыда, әлбәттә, егерменче еллардан ук бик күп бәхәсләр бара. Х. Сирин, мәсәлән, чувашның егерме бер яшьлек шагыйре П. Хузангай турында язганда, аның әсәрләренең сәнгатьчә эшләнешенә соклана. "Аның язган шигырьләре бер төрле көчәнеп язган нәрсәләр түгел, ә, киресенчә, алардан ерак качкан табигый бер осталык белән агып торган чуваш теленең бөтен байлыгыннан файдаланып язылган шигырьләрдер. Форма ягына килгәндә, әле безнең татар әдәбиятында күрелмәгән бер форма-аркынлы ритмнар белән язылган аның шигырьләрен үз формаларын саклаган хәлдә татарчага күчерергә дә мөмкин түгел. Чуваш телендә алар шундый матур музыкалы гармонияле төзелгәннәр ки, әгәр дә гел шул көе татарчага күчерә алсак, татар әдәбиятында беренче матур шигырьләр, шиксез, Хузангай шигырьләре булыр иде"[4].

Күрәбез, татар шагыйре чуваш каләмдәшенең иҗатына соклана. Аның әсәрләренә бәя бирүе без үзебездә Такташны сыйфатлавыбыз белән бик аваздаш. Шул ук вакытта Х. Сирин егерменче еллар ахыры өчен хас булмаган фикерләр әйтергә дә җөрьәт итә. "Аның (П. Хузангайның—Ф. Г.) икенче бер ягы да бар әле. Ул да булса, аның шигырьләрендә агитация булмавыдыр. Әле безнең күп яшь язучыларыбыз шул агитациягә батып яткан бер вакытта (1925) Хузангай чын мәгънәсе белән сәнгатьчә эшләнгән шигырьләр бирде. Бу сүзләрдән Хузангайны революционный нәрсәләр язмый икән, яхут идеология ягыннан мактарлык түгелдер дип тә уйларга ярамый, ул революционный нәрсәләрне тәмам җиренә җиткереп—сәнгатьчә эшләп бирә, "Сундал" журналында басылган "Егерме алты" дигән поэмасы мисал була ала"[5].

[1]Кызыл Татарстан.—1930.—6 август.
[2]Шунда ук.
[3]Ибраһимов Г. Әсәрләр.—К.: 1978.—5.—509 б.
[4]Яналиф.—1928.—N 5.—8 б.
[5]Шунда ук.

П. Хузангай иҗаты мисалында татар язучылары колагына мондый фикерләр әйтү, безнең шагыйрьләрнең "агитациягә батуларын" күрсәтеп бирү—яңа сүз иде. Юк, Х. Сирин дә—шул чор идеологиясен хуплаучы, ләкин аны сәнгатьчә бирүне өстен күрүче. Чөнки турыдан-туры, маңгайга терәп үгетләүнең сәнгатьлелектән ерак торуын күреп тора ул. Без заманында мәгърифәтчеләрнең әнә шулай үгет-нәсихәт белән мавыгуларын аларның кимчелеге итеп күрсәтә идек. Совет хакимиятенең беренче унъеллыкларында каләм әһелләре шул ук мәгърифәтчеләрнең кайбер алымнарын корал итеп алырга тиеш булдылар. Ә. П. Хузангай, Һ. Такташ кебек сәнгатьчә язарга омтылучылар соры массадан нык аерылып торды. Шуңа күрә аларга һөҗүм аеруча оешкан төс алды да.

Алдарак телгә алынган чыгышында чуваш авторы А. Федоров тагын бер әһәмиятле мәсьәлә күтәрә. Күрше мари, удмурт, чуваш, мордваларның байтагы татар әдәбияты әсәрләрен егерменче елларда оригиналында укыганнар, чөнки алар татар телен белүгә шактый әһәмият биргәннәр. Чуваш язучысы А. Федоров исә татар язучыларына да мари, удмурт, чуваш, мордва әдәбиятлары белән якыннан танышып баруның кирәклеген әйтә. Алар белән эшне яхшы белеп сөйләшү өчен, татарларга да бу телләрне белү ихтыяҗын күрсәтә. Чыннан да, бу—бәйләнешләрне тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрүнең иң нәтиҗәле юлы. Моны Зариф Бәшири эшчәнлеге дә раслап тора. Әлеге татар язучысы чуваш телен ана теле дәрәҗәсендә камил белә. Ул—чуваш язучылары әсәрләрен татарча яңгыратуга шактый өлеш керткән тәрҗемәче дә. Соңгырак чорларда бу игелекле өлкәдә Кави Латыйп нәтиҗәле эшләде.

Чуваш шагыйре Николай Шелеби исә 1930 елда, татар язучылары әсәрләрен тәрҗемә итеп, үз ана телендә бастырып чыгарды. Ул туплаган җыентыкта Һ. Такташ, Г. Кутуй, Г. Минский, М. Әмир, З. Бәшири, Н. Баян, М. Максудларның әсәрләре тупланган. Тәрҗемәченең бу хезмәте матбугатта да уңай бәя алды, "тәрҗемәдә сәнгатьчә югалтулар сизелми" дигән нәтиҗә ясалды[1].

Г. Гали сүз башы белән чыккан бу җыентык үз вакытында чуваш телендә укучылар тарафыннан яратып кабул ителде.

Инде әйтелгәнчә, татар язучысы һәм журналисты Зариф Бәшири ике халыкның сүз сәнгатен үзара якынайту эшенә сизелерлек өлеш кертте. Ул яшьтән үк чувашлар белән аралашып үсә, аларның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен яхшы белә. Аның беренче хикәяләренең берсе "Чуваш кызы Әнисә" дип атала. Ул Сәгыйть Рәмиев тәкъдиме белән язылган. Анда, билгеле булганча, чуваш һәм татар халыкларының дуслыгы чагыла. Татар карты Тажи һәм чуваш Аксаби, татар егете Зәрби һәм чуваш кызы Әнисә милләт аермыйлар, дустанә яшиләр. Тажи карт (Зәрбинең бабасы) бу дуслыкны нык сакларга өнди. Зәрби-Әнисә мәхәббәте бу дуслыкның югары ноктасы буларак кабул ителә.

1928 елда Татарстанда "Күрше милләтләр әдәбиятыннан" дигән серия чыгару башлана. Аның беренче китабы "Чуваш әдәбияты" дип атала. Аны З. Бәшири төзи, үзе үк әсәрләрне татар теленә тәрҗемә итә. Җыентыкка Н. Шелеби (Полорусов Николай Иванович), Н. Шубосинни (Васильев Николай Васильевич), Хумма Семен (Фомин Семен Фомич), П. Хузангай (Петр Петрович), Н. Васянка (Васянка Никифер Тарасович), В. Алагер (Осипов Василий Осипович), Трубина Марфа Дмитриевна кебек авторларның әсәрләре тупланган. Ш. Мөдәррис тә чуваш әдәбияты классигы К. Ивановның "Нарспи" әсәрен татарчага тәрҗемә итеп бастырды.

Үз әсәрләрендә чуваш милләте кешеләрен гәүдәләндергән татар каләм әһелләре З. Бәшири белән генә чикләнми, әлбәттә. Безгә таныш А. Федоров, "Тирән тамырлар" романында чуваш Полорусов образын сурәтләгәне өчен, күренекле татар әдибе Г" Ибраһимовка җылы сүз әйтә. "Ул анда,—ди автор,—милли тенденция һәм шартлардан башка татар, урыс, чуваш һәм башка милләт эшчеләрен булганынча бирергә тырыша"[2]. Г. Бәширов "Намус" романында алдынгы игенче Наташаны, К. Нәҗми "Язгы җилләр" романында Егор образын аерым җылылык белән сурәтләделәр. К. Латыйп "Йолдыз таккан егет" (1972) повестенда милләте буенча чуваш булган космонавт Андриан Николаев образын гәүдәләндерде. Аны чуваш теленә Владимир Ухли тәрҗемә итте.

Шул рәвешле, татар һәм чуваш әдәбиятларының үзара хезмәттәшлеге хәзер дә дәвам итә. Чуваш каләмдәшләребез Г. Тукай юбилейларына килсәләр, татар язучылары Я. Ухсайның бәйрәмендә катнаштылар. Чабаксарда Р. Харисның шигъри кичәсе уздырылса, Татарстанның Чирмешән районында Порфирий Афанасьевның 60 яше зурлап билгеләп үтелде. 2003 елның март аенда Чувашстанда татар әдәбияты көннәре уздырылу бу дуслыкның тагын да көчәеп дәвам итүен күрсәтте. Быел яз чуваш дусларны без үзебездә кабул итәчәкбез. Рәхим итегез, кадерле ут күршеләребез!

---

[1]Гали Гази улы. Татар әдәбияты чуваш телендә // Кызыл Татарстан.—1930.—27 июль.
[2]Кызыл Татарстан.—1930.—6 август.

70—МӘГАРИҖ (БАСКЫЧ БУЙЛАП) СҮРӘСЕ

(Мәгариҗ сүрәсе 44 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Мәгариҗ–баскычлар буйлап өскә менү, дәрәҗәгә күтәрелү мәгънәләрен эченә ала.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. Берәүсе хәтәр җәза килүен *(юри генә)* сораган булды. **(2)** Кяферләр өстенә төшәчәк *(бу газапны)* беркем дә кире кайтара алмый. **(3)** Ул *(газап)* бөтен дәрәҗәләргә ия Раббы тарафыннан булачак. **(4)** Фәрештәләр дә, рух та *(Җәбраил дә)* дәрәҗә баскычлары буйлап, озынлыгы илле мең ел булган араны бер көндә менеп җитәрләр. **(5)** Шуңа күрә, син *(Мөхәммәд, кяферләрнең җәберләренә)* сокланырлык сабырлык белән түз, чыда. **(6)** *(Кяферләр)* моны *(Кыямәтне)*: хәзер генә килмәс, ул әле ерак, диделәр.

7. Без аны якын итеп күрәбез. **(8)** Ул көнне Күк йөзе эрегән бакыр төсенә керер. **(9)** Ул көнне таулар тетелгән йон кебек булачак. **(10)** Һичбер кеше икенчесенең хәлен белмәс *(сорашмас)*. **(11)** Алар бер-берләрен күрер *(ләкин хәл-әхвәл сорашу булмас)*. Ул көнне гөнаһкяр җәзадан котылыр өчен угылларын, **(12)** хатынын, ага-энесен, **(13)** үзенә торырга куыш һәм ашарга ризык биргән нәсел-нәсәбен, **(14)** Җир йөзендә кем бар–барысын да корбан итәргә хәзер булыр. *(Бары тик үзе генә котылсын.)* **(15)** Ләкин–ни файда! Җәһәннәм–*(кяферләр өчен махсус хәзерләнгән)* тәмуг уты **(16)** аны *(гөнаһлы кешене)* башыннан аягына кадәр ялмап алыр. **(17)** Ул *(коточкыч ялкын хәтәр кодрәт илә иманнан, Хактан)* качканнарны үзенә тартып-чакырып торыр. **(18)** *(Байлык, мал)* җыеп, йозакта бикләп тотканнарны *(тәмуг ялкыны)* үзенә суырыр. **(19)** Хактыр ки, кеше хөсетле һәм тәкатьсез итеп, һәм сабырсыз, түземсез итеп яралтылган зат. **(20)** Башына бәла *(малсыз калу, хасталык)* килсә, ярдәм сорап акыра башлый. **(21)** Аңа байлык килсә, саранлана.

22, 23. Һәрдаим намазда Аллаһка сәҗдә итүчеләр андый түгел. **(24)** Малларының мәгълүм бер өлеше **(25)** соранучы һәм сорамаучы мохтаҗларга тиеш, дип гамәл кылганнар *(хәер-садәка, зәкят биргәннәр)*, **(26)** хисап һәм җәза көненең киләчәгенә инанганнар, **(27)** Аллаһның *(җәзасыннан)* курыккан, **(28)**–хактыр ки, Раббының газабыннан беркем дә читтә калмас *(беркем дә: мин–мөселман, миңа Аллаһ җәза бирмәс, дип курыкмыйча гына яшәргә тиеш түгел)*; **(29)** гыйффәтләрен саклаган кызлар; **(30)** үз хатыннарына, җарияләренә якынлык кылганнар гаепләнмәс. **(31)** Әмма болардан тыш *(башка никахсыз хатыннар, чит-ят кызлар)* артыннан йөрүчеләрне Без хәттин ашканнар *(хәләлдән харамга күчкәннәр)* рәтенә куячакбыз. **(32)** Әманәт саклаганнар, антка тугры булганнар, **(33)** дөрес шаһитлек кылганнар, **(34)** дөрес итеп намаз укыганнар, **(35)** барысы да *(шәрәф вә гыйззәт алып)* җәннәт бакчаларында йөрер.

36. *(Ий, Мөхәммәд)* ни булган аларга *(кяферләргә, мөшрикләргә, монафикъларга)*? Акылдан язганнармы? **(37)** Алар өерелешеп, уңнан да, сул тарафтан да синең янына ыргыла. **(38)** Алар шулай итеп, җәннәт бакчаларына керергә ашкынамы? **(39)** Өметләре бушка! Алар үзләренең нинди токымнан *(балчыктан)* ясалганын бик яхшы белә. **(40)** Юк! *(Эш алар уйлаганча булмас.)* Көнчыгыш-көнбатыш *(бөтен галәм)* хуҗасының исеме белән ант итеп әйтәмен ки: **(41)** әлбәттә, Без алар урынына үзләреннән дә яхшырак халыкны китереп куярга кодрәтлебез; бу эштә Бездән алга чыга алырлык куәт юк. **(42)** *(Ий, Мөхәммәд)* хәзер син инде аларны ташла. Вәгъдә ителгән көнгә *(Кыямәткә)* чаклы гөнаһ эчендә типтерә-уйный торсыннар. **(43)** Ул көнне алар күзләрен шакмакландырып, бер ноктага текәп, каберләреннән кубарылып чыгар да, шашып йөгерә башлар. **(44)** Сонра хурлыктан карашлары аска текәлер, алар рисвай

булыр. Менә бу көн аларга *(күптән, фани дөньяда ук)* вәгъдә ителгән Мәхшәрдер.

71—НУХ (НУХ) СҮРӘСЕ

(Нух сүрәсе 28 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Сүрә хәзрәти Нух пәйгамбәребез исемен йөртә.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1.–Башларына хәтәр җәза килмәс борын, үз халкыңны кисәтеп-куркытып куй,–дип, Нухны үз кавеменә күндердек. **(2, 3, 4)** Нух *(халкына)* әйтте:

–Әй, кардәшләрем, сез шик тотмагыз,–диде.–Мин сезне: Аллаһка буйсыныгыз, Аңа каршы баш күтәрүдән сакланыгыз, *(сөйләгәннәремә ышанып)* миңа иярегез, Аллаһ гөнаһларыгызның бер өлешен генә булса да ярлыкасын һәм сезне билгеләнгән вакытка чаклы яшәтсен, дип ачык рәвештә кисәтүче бер кешемен. Мәгълүмдер ки, Аллаһ вәгъдә иткән *(Кыямәт әҗере)* күпкә кичектерелмәс. Их, сез *(Кыямәтнең нинди икәнен)* белсә идегез! *(Бервакытта да гөнаһ кылмас идегез.)* **(5)** Ахырда Нух әйтте:

–Шунысы хак, Раббым, мин халкымны кич-көндез иманга чакырдым. **(6)** Ләкин минем чакыруым аларны Синнән тагын да ераклаштырды. **(7)** Чыннан да, *(иманга килегез)* Аллаһ гөнаһларыгызны ярлыкар,дип күпме генә өндәсәм дә, бармаклары белән колакларын томалап, чапаннары белән башларын каплап, аяк терәп каршы торалар, тәкәббер рәвештә азгынлыкларын дәвам итәләр. **(8)** Шуннан соң мин аларны катырак тавыш белән чакырырга тотындым. **(9)** Янә дә мин алар белән ачыктан-ачык та, аулакта да кат-кат сөйләштем, вәгазь укыдым. **(10)** Шуннан әйттем: Аллаһтан ярлыкау сорагыз, Аллаһ–мәрхәмәтле ярлыкаучы, дидем. **(11)** *(Яманлыктан баш тартсагыз)* Аллаһ өстегезгә мул яңгыр яудырыр, дидем. **(12)** Сезнең малларыгызны, угылларыгызны арттырыр, сезгә бакчалар *(җимеш бостаннары)*, чишмәләр бирер, дидем. **(13)** Нишләп соң сез Аллаһны кирәгенчә олыламыйсыз? **(14)** Гәрчә, Ул сезне үсешнең төрле-төрле шәкелләрендә яралтты. *(Балчыктан Адәмне, аннан Һаваны, аннан аналыкта яралгыны, туыны, үсүне, картаюны, әҗәлне бар итте).* **(15)** Күрмисезмени, Аллаһ җиде күкне бер-берсенә яраклаштырып ясады. **(16)** Анда Ай нур чәчә, Кояш та кандил кебек яктырта. **(17)** Аллаһ сезне туфрактан шытып чыккан үсемлек кебек итеп үстерде. **(18)** Ахырда ул сезне тагын туфрак эченә кертәчәк. **(19)** Аллаһ Җирне сезнең өчен түшәк-ястык кебек итеп кабартты.

20. Җир өстендәге юллардан рәхәтләнеп йөрсеннәр дип. **(21)** Нух әйтте:

–Йа, Раббым, шунысы хак, алар миңа дошман булды. Маллары, балалары белән алар яманлыктан башка нәрсә китерми торганнарга иярделәр. **(22)** Болары да мәкерле хәйләләр кора башлады. **(23)** *(Нух халкы бер-берсенә әйтте):*

–Аң булыгыз! Табына торган сыннарны ташламагыз. Вәд, Суваг, Йәгус, Йагук һәм Нәсерләрдән ваз кичмәгез,–диделәр. **(24)** Шулай итеп, алар байтак кешеләрне юлдан яздырды. *(Йа, Раббым)* син ул залимнәргә адашудан башка һичнәрсә арттырып бирмә.

25. Шушы гөнаһлары аркасында алар суга батырылды. Ахырда утка атылдылар. Аллаһтан башка һичбер ярдәмче табалмадылар. **(26)** Нух болай диде:

–Йа, Раббым, йорт тотучы кяферләрнең берсен дә Җир йөзендә калдырма. **(27)** Әгәр дә син аларны калдырсаң, алар бәндәләрне юлдан яздырыр һәм алар яман кяферләрдән башка бала тудырмаслар. **(28)** Йа, Раббым, минем үземне, анамны, атамны, иман китереп, өемә кергән кешеләрне, мөэмин ирләрне, мөэминә хатын-кызларны, зинһар, ярлыка. Явыз залимнәргә җәзадан башка нәрсә арттырма.

72—ҖЕН (ҖЕН) СҮРӘСЕ

(Җен сүрәсе 28 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Бәгъзе бер җеннәрнең дә Корьән тыңлаганнан соң, иман китереп, мөселман булганнары турындагы сүрә.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

–Җеннәр кавеменең бер төркеме *(мин Коръән укыганда)* тыңлап, иман китергән икән. Бу турыда мин вәхий аша белдем,–диген.

Җен кавеменнән булганнарның бер төркеме болай дигән:

–Чыннан да, без тугры юлга өнди торган, гадәттән тыш гүзәл Коръән сүзләрен тыңладык **(2)** һәм иман китердек. Моннан соң без Раббыбызга тиң затлар эзләмибез. **(3)** Хактыр ки, Раббыбызның бөеклеге һәр бөеклектән дә бөек. Аның хатыны да, баласы да юк. **(4)** Хактыр ки, ахмак бер наданыбыз *(Иблис)* Аллаһ хакында хәттин ашкан уйдырмалар, ялган сөйләп йөри иде. **(5)** Гәрчә, без–кешеләр дә, җеннәр дә Аллаһ турында ялган түгел, дөресен сөйли, дип уйлый идек. **(6)** Шунысы да чынбарлык, кайбер кешеләр, кайбер җеннәргә ияреп, үзләренең азгынлыкларын арттыра иде. **(7)** Алар да сезнең кебек үк, Аллаһның кабат терелтәсенә ышанмый иде. **(8)** Хактыр ки, без *(җеннәр)* Күккә менәргә *(Аллаһ белән фәрештәләрнең сөйләшкәнен тыңларга)* тырышып карадык. Ләкин Күкнең хәтәр сакчылар-каравылчылар белән һәм атыла торган утлы йолдызлар белән тулганлыгын күрдек. **(9)** Яшеренеп тыңлар өчен без *(Күкнең)* уңай почмакларына постык. Ләкин тыңларга теләгәнне анда ут чыбыркысы сагалап тора икән. **(10)** Хактыр ки, без аңламый калдык: җирдәге кешеләргә зыян-зәхмәт китерер өчен шулай максат ителгәнме, әллә Раббы аларга игелек кылырга телиме? Белгән юк. **(11)** Хакыйкатән, безнең арада игелекле булганнар да бар, гөнаһлыларыбыз да юк түгел. Без төрле-төрле юллар белән киттек. **(12)** Без шуны да аңладык, Җирдә булсак та, Күккә менсәк тә, без Аллаһны бичара хәлгә калдырып, җиңә алмаячакбыз. **(13)** Хактыр ки, без *(Коръәнне)* тыңлап, иман китердек. Аллаһка иман китергән зат әҗердән дә мәхрүм калмас, нахакка рәнҗетелмәс тә. **(14)** Чынлыкта, кайсыбыз мөселман булды, кайсыбыз юлдан язды. Тугры юлны эзләп тапканнар–мөселман булыр. **(15)** Гаделсез залимнәр җәһәннәм кисәве булыр.

(«Җеннәр» дип әкиятләрдәге һәм кешеләрнең күз алдына китерә торган «койрыклы җеннәр» күз алдында тотылмый. Мәүланә Али нөсхәсендә «җеннәр» дип атала торган халыклар–кешеләр турында сөйләнә. Бу «җеннәр» астрологлар, фикерләре белән Күккә менеп, сихер вә ырымнары белән халыкны алдаучы кавем икәнлеге әйтелә.)

16. Әгәр дә алар тугры юлдан чыкмаенча барса, әлбәттә, аларга Без мул итеп яңгыр яудырыр идек. **(17)** Шулай итеп, Без аларны сынап карар идек. Раббыны зикер итүдән баш тарткан кешене Аллаһ хәтәр газапка тартыр.

18. Барча мәчетләр бары тик Аллаһка гыйбадәт кылу урыны. Шуңа күрә, сез Аллаһка тиң дип, һичбер башка затка табынмагыз. **(19)** Хакыйкать, Аллаһның колы *(Мөхәммәд)* Раббыга гыйбадәт кылыр өчен калыкканда *(Коръән тыңлар өчен килгән җеннәр)* араларыннан җил үтмәслек булып, тыгыз урнашты.

20. Әйт син:

–Мин бары тик Раббыма дога кыламын. Аңа һичбер тиндәш тотмам,–диген. **(21)** Әйт син:

–Хактыр ки, мин сезнең өчен зарар да, файда да эшләр дәрәҗәдәге зат түгелмен,–диген. **(22)** Әйт син:

–Хактыр ки, *(Көферлек кылсам)* мине Аллаһның җәзасыннан берәү дә коткара алмас. Аллаһтан башка сыеныр зат мин табалмам,–диген. **(23)**–Минем кулымнан килгән эш–Аллаһның хөкемнәрен сезгә ирештерү. Аллаһка, Пәйгамбәргә каршы баш күтәргән кеше, һичшиксез, җәһәннәм утына лаек булыр, ул анда мәңгегә калачак.

24. Ниһаять, алар вәгъдә ителгән җәзаны күргәч, кемнең ярдәмчеләре аз, кемнеке күп икәнен белер.

25. Әйт син:

–Вәгъдә ителгән газапның якынмы, әллә Раббы аны озак вакытка кичектергәнме икәнен мин белмим,–диген.–**(26)** Яшерен серләрне бары тик Ул гына белә. Һәм Аллаһ яшерен серләрнең ачкычын беркемгә дә бирми. **(27)** Үзенә аеруча якын Пәйгамбәреннән башка. Ул *(Пәйгамбәрнең)* алдына да, артына да күзәтүчеләр *(сакчылар)* куелган. **(28)** Шулай итеп, аларның *(пәйгамбәрләрнең)* Раббы күндергән әмерләрне дөп-дөрес итеп җиткерәме икәнлекләрен барлар өчен, Аллаһ Пәйгамбәр янында булганнарның барысын да гыйлеме белән уратып алган вә һәрберсенең санын берәмләп теркәгән.

73—МҮЗӘММИЛ (ЯБЫНГАН) СҮРӘСЕ

(Мүзәммил сүрәсе 20 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Кайбер аятьләре Мәдинәдә иңгән. Мүзәммил–капланган, бөркәвеч ябынган, баштанаяк төренгән, дигән мәгънәдәге сүз.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. Ий, бөркәвеч ябынган (*Мөхәммәд*)! **(2)** Төннең бер өлешендә йоклама, намаз укы. (3) Төннең яртысы яки аннан азрак вакытында гыйбадәт кыл. **(4)** Яки төннең яртысыннан күбрәк вакытында Коръәнне ашыкмыйча, ачык итеп укы. **(5)** Хактыр ки, Без сиңа әһәмияте гаять зур, сүз (Китап) йөкләрбез.

6. Төнлә тору (*Коръән уку*)–савап мәсьәләсендә гаять тәэсирледер, сүзләрнең куәтен арттыра. **(7)** Чөнки көндезен синең мәшәкатьләрең күп була. **(8)** Раббыңның исемен әйтергә онытма. Бөтен барлыгың белән Аңа юнәл. **(9)** Ул–Көнчыгышның да, Көнбатышның да Раббысыдыр. Аннан башка Аллаһ дип әйтерлек кодрәт иясе юк. Шулай булгач, бары тик Аллаһ химаясенә күчегез. **(10)** Аларның (мөшрикләрнең) сүзләрен сабыр тыңла. Һәм алардан бик әйбәтләп кенә аерыл. **(11)** Байлык эчендә йөзүче һәм хак динне ялган әйтүчеләрне Минем хөкемемә калдыр. Һәм аларга бераз вакыт бир. **(12)** Безнең янда алар өчен богаулар һәм ут бар. **(13)** Бугазларыннан үтмәс ризык вә хәтәр җәза да бар. **(14)** Ул көнне Җир йөзендәге таулар тетрәр. Таулар агып китә торган ком кебек булыр.

15. Фиргавенгә бер пәйгамбәр күндергән кебек, сезгә дә нәкъ шулай, кылмышларыгызга шаһитлек кылачак бер Пәйгамбәр күндергән идек. **(16)** Әмма Фиргавен ул пәйгамбәргә каршы чыкты. Без дә аны авыр, читен рәвештә җәзаладык.

17. Көфер итсәгез, балаларыгызның чәчен агартырлык дәрәҗәдәге хәтәр көндәге җәзалардан ничек котыла алырсыз икән? **(18)** Ул дәһшәттән хәтта Күк йөзе ярылачак. Аллаһның вәгъдәсе максатына ирешәчәк. **(19)** Менә бу аңлаткан нәрсаләребез–үгет, гыйбрәттер. Теләгән кеше Раббыга алып баручы тугры юлны тотар.

20. (Ий, Мөхәммәд) хактыр ки, синең белән бергә булган кешеләрнең, аз дигәндә, төннең өчтән икесен, кайчакларда яртысын, кайчакларда өчтән берен йокламыйча намаз укыганнарын Раббы белә. Төн һәм көн вакытларын Аллаһ билгели. Ул сезнең төн вакытларын чамалап бетермәгәнегезне белә, шуңа күрә, Ул тәүбәләрегезне кабул итә. Коръәннең үзегезгә җиңел булган өлешләрен укыгыз. Арагызда хаста кешеләр дә, Аллаһ бирәчәк ризыкны эзләп, сәфәр чыкканнар да бар һәм Аллаһ юлында сугышып йөрүчеләр дә бар. Аллаһ аларның барысын да белә. Алар да (шартларына күрә) Коръәннең үзләренә күлай өлешләрен генә укысын. Намазны дөрес укыгыз. Зәкятне биреп барыгыз вә Аллаһ әҗер бирсен дип, алдан ук игелек кылыгыз. Кылган игелегегез сезнең өчен тагын да хәерлерәк әҗер булачак. Аллаһтан ярлыкау сорагыз. Шик юк, Аллаһ–ярлыкаучы, чиксез мәрхәмәтле.

74—МҮДӘССИР (БӨРКӘНГӘН) СҮРӘСЕ

(Мүдәссир сүрәсе 56 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Мүдәссир–каплаулы, уранган, бөркәнгән, дигән мәгънәләрдәге сүз.)

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

1. Ий, бөркәнеп йөрүче (*Рәсүлем*)! **(2)** Аягыңа бас һәм халыкларны үгетлә. **(3)** Вә Раббыңны олыла. **(4)** Киемеңне пөхтә тот. **(5)** Нәҗеслектән вә яманлыктан ваз кич. **(6)** Кылган игелегең өчен артык хак таләп итмә. **(7)** Раббыңның ризалыгын аласың килсә, түз, сабыр ит. **(8)** Сур быргысына өрелгән көн **(9)** иң кыен көн булыр. **(10)** Ул көн кяферләр өчен бик авыр булыр.

11. Ялгызы гына яралтылган теге кеше белән икебезне бергә (*хөкемебезгә*) калдыр. **(12)** Мин аңа күп төрле мал биргән идем. **(13)** Һәм үзе янында гына тора торган тәүфикълы балалар бирдек. **(14)** Аңа тормышта киң мөмкинлекләр ачтык. **(15)** Шулар өстенә дә малын арттырырга теләп, комсызлана башлады. **(16)** Юк инде, җитте! Ул үҗәт рәвештә аятьләребезгә каршы торды. **(17)** Мин аның өстенә тау хәтле (җәзасы) йөкләячәкмен. **(18)** Чөнки ул мәкерле тозаклар уйлады һәм төгәл хисап белән тозак корып куйды. **(19)** Каһәр төшсен аңа! Ул мәкерләр корды.

(20) Ахырда да, әче каһәр суккыры, мәкерләрен кора бирде, ничек кенә кора иде әле. **(21)** Аннан соң әтрафына бакты. **(22)** Һәм кашларын җыерды, чырае җимерелде. **(23)** Аннан соң артына борылып, тәкәббер рәвештә: **(24)**

–Бу,–диде,–(*Коръән*) борынгылардан калган сихер галәмәтләреннән башка нәрсә түгел! **(25)** Хактыр ки, бу адәм уйлап чыгарган сүз генә.

26. Аны Сәкаргә (җәһәннәмгә) ташлаячакмын. **(27)** Син Сәкарнең ни икәнен беләсеңме? **(28)** Сәкар–ул шундый тәмуг–берни калдырмый бөтенләй яндырып бетерә торган, гәүдәне яңадан үз хәленә кайтарып, тагын яндыра торган җәһәннәм. **(29)** Тиреләрне көйдерә. **(30)** Анда унтугыз фәрештә булыр. **(31)** Без янып торган утның сакчыларын бары тик фәрештәләрдән генә сайлап куйдык. Аларның санын да кяферләрне каушатыр өчен, шулай итеп, үзләренә китап бирелгән халык (*Мөхәммәдкә, Коръәнгә*) ышансын дип, иман китергәннәрнең иманы тагын да ныгысын өчен, үзләренә Китап бирелгән халык һәм мөэминнәр шиккә калмасыннар, дип, рухларында хасталык булганнар һәм кяферләр:

–Аллаһ моның белән ни әйтергә тели?–дип баш ватсыннар өчен.

Менә шулай итеп, Аллаһ тугры юлга басарга теләмәгәнне адаштырып, теләгәнне тугры юлга күндерер. Раббының күпме гаскәре барлыгын Аның Үзеннән башкасы белмәс. Болар инсаннар өчен ап-ачык кисәтүләр булыр.

32. Хәер, (алар сабак алмастыр) Ай исеме белән, **(33)** узып бара торган төн, **(34)** атып килә торган таң исеме белән әйтәмен ки, **(35)** (*Сәкар*) ул хәтәр кисәтүләремнең берсе генә. **(36)** Кешеләрне куркытыр (*гөнаһ кылудан тыяр*) өчен, **(37)** игелек кылуда алга киткәннәр өчен дә, игелек кылудан тәмам артта калганнар өчен дә кисәтү, хәтәр афәтләрнең берсе Сәкар булыр. **(38)** Һәр җан иясе үзенең гамәлләренә (гөнаһларына) бәйләнгән. **(39)** (*Гамәл дәфтәре*) уң яктан бирелгәннәрдән башка. **(40, 41, 42)** Алар җәннәтләрдә булыр. Һәм җәһәннәмгә кергән танышларыннан гөнаһкярларның хәлен сораштырырлар.

–Сез ничек итеп Сәкаргә килеп эләктегез?–дип. **(43)** Гөнаһлылар әйтер:

–Без намаз укымадык. **(44)** Фәкыйрьләрне ашатмадык. **(45)** Көфер сөйләгәннәр арасында без дә көфер сөйләдек. (46) Кыямәт көнен ялган, уйдырма,–дидек. **(47)** Ниһаять, безне үлем килеп якалады.

48. Шәфәгать итәргә (якларга) теләгәннәрнең шәфәгате (яклавы) аларга һичбер файда бирмәс. **(49)** Ни өчен соң алар гыйбрәт алудан (ялганны хактан аерырга өйрәнүдән) качалар? **(50, 51)** Әйтерсең лә, алар арысланнан качып баручы кыргый ишәк өере. **(52)** Әлбәттә, аларның һәрберсе үзләренә генә Китап иңдерелгәнне тели. **(53)** Булмас! Иң аянычы, алар Ахирәт көнендә булачак җәзалардан курыкмый. (*Шуңа күрә дә, алар һич тә вөҗдан газабы кичермәенчә җинаять кыла.*) **(54)** (*Нишләмәк кирәк–үз ихтыярлары*) Коръән–ул вәгазьләр-кисәтүләр Китабы. **(55)** Теләгән кеше аннан үгет-сабак алыр. **(56)** Аллаһ ихтыярыннан башка бирәү дә Коръәннән сабак ала алмас. Аллаһның җәзасыннан коткару да Аллаһ ихтыярында. Ярлыкаучы да Аллаһ кына.

Ғәп
Фән

КОРЪӘН КӘРИМНЕҢ ТАТАР МӘКАМЕ

Утырып уйлар уйладым да, "Казан утлары"нда Коръәне-Кәрим шәриф ләренен Рабит әфәнде Батулла җәнаблары тарафыннан татар телендә бирелә килүенә үтә дә куанганлыктан, Изге Китап мәкамен рәхмәтлебез Бакый ага Урманче укыган шәкелдә бирүне мәгъкуль күрдем.

"Шәкел" дигәнем, 33 сүрә "Әхзаб"ның ("Төркемнәр") 40-44 аятьләре белән 37 сүрә "Саффат" ("Сафлар") 180-182 аятьләрен бергә кушып, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә мөгаллимнәре Вәли Карый өйрәткән мәкам белән укылган догадыр ул. Вәли Карый өч шәкертен—Бакый Урманчены, Фәтхи Бурнашны, Нәкый Исәнбәтне өенә алып, үзе фисгармониясендә уйнап, аларга "Казан сөлгесе", "Ашказар", "Казан" "Тәфтиләү"не өйрәтүе турында Бакый ага озын-озак итеп сөйли торган иде.

Татарстанның Тау ягы—Апас, Буа, Тәтеш, Кама Тамагы районнары авылларында әлеге мәкамнең әле дә саклануы хакында хәбәрләребез бар. Аны Идрис угылы Бакый Урманче (1897—1990) бу дөньяга күзен ачуга ук бабасы һәм әбисе Күл Черкене авылы мулласы Сәйфулла угылы Кәлимулла хәзрәт (1893 елда вабадан вафат) вә Маһибәдәр Ишморат кызы (1856—1932) өендә әтисе Хәсән угылы Идрис хәзрәт (1860—1931) вә әнисе Кәлимулла кызы Мәгъҗүбә абыстай (1874—1928) Урманчелардан да ишетеп үскән, әлбәттә. Сонрак Идрис хәзрәт үзе туган Кече Салтык авылына имам булып кайткач, мөгаллимә апалары Гайнелкануга (1893—1921) һәм Мөхсинә (1895-1986) ханымнар көйләвен дә тыңлагандыр.

Өйдә мин аны магнитофонга 1976 елның 14 декабрендә язып алганмын. (Нотага сәнгать фәннәре кандидаты Наилә Әлмиева салды.)

Ул вакытта Галимҗан Ибраһимовның күп томлыклары чыккан иде.[1] Анда әдипнең "Яшь йөрәкләр" һәм "Казакъ кызы" әсәрләре дә басылды. "Сүзгә осталык вә фикер байлык җәһәтеннән татар әдәбиятында беренче урынны тотарлык" (Җ. Вәлиди) "Яшь йөрәкләр"не 15-16 яшьлек Габделбакый беренче басылган елында (1912) ук укыган булган. Яңадан укырга хәзер теләк зур булса да вакыт әз һәм ул татар әдәби әсәрләрен, үзе әйтүенчә, "керәшен хәрефләре" белән укуга да өйрәнә алмаганлыктан, шулай ук үзе әйтүенчә, "моңлы тавышлы" хатыны укыганын хуш күргәнлектән, минем портретларны язаяза тыңлый иде. Кайчак көнгә өчәр йөз бит укыла, мин өй эшләре белән мәшгуль булганда ул да кычкырып, Гаяз Исхакыйның, Галимҗан Ибраһимовның гарәп имлясындагы китапларын укый иде. Бу аның табигый туктаусыз, тыгыз, тоташ иҗат халәте иде.

ТӘРӘВИХ



Г. Ибраһимов проспектында куелачак (Казан) гүзәл һәйкәл эскизы да шул заманда иҗат ителгән шедеврларыннан булды. Конкурсның өч турында да җиңү яулаган эскиз үз көче белән җиренә җиткерелә алмагач, сәләтсез, рухсыз, намуссыз кешеләр кулына калып, юкка чыкты. Һәйкәлнең татар сәкесе кебек дүрт почмаклы пьедесталында "Казакъ кызы", "Татар хатыны", "Табигать балалары", "Көтүче" скульптураларыннан композиция һәм уртада яраткан әдипнең 2 метрлы фигурасы нур сибәргә тиеш иде.

Галимҗан Ибраһимовның 5 портреты агач, гипс, бронза, бронзобетоннан скульптурада

[1]Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр., 9 томда.—т. 2.—Казан.—Тат. кит. нәшр.—1975.

ясалган булса, татар хатын-кыз кыяфәтен рәссам күбрәк нәгышь вә графикада бирергә омтылды. Көчле, мәгърур татар асыл затлары галереясынннан "Мөнирә Булатова", "Диләрә Тумашева", "Фәридә Кудашева" һ. б. портретларындагы төсләр симфониясе күз явын алырлык иде.

КОРЪӘН



Соңгы елда язган татар хатын-кыз портретларын кыпчак-төрки тибында иҗат итү тенденциясен дә шәйләргә мөмкин. Ул Ләбибә ханым Ихсановаларның шәҗәрәсе белән кызыксынган. Эшчән, чибәр татар ханымнарыннан Ания Туишева, Венера Ихсановаларның бай рухи дөньясын ачкан портретларын язды. 85 яшенә багышланган шәхси күргәзмәсендә "Айгөл" (1975) дип аталган "Флорасы" 1927 елда иҗат ителгән "Сепаратор янында" (моделе—артистка Нәфига Арапова) белән рәттән куелып, ярты гасыр аралы бу ике нәгышь әсәре хәзер Б. Урманченың иң югары профессиональлеген күрсәткән шаһәсәрләре дип танылa. "Салтык болыны", "Уралтау эргәсе" өчен позировать иткән Себер кызлары Фәүзия, Кадрия, Фәридә, Наиләләрнең аерым портретларын буяулары кипкәнче үк, Татарстан Сынлы Сәнгать Музее, Якутск, Төмән, Түбән Кама дәүләт музейларына сорап алалар. "Замандаш" әсәре өчен модель булган Лия Заһидуллинага ак пальтолы үз портреты язып бирелде.

Дөрес, монда рәссамның "Чтобы не пропадала правдивость изображения" дигән принцибыннан чыгып, Кол Галинең 800 һәм "Кысса-и Йосыф"ның 750 еллыгына багышланган фәнни конференциядә әйткән сүзләрен онытмау лазем: "Веласкес һәм Рембрандтның нәгышь шаһәсәрләре безне бары сәнгать әсәре буларак кызыксындыра. "Давид" һәйкәленә сокланганда скульпторның кемне ясаганын түгел, ә Микеланджелоның үзе хакында уйлыйлар". Әмма "милләт кыяфәтен бары рәссамнар гына төгәл тасвирлый" (Поль Гоген) дигән гыйбарә дә бар бит әле.



Әйтик, татарча гарәп имлясында гына язган Б. Урманче "Яшь йөрәкләр"дән дә бер кәгазьгә үз кулы белән шундый юлларны күчереп алган: "Тәңре мине үз каршысына чакырып—"Җә, колым Зыя, ни максудың бар, ни телисең, сөйлә—бу көн ни сорасаң шуны бирәм",—дисә, мин аңа: "Татар угылы татардан чын мәгънәсе белән даһи булган бер рәссам һәм дә татар рухында булган барлык гармонияләрне вә барлык тирән серләрне, хәзинәләрне тәмамы белән ачып бирерлек мәртәбәдә куәтле булган бер композитор житешсен! Мин шуны сорыйм!"—дияр идем..

Әсәрнең төп герое Зыя мәхдүмнең "чәчне кәләпүш эченә тыгып, өсткә җөббә киеп, мәчеткә китүен искә төшергәндә.

—Нинди мәкам белән укылды икән?—ди иде Бакый ага.

Мин шунда магнитофонга үзе Вәли Карыйдан өйрәнгән шушы мәкамне язып куйдым. Соңыннан аны радиога, Әмирхан ага Еникига да күчереп бирдем. Хәйдәр Бигичев һәм Зөһрә Сәхәбиева өчен "Ончы Фәхри", "Казан сөлгесе" һ. б. җырлары белән бергә күчергән идем.

Әмирхан ага Еники: "Җыр-моң Бакый абзыйдан чишмә шикелле бәреп тора иде. Күпләр белә моны, күпләрнең аны сокланып, исләре китеп тыңлаганнары бар. Әмма миңа ни сәбәптер, аның Корьәнне кычкырып укуы гаять ошый иде",—дип язды һәм бер мәҗлестә

аны аеруча тәэсирле укуын бәян итте *(Казан утлары, 1997, № 1, 137 б.)*. Үзара сөйләшкәндә Бакый аганың Коръән укуыннан симфонияләр тыңлаудан артык ләззәт алуы хакында әйтә торган иде ул. Әмирхан аганың бу фикере Коръән тәрҗемәчесе шәрекъшонас Г. С. Саблуков фикере белән аваздаш. Тәрҗемәче Коръән укылуын шәрехләп болай язган: "...все пение приняло выражение какой-то торжественности, так что слушатели его, кажется, чувствовали удовольствие такое же, какое европеец испытывает под влиянием волшебных звуков Россини, Бетховена. Сравнение не преувеличенное, ибо чувство религиозное бывает живее, сильнее, упоительнее, нежели чувство изящного" *(Саблуков Г. С. Сведения о Коране, законоположительной Книге мухаммеданского вероучения.—Казань.—1884)*.



Аннан соң Б. Урманче фоноязмасын Н. Әлмиева тамгалаган ноталарны консерваториядәге студентларым Чулпан Фәйзрахманова, Гөлнара Мәрдәнова, Алсу Хәсәнова, Айгөл Габдуллина, Әлмира Касьяновалардан пианинода уйнатып, җырлатып тыңлап карасам, алар нәкъ Бакый аганың үзе укыганча янгырый иделәр. Кайберәүләр, бәлки, Коръәне-Кәрим мәкамен тыңлап симфонияләрдән алгандай ләззәткә ирешмәсләр дә, шәт, аның өчен чын татар булу лаземдер, әмма белеп тору да мөһим бит. Бу ноталар буенча да Коръән догасын уку насыйп булсын, амин.



Токио мәчете. 1936 ел.

Америка татарлары Шәмсия ханым Апакай, Нәфисә ханым Алмакай (күптән түгел вафат, урыны җәннәттә булсын) Асия ханым Аги вә гайреләрдән 1990 елда "Тәравих"ны нәкъ Бакый ага мәкаме белән, димәк, борынгы татарча әйтүләрен магнитофонга язып алган идем. Ә Коръәне-Кәрим мәкамен Шәмсия ханымның нәкъ аныңча укуын 2003 елның 18 май кичендә Сан-Францискодан телефон аша ишетү насыйп булган иде. 2004 елның гыйнварендә 90 яшен тутырасы мөхтәрәмә Ш. Апакай Мәүлид кичә белән котлап, үзе әйтүенчә, "телефон ачкан". Мин тиз генә магнитофонга бу язманы куйдым. Ул аны, сүрәләрен дә атап, рәхмәтлебез Бакый агага ияреп укып барды һәм хәләле Салих Апакай белән никахларын да шул мәкамдә Харбин мулласы, гаскәри имам Мөнир хәзрәт Хәсбиуллин укыганын әйтте.

Озак вакытлар Харбинда яшәгән, "Рәшит казый Токио да мәсҗед салдыра" дип Г. Тукай эпиграммасына да эләккән, әмма җир алу өчен башлап кына йөреп калмыйча, мәчет салдыруга да ирешкән һәм үзе салдырган мәчеттә имам вазыйфасын да башкарган якташыбыз Рәшит казый Ибраһим да (1857—1944), шәт иншалла, Токио мәркәзен шул мәкам белән яңгыраткандыр, дип фараз итәсе килә *(Гүзель Сайфуллина. Музыки Священного слова. Чтение Корана в традиционной татары-мусульманский культуре.—Казань, 1999.—С. 15)*.

Журналда без ул мәчетнең сурәтен дә бирергә уйладык. Дөрес, мәчет 1936 елда җир тетрәү вакытында җимерелә. 2001 елда Төркия хөкүмәте ул мәчетнең яңасын салдырды. Ачылу тантанасында Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхакый җәнаблары да катнашты.

Флера
ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ

«Ялкын» журналына—80 яшь

СИКСӘНДӘ ДӘ УЛ БАЛА

Балалар өчен махсус әдәбият, матбугатның кирәклеге турында фикерләр электән үк яшәп килгән. Бала тәрбиясенең нәкъ менә үзе өчен атап язылган басмалар аша яхшырак сеңдерелүе хакында язучылар да, педагоглар да, журналистлар да уйланган. Балалар өчен язылган китапның беренче үрнәге—педагог Ян Амос Коменскийның "Мир в картинках" китабы булган. Ә беренче балалар журналы "Лейпцигский еженедельный листок" (1772—1774) Германиядә нәшер ителгән. Аннары 1785—1789 елларда Мәскәүдә Н. Новиков "Детское чтение для сердца и разума" журналын бастырган. Балалар басмалары үз эшен ике юнәлештә алып барган: дөньяви һәм дини. Революциягә кадәр үк инде татар телендә балалар өчен 2 газета, 3 журнал нәшер телгән. 1910 елда Бакчасарайда И. Гаспринскийның "Тәрҗеман" газетасына кушымта рәвешендә чыккан "Галәме сабиян" һәм "Мәктәбе сабиян" басмалары—балалар газетасының беренчесе үрнәкләре. Аларда балалар тормышыннан гыйбрәтле мәкаләләр, хәбәрләр, хатлар, шигырьләр, тәрбияви характердагы язмалар бирелгән.

Ә татарча балалар журналының иң беренчесе—"Тәрбияи этфаль"— 1907 елның январь-март айларында Мәскәүдә нәшер ителә. Редакторы һәм нашире—Заһид Шамил. Үзе татарча бик үк яхшы белмәгәнлектән, бөтен редакция эшләрен ул Фатих Әмирханга йөкли. Журналда "...хикәяләр, кыйссалар, тарихи хикәяләр һәм шигырьләр, дөньяны аңлау өчен вә табигать хакында мәгълүмат, мөгаллимнәр вә шәкертләр өчен киңәшләр вә тәҗрибәдән күренгән нәрсәләр" бирелә. Журнал балаларга багышлап язылса да, программасы һәм рәсемнәре белән олыларга да файдалы булыр дип көтелә. Журналның беренче санындагы баш мәкаләдә Ф. Әмирхан "Тәрбияи әтфаль"нең балаларга остаз да, яхшы иптәш тә булачагын ассызыклый.

Остаз гына түгел, иптәш тә булырга теләү—"Тәрбияи әтфаль"гә генә түгел, барлык журналларга да хас. Нәкъ менә шушы теләк 1913—1916 елларда "Ак юл"ның мөхәррире һәм нашире Фәхрелислам Агиевны балаларга мөрәҗәгать итәргә этәрә. "Моңа кадәр күңелсезләнсәңез дә, шатлансаңыз да тик ялгыз идеңез. Инде бу көннән соң, сәламәт булсаңыз, сезнең шатлыгыгызны да, күңелсезлегегезне дә, эч пошуыңызны да уртаклашучы булды",—дип яза ул журналның беренче санында. "Ак юл" "...матур һәм җиңел телдә язылган шигырьләр, әдәби вә тарихи хикәяләр, милләтебезнең бөек адәмнәренең вә Европа мәдәниятенә хезмәт иткән бөек затларның кыскача тәрҗемәи хәлләре, аларның рәсемнәре һәм язган әсәрләреннән кечкенә өзекләр, балаларның зиһеннәрен вә фикерләрен ачар өчен гаять файдалы булган башваткычлар бүлмәсе..." тәкъдим итә.

1917 елда "Сөембикә" журналы нашире Якуб Хәлили тарафыннан чыгарылган "Балалар дөньясы" да шул ук программага нигезләнеп эшли: "...матур һәм җиңел телдә язылган гыйльми, фәнни, әдәби, тарихи һәм дини хикәяләр, балалар телендә язылган шигырь вә поэмалар, балаларның зиһеннәрен ачарлык сөяльләр һәм башваткычлар..." бастыра.

Совет власте урнашкач балалар өчен яңа басма булдыру ихтыяҗы алга килеп баса. 1918 нче елның 27 сентябрендә Казанда чыга башлап, 1922 елдан 1931 нче елга кадәр

Мәскәүдә басылган "Эшче" газетасында 1923 нче елның 5 августыннан "Балалар почмагы" кушымтасы бирелә башлый. Бу кушымтада шигырьләр, кыска-кыска хикәяләр һәм парчалар, балалар тормышы турында мәкаләләр бирелеп килә. Әлеге кушымтаны әзерләүдә Муса Җәлил еш катнаша. Ләкин бер газетадагы кушымта гына балалар матбугатына ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый. М. Җәлил бу хакта республика матбугатында кат-кат чыгыш ясый, журналны оештырып йөрүчеләрнең берсе була. 1924 елны "Татарстан" (хәзер "Ватаным Татарстан") газетасында М. Җәлил "Кечкенә иптәшләр" дигән мәкаләсендә 9-14 яшьлекләр өчен журнал чыгарырга әзерлек баруы хакында хәбәр итә. Ниһаять, балалар матбугаты турындагы хыял тормышка аша: 1924 елның март аенда Ленинчы комсомолның татар-башкорт бюросы тарафыннан айга бер тапкыр "Кечкенә иптәшләр" исемле балалар журналы чыгарыла башлый. (Бераз соңрак—10 октябрьдә "Яшь ленинчы" газетасының да беренче саны дөнья күрә, чыгу ешлыгы—атнага ике тапкыр.) Беренче санында ук "Кечкенә иптәшләр"нең программасы басылып чыга. Анда: "Журнал эшче-крестьян балалары тормышыннан хикәяләр, шигырьләр язачак. Яшь пионерларның кем икәнлекләре, аларның тормышлары һәм эшләре язылачак. Кечкенә хәбәрчеләр почмагы булачак",—диелә. Журналның беренче редакторы—Һ. Курмаев, тиражы—3000 данә була. Редакциядә (Мәскәүнең Никольская урамындагы 10 йортта, СССР халыклары үзәк нәшриятының төп конторасында урнашкан) нибары биш кеше эшли. Язучылардан М. Җәлил, А. Мохтаров, Г. Кутуй, Ш. Усманов, М. Крымов, С. Кудаш редакция белән хезмәттәшлек итә. 1927 елны журналның редакторы итеп М. Җәлил билгеләнә. Ул редакторлык иткән елларда яшь хәбәрчеләр белән эшләү даими төс ала, журнал битләрендә ничек иҗат итәргә, нәрсәләр хакында һәм ничек язарга кирәклеге хакында мәкаләләр һәм, әлбәттә, илнең төрле почмакларыннан килгән пионерлар хатлары басыла. Мисал өчен, 1925 елның 8 нче санында Свердловск, Сәмәрканд, Ленинградтан килгән язмалар чыккан. "Кечкенә иптәшләр" (1929 елдан—"Октябрь баласы") көннән-көн актуаль темаларга бай, балаларны интернациональ, хәрби-париотик рухта тәрбияләү юнәлешендә эшли. Көн кадагына суккан мәсьәлә—балаларга коммунистик тәрбия бирү—журналистлар алдында беренче урында тора. Революциягә кадәр чыккан балалар журналларында өстенлек иткән темалар—туган якка, туган телгә, әти-әнигә, Ходайга мәхәббәт, уку, белем алу, фән-техника яңалыклары, ятим балалар тормышын сурәтләү булып, алар "Октябрь баласы"нда да кабатлана, бары тик акцентлар гына үзгәрә төшә. Алла турында сүз әйтелми башлый, чөнки атеистик тәрбия пропагандалана, ятим балалар тормышы да иске тормышны сурәтләгән хикәяләрдә генә кала. Туган телгә, әти-әнигә мәхәббәт янына пионериягә, коммунистик идеалларга бирелгәнлек тә өстәлә.

"Октябрь баласы" 1933 елда чыгудан туктый. Журнал Казанга күчерелеп, "Пионер каләме" исеме белән басыла башлый. Бу елларда журналда җаваплы секретарь булып Муса Җәлилнең көрәштәше, балалар язучысы Абдулла Алиш эшли. Балалар арасында яратып кабул ителә торган күп кенә әкиятләрен Алиш шунда эшләгәндә яза, һәм алар журналда басылып та чыга. Ш. Маннур, М. Әмир, Ф. Бурнаш, Х. Туфан, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Ә. Бикчәнтәева, Җ. Тәрҗеманов, Ә. Камал һәм башка әдипләр бу елларда "Пионер каләме" белән хезмәттәшлек итәләр. Журнал татар әдәбиятын гына пропагандалап калмый, русчадан (А. Пушкин, С. Маршак, Б. Житков һ. б.) тәрҗемәләр бастыра, көнбатыш авторлары (Э. Золя) белән таныштыра. Союздаш республикалар турында мәгълүмат, тугандаш халыклар әдәбиятлары үрнәкләрен бастырып чыгара, бөек язучылар, композиторлар, сәнгать кешеләренең тәрҗемәи хәлләре турында яза, фән-техника яңалыклары белән таныштыра, пионерлар иҗатын, аларның хатларын бастыра. Элгәрләреннән аермалы буларак, "Пионер каләме" СССР Верховный Советы Президиумы карарлары, партия юлбашчылары турында язмалар бирен килә, В. И. Ленин хакында күп яза.

Бөек Ватан сугышы елларында, бик күп газета-журналлар кебек үк, "Пионер каләме" дә ябыла.

Сугыш беткәч тә журналны тиз генә яңадан торгызу мөмкин булмый әле: яңартылган журналның беренче саны "Пионер" исеме белән укучыларга 1951 нче елның ноябрендә генә барып ирешә. "Пионер" белән башта фронтовик язучы А. Әхмәт, 1953 елдан Л. Ихсанова җитәкчелек итә. 1957 елда журналның исемен алыштыру да Ләбибә Ихсанова идеясе. "Пионер" журналлары күп иде, дип аңлата ул моны, Мәскәүдә дә, Башкортстанда да, Украина белән Белоруссиядә дә, Эстониядә дә—һәркайда балалар журналы "Пионер" исеме белән чыга. "Бервакыт шулай редколлегия членнары Лотфулла Фәттах, Госман Бакир, Гариф Гобәй белән журналның исемен алыштыру хакында сөйләшеп утырдык. Аннары мин, журналның исемен алыштыру нияте белән, ВЛКСМ өлкә комитетына, укучы яшьләр бүлеге мөдире Ләлә Зарипова янына бардым. Ул теше-тырнагы белән

каршы төште: "Нинди "пионер" сүзеннән курку ул, нигә аңардан качарга тырышасыз?"— ди. Югыйсә, "Ялкын" дигән күпмәгънәле исем дә уйлап куйган идек. Ул—учак ялкыны да, яшьлек ялкыны да, пионер ялкыны да, укуга, хезмәткә дәрт ялкыны да",—дип сөйли Ләбибә апа. Баштарак каршы төшсәләр дә, аларның нияте тормышка аша—1957 елның июль аеннан журнал "Ялкын" исеме белән чыга башлый. Инде "Ялкын"ның элгәрләрен укып үскән балалар үзләре танылган язучы-галимнәр булып җитешә. 1925 елда "Кечкенә иптәшләр"дә язмалары басылган әдәбият галиме Хатип Госман, 1937 елда "Пионер каләме"нә язышкан Зәки Нури, 1935 елда шигырьләрен бастырып чыгарган Шәрәф Мөдәррисләр журналның даими авторларына әйләнә. Бүгенге күренекле язучы-шагыйрьләребезнең беренче әсәрләре дә "Ялкын"да басылып чыга. Әйтик, илленче еллар ахырында әле мәктәп укучылары гына булган Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов шигырьләре, Ренат Харис рәсемнәре журналда басылып чыккан.

1962 елда "Ялкын"га баш редактор булып Роза Хафизова килә. Ул җитәкчелек иткән елларда журналның тиражы 80 меңгә җитә. 1978 елда ул офсет ысулы белән төрле төсләрдә басыла, редакциядә хезмәткәрләр дә арта. Журнал, тиражы артып, керем бирә башлый. Роза Хафизова эшләгән чорда журналның үз стиле формалаша—ул укучы бала белән күзгә-күз карап сөйләшү, диалог формасын ала. Һәрбер мәкалә, кыска хәбәр камил итеп эшләнгән кыска хикәя рәвешенә җиткерелгәнче эшләнә. Журнал үзенең әдәби-нәфис дигән исемен аклый, укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. Роза Сәетовна белән бер вакытта эшләгән Габделхәй Сабитов, Хәйдәр Гайнетдинов, Разил Вәлиев тә журналны үстерүгә зур өлеш кертәләр. Р. Вәлиев—журналның 50 еллыгына багышланган, радиода еш яңгыраган "Пионер ялкыны" дигән җырның авторы да. Ул бүген дә журнал белән хезмәттәшлек итә: инде 30 елдан артык "Ялкын"ның соңгы битендә балаларны сөендергән дөнья халыклары әкиятләрен рәссам Т. Хаҗиәхмәтов белән Р. Вәлиев әзерли.

1984 елның 5 гыйнварында "Ялкын" журналы СССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан балаларны коммунистик рухта тәрбияләүгә зур өлеш керткәне өчен Почет билгесе ордены белән бүләкләнә. Бу—журналның 60 ел буена армый-талмый яшь буынны тәрбияләве өчен зур бүләк. Туксанынчы еллар башына тиражын стабиль рәвештә 50 меңнән дә киметми саклый алган журналны туксанынчы еллар башындагы икътисадый кризис кыен хәлгә куя. Журнал ябылу алдында кала, аның тиражы ярты ел эчендә сизелерлек кими. Советлар Союзы чорында журналны тарату, аны пропагандалау белән комсомол, пионер оешмалары шөгыльләнгән булса, хәзер барлык оештыру эшләре редакциянең үз өстендә кала. (Бу чорда "Ялкын" белән Р. Туфитуллова, Җ. Дәрзаман, Э. Закировалар җитәкчелек итә).

Бүгенге "Ялкын"ны моннан унбиш-егерме ел элек чыккан журналлар белән чагыштырып та булмый. Ул көннән-көн камилләшә: аның техник мөмкинлекләре дә, бизәлеше дә, кәгазенең сыйфаты да күпкә яхшырак. Соңгы ун-унбиш елда журнал мәктәп укучыларының барлык категорияләре өчен түгел, 12-16 яшьлек яшүсмерләргә атап чыгарыла. Журналны, заманга хас булганча, көнбатыш тәэсире дә читләтеп узмады. Аңа үсмерләрне "тинейджерлар" дип атау да, көнбатыш киносы һәм шоу-бизнесы турында сөйләү дә хас. "Ялкын" үсмерләрне бүген борчыган мәсьәләләр хакында яза: ул—әтиләр һәм балалар проблемасы да, үсмерләрнең социаль-психологик проблемалары да, бала хокуклары темасы да, киләчәк турында уйлану, телебез хакында кайгырту да... Журналның рубрикалары һәм бүлекләре моңа дәлил: балаларның күпсанлы сорауларына җавап бирә торган "Минем хокукларым", уку йортлары турында сөйли торган "Абитура" рубрикасы, психологик проблемаларга, үсмерләрне борчыган сорауларга җавап эзләшә торган "Оялчан алма", яшьтәшләренә үзләрен күрсәтергә ярдәм итә торган "Кәеф" кушымтасы, "Балалар хатлары", "Балалар иҗаты", "Борчылам, шуңа язам да", тел һәм әдәбият белгечләре белән бергә әзерләнгән "Җырдай моңлы татар теле", "Әдәбият дәресендә кунак бар", гореф-гадәтләребезне, этнографиябезне чагылдыручы "Ачык сандык", Казанның меңьеллыгына багышланган "И Казан, серле Казан" рубрикалары шундыйлардан. Бүгенге "Ялкын"ның "Кечкенә иптәшләр" белән охшашлыгы бик аз кебек: ул чор идеаллары онытылган, җәмгыятьне борчыган проблемалар да икенче, укучыларның яшь үзенчәлекләре дә, тормыш рәвеше дә башка төрле, журналның бизәлеше дә, материалларның бирелүе дә үзгә, эчтәлек тә яңа—әдәби әсәрләрнең чагыштырмасы элекке шикелле күп түгел, публицистик язмалар да жанр ягыннан төрле. Шулай да аларның максатлары бер: ул—журнал укучыларын хәзерге буынга лаеклы алмаш итеп тәрбияләү, аларны намуслы, югары әхлаклы кешеләр итеп үстерү.

Айсылу ГАЛИЕВА

Әхмәт Саттар

Саттаров Әхмәт Саттар улы 1939 елны Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районы Кочко-Пожарки авылында туа. 50 еллар башында Әхмәтләр гаиләсе Мәскәүгә килеп урнаша һәм үсмер малайның алдагы гомере башкала белән бәйле. Мәктәп, һөнәр училищесы, заводта эшләү... Ерак Көнчыгышта өч ел армия хезмәтеннән соң, янәдән уку. Бу юлы югары категорияле метрдотельләр әзерләү курслары. 1963 – 1972 елларда ул Кремльдә дәүләт житәкчеләрен, чит ил кунакларын, төрле рәсми делегацияләрне аш-су белән тәэмин итүче махсус группада өлкән метрдотель булып эшли. Ә. Саттар шул чорның күренекле шәхесләрен күреп, танып белгән кеше. Соңрак Әхмәт Саттар төрле-төрле күп эшләрдә хезмәт итсә дә, бу чор аның гомерендә аерым бер урын тота. Табигый, аның "Метрдотель язмалары" укучылар тарафыннан зур кызыксыну белән кабул ителде дә.

Әхмәт Саттар әдәби иҗат белән мәктәптә укыган еллардан бирле шөгыльләнә. Әмма аерым китабы фәкать 1989 елны гына басылып чыга. Күрәсең, төрле тармакларга бүленеп-чәчелеп эшләү, ике телдә — русча һәм татарча язарга омтылу, бу очракта, ахыр нәтиҗәдә үзенчә чагылыш тапкан. Соңгы елларда Әхмәт Саттар, нигездә, әдәби иҗат эше белән генә мәшгуль. Әсәрләре үзәк матбугатта еш күренә. Кайбер шигырьләре татар матбугатында да чыгып тора ("Казан утлары", Ватаным Татарстан", "Чаян", "Идел" һ. б.). Ул шигъриятнең кыска формаларында уңышлы иҗат итә. Аны афоризмнар, робагыйлар остасы дип тә атап буладыр. 2002 елда Ә. Саттарның "Прощай, XX век" исемле китабы дөнья күрде. Анда, нигездә, кыска шигырьләр — робагыйлар урын алган.

Әхмәт Саттар җыр жанрында да уңышлы эшли. Күренекле композиторлар белән бергә иҗат ителгән аерым җырлары халык арасында популярлык казанды. Р. Яхин көй язган "Ялгыз агач", "Серле күзләр" әнә шундыйлардан.

Әхмәт Саттар холкы белән тынгысыз, хәрәкәтчән, гомумән, актив кеше. Мәскәүдә татар җәмәгатьчелегенә кагылышлы булган чараларда ул һәрвакыт алгы сафларда; оештырыша, булыша, ярдәмгә килә. 1970 — 1980 елларда Мәскәүдә (Главмостстрой культура сарае каршында) М. Җәлил исемендәге әдәби-музыкаль берләшмә җитәкчесе булып эшләде.

2003 елның декабрендә Язучылар Берлеге идарәсе, Кабул итү Коллегиясенең карары нигезендә (тәкъдимнамә бирүчеләр — Зөлфәт, М. Юныс, Н. Кәримова), Саттаров Әхмәт Саттар улын Татарстан Язучылар Берлегенә әгъза итеп кабул итте.

«Казан утлары» архивыннан

«Ибраһим бабай атлы булды!» Күренекле прозаик, Ибраһим Салахов үзенең 80 яшьлек юбилее көннәрендә. Казакъстан. Кызылтъяр. 1991 ел.

Үткән гасыр татар әдәбиятының яшь көчләре. Сулдан уңга: Габдрахман Минский, Һади Такташ, Гадел Кутуй. 1928 ел. Казан.

Шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалимов, драматург Ризван Хәмид. 1998 ел. Казан.

Уфа кунагы Сәйфи Кудаш замандашлары, фикердәш дуслары белән. Сулдан уңга: Сибгат Хәким, Сәйфи Кудаш, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники. 1964 ел. Казан.

Шагыйрә Флера Гыйззәтуллина. 1989 ел. Казан.

Язучы Рафаэль Сибат. 1990 ел.

АВЫР ЮГАЛТУЛАР

Холкы белән башка еллардан әллә ни аерылып тормаса да, быелгы кыш әдәбиятыбыз өчен шактый рәхимсез булып чыкты: каләмдәшләребез бер-бер артлы Мәңгелек йортка китеп тора. Шунысы аяныч—бик ешаеп китте бу озату-хушлашулар.

Яна елнын беренче көннәрендә үк хезмәттәшебез, язучы Кояш ханым Тимбикованы жирләдек. Бу хакта журналыбызда хушлашу сүзе дә язып чыккан идек. Югалту кичерешләре сүрелергә дә өлгермәде, унбиш-егерме көн эчендә янә өч җеназа. Авыр югалтуларга дучар итеп башланды бу Кәбисә елы...

Әдхәт Синугыл



14 январьда күренекле шагыйрь, тәржемәче Әдхәт Синугыл Язучылар йорты бинасында йөрәк өянәгеннән кинәттән жан тәслим кылды.

Ул 1935 елның 15 мартында Башкортстанның Эстәрлебаш районы Куганакбаш авылында туган. 1959-64 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә белем ала. Дипломлы белгеч буларак, Пермь өлкәсенең Барда, Татарстанның Сарман районнарында укытучы, туган ягында мәктәп директоры булып эшли. Аннан дистә елга якын Татарстан китап нәшриятында редактор, Татар дәүләт филармониясендә әдәби бүлек мөдире вазыйфаларын башкара.

Ә. Синугыл-Куганаклы гомеренең 30 лап елы Үзбәкстан һәм Кырым белән бәйле. Ташкентта ул "Йолдыз" журналы редакциясендә, кино сәнгате тармагында һәм кайбер башка оешмаларда эшли. 1983-85 елларда Әдхәт Мөкәрим улы Мәскәүдәге Югары әдәби курсларда укый. 10 ел дәвамында ул "Ватаным Татарстан" газетасының, "Татар-Информ" агентлыгының һәм "Азатлык" радиосының Урта Азиядәге үз хәбәрчесе вазыйфаларын башкарды. Аның иҗтимагый-сәяси, милли-мәдәни, тарихи темаларга язылган мәкаләләре, публицистик чыгышлары бик күпләр өчен яхшы таныш.

Ә. Синугыл-Куганаклының шигъри әсәрләре матбугатта 40 ел дәвамында даими басылып килде. Ул "Чалгы жыры", "Жыр төбәген сагынып", "Көньяк гөлләре", "Ник елыйсың, курчагым?", "Ефәк кәрваннар", "Иман гасыры" һ. б. шигырь китаплары авторы. Шагыйрьнең кырымтатар телендә "Яшьлек һәйкәле", "Каракаш" исемле китаплары да дөнья күрде. Ул татар шигъриятендә робагый һәм фәрд жанрларын жанландырып җибәрүгә зур өлеш кертте. Әдхәт Мөкәрим улы тәржемә өлкәсендә дә озак еллар буе нәтиҗәле эшләп килгән татар шагыйрьләренең берсе.

1982 елдан СССР һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзасы булган шагыйрь, Татарстанның һәм Украинаның атказанган сәнгать эшлеклесе дә иде.

Рахмай Хисмәтуллин

27 январь көнне аяусыз үлем тагын бер каләмдәшебезне—Рахмай Хисмәтуллинны арабыздан алып китте. Быелның сентябрь аенда аңа 70 яшь тулган булыр иде.

Рахматулла Хисмәтулла улы Хисмәтуллин 1934 елның 25 сентябрендә Татарстанның Актаныш районы, Әнәк авылында туып үсә. 1952 елда Пучы урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетында белем ала. Аннары Питрәч һәм Азнакай район газеталарында, Казан телевидениесендә әдәби хезмәткәр, редактор булып эшли. Кама буенда нефть-химия комплексы төзелә башлагач, 1966-1981 еллар арасында Түбән Кама шәһәрендә экономист, "Социалистик Татарстан" газетасының үз хәбәрчесе, укытучы, инженер, халык театрында режиссер вазыйфаларын башкара. 1982 елдан "Нефтехим" берләшмәсе хезмәткәре була.

Ул "Жидегән чишмә" әдәбият-сәнгать иҗат берләшмәсен оештырып җибәрә. Аның 20 елга якын гомере шунда кайнап уза. 1984 елны ана Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә, ә 1988 елда ул җитәкләгән "Жидегән чишмә" иҗат берләшмәсе М. Жәлил исемендәге республика бүләгенә лаек була. Соңрак, 1993 елда Р. Хисмәтуллинның нәкъ шул чорны яктырткан "Кыйбла җиле" исемле китабы дөнья күрә, һәм әдип Г. Исхакый премиясе белән бүләкләнә.

Р. Хисмәтуллинның иҗтимагый эшчәнлеге әдәби иҗат белән үрелеп бара. Ул талантлы публицист, очеркист иде. Очерклар, публицистик язмалар, хикәяләр тупланган дистәгә якын китаплар ("Салават күпере", "Күкрәү авазлары", "Сусау", "Үземне таптым" һ. б.) авторы. Күпкырлы талант иясе буларак, Р. Хисмәтуллин шулай ук тумыштан шагыйрь дә иде. Аның "Дөньяга көлеп чык", "Яшенле тау", "Ак догалар" исемле шигырь китаплары бар.

Мәрхүмнең җәсәде туган авылында җирләнде.

Барлас Камалов

5 февральдә тагын бер кайгылы хәбәр: күренекле прозаик һәм публицист Барлас Камалов вафат...

Барлас Хәмит улы Камалов 1930 елның 17 гыйнварында Татарстанның Чистай каласында мөгаллимнәр гаиләсендә туа. Аның балачагы һәм мәктәп еллары Буа районы Янтуган, Исәк, Кул-Черкен авылларында уза. Урта белемне Буадагы М. Вахитов исемендәге урта мәктәптә ала. Аннары Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. Соңрак шул ук институтның аспирантурасын тәмамлый.

1956-1959 елларда Б. Камалов Буа район газетасында эшли, ә 1959-1962 елларда "Татарстан яшьләре" газетасының баш мөхәррире. 1962-1966 елларда ул "Социалистик Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, аннары "Чаян" журналында, Татарстан радиосында төрле җаваплы вазыйфалар башкара. Алтмышынчы еллар ахырыннан башлап ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнде.

Барлас Камалов үзен проза жанрында иң нәтиҗәле эшләүче язучыларның берсе итеп танытты. Аның беренче хикәясе ("Күңел газабы") "Яшь сталинчы" (хәзерге "Татарстан яшьләре") газетасында 1953 елда, ә "Гомер иткәндә" дип исемләнгән беренче китабы 1959 елда басылып чыга.

Ярты гасырдан артык дәвам иткән иҗат гомерендә язучы дистәләгән китаплар чыгарды. Алар арасында—"Яшьлек эзләре", "Күңел кыңгыраулары", "Үр менгәндә", "Урамнар кинәя", "Күршеләр", "Канатлы кырмыска", "Ялыкмаслар", "Сарсаз кызы Сария", "Өметең өзелмәсен" һ.б. Б. Камаловның байтак әсәрләре иң әүвәл безнең журналда дөнья күрде. Бер ел гына элек аның соңгы хикәяләреннән берсе "Соңгы көннәрдә" исемлесен бастырып чыгарган идек...

Б. Камаловның иҗатта төп кыйбласы—бүгенге тормышның кайнар эзләреннән барып, чынбарлыкны сурәтләү булды. Ул, әдип буларак, үзе яшәгән заманга аеруча сизгер карашы, әсәрләрендә заманның актуаль мәсьәләләрен вакытында кузгатырга, күтәрергә омтылуы—оперативлыгы белән аерылып торды.

Әдәбиятыбызны үстерүгә керткән зур хезмәтләре өчен Барлас Хәмит улы Камаловка Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелде.

6 февральдә Казанның Язучылар йортында мәрхүм белән саубуллашу булды.

İctimagi-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

ДУМАГА ҮТКӘН ДЕПУТАТЛАР

Мәгълүм булганча, Татарстанда Россия Дәүләт Думасына сайлаулар халыкның зур активлыгы белән үтте. Анда барлык сайлаучыларның 77,25 проценты (Россия буенча—57,7 %) катнашты. Быел үз эшен башлап җибәргән IV чакырылыш Дәүләт Думасы составына Татарстаннан кемнәр үтте һәм алар Думада нинди вазифалар башкара соң? Бер мандатлы округлардан сайланган депутатлар—Марат Мәһдиев, Ринат Гобәйдуллин, Олег Морозов, Альберт Салихов, Айрат Хәйруллин; Партияләр исемлеге буенча үткән депутатлар—Юрий Нәҗмиев, Әнвәр Мөхәммәтзакиров, Михаил Рокицкий, Анбяр Кармеев, Ильдар Гыйльметдинов, Виктор Ельцов, Александр Козловский. Алар арасыннан О. Морозов Дәүләт Думасы рәисе урынбасары итеп сайланды. Ю. Нәҗмиев—мәгариф һәм фән буенча комитет рәисе урынбасары, Р. Гобәйдуллин—бюджет һәм салымнар буенча комитет рәисе урынбасары, А. Салихов—җирле үзидарә буенча комитет рәисе урынбасары, А. Козловский—халыкара эшләр буенча рәис урынбасары, М. Рокицкий—сәламәтлек саклау, шулай ук, мандат һәм депутат этикасы буенча комитет рәисе урынбасары, И. Гыйльметдинов физкультура һәм спорт буенча комитет рәисе урынбасары итеп расландылар. Башка депутатлар Дәүләт Думасында төрле комитет (М. Мәһдиев—Федерация һәм региональ сәясәт, А. Кармеев—мәгълүмат сәясәте, В. Ельцов—промышленность һәм төзү эшләре, Ә. Мөхәммәтзакиров—экономик сәясәт, эшмәкәрлек һәм туризм) әгъзалары сыйфатында эшләячәкләр. Дума депутатлары арасында тагын бер якташыбыз бар: ул—Фәридә Гайнуллина. Үткән чакырылыштан аермалы буларак, бу юлы ул депутат булып Саратовтан сайланды, хәзерге Думада хезмәт һәм социаль сәясәт комитетында әгъза һәм тавыш бирүне контрольдә тоту буенча җаваплы координатор. Шунысын да искәртеп узыйк: Дәүләт Думасына сайланган депутатларның күпчелеге "Бердәм Россия" партиясе вәкилләре.

МАТБАГАЧЫЛАРНЫ КОТЛАУ

"Татмедиа" агентлыгында Россия басмаларының үз хәбәрчеләрен һәм республика гаммәви мәгълүмат чаралары җитәкчеләрен Россия Матбугаты көненә багышланган тантаналы кабул итү мәҗлесе булды.

Журналистларны бәйрәм белән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады. Ул аларга Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев котлавын җиткерде. "Демократияләштерү Россиядә дә, Татарстанда да тормышның барлык өлкәләренә кагылды. Ул гаммәви мәгълүмат чараларын да читләтеп узмады—күп кенә хосусый басмалар барлыкка килде. Алар да тормышыбызны яңартуга өлеш кертә. Республика үз журналистлары белән горурлана,— диде Ф. Мөхәммәтшин. Ул журналистларның РФ Дәүләт Думасы депутатларын сайлау кампаниясенә җитди өлеш кертүен билгеләп узды. —Сәяси имтихан уңышлы тапшырылды. Гаммәви мәгълүмат чараларына карата берниндн дә гаепләү булмады, журналистлар югары һөнәри осталык күрсәтте,— диде Ф. Мөхәммәтшин. —Россия Федерациясе Президенты һәм ТР Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар игълан ителде. Бу—бик әһәмиятле сәяси кампания, аны югары дәрәҗәдә үткәрергә кирәк. Кайчакларда хакимиятнең журналистларга, журналистларның хакимияткә үпкәләвенә карамастан, журналистларның Татарстан парламентын формалаштыруга һәм Россия Федерациясенең лаеклы лидерын сайлауга ярдәм итәчәгенә минем бернинди дә шигем юк. Күпчелекнең генә түгел, үз фикере булган аз санлы кешеләрнең дә мәнфәгатьләрен алга сөрүче кешеләрнең депутат булып сайлануы әһәмиятле. Башкача әйткәндә, парламентта җәмгыятебезнең барлык катлаулары урын алырга тиеш".

Аннары журналистларны "Татмедиа" агентлыгы генераль директоры Марат Моратов тәбрик итте.

ХАЛЫК ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ СӘЯСИ ӘДӘПЛЕЛЕК

Казанда, Татарстан журналистлар йортында Татар ПЕН-үзәге оештырган конференция әнә шулай аталган иде.

Әлеге җыен узган ел азагында "Мәгариф" нәшрияте тарафыннан чыгарылган "Татар юлы: халык хокуклары һәм сәяси әдәплелек" дигән китапны тәкъдир итү рәвешендә үтте. Бу басмада урыс һәм инглиз телләрендә мәкаләләр һәм рәсми материаллар тупланган, аларда Россия Федерациясендәге демократия һәм сүз иреге, милләтләрнең тигез хокуклыгы һәм федерализм сәяси әдәплелек күзлегеннән чыгып бәяләнә.

Конференциядә рус ПЕН-үзәге президенты Андрей Битов, Халыкара ПЕН-клубның

башкарма комитеты әгъзасы Александр Ткаченко, Россия гуманитар университеты профессоры Әгъдәс Борһанов, Мәскәүдәге Татар ПЕН-үзәге вәкиле, юстиция кинәшчесе Борис Пантелеев катнашты.

Эшлекле мәҗлесне ачу вакытында Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан Миңнуллин дөньядагы 134 илнең әдипләрен берләштерүче Бөтендөнья язучылар ассоциациясе—Халыкара ПЕН-клубның роле, язучыларның бу оешмасында тулы канлы тормыш алып бару зарурлыгы турында сөйләде.

Андрей Битов үз чыгышында болай диде: "Заманыбызның төп казанышы—сүз иреге, аны әле бездән бөтенләй үк алып бетермәделәр. Ләкин безнең күпмилләтле мәдәниятебезне, берниндн үзенчәлекләрне дә исәпкә алмыйча, бер гомуми асфальт белән каплап куярга җыеналар дигән тәэсир туа. Бөтен кеше өчен бер үк төрле булган дөреслектән куркырга кирәк. Иң мөһиме—дөреслек агрессив булмаска тиеш."

Александр Ткаченко үз чыгышында безнең илдәге кануннарның үтәлмәве, ә бәлки хакимият башында утыручыларның үз мәнфәгатьләрендә генә файдалануына тукталды:

"Россиянең хәзерге Президенты болай ди: "Әйе, сүз иреге булырга тиеш, ләкин..." Нәкъ менә шул "ләкин" булмаска тиеш тә инде",—диде ул.

Борис Пантелеевның доклады "Халыкара һәм россия шартларында сәяси әдәплелекнең хокукый механизмы" дип атала иде. Ул 2003 елда Россиядә чыккан китаплар арасында милли мәсьәләләрне тәкъдир ителгән китаптагыча җитди яктырткан башка басманың булмавын әйтеп китте.

Әгъдәс Борһанов фикеренчә, милләтне һәм аның мәдәниятен саклап калу өчен, халыкка аягында нык басып торган урта сыйныф булдырырга кирәк.

Конференциядә шулай ук Разил Вәлиев, Фәндәс Сафиуллин, Римзил Вәлиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин һ. б. чыгыш ясады. Җыенда катнашучылар мондый нәтиҗәгә килде: "сәяси әдәплелек" термины—сәяси, иҗтимагый, фәлсәфи, әхлакый даирәләрдә генә түгел, көндәлек тормышыбызда, әхлакый мөнәсәбәтләребездә дә булган критерийлар һәм стандартларның тулы бер системасы; кешенең дәүләти-сәяси статусы югарырак булган саен, аның әдәплелек һәм түземлелек дәрәҗәсе дә югарырак булырга тиеш.

Конференция РФ Мәгариф министрлыгының Татарстан мәктәпләре һәм гимназияләрендә татар теле укытуны кыскарту буенча күргән чараларын кискен тәнкыйтьләде.

Икенче көнне язучылар Андрей Битов һәм Александр Ткаченко Казанның әдәби җәмәгатьчелеге белән очрашты.

ТАТАР ҖЫРЫН—ХАЛЫКАРА ДӘРӘҖӘГӘ

9-11 январьда Казанның "Пирамида" мәдәни күңел ачу комплексында—"Татар җыры—2003" IV Халыкара татар җыры фестивале узды.

Быел фестиваль мәркәзебез чикләреннән чыгып, халыкара статуска лаек булды. Татар җыры бәйрәменә махсус кунаклар сыйфатында Ринат Ибраһимов (Мәскәү), Идрис Газиев (Башкортстан), Зөлфия Камалова (Австралия) чакырылган иде. Фестивальнең сәхнәдә куелышы белән Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев җитәкчелек итте. Жюри фестиваль лауреатларын ел дәвамында сайлап алган, сайлауда әһәмиятле шартларның берсе булып башкаручыларның CD дисклары, аудио һәм видео-кассеталары сатылу рейтингы торган.

Фестивальнең беренче көнендә лауреатлар үзләренең яна җырларын башкарды. Ә 10 январьда исә, "Алтын Барс" премиясен тапшыру тантанасы узды. Бу көнне фестиваль тамашачылары арасында ТР Президенты Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин һәм башкалар бар иде. "Алтын Барс" сыннары Салават Фәтхетдиновка, Зәйнәп Фәрхетдиновага, Хәния Фәрхигә, Айдар Галимовка, Гүзәл Уразовага, Ләйсән Гыймаевага, "Фәридә—Алсу" дуэтына, "Айфара" төркеменә, Габделфәт Сафинга, Мәликәгә һәм башка популяр башкаручыларга тапшырылды. Җырларның композиторлары һәм авторлары дипломнар һәм акчалата премияләр белән бүләкләнде. Фестивальдә катнашкан өчен "Азатлык" радиосы Казан бүлекчәсенең махсус премиясенә татар җырларын World music стилендә башкаручы Австралиядән Зөлфия Камалова лаек булды.

"Татар җыры—2003" фестиваленең гала-концерты 11 январь көнне "Яңа гасыр" спутник телеканалында туры эфирда трансляцияләнде.

ТӨРКИ ХАТЫН-КЫЗЛАР ҖЫЕНЫ

Анкарада төрки дөнья хатын-кызларының II Дуслык һәм кардәшлек корылтае үткәрелде. Төрки дөнья хатын-кызлары җәмгыяте тарафыннан оештырылган корылтайда Төркия, Әзәрбайҗан, Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан, Төньяк Кипр-Төрек җөмһүрияте, Төркмәнстан, Кырым, Гагауз, Гыйрак, Болгария, Румыния, Косово, Македония, Алмания, АКШ, Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Кабардин-Балкар, Тыва, Алтай, Хакассия, Дагъстан һ. б. илләрдән-төбәкләрдән (җәмгысе—32 ил) рәсми вәкилләр, хатын-кыз оешмалары җитәкчеләре, язучылар, журналистлар, сәнгатькярләр, галимнәр катнашты.

Башкортстаннан профессор Фирдәвес Хисаметдинова, Гөлнур Гөлсарина, Римма Сөләйманова, халык вәкиле Гүзәл Садыйкова, Чувашстаннан Рәисә Сәрби, Кырымның Милли Мәҗлес рәисе Мостафа Җәмилевнең хатыны Сафинар Җәмиоглу, профессор Зарема Нагаева һ. б. катнашкан корылтайда Татарстаннан язучы Фәүзия Бәйрәмова, та-

нылган татар жырчысы Гөлзадә Сафиуллина, журналистлар Әлмира Әдиятуллина, Филисә Хәкимова һәм Наилә Хөрмәтова вәкиллек итте. Корылтай эшендә шулай ук Себер якларыннан татар журналистлары Сания Мирхалиева һәм Төмәннән Гөлсинә Ниязова катнашты.

Хатын-кыз ижтимагый оешмаларына караган һәм төрки хатын-кызларын борчыган башка мәсьәләләр дә корылтайда каралды. Корылтай кысаларында төрки дөнья хатын-кызлары вәкилләре Ататөрек мавзолее урнашкан Аныткаберне зыярәт итте. Төрек парламенты Төркия Бөек Милләт Мәжлесендә очрашулар үткәрде. Татар ханымнары исә, корылтайдагы чаралардан тыш, Төркиядә яшәүче күренекле татар зыялылары—Бөтендөнья татар лигасының беренче һәм бүгенге рәисләре—язучы һәм журналист Гали ага Акыш һәм танылган җәмәгать эшлеклесе, Идел-Урал төбәгендә төзелгән Милләт Мәжлесенең рәисе Садри Максудиның оныгы, язучы һәм мөхәррир, фәннәр докторы Гөнүл ханым Пултар белән дә очрашып сөйләште.

Төркия башкаласында белем алучы кайбер татар талибәләре дә катнашкан бу очрашуда милләттәшләребез татар халкын кызыксындырган һәм борчыган мәсьәләләр турында фикерләр белән уртаклашты, төрек илендә яшәүче татар лидерлары үз теләкләрен җиткерде.

КАЗАН ҮРНӘК КҮРСӘТӘ

Казан хакимияте күпмилләтле башлангыч мәктәп ачу турында карар кабул итте. Анда грузин, әзәрбайҗан, әрмән, чуваш һ. б. телләр укытылачак.

Шәһәрдә төрле милләт балалары өчен якшәмбе мәктәбе эшләп килә иде инде. Белгечләр әйтүенчә, әлеге уку йортында белем бирү системасы мактанырлык түгел. Ярты ел саен класс яңа укучылар белән тулылана. Шунлыктан мөгаллимнәргә үткән теманы кабатларга туры килә. Якшәмбе мәктәбендә дәресләр атнага бер тапкыр гына оештырыла.

Күпмилләтле башлангыч мәктәп яңа уку елында ачылырга тиеш. Ул шәһәр үзәгендә урнашыр дип көтелә.

ЯЗУЧЫЛАР ИДАРӘСЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда иҗат оешмасының әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышын уздыру мәсьәләсе каралды. Ул 18 мартка билгеләнде.

Билгеле булганча, узган ел башында Чуваш республикасында Татар әдәбияты көннәре уздырылган иде. Быел исә безгә чуваш каләмдәшләребезнең килүе көтелә. 23-25 мартта Татарстанда Чуваш әдәбияты көннәре уздырылачак. Идарә шушы очрашуларга әзерлек мәсьәләләрен дә карады.

Проза әсәрләре, аеруча хикәя иҗат итү өлкәсендәге казанышларны билгеләү өчен Татарстан Язучылар берлеге халык язучысы Фатих Хөсни исемендәге бүләк булдырган иде. Быел ана соңгы еллардагы иҗади уңышлары өчен Камил Кәримов лаек булды.

Идарә утырышында Галиәхмәт Шаһи (Чаллы) һәм Ринат Батталов (Ижау) Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителделәр.

ЯЗУЧЫЛАР ХИСАП ТОТА

Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә хисап-сайлау җыелышы булды. Анда доклад белән бүлекнең җаваплы сәркатибе, прозаик Вахит Имамов чыгыш ясады. Фикер алышуларда язучылар Факил Сафин, Әнвәр Шәрипов, Мансур Сафин, Мирһади Разов һ. б. катнашты. Бүлек җитәкчелегенең эшчәнлеге канәгатьләнерлек дип бәяләнде. Аның җитәкчесе итеп кабат Вахит Имамов сайланды.

Җыелыш эшендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Фоат Галимуллин, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзалары: Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Шаһинур Мостафин; Татарстан мәдәният министры урынбасары, шагыйрь Илфак Ибраһимов, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, Чаллы хакимияте башлыгы урынбасары Фәйрүзә Мостафина катнашты.

СЕБЕР ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

Январь аенда бертөркем каләм әһелләре—шагыйрь Шәүкәт Гаделша, Татарстан китап нәшриятенең нәфис әдәбият редакциясе мөдире Рафис Корбан һәм "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррир урынбасары Газинур Морат составындагы делегация Төмән өлкәсендә булып кайтты. Алар анда "Янарыш" газетасы редакциясе каршында күптән түгел генә оештырылган "Әдәби Төмән" иҗат берләшмәсе чакыруы буенча барган иде.

Өлкә татарларының "Янарыш" газите (мөхәррире Азат Сәгыйтов) 1990 елдан бирле чыгып килә һәм өлкә бюджетыннан финанслана. Биредә шулай ук татарча теле-радиотапшырулар да даими рәвештә алып барыла. Төмән китап нәшриятенда махсус татар редакциясе булдырылган, һәм анда хәзерге көнгә җирле авторларның 40лап китабы дөнья күргән. Алар арасында Якуб Зәнкиев, Булат Сөләйманов, Ханисә Алишина, Изил Гарифуллин кебек, Татарстан укучыларына да яхшы таныш язучы, галимнәрнең китаплары бар.

"Әдәби Төмән"нең чираттагы утырышына да 30лап җирле автор килгән иде.

Казан кунаклары шулай ук Ямбай, Кырынкүл, Талдымхан, Каскара кебек татар авылларында булды, мәчет-мәдрәсәләрдә, мәктәп-музейларда милләттәшләребез белән очрашулар үткәрде. Кырынкүл мәктәбендәге очрашуда Төмән өлкә Думасы рәисе урынбасары Геннадий Корепанов һәм Төмән шәһәр Думасы депутаты Ришат Җиһаншин да катнашты.

Һәр очрашуда милләттәшләребез Төмән

белән Казан арасындагы элемтәләрне, әдәби, мәдәни багланышларны тагын да ныгыту зарурлыгы турында әйтте. Себер татарларының мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүдә Казан татарларының элек-электән мөһим роль уйнавын искәртте.

КАМАЛ ТЕАТРЫНДА КАМАЛ ТУРЫНДА

Үз исемен йөрткән Татар дәүләт академия театрында (төп театрыбыз инде 65 ел Галиәсгар Камал исемен йөртә) драматург Галиәсгар Камалның тууына 125 ел тулуга багышланган кичә булып үтте. Г. Камал—классик драматург, татар театр сәнгатенә нигез салучы шәхесләрнең берсе. Заманында Г. Камал турында Г. Тукай болай дигән: "Татар Островские. Милләтебезнең моңарчы беркемгә дә күренмәгән почмакларын кояш кебек якты итеп сәхнәдә күрсәтергә аның көченнән килә".

Кичә драматург Г. Камалның иҗатын халыкка янә бер искә төшерү, аның әһәмиятен яңа буыннарга төшендерү акциясе булды. Залны тутырып утырган тамашачылар алдында күренекле язучылар, сәнгать белгечләре, артистлар чыгыш ясады. "Без үзебезнең театрны милли драматургия әсәрләре белән тәэмин итеп торабыз, бездән алда яшәгән, юл салып калдырган бөекләребезнең эшен дәвам итәбез. Монда без үткәннәребезне хөрмәт итәргә өйрәнеп, аларга баш иярге җыелдык. Мин театрыбызның киләчәге тагын да яхшырак буласына ышанам",— диде Туфан Миңнуллин. Кичәдә, шулай ук, Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, сәнгать фәннәре докторы Гали Арсланов һ. б. чыгыш ясады.

Кичәдә Г. Камалның "Банкрот", "Беренче театр", "Бәхетсез егет" пьесалары буенча эшләнгән спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

ОПЕРА ОСТАСЫН ХӨРМӘТЛӘП

С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында татар опера сәнгатенең күренекле вәкиле Нияз Даутовның тууына 90 ел тулу уңаеннан, Н. Җиһановның "Алтынчәч" операсы арияләреннән оештырылган концерт булды.

Атаклы опера җырчысы, режиссер, талантлы педагог, җәмәгать эшлеклесе, Россиянең халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге премиясе лауреаты, Казан дәүләт консерваториясе профессоры Нияз Даутов татар сәнгате үсешенә зур өлеш керткән, күренекле җырчылар тәрбияләгән шәхес. Ул сәхнәдә баш партияләрне башкаручы сыйфатында ике меңнән артык чыгыш ясый. Россиянең күп кенә театрлары сәхнәләрендә 50дән артык опера куя. "Сильва" музыкаль фильмындагы роле аңа Бөтенсоюз күләмендә зур танылу китерә.

МӘХӘББӘТ ЙОЛДЫЗЛЫГЫНДА

Республика яшүсмерләр китапханәсендә "Мәхәббәт галактикасы" әдәби-музыкаль фестиваленең йомгаклау туры узды. Анда Татарстаннан 50гә якын автор-башкаручы һәм шагыйрь катнашты.

"Мәхәббәт галактикасы" шигърият һәм автор җырлары фестивале республика, күрше төбәк шагыйрьләрен һәм прозаикларын башкалабызга инде 7 нче тапкыр җыя. Сайлап алу туры узган елның ноябрендә башланган иде. Анда 200дән артык сәләтле яшүсмер катнашты, аларның иң кечкенәсе Михаил Урецкийга нибары 13 яшь. Фестивальнең финалы Изге Валентин көнендә Халыклар дуслыгы йортында үтәчәк. Йомгаклау концертында 14 иң сәләтле яшүсмер "Шигърият", "Автор җырлары" һәм "Проза" төрләрендә көч сынашачак. Тамашачылар да яратып өлгергән башкаручыларга өчен тавыш бирә ала. Шул ук көнне мәхәббәт темасына багышланган фоторәсемнәр һәм графика бәйгесе үткәрелә. Жюри әгъзалары арасында республикабызның танылган язучылары, әдәби берләшмәләр җитәкчеләре һәм үткән фестиваль лауреатлары бар. Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылачак. Ә иң яхшы әсәрләрне аерым җыентык итеп һәм матбугатта бастырып чыгару күздә тотыла.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хәзерге татар әдәбияты өлкәсендәге һәм республикада матбугат системасын үстерүдәге казанышлары өчен "Мәйдан- Чаллы" журналы баш мөхәррире **Сафин Факил Миннемөхәммәт** улына "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татар әдәбиятын һәм журналистикасын үстерүдәге казанышлары, чит илләрдәге татар иҗтимагый оешмалары белән багланышлар урнаштыру һәм ныгытудагы актив эшчәнлеге өчен Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының якын һәм ерак чит ил татар иҗтимагый оешмалары белән эшләү бүлеге башлыгы **Гыйсметдинов Дамир Минсәгыйрь** улы Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән бүләкләнде.

***

Сынлы сәнгать өлкәсендәге олы казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен рәссам **Имашев Рәшит Фатыйх** улына "Татарстан Республикасының халык рәссамы" дигән мактаулы исем бирелде.

КАЗАН ПАТШАБИКӘСЕ СӨЕМБИКӘ

Журнал тышлыгының беренче битенә игътибар белән күз салыгыз әле, кадерле укучы. Дөнья әдәбияты һәм сәнгате тарихына Яңарыш чоры дип кереп калган күтәрелеш, француз романтизмы чалымнарын гаҗәеп дәрәҗәдә оста синтезлаштырып ясалган бу рәсемдә Казан дәүләте тарихында аерым урын тоткан мәгърур ханбикәбез Сөембикә сурәтләнгән. Киндергә майлы буяу белән ясалган портреттан безгә данлы хөкемдарыбыз — дәүләт кадәр дәүләт белән идарә итә белүче кырыс һәм тотнаклы, бер үк вакытта моңлы вә гүзәл, һәр чалымында рухи көч сизелеп торган, матурлыкны гаять нечкә тоемлаучы сөйкемле ханбикәбез карап тора. Аурупа вә Азиядәге мәмләкәтләрне дер селкетеп торган госманлы төрек солтаны, Польша һәм Литва корольләре, урыс кенәзләре һәм эреле-ваклы башка дәүләтләр хөкемдарлары белән бертигез дәрәҗәдә, тарихи чордагы үз урынынны белеп сөйләшү-аңлашу өчен нәкъ менә шушындый көчле һәм затлы шәхес булырга кирәк булгандыр да. Рәссам ерак чорлардан безгә әле һаман аваз салучы, тарихи хәтеребездә өзлексез яңарып торучы Казан патшабикәсенең әнә шундый якты образын тәкъдим итә.

Бер караш ташлаудан ук күңел түрендә уелып калырлык бу рәсемнең авторы кем? Аның тагын нинди хезмәтләре бар? Нишләп без аны моңа кадәр белмәгәнбез? Табигый рәвештә күңел төбендә шундый сораулар җанлана. Ә аңа җавапны еракларданэзләргә туры килә.

Рәсемнең авторы — милләттәшебез, Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казакъстан Фәннәр Академиясе академигы, сынлы сәнгатьтә үз йөзен һәм алымнарын тудырган, күп төрле жанрларда бер үк дәрәҗәдә уңышлы һәм оста эшләүче танылган рәссам Камил Муллашев.

Камил Вәлиәхмәт улы Муллашев 1944 елның 27 октябрендә Кытай Халык Республикасының Синьцзян вилаятендәге Өремче шәһәрендә дөньяга килә. Кытайдагы сәяси чуалышлар нәтиҗәсендә кайчандыр монда килеп төпләнгән татар халкына да яшәү кыенлашканнан-кыенлаша бара һәм 1963 елда Муллашевлар гаиләсе Казакъстанга күчеп кайта. Камил 1967 елда Алма-Атада сәнгать училищесын тәмамлый, аннан соң Мәскәүдә В. И. Суриков исемендәге дәүләт сәнгать институтында, СССРның халык рәссамы Таир Салахов остаханәсендә белем ала.

Камил Муллашевның барлык иҗаты тормышка кайнар мәхәббәт белән сугарылган. "Мин бар эшне дә яратып эшлим", ди ул. Һәм шушы сүзләрдә рәссамның яшәештәге һәм иҗаттагы анык позициясе ачык күзаллана да инде. К. Муллашев сәнгатьтә үзенә бөек һәм җитди максатлар куеп эшли, ул заманыбызның һәм чал тарихның тирән катламнарын бер үк дәрәҗәдә колачлый белә торган сирәк сәнгатькәрләрдән. Әле 1980 елда ук ул "Яшьлек", "Җир һәм заман" триптихлары өчен Франция Сәнгать Академиясенең көмеш медаленә лаек була. Туксанынчы елларда К. Муллашев сынлы сәнгатьтә авангард даирәсенә үтеп керә, үзенә хас максимализм белән төрки бабаларыбызның яшәеш катламына ыргыла, аларның мәҗүси инануларын сынландыра.

Төрки антик дөньяны сурәтләү аны котылгысыз рәвештә бу цивилизациянең дәвамы булган казакъ-татар даирәсенә алып килә. Бер-бер артлы бу галәмнең символы булып кабул ителерлек "Кыпчак кызы — Ауразия", "Назарбаев портреты", "Сөембикә-ханбикә" шедеврлары туа. Бу чорда "Әтием", "Әнием" портретлары сыман әсәрләрдән башланган татар тематикасы рәссам иҗатында киң дәрья булып, ашкынып ташый башлый: "Идел агымнарында", "Казан тәхете тирәли", "Киленчәкләр", "Рәссамның алиһәләре", "Житкән кызлар серләшүе" һ. б.

Дөньякүләм абруйлы Камил Муллашев иҗаты да Б. Урманче, Ч. Әхмәров мирасы кебек үк татар мәдәниятенең алтын хәзинәсен тәшкил итә.

Тышлыкның дүртенче битендә: шагыйрә **Фәйрүзә Мөслимова.**

ЯҢА КИТАПЛАР



Фәүзия Бәйрәмова. Таралып яткан Татар Иле. Фәнни-популяр язмалар. — Казан: "Аяз" нәшрияты. 2003. — 352 бит. Тиражы — 2000 данә.

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә еш була. Соңгы берничә елда ул Оренбург, Чиләбе, Киров, Мордовия һ. б. җирләрдә булып, милләттәшләребезнең бүгенге яшәү рәвешләрен, рухи тормышларын, киләчәккә өмет-ышанычларын тирәнтен өйрәнеп нәтиҗәле иҗат итте. "Таралып яткан Татар Иле" дигән исем безнең халыкның җисеменә бик тә туры килә. Чәчелгән, сибелгән, таралган халык... Ә менә ничек бергә җыелырга, милләт булып ничек сакланып калырга? Авторны әнә шул мәсьәләләр борчый, һәм ул, үзенчә җавап табарга омтыла. Тугыз бүлектән торган ("Уралтау татарлары", "Атом тамгалы татарлар", "Аҗдаха авызында", "Кар Иле татарлары", "Саба иле серләре", "Калатауга кайту", "Ырынбур татарлары", "Дала-Тау татарлары", "Таралып яткан Татар Иле") китапның аннотациясендә әйтелгәнчә, борынгы татар тарихы, милләтебезнең бүгенге хәле, халыкка хезмәт итүче шәхесләрнең язмышлары тасвирлана.

Китап Бөтендөнья татар Конгрессы ярдәме белән чыгарылган.

Рашат Низами. Яшьлеккә хат. — Казан: "Мәгариф" нәшр., 2003. — 152 бит. Тиражы — 1000 данә.

Поэзиядә, прозада, публицистикада талантлы итеп яза ала торган каләмдәшебезнең бу китабына өч әсәр кергән: "Яшьлеккә хат" (фәлсәфи трактат), "Шәһәр өстендә акчарлак" (повесть), "Матур ялган" (хикәя). "Бу китап — яшьлек, мәхәббәт, романтика, яшәү фәне турында" дип яза автор китабының титул битендә. Шуңа өстәп, "Яшьлеккә хат" әсәренең башына "Яшь замандашым белән әңгәмәләр" дип тә куелган. "Геометрик фигуралар арасында иң тотрыклысы — өчпочмак, диләр. Нәселдәнлек, мохит, тәрбия — кешенең язмышын хәл итүче тылсымлы өчпочмак, бәлки, менә шушыдыр ул... Мин кем? Ни өчен яшим? Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә?" — ди язучы. Шуңа күрә, табигый, бу китап, беренче чиратта, яшьләргә, өлкән яшьтәге мәктәп укучыларына адресланган.

Индекс 73210

Фәйрүзә Мөслимова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)